# Фәнис Яруллин

# Әйтелми калган сүз

*Повестьлар, хикәяләр*

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2013

УДК 821.512.145-3
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Я74

Төзүчесе *Сәүия Хәкимова*

**Яруллин, Ф. Г.**

Әйтелми калган сүз : повестьлар, хикәяләр / Фәнис Яруллин ; [төз., кереш сүз авт. С. Хәкимова]. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2013. – 447 б.
ISBN 978-5-298-02392-4

Татарстанның халык шагыйре, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Фәнис Яруллинның бу китабына моңарчы җы-ентыкларга кермәгән ике повесте һәм хикәяләре тупланган. Аларда безнең заман кешеләренең уй-хисләре, үзара мөнәсәбәтләре, сөю-сөелүләре, әхлакый сыйфатлары чагылдырыла.

УДК 821.512.145-3
ББК 84(2Рос=Тат)-4

ISBN 978-5-298-02392-4
© Татарстан китап нәшрияты, 2013
© Хәкимова С. Г., төзү, 2013

## *Төзүчедән*

Фәнис Яруллин!

Бу исем менә инде илле ел әдәбият сөючеләрнең теленнән төшми. Берәүләр аның хискә, тирән кичерешләргә бай шигъриятенә; икенчеләр иң актуаль темаларга корылган мавыктыргыч сюжетлы, драматизмга, гыйбрәтле язмышларга бай прозасына; өченчеләр күңелләре бушаганчы көләрлек комедияләренә яки җаннарны тет-рәтерлек драмаларына; дүртенчеләр бүгенге көннең «яман шешенә» әверелеп баручы явызлык, комсызлык кебек сый-фатларның җәмгыятьтә һаман саен тирәнрәк тамыр җәя баруын ачучы публицистикасына; ә кемнәрдер аның балалар өчен язылган самими дә, шул ук вакытта мәгънәле дә булган, төбендә фәлсәфи фикер яткан әкиятләренә өстенлек бирер. Һәм боларның һәрберсе үзенчә хаклы булыр.

1960 еллар башында беренче шигырьләре дөньяга чыга башлауга ук, шагыйрьгә укучылардан хатлар килә башлый. Бу чорда әдәбиятка аяк баскан талантлы шагыйрь һәм әдип-ләр күп булуга карамастан, укучы Ф. Яруллинга үз күңелендә аерым урын бирә. Безнең карашка, моның сәбәпләре берничә. Беренчедән, әдипнең язмышы беркемнекенә дә охшамаган. - Башта мәктәп, аннары институт бетереп, үзенең хезмәт юлын газета яки журнал редакцияләрендә башлап җибәргән язучылардан аермалы буларак, Фәнис Яруллин әдәбиятка шак-тый ук тормыш тәҗрибәсе туплаган, зур фаҗигаләр кичерергә өлгергән шәхес булып килеп керә. Ул беренче әсәрләрендә үк үзенең эчке дөньясын: шатлык-кайгыларын, сагыш-моңнарын, уй-гамьнәрен, җиңү-җиңелүләрен, яшермичә, уку-чысына ача. Күпләр производство, зур төзелешләр, кыскасы, гигантомания белән мавыкканда, Ф. Яруллин җәмгыятьтә иң беренче шәхес язмышы булырга тиешлеген үз әсәрләре аша күрсәтә алды. Коллективизм, интернационализм сәясәте хөкем сөргән чорда аерым шәхескә, аның эчке кичерешләренә, хәтта интим хисләренә игътибарны юнәлтү шагыйрьнең кыюлыгы иде. Шуның белән бергә әдипнең гыйбрәтле язмышы да килеп кушылгач, иҗат белән янәшә шагыйрьнең язмышы бербөтен булып күз алдына килеп басты. Нәтиҗәдә Фәнис Яруллин бер-ике ел эчендә республика күләмендә генә түгел, бөтен союзда танылды. Аның китаплары Мәскәүнең төрле нәшриятларында басылды, ә алар аша чит илләргә дә чыга башлады.

Әдипнең иҗаты күпкырлы һәм киң колачлы. Ул – алт-мышынчы еллар башында иҗат итә башлаган каләмдәшләре арасында иң зур популярлык казанган һәм әле дә халык мәхәббәтен югалтмаган язучыларыбызның берсе. Популярлык иҗатның сыйфатын, кыйммәтен бәяләгәндә төп критерий булып саналмаса да, киң катлам укучының мәхәббәтен казану һәм шушы мәхәббәтне илле елга якын саклап килү талант үзенчәлегенә һәм аның шәхесенә барып тоташа дип әйтә алабыз. Кайбер язучы һәм шагыйрьләр, зур шәхес булып өлгергәнче, шактый озын иҗат юлы узалар. Андыйларның әсәрләрен укыйлар, ә авторларын истә калдырмыйлар. Чөн-ки андый авторларның иҗатлары шәхесләреннән аерыла. Ә Фәнис Яруллинның әсәрләрендә аңлы, бай интеллектлы, уйланучан укучы әдипнең кабатланмас яз-мышын, шул авыр язмышны сыкранмый-сыктанмый күтәреп баручыны, алай гына да түгел, шушы язмышның үткен тырнакларыннан ычкыныр өчен бөтен көчен куеп, рухи биеклеккә омтылучан олы шәхесне күрә алды.

Билгеле, шагыйрь һәм әдип һәр әсәрендә үз язмышы турында гына язмады. Ул халыкның, милләтнең сулышын тоеп, әсәрләрен үзенең кайнар каны, тынгысыз һәм серләргә бай җанының лабиринтлары аша уздырып, кырыс чынбарлык белән бай фантазиясен кушып иҗат итте. Әгәр ул тормыш чынбарлыгын ничек бар, шулай язса, укучылар аның әсәрләреннән бик тиз туярлар иде.

Татарстанның халык шагыйре, Г. Тукай исемендәге Дәүләт һәм М. Җәлил исемендәге Республика премияләре лауреаты, «Халыклар дуслыгы ордены» кавалеры, Атказанган мәдәният хезмәткәре Фәнис Яруллин әдәбият мәйданына шигърияте белән килеп керде. Аның беренче шигырьләрендә яшәү мәгънәсен эзләү, матур эш-гамәлләрең белән кешеләргә кирәкле булу, күктә ак юл сузып үткән самолёт кебек, үзеңнән соң якты эз калдыру кебек мотивлар чагылды. Башта ук шуны искәртеп китү урынлы булыр: Ф. Яруллин һәрвакыт алдына зур максат, изге бурыч куеп эшләде. Үз-үзенә, иҗатына карата булган аяусыз таләп яшь авторны гел алга, яңа эзләнүләргә өнди. Аңа ике зур максатка берьюлы ирешергә кирәк була. Беренчедән, физик көчсезлектән – армиядә алган имгәнү нәтиҗәсендә рухи көчкә буйсынырга теләмәгән гәүдәгә бераз гына булса да хәрәкәт кертү юлларын табарга, икенчедән, табигать тарафыннан салынган йөгерек уй, үткен образлы тел, халык тормышын белү кебек сыйфатларны эчтә яшереп яткырмыйча, аларны иҗатның серле чишмәсенә әверелдереп, күкрәктән этеп чыгарырга кирәк. Әмма бу җиңел эш түгел. Яшь автор беренче әсәрләрен язганда ук моның шулай икәнлеген аңлый. «Иҗат эше йод-рык белән таш ватудан да кыенрак икән. Кулыңда көч бар икән, таш ватарга була. Ә менә йөрәгеңдә көч барын белә торып, шуны тышка чыгара алмау – газап. Ташны йодрыкка кыссаң, бер тамчы булса да су чыга, ә башны күпме кысма, шигырь чыкмаска мөмкин»*.

Алтмышынчы еллар башында иҗат юлына басып, үзен-чәлекле, кабатланмас тәрҗемәи хәле белән әдәбиятка шигырьләре аша килеп кергән әдип параллель рәвештә әдәбиятның башка төр жанрларына да мөрәҗәгать итә.

Югары эстетик зәвыкка ия булган күпкырлы талант иясе Ф. Яруллин нинди генә жанрда язмасын, үз әсәрләрендә матурлыкны, камиллеккә омтылышны һәм рухи байлыкны иң зур кыйммәтләрдән санады. Үзенең укучыларына да шушы идеяне ирештерергә омтылды. Әдип иҗатында табигать образы еш кулланыла икән, әлбәттә, ул фон өчен генә түгел, ә

матурлыкны кеше белән табигатьнең гармониясе аша сурәтләү өчен алына. Кеше һәм табигать – бербөтен. Шушы бөтенлек саега башлаган күңел байлыгын тулыландыра, аңа бизәкләр өсти. Тау, елга һәм чишмәләр, урман-кырлар, чәчәкле болыннар, кояшлы, айлы, йолдызлы күкләр; җил-давыллар, кар-бураннар, болыт һәм яшеннәр; чиксезлек һәм кешенең үзенә генә билгеле булган микродөньясы – болар әдипнең яратып кулланган образлары. Табигать төрле халәттә, төрле төстә булган кебек, әдип әсәрләрендә дә мондый халәтләр җанның бөеклеген яки түбәнлеген, хисләрнең төрлелеген, кичерешләрнең катлаулы яки тирәнгә яшерелгән икәнлеген күрсәтү өчен кирәк.

Шагыйрь үз әсәрләрендә Вакыт һәм Чиксезлек төшен-чәләрен бик табигый рәвештә кертеп җибәрә. Бу аның әсәр-ләренә киңлек, биеклек кенә өстәп калмый, образлар эченә төренгән фәлсәфи фикерләрне ачарга, аларны җирдән биеккәрәк күтәрергә ярдәм итә.

Поэзия жанрының кече төренә керүче шигъриятькә генә түгел, поэмалары белән дә Фәнис Яруллин үзен танытты. «Нәсел агачы», «Ак үлем», «Коткарыгыз», «Гүзәл зат» кебек эпик планда иҗат ителгән әсәрләре галимнәрнең өйрәнүен көтә. Һәм формасы, һәм күтәргән проблемалары, – аларның чишелеше, кыскасы, нинди аспекттан гына чыгып карама, – аларда моңарчы безнең татар шигъриятендә күтәрелмәгән яки бик өстән генә чагылып үткән вакыйгалар ята. «Нәсел агачы»нда Әфган сугышының безнең халкыбызга нинди афәтләр алып килүе хакында сурәтләнсә, «Гүзәл зат» поэмасы сатирик формада язылган. Хәзерге ялган демократиянең җәмгыятьне упкынга сөйрәвен гипербола алымы белән чагылдыруы кызыклы.

Ф. Яруллин иҗатында табигать күренешләре катлауландырылган метафоралар, чагыштыру, параллель кую яки капма-каршылык (антитеза) рәвешендә бирелсә, халык традицияләре, әхлак проблемалары җанны тетрәндерерлек вакыйгалар эчендә сурәтләнә. Төрле жанрларда иҗат итүче әдип буларак, аның хикәя, повесть һәм кайбер драма әсәрләренә игътибарны юнәлтү урынлы булыр. Автор «Тәрәзәгә кунган күбәләк», «Сандугач оясы», «Курку», «Рәнҗү» һ. б. хикәяләрендә хәзерге заманның характерлы проблемаларына әйләнеп баручы әхлаксызлык, халкыбызда булган матур традицияләрнең – кешелеклелек, ата-ананы зурлау, үз гаебеңне тану кебек матур сыйфатларның югала баруы өчен борчыла. Олыны олы, кечене кече итеп карау, авыр чакта бер-береңә ярдәмләшү – безнең халкыбызны үзеге нык булган милләт итүдә зур роль уйнаган сыйфатларның берсе. Күп кенә күркәм гадәтләребез онытыла яки башка халыкларның традицияләре белән катнашып, татар халкындагы кыйммәтле сыйфатлар башлангыч чордагы сафлыгын югалта бара. Кешеләрдә хөсетлек, бер-берсеннән көнләшү кебек яман сыйфатлар өстенлек ала башлады. Бу хәл совет чорында бер төрле сөйләп, икенче төрле эшләү, ягъни ялганга корылган идеология тәэсирендә башланган иде. Ф. Яруллинның «Әнә килә автомобиль», «Бай эти», «Койрыксыз сандугач» һ. б. комедияләрендә (ә бит боларның беренчесе 1974 елда ук сәхнәгә куела) үз туганыңнан да көнләшү, байлыкка табыну, этиләренең акчасын һәр бала бары тик үзенә генә тиешле дип санау матур традицияләребезнең инде күптән бозыла башлавын күрсәтә. Номенклатур катлаудагы кайберәүләр урлашты, алдашты, халыкны хәерчелектә тотып, үзенә буйсындырырга теләде. Җәмгыятьнең барлык өлкәләренә таралып өлгергән бу афәт формация алышыну белән юкка чыкмады, киресенчә, тагын да киңрәк мәйданга таралды. Хәзер инде урлашу үзе бер батырлыкка әйләнде. Халкыбыздагы батырлык төшенчәсе дә астын өскә әйләндереп куелган баскыч хәленә төште. Әдипнең «Җимерелгән хыяллар» пьесасында бу проблема кискен куела. Үз теләге белән укып, очучы һөнәрен алган Мансурны Таулар иленә бомба яудырырга җибәрәләр, һәм ул үзенә йөкләтелгән вазифаны шатланып, тырышып башкара. Нәтиҗәдә аңа Герой исеме бирелә. Ул, бик горурланып, сыйныфташлары белән очрашуга кайта. Ләкин элекке дуслары аны үз араларына кертмиләр. Чөнки ул әлеге исемне дошманга каршы сугышып түгел, ә тыныч халыкны, ирек сөйгән һәм шул үз иркен, үз азатлыгын саклау өчен көрәшкә күтәрелергә мәҗбүр булган халыкны юк итү, йортларын җимерү бәрабәренә алган. Мансур үзен үзе атып үтерергә омтылып карый, ләкин пистолеты да аны тыңламый. Автор үзенең героен әнә шундый тетрәндергеч вакыйгалар аша гомерлек хурлык эчендә калдыра.

Әхлагыбыз бозылу «Яралы язмышлар» повестенда да калку сурәтләнә. Яңа гына туган нарасыен чүплеккә ыргыту яки аны тудыру йортында калдырып китү – татар халкында гомердә булмаган хәл. Хәтта совет чорында да ятим сабыйларны гына балалар йортына урнаштырганнар. Хәзерге ялган демократияне халык теләсә нәрсә эшләргә ярый дип кабул итте. Шуның нәтиҗәсендә ата-аналы ятимнәр артты. Ф. Яруллинның бу повесте татар, рус һәм инглиз телләрендә басылып чыгуы белән укучылар контингентын һәм аның таралу географиясен янә киңәйтеп җибәрде. Бу әсәре белән Ф. Яруллин тагын бер кат әхлакый батырлыкның (Миңлегөл образы аша) сугыштагы яки хезмәттәге батырлыктан ким булмавын күрсәтте.

Фәнис Яруллин, талантлы шагыйрь, прозаик, драматург, балалар язучысы булу белән бергә, яшәешнең барлык проблемаларын күрсәтүче, иҗтимагый-сәяси хәлләргә нәкъ үз вакытында объектив бәя биреп баручы публицист та иде. Соңгы елларда язылган «Вакыт уза безнең йөрәк аша», «Таркалу», «Төшәбезме, күтәреләбезме?», «Кысылабыз, буылабыз» һ. б. мәкаләләрендә әдип бүгенге көн вакыйгалары тудырган мәсьәләләрнең кискенлеген һәм аларны чишмәгән очракта нинди хәлдә калачагыбызны үтемле мисаллар ярдәмендә дәлилли.

Мәсәлән, «Төшәбезме, күтәреләбезме?» исемле мәкаләсе әдәби процессны киң колачлап күрсәтүе белән аерылып тора. Кайбер тәнкыйтьчеләр совет заманында язылган әсәр-ләрнең күпчелеген кире каккан бер чорда Ф. Яруллин ул

вакытта да татар әдәбиятында дөньякүләм данланырлык әсәрләр булганлыгын раслый (Г. Бәширов. «Намус», К. Нәҗми. «Язгы җилләр», М. Җәлил. «Моабит дәфтәрләре»). Әлеге күләмле мәкаләсендә әдип әдәбиятта дәвамчылык дигән төшенчәнең барлыгын искә төшерә. Кайвакыт без үзебез-нең элгәрләребезне онытып җибәрәбез. Ә бит безнең әдәбия-тыбызның көче, олылыгы буыннар чылбырының нык-лыгыннан килә. Ф. Яруллин Татарстан Республикасында 2006 елның Әдәбият һәм сәнгать елы итеп игълан ителүенә үзенең уңай мөнәсәбәтен белдерә һәм татар халкын дөнья аренасына чыгару юлларын күрсәтә.

«Без халкыбызның рухи байлыгын, гореф-гадәтләребез-нең матурлыгын, әхлагыбызның сафлыгын әдәбиятта һәм сән-гатьтә чагылдыру юлы белән генә татар исемен югары күтәрә алабыз. Бу ел безнең халкыбыз өчен интеллектуаль үсеш елы булсын һәм шушы үсешебезне без дөньяга күрсәтә дә алсак иде. Безнең әдәбиятыбыз гасырларны иңли торган әдәбият. Халкыбыз, төрле җиңү һәм җиңелүләргә дучар булуга карамастан, үзенең интеллектуаль көчен, иҗади сәләтен буыннан-буынга бирә барган. Һәм менә шушы зыялы дәвамчылык дәүләтебезне югалтканда да, милләтебезне, телебезне, үз традицияләребезне югалтмаска ярдәм иткән. Әдәби әсәрләр аерым кешеләрнең хезмәте белән туа. Ул кешенең исеме һәм милләте була. Ә машиналар, нефть чыгарулар алар зур коллектив белән эшләнә. Шуңа күрә монда нинди генә уңышка ирешмә – милләтләр коллектив эчендә эреп юкка чыга», – дип язды ул.

Ф. Яруллин шулай ук үзенең каләмдәшләре иҗатына да игътибарлы булды. Аның «Көн сулышы» һәм «Вакыт елгаларын кичкәндә» дигән китапларында күп кенә әдипләрнең һәм башлап язучыларның иҗатларына объектив бәя бирел-гән мәкаләләре урын алган.

Йомгаклап шуны әйтергә мөмкин: әдипнең үзенчәлеге – тирәнтен фикер йөртеп, гап-гади тоелган тормышыбызда бик күп матурлыклар, тирән фәлсәфәләр, катлаулы вакыйгалар яшеренеп ятуын чын рәссам каләме белән сурәтләп бирә белүдә. Ул гади кешеләрнең күңелләрендә йөреп тә, аларны тышка чыгара алмаган гыйбрәтле вакыйгаларны, тет-рәндергеч язмышларны, беренче карашка сәер күренгән кешеләрне әсәрләренә герой итеп алып, аларның күңел төп-ләрендә яшеренеп яткан энҗеләрен күрсәтте һәм шулар-дан чын сәнгать әсәрләре тудырды. Аның иҗаты татар әдә-биятында үз урынын, үз укучысын тапты.

Ф. Яруллинның укучыларга тәкъдим ителә торган бу китабына дистә еллар дәвамында язылган, ләкин аерым җы-ентыкларга кермәгән ике повесте һәм хикәяләре тупланды. Аларны укучылар әдипнең әйтергә теләп тә, үзе исән чагында әйтергә өлгерә алмый калган сүзе буларак кабул итсеннәр иде.

*Сәрия Хәкимова*
*филология фәннәре кандидаты*
*2012*

## ТАМЫРЛАР

Зөлфия белән Рәсим, игезәкләр кебек, бергә үстеләр. Аларның авылы Ташлыяр дигән зур авылның бер бистәсе санала иде. Нибары егерме бер йорттан торган Баланлы авылы искиткеч матур җиргә урнашкан: бер ягында җиләкле, баланлы аланнары белән дан казанган урманы, икенче ягында башлары белән болытларны сөзеп утыручы таулар. Тау итәгендә чишмә агып ята, ә бераз түбәндәрәк – яр читләре таллар белән каплап алынган тирән күл. Авыл элек егерме бер йорттан торган чакта, бала-чагаларны күл янына җибәрмиләр иде. Имеш, ул күлдә ниндидер күзгә күренми торган җан иясе яши, үзенә якын барганнарны суыра. Бик көчлеләр генә аннан чыга. Ләкин исән-сау чыкканнар да тамыры киселгән агач кебек корый, ә тора-бара ниндидер өрәккә әверелә икән. Тау куышларында шул өрәкләрнең вакыт-вакыт туйлары була, андый чакларда урманнарга, тауларга бармавың хәерлерәк икән.

Зөлфия белән Рәсим бүген шул күл буена килделәр. Икесе дә яңа гына университет бетереп кайттылар. Ке-сәләрдә – диплом, йөрәкләрдә – ашкыну. Кайчандыр алар, өлгергәнлек аттестаты алгач та, шушында килгәннәр иде. Бу күл аларның яшьлек хатирәләрен үзенең иң тирән төпкелләренә яшереп саклый.

– Хәтереңдәме, син, мине куркытыр өчен, шушы күл-гә чумган идең.

– Хәтеремдә. Ләкин мин анда сине куркытыр өчен түгел, ә күлдәге өрәкне күрергә дип чумдым.

Хәзер алар ул көннәрне сүзгә-сүз искә төшереп алдылар...

– Минем бу күлдә коенып карыйсым килә, – дигән иде Зөлфия, Рәсимне котырткандай. – Шушында чумып чыксам, чибәр кызга әверелермен кебек.

– Юләрләнмә, теге өрәк эләктерсә, – диде Рәсим.

Зөлфия аның сүзләрен кулъяулык селкегәндәй сел-кергә тотынды:

– Өрәк, җен-пәриләр, су аналары, тагын әллә кем-нәр – юк нәрсәләр.

– Минем үземнең күргәнем бар аларны.

– Кайда?

– Каймалы базарында.

– Әкият! – Зөлфия көлә башлады.

– Көлмә кешедән – авызың өшегән.

– Өшесә соң! Шул өшегән авызны ничек бер үбәргә икән, дип кызыгып торасың бит әле.

– Тезләнеп ялынсаң да үпмим мин сине. Синең кебек кычыткан чыпчыклары беткән ди.

Алар шулай һәрвакыт төрткәләшеп алырга яраталар иде. Рәсим бераз тәкәбберрәк. Егетнең шул гадәтен белгән Зөлфия аңа үртәү сүзләре яудыра гына:

– Ярар, иптәш Камыр батыр. Мин чишенә башлыйм. Читкәрәк кит.

– Китми генә торыйм әле.

– Алайса китмә. Син бит койма ярыгыннан да мине күзәтеп йөрисең.

– Кычыткан чыпчыгын койма ярыгыннан күзәтәсе юк. Алар урман тулы.

– Мин авылда бердәнбер.

– Дөньяда һәркем бердәнбер. Беркемнең дә копиясе юк.

– Чуар чыпчыкның канаты бар: очты-китте булыр.

– Кем алдарак очар әле, – диде Рәсим.

– Алайса, син очарга әзерләнә тор. Мин күлдә коенып чыгам.

Зөлфия, Рәсимне үрти-үрти, әкрен генә чишенә башлады.

– Коену костюмыннан керимме икән, әллә ялангач кына чумыйммы?

– Ялангач кына чум, син бит аннан барыбер чык-маячаксың. Ичмасам, коену костюмың әрәм булмас.

– Янымда Камыр батыр торганда курыкмый чумам, коткарырсың әле.

Рәсим, кызның соңгы сүзләрен ишетмәгәндәй, Зөл-фиягә карап катты: бөтенләй чишенерме икән? Гәүдәсе сылу чукынчыкның. Чыпчык күкәе кебек чуар йөзен күр-мәсәң, кочарга да мөмкин булыр иде.

Зөлфия, егетне үртәп, лифчик төймәләрен юри бер ычкындырды, бер төймәләде. Рәсимнең авызыннан сулар килә башлагач кына каптырып куйды. Ләкин болай озак торырга ярамый иде, юкса кызның үзенең күңеленә дә шом шәүләсе керүе бар. Чумарга икән чумарга! Бәлки, чынлап теге өрәк очрар.

Ул текә яр читенә килеп басты.

Зөлфия бу минутта үз халәтен үзе дә аңлап бетермәде: үзенең кыюлыгын сыныйсы килә идеме, легендаларга ышанычы көчле идеме – белмәссең. Бәлки, аның Рәсимне сынап карыйсы килгәндер: нишләр икән? Зөлфия бата башласа, коткарыр өчен суга ташланырмы? Авыр чакта дус итеп аңа таянырга буламы? Юк, сәбәп боларда гына

түгел. Зөлфия уйлавынча, кеше һәр көн үзенең кеше икәнлеген раслап яшәргә тиеш. Моның өчен батырлык эшләү мәҗбүри түгел. Эш беләнме, берәрсенә күрсәткән яхшылыгың беләнме, башкалар арасында үз-үзеңне тотышың беләнме – анысының әһәмияте юк. Ничек кенә булмасын, син җирдә яшәвеңне, үзеңнең бердәнберлегеңне, ягъни бүтәннәрдән кай ягың беләндер аерылып торуыңны раслап яшәргә тиеш.

Текә ярдан тирән суга карап озак уйланып торды Зөлфия. Әгәр шушы мизгелдә Рәсим, килеп: «Кирәкми, Зөлфия, ташла бу уеңны», – дисә, бәлки, ашкынган җанын тыеп калыр, бәлки, тагын да хәтәррәк нәрсә эшләп ташлар иде. Ләкин Рәсим, кызны тыеп каласы чакта, киресенчә, аңардан читкәрәк китте. Рәсимнең читкә китүе Зөлфияне ярсытты гына. Ул бераз артка чигенде дә, кинәт чабып килеп, текә ярдан суга сикерде.

– Җүләр тәре! – диде Рәсим, авыз эченнән мыгырдап. – Күлгә түгел, башың белән таудан түбән сикерсәң дә, мин сине яратмаячакмын. Дөньяда бүтән бер кыз булмаса да яратмыйм, яратмыйм, яратмыйм! – дип, күлгә таба карап кычкырды егет.

Шулвакыт Рәсимнән ерак түгел бер талга ниндидер кош кунып, талпына-талпына сайрарга тотынды. Рәсимгә ул: «Яратасың, яратасың», – дип әйтәдер кебек тоелды.

Кыз күлгә чумуга, Рәсимнең күңелен ниндидер курку бозрасы кысып алды. Юк, бу кыз өчен курку түгел, ул үзе өчен курыкты. Әгәр шушы чумудан чыга алмаса, коткармагансың, дип, Рәсимнең күзен ачтырмаячаклар. Иң яхшысы – тизрәк моннан таю!

Рәсим, үзеннән бернинди эз калдырмас өчен, килгәч тә салып тал ботагына элгән күлмәген алды. Үзенең күзләре гел күлдә. Зөлфия калкып чыкмаганмы?

Кабаланып көткәндә, вакыт бик әкрен уза шул. Зөлфия күлгә чумганда Рәсим сәгатенә карамаган иде. Инде бик-бик озак булды шикелле. Шул гомер кеше су астында тора алырга тиеш түгел. Димәк, «күлнең иясе бар икән» дигән сүзләр дөрес. Зөлфияне күл иясе эләктергәндер.

Рәсимнең йөрәге телгәләнде. Күзләреннән яшьләр атылып чыкты. Никадәр теләсә дә, ул күл буеннан китә алмады.

Хисләр өермәсендә бөтерелеп нишләргә белми яр читендә таптанып йөргәндә, еррактан: «Һәй-әй!» – дип кычкырган тавыш ишетелде. Бу Зөлфия тавышы иде. Рәсимгә җан керде. Ул, курка-курка, күлгә карады. Зөлфия ярдан бик ерракта иде. Ул, аркасына яткан килеш, әкрен генә ярга якыная башлады. Рәсим яр өстендә әрле-бирле йөренде.

– Тизрәк, Зөлфия, тизрәк! Юкса туңасың.

Зөлфия әллә аның сүзләрен ишетмәде, әллә егетне үртәр өчен, яңадан суга чумды.

– Батырлыгын күрсәтә инде, җүләр кызый.

Рәсим биек яр өстендә, үз-үзенә сөйләнеп, кызның күлдән чыкканын көтте. Ниһаять, Зөлфия бөтенләй көтелмәгән яктан килеп чыкты. Ярга менгәндә, аның аяклары, коену костюмнары ләмгә пычранды.

– Уф! – диде ул, ярга менеп җиткәч. – Күрдем бит мин теге өрәкне. Күлнең тамырларына эләгеп, тыным бетә башлагач, өрәк мине кулы белән өскә күтәрде.

– Ниндирәк нәрсә иде соң ул?

– Синең төсле кыяфәтсез нәрсә иде инде.

– Минем кебек булгач, син аның белән үбешеп ят-кансыңдыр әле.

– Синең кебек булса, мине коткармас, киресенчә, батырыр иде ул.

Алар шулай үртәштеләр.

– Мине куркытыр өчен чумдың бит син.

– Курыктыңмыни?

– Курыктым шул.

– Мин үзем дә курыктым, – диде Зөлфия, кичереш-ләрен яшермичә. – Суга чуму белән, аяк-кулларны нидер урап алды. Куркуымнан беләгемне канатканчы тешләдем. Күзне ачып карасам, мине күлнең тамыры урап алган икән.

– Нәрсә? Нәрсә?

– Күл тамыры.

– Нинди тамыр?

– Күл тамырлары белән җиргә тоташкан икән.

– Әкият сөйләмә.

– Ышанасың килмәсә ышанма. Әмма дә ләкин күлнең тамырлары бар!

– Шул арада син ничек күлнең тамырларына кадәр күрә алдың?

Зөлфия, аның сүзләрен ишетмәгәндәй, үзенекен дәвам итте:

– Дөньяда бөтен нәрсәнең тамыры бар. Яшен дә озак яшьнәми, тик тамырларын болытларга җәеп өлгерә.

– Ярый, – диде Рәсим, аның белән килешеп. – Син туңгансың, пычрангансың. Юынып, коры киемнәреңне ки. Юкса салкын тидерерсең.

– Ә син читкәрәк кит.

– Һаман куасың. Күз тияр дип куркасыңмы әллә?

– Тияр дә. Мин бит авылда бердәнбер чуар чыпчык.

– Синең кебек чуар чыпчыклар белән бөтен кычыткан арасы тулган.

– Алайса, берәрсен тотып алып кил. Карарбыз, минем кебек матур микән?

– И Аллам, синең кебек булсалар, чыпчыклар хурланып үләр иде.

– Алайса, мин бердәнбер булып калачакмын. Минем кебекләр гасырга бер генә туа.

Рәсим кызның шаяруларын кабул итә алмады. Ул үпкәләгән кыяфәт белән читкә, таллар арасына кереп кит-те.

Кыз ярның сөзәк җиренә барып юына башлады. Рәсим тал арасыннан бөтенесен күзәтеп торды. Кызның «өлгергән алмалар»ын күргәч, тәне калтырый башлады. Ул кызга ташланудан көчкә тыелып торды. Ә тыелу авыр хәл икән. Тәннең бөтен күзәнәкләре уяна. Җан йөгәннән ычкына. Хисләр өермәсе сине, җирдән югары күтәреп, үзенең сихри канатларында кыз янына илтеп куярга тели. Йөрәк икеләтә-өчләтә катырак эшли башлый. Рәсим Зөлфияне үзләренең койма ярыгыннан күзәткәндә дә шундый халәт кичерә. Ни соң бу? Ул Зөлфияне яратмый бит. Хәтта кайвакыт аны тотып кыйнардай була. Ә үзе Зөлфия озаграк күренми торса кәефсезләнә, тиктомалдан ачуы килә башлый.

Зөлфия киенеп Рәсим янына килгәч, егетнең дер-дер калтыравын күрде.

– Карале, син үзең туңгансың бит.

– Ә-ә, әйе шул. Нишләптер калтырата башлады.

– Кил, җылытам. – Зөлфия Рәсимне үзенең кайнар кочагына кысты.

Кызның күкрәкләре үз күкрәгенә terәлгәч, Рәсим кызыша башлады. Алар күпмедер шулай кочаклашып тордылар. Зөлфия үзенең кендек астына ниндидер каты нәрсә төртелгәнен сизгәч кенә, сискәнеп, егетне этеп җибәрде. Рәсим, оялып, башын түбән иде.

– М-м-мин, – диде ул, – ялгыш кына...

– Ышанам, – диде Зөлфия, – кайчагында ялгыш кына әллә нишләп ташлыйбыз шул. Әйдә киттек. Ялгышларга юл куймыйк.

Саубуллашканда, Зөлфия:

– Мәскәүгә кайчан китәсең? – диде.

Егет башка уйларга чумып бара иде, Зөлфиянең сүз-ләреннән уянып киткәндәй булды:

– Мәскәүгә? Ә-ә, әйе, җыенам инде. Документларны Зөлкарнәй абыйга җибәрдем. Ул кирәкле кешеләргә тапшырыр.

– Әйе, синең эшләр майлаган кебек бара. Абзагыз университетта укыткач, сине җитәкләп кенә алып кереп китәр инде.

Кызның бу сүзләре Рәсимнең күңелендәге мактану хисен кабартып җибәрде. Күкрәге һава тутырылган шар йөрткән кебек кабарды, хәтта тыны кысылып куйды.

– Безнең Зөлкарнәй абый университетта бик зур кеше. Күпләрне кертте инде ул Мәскәү университетына. Син кая кермәкче?

– Күпләргә булышкач, мине дә кертер әле. Абыеңа, бу минем яраткан кызым, мин аннан башка тора алмыйм, диярсең.

– Кем ярата әле сине?

– Син бит мине яратудан йоклый алмый ябыгып бет-тең.

Кыз Рәсимнең юанлыгына төрттереп әйткәнлектән, егет үпкәләде.

– Әй, синең белән сөйләшкәнче!

Рәсим, капкаларын шартлатып ябып, өйләренә кереп китте. Кызның болай ачуланышып аерылышасы килми иде. Ул кинәт: «Ай, аягым!» – дип кычкырды. Капка артында торган Рәсим, йөгереп, урамга чыкты.

– Әллә аягыңны каймыктырдыңмы? – диде ул.

– Шулай сыман шикелле.

– Кайсы җире авырта? – диде Рәсим, кыз алдында иелеп.

– Менә монысы. – Кыз уң аягының тез турысын күр-сәтте.

Рәсим Зөлфиянең аягын сыйпый башлады. Аның күңелендә өр-яңадан хисләр дулкыны кузгалды. Бу юлы максат бик якын кебек. Әнә ничек, Рәсимнең кулы кагылган саен, Зөлфия дерт итеп куя. Бәлки, ул да «шуны» көтәдер. Ә Рәсимнең куллары торган саен өскәрәк күтәрелә. Ул инде «сандугач оясы»на кадәр килеп җитә язган иде, ләкин Зөлфия сикереп торды да:

– Ах, менә син нинди икән! – дип, аягыннан төшкән туфлие белән Рәсимгә тондырды.

Зөлфиянең юри егылганын Рәсим шунда гына аңлады. Тик үпкәләгән булып:

– Кыланчык! Үзең котыртасың, әллә минем җаным юкмы?

– Кайда соң ул синең җаның? Җаның булса, мине, күтәреп, әнә теге тауга алып мен.

– Бәләкәй чакта бик күп алып мендем инде.

– Бәләкәй чакта мин дә үзебезнең алабайны күтәреп менә идем.

Аларның күз алдыннан яшен булып үсмер чаклары сызылып үтте. Тауларга менүләр, җиләккә йөрүләр, чикләвек җыюлар. Зөлфия иң кызыл, иң өлгергән җиләк тапса, Рәсимгә: «Күзеңне йом, авызыңны ач, җиләк салам синең тубал авызыңа», – дип, Рәсимне үрти. Беркатлы Рәсим аңа ышана: күзләрен йомып, авызын ача. Ә Зөлфия малайның авызына пешмәгән шомырт яки аю җиләге сала да үзе тиз генә куак арасына поса. Рәсим, кызга үпкәләвен онытып, аны эзли башлый. Ромашкалы күлмәк Зөлфияне табигать белән бер итә. Кайвакыт Рәсим аны шунда ук күреп ала, ләкин бөтенләй икенче якка китеп эзли. Эзләү озаккарак китсә, Зөлфия качкан урыныннан чыга һәм көмеш кыңгырау тавышы чыгарып көлеп җибәрә. Аның көлүенә Рәсим кушыла. Алар, юк кына нәрсәдән кызык табып, көне буе урманда йөриләр.

Кайвакыт Зөлфия, әллә чынлап, әллә шаярып: «Уф, арыдым. Бүтән бер адым да атлый алмыйм», – дип, чәчәкле болынга сузылып ята. Рәсим: «Әйдә минем аркага атлан», – дип, кызга таба иелә. Зөлфия Рәсимнең, муеныннан кочып, аркасына атлана. Рәсимнең адымнары әкренәйсә: «Әйдә, бахбай, ялкауланма», – дип, берәр үләнне чыбыркы итеп, «бахбаен» куалый. Рәсим кызны атландырып озак бара алмый, җиргә тәгәри.

Үзләре үсә барган саен, уеннары төрлеләнә. Кайвакыт алар, качышлы уйнаганда, бер-берләрен чынлап югалталар. Табышкач, чын-чынлап сөенәләр. Зөлфия аеруча кызыксынучан. Ул бүре өннәренә кереп чыгарга да курыкмый. Ә кайвакыт алар кичләрен капка төпләренә чыгып утыралар. Аларны йолдызлар күтәреп ала. Зөлфия белән Рәсимнең балачак эзләре йолдызларда кала.

* * *

Көннәрдән бер көнне Ташлыяр авылында колхоз рәисе булып эшләүче Сәлахов Баланлыга менеп төшәргә булды. Егерме бер генә йорттан торган бу авыл, үзе бер колхоз булып, матур гына яшәп ята икән. Йортлар төзек, игеннәре дә уңа. Ә Ташлыяр кырларында гомер буе икмәк уңмады.

Бу хәлне төзәтергә кирәк, дип уйлады ул һәм Баланлыдан районга элдертте. Район җитәкчеләре башта моны кирәкмәгән бер мәшәкать дип санасалар да, Сәлахов аларга, кайчандыр партия авылларны эреләндерү турында карар кабул иткән иде, бу карарның әле дә гамәлдән чыкканы юк, дигәч, уйлап карарга булдылар. «Партия» сүзеннән уттан курыккандай куркып яшәүне күңелләреннән чыгарып ата алмаган җитәкчеләр, уйлый торгач, Сәлаховка Баланлыны Ташлыярга кушарга рөхсәт бирделәр. Кулына рөхсәт кәгазе кергәч, Сәлахов эшне коры тотты. Башта ул Баланлыдан Ташлыярга килеп эшләп йөрүче тракторчыларның өен күчертте, аннары пенсионерларныкын. Пенсионерлар каршы төшеп маташа башлагач, Баланлыга сузылган утны өздертте, алай да кайберәүләр буйсынмагач, пенсияләрен Баланлыга илттерми башлады. Күрше-тирәгә дә көч-хәл белән кереп йөргән карт-коры Ташлыярга кадәр пенсиягә бара алмый иде. Күченергә мәҗбүр булдылар. Тик Сәлахов күпме генә тырышмасын, Зарифулла белән Фатих Ташлыярга күчүдән баш тартты. Фатих әле яңарак кына Ташлыярда инженер булып эшли башлаган иде. Аның күченергә теләмәвен белгәч, Сәлахов акырына-бакырына башлады:

– Нәрсә, тамагың туйдымыни? Әгәр беләсең килсә, университет ректорына хат язып, сине Ташлыярга мин кайтарттым.

– Рәхмәт инде, бик зур эш эшләгәнсең, юкса ачтан үлгән булыр идем. Әнә минем белән укыган Расих Үзбәков нефтьчеләрнең автопаркында «ачтан үлеп» ята. Хезмәт хакы бик кечкенә булгач, «Волга» машинасында йөреп интегә. Икенче дустым Төмән якларында илле меңгә эшләп җәфалана. Ә мин монда уч тутырып сигез йөз алам. Машинам да егерме ел йөреп нык сыналган «Москвич». Баралмый да, таралмый да.

– Ах син, сволочь, бу сүзләреңне син бит колхозны күз алдында тотып әйттең.

– Дөрес аңлагансың, иптәш Сәлахов. Кайвакыт сезнең аңга да нидер барып җитә икән.

– Җитте! Бу сүзләрең өчен, Сталин заманасы булса, сине хәзер үк стенага терәп атарлар иде.

– Сталин заманнарын сагынасыңмыни? – диде Фатих. – Сагын әйдә, сагын. Ләкин, нишләсәң дә, мин ата-бабаларыбызның нигезен корытырга ирек бирмәм.

– Мин, мин, имеш. Син кем соң? Сытарга теләсәм, мин сине менә болай итеп сыта алам. – Сәлахов идәнгә төкерде дә төкереген таптый башлады, ләкин аягы тайдымы, бераз салмыш идеме, башы әйләнеп егылды.

Фатих чыгып китәргә җыенган иде, Сәлахов, сикереп торып, аның каршысына килеп басты:

– Беләсеңме мин синең ул изге нигезеңне ниш-ләтәм?!

– ?

– Бүген үк трактор җибәрәм дә өстерәтеп төшерәм. Ә сиңа яңа урынны арт урамдагы чүплектән бирәм.

Колхоз рәисе сүзендә торды. Тракторлар җибәреп, Фатихларның өен Ташлыярга төшермәкче булды. Моңа кадәр берничә механизаторның йортын шулай күчергән-нәр иде. Ләкин аларның күбесе никтер тернәкләнеп китә алмады. Картаеп килүче агачны башка туфракка күчереп утыртсаң, тамыр җибәрә алмый, корый. Табигатьнең ке-ше аңы үзләштерә алмаган серләре бардыр, күрәсең. Ташлыярга күчерелгән гаиләләрнең күбесе таркалды. Көчлерәк, яшьрәк ир-атлар, нефть эшенә кереп, район үзәгеннән фатир алды. Карт-корылар, үзләренең туган нигезләрен сагынып, кире әйләнеп кайтмаслык дөньяга юл тоттылар. Бары тик берничә гаилә генә Ташлыярда тамыр җәйде. Ә Фатихларның йорты шактый иске иде. Трактор чанасына домкратлар белән күтәрткәндә үк, астагы ниргәләре сынды. Астына яңа бүрәнәләр тыгып кран белән күтәртә башлагач, өй бөтенләй икегә аерылды. Фатих ул көнне колхоз йомышы белән Казанга киткән иде.

Колхоз рәисенә кайтып хәлләрне сөйләп бирделәр. Рәис өстәлгә шап итеп сукты:

– Селәгәйләр! Аны саграк эшләп булмый идемени?!

Рәис озак сүгенде. Секретарена әшәке сүзләр әй-теп- бетерде. Кул астына эләккән механизаторларны «се-ләгәйләр» дип сүгә торгач, аның үзенең селәгәйләре агып чыкты. Хәер, мондый хәл беренче генә түгел, һәм рәиснең кушаматы да Селәгәй иде.

Фатих Селәгәйне судка бирсә дә, район җитәкчеләре эшне зурга җибәрмәде. Селәгәйне эшеннән алдылар, ә Фатихка колхозның амбар төзергә дигән бүрәнәләрен китереп аудардылар. Китерелгән зыян өчен күпмедер акча түләделәр. Фатих, билгеле, бу хәлләрдән соң колхозда инженер булып кала алмый иде. Үз теләге белән эшен ташлады. Иске «Москвич»ы белән Ташлыярга барып эшләп йөрү аны туйдыра башлаган иде. Хәлнең болай үзгәрүенә ул сөенде генә.

Аның әле яңа өйләнгән чагы иде. Рәшидә Ташлыяр фермасында сыерлар сава. Иренә каршы төшмәде. Гомумән ул, Фатихны яратудан бигрәк, аңардан куркарак төшә иде бугай. Фатих аның белән рәтләп йөрмәгән дә килеш өйләнеп куйды. Чөнки әтисе белән әнисе ниндидер билгесез авырудан бер-бер артлы дөнья куйдылар. Әтисе, үләр алдыннан, улына соңгы сүзләрен әйтте:

– Улым, нигезне корытма. Без сиңа бүтән байлыклар- калдыра алмыйбыз. Бездән калган бөтен байлык – шушы нигез. Нигез ул – буынны буынга бәйләүче мәңгелек чылбыр. Кеше читкә китәргә, өен күчерергә, телен алмаштырырга мөмкин. Тик нигезне читкә дә алып китеп булмый, башка җиргә дә күчерә алмыйсың. Йорт нигезе ул – милләт нигезе. Безнең татар, шуны аңламыйча, читкә тарала. Кемдер шахтада күмер чаба, кемнәрдер Себердә урман кисә, нефть чыгара. Алар бит яңадан туган якларына кайтмый. Шулай нигезләр таркала, милләтебез сыеклана. Кайчан да булса нигез үзенә тарта, диләр диюен, әмма дә ләкин ераграк киткән саен, аның тарту көче кими. Безнең бу җирләребезнең өсте дә, асты да байлык кына бит.

– Ул байлык безнеке түгел шул, әти.

– Нигә безнеке булмасын. Аллага шөкер, җиләк-җимешләрен җыябыз, печәнен чабып, мал-туар асрыйбыз. Йортларыбыз да үз урманыбыз агачыннан. Нигез ул – җимеш агачы. Вакыт үткән саен, ул үсәргә, тармакланырга, яңа җимешләр бирергә тиеш. Авылны бетерергә ирек куйма, улым. Кырыкка ярылсаң ярыл, әмма авылны үстерергә тырыш.

Әтисенең соңгы сүзләре шул булды. Бу сүзләр Фа-тихның күңеленә нык сеңеп калды. Әтиләре вафат булганнан соң, алар тагын да тирәнрәк мәгънә алды: нигез агачының тамырлары зиратка ук барып тоташа икән ләбаса. Зарифулла картның Баланлыга ябышып ятуы да шуннан. Армиядән аның төпчек улын, цинк табутта кайтарып, Баланлы зиратына җирләделәр. Аның каберенә барып кына кайтса да, ул күңеленә җиңеллек таба.

Фатих Рәшидәгә колхоз рәисе Сәлаховка үч итеп өйләнде. Сәлахов Рәшидәне гел эзәрлекли, үз кармагына каптырырга йөри иде. Аннары өйнең хуҗабикәсе булырга тиеш бит. Әтисе әйтмешли, нигез агачы үсәргә, тармак-ланырга, үзенең җимешләрен бирергә тиеш.

Кызның әти-әниләре бишкуллап риза булдылар, чөнки Рәшидәдән соң тагын өч кызлары өлгереп пешкән, тик өзеп алучысын гына көтә иде.

* * *

Расих белән Фатих кайчандыр Казанда бергә укыганнар иде. Расих белем ягыннан бик булдырмаса да, теленә шайтан төкергән бәндә иде. Шул теле аркасында ул нефтьчеләрнең автопаркына механик булып урнашты. Ә озакламый аны автопаркның директоры итеп куйдылар. Ул инде махсус машинада, машинаның да ниндиендә әле – кара «Волга»да гына йөри башлады. Тиз арада шулай югары күтәрелүгә карамастан, ул үзенең сабакташ дусты Фатихны онытмады. Гамәлдән чыгарылган иске «Москвич»ны Фатихка ул алып бирде. Запчастен, сварка аппаратларын биреп торды.

Расих, укыган вакытта, Фатихларда ял итәргә ярата иде. «Мондагы табигать Швейцариядә дә юк, валлаһи!» – дип, ул тауларга, чишмәләргә, урман байлыкларына сок-ланып йөри иде.

Дустының авыр хәлдә калуын ишеткәч, Расих, «Волга»сына утырып, Баланлыга элдертте. «Неужели мунчада яшәп яталар икән?» Шушы уй борчыды аны.

Расих Баланлыга килеп кергәч аптырап калды. Монда элекке йортлар урынында җимерелгән нигезләр, сүтелгән мичләр таралып ята һәм урамда бер кызыл әтәч кенә кукраеп басып тора иде. Бердәнбер исән калган йорт Зарифулла картларныкы. Расих, Фатихларны эзләп, аларга сугылды, тик Зарифуллаларның ишекләре бикле иде. Фатихларның мунчасы исән калган икән – шунда китте. Мунча эчендә ут күренми, ләкин кемнеңдер кыштырдаганы ишетелә. Расих сак кына эчкә атлады, ә анда кемдер стеналарны юып йөри иде. Ул Фатихның хатыны Рәшидә булып чыкты. Рәшидә иртәдән бирле мунча стеналарын юып тирләгән һәм, тирле киемнәрен суга батырып, ялангач килеш эшләп ята иде. Расих аның кызларныкы кебек зифа буена, хәрәкәтләнгән саен селкенеп-селкенеп куйган күкрәкләренә сокланып карап торды. Рәшидә, чиләктәге пычрак суын тышка түгәргә дип, ишеккә таба килә башлады һәм шунда үзенә карап торган Расихны күрде.

– Ай, оятлы булдым, – диде яшь хатын, тәнен ни белән капларга белмичә. – Сез кем, нишләп йөрисез монда?

– Курыкма, мин Расих.

Расих хатынның кулындагы чиләген алды да пычрак суны тышка түкте. Ул арада Рәшидә өстенә ниндидер җәймә каплап өлгергән иде.

– Шушында яшәп ятасызмы? – диде Расих.

– Нишлисең инде, – диде Рәшидә.

– Фатих кая соң?

– Урманга киткәние.

– Нәрсә, йорт салырга агачлар кирәкме?

Хатын баш какты. Расих, Рәшидә янына утырып:

– Берәр җаен табарбыз, борчылма, Рәшидә ханым. Бәлки, сез мине хәтерләмисездер дә. Ләкин мин сезне онытмадым. – Расих Рәшидәне кочагына кысканнан-кыса барды.

Хатынның өстендәге җәймәсе ачылып китте. Ул елап җибәрде:

– Бар да Фатихның кирелеге аркасында. Шунда Ташлыярда инженер булып эшләсә, колхоз аңа йорт салып бирмәс идемени?

– Әйе, Фатихың үзсүзлерәк шул. Ә кирелек белән киртә генә җимереп була. Бу дөньяда нәрсәнедер корбан итмичә, бернигә ирешә алмыйсың, Рәшидә ханым.

Рәшидәгә моңарчы «ханым» дип дәшүче юк иде. Бу сүзләр аның җанын эретеп җибәрде. Кечкенә чакта аны әнисе шулай кочагына алып иркәли, тәмле сүзләр әйтеп юата иде.

Расих кочагында утырганда, аның аңы томалангандай булды. Әйтерсең ул әнисенең кочагында назлана.

Фатих һәр көн иртән мунча керергә ярата. Ул мунча кереп чыкканнан соң, Рәшидә, чишмәдән салкын су ташып, кызган стеналарга, түшәмнәргә су сибә. Шулай итмәгәндә, мунча суынмый, ә бит анда төнлә йокларга кирәк. Абзарда, мунча алачыгында өй җиһазлары. Бер җиргә борын төртерлек тә урын юк.

Баланлыдан күчергәндә йортлары таралып беткәч, Рәшидәнең бөтен эше мунча ягу, аны юып чыгару һәм төнлә йокларлык хәлгә китергәнче җиллә түгә кайтып калды. Ул хәтта үзенең Ташлыяр фермасында сыер савып йөргән чакларын сагынды.

Расих Рәшидәне туйда гына күргән һәм, дусты Фатихтан көнләшеп: «Чукынчык Фатих хатынның чибәрен эләктергән», – дип утырган иде. Хәзер ул Рәшидәне кочагында әвәли. Хатын, йомшак курчак кебек, аның һәр хәрәкәтенә буйсына. Ләкин бу халәт озакка бармый, Рәшидә айнып китә:

– Ямьсезләнмик, Расих. Күрдем, туйда син гел миңа карап утырдың. Минем күңелем сиңа төшмәде түгел. Ләкин хәзер мин – ир хатыны.

Рәшидәнең тыныч кына «ямьсезләнмик» диюе Расихка гипноздай тәэсир итте. Әгәр Рәшидә тарткалашса, ямьсез сүзләр әйтсә, Расих, бәлки, үзенекен эшләр иде.

– Әйе, – диде Расих, – ямьсезләнмәү хәерле. Ә бер ямьсезләнсәң, аны кырып юсаң да бетереп булмый. Йөрәк мунча стенасы түгел. Аны су сибеп кенә суытып булмый.

– Шуңа күрә аны кыздырмаска кирәк.

– Дөрес, – диде Расих. – Йөрәкне кыздырмау хәерле. Мин туйда ук сине урлап китә ала идем. Тыелып калдым.

– Рәхмәт!

Рәшидәнең рәхмәте Расихны бик сөендерде. Димәк, Рәшидәгә юкка күзе төшмәгән икән. Әнә иренә нинди туг-рылыклы ул. Юкса монда, Фатихка ачу итеп кенә булса да, гөнаһ эшләргә була иде.

Шушы тугрылыгы өчен Расихның Рәшидәгә берәр яхшылык эшлисе килде. Һәм ул уйлап тапты: икенче көнне үк Фатихларга нефтьчеләрнең вагон-будкасын китертте. Вагон-будка ике бүлмәле итеп эшләнгән, миче дә бар.

Ике дус кочаклашып күрештеләр. Фатихның сораулы карашын күреп:

– Кичә мин сезгә килгән идем, урамыгызда бер кызыл әтәчтән кала җан иясе күрмәдем. Йә, ничек соң, машинаң кәҗәләмиме?

Фатих:

– Машина чаба әле, шөкер. Ләкин бу вагон-йорт өчен түләргә кирәктер бит?

– Син ул турыда башыңны ватма, Фатих дус. Списать ителгән ул.

– Өр-яңа бит...

– Әллә белмисеңме? Безнең ил бай ич. Өр-яңа әйберләрне «брак» дип списать итәләр дә начальство үзенә илтеп куя. Мин дә бит начальник. Нигә миңа шулай эшләмәскә? Әнә бер җитәкче өр-яңа япон телевизорын, списать иттереп, сөяркәсенә бүләк итте.

– Минем хатын синең сөяркәң түгелдер бит? – диде Фатих.

– Дурак! – Расих шулай диде дә, машинасына утырып, эшенә сыпырды. Рәшидә, вагон-йортны күрәсе килсә дә, ирләрнең күзенә чалынмас өчен, юк эшне бар итеп, бәрәңге кортлары чүпләргә бакчага китте. Ул ирләрнең нәрсә турында сөйләшкәнен ишетмәде.

Бераздан ул, ире янына килеп:

– Нишләп дустың бик тиз китте? – дип сорады.

– Начальникларның холыклары бик тиз үзгәрә бит аларның. Бер сүз ярамады.

– Нинди сүз?

– Анысы сиңа кирәк түгел, эшеңдә бул. – Рәшидә китә башлаган иде, Фатих аны туктатты. – Кичә Расих килгәндә син кайда идең?

Хатын уйланып торды. Аннары:

– Ул кайчан килгәндер, белмим. Бәлки, минем чишмәгә суга барган чагым булгандыр, – диде.

Рәшидә, дөресен сөйләсә, Фатих аңа һич ышанмаячагын белгәнлектән, җавапны шулай бирде. Бу аның беренче алдашуы иде. Фатих исә, иренә хыянәт итмәгән хатын, хатынына тугры булып яшәүче ир юк, дип саный. Җай чыкканда, үзе мондый эштән баш тартмый. Укыган чакта, Казан тулай торакларында шактый гына «корбан ите» ашады ул. Ләкин бу эшне гөнаһка санамады, киресенчә, егетлеккә генә исәпләде.

Рәшидә иреннән тагын сораулар көткән иде, Фатихның сүзе беткән булып чыкты.

– Йә, ярый, бар, эшеңдә бул, – диде Фатих.

Рәшидә аяк-кулларын юды да вагон-өйгә кереп китте.

– Фатих, Фатих, дим, кер әле.

Фатих, керә-керешкә:

– Нәрсә? – диде.

– Нинди матур өй! – диде Рәшидә, балаларча куанып. – Бу өй бөтенләйгә безгә микән?

– Мин бу әрлән оясында озак яшәмәячәкмен.

– Ярар, өй салырбыз. Тик мин көянтә-чиләк белән Октябрьск каласына барып сөт сатып йөрүләрдән арыдым. Аралашыр кеше юк.

Фатих хатынына ачулы караш ташлады:

– Фермадагы пычрак артлы сыерларыңны сагынасыңмыни?

– Сагынам шул.

– Сагынсаң, Ташлыярга күч. Сыер савучыларны яраталар бездә. Бәлки, депутат итеп сайларлар үзеңне. Мәскәүдәге Съездлар сараеннан чыгыш ясаганыңны телевизордан карап утырырбыз.

– Көлмә!

– Ничек инде көлмисең, кызык бит!

Хатын белән ир бераз чәкәләшеп алдылар. Ул арада караңгы төшә башлады. Баланлыда электр юк иде, яңа вагон-йортлары эченә керосин лампасы кабызып куйдылар. Ул лампаның куыгы күптән шартлаган иде, куыксыз лампадан өйгә керосин исе таралды. Шулвакыт Фатих сикереп торды да, тиз-тиз атлап, тышка чыгып китте. Берничә минуттан ул машинасының аккумуляторын күтәреп керде. Өй ялт итеп яктырып китте. Яктылыкның сихри көче бардыр, күрәсең, әле генә әйткәләшкән ир белән хатын татулашты. Аш алдыннан бераз «шайтан суы» кабып куйган Фатихның күңеле күтәрелде.

– Бу вагон-йорт матур булса да, без монда озак яшәмәячәкбез, хатын. Иртәгә кирпеч заводына барам. Колхозның ул киртәләреннән өй салып куйсак, бездән бөтен кеше көләчәк. Иң беренче теге Селәгәй килеп мыс-кыл итәчәк. Аннары башкалары: «Инженер башың белән шушында яшәп ятасыңмы? Вагоныңны берәрсе тракторга тагып алып китсә нишләрсең?» – дип көләчәкләр. Ләкин Фатихның аңында әтисенең сүзләре яңгырап торды: «Нигез ул буынны буынга бәйләүче чылбыр!» Ә вагонда озаграк яшәсәң, нигезнең эзе дә калмаячак. Озакка сузмый, үз нигезебезгә бик шәп йорт салырга кирәк. Кирпечтән. Аны Селәгәйләр трактор белән сөйрәтеп алып китә алмас.

– Ә акча?.. – дия башлаган иде Рәшидә, Фатих аны бер җөмлә белән туктатты:

– Чын ирнең йөрәгендә алтын хәзинә ята, – диде ул. Фатих үзенең көчлелеген, булдыклылыгын раслый алгангамы, хатынына назлырак карады.

Рәшидә, яшь кызлардай оялып кына, иренең кочагына сеңде. Ире һәрвакыт кырыс, дөньяга ачулы йөргәнлектән, назланасы килгән чакларда да Рәшидә ире янына килеп сырпаланудан тыелып кала иде. Рәшидә инде эреп бетәм дигәндә генә, Фатих, ятактан төшеп, утны сүндерде.

– Аккумулятор утырса, иртәгә машина кабынмас, – диде ул һәм хатыны янына ятты.

Ләкин Рәшидәнең ялкыны сүнгән иде инде. Аларның назлары ниндидер йомыш үтәү кебегрәк килеп чыкты.

– Салкын син, хатын-кызның нинди булырга тиешлеген белмисең, – диде Фатих. – Егылган агач кебек ятасың.

– Нишлим соң? – диде Рәшидә.

– Хатын була бел, – диде канәгатьсез калган ир. – Сыерны савар алдыннан күпме сыпырасың, имчәкләрен кыскалыйсың, сөт бирсен өчен тырышасың. Сыер имчәге генә түгел бит миндә.

Әйбәт башланган төн икесе ике ятакта ятып тәмам-ланды.

Рәшидә, Фатих торганда, сыерларын урман аланына куган һәм мунча алачыгында кул белән әйләндереп эшли торган сепараторда сөт аерта иде. Дөрес, аларның электр белән эшләүче сепараторлары да бар, ләкин Баланлыга килә торган электр линиясен өзгәннән соң, ул кирәксез әйбергә әйләнде. Рәшидә колхозга сыер саварга йөрми башлагач, эше кимер дип уйлаган иде, киресенчә, артты гына. Сыерларны һәр көн иртән урман аланына илтергә, кичтән эзләп алып кайтырга кирәк. Алар кайвакыт бик ерак китәләр. Эзли-эзли, Рәшидәнең аяклары калмый. Иркендә йөргәнгәме, сыерлары сөтне күп бирә. Аларны сатып өлгереп булмый. Шуңа күрә Рәшидә күпчелек сөтен сары майга әйләндерә. Ярый әле эчен таш белән әйләндергән кар базлары бар. Яз җитүгә, Фатыйх аңа таптый-таптый кар тутырып куйган иде. Монда иткә, сөткә, майга урын җитәрлек. Майлары күбәеп киткәндә, Фатих хатынын базарга илтеп куйгалый.

Фатих йокысын туйдырып чыкты. Салкын су белән баштанаяк коенды, аннары тәне кызарганчы сөртенде.

– Кая, ашарга берәр нәрсә бир әле, – диде ул хатынына, исеме белән дә дәшмичә.

Хатын сүзсез генә иренә итле бәрәңге китереп куйды. Ашарга пешерер өчен Фатих ишегалдында берничә генә кирпечтән мич әмәлләгән иде. Төтен тартыр өчен бер торба да куеп җибәргәч, ярыйсы нәрсә килеп чыкты. Утын өчен кайгырасы юк – урман өскә аварга тора.

Ашап туйгач, Фатих кешелеккә генә кия торган ак күлмәген, кыйммәтле костюмын киде. Рәшидә сүзсез генә аңа карап торды. Сорау бирсәм, тупас җавап ишетермен, дип курыкты.

Ниһаять, Фатих киенеп-ясанып бетте һәм, машина ачкычын бармагында бөтереп: «Мин кирпеч заводына барам. Тиз генә кайтмасам аптырама», – диде дә машинасыннан әчкелтем төтен таратып китеп барды.

Фатихның кирпеч заводы директоры Әшнәев белән дуслыгы бар. Колхозда инженер булып эшләгән чакта итен, маен, балыгын аз ташымады аңа Фатих. Әшнәев күчтәнәчсез кулга ватык кирпеч тә сала торган кеше түгел. Ә колхозның тишекләре күп. Аны ямап торырга кирәк. Гомумән, колхозларга ямаулык та сирәк эләкте.

Фатих күчтәнәчләрне бер таныш кибетчедән алды. Ләкин әллә яхшыга, әллә яманга дигәндәй, кирпеч заводының директоры Әшнәев урынында бер чибәр генә ханым утыра иде.

– О-о, – диде Фатих, соклануын белдереп, – әллә күзләрем ялгыш күрәме: шиңгән чәчәкне алып ташлап, вазага гүзәл чәчәк утыртып куйганнар икән!

– Йомышыгыз? – диде директор кырыс кына.

Фатих бик хәйләкәр иде, сүзне читтән башлады:

– Кирпеч заводына Голливуд артисткасы кебек чибәр ханымны куйганнар, дип ишеттем дә, чынмы икән бу, дип күрергә кердем. Бар икән әле матурлыкның үрнәге булырдай хатын-кызлар... – Дөрестән дә, бу ханым Фатихның йөрәк тибешен ешайтты. Бер мизгел эчендә ул өйләнмәгән яшь егеткә әверелде.

Әмма чибәр ханым шактый кырыс күренә иде.

– Йомышыгыз? – дип кабатлады директор. Ләкин инде бу юлы аның тавышында кырыслык кимегән иде.

– Сезне күргәч, йомышым онытылып китте.

Хатын-кызның психологиясен яхшы белгән Фатих, йомышчы малайдай, бераз ишек төбендә таптанып торды. Хатын-кыз директор дәрәҗәсенә күтәрелгән икән, димәк, ул власть ярата. Власть яратучылар алдында үзеңне кечерәк итеп тоту хәерле. Бу ханымны кирпеч заводын тәмам аяктан егар өчен куйганнардыр. Яки район җитәкчеләренең сөяркәседер. Ничек кенә булмасын, Фатих бу хатынга ошарга тиеш. Юкса эш пешмәячәк. Фатих, үзенең югалып калуын күрсәтмәскә тырышып:

– Бәлки, башта танышырбыз? – диде.

– Йомышыгыз? – диде директор.

Ләкин Фатих, аның сүзләрен ишетмәгәндәй, тавык басарга килгән әтәчтәй бераз кабарынып (чөнки хатын-кыз артык мескеннәрне дә яратмый), директор өстәле янына якынлашты һәм үзенең көрәктәй кулын сузды:

– Мөмкин булса, башта танышып алыйк. Без инженер Фатих Рәхмәтуллович булабыз.

Директор, урыныннан тормыйча гына, Фатихның учына кулын салды:

– Нәркизә Хафизовна! – диде ул.

Фатих сузылган кулны озак кына учыннан ычкындырмый торды:

– Нинди гүзәллек! Бу куллар аккош мамыгыннан ясалгандыр, мөгаен?!

Нәркизә тыштан белдермәсә дә, күңеленнән канәгать калды: «Матурлыкны күрә алучы ир-атлар бар икән әле!» Нәркизә кулын Фатихның учыннан алмакчы булды, ләкин Фатих:

– Мин бу күмәч камырыдай йомшак кулларны гел учымда йөртер идем, – диде һәм Нәркизәгә якынлашты. Тик Нәркизәнең йөзенә салкынлык чыкканын күргәч, чикне уза башлаганын тоемлады һәм кулны ычкындырды.

– Йомышыгыз? – диде директор, үз роленә кереп.

– Бәлки, ишеткәнсездер дә, – диде Фатих, – безнең Баланлы авылын Ташлыярга күчерделәр бит. Ә минем Баланлыдан күчәсем килмәде. Ул кабахәт мин югында өйне күчереп куймакчы булган. Өй таралган. Мин Ташлыярда баш инженер идем, киттем.

– Хәзер кайда эшлисез?

– Әлегә эшләмим. Кошлар да бит башта үзләренә оя кора. Бераз туплаган мая бар. Башта өй салырга исәп. Колхозны судка бирдем. Аннан да бераз тамды. Хәзер миңа эшне башлап җибәрергә кирпеч кирәк.

– Кирпеч бөтен кешегә кирәк, – диде директор. – Әмма без иң беренче чиратта дәүләт төзелешләрен тәэмин итәбез.

– Ярый миңа икенче чират та, – диде Фатих.

– Ә ул икенче чиратның ун яки егерме елда да килеп җитмәячәген беләсезме соң сез?

– Беләбез.

– Белгәч.

– Эшне бит аны төрлечә эшләргә була.

– Мәсәлән?

– Мәсәлән, фәлән мең кирпеч брак булды, дип, акт төзисез дә иң яхшы кирпечләрне, төяп, миңа сатасыз. Ә бракларын колхозларга, төзелешләргә. Сарык та исән, бүре дә тук була.

– Оста икән сез.

– Совет илендә үстем бит мин. Гомер буе начальство шулай эшләде. Власть башында утыручылар иң яхшы товарларны үзләренә ташыдылар. Алар шундый «яраксыз» товар белән баеды.

Нәркизә Хафизовна форточканы ябып куйды. Фатихның сүзләреннән аның беләкләренә каз тәне чыкты. Ул хәтта өшеп киткәндәй булды.

– Күп беләсез! – диде ул.

– Моны бөтенебез беләбез, ләкин әйтергә генә куркабыз. Менә шушы куркаклык безне артка сөйри дә инде.

– Ул гына түгел шул безне артка сөйрәүче. Бер төрле сөйләп, икенче төрле эшлибез. Шул безнең тәгәрмәчкә таяк тыга.

Ят кешегә үзенең фикер оеткысын салгач һәм ул ят кеше синең уйларыңны дәвам иткәч, Нәркизә куркыбрак калды. Мондый сүзләрне, гадәттә, иң якын кешеләрең янында, анда да пышылдап кына сөйлиләр. Бу Фатих Рәхмәтуллович дигән бәндәдә үз-үзенә ышану, горурлык һәм шуның өстенә фикерен башкаларга йоктыра белү көче бар, ахры. Гәүдәсе дә бик мәһабәт. Күзе кешене киемнәре аша да күрә кебек.

– Акыллы кеше сез. Гадәттә, акыллыларны батыралар иде. Ә сез күтәрелгәнсез.

Нәркизә үзе дә сизмәстән ак кофтасы изүеннән күренеп торган «шарларын» калкытып куйды. Фатих үзенең бу ханымга инде тәэсир ясавын сизми кала алмады, әлбәттә.

– Ярый, Нәркизә ханым. Без сукыр һәм телсез.

«Син уйлап җиткермисең, ул инде фикерен әйтеп өлгерә, – диде Нәркизә эченнән. – Их, нигә мондый ирләр әллә нинди Баланлыда яталар икән?! Кабинетларыннан чыкмый сөрсеп беткән безнең «кәҗә тәкәләре»нең унысын алыштырыр иде бу».

Фатихны озатканда, ул:

– Сез әйткән брак кирпечләр хакында мин уйлап карармын. Ә хәзергә эшем бар.

Нәркизә урыныннан торып басты. Фатих моны чыгып китәргә вакыт дип аңлады.

Кайвакыт хәрәкәт, мимика сүзгә караганда күбрәк аңлата. Нәркизә Хафизовнаның йөзендә канәгатьлек төсмерен күрү озакламый Фатихның йомышы үтәләчәгенә ышаныч тудырды. Нәркизә Хафизовна, күпчелек хатын-кыз кебек, эчке бер сиземләү белән, Фатихның үзенә ошаганлыгын сизде. Саубуллашып чыгып киткәндә, күзләр үзара «сөйләшеп» алдылар. Фатихның күзләрендәге соклану Нәркизә ханымның күңелендә умырзая булып чәчәк атты. Ул хәтта, эчтән көрсенеп: «Их!» – дип куйды. Бу аның үз тормышының болганчык сулы елга кебек ямьсез булуыннан идеме, әллә Фатих кебек ирләрнең моңарчы очрамавы өченме – моны Нәркизә үзе дә әйтә алмады. Карьера артыннан куып көпшәк адәмнәргә тагылуы, бу эче черек адәмнәрнең урынга ятуга мышкылдый башлаулары һәм тагын әллә ниләр үтте Нәркизә ханымның хәтер күпере аша.

Әгәр берәр борылыш ясамаса, күңелендәге байлыкның югалуын, тора-бара күңел аланындагы чәчәкләренең йолкынып бетәргә мөмкин икәнлеген аңлады ул.

* * *

Фатих үзенең сумкасын Нәркизә кабинетында «онытып» чыгып китте. Моны Нәркизә күрмәмешкә салышты, ләкин, Фатих чыгып китү белән, сумкага ташланды. Ирнең зәвыгы әйбәт икән: кызыл балык, түгәрәк шешәле француз коньягы һәм башка кыйммәтле әйберләр килеп чыкты сумкадан. Нәркизә яңарак кына ирен җирләгән кеше. Яшь тән, яшь күңел «кычкырып» наз-иркәләүләр сораса да, Нәркизә исә директор буларак бик һавалы, үзенә күз атучы ирләрне моңа кадәр күрмәмешкә салышып кына үтә иде. Ләкин җаны гел нидер эзләде. Яшерен-батырын түгел, Фатих кебек ирләр Нәркизәнең тормыш юлында очраштыргалады. Ләкин аларда ниндидер җылылык җитмәдеме, әллә аны тизрәк үзләренеке итәргә тырышулары ошамадымы – андыйларны Нәркизә, тузганак мамыгына өргән кебек, бик тиз куып җибәрде. Ә Фатих бөтенләй башка: горур да, итагатьле дә.

Нәркизә Фатих турындагы уйларын күңеленнән куарга тырышты. Әмма ул куган саен, Фатих аңа якыная гына барды. Хәтта йокысының рәте китте. Бүген менә Фатих килергә тиеш. Аның күңелендә ниләр ята икән? Нәркизә, сулышы белән тартып китерердәй булып, аны көтте. Форточканы ачып куйды. Тәрәзәдән кергән җәйге җил Нәркизәнең чәчләреннән сыйпап үтте. Ул тәрәзәгә күз салды һәм Фатихның «Москвич» белән килеп туктавын күрде. Нәркизә каршы алу бүлмәсендәге секретарена: «Бер ун-унбиш минут беркемне дә кертмә, бетерәсе эшләрем бар», – диде.

Директор ханым бик җитди кыяфәт белән үзенең кәнәфиенә утырды. Алдына калын папка куйды. Аннары кечкенә көзгесеннән үзенең кашын-күзен, керфекләрен барлады. Һәммәсе тәртиптә, тик ни өчендер үзен яратмады ул бүген. Күз төпләрендә җыерчыклар күрде. Чәче дә матур итеп җыелмаган төсле тоелды. Аннары ул көзгесен сумкасына тыгып куйды да тәрәзәгә күз төшереп алды: «Фатих күчтәнәч алып килерме икән бүген?» Нәркизә ханым Фатихның теге көнне алып килгән коньягыннан өенә кайту белән авыз итеп карады. Гадәттә, ул коньякны кофега кушып эчәргә ярата. Бер бокал кофега салынган утыз граммлап коньяк канны кыздырып, дәртләндереп җибәрә. Ләкин Нәркизә Фатихның француз коньягын кофега кушмыйча гына авыз итәргә булды.

– О-о... – дип куйды ул, бөкене ачуга. – Моның исе үк башка. Әрмән коньякларыннан ниндидер авыр ис килә. Кабып карыйк әле, тәме ниндирәк икән? – Нәркизә ханым, көмеш чәй кашыгына салып, коньякның тәмен тикшерде. Тәме дә әйбәт икән. Ләкин ике йортлы авылда яшәп ятучы Фатихка бу коньяк каян килгән? Серле кеше булырга охшый бу Фатих.

Нәркизә ханымның кабул итәр вакыты җитте. Гадәттә, хатын-кыз үзен көттерергә ярата. Шуның белән бәямне күтәрәм дип уйлый, ләкин шуның белән оттыра. Фатих та инде китәргә уйлаган иде, шулвакыт Нәркизә секретарена «Москвич»лы кешене кертергә кушты. Ләкин Фатих үзеннән алда бер әбине кертеп җибәрде Моңа Нәркизәнең кәефе кырылды.

Ләкин әби озак тормады, авыз эченнән: «Безгә дигән кирпеч тегендә генәдер. Анда барып җитсәк, морҗасы да, дөньясы да кирәкмәсие. Ходайдан вакыт җитмәгәч барып булмый шул», – дип сукранып чыкты. Хәер, бу сукрану түгел, язмышка буйсыну рәвешендә әйтелгән сүзләр иде.

Карчык чыгып киткәч, Фатих керде.

– Исәнмесез! – диде Фатих. – Гафу итегез, вакытсызрак килдем, ахры... Эшегез күп күренә.

– Эшенә түзәр идек, төрле отчётлар, сметалар, актлар һәм тагын йөз төрле кәгазьләр белән теңкәне корыталар. – Нәркизә шулай диде дә шап итеп папкасын япты. Аннары, башын күтәреп, Фатихка карады. – Сезнең белән нишләргә икән соң инде?

– Анда сезнең ватык кирпеч өемнәрегез күбәйгән. Шулар янына тагын бераз өеп булыр әле. Алып китү юлын мин карармын.

– Алай барып чыкмас. Бер өйлек кирпеч шырпы кабы гына түгел ул. Эте күрмәсә, бете күрер.

– Алайса нишлибез соң?

– Законлырак юлын эзләрбез. Ләкин... – диде Нәркизә Хафизовна, – минем бер әйбергә төшенәсем килә: ни өчен сез, Ташлыярга күчмичә, ике йортлы перспективасыз авылга йорт салырга җыенасыз? Ташлыярда урта мәктәп бар, өр-яңа мәдәният йорты гөрләп эшләп тора. Бәрәңге бакчалары артында гына Ык елгасы агып ята.

– Анысы шулай, ләкин минем Баланлыда яшисем килә. Әгәр сез безнең авылны берәр тапкыр күрсәгез, сезнең анда бөтенләйгә каласыгыз килер иде. Аннары туган нигезем Баланлыда. Әтием, җан биргәндә: «Нигезне корытма, улым. Нигез ул – безнең нәсел тамырыбыз», – дигән иде.

– Хәзер нигез турында уйламыйлар. Шәп фатир, җиңел эш эзли күпләр, – диде Нәркизә.

– Андыйлар да бардыр, – диде Фатих. – Ләкин нигез минем өчен изге нәрсә: ул – мине үткәнем белән бүгенгене тоташтыручы күпер. Нигез тормышымның тамырлары да. Әгәр шушы тамырларга корырга юл куйсам, минем бер дүңгәләккә әйләнүем бар.

– Кызык фикер.

– Кызыкмы-түгелме, әйтә алмыйм. Әмма безнең татар халкының фаҗигасе – акча дип, тамырларын өзеп, читкә китүдә. Нигез безнең крепость булырга тиеш.

– Алайса күрсәтегез шул крепостьны, – диде Нәркизә Хафизовна.

– Күрсәтәм, – диде Фатих. – Кәгазьләрегездән бераз арынып, саф һава сулап кайтырсыз. Хәзер китәбезме?

– Ярый, сезнеңчә булсын, барып кайтыйк. Тик бер шарт белән...

– Нинди шарт?

– Әгәр авылыгыз миңа ошамаса, сезгә бер кирпеч тә сатмыйм.

– Үзегезне йөртә торган «Волга»гызны бүгенгә отс-тавкага чыгара аласыз. Минем «Москвич»ка утыру сезне түбәнсетмәсә, билгеле.

Нәркизә Фатихның сүзенә җавап биреп тормады. Секретарена:

– Мине сорасалар, объектларга чыгып китте, дияр-сең.

Нәркизә Хафизовна, урамга чыккач:

– Сез, машинагыз белән посадкага барып, мине көтеп торыгыз. Мин җәяүләп кенә янычызга килермен, – диде.

Фатих аны дөрес аңлады: гайбәтләрдән курка. Гайбәт – безнең иң яраткан әйберебез. Гайбәт кешене, таудан яшен кубарып аткан таш кебек, түбән тәгәрәтә ала. Мәңге аумас кебек тоелган бетон баганаларны аудара. Арага гайбәт керсә, иң кайнар мәхәббәт уты да сүнеп кала. Гайбәтнең көчен югарыда утыручылар да яхшы аңлый һәм, кирәк чакта, аңардан бик оста файдалана. Тиешсез сукмакка керәсең икән, эзеңне калдырма. Нәркизәнең бу мәсьәләдә авызы пешкән, күрәсең, бик сак кылана.

Нәркизә Хафизовна машинага утыру белән кузгалып киттеләр. Фатих тизлек рычагын әле бер, әле икенче юнәлешкә күчергәндә, аның кулы алгы утыргычка утырган Нәркизә ханымның ботына тиеп-тиеп китте. Юка капрон оек аша алтын сыман булып күренүче бу аяклар Фатихны әллә нинди ләззәтле уйларга салды. Ул Нәркизә

ханымны чишмә буена алып килде, ләкин чишмә ханымга бернинди тәэсир ясамады. Фатих, кунагыннан рөхсәт сорап, чишмәдән су алды. Аннары алар Бүре аланына менеп киттеләр. Бер урында Фатих машинасын туктатты.

– Иң зур бүре оясына кереп чыгасыгыз килмиме? Юкса машина эчендә кыздыра башлады.

– Кунак – хуҗаның ишәге, – дип, Нәркизә туктауга каршы килмәде.

Фатихның «бүре оясы» дигәне землянкага охшаш бер нәрсә иде. Аның эченә печән җәелгән. Бусаганы атлап керүгә, борынга җиләкле печән исе килеп бәрелде.

– Монда сезнең яшерен куышыгыз, ахры. Иң зур бүре сез буласыздыр инде?!

Көлешеп алдылар.

Стенага тәлгәшле җиләкләр, баланнар, миләшләр эленгән. Юкә яфраклары, каен бөреләре, мәтрүшкәләр – һәммәсе бер тәртип белән куелган. «Бүре оясы»сындагы хуш ис башны әйләндереп, күңелне күтәрә. Уй-хыяллар биеккәрәк күтәрелә. Гел конторасында утырып «иркенлек» дигән төшенчәне оныта башлаган ханым агачлар шаулавыннан, кошлар сайравыннан, җиләк һәм төрле чәчәк исләреннән тәмам исерде. Әмма бу шәраб эчеп исерүгә охшамаган. Бередә күзләр – матурлыктан, колаклар – берсеннән-берсе уздырып сайраучы кошлар авазыннан, тән җәйнең назлы җиленнән рәхәтлек кичерә. Өстәвенә бу куышы тагын! Күңеленнән романтика чыгып бетмәгән Нәркизәгә ул Адәм белән Хавадан калган куыш булып күренде.

– Өй салырга кирпеч сорап йөрисез, менә бит монда нинди хозурлык! – диде Нәркизә, колачын җәеп.

– Әйе, – дип килеште аның белән Фатих, – мин монда яши алыр идем, тик...

– Нигә яшәмисез соң?

– Тик сезнең белән генә, – диде, бөтен батырлыгын җыеп, Фатих.

– Аппетитыгыз зур икән.

– Әйе, аппетиттан зарланган юк анысы. Аппетит димәктән, әллә бераз капкалап алабызмы?

Фатих, кунагының ризалыгын да көтмичә, машинасын ачып, багажнигыннан бер сумка һәм бая чишмәдән алган сулы канистрын күтәреп, куышка керде. Аның сумкасында нәкъ теге көнне директор кабинетында калдырып киткән төсле коньяк, телемләп тозланган кызыл балык һәм бармак башы кадәр генә вак-вак гөмбә тутырылган банка. Шулар янына өйдә пешерелгән түгәрәк күмәч. Кайнар чәй кирәксә, анысы термоста.

– Карале, иптәш... – Нәркизә Фатихның исемен оныткан сыман кыланды.

– Фатих, дип кенә дәшегез миңа.

– Ярар, Фатих, диярмен. Тик бер нәрсә сорыйсым килә: үзегез бүре өнендә яшисез, белүемчә эле эшләмисез дә бугай. Мондый затлы ризыкларны каян аласыз сез?

– Затлы кешегә ризыкның да затлысын табарга тырышасың инде.

– Тырышып кына кирпеч тә табып булмый бездә.

– Анысы дөрес. Ләкин икәүләп тырышсак, кирпечен дә табарбыз дип өметләнәм. Мондый гүзәл ханым эшли алмаган эш булмас.

– Шулай да сез минем соравыма җавап бирмәдегез әле.

– Ярый алайса, әйтәм. Мәскәүдә минем бер абый яши. Ягъни әтинең энесе. Ул Мәскәү университетында укыта, күп телләр белә. Вакыт-вакыт аны йә Франция, йә Англия университетларына чакыралар. Ул шунда лекцияләр укып кайта. Бу күчтәнәчләр кайсы илнекедер – белмим. Абый, кунакка кайткан саен, андый күчтәнәчләрне күпләп калдырып китә. Тормышлары бик шәп.

– Мәскәүдә эшләүче шундый абыең була торып, өй салырлык кирпеч таба алмыйсың. Кайвакыт акча белән табып булмаган нәрсәләрне исем эшли. Тик аны урынлы куллана белергә кирәк. Менә, минем абыем фәлән җирдә эшли, дип түгел, сүз арасында, сиздермичә генә, абыең турында кирәкле җиргә сүз кыстырып җибәрергә кирәк. Анда да ул әңгәмәнең эчтәлегенә табигый рәвештә килеп керергә тиеш. Әңгәмәдәшең башта аны абайламас-ка мөмкин. Әмма үзе генә калгач, диалоглар күңелдән кабатлана, шунда акыл син атаган кеше исемен бүтән исемнәрдән аерып куя.

Фатих Нәркизәнең кешеләр күңелендәге нечкәлекләр-не фәлсәфи фикер дәрәҗәсенә күтәрә алуына таң калды. «Без хатын-кызны бәяләп бетермибез шул», – дип уйлап алды.

Фатихның уйланып торуын күреп, Нәркизә:

– Хәтереңне калдырдым, ахры, – диде.

– Юк ла. Дөрес сүзгә җавап юк, диләр бит. Әйдәгез, Нәркизә ханым, фәлсәфәне туктатып торып, бераз тамак ялгап алыйк. Кулларыгызны юарга кирәк булса, үзем су салып торырмын.

Юынып алганнан соң, Фатих куышта яңа кипкән печән өстенә зур ашъяулык җәйде. Шунда табын әзерли башлады.

– Сез бит минем киләсемне белми идегез, ризыкларны әзерләгәнсез.

– Кеше һәрвакыт өмет белән яши. Теге көнне сезне кабинетыгызда күргәч, йөрәгем кысып куйды: их, мин әйтәм, шушындый хатын-кыз белән бер сөйләшеп утырасы иде.

– Сез чынлап та карт бүре. Корбаннарыгызны сайлый беләсез. Елан авызына кергән куян кебек, хатын-кызлар сезнең кочакка кереп китүләрен сизми дә калалардыр.

– Кочакка керүчеләр бөтенләй булмады, дисәм ышанмассыз. Ләкин сез уйлаганча күп түгел.

Алар бер-берсенә серле карашып алдылар. Эчелгән коньяк, җиләк исләре, аска җәелгән яфракларның кузгалган саен кыштырдап куюлары күңелгә ниндидер иркенлек, рәхәтлек бирә иде.

– Бөркү булып китте, – диде Нәркизә ханым һәм кофтасының төймәләрен чишеп җибәрде. Төймәләр чишелгәч, кофта каплап торган байлыклар калкып чыкты. Фатих аларга кырын күз ташлап алды.

– Рөхсәт итсәгез, мин дә күлмәкне салыр идем, – диде Фатих. – Чынлап та бөркүрәк шул.

– Сез бит үз өегездә, – диде Нәркизә.

Фатихка шул сүз җитә калды. «Әһ» дигәнче күлмәген салып атты.

– Әллә тагын берәр рюмка кабабызмы?

– Кабыйк алайса, – диде Нәркизә, – күптән шушындый тыныч урында рәхәтләнеп утырган юк. Эшкә бар-саң – кешеләр, өйгә кайтсаң – бушлык.

Өйдәге бушлыкның нилектән икәнен аңлатып тормады Нәркизә, рюмкадагы коньякны кабып куйды. Фатих аңа сабагында кипкән бер тәлгәш җиләк сузды.

– Рәхмәт, Фатих. Сез хатын-кызга хөрмәт күрсәтә беләсез. Җиләкләре бигрәк тәмле.

Фатих исә, үз өлешен эчкәннән соң, борылып Нәркизә ханымның түшенә кунган күгәрченнәргә төртте. Нәркизә, көлә-көлә:

– Кытыгымны китерәсез бит, – диде.

Алар шулай шаярыша-шаярыша кытыклаштылар. Фа-тихның атлетларныкы кебек киң күкрәге, нечкә биле, төз гәүдәсе соклангыч матур тоелды Нәркизәгә. Ул үзенең үткән тормышын күз алдына китереп утырды. Ни өчендер яшь вакытта Нәркизә артыннан чабучылар күп түгел иде. Әллә артык матурлыгы куркытты. Халыкта бит чибәр кыз б...т була дигән сүз йөри. Бәлки, әтисенең зур урында эшләве куркыткандыр. Ни генә булмасын, Нәркизәнең яшьлеге сагындырып түгел, йөрәкне ачыттырып-ачыттырып искә төшә иде. Ләкин ул үз халәтен Фатихка сиздермәде.

Фатих Нәркизәне яфраклар белән күмеп ташлады да:

– Каяле, монда берәр җиләкле алан юкмы икән? – дип, яфракларны Нәркизәнең өстенә учлап-учлап сибә башлады. Җиләкле урынны тапкач: – Менә кайда икән ул җимеш бакчасы, – дип, үләннәр арасына кереп китте.

Бу уен Нәркизәгә дә кызык тоелды. Бераз вакыт үткәч, ул Фатихны яфраклар белән күмде һәм яфрак арасыннан гөмбә эзләде.

Әллә юләрлек, әллә кабынып килә торган мәхәббәт кан тамырлары буйлап йөрәкләргә бәреп керде һәм аларны җирдән күккә күтәрде.

– Причёскамны боздың! – диде, куыштан чыкканда, Нәркизә. Һәм сумкасыннан көзге эзли башлады.

Фатих ул арада машинасының көзгесен Нәркизәгә тоттырды. Ә үзе, ханымның артына басып, Нәркизә кулындагы көзгегә карады. Аларның күзләре көзгедә очрашты.

– Причёскаңны хәзер рәтлибез аны, – диде Фатих һәм, Нәркизәнең иңнәренә төшкән чәчләрен бер яккарак этеп, ханымның иңнәрен үбәргә тотынды. Җыела башлаган чәчләр яңадан таралды.

– Җитте инде, – диде Нәркизә, ә үзе әкрен-әкрен куышка таба чигенде.

Өр-яңадан иркәләшеп алдылар. Нәркизәнең йомшак беләкләре, ап-ак тәне гел наздан гына тора кебек иде. Тәнгә кагылганчы ук, рәхәтлек җаныңны урап ала. Бу тән рәхәтлеге генә түгел, ә тәләкләрнең бергә кушылуыннан барлыкка килгән ниндидер аңлаешсыз, шул ук вакытта кайчандыр кичереп тә онытылган бер халәт иде. Алар гөнаһ турында уйламадылар, бу алар өчен табигый нәрсә булып тоелды. Нәркизә, исенә килеп, сәгатенә карады:

– О-о, никадәр вакыт узган, ә мизгел генә булып тоелды.

– Бәхетле мизгелләр тиз уза шул, – диде Фатих. Аннары табындагы ризыкларга карап: – Минем нишләптер үтереп ашыйсы килә башлады, – диде.

– Ашап алырга мин дә каршы түгел, үткән көн үткән инде, – диде Нәркизә.

Канистрдагы чишмә суы белән юынып алганнан соң ашарга утырдылар. Термостагы чәй ярап куйды. Өйдә кабарып пешкән ипи өстенә маринадланган кызыл балык куеп ашагач эчәселәре килгән иде. Чәй эчкәндә, куыш стенасында эленеп кипкән җиләкләрнең дә кирәге чыкты. Җиләкләрне Фатих Нәркизәгә үзе каптырды.

Кайчагында, үртәп, «кабам» гына дигәндә, җиләк тәлгәшен өскәрәк күтәрде. Шаяра-шаяра ашый торгач, табында ипи белән банкасы ачылмаган гөмбә генә калды.

Табынны җыйгач, Фатих Нәркизәне Октябрьск каласындагы фатирына илтеп куйды. Ә өенә кайтса, өй буш иде. Өстәл өстендә бары тик бер бит кәгазь генә ята. Анда Рәшидә эре-эре хәрефләр белән болай дип язып куйган: «Фатих, синең колың булып яшәүдән туйдым. Көне буе бер авыз сүз сөйләшми йөреп, телемне дә югалтасым килми. Син машинаңа утырасың да чыгып югаласың. Кайда, нишләп йөргәнеңне беркем белми. Хуш! Минем арттан килеп йөрмә, барыбер кайтмыйм. Синең салкын тәнеңне кочаклап ятканчы, мин ферманың сасы сыерын кочаклап ятам. Рәшидә».

Фатих Рәшидә калдырган язуны кат-кат укыды. Хатыныннан ул моны көтмәгән иде. Фатих аны какмады, сукмады. Дөрес, иркәләүләр кимеде, ләкин көне-төне өй мәшәкате белән чапканда иркәләшеп утырырга вакыт каламы?

Рәшидәнең ташлап китүе Фатихның мин-минлегенә бераз сукса да, артыгын борчылмады. «Муены булгач, камыты табылыр», – дип тынычланды. Үз араларында мәхәббәт юклыгын күптән аңлаганлыктан, бу төеннең үзеннән-үзе чишелүенә шатланды ул хәтта. Алда эшләр бик күп, ә мондый эшләрдә Рәшидә иптәш, ярдәмче була алмый, ә Нәркизә киң фикер йөртә. Ул Фатихка:

– Менә син «нигез» дисең, йорт салырга йөрисең. Ә бит бер йорт ул – бер агач. Ялгыз агачны давыллар төбе-тамыры белән каерып атарга яки яшеннәр сугарга мөмкин.

– Ә син нәрсә тәкъдим итәсең?

– Синең Баланлыңны зур авыл итәргә кирәк. Шул вакытта гына «милләт, нигез, тел» дип сөйләргә хакың булачак.

– Син хаклы. Ләкин әфсен укып кына авыл салып булмый шул.

– Без аны әфсен укып түгел, үз кулларыбыз белән салырбыз.

– Ничек?

– Ничекме? Мәсәлән, минем өстәл тартмасында гына да фатир сорап язылган иллеләп гариза ята. Баланлы шәһәргә якын. Монда рәхәтләнеп киләчәкләр.

– Әйбәт фикер бу. Ләкин халыкның психологиясе үзгәрде хәзер. Урбанизация заманы бит. Бөтенесе шәһәрдә торуны бер баскычка күтәрелү дип саный. Ни генә дисәң дә, бер өйдән башларга туры килә.

Фатих Нәркизәгә сокланып карады: чәче генә түгел, акылы да озын бу ханымның. Фикерләре бүгенге көнгә генә ябышып калмаган. Фатихның да бит Баланлыны нәкъ элекке хәленә кайтарасы, хәтта элеккедән дә шәбрәк итәсе килә. Ләкин моңа тотыныр өчен үзеңнең таяныр нигезең булырга тиеш.

– Чибәрлегең өстенә акыллы да икәнсең син, – диде, Нәркизәгә сөйкемле карап.

– Сез ирләр хатын-кызларны икенче сортлы дип санаганга, бездә акыл түгел, башка нәрсә күрәсез.

– Анысы дөрес. Ир-ат хатын-кызга түшәк итеп карарга өйрәнгән. Ә бит тормышта четерекле хәлләр адым саен. Мондый четерекле хәлләрдән чыкканда без, гадәттә, хатын-кыз белән киңәшмибез. Янәсе, без ирләр бөтенесен үзебез чишәргә тиеш. Ә бит югыйсә хатының, синең уй-фикерләреңне аңласа, башкарган эшләреңне дә хөрмәт итә башлаячак.

Нәркизә белән Фатихның фикерләре ерак офыклар-ны айкады. Алар әле җиргә төштеләр, әле күккә күтәрелделәр. Кайвакыт уй-фикерләр, реаль тормыш вакыйгаларына әйләнеп, күз алдына килеп басты. Фатихка Нәркизә белән сөйләшү рәхәт иде. Чөнки берсе башлаган фикерне икенчесе үстереп җибәрә. Уйлар тирәнәя һәм яңа форма ала башлый. Ә бит Фатих Рәшидә белән болай сөйләшә алмый. Югарырак күтәрелсәм егылып төшәрмен дигән кош кебек, аның фикерләре өй һәм ишегалды тирәсендә генә әйләнде. Биеклек икән – ул югары пост булсын. Рухи биеклекне кеше күрми, ә кеше күрмәгән нәрсә Рәшидә өчен буш нәрсә.

* * *

Фатих атнага якын югалып торды. Нәркизә әллә ниләр уйлап бетерде. Килсә кертмәм дә әле, дип, күңеленә беркетте. Фатих килеп кергәч, Нәркизә аны сытык чырай белән каршы алды.

– Мин сезгә кирпеч кирәкмиме әллә дип уйлаган идем, – диде ул.

– Бик кирәк, Нәркизә Хафизовна. Тизрәк эш башларга куллар кычытып тора.

– Алай кулың кычыткач кайда йөрдең соң?

– Мәскәүгә, абый янына барып кайтырга туры килде. Өйне кирпеч белән генә салып булмый бит. Акча да кирәк.

– Эшләрең уңдымы соң?

– Уңды.

– Котлыйм, – диде ул салкын гына. Фатихның Мәс-кәүгә шыпырт кына китеп баруы Нәркизәне кимсеткән, шуңа кәефе китеп утыра иде.

Фатих Нәркизәгә Мәскәүдән кытай ефәгеннән тегел-гән, зәңгәр тукымага нур сибеп торучы йолдызлар төшерелгән бик матур күлмәк алып кайткан.

– Бусы сиңа кечкенә генә бүләк, – дип, күлмәкне ханымга тоттырды.

Төргәкне ачып җибәргәч, Нәркизә аһ итте.

– Киеп карамый ничек түзәсең инде? – Нәркизә, Фатихны коридорга чыгарып торып, күлмәкне киде. Ул үлчәп тегелгән кебек таман һәм Нәркизәнең йөзенә килешле иде.

– Минем үлчәмне каян белдең? – диде Нәркизә.

– Синең белән үлчәнгән бар бит инде, – диде Фатих.

– Шәп! Зәвыгың бар икән. Мин сиңа бер машина кирпеч әзерләп куйган идем. Эшнең башын башлый торырга. Өеңә җитәрлеген җайларбыз. Шушы көннәрдә «яраксыз» кирпечләрне илттерермен. Өеңне зур итеп сал.

– Ул яктан махы бирмәбез. Өйне ике катлы итеп салырга исәп бар: асты кирпеч, өсте агачтан.

Нәркизәнең күңелендә хыял сарайлары калкып чыкты. Менә алар Фатих белән хыял сараеның иң югары катындагы балконда басып торалар. Каршыда – урман, таулар. Чишмә суы, челтерәп, өйгә үзе керә. Баш өстеннән бөркетләр очып үтә.

Фатих, Нәркизәнең уйларын укыгандай, ханымның балкыган йөзенә күз ташлады.

– Сез романтик, сез бары тик сөю-сөелү өчен генә яратылган. Нишләп сезне бу ташлар, комнар арасына китереп тыкканнардыр, аңламыйм, – диде ул.

– Фатихка кирпеч кирәк булганга, – диде Нәркизә һәм, күзендә чаткылар уйнатып: – Без бит җирне матурларга килгән. Совет хатын-кызы таш өстендә гөл үс-терергә тиеш, – диде.

– Сез шул гөл инде алайса, – диде Фатих.

Алар дөнья турында, яшәүнең мәгънәсе турында сөй-ләшеп алдылар.

– Яшәү мәгънәсе – үз-үзеңне табуда, – диде Фатих.

– Ә бәлки, яраткан кешеңне табудадыр, – диде Нәр-кизә.

– Бәлки, – дип килеште Фатих.

Нәркизә, хисләнеп, урыныннан сикереп торды:

– Син бит әле теге көнне үзеңнең Баланлыңны да күр-сәтмәдең.

Нәркизә «син»гә күчкәнлеген сизми калдымы, махсус шулай әйттеме, белмәссең. Хатын-кыз бик хәйләкәр бит ул. Ир-атның үз-үзен тотышына карап, кинәт үзгәрергә мөмкин. Шуңа күрә Фатихка сизгер һәм сак булырга кирәк иде. Ул Нәркизәнең үзе кебек бик гади генә:

– Теләсәң, бүген күрсәтәм, – диде.

Алар шулай «син»гә күчтеләр.

– Әгәр берәр сәгать көтәргә түземең җитсә...

Фатих Нәркизәгә сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмәде, чибәр ханымны кәнәфие белән бергә күтәреп алды:

– Мин гомер буе көтәргә риза.

– Алайса, мин бераз эшләп алыйм...

– Ә мин ул арада заправкага барып кайтырмын.

Гөнаһлы мәхәббәт аеруча ләззәтле була, диләр. Дөрестер, ахрысы. Әнә бит утызны узган Фатихның йөрәге иске «Москвич» моторыдай шыкы-шыкы килеп тибә. Хәер, гөнаһ белән савап арасын кем үлчәгән. Кеше гомере буе үзенең идеалын эзли. Бу гөнаһмы? Бәлки, яратышмый яшәп, бер-береңне газаплау гөнаһтыр?! Тормыш катлаулы. Бик бәхетлеләрнең генә иңенә аккош куна. Ә күпләр үз аккошларын гомер буе эзли.

Фатихның машинасы килеп туктауга, Нәркизә, кабинетын бикләп, урамга ашыкты. Югарыдан шалтыратсалар дип, телефон чыбыгын да өзеп куйды. Районда телефоннар начар эшләгәнен өстәгеләр яхшы беләләр. Бәлки әле, шалтыратып та маташмаслар. «Үзе» – Казанда, ә ул югында вак-төяк җитәкчеләр төрле якка таеп бетә.

Фатих, машинасының ишеген ачып, Нәркизәне кертеп утыртты. Каешларны эләктерергә дип, аска иелде. Шунда аның иреннәре ханымның колак яфракларына тиеп алды, кыска итеп киселгән чәчләре битен кытыклады. Ләкин бу «ялгышлык»ка Нәркизә әһәмият итмәгән кебек утырды. Әмма үзенең тамырларында кан агышы тизләнде, тәннең назга сизгер урыннары уянды. Нәркизә ниндидер сихри урыннар, әкияти матурлыклар күрергә өметләнеп барды. Хыялы ераккарак киткән саен, татыйсы бәхет зуррак булып тоелды.

– Кая барабыз, теге бүре өненәме? – диде Фатих.

– Юк, Баланлыга. Йорт салып мәшәкатьләнер урынмы ул? Күрик әле.

Фатих икеләнебрәк калды. Моны Нәркизә машинаның әкренәюеннән үк сизде.

– Әллә өйдә хатының бармы? Сине болай куркактыр дип уйламаган идем.

– Үзем курыкмыйм. Авылыбызда Наҗия исемле кияүдән кайткан хатын бар. Менә шул минем тормышымны бик каты күзәтә.

– Аның янына кереп йөрисеңдер әле.

– Юк ла. Рәшидә белән яшәгән чакта, без аларда бераз торган идек. Тычкан тотарга җыенган мәчедәй мине сагалап йөри башлагач, без, алардан чыгып, үзебезнең мун-чада тора башладык.

– Матурмы?

– Кем?

– «Кем» дип, шул Наҗияңне әйтәм.

– Мин үзем яратмаган хатын-кызның матурлыгын күр-мим.

– Ямьсезләр аеруча сексуаль була, ди бит.

– Белмим, – диде Фатих. – Хатын-кыз мәсьәләсендә мин бик надан.

– Надан түгел, хәйләкәр төлке син.

– Нәрсәдән чыгып әйтәсең?

– Икебез арасында булган хәлләрдән чыгып. Син мине үз кармагыңа тиз каптырдың.

Фатих Нәркизәгә нидер әйтмәкче иде, ләкин машина, түмгәккә эләгеп, кинәт сикертеп куйды. Алар авыл эченә килеп кергәннәр иде. Урам уртасында зур кызыл әтәч тибенеп йөри. Аңа ике тавык ияргән. Әтәч нәрсәдер тапты, ахрысы, куркылдап алды. Тавыкның берсе әтәч тапкан калҗаны эләктереп читкәрәк чапты, ә икенче тавык калҗага алданмады, әтәч тирәсендәрәк тибенде. Шул арада әтәч аның өстенә менеп төшәргә дә өлгерде.

– Менә, – диде Нәркизә, – сез ирләр нәкъ әтәч төс-ле.

– Ул яктан табигать, чынлап та, ир-атларны әтәч кебегрәк итеп яраткан шул.

– Менә үзең дә танышың: әтәчләр бит күрше тавыгын басарга ярата.

– Күрше тавыкларына, димәк, күрше әтәчләре ошый.

Сүз шул урында өзелде. Фатих үзләре турысына килеп туктады. Машина тавышына, йөгереп, Наҗия килеп чыкты. Аның өстендә юыла-юыла төсен югалткан халат. Фатихлар каршына килеп басуга ук, халатның итәген җил күтәреп-күтәреп алды. Наҗия халат итәкләрен ике тезе белән кысты.

– Кунак килгән икән безнең авылга. Рәхим итеп безгә керегез. Самавырым кайнап тора, чәй эчеп чыгарсыз.

Нәркизә, Фатихка гына ишетелерлек итеп:

– Моның самавыры кайнап тора. Кара әле син аның күзләренә. Ул күзләрдән сиңа таба күпме нур агыла.

Фатих, Нәркизәне көнләштерүдән рухи ләззәт кичерсә дә, Наҗиягә кырыс карап:

– Юк, чәйләп тормыйбыз. Барасы җирләребез бар, – дип, машинасын кабызды.

Кузгалырга дип торганда, өйдән Зарифулла килеп чыкты.

– Син, Фатих энем, кайчан сала башлыйсың инде өеңне? – диде, Нәркизәгә игътибар да итмичә. – Ату безнең өй бөтенләй ятим калды.

– Озакламый тотынабыз, – диде Фатих һәм кузгала башлады.

– Туктале, – диде Зарифулла. – Бераз сөйләшеп утырыйк.

– Сөйләшер чаклар алда әле, Зарифулла абый, ә хәзер без киттек.

– Ай-һай теге хатынның күзләре, – диде Нәркизә. – Озаграк торсак, сине ашап бетерә иде.

– Син бигрәк инде.

– Әйдә, мунчаңны күрсәт, – диде Нәркизә.

Алар мунчага кереп чыктылар, бакчаларны карап йөр-деләр. Рәхәт җил, исеп, Нәркизәнең чәчләре белән уйнады. Һава монда шундый саф, үпкәләргә йомшак агым булып керә. Үзеннән-үзе күңел күтәрелә. Ишегалдында үскән усак яфракларының җилдә лепердәп утырулары да серлелек бирә.

– Яратам мин усак агачларын, – диде Нәркизә. – Алар урман-таулар турында шигырь сөйләп торалар кебек.

– Әйе, табигатьтә шигърият күп. Ләкин дөнья безне сукырайта, саңгыраулата. Һәм без табигатьнең матурлыгын күрми башлыйбыз.

– Моннан күчмичә дөрес эшләгәнсең, – диде Нәрки-зә. – Киләчәктә бу урынны дачниклар сырып алачак. Ашыгырга кирәк. Давай, бүгеннән эшчеләр эзли башла. Нигезеңне тергезик. Аннан башкаларына тотынырбыз.

Бу хәбәр Фатихны бик сөендерде.

– Мин сине бүген чишмәләр башланган тауга алып барам. Анда сиңа тагын да ныграк ошар дип уйлыйм, – диде ул.

Нәркизә нидер уйланып бара иде, Фатихның сүзен әллә ишетмәде, әллә ишетеп тә игътибар бирмәде. Аның уйлары еракта. Ул инде күңеленнән Баланлы урамының ике ягына да матур йортлар тезеп чыккан, һәм ул йортларда бала-чагалар мыжлап тора иде.

Фатих исә, эшләрнең уңай якка борылуына шатланып, эчтән генә нидер көйләп бара. Менә алар чишмәле тауга килеп җиттеләр. Гаҗәеп тау иде бу: ике чишмә ярышып ага, ләкин берсенең суы – тешеңне сындырырлык салкын, икенчесенеке – кайнар. Җитмәсә, ике чишмә арасында зур гына тау куышы бар.

– Борынгы бабаларыбызның йорты бу, – диде Фатих. – Борынгылар аңгыра, надан булган, дибез. Бик акыллы булганнар алар. Куышларын җылытыр өчен кай-нар чишмәне үзләренә борганнар. Әнә анда керамикадан эшләнгән торба ватыклары бар. Мунча да янда, салкын чишмәсе дә.

Фатих Нәркизәне, җитәкләп, бер борылышка алып китте. Анда керә торган урын таш белән ябылганлыктан, ул гадәти тау булып кына күренә. Фатих иплəп кенә ташны ачты. Ләкин эчтә караңгы булганлыктан, берни күренми, бары тик чишмәләр чылтыравы гына ишетелә иде. Күзләр караңгылыкка бераз ияләшә төшкәч, тау куышының бу өлеше шактый зур һәм үзенчәлекле икән-леге беленде. Куышның бер ягында нindидер ялтыравык ташлардан ясалган берничә ятак, икенче ягында зур гына табигый бассейн.

– Мин куркам, бу берәр каберлек түгелме икән? – диде Нәркизә, Фатихка сыена төшеп.

– Курыкма, матурым. Моның торак урын икәнлеге күренеп тора. Әнә бит тегендә, югарырак җирдә, стеналар ялтыравык ташлар белән бизәлгән. Ятак урыннары да матурлап бизәлгән. Кешеләр бит бервакытта да тигез генә яшәмәгән. Ярлырак катлам тауның олы куышында идәндә йоклаган, югары катлам әйбәт урын сайлаган. Алар йоклар алдыннан, бәлки, менә бу бассейнда коенганнардыр. Су белән, ләм белән дәвалануны без әле генә уйлап таптык дип йөрибез. Борынгылар аны күптән белгән. Куышның икенче борылышында җып-җылы сазлык. Анда кереп, бер ун-унбиш минут утырганнан соң менә бу бассейнга чумып аласың да бөтен арыганнарыңны шунда калдырып чыгасың.

– Син үзең монда яшәгән кебек сөйлисең, – диде Нәркизә.

– Мин монда яшәп карадым бераз. Әтине колхоз арышын урлауда гаепләп төрмәгә япмакчы булганнар. Әти белән мин, шунда качып, бер кыш яшәдек. Ә әтигә бу куышның барлыгын бабай әйтеп калдырган. Бабай безнең мулла булган, ул өендә балалар укыткан. Шәхес культы елларында үзен тотып сөргенгә озатачакларын белгәч, бабай шушында, яшеренеп, биш ел яшәгән. Әби төннәрен ашарына илткән. Шулай, матурым, бу тау куышын безнең шәхси йортыбыз яки бабайлардан калган мирасыбыз, дияргә була. Аны беркем дә белми.

– Тикшерә китсәң, тамырларыбызның нинди тирәндә икәнлеген аңлыйсың. Без бит ничәмә-ничә гасырлар буынсыз, илсез-җирсез халык исәпләнеп яшәдек.

– Әйе, – диде Фатих, – минем монда йорт салырга йөрүемне күпләр юләрлек дип саный. Ә бит борынгыдан килгән, бик тирәнгә җәелгән тамырларны балта белән генә чабып өзеп булмый. Алар йөрәккә тоташкан. Мин йорт кына салмыйм, хәтерләрне яңартам.

Нәркизә Фатих белән килеште. Мондагы соңгы йортларны да бетерсәң, күпме кешенең нәсел тамыры корыячак.

Алар озак кына сүзсез тордылар. Аннары Нәркизә:

– Шушындый әйбәт урынны нигә яшереп яткырасың? Кешеләргә әйтмисең?

– Ярамый. Сәясәт бит гел үзгәреп тора. Ә кеше үзенең гомерен саклап калырлык урыны, сыеныр куышы барлыгын белеп яшәргә тиеш. Безнең бит әле тормыш алда.

Фатихның бу сүзләре Нәркизәнең күңелен яктыртып җибәрде. Димәк, бу баһадир ир үзенең киләчәген Нәр-кизә белән бәйләргә тели. Шулайдыр, юкса беркемгә күр-сәтмәгән тау куышларын Нәркизәгә күрсәтмәс иде. Кеше катлаулы зат шул. Без хатын-кызлар ир-атларга үз акылыбыздан чыгып бәя бирәбез. Әйе, җирдә һәр кеше үзе бер дөнья. Ә дөнья һәр көн саен яңара, үзгәрә, байый яки ярлылана. Үзе белән бергә дөнья безне дә үзгәртә. Тормыш алдыбызга куйган төеннәрне чишәр өчен, кайвакыт түбәнлеккә төшәбез. Ә кайвакыт вакыт агымының дулкыны безне югары чөя. Югарылыкта калу авыррак, чөнки анда таяну ноктасы кечерәк.

Нәркизә тау куышында шундыйрак фәлсәфи уйларга бирелеп алды. Тиккә генә Әбүгалисина тау куышында гый-лем җыеп ятмагандыр. Нәркизәнең уйларын укыгандай, Фатих та күңел тирәнлекләрен күрсәткәләп алды.

Алар шулай күңел мәйданнарының зурлыгын, акыл көчләренең тирәнлеген, хисләр диңгезенең кайнарлыгын барладылар. Якынаю физик яктан гына түгел, ә рухи яктан да булырга тиешлеген һәр икесе яхшы аңлый иде.

Көн кызуландымы, тау куышы бөркүләнеп китте.

– Әйдә үзебезнең бассейныбызда коенып алабыз, – диде Фатих. – Суы йомшак аның, кызлар тәне кебек.

– Күп кызларның тәнен капшагансыңдыр, ахрысы.

– Әйдә үткәннәргә кайтмыйк. Үткәннәр үткәндә калсын.

Нәркизәнең дә үткәннәрне актарасы килми иде, Фатихның тәкъдимен бик теләп кабул итте. Алар тиз арада чишенеп аттылар. Караңгыда бары тик Нәркизәнең ап-ак тәне генә чамалана иде.

– Мин куркам, – диде Нәркизә, Фатихка тотынып.

Фатих аны кочып алды:

– Курыкма, матурым. Үлсәк, икәү үләрбез.

– Минем үләсем килми.

– Беркөнне бит үзең, туйдым бу эштән, туйдым дөньясыннан, үләселәрем килә, дигән идең.

– Беркөн бит ул.

– Аннан соң нәрсә үзгәрде соң?

– Бик күп нәрсә, – диде Нәркизә.

«Без бер-беребезне, гомер буе эзләгән мәхәббәтебезне таптык», – дияргә уйлаган иде, ләкин уйларын эченә яшереп калдырды. Ирләрнең кайбер нәрсәләрне белмәүләре хәерле. Арада мәхәббәтнең бетүе дә мөмкин. Ул минем җанымны үзе ачсын. Шунда мин аңа кадерлерәк булырмын. Ирләр бит алар бала-чага кебек: бала-чага үзенең катлаулы уенчыгының серенә төшенсә, башка уенчык эз-ләргә тотына. Ә инде уенчык тапмый икән, үзенең хыялы белән гап-гади нәрсәләрне йә самолёт, йә поезд итә. Хәт-та нәни куянны да бала хыялы арысланга әйләндерә ала. Ирләр дә нәкъ шулай: үз фантазиясе белән хатын-кызны йә бик матур, йә бик ямьсез, йә акыллы, йә җүләр ясый.

Нәркизәнең күңеленнән: «Фатих мине нинди категориягә кертә икән?» – дигән сорау узды. Һәм ул җиңелчә калтыранып куйды. Фатих, аны кочып торганлыктан, бу калтырауны тойды, ләкин сәбәбен аңлый алмады. Кеше, гадәттә, күңелендә туган сорауга җавап таба алмаганда шулай югалып кала. Фатих Нәркизәне кайнарланып үбә башлады. Нәркизәнең тәне иркәләү көтә иде, ул да назга наз белән җавап бирде. Аннары алар тау куышы эчендәге күлдә коенып чыктылар. Күлнең суы искиткеч йомшак, аны җир өстендәге бернинди су белән чагыштырырлык түгел. Алар суда эрегән кебек булдылар. Тәндәге бөтен әгъза бераз гына тыгызландырган һава кебек тоелды. Хәтта сөякләр йомшарган төсле иде.

Күлдә коенуның рәхәтлеген бернинди наз белән дә чагыштырырлык түгел иде. Гадәттә, без табигать биргән рәхәтлекләрне шулай булырга тиеш дип кабул итәбез. Шуңа күрә аның кадерен белмибез.

– Бу күлнең суы яшәртә, ди торган иде эти. Ләкин мин, әле ул чакта бәләкәй булганлыктан, яшәрәсем түгел, тизрәк үсәсем килә иде. Шуңа күрәдер, ахры, әтинең күл турындагы барлык сүзләре истә калмаган. Бары тик шунысы хәтердә: күлнең серен ачарга ярамый. Кешеләргә сөйләдеңме, аның тылсымы бетә.

Коенып чыккач, аларга сөртенергә дә туры килмәде: үтәли искән җылы, йомшак, назлы җил «эһ» дигәнче тәннәрен киптерде. Су коенганчы җил юк иде кебек, каян килеп чыкты ул? Тау куышына ничек үтеп керде?

Фатих белән Нәркизә аптырашта калдылар.

– Табигатьтә без белмәгән көчләр күп шул, – диде Фа-тих.

– Минем уйлавымча, бу хисләр өермәсе тудырган хикмәт. Күлнең суы да бит тәннәребезне ничек назлады. Шушы назның иркә кулы, җаннарыбызда яшеренеп яткан хисләр кайнарлыгы белән бәрелеп, шундый наз өермәсе тудыргандыр. Без бит дөньяның күзгә күренгән өлешен генә беләбез. Башкасы турында уйланмыйбыз. Табигатьне рәнҗетәбез. Юкса бит һәр күренештә бер хик-мәт ята.

– Әйе шул, – дип килеште Фатих Нәркизә белән.

Бераздан алар, киенеп, тау куышыннан чыктылар. Фатих Нәркизәнең чәчләренә игътибар итте:

– Карале, Нәркизә, чәчләрең ефәк кебек йомшарган.

Нәркизә чәчләрен тотып карады. Алар кулны иркәләрлек дәрәҗәдә йомшарган, хәтта куерган да кебек иде. Фатихның беләгендә бүре тешләгән урыннар чокыр-чокыр булып тора иде, алар да юкка чыккан.

– Мондый урынны ташлап каядыр күченергә мөм-кинме соң? Бая әйткәнемчә, өй сал һәм моны озакка сузма. Эшне яратып эшли торган кешеләр тап. Синең өеңне корып бетерүгә, Баланлыны үстерә башлыйбыз. Район җитәкчеләре белән сөйләшүне үз өстемә алам. Кирәксә, Казанга барып җитәрмен.

Алар шундый күтәренке рухта аерылыштылар.

* * *

Фатихларга кирпечне күпме кирәк, шуның кадәр китереп ташладылар. «Цементны каян табарга икән?» дип йөргәндә, авылдан ерак түгел бер тигезлеккә нефтьчеләр килеп урнашты. Ә нефтьчеләр бораулый башлауга,

цементы, зур-зур руслары, торбасы-ние һәм тагын әллә нәрсәләр чутсыз-чамасыз китереп өелә. Зур кибәнне бер кәҗә ашап бетерә алмаган кебек, Фатих әз-әзләп ташыган цемент һәм башка кирәк-яракларның кимүе сизелмәде дә. Хәйләкәр Фатих өем зур чакта кирәген ташып куйды. Аннары Ташлыярда ферма салып, каядыр китеп барган әрмәннәрне эзләп тапты. Әрмәннәр салыначак өйгә урын әзерли башладылар. Өй тирәсендә иске йорт калдыклары, яртылаш җимерелгән мич һәм башка кирәксез әйберләр аунап ята иде. Аларны бакча артындагы чокырга күмделәр. Подвал өлешен казытырга экскаватор чакыртырга туры килде. Фатихның Расихка йомыш белән барасы килми иде, ләкин, кирәк йөрәкне җиңәр, диләр. Барырга туры килде. Расих Фатихны кочып алды:

– О-о, – диде ул, – тәкәббер дустым килгән икән. Ди-мәк, мин дә кирәк булганмын.

– Ташла әле шул урынсыз төрттерүләреңне.

– Йә, ярый, үпкәләмә. Сагынган идем үзеңне, – диде Расих. – Минем күп сөйләшергә яратканымны беләсең бит инде. Өй сала башлагансың дип ишеткән идем. Молодец!

– Ишетеп тә өлгергәнсең: әллә җилләр хәбәр итеп тора инде сиңа?

– Бу нәрсәгә ишарәләвең? – диде Расих.

– Йә инде, үпкәләмә, – диде Фатих, – мин бит болай гына.

– Үпкәләмим. Тик синең элекке дусларыңнан читләшә баруың гаҗәпләндерә мине.

– Йомыш чыккач, менә килдем бит. – Һәм Фатих нигә килгәнлеген Расихка сөйләп бирде.

– Ярый, – диде Расих, – экскаватор җибәрермен, тик менә экскаваторщик...

– Нәрсә?

– Авырып больницада ята. – Расих аның исерек килеш эшкә чыгып, экскаваторы белән авуы һәм каты имгәнүе турында сөйләп тормады. Монда үзен дә гаепле саный иде. Бәлки, шуңа сүзне куертасы килмәгәндер.

– Син минем инженер икәнлекне онытма. Экскаваторда гына эшли беләм инде мин.

– Алайса, бик шәп! – Расих Фатихның җилкәсенә сугып куйды.

Җилкәдән кагуны Фатих малайсыту дип саный иде. Расих кагылуыннан куырылып киткәндәй булды. Ләкин эчке кичерешләрен тышка чыгармады.

Сөйләшү киеренкелек төсен алганчы, Расихны телефонга чакырдылар. Ул, конторасына кереп киткәндә, Фатихка: «Кайгырма, дускай, бүген үк илттерермен», – дип вәгъдә бирде. Фатих, «Москвич»ына утырып, өенә кайтып китте.

Расих сүзендә торды. Экскаваторны кичкә китереп җиткерделәр. Расих – эчкерсез, шәп дус. Ә ул аны ни өчендер артык якын итә алмый. Әллә аның тиз арада зур дәрәҗәгә ирешүе Фатихны көнләштерә микән? Бәлки, моңа Рәшидә сәбәпледер? Алай дисәң, Рәшидә белән Расих арасында берничнди мөнәсәбәт булганы юк. Ул үзе артык эгоисттыр. Бөтенесен үзе генә эшләргә тырыша. Ә бит дөньяда ялгызың гына ерак китеп булмый.

Була бит шулай: кайберәүләр ни тотса, шуны булдыра. Эшне уйнап кына эшли. Алар фәлсәфи уйларга бирелеп утырмыйлар. Расих әнә шундыйлардан. Фатихның үзенә мондый сыйфатлар хас түгел. Ул эш башлаганчы озак уйлана. Уйлары тормыш турында, яшәү мәгънәсе турында фәлсәфәгә алып кереп китә. Характерлар төрлелеге бу ике дусны әле якынайта, әле ерагайта иде.

Шулай уйланып, Фатих экскаватор янына чыгып китте. Үзенчә ул аны «әрлән» дип атады. Расих «әрлән»нең шәбен биргән икән, ташлы җирне шытырдатып умыра гына. Әрмәннәргә «әрлән» казып чыгарган балчыкны бакча артына ташырга кушылды. Фатих эшкә сусаган иде, төшкә кадәр бер минутка да туктап тормады.

Эшчеләргә аш пешерергә Фатих Наҗияне чакырды. Наҗия моңа сөенеп риза булды. Рәшидә ирен ташлап Ташлыярга киткәч, ул эчтән куанып йөрде. Авылда бүтән хатын-кыз юк, Фатих миңа карар дип уйлады. Ул әле Фатихның карашы еракта икәнен белми иде.

Көндезге аш әзер булуга, Наҗия эшчеләрне тамак ялгап алырга чакырды. Бүген Фатихның күңеле күтәренке иде. Ул күлмәген салып ташлады. Салкын чишмә суын чиләге белән аркасына койды. Ашаганда ул, тагын да ачы-ла төшеп:

– Патша сарае корып куячакбыз әле без монда. Сәлаховның селәгәе тагын да ныграк аксын, – диде.

– Зур өйне ничек җылытмак кирәк? – дип, Наҗия сүзгә кушылды. – Акча да күп кирәктер аңа?

– Анысы безнең эш, – диде Фатих, шикләнергә урын калдырмаслык итеп. Ул беркөнне, районның шәһәрара сөйләшү пунктыннан абыйсына шалтыратып, үзенең нинди мәшәкатьләр белән йөрүен сөйләгән иде. Абыйсы: «Мин сиңа тагын акча җибәрермен, – дигән иде. – Ләкин кирәкле материалыңны тизрәк алып куй. Дөньяны үзең беләсең. Бөтен нәрсәнең асты өскә килергә тора».

Абыйсы телефоннан ачык кына әйтмәсә дә, Фатих аның тел төбен аңлады. Димәк, югарыда ниндидер үзгәрешләр көтелә. Ә югарыда берәр үзгәреш булдымы – халык кесәсендәге акча яна. Безнең илдә гомер буе шулай булган. Барлык авырлыкны халык күтәргән.

Шушы хакыйкатьне истән чыгармыйча, Фатих кирәк-ле материалларны, бәясенә карап тормыйча, каян тапты, шуннан сатып ала башлады. Район җитәкчеләренә кем-нәрдер Фатихның бу кыланышларын җиткерде. Аны про-куратурага чакырдылар. Йорт өчен алынган материалларның каян алынуы турында документ сорадылар. Фатих каушап калмады: үзенең йорты колхоз рәисе Селәгәй тарафыннан җимертелүе турында прокуратура тарафыннан бирелгән белешмә кәгазен китереп салды һәм:

– Сез үзегез миңа йортны салуны колхозга йөкләргә тиеш идегез.

– Сезгә колхоз бүрәнәләр китергән.

– Зурайткыч пыяла аша карасаң, бәлки, алар бүрәнә булып күренәдер, – диде Фатих.

– Бу сезнең урлашуыгызны акламый, – дип, өстәлгә сукты прокурор.

– Акланырбыз, – диде Фатих. – Урыныгыздан очкач, үзегез, йөгереп килеп, миннән гафу үтенерсез әле.

Ишекне шартлатып ябып, Фатих чыгып китте.

* * *

Теге әрмәннәрнең берсе Зарифулланың ирдән кайткан кызы Наҗиягә күз салгалап йөри башлады. Наҗия үзе дә аңа карата битараф түгел иде бугай: һәрхәлдә, теге бәндәнең карашы аның кытыгын китерә һәм Наҗияне шырык-шырык көлдерә иде.

Фатих, бу хәлне сизүгә, теге бәндәне чакырып алды да, көрәктәй куллары белән түшеннән умырып тотып: «Син безнең татар кызларын аздырырга уйлама. Әгәр тагын бер сине Наҗия белән күрсәм ботарлап атачакмын. Ә хәзер марш, эшеңдә бул! – дип кисәтте.

Бу сөйләшүне Наҗия дә ишетеп торган икән, ул, кайнарланып, Фатихка ташланды:

– Син нигә үзеңә кагылмаган эшкә тыгыласың? – диде ул. – Эт печән ашамас, кәҗәгә ирек бирмәс. Шушы буладыр инде. Мин туйдым бу тау башында ялгыз яшәүдән. Шуны бел: мин синең яклавыңа мохтаҗ түгел. Ни теләсәм – шуны эшлим.

– Эшләрсең, – диде Фатих. – Тик син шуны аңларга тиеш: безнең татар кызлары, чит милләт кешеләре белән якын мөнәсәбәткә кереп, татарлыгын җуярга тиеш түгел. Син чибәр, акыллы хатын, татарлар арасыннан үз тиңеңне табарсың.

Һәм чынлап та бераз вакыт үтүгә, күрше авылның Исмәгыйль исемле бер татар егете Наҗияләргә йортка керде. Туйлар ясап маташырлык хәлләре юк идеме – болар тыйнак кына итеп яшәп киттеләр. Наҗиягә күз атып йөрүче теге бәндә каядыр юкка чыкты.

* * *

Өй салу мәшәкатьләре белән бераз вакыт Фатих Нәр-кизә янына бара алмый торды. Кабинетына кереп килүче Фатихны күргәч, Нәркизә:

– Син дә исәнмени әле? – дип каршы алды.

Фатих акланып маташмады.

– Шулай инде. Без барыбыз да үзебезгә берәр нәрсә кирәк булганда гына өтәләнеп йөрибез. Ә үз кирәгебезне алгач... – Фатих сүзен әйтеп бетермәде, хатын-кыз алдында артык туры сүзнең кирәксез икәнлеген төшенеп, фикерен йомшарта төште: – Кичерә алсаң кичер, Нәркизә. Вакыт тыгыз булды. Акланырга теләмим. Бик теләгәндә, вакытны табып була...

– Димәк, сиңа минем кирәгем калмады.

– Юк, Нәркизә, эш белән артыграк мавыктым. Үзебезнең мөнәсәбәтләр турында уйландым. Безнең мөнәсәбәтләр гади генә түгел. Синең хакта уйлый башласам, унсигез яшьлек егеткә әйләнәм. Хыяллар мине югарыга күтәрә. Әйе, Нәркизә, синсез яшәү мөмкин түгеллеген аңлаганга килдем. Син минем җаныма ниндидер очыш бирдең. Бу очыш мине әкият батыры итте. Мин, оча торган келәмгә утырып, айга, йолдызларга менеп төшәм. Югарыдан үземнең балачагыма, яшьлегемә карыйм. Яшьлек илем ничек матур булмасын, анда сине таба алмагач, миңа күңелсез булып китә.

– Матур сөйлисең, хәтта ышанасы килә, – диде Нәр-кизә.

– Ышану-ышанмау – синең эш. Әмма синсез торган көннәрдә эчемдә бушлык сизәм. Әйтерсең мин һава тутырылган шар: син булганда, ул шар тыгыз, түгәрәк, талгын җилдән дә күккә күтәрелергә тора. Сине озаграк күрми торсам, ул шарның тыны чыга башлый һәм бераздан бөтенләй шиңә.

– Хәзер шарың шиңде дә, кабартырга килдеңме? Күр-шеңдә генә кияүдән кайткан хатын яши. Шуның белән кабартыгыз шарны.

– Ул үз парын тапты инде.

– Ә-ә. Шуңа күрә монда килгәнсең икән.

Фатих, аның сүзләренә игътибар итмәгәндәй, үзенекен тукыды:

– Сине күргәч кенә яратуның ни икәнен аңладым.

– Синең мине яратуың – урланган алма ашау. Урлап ашаган һәр нәрсә тәмлерәк була. Әгәр без бергә тора башласак, мин үз бакчаңдагы теләсә кайчан өзеп ашый торган гап-гади алмага әвереләчәкмен. Син яңадан чит бакчалардан алма өзәргә тырышачаксың.

– Тыелган җимеш кенә тәмле була, димәкче буласың, аңлыйм. Бәлки, синең сүзләрдә хаклык бардыр. Тик син-дә әле мин аңлый алмаган нииндидер көч бар.

– Мәсәлән?

– Без бит җилне, үзебез сулый торган һаваны, йөрәктән туктаусыз бәреп чыккан хисләрне күрмибез. Синдә дә әнә шундый күзгә күренми торган нииндидер көч бар. Бәлки, бу рухи байлыктан киләдер, бәлки, матурлыгыңнандыр. Матурлык, минемчә, нииндидер энергия бүлеп чыгара.Әгәр шулай булмаса, без матурлыкка сокланмас һәм шун-нан рәхәтлек, көч алмас идек. Димәк, матурлыкның сок-ландыру көче бар. Матурлыкта тагын дәртләндерә, шатландыра алу көче дә бар.

Мин кайчакта уйланып куям: ни өчен кояш ничәмә-ничә еллар буе гел янып тора? Моңа, әлбәттә, марксистларча, материя булган һәм булачак, дип җавап биреп булыр иде. Ләкин, минемчә, дөнья без уйлаганга караганда күпкә катлаулырак. Әйтик, миллионнарча кешеләр бер-берсен ярата. Ни өчен? Ратканда хисләр, кичерешләр йөзләрчә-меңнәрчә тапкыр көчәя. Бәлки, шушы хисләр кояшка ягулык булып хезмәт итәдер. Безнең кәефебез дә бит һәрвакыт кояш чыгу-чыкмаудан тора. Иртән торуыңа тәрәзәдән кояш керсә, кәефең күтәрелеп китә.

Алар мәхәббәт турында сөйләшә башласалар, унҗиде-унсигез яшьлек егет һәм кызга охшап калалар иде. Тормыш тәҗрибәсе, яши-яши тупланган акыл хисләр тарафыннан җиңелә. Иңнәрне басып торган еллар югала.

Нәркизә сәгатенә карап аһ итте:

– Эш сәгатем бетеп килә икән бит, ә мин объектларга барырмын дигән идем. Сүз бозау имезә, диләр. Бозауны күп имезгәнбез.

– Әйе, – диде Фатих, – без күп вакыт сабыйларча фикер йөртәбез. Бу – дөньяны кабат ачарга теләүдән, күрәсең.

Нәркизә өстәлдәге кәгазьләрен бер папкага тутырды һәм: «Боларны өйдә карармын инде», – дип, урыныннан торды.

– Өеңә үзем генә илтеп куйыйммы? – диде Фатих.

Ун-унбиш минуттан алар Нәркизәләргә кайтып җиттеләр.

– Матур оя коргансың, – диде Фатих, фатирны карап. Нәркизәне күп тапкырлар өенә кайтарып куйса да, Фатихның эчкә узганы юк иде. – Гөлләр яратасың икән.

– Әйе. Мин, өйгә кайту белән, гөлләрем белән исән-ләшәм. Башларыннан сыйпап чыгам. Гөлләр үзләрен ярат-канны аңлыйлар. Балкып китәләр.

Өч бүлмәле фатирының ике тәрәзәле почмак бүлмәсен-дә гел гөлләр генә иде. Фатих аларның күбесен беренче тапкыр күрә. Ахрысы, безнең як гөлләре түгелдер.

Нәркизә гөлләрнең башларыннан сыйпап чыкты. Бер гөлнең, ул сыйпаганда, хәтта чәчәге ачылып китте.

– Әй, матуркаем минем, – дип, Нәркизә ачыла башлаган чәчәккә иелеп иренен тидереп алды. – Ике ел көттем бит мин синең чәчәк атуыңны. Ә-ә, белдем, белдем сереңне. Син минем кунагым хөрмәтенә ачылгансың. Мине көнләштерим дидеңме?

Фатих гөлләр арасында балкып торган Нәркизәне кочагына алды.

– Кадерлем минем! Син бит үзең иң матур чәчәк.

– Мактама, йә ышанып куярмын.

– Ә син ышан. Син күңелеңнең матурлыгын гөлләреңә бирәсең икән. Ә күңел матурлыгы өләшкән саен арта гына бара. «Саран баемый, юмарт байый» дигән сүзләр дөрестер, күрәсең.

Фатих Нәркизәнең гөлләргә тартылуын бу кырыс һәм әшәкелек белән тулы дөньядан бераз булса да арынып тору һәм күңелен сафландыру дип аңлады.

Әйе, Фатих яхшы аңлый: табигатькә якынрак булган саен, кешенең күңеле байый төшә. Табигать җанның фильтры – бөтен пычракны үзенә җыеп кала.

Чәйне алар бергәләп әзерләделәр. Табын янында ханым күңелен ачып ташлады:

– Ирем Кодрәт калдырган фатир бу. Ирем үземнән уналты яшькә өлкән иде. Карьерасын булдырган, күтәреләсе биеклеккә күтәрелгән. Институт бетереп кайткач, мине ул эшли торган конторага эшкә җибәрделәр. Кодрәт, мине беренче күргәч, баскан урынында катып калды һәм йөрәген тотып кәкрәеп төште. «Абый, абый, ни булды?» – дидем мин һәм графиннан су алып эчердем. Аңа бераз хәл кергәндәй булды. Ул арада секретаре да килеп керде. «Тагын йөрәкме, Кодрәт Абдуллович? Мәгез әле даруларыгызны эчегез». Секретарь өлкән яшьтәге хатын. Күрәсең, Кодрәт Абдулловичка нинди дару кирәген белә иде.

Бераздан Кодрәт Абдулловичка хәл керде. Секретарь, миңа үтергеч караш ташлап, горур атлап чыгып китте. Секретаре чыгып киткәч, ул: «Сез кем, монда нишләп йөрисез?» – диде ул, минем күзләремә карап. Аның күзләре бераз гына яшьләнгән, ләкин яшь пәрдәсе астында гаҗәпләнүдән туган нур чаткылары чагыла иде. «Мине сезгә эшкә җибәрделәр, инженер итеп». Мин аңа документларымны суздым. Ул бераз уйланып торды, аннары, өстәлгә сугып: «Иң зур сәхнәләрне бизәрлек шушындый гүзәл туташны төзелешкә җибәрергә бары тик безнең ил җитәкчеләре генә булдыра аладыр», – диде.

Кыскасы, Кодрәт Абдуллович мине кадрлар бүлеге җитәкчесе итеп куйды. Эшкә килгәндә, минем өстәлемдә һәр көн бер роза чәчәге утыра иде. Аның хатыны күптән түгел генә вафат булган икән. Мине гаиләдә артык иркәләп үстермәделәр. Тугыз бала идек. Әти-әни колхозда эшли. Өйдә һәр бәрәңге чутлы иде. Шуңаргадыр инде, Кодрәт Абдуллович мине сорарга килгәч, бишкуллап риза булдылар. Миңа бу нининдидер уен гына булып тоелды. Кодрәт белән яши башлагач кына, чынбарлыкның роза чәчәкләреннән генә тормавын аңладым. Юк, син уйлама, Кодрәт начар кеше түгел, ләкин артык көнче иде. Юкса аның белән торганда, мин бер ир затына да күтәрелеп карамадым. Тик көнләшер өчен сәбәп кирәкмидер, күрәсең. Шушы көнчелек аның болай да авырткан йөрәген туктаусыз кимерә торгач, эшләп утырган җиреннән өстәлгә башын салып вафат булды.

Менә шулай, Фатих иптәш...

Фатих бераз сүзсез торды, аннары Нәркизәнең күзләренә карап:

– Матур хатын-кыз турында, гадәттә, гайбәт күп йөри. Синең хакта да: «Мондый матурлыгы белән карт ире-нең күзләренә генә карап ятмыйдыр, әллә кайларда сөяркәләре бардыр!» дип сүз таратучылар булгандыр. Чынлыкта исә ямьсезрәк хатын-кызлар бик сексуаль бит.

– Кызык, – диде Нәркизә, – ни өчен алай икән?

– Сәбәбе, минемчә, монда бик гади. Әйтик синең кебек чибәрләрне һәрбер ир-ат күз белән, караш белән наз-лап китә. Чибәр хатын-кызларның күбесе сокланулы карашларның назында коенудан рәхәтлек таба. Җаннары шуннан канәгатьлек ала. Ә ямьсез хатын-кызларга мондый наз эләкми. Алар инде җан сусавын тән аша алу юлларын эзли башлыйлар. Тагын шунысы да бар: алар үзләренчә чакыру ташлыйлар. «Менә мин дә синнән ким түгел, артымнан өере белән ир-атлар чаба», – дип мактану өчен дә алар, теләкләренә ирешкәндә, назларын кызганмыйлар. Ә күп ир-атка рухи якынлык бөтенләй кирәкми. Бөтен рәхәтлекне ул тән якынлыгыннан гына ала. Ә бит җан белән тән гармониясе генә кешене бәхетле итә.

Нәркизә Фатихның кочагына ныграк сыена төште. Алар хәтта бер-берләренең йөрәк тибешен ишеткәндәй булдылар.

* * *

Наҗия иргә чыкса да, Фатихларның эшчеләренә аш пешерүдән туктамады. Якын-тирәдә эш тә юк, ә Фатих азмы-күпме акчасын түли. Исмәгыйльгә кияүгә чыккач, Наҗия Фатихка күзен майландырып карамый башлады. Беренчедән, Исмәгыйльнең астыртын гына үзен күзәтүен сизде, икенчедән, ул ирен чын-чынлап яратты. Исмәгыйль аны бар яктан канәгатьләндерә иде.

Фатих Нәркизәләрдән кайтуга, Наҗия табын әзерли башлады.

– Әзерләмә. Соңрак ашармын. Эшчеләр янына барыйм әле.

Эшчеләр хуҗаның зәңгәр «Москвич»ын күрүгә кызурак кыймылдый башлаганнар иде. Алар, Фатихны бөтенләй күрмәгәндәй, кулларында ут уйнаттылар.

– Шәп, шәп, егетләр! – дип мактап куйды Фатих. Ачулануга караганда мактау көчлерәк тәэсир иткәнен белгән Фатих хуплау сүзләренә саранланмады.

– Болай булса, егетләр, эшне август ахырларына бетереп тә куярсыз әле.

– Жук-жук, – диде бригадирлары. – Август айларына түбәне җабып булса бик җакшы.

– Тизрәк эшләсәгез, сезне саллы гына премия көтә.

Егетләргә бу сүзләр дәрт өстәде. Алар нибары биш-алты сәгать кенә йокладылар.

Кешене терелтергә дә, үтерергә дә бер сүз җитә, диләр. Фатих бу хакыйкатьне җае чыккан саен файдалана килде. Тырыша торгач, сентябрь ахырларына өйгә кереп утырырлык булды. Фатих сүзендә торды: сөйләшенгән бәягә тагын җидешәр мең өстәде.

Өй әзер. Инде эш табу турында уйларга вакыт. Нәр-кизәнең Баланлы авылын үстерү хакында фикерен исенә төшерү дә урынлы булыр. Юкса бер авыл өчен ике өй, ике тавык та бер әтәч бик аз. Нигезләргә җан өрә башларга кирәк.

Кайвакыт без күктән эзләгәнне җирдән табабыз. Фатих белән дә шулай булды. Нәркизә янына баргач, директор ханым үзе бу хакта сүз башлады.

– Карале, Фатих, – диде ул. – Миңа срочно инженер кирәк. Конвейрлар туктаусыз ватылып тора, техника иске. Ә безнең инженер белгәннәрен дә онытып бара, картайды. Әйдә, алын әле шушы эшкә.

Фатихка бу тәкъдим бик ошады, ләкин ул:

– Минем бит профиль башка, булдыра алырмынмы икән? – дип маташты.

– Техника кайда да бер инде ул, – диде Нәркизә. – Синең бит башың шәп эшли. Хәер, башың гына түгел...

Нәркизә сүзен әйтеп бетергәнче үк, Фатих елмаеп куйды. Нәркизә, бик тапкыр һәм урынлы сүз әйттем, дип, үзеннән канәгать калды. Ир-атны ул мәсьәләдә бераз мактап алсаң, күңелләре була. Бичара ире Фатихтан бик күп мәртәбәләр калышса да, Нәркизә канәгатьлек белдерсә, бик шатлана иде.

Фатих тәкъдимне кабул иткәч, Нәркизә чиксез шатланды. Ул сейфыннан виски чыгарып, ишекне бикләп куйды.

– Әйдәле, бу вакыйганы билгеләп үтик.

– Бик рәхәтләнеп, – диде Фатих.

Алар олы фужерның төбенә кырык-илле грамм тирәсе эчемлек агызып чәкешеп эчтеләр. Аннары Нәркизә, шешә һәм фужерларны урынына куеп, сейфын бикләде.

Шуннан соң алар кичкә кадәр заводны карап йөрделәр. Дөрестән дә, бөтен нәрсә искергән. Кирпечләрне яндыра торган мичләр менә-менә ишелеп төшәргә тора. Кирпечләре чыгарып өйгәндә үк ярыла, чатный башлый. Кояшта озаграк ятканнары бөтенләй таркала. Кояш ашамасын өчен, кирпеч өемнәрен кара полиэтилен белән каплап куйганнар. Өстәвенә бөтен эшне хатын-кызлар башкара. Бу турыда әйткәч, директор:

– Бездә бит хезмәт хаклары бик түбән. Ипи белән чәйгә генә җитәрлек. Ирләр мондый акчага эшләп йөрми.

– Әйе, – дип килеште Фатих аның белән. – Ир-егетләр хәзер нефтькә тартыла. Нефтьчеләр акчаны көрәп ала, эшләре дә мондагыдан җиңелрәк.

Заводны карап чыкканнан соң, Фатих: «Моны бөтен-ләй яңартмый торып, юньле кирпеч чыгарып булмаячак», – дигән нәтиҗәгә килде.

Фатих эшли башлаганда, күп кенә завод-фабрикаларны шәхси милеккә әверелдерү башланган иде. Эшчеләргә, зур вәгъдәләр биреп, ваучер дип аталган кәгазьләр тараттылар. Кемдер аны ниндидер компанияләргә илтеп бирде һәм берничә елдан бер-ике кап шырпылык акча алды. Кемнәрдер ярты литр аракы бәясенә завод хуҗаларына сатты.

Нәркизә белән Фатих, шушы ваучер дигән хикмәтле кәгазьләрне күпләп җыю аркасында, кирпеч заводын үзләренеке иттеләр. Моңа беркем көнләшеп карамады. Киресенчә, акчаларын суга салучы юләрләр дип санадылар. Завод кайчан да булса тернәкләнеп китәр дип уйламадылар.

* * *

Фатих белән Нәркизә таркалып бара торган кирпеч заводын акционерлык җәмгыяте, дөресрәге, үзләренеке иткәч, эшне яңа җиһазлар кайтартудан башладылар. Фатих бер ай буе Германиядә кирпеч сугу серләренә төшенеп йөрде. Кызыл балчыкның үзенчәлекләрен тикшерде, аңа ниләр кушылуын, балчыкка буяу сеңдерү технологиясен һәм башкаларны өйрәнде. Кайткач, банктан ссуда алып, Германиядән яңа машиналар кайтартты. Германиядән кайтартылган машиналарда эшли белүче юк иде, аннан бер инженер чакыртырга туры килде. Завод әкрен-әкрен кояшта таралмый, яңгырда шикәрдәй эреми торган кирпечләр чыгара башлады. Мондый кирпечләрне өй салырга йөрүче яңа байлар ябырылып алды. Моңарга Фатихтан бигрәк Нәркизә шатланды. Ул, Фатихка карап, шаянрак тонда:

– Баш бар икән миндә, – диде.

Фатих аны аңламыйчарак торды:

– Әйе, башың да, бүтән җирләрең дә Аллага шөкер синең, – диде.

– Юк, син мине дөрес аңламадың.

– Дөресе ничек соң?

– Сине үземә инженер итеп алып дөрес эшләгәнмен.

– Ул яктан караганда мин дә директорымнан уңдым.

Нәркизә нурланып киткән күзләрен Фатихка төбәде. Аңа Фатих белән эшләү бик рәхәт. Тик нигәдер өйләнешү турында сүз катмый. Рәшидәсе елгыр булып чыкты: Фатихтан китүгә, Расих кочагына барып керде. Хәзер, импортный машинага гына утырып, байбикә булып йөри. Расих инде автоколонна начальнигы түгел, зур бер регионда урнашкан НГДУ начальнигы.

Гомер буе куллары эштән бушамаган Рәшидәне баштарак эшсезлек интектерде. Ләкин Расихтан авырга калгач:

– Хатын-кыз эшләр өчен түгел, бала табып, аны тәрбияләү өчен туган, – дип, үз-үзен юатты. – Безнең әти-әниләр гомер буе колхозга бил бөкте. Нинди рәхәт күрделәр соң? Миңа да алар юлын кабатларга димәгән.

Расих Рәшидәне затлы киемнәргә төрде. Рәшидә матур җырлый иде. Баштарак ул бу һөнәрен күрсәтергә ояла иде. Ләкин мәҗлесләрдә өнсез этәч кебекләрнең дә җырлавын күргәч, күкрәк киереп җырлый башлады. Әнә шулай мәҗлесләрнең иң кирәкле кунагына әйләнде.

Расих үзенең элекке хатынын күз алдына китерде. Аңа нибары унсигез яшь кенә булуга карамастан, бер-нәрсәдән дә ояла белми иде. Мәҗлесләрдә, ире алдына менеп утырып, чуп-чуп Расихны үбәргә тотыну дисеңме, чит-ят ирләр өстәл астыннан аның шәрә ботын сыйпаганда, Расих күрми дип уйлап, тегеләр белән чытлыклануы, өйдә, бөтенләй йөгәнсезләнеп, анадан тума хәлдә йөрүе Расихның ачуын чыгара иде.

– Өйгә кем кермәс, бераз киенебрәк йөрергә кирәк, – дигәч, ул:

– И Расихчигым минем, матур җирләремне син күрсен дим бит мин. Кара инде менә аякларны, алтын багана кебек бит. Төп-төзләр. Билемнең нечкәлеген күр. Кайсы дустыңның хатынында бар мондый гәүдә?!

– Ир-атлар күлмәк аша да күрә белә.

– Күлмәк ул кешенең кимчелеген яшерер өчен. Ә минем яшерерлек кимчелегем юк.

– Шулай да, мин матур, дип, шәрә йөрергә ярамый.

– Ярар алайса, – диде иркә хатын, үпкәләп, – йоклаганда да тун киеп ятармын. Битемә пәрәнҗә каплармын. Матур ботларым күренмәсен өчен, ярлы студентлар кия торган каткан джинсы киярмен.

Һәм Энҗе (яшь хатынның исеме Энҗе иде) берничә көн ире янына чалбар киеп ятты. Расихның теләге уянып аңа кагыла башласа, тагын да йомыла төште: «Кагылма, сиңа монашка кирәк иде бит», – дип, ирен читкә тибәрде.

Расихның түземе озакка бармады: беркөнне ул бераз кызмача кайтты. Ул ярсулы иде. Хатынының кара пәрәнҗәсен умырып алды да яңагына чабып җибәрде. Чалбарын салдырып, арт чүмеченә чалбар каешы белән берне сылады. Энҗе кычкырмады, тавыш чыгармады. Бары тик усал елмаеп:

– Минем байлыкларымны сагындыңмы? Ирләр үзләрен үзләре аңламыйлар. Сезнең барыгызга да бит шушы кирәк. – Энҗе үзенең кендек астына сукты. – Йә, кил, тансыклагансыңдыр.

Расих, тыңлаучан бозау кебек, хатынын кочып алды. Хатыны аны, «әһ» дигәнче чишендереп, үзе янына салды. Энҗенең сыгылмалы яшь тәне Расихны урап алды. Төн аларны татулаштырды. Иртән Расих канәгатьлек белән юынырга кереп китте. Аның артыннан, песи кебек кенә басып, Энҗе дә керде һәм, Расих иелгәндә, иренең муенына менеп атланды.

– Шушылай юынабыз, – диде ул.

Расих дәшми генә ризалык бирде. Авызына ниндидер әчкелтем тозлы су кергәнен сизгәч кенә, эшнең нәрсәдә икәнен аңлады.

– Аһ, син мине мыскыл итәргә уйладыңмы әле?!

– Аңгыра авыл мужигы син. Сексның күп төрле икәнен аңламыйсың.

– Аңламыйм һәм аңларга да теләмим. Вон! Бүген үк чыгып кит минем өемнән!

– Китәм, ләкин артымнан елап килмә.

Энҗе шул китүдән күзгә-башка күренмәде. Ир озын колаклар аша гына аның Казанга китеп, Расихтан ун яшькә олы, күп кибетләр хуҗасы булган бер түрәккә чыгуын ишетте.

Энҗе турында ул оныткан да булыр иде, көннәрдән бер көнне Расихларның күршесе – Ислам исемле утызга якынлашып килүче өйләнмәгән егет – исерек көе Расихларга килеп керде. Кулына ниндидер чүпрәк-чапраклар тоткан, күзендә – яшьләр.

– Китте бит безнең Энҗебез, – диде һәм мышкылдап елап җибәрде.

Исерекләрне Расихның җене сөйми иде, күршесен этеп-төртеп чыгарып җибәрмәкче булды. Ләкин егет чыгарга теләмәде, ишек яңагына тотынып мышкылдавын белде:

– Их, Энҗе, Энҗе! Ике ирне ятим итеп китеп югал-дың...

– Нинди Энҗе, нинди ике ир? – диде Расих, берни аңламыйча.

– Нинди булсын, уртак Энҗебез. – Егет тагын кулындагы чүпрәкләре белән күзләрен сөртеп алды. – Белмәгән булып кыланма. Төнлә – синеке, көндез минеке иде ул. Менә истәлеккә шушылар гына калды. – Егет Энҗенең эчке киемнәрен тотып селкеде. Расих аларны шунда ук таныды, ләкин сер бирәсе килмәде.

– Энҗе андый хатын түгел иде, бар, чыгып кит, юкса башыңны яруым бар. – Расихның кулында гантельләр иде, ул аларны егетнең борын төбендә уйнатып алды. – Гөнаһтан башаяк.

Егет, исерек булса да, хурлыкка төшкән ирнең теләсә нинди акылсызлык эшләргә сәләтле икәненә төшенерлек хәлдә иде, кулындагы киемнәрен идәнгә ташлап чыгып китте. Ләкин Расих: «Тукта, ал бу чүпрәкләреңне», – дип, егет артыннан аларны аягы белән типкәләп коридорга чыгарды. Егет өенә кереп җитмәгән иде әле, сөяккә ташланган эттәй, чүпрәкләргә ташланды.

Расих, йөрәген тотып, караватка ауды. Рәшидә кибет-тән кайтып кергәндә, Расих, һаман шулай түшәмгә карап, хәрәкәтсез ята иде. Рәшидә куркып китте.

– Абау, Ходаем, ни булды? Әллә чирләдеңме? – диде ул.

Ире озак кына тавыш-тынсыз ятты. Рәшидә, сумкасын кухня ягында калдырып, Расихның караватына утырды.

– Ни булды, Расих? – дип кабатлады ул.

– Булмады! – диде Расих.

– Алайса... – дип, Рәшидә нидер әйтергә теләгән иде, Расих сикереп торды да:

– Төпченмә! – дип, тупас тавыш белән хатынына кычкырды.

Рәшидә, ни уйларга белмичә, баскан урынында катып калды. Ул ничектер өшеп киткәндәй булды. Күңеленнән үкенү, рәнҗү хисләре кайнар агым булып узып китте дә, бераздан каты төенгә әверелеп, бугазга утырды. Рәшидә ирен мондый хәлдә күргәне юк иде, аптырашта калды.

– Нәрсә, – диде ул, – әллә мин берәр ярамаган эш эшләдемме? Берәр сүз әйт инде, Расих.

– Хатын-кызның нәрсә эшләп йөргәнен кем белгән?! Сез барыгыз да бер чыбыктан сөрелгән.

– Әстәгъфирулла, бу ни дигән сүз?

Расих аңа җавап бирмәде. Ул үткәннәрнең барысы да артта калды дип уйлый иде. Ләкин вакыт елгасында күпме чайкап та бетми торган пычраклар була икән шул.

* * *

Нәркизәнең Фатихка кияүгә чыгуы бик гади булды. Фатих, иске «Москвич»ын ташлап, үзенә яңа машина алган иде. Ул, ярым шаяртып, ярым җитди итеп:

– Яңа йортка яңа машинада яңа хатын алып кайтырга исәп бар. Бәлки, сез, Нәркизә ханым, риза булырсыз? – диде.

Бу сүзне күптән көткән Нәркизә:

– Яңалыкны яратам мин, – диде һәм Фатихның машинасына утырды.

Фатих белән Нәркизә өйләнешеп Баланлыда ике катлы йортка күчеп яшәп ятканда, заводта эшләүче ике балалы хатынның өе янды. Ул завод янына урнашкан эшчеләр бистәсендә искереп аварга торган өйдә яши һәм күптән үзенә яңа фатир сорап йөри иде. «Өен үзе яндырган» дигән сүзләр дә таралды. Ничек кенә булмасын, ике балалы хатынны урамда калдырып булмый иде. Районда төзелеш эшләре бөтенләй бармый диярлек. Фатих Нәркизәгә:

– Нишлибез инде, матурым? – диде. Бу сорауны ул Нәркизәнең шәһәрдәге фатирын күз алдында тотып сорады.

Ләкин Нәркизә, аңламаганга салышып:

– Бу, бәлки, Ходайдан килгән хәбәрдер.

– Нинди хәбәр?

– Баланлыны үстерә башларга вакыт.

– Әйе шул, һаман сузабыз. Ә калган эшкә кар ява. Беләсеңме нәрсә: совет чорыннан калган ватык кирпечләр өемен юлга түшибез. Беренчедән завод ишегалды чистарып, зураеп китәчәк. Икенчедән, Баланлыны үстерәбез икән, монда эшчеләр йөртергә автобус җибәрергә туры киләчәк.

– Әйе, – дип килеште Нәркизә, – ләкин ике балалы хатынны киләчәктә булачак йортка күчереп булмый.

Фатих җилкәсен кашып куйды. Нindидер сүз әйтергә теләп тә кыюлыгы җитмәгәндә аның шулай эшләгәнен белә иде Нәркизә. Сорап куйды:

– Йә, нәрсә әйтергә телисең?

– Әллә, мин әйтәм, синең шәһәрдәге фатирыңа кертеп торабызмы? Аннан соң берәр нәрсә уйларбыз.

– Булмый, ул фатирга кешеләр керттем инде мин.

– Алай... Нишләргә икән соң? Балалары яшь. Балалы кешеләрне фатирга кертергә тормыйлар бит.

Нәркизә бераз уйланып торды. Үзе бала табып карамагач, бу мәсьәлә аңа җитди тоелмады. Әмма хатын-кыз буларак кешеләрне кызгану хисе күңелендә сүнмәгән иде.

– Йорты янган хатынга вагон-йортны бирсәк? – диде Нәркизә.

– Әйбәт фикер, – диде Фатих. – Тик син, аны бакчама алып китәм, дигән идең түгелме?

– Безнең бакчабыз уртак. Җиләк-җимешне үстереп йөрисе юк. Аларны Аллаһы Тәгалә үзе үстерә.

Фатих, хискә бирелеп, Нәркизәне кочагына алды. Мондый чакта алар унҗиде яшьлек кыз белән егеткә әвереләләр. Күңелләр нечкәрә, хис-тойгылар уртак учакка әверелеп, ялкыннары күккә күтәрелә, учакның очкыннары гашыйк җаннарның күзләренә күчә.

– Акыллым минем, – диде Фатих, хис давылы бераз ерагайгач, – рәхмәт сиңа!

– Син нәрсә? – диде Нәркизә. – Рәхмәтең нигә? Вагон-йорт синеке. Монда сиңа рәхмәт әйтергә кирәк.

– Без күп чакта яныбыздагы әйберне ерактан эзлибез, – диде Нәркизә. – Тик вагон-йортны тегендә-монда күчереп йөртә башласак таралып бетмәсме?

– Иплә эш иткәндә таралмас. Ләкин бит безнең максат – Баланлыны үстерү.

– Теге хатын монда күчәргә риза булырмы соң? Эшкә йөрергә ерак бит.

– Әлегә үзебезнең машинага утыртып йөртербез. Йортлар күбәеп киткәч, автобус җибәрербез.

Эшкә килүгә үк, Нәркизә йорты янган Хәтимәне чакырып кертте. Эшнең нәрсәдә икәнен сөйләп бирде һәм:

– Барасыңмы Баланлыга вагон-йортта торырга? – дип сорады.

Хәтимә шатлыгыннан елап җибәрде, озак кына сүзен әйтә алмый торды.

– Барам, барам, Нәркизә Хафизовна. Безнең ата-бабаларыбыз Баланлыдан. «Баланлыны Ташлыярга күчерәләр икән» дигән хәбәрләр йөри башлагач, бабай урманга чыгып китеп юк булган. Үле гәүдәсен дә тапмадылар. Миңа бервакыт әти нигезебезне күрсәткән иде. Теге безгә бирәсе вагон-йортыгызны, мөмкин булса, үзебезнең нигезгә утыртсагыз иде.

– Карарбыз, – диде Нәркизә.

Хәтимәне ике баласы белән Баланлыга күчереп куйдылар. Вагон-йортны үзләренең элекке нигезләренә утыртып куйгач, шатлыгының иге-чиге булмады. Тик балаларны кемгә калдырырга? Наҗия риза булса гына инде. Ул йөкле хатын. Көне буе өйдә утыра. Ире Исмәгыйль берничә атна шабашниклыкта йөреп, кесәләрен акча белән тутырып кайта да өч көн айнымастан эчә. Дүртенче көнне суррогат аракы эчәгеләрен кискәли башлагач, На-җиягә кычкырып ята башлый: «Сөт, сөт китер миңа. Үләм, тизрәк сөт китер!» Наҗия өч литрлы банка белән аңа сөт китерә. Исмәгыйль аның бер литрга якынын тын да алмый эчә. Аннары: «Ух!» – дип, тирән сулыш ала. Тирән сулыш берничә тапкыр кабатлангач, яңадан банкадан сөтне эчә башлый. Ахылдау-ухылдаулар янә берничә тапкыр кабатлана. Ярты сәгать дигәндә өч литр сөтнең тамчысы да калмый. Исмәгыйль, зур батырлык эшләгәндәй, буш банка төбенә озак кына карап тора да, берни булмаган кебек, йөгереп ишегалдына чыгып китә. Салкын чишмә суы белән озак кына баштанаяк юына. Аннары табынга утыра. Исмәгыйле табынга утыргач, На-җия мыгырдап ала:

– Озакламый балабыз туарга тора, ә син һаман шул «шайтан суы»ннан арына алмыйсың.

– Бетте, хатын, бетте! Бүген бер илле грамм салып бир дә, бүтән аны авызыма егып салсалар да эчмим.

Наҗия, аңа ышанып, илле грамм салып бирә. Исмәгыйльгә җан керә.

– Карале, карчык, синең белән йоклаганымны да хәтерләмим. Әллә мин югында берәрсе белән кети-мети уйныйсызмы? – ди һәм үзе бик шаян сүз әйттем дип шаркылдап көлә.

Ләкин Наҗиягә көлке түгел, ул:

– Оятсыз, өчәр атна кайтмый йөргәндә, үзең әллә кемнәрне кармалыйсыңдыр әле, – ди.

– Мин бит шаярдым гына.

– Андый сүзне уйнап әйтсәң дә уйлап әйт.

– Бетте, бетте, карчык. Кил әле, үзеңне бер пәп итим. – Исмәгыйль, кулын сузып, хатынын үзенә тартып китерә һәм комсызланып үбә башлый. Мәхәббәткә-назга сусаган Наҗия иренең кочагында эри. Исмәгыйль, аны җиңел генә күтәреп, мунча алачыгына алып кереп китә. Анда иске карават тора. Караватта Зарифулланың тузып таушалган туны, Наҗиянең кайчандыр мәктәпкә киеп йөргән пальтосы һәм тагын әллә нинди иске-москылар түшәлгән. Исмәгыйль Наҗияне чишендерә башлый.

– Ярамый, – ди Наҗия. – Балага зыян килүе бар.

– Ярый, – диде Исмәгыйль. – Без сак кына кыланырбыз.

– Син назла гына, миңа синең иркәләвең-назлавың да җитә.

– Ансыз ничек назлап була соң? – Исмәгыйль аптырап кала. Ул тагын хатынын үбә башлый.

Хатыны:

– Менә туачак малаеңны иркәлә. Аңа өченче ай китте бит инде, – дип, иренең кулларын үзенең эченә куя.

Исмәгыйль сак кына эчне сыйпый башлый. Ләкин кул-лары әкрен-әкрен түбәнгәрәк төшә. Наҗиянең түземе бетә.

– Әйдә, – ди хатын, ярым пышылдап, – тик кара аны, саграк кылан.

– Курыкма, – ди Исмәгыйль, – балага зыян китерерлек итеп эшләмибез инде аны. Җаен гына белергә кирәк.

Наҗия иренең соңгы сүзләрен ишетми дә. Ул инде наз диңгезендә йөзә. «Йа Алла, шушы назларны биргәнең өчен мең-мең рәхмәт сиңа!» – ди ул эченнән. Ярый әле Исмәгыйле дәртле. Аның куллары кагылуга, Наҗия учак булып кабына. «Әллә зәмзәм суы дигәннәре шушы микән?» – дип уйлый ул, рәхәтлектән изрәп...

Элек эш юклыктан интеккән Наҗия хәзер Хәтимәнең балаларын карап юанды.

* * *

Нәркизә белән Фатих, үзара киңәшеп алганнан соң, акционерлар җыелышы җыярга булдылар. Төп мәсьәлә завод эшчеләрен фатирлы-йортлы итү иде. Сүзне Нәркизә башлады:

– Менә минем өстәлемдә бер папка гариза ята. Һәр-кайсына яшәр өчен уңайлы оя кирәк. Әгәр сез каршы булмасагыз, мин шундый тәкъдим кертергә уйлыйм. – Җыелган кешеләрнең сулыш алганлыклары да ишетелерлек тынлык урнашты. Барысының күзләре Нәркизә Хафизовнага текәлде. – Эш болай тора, кадерле хез-мәттәшләр. Үзегез күрәсездер, хөкүмәт эшчеләр турында кайгыртудан туктады. Без йортларны үзебезгә үзебез салырга тиешбез.

– Ничек?

– Кайда?

– Нинди акчага? – дигән сораулар яңгырады.

Сорауларга җавап бирергә Фатих торып басты:

– Акционерлар җәмгыяте советының урынбасары буларак, мин сезгә шуны әйтә алам. Йортларны Баланлыга салырга уйлыйбыз. Анда урын күп, һавасы әйбәт.

Шулвакыт Хәтимә сикереп торды:

– Баланлы авылы заводтан ун-унике чакрым гына. Бакча артында урман. Агачларында сандугачлар сайрап тора.

Хәтимәнең бу сүзләреннән соң бер ир сикереп торды:

– Безгә сандугачлар түгел, торырга йорт кирәк. Шәһәр фатирларына газ кергән, анда газ булачакмы? Минем ишетүемчә, анда электрны өзгәннәр. Хәтимә ярый ла директор машинасында гына йөри. Ә без унике чакрымны тәпи-тәпи атларбызмы?

– Сүземне тыңлап бетермәдегез, – диде Фатих тыныч кына. – Без Нәркизә Хафизовна белән бу мәсьәләләр турында сөйләштек. Беркемне дә Баланлыга көчләп алып барырга җыенмыйбыз. Әгәр үзегез яши торган урын ошый икән – рәхим итеп шунда калырсыз. Йортларыгызны комиссия карап чыгар. Дөресен әйтергә кирәк: без берьюлы илле гаиләгә йорт салып бирә алмыйбыз. Бу эш әкренләп барачак.

– Әкренгә калгач булмый инде ул, – диде кемдер.

Ләкин Фатих, ишетмәмешкә салышып, сүзен дәвам итте:

– Бая кемдер, нинди акчага, дип сорады. Бу бик мөһим сорау. Сезнең кулларыгызда завод акцияләре бар-мы? Бар. Менә шушы акцияләрегезне безгә тапшырасыз!

– Аннан завод тулаем сезгә күчәме?

– Бездә бит илле кеше эшли. Менә түбә ябарга черепица цехы ачарга җыенабыз. Тагын эшчеләр кирәк. Баланлыга совет заманнарыннан калган кирпеч ватыкларыннан юл түшибез. Эшчеләрне үзебезнең автобус йөртәчәк! Юл түшәү эшләре башланды да инде. Юл тигез булсын өчен Ык буеннан гравий алырбыз. Аралаштырып салгач, юлыбыз тигез дә, ныклы да булыр.

Арадан берсе әйтеп куйды:

– Алайса, коммунизмга барасы гына калган инде.

– Сез көлмәгез, бу эшләрне күктән төшкән фәрештәләр эшләмәячәк. Әйбәт яшисебез килсә, үзебезгә тырышырга туры килер.

– Ә минем Баланлыда яшисем килми, – диде бер яшь кыз. – Анда күңел ачарга ни клубы, ни балалар укытырга мәктәбе юк.

– Әзергә бәзер кем дә килеп утыра. Менә сез бөтенесен үз кулларыгыз белән салып карагыз.

Зал гөжләп алды. Кемнең нәрсә әйткәнен аңларлык түгел иде. Кешеләрнең уйлары, умарта күче кебек, килеп сарырга урын тапмый йөрде. Фатих, уйлар болытын кылыч белән кисеп төшерергә теләгәндәй, кискен хәрәкәт ясады һәм:

– Тыңлап бетерик! – диде.

Фатихның тавышы залда күк күкрәгәндәй яңгырады. Зал тынды. Фатих сүз башлады:

– Бүген-иртәгә Баланлыга йортлар сала башлыйбыз. Кемнәр анда яшәргә тели, кулларыгызны күтәрегез.

Унлап кул күтәрелде.

– Ярый, – диде Фатих, канәгать калып.

Җыелыштан шаулашып таралыштылар. Күпләрнең күзләрендә өмет чаткылары ялтырады. Чит илдән яңа җиһазлар кайтарткач, кирпеч өчен ясала торган кызыл балчыкны ныгытырга яңа технология кулланган, сыйфат бик нык яхшырды. Кирпечнең бәясен шактый югары күтәрүгә карамастан, хаҗәт арта барды, заводка күп керем керде.

Җыелыштан соң Фатих белән икәү генә калгач, Нәр-кизә, назлы итеп:

– Яныма кил әле, Фатих, мин үземдә бик нык үзгәреш сизәм.

– Нинди үзгәреш?

– Хәзер. – Нәркизә ишекне бикләп куйды һәм күк-рәкләрен ача башлады. – Менә кара әле: алар тыгыз-ланганнан-тыгызлана баралар. Анысы бер хәл, кул да тидереп булмый – авырталар.

Фатих Нәркизәнең күкрәкләрен тотып карамакчы бул-ган иде, ханым артка чигенде.

– Кагыла күрмә, Фатих. Күлмәккә очлары тиеп кит-кәндә дә шундый нык авырталар. Әллә миндә берәр яман шеш бармы икән?

– Юкны сөйләмә, син балага узгансың. Врачка күренергә кирәк. Алып барыйммы соң?

– Мин куркам!

– Нәрсәдән куркасың?

– Шигем дөрес булса? Кил әле, Фатих, тотып кара әле.

Фатих Нәркизәнең күкрәгенә кагылуга, тегесе кычкы-рып җибәрде:

– Ипләп! Авырттырасың.

– Нишләтим соң инде алайса?

– Йомшак кына итеп сыйпа, назла.

– Кулларым да кытыршы.

– Ә син битләреңне тидереп тор.

Мондый чакта хатын-кызга аеруча наз кирәген аңлый иде Фатих. Ләкин аның Рәшидәсе, авыл кызы буларак, оялчан иде. Ул хәтта баштарак ире янына киемнәрен сал-мый ята иде. Фатих аны көчләп диярлек чишендерә, ә инде тәненең яшеренрәк урыннарына кагыла башласа, тәне җыерыла, бөтен мускуллары тартыша иде. Андый чакта Фатих, үпкәләп икенче якка борылып ятып, йок-ланганга салыша. Рәшидә, үзен гаепле сизеп, иренә якыная. Фатих бераз вакыт уянмаган кебек кылана. Рәшидә, аны чынлап йоклый дип уйлап, иренең тәне буйлап тидерер-тидермәс кенә итеп кулын йөртә. Кулы үзендә юк нәрсәгә барып төртелгәч, йөрәге еш-еш тибәргә тотына. Шулвакыт Фатих Рәшидәне кулларыннан эләктереп ала. Шаярып: «Әле син минем байлыгымны урламакчы идеңме? Моның өчен җәзаның катысы биреләчәк», – дип, Рәшидәне кочагына ала. Рәшидә әйбер урлагандай кыенсына, әмма ире кочагында барысы да онытыла.

Ә Нәркизә, бернинди тартынусыз, теләсә кайсы җирен Фатихка күрсәтә. Назлата, сыйпата. Өйдә вакытта ул бө-тенләй киемсез дә йөри ала. Аның бер марҗа дусты ирләрдән ничек яраттырырга икәнен гел өйрәтеп тора:

– Өйдә син ачыграк кием ки. Шул ук вакытта бөтен байлыгың күренеп тә тормасын. «Ялгыш» иелгәндә генә, матур җирләрең күренеп китсен. Ләкин «ялгыш» иелүләр озакка сузылмасын, юкса ирләр хәйләңә төшенергә мөм-кин. Ирең телевизор карый яки газета укый, ул барыбер берни күрми, дип уйлама, алар карамый да күрәләр. Тагын, аш-су пешергәндә, синең кулың камырлы яки башка берәр нәрсәгә буялган булырга мөмкин. Менә шунда, уф, эссе, алъяпкычымны гына чишеп җибәр әле, дисең. Бераздан кофтаңның төймәләрен ычкындыртасың. Шунда инде аларның түземе бетә, ашларың көтеп торыр, дип, сине күтәреп ала.

– Андый хәйләләрдән башка да мине Фатихым бик ярата, – ди Нәркизә.

– Яратышу озакка бармый ул, – ди Нәркизәнең дус-ты. – Синнән чибәррәк берәр кәнтәй башын әйләндерсә, йөз төрле хәйлә табып, алар синнән качарга телиләр. Миңа ышанмасаң, иреңне берәр төрле сынап кара.

Нәркизә дустына ышанып җитми, ләкин Фатихны сынап карыйсы килә.

Бүген Фатих Нәркизәне врачка алып барды. Врач аның йөкле икәнлеген раслады.

Нәркизә берничә көн ире янында йокламады. Фатих икенче бүлмәгә кереп ятты. Иртәнге аш вакытында Нәркизә:

– Без һаман синең белән сөяркәләр кебек яшибез, – дип сүз башлады. Дөресрәге, Фатихның икенче бүлмәгә чыгып ятуы ачуын китергән иде аның.

– Ничек «сөяркәләр кебек»? – диде Фатих.

– Язылышмыйбыз. Бала тугач, атасын кем дип яздырырмын?

– Мәхәббәт бит ул иректе. Аны рәсмиләштерсәң, ул үзен читлектәге кош кебек сизәчәк.

– Мәхәббәт, бәлки,ирекледер, ләкин без мәхәббәт алдында ирекле түгел.

– Кирәк санасаң язылышырбыз.

Бу хакта сүз шуның белән бетте. Икесен дә эш бөтереп алды. Баланлыга бульдозер китертеп, йорт салырга нигез әзерли башладылар. Кирпечләр китереп аудардылар. Төзү бригадасы төзелде. Эш башлаганда, эшчеләргә Фатих болай диде:

– Сез йортны үзебезгә салабыз дип салыгыз. Никадәр тизрәк эшләсәгез, шулкадәр тизрәк өйле булырсыз.

– Без караңгыда да эшләр идек, электр юк бит, – диде эшчеләр.

Ут юклык күп кыенлыклар китереп чыгара: бетон-измә болгаткычны электрга тоташтырсаң, эшләр күпкә тиз-рәк барыр иде. Әле ярый суны, комны ерактан ташыйсы юк. Кул астында гына чишмә ага. Эшчеләр чишмәгә торба суздылар: насос та кирәкми, чишмә югарыдан агып төшкәнлектән, үз көче белән торба буйлап теләгән җиргә килә. Ә ком тау итәгендә генә.

Эшкә вагон-йортта яшәп ятучы Хәтимә дә чыкты. Ләкин аның эшләп йөрүен башкалар өнәп бетермәде. Аны яңа йортка дәгъва итә дип уйладылар.

Берсе хәтта:

– Сиңа нәрсә кирәк тагы? – дип, аны куып җибәрмәкче булды.

Ләкин Хәтимәнең нияте изге иде.

– Аллага шөкер, миңа берни кирәкми. Барыгызга да рәхмәт. Кыен чакта ярдәм иттегез. Яхшылыкка яхшылык булсын дип чыгуым.

– Алай булса ярый, – диделәр.

Үзең өчен эшләгән эш һәрвакыт тизрәк бара, сыйфаты да яхшырак була. Эшчеләр беренче йортның кемгә буласын белмәсәләр дә, күңеленнән һәркем: «Бу минеке булырга тиеш», – дип өметләнде.

Йорт төзелеп беткәч, Нәркизә белән Фатих, болар янына килеп:

– Йә, кемгә бирәбез инде бу өйне? Курчак йорты кебек матур салгансыз. Молодцы. Теләгәндә, моны ике катлы итеп тә була. Фронтонны кирпечтән салуыгызны хуплыйм. Хәзер такта, гомумән, агач материаллары бик кыйммәт. Ә кирпеч үзебезнеке, – диделәр.

– Без кирпечне күбрәк тә суга алабыз, – диде бер таза гәүдәле хатын.

Ирләр аның сүзеннән көлемсерәп куйдылар.

– Теге ватылган конвейрны син әйләндереп торсаң гына инде.

– Ә нигә әйләндермәскә? Сезнеңише ирләрнең өчесен бер кесәгә салып йөртә алам мин, хәчтерүшләр!

– Ягез, егетләр, кызлар. Сүзнең кыскасы яхшы. Кемгә бирәбез бу йортны?

– Сез бит начальник, сез әйтегез.

– Начальниклар һәрвакыт хаклы була дигән сүз юк бит әле.

Сүзгә Нәркизә кушылды:

– Җирәбә салсак?

– Дөрес, җирәбә салабыз.

Җирәбә салу хокукын Нәркизәгә бирделәр. Җирәбә дигәннәре озын таяк иде. Кемнең кулы иң өскә чыга – өй шуныкы.

– Безгә дә катнашырга ярыймы? – диде яңарак өй-ләнешкән пар. Хатынының «йөге» инде сизелерлек иде, ул, кешеләр кысмагае дип, таякка үрелде.

Өч-дүрт тапкыр таяк сайланды, бәхәсләр кызды. Ничә тапкыр тотынсалар да, өскә йөкле хатын чыкты. Кайберәүләр, моңа ризасызлык белдереп: «Һәр гаиләдән берәр генә кеше катнашсын», – дигән тәкъдим кертте. Моны һәммәсе хуп-лады. Йөкле хатынны: «Бар, матурым, син читтәрәк тор, балаңа зыян килмәсен», – дип, бер эскәмиягә утырттылар. Иң соңгы көрәш башланды, һәм бу юлы өскә йөк-ле хатынның ире чыкты. «Тфү! – диде бер хатын. – Бәхетленең бәхете алдан йөрер, диләр иде, дөрес икән!»

Бернинди хәрәмләшү булмаганлыктан, кайберәүләр ризасызлык белдерсә дә, бәхәс купмады. Ир, үзенә бәхет китергән таякны тотып, хатыны янына килде. Алар үзара нидер сөйләштеләр һәм бер читтә күз яшьләрен җиңе белән сөртеп торучы хатын янына килделәр: «Хәдичә апа, бу йорт сезгә тиеш, – диде йөкле хатын, – сез бит инде бу заводта егерме биш ел эшлисез. Биш кеше бер бүлмәдә торасыз».

Бәхетле парга кемдер йорт ачкычын биреп өлгергән иде, йөкле хатын аны: «Рәхәтен күрегез!» – дип, Хәдичәнең кытыршы кулларына салды. Кулыңа килеп кергән бәхет ачкычын үз теләгең белән башка кешегә бирү җиңел түгел иде, әмма бу парлар үзләренең шушы гамәлне кыла алулары белән моңарчы кичерелмәгән сөенеч кичерделәр. Бу рухи биеклеккә күтәрелүнең татлы җимешен тату иде.

Хәдичә шатлыгыннан елап җибәрде. Дөрестән дә, аның тормышы авыр иде. Ул туберкулёз белән авырый. Кызы, кияве белән тора. Кызы әнисенең чире үз балаларына йогар дип бик курка. Хәдичәнең өйдә үз савыты, үз кашыгы. Башка савыттан ашарга рөхсәт ителми. Зур бүлмәне икегә бүлеп, аңа карават белән өстәл сыярлык кына урын калдырдылар. Кухняга кереп, савыт-сабаларга тотынмасын өчен, аңа бер электр плитәсе белән эмале коелган кәстрүл бирделәр. Хәдичә үз почмагы булуга шат иде, тик оныклары белән аралаша, назлый алмау гына йөрәген кысып-кысып ала.

Ул, кулына ачкыч тоткан килеш, барысына да рәхмәт әйтеп чыкты. Соңыннан:

– Мондый зур йортта мин нишләрмен соң? Әгәр сез рөхсәт итсәгез, мин бу йортны кызым белән киявемә бирер идем. Аларның бит ике баласы үсеп килә. Ә мин үземнең иске почмагымда калырмын. Әгәр инде миннән җирәнмәсәгез, кияүләр торган якка берәр кеше кертә алам, – диде.

Шунда бер аксак карт:

– Мин дөньядагы бөтен чирләр белән чирләп чыктым инде. Чуртым да булмады. Чир курыккан кешегә генә тия. Ә мин шайтанның үзеннән дә курыкмыйм. Фатирыңа кертәсеңме мине, Хәдичә? – дип сорады.

– Кияүләр монда күченү белән керерсең, – диде Хәдичә.

Аксак Миңнулла каравылчы булып эшли иде, сөе-неченнән биеп алды.

Фатих белән Нәркизә гап-гади кешеләрнең шундый киң күңелле, кешелекле булуларына сөенеп бетә алмадылар. Алар, өйне салып бетергәч, тавыш-гауга кубар, һәркем бу өйгә үзен лаеклы санар, дип уйлаганнар иде. Әнә ничек матур тәмамланды. Тик менә ут булмау гына шатлыкны бераз киметте.

Нәркизә, Фатихка карап:

– Әллә нефтьчеләргә барып карыйсыңмы? – диде.

Баланлыдан өч чакрым чамасы гына ераклыкта нефть промыселы урнашкан иде.

– Әйе, – диде Фатих, – Баланлы үсәргә тиеш. Ут белән дә эш җайланыр дип уйлыйм.

Һәм Фатих, вакытны озакка сузмыйча, нефтьчеләр янына китте. Промысел җитәкчесе аны караңгы чырай белән каршы алды. Фатихның гозерен ишеткәч, чырае тагы да караңгыланды:

– Без кешеләргә кулдан килгән ярдәмне күрсәтергә тырышабыз. Ә алар урлашалар.

Промысел җитәкчесе авыр сулап куйды, Фатих аңа сорау бирергә кыймады.

– Бер начар сыер бөтен көтүне пычрата шул, – дип, аның хәленә керергә тырышты.

– Иң кыйммәтле торбаларны урлаганнар – эче пыялаланган торбаларны.

Җитәкченең сүзләреннән Фатих уңайсызланып китте. Өй салган вакытта ул үзе дә моннан шактый цемент ташыган иде. «Эскерттән йолкынган берничә сәнәк печән», – дип караган иде ул үзенең бу гамәленә. Тик эскерттән йолкучылар ул гына түгел икән шул.

Ташлыярда яшәгәндә, көпә-көндез нефтьчеләрнең торбаларын колхоз тракторы белән тарттырып кайтучыларны шактый күп күрде ул. Ләкин: «Минекен урламыйлар әле», – дигән фикер аның миенә нык кереп урнашканлыктан, бу угрыларга күз йомып карады. Баксаң-күрсәң, бөтенесе халыкныкы бит. Кайдан ни генә урласалар да, халыкка тиешлене урлау булып чыга.

Нефтьчеләргә авыл халкы ачулы иде. Чөнки нефть-челәр җирне, суны, хәтта һаваны пычраттылар. Һөҗүм ике яклы барды. Урманнар тракторлар белән тапталды, басу-кырларга нефть акты, чишмәләр корыды. Ә авыл кешеләре нефтьчеләрнең пыяла эчле торбаларын, урлап, җир асты чишмәләренә төшерделәр. Һәркем коелы булды. Бакча үстерә башлады. Ләкин бу бәхет озакка бармады. Нефть кими барган саен, нефтьчеләр эш ысулларын үзгәртә барды. Башта җир астына Ык суын кудырып, су басымы белән нефтьне өскәрәк күтәрттеләр. Аннары, күпчелек өлеше судан торган нефтьне бераз чистарту нияте белән, нефть катламына химикатлар җибәрә башладылар. Бакчадагы җиләк-җимеш агачлары саргайды. Нефтьчеләргә болай да сагаеп караган халык хәзер аларны каһәрләде, үчләнде. Эченә парафин утырмасын өчен пыялаланган торбаларны халык, урлап, койма баганаларына утыртты. Абзар-кураларның багана-киртәләре торбадан салынды. Ишелә башлаган ярлар шуның белән

ныгытылды. Ләкин елга ярларын болай итеп кенә сак-лап калырга мөмкин түгел иде, чөнки нефтьчеләр елганың комын, вак ташын алдылар. Аларга скважиналарга үтәргә юл кирәк иде. Шулай итеп, җирләр бозылды, ярлар ишелде. Кайбер авылларның су буенда утырган урамнары юкка чыкты. Колхозлар тарала башлады. Сакланып калганнары исә иген үстерү бәрабәренә түгел, басу-кырлар өчен нефтьчеләр түләгән акча исәбенә яшәделәр.

Таяк ике башлы шул: бер башы файда китерсә, икенче башы зыян салды. Шуңа күрә авыл халкы курыкмый урлашты. Нефтьчеләр безнең гомерлек байлыкларыбызга кул суза икән, нигә әле безгә куркып торырга?!

Промысел начальнигы Фатихка ярдәм итәргә сүз бир-де. «Ләкин, кунак ашы кара-каршы дигәндәй, сез дә халыкка аңлату эшләре алып барырга тиеш. Без бит нефтьне үзебез өчен чыгармыйбыз. Нефть чыга башлаганчы халыкның ипигә дә туймый яшәгәнен онытмаска кирәк», – диде ул.

Фатих моны үзе дә белә. Икмәк үстергән авыл халкы гомер буе ач яшәде. Совет власте халыкны өч сыйныфка бүлде. Беренче урында – «богауларыннан башка нәрсәсе булмаган» эшче, икенче урында – интеллигенция, иң соңгы урында – крестьян. Крестьянның өй янындагы бәрәңге бакчасын шәхси милек итеп санадылар. Мондый «шәхси милек» хуҗаларының җелеген налоглар белән суырдылар. Авыл халкын колхозларга берләштерүче дә, аны тамак хакы өчен читкә таралырга мәҗбүр итүчеләр дә власть башында утыручы «акыллыбаш»лар булды.

Фатих белән Нәркизә, халыкның тамырлары җирдән аерылмасын өчен, эшне үзләреннән башладылар. Сәясәт алмашыну нәтиҗәсендә хезмәт хакларын натуралата түли башладылар. Фатихлар өчен бу файдалы булып чыкты. Совет чорында бер кирпеч тә таба алмаган халык рәхәтләнде. Баланлыны үстерергә бу үзенә күрә хөкүмәт-нең ярдәме булды. Башта Баланлыга үз эшчеләре өчен генә йорт салудан тотынганнар иде. Тора-бара Баланлыга элек Ташлыярга күчерелгәннәр дә килә башлады. Чөнки туган җир, торган нигез үзенә тарта икән. Бу тарту көче кемнәрнеңдер күңеленә сагыну хисе булып бәреп керә, кемнәрнеңдер беренче мәхәббәтен исе-нә төшереп, яшьлек сукмаклары буйлап йөгерергә чакыра, кемнәрнеңдер йоклаган хәтерләрен уятып, ата-бабаларының рухын сак-лаган зиратларга чакыра. Әгәр кеше үзенең хәтерен үткәндәге истәлекләре белән яңартып тормаса, аның хәтер чишмәсе саега, һәм бу кеше рухи яктан ярлылана. Рухи ярлылыкны алтын-көмешләр алмаштыра алмый. Фатих шуны аңлый башлады.

* * *

Кечкенә генә Баланлы авылында зур-зур вакыйгалар булып торды. Нефтьчеләр сүзләрендә торды: авылга электр линиясе суздылар. Тиз арада авылга өч йорт салдылар. Һәр йорт ике подъездлы булганлыктан, икешәр гаилә урнашты. Фатихлар, Зарифуллалар йортын да кушкач, Баланлыда биш йорт, ягъни сигез гаилә яши башлады. Шунысы кызык: авыл өйләрендә лампочкалар кабынган көнне Наҗия белән Нәркизә бала таптылар. Бу зур вакыйганы бөтен авыл бәйрәм итте. Шатлыгыннан нишләргә белмәгән Зарифулла:

– Менәтерә нинди шатлык! Ходай бәхетне безгә бишкуллап бирде. Безнең кыз бөтен Баланлыга ишеттерерлек итеп җылый белә. Җылап туган бала бәхетле була ул.

– Кызыгызга нинди исем кушасыз соң?

– Ничек «нинди»? Зөлфия инде. Карчыгымның исеме Зөлфия ие бит.

– Фатих нишләп күренми әле?

Авыл халкы ишекне какты. Барысы бертавыштан:

– Котлыйбыз! Малаең белән котлыйбыз! – дип кычкырды.

Моңарчы тавышсыз-тынсыз яткан бала кинәт чәрелдәп елап җибәрде. Бала янында мәш килеп яткан акушер кыз да шатлыктан бәреп чыккан күз яшьләрен сөртеп алды. Балаларының елау тавышы Фатих белән Нәркизәгә дөньядагы иң матур җыр булып яңгырады.

– Бөтен хикмәт утта, – диде Зарифулла, ни сөйләгәнен белмичә. – Менәтерә, ут булгач, балалар да туды. Юкса ятарларые әле.

– Ике бала бер үк көндә туган икән, монда ниндидер хикмәт бар, – диештеләр.

Балаларның туен бергә уздырырга булдылар. Сарыкның иң симезе суелды. Урам уртасына казан асып аш пешерделәр, шашлык кыздырдылар. Наҗия белән Нәрки-зә дә рәтләнеп киләләр иде. Алар да, балаларын күтәреп, урамга чыктылар. Аларны космоска менеп төшкән космонавтлар кебек котладылар, бүләкләр бирделәр.

– Авылыбызда балалар үрчи башлады. Үсүгә таба барабыз.

Дөрестән дә, яңа салынган йортларда ким дигәндә ике-өч бала бар иде.

Беркөнне Нәркизә Фатихның эштән кайтып керүенә беренче сүз итеп:

– Безгә срочно мәктәп сала башларга кирәк, – диде. – Яңа килгәннәр арасында бер укытучы бар икән. Аны читкә җибәрмәбез бит инде.

– Дөрес әйтәсең, мәктәпсез булмый. Ләкин аны бер-ике көндә генә салып булмый, үзең беләсең. Ә балаларны бүген үк укыта башларга кирәк.

– Син каршы килмәсәң, мин... – Нәркизә, сүзен әйтеп бетермичә, Фатихка карады. Аның күңелендә уйлар болыты чайкалды. Әйтергәме, юкмы? Әйе, әйтергә кирәк. Гәрчә сүз Фатих өчен, шул ук вакытта Нәркизә өчен дә бик кадерле нәрсә турында булса да, әйтми калырга ярамый. Нәркизә тәвәккәлләде: – Әллә, мин әйтәм, үзебезнең өйнең аскы өлешендә мәктәп ачабызмы?

Өйдә кылыч эләрлек тыгыз тынлык урнашты. Фа-тихның хәтер күпере аша бу өйне салу мәшәкатьләре, тынчу мунчада җәйге эссе көннәрдә төн чыгулары, иң яманы: туган авылын таркатмас өчен борчылып йөргәндә күпме кеше белән ачуланышулары – барысы-барысы йөгереп узгандай булды. Аның Баланлы авылында өй салуын үзе турында гына кайгырту дип кабул иттеләр. Әмма Фатихның күңел түрендә Баланлыны саклап калу гына түгел, ә аны тагын да үстерү уе ятканын беркем белми иде.

– Нәрсә? – дип кабатларга мәҗбүр булды Нәркизә.

– Фикерең начар түгел, – диде Фатих. – Ә бала?

– Улыбыз Рәсим безнең белән өске катта яшәр.

– Аскы каттагы тавыш өскә дә яңгырап торачак. Мәк-тәп балалары тавышсыз-тынсыз гына йөрмиләр. Алар өске катка да менәрләр. Без, мәсәлән, мәктәпнең утын сараеннан башлап чардакларның бөтен почмакларын актарып йөри идек.

– Болар бит алты-җиде бала.

– Бүген – җиде, иртәгә унҗиде булырга мөмкин.

– Бик әйбәт. Алар унҗиде булганчы, мәктәпне дә салып бетерербез, Алла боерса.

– Районнан, хәтта Казанның үзеннән ярдәм сорарга кирәк, – диде Фатих. – Без бит үзебез өчен дип йөр-мибез. Бу – дәүләт эше.

Фатих шулай дисә дә, өйләренең аскы катында балалар укытырга ризалыгын бирде. Укыту эшләре турында сөйләшергә Баланлыга күченеп килгән укытучы кыз Алсуны чакырдылар. Алсу егерме биш-егерме җиде яшьләр тирәсендәге бер кыз икән. Шәһәрдә укытучы акчасына яшәп булмый, дип, монда әбиләренә кайткан. Ул гына да түгел, шәһәр егетләре укытучыларга өйләнергә ашкынып тормыйлар. Аларга бай әти-әниле кызлар кирәк. Бай әти-әниле гаиләләр кызларына, кияүгә чыгуга, фатир алып бирәләр.

– Элекке муллалар үз өйләрендә мәдрәсә ачканнар бит, ник хәзер ярамасын? – диде Нәркизә нindидер уйлар белән борчылып йөргән Фатихына.

– Элек һәм хәзер, – диде Фатих.

Алсу мәктәп ачу эшләре белән йөри башлады. Моның мәрәкәсе болар уйлаганнан да күбрәк булып чыкты. Әмма Алсу, яшь кенә булуга карамастан, сүзен үткәрә белә иде. Казанга Мәгариф министрлыгына кадәр барса барды – барыбер үзенекен итте, мәктәпкә кирәкле җи-һазларны кайтартты.

Нәркизә бала белән өйдә утырганлыктан, директор вазифасын Фатих үз өстенә алды. Заводка алынган яңа җиһазлар әйбәт кенә эшләп тора. Керем керә. Әкренләп булса да Баланлыда яңа йортлар калкып чыга. Кулыннан эш килгәнрәк ирләр чишмәдән өйләренә су кертте. Урман өскә аварга торганлыктан, газ булмаганга артыгын кайгырмадылар. Күпләр өй янына мунча салып куйды. Нефтьчеләр якын-тирәдә генә эшләгәнлектән, тимер-томырга кытлык юк иде. Мунча мичләренә зур-зур баклар эшләтеп, кайнар суга булган кытлыктан котылдылар.

Мәктәптә укулар башланды. Җиде баланың икесе- – беренче, берсе – өченче һәм тагын дүртесе икенче сыйныфта укыдылар. Боларның һәммәсен бер укытучы – Алсу укытты. Кырык биш минут эчендә өч төрле дәрес бирсә дә зарланмады. Бер-берсенә туганнар кебек булып киткән авыл кешеләре аңа яратып карадылар. Ә кешеләрнең мәхәббәтен тою йөрәктә матур хисләр уята. Яхшылык бит ул салават күпере кебек: бер башы – сиңа, икенче башы халыкка барып тоташа. Алсу үз эшенә җаны-тәне белән бирелде. Хыял канатларында очынып йөргәндә, яңа салынган бер йортка авыру әнисе белән Фатихны йөртүче шофёр егет Айрат күченде. Айрат башта заводта эшләде. Көндезге аш вакыты җитүгә, өенә чаба иде. Фатих, аның тормышы белән кызыксынып:

– Нәрсә, егет, өеңдә әллә чибәр хатының көтеп торамы? – диде.

Егетнең күзләреннән яшьләр бәреп чыкты.

– Их, абый, – диде ул җан ачысы белән, – чибәр хатыннар кайгысы гына булса иде монда.

– Нәрсә соң?

– Әни урын өстендә ята. Ашатырга-эчертергә, башка йомышларын үтәргә кирәк. Эшләмичә, әнине генә карап ятар идем, әни пенсиясенә генә яшәп булмый. Их, дөньясы!..

– Әйдә миңа шофёр булып кер. Кирәк чакта, өеңә кайтырга да тизрәк булыр.

Шулай итеп, Айрат директорны йөртә башлады. Фатих, аны кирәк чакта өенә җибәреп, рульгә үзе утыра. Айрат өчен бик шәп эш булды бу. Ул Баланлыга күчәргә кызыгып йөри иде, ләкин үзләренең фатирлары булганлыктан, бу сорауны кузгатырга кыймады. Көннәрдән бер көнне Фатих бу хакта үзе сүз башлады.

– Карале, Айрат энекәш, – диде ул. – Әниеңә мондагы саф һава бик әйбәт булыр иде. Капка төбенә чыгарып утыртсаң, сөйләшергә кешеләр бар. Монда йортлар иркен, җир әйбәт. Бакча үстерерсең. Үз кулларың белән үстергән кыяр, помидор, кишер, шалкан бөтенләй башка бит ул. Синең кул җылың әниеңә күчә. Беренче кыярны өзеп әниеңә кертеп бирсәң, ул ничек шатланыр иде.

– Мин үзем дә Баланлыга күчәргә күптән хыялланып йөрим. Ләкин сезгә бу хакта әйтергә генә кыенсындым.

– Нигә?

– Соң бит безнең район үзәгендә менә дигән фатирыбыз бар.

– Бәлки, кемнеңдер район үзәгендә яшисе киләдер. Алыштырырсыз.

– Рәхмәт инде сезгә, Фатих абый! Сез үзегезгә шофёр итеп алып та зур яхшылык эшләдегез. Монда күчсәк, әнигә әйбәт булыр иде. Рәхмәт яхшылыгыгыз өчен!

– Кешеләргә нәрсәдер эшли алсаң, үзеңә дә рәхәт, – диде Фатих. – Ләкин күп вакыт эшләргә мөмкинчелек булмый.

Айрат эшне озакка сузмады. Әнисе белән Баланлыга күченеп килде. Әнисе, авылны күрүгә:

– Сөбханалла, мондый матур җирләр дә бар икән әле, – диде. – Алла боерса, бәлки, терелеп тә китәрмен. Алланың рәхмәте киң бит аның.

– Терелерсең, әни. Җир җимертеп йөрерсең әле.

Айрат бер иптәше белән әйберләрен өйләренә ташыган чакта, болытлы күктә ай калыккан кебек, урамга, балкып, Алсу килеп чыкты. Ул бер укучысына барырга чыккан иде. Айратны күргәч, кая барганын онытып туктап калды.

– Яңа кешеләр килгән икән, – диде ул аптыраганнан.

– Кабул итсәгез – килдек әле менә, – диде Айрат, кыздан күзләрен ала алмыйча.

Алсуның зифа гәүдәсе, көләч йөзе, керфекләреннән сирпелеп торган нурлар егет йөрәгендә хисләр учагы кабызып җибәрде. Аның моңа кадәр яратам дип уйлап йөргән кызлары юк түгел, берсе белән хәтта шактый якынайганнар иде. Алсуны күргәч, ул кыз җил тараткан томан кебек юкка чыкты. Ә Алсу исә үзен карт кыз дип санап йөрсә дә, Айратны күрүгә, аның иңнәреннән ун ел гомере очып төште. Ул үзенең чая яшьлегенә кайтты. Хәтта керфек төпләренә җыела башлаган вак-вак җыерчыклары да таралды.

– Сезгә ярдәм кирәкмиме? – диде ул, кыюланып.

– Сезнең кебек чибәрләрнең ярдәменнән кем генә баш тартыр икән?!

Алсуның кабынырга торган йөрәгенә егетнең сүзләре янган шырпы булып төште: «Димәк, ул да мине ошаткан!»

Кыз, мендәр-ястык ише нәрсәләр күтәреп, өйгә кереп китте. Өйдә шактый таушалган кәнәфидә бер апа утыра иде. Алсу сискәнеп китте.

– Исәнмесез, апа! – диде ул.

– Исән әле, – диде кәнәфидәге хатын.

Ул арада Айрат та килеп керде:

– Бу – минем әнием. Исеме Җәннәт була. Ә сез?

– Мин Алсу. Монда укытучы булып эшлим.

– Әйдә, танышкач танышыйк алайса. Мин – Айрат.

Алар кул биреп күрештеләр. Алсу Айратның әнисе Җәннәткә дә кулын сузды, ләкин ул Алсуга таба тик бер омтылыш кына ясады, кулын сузмады.

– Гафу итегез, Алсу, – диде егет, – әнием авырый.

Алсу, үзен гаепле санагандай, керфекләрен түбән төшерде. Ләкин үзен тиз кулга алды.

– Сезнең чәй эчәсегез киләдер, апа. Хәзер мин өйдән чәйнекне алып керим әле. – Алсу йөгереп чыгып китте. Ул өендә бераз тоткарланды. Чөнки мичендә ипиләре пешеп килә иде.

Айратлар өйгә әйберләрне ташып бетерделәр. Ярдәмгә килгән иптәше, Айратның еш-еш ишеккә күз салуын күреп:

– Син көтмә инде аны. Чәйне үзебез кайнатырбыз. Авыру булган йортка кызлар аяк басмаячак. Син авырга алма, Айрат, хәзерге яшьләргә инкубаторда үскән егетләр кирәк.

Сүз шул урында өзелде. Ишектә Алсуның балкыган йөзе күренде.

– Озаграк тоткарландым, гафу итегез. Мичемдә ипи пешеп килә иде. – Ул ашъяулыкка төргән ипине өстәлгә куйды. «Тефаль» чәйнеген токка тоташтырды. Ашъяулыкны чишеп җибәрүгә, өйгә ипинең тәмле исе таралды. Ул арада чәй кайнап чыкты.

– Кулларны юарга су алып керим әле мин, – дип, Айрат егерме литрлы су савытын күтәреп чишмәгә чыгып чапты.

– Сезнең күченәсегезне белсәм, су китереп куйган булыр идем, – диде Алсу.

– Хафаланма, кызым, – диде Җәннәт, – син күч-тәнәчнең иң олысын алып кергәнсең инде. Ипидән олы ни бар дөньяда?

Җәннәт белән Алсу арасын нindидер җылы дулкын тоташтырды. Айрат судан кайтып җиткәнче, алар инде, күптәнге танышлар кебек, матур әңгәмә корып утыралар иде. Айрат әнисенең чит кешегә болай ачылганын күргәне булмаганлыктан, моны әйбәткә юрады: «Алсу әйбәт кыз булырга охшый, бәлки, берәр вакыт аларга да бәхет елмаер».

Ипине калын телемнәр белән кискәндә, Айрат кызның һәр хәрәкәтен күзәтеп торды. Алар шундый житезләр, шул ук вакытта ипигә хөрмәт белән каравы да сизелә.

Ниһаять, табын әзер. Айрат әнисен, кәнәфие-ние белән күтәреп, табын янына утыртты.

– Әйдәгез, алайса, яңа өйдә яңа дуслар белән тамак ялгап алыйк. Рәхмәт Алсуга! Ул өебезгә яктылык алып килде. Шушы яктылык безнең күңелләребезне яктыртып торсын.

Айрат иң беренче итеп әнисенә чәй ясап куйды, аннары, җылы ипигә май ягып:

– Әйдә, әни, син арыгансыңдыр, ачыккансыңдыр, – дип, әнисенә майлы ипиен каптырды, икенче кулына чәйле чынаягын тотып, һәр кабым саен чәй йоттырды.

Башкалар, ягъни Алсу белән Айратларга җиһазлар китерешкән агайлар, улының анасына булган мәхәббәтнең нинди зур икәнлеген сокланып һәм гаҗәпләнеп күзәт-теләр. Игътибарны үзләренә юнәлтмәс өчен, алар күбрәк алларына куелган ризыкка карап ашарга тырыштылар. Айратның исә бөтен игътибары әнисендә. Капкан ризыкның валчыгы авыз тирәсендә ябышып калса, аны чис-та салфетка белән сөртеп алды. Әнисе:

– Син мине генә түгел, кунакларыңны да онытма, – дигәч кенә, Айрат айнып киткәндәй булды.

– Сезнең хакта онытып җибәргәнмен, гафу итегез. Өстәлдә әллә нинди сыйлар булмаса да, бары белән сыйланып утырыгыз.

– Сез кыенсынмагыз, балалар, – диде ана, – үз өе-гездәге кебек утырыгыз.

Өйдә авыру кеше бары онытылды. Айрат, бер мәзәк сөйләп, кунакларны көлдереп алды. Табын түрендә утырган ана да аларга кушылды. Аның чисталыгы, пөхтәлеге, кызык сүзләрдән рәхәтләнеп көлүе башкаларның кысылып куйган күңелләрен бәйдән чишеп җибәрде. Чәй яңадан кайнарланды.

– Болай булгач, тагын бер чынаяк эчми булмас, – диде ана, – ипие бигрәк тәмле. Кулың тәмле икән, кызым.

– Рәхмәт, апа! – диде Алсу, бераз кызара төшеп. – Яратсагыз, мин тагын кертермен.

Өйдә һава сафланып киткәндәй булды. Алсуның бу яңа кешеләргә үз итеп каравы, матур итеп көлүе, Ай-ратның үз әнисенә мөнәсәбәте өйдә авыру барлыгын оныттырды. Чәйләр эчелеп беткәч, Алсу белән Айрат табынны җыеп алдылар. Вакыт-вакыт аларның күз карашлары очрашып, чакматашлар ышкылганда очкыннар чәчрәгәндәй, бу карашлар кисешкәндә дә, өйгә йомшак нурлар сирпелде.

Савыт-сабаларны югач, Алсу чыгып китте, ләкин шун-да ук кулына чүпрәк белән җылы су күтәреп кире керде.

– Өегезне бераз җыештырыйм дигән идем. – Ул кер-гәндә, Айрат әнисен караватка яткырып, өстенә юрган ябып маташа иде. – Вакытсызрак кердем, ахры, – диде Алсу.

– Сез һәрвакыт вакытлы йөрисез, – диде Айрат.

Егетнең җанында моңарчы күрелмәгән күтәренкелек, тәнендә җиңеллек туган иде. Ул, шатлык канатларында очынып, өй җиһазларын бераз тәртипкә китерде. Кухня белән зал бөтенләй буш иде. Алсу шуларның идәнен юудан башлады. Идәннәрне юып җибәргәч, өйгә нарат исе таралды. Айратка бу хуш ис Алсудан тарала кебек тоелды.

Караңгы төшеп килә иде, Айрат кызны озата чыкты.

– Сез кем? – диде ул Алсуга. – Фәрештәме, кешеме?

– Мине алай бик үсендереп җибәрмәгез. Мин гади бер укытучы.

– Юк-юк, – диде Айрат, – сезнең һәрбер хәрәкәтегез җылылык, рәхәтлек тарата. Мин моны хәтта сүзләр белән әйтә дә алмыйм. Минем бервакытта да мондый тойгылар кичергәнем юк иде. Бу тойгы, йомшак җәйге җил булып, куеннарыма тулды, кояш нурларына әйләнеп, битләремнән сыйпады.

– Сез мине чынлап та фәрештәгә әверелдердегез. Алай илаһилаштырмагыз, соңыннан кыен булыр.

Шулвакыт Айратның күз алдына Регина килеп басты. Регина бик чибәр, хәтта артыгы белән чибәр кыз. Айратка юлда очраган иде. Айратның районга барышы. Кызны утыртты.

– Мине Туймазыга илтеп куя алмассызмы, чибәр егет?

– Сезнең кебек асыл затны Туймазыга гына түгел, айга менгереп куярга да әзер, – диде Айрат.

– Айда синең кебек егетләр юктыр шул.

– Мин дә айда калырмын.

Аларның сүзләре шулай үзеннән-үзе ялганып китте. Кыз, юл тигезсезлегеннән файдаланып, әле итәген өскәрәк тартты, әле кофтасының кендек турын ачарак төште. Айрат кызның кендегендәге алкага карап куйды. Аның андый алкалы кызларны күргәне бар иде, шунлыктан аңа исе китмәде. Регинаның ялганган тырнаклары гына аны бераз сискәндереп җибәрде. Алар карчыга тырнагына охшаганнар иде. Айрат, сынар өчен генә, кызның ботына кулын куйды. Кыз бу хәрәкәтне шулай тиешле дип кабул итте.

– Туктап аласың килсә кыенсынма, чибәр егет, – диде кыз.

– Айрат исемле мин.

Бер текә борылышта Регина бөтенләй Айратның иңнәренә ятты. Кыздан тәмле ислемай исе килә иде. «Әллә полоса турында туктап алырга микән? – дигән гөнаһлы уй йөгереп үтте егетнең ми ерганаклары аша. – Нишләр иде икән? Чынлап та, туктыйм әле».

Айрат кырт кына машинасын туктатты да:

– Мин йөгереп кенә куаклар арасына кереп чыгам, син утырып тор, – дип кереп китте.

Кыз аның артыннан төшмәкче иде, кире уйлады. Күңелендә аның үз планнары бар иде. Әниләре аны бөтенләй юлдан язганчы кияүгә бирмәкчеләр. Дөрес, ул кияүдә озак яшәмәячәк. Ичмасам, аерылып кайткан хатын булып йөрер. Аерылучылар күп бит хәзер. Югыйсә урамда очраган һәр кеше Регинаның нинди эш белән шөгыльләнгәнен эти-әниләренең йөзенә бәреп әйтә башлады. Регина аларның сүзләреннән котылыр өчен берәр авыл мокытына кияүгә чыгып, кирәк чакта, башкалар белән типтереп яшәү турында хыяллана иде.

Кыз, кофтасын аскарак тартып, кендеген каплады. Итәген дә тезенә кадәр тартты, ирен буяуларын үбешер алдыннан сөртә торган салфетка белән сөртеп алды. Айрат килгәндә, машинада гүяки башка кыз утыра иде.

– Туймазыда нинди йомыш? – диде Айрат.

– Театрда бер дус кызым эшли. Менә бу алкаларны, йөзек, беләзекләрне аннан алып торган идем. Шуларны илтәм. Хәзер аларның миңа кирәге калмады. Бер классташымның туена барыр өчен генә алып торган идем мин аларны.

– Ә-ә, – диде Айрат. – Сез үзегез дә артисткага охшаган. Чибәр. Зифа буй-сын. – Айрат кызга хөрмәт йөзеннән «сез»гә күчте.

– Күңелем булсын өчен генә әйтәсездер бу сүзләрне, – диде кыз тыйнак тавыш белән. – Егетләр кызларга комплимент әйтергә яраталар инде.

– Валлаһи, сез шундый чибәр. Айдан төшкән Зөһрә кыз диярсең.

– Сез бигрәк инде.

– Чынлап әйтәм.

Алар кабат очрашырга сүз куешып аерылыштылар. Кыз Октябрьск шәһәрендә яши икән. Егетнең: «Кайда эшлисез?» – дигән соравына ул: «Анысы әһәмиятле түгел», – дип җавап бирде.

Регина Айрат белән еш кына очраша башлады. Ләкин егетне өенә чакырмады.

– Безнең эти-әниләр минем егетләр белән очрашуыма каршы. Алар мине вечно үз кочакларыннан чыгармаска исәплиләр бугай. Син чакырганда да, иптәш кызларыма барам, дип кенә чыгам.

Айрат кызны җәлләп куйды. Аны яратып күкрәгенә кысты. Кызның йомшак тәне Айрат күкрәгендә эреде. Айрат хисләр диңгезендә коенды. Ул үзен каядыр югарыда, болытлардан өстәрәк итеп тойды. Ә кыз, аңа айнырга ирек бирмичә, егетнең ачылып киткән күкрәген, муенын үпте. Айрат кызның кочагында яңа кабарып чыккан камырга әйләнгән һәм аны, әвәләп, мичкә тыгасы гына калган иде.

– Әйдә бер җиргә барабыз, – диде Регина. – Бу шау-шулы дөньядан аерылып, икәү генә калыйк әле. Нинди егет икәнеңне шунда күрербез.

Регинаның тел төбендә ни ятканын Айрат аңлап бетермәде, аның аңы томаланган иде. Ул, муенчагыннан тартып барган бозау кебек, кыз артыннан барды. Бер кибет турына җиткәч, Регина, кинәт туктап, сумкасын актара башлады.

– Аһ, аңгыра баш, акчамны автобуста алдырганмын, ахры. Синең янга тизрәк килеп җитим дип, бик тыгыз автобуска утырган идем. Шунда алдырганмын, күрәсең.

– Акчаң күпме иде?

– Күп түгел дә...

– Шулай да?..

– Ике мең тирәсе генә иде.

Кызның бу сүзләреннән егет чайкалып китте. Ике меңне әз акчага саный, димәк, әти-әниләре байлардыр. Айратның кесәсендә биш-алты йөз чамасы акчасы бар иде. Ул:

– Менә миндә бераз акча бар. Кибеттән берәр әйбер алырга теләгән идеңме әллә? – диде.

– Әйе.

– Мә, әгәр җитсә... – Егет акчаларын кызның учына салды.

– Син шунда гына тор, мин үзем генә кереп чыгам, – дип, кыз кибеткә кереп китте. Бераздан ул полиэтилен пакетка шактый әйбер төяп чыкты. – Әйдә, киттек.

Кыз Айратны шәһәрдән шактый гына читтә торган бер йортка алып килде. Тәрегә охшаш ачкычы кызның муенында икән. Йозакны бик җайлы ачты, димәк, бу йортка беренче генә килүе түгел.

Өй эчендә җиһазлар иске. Монда тәртипсезлек хөкем сөргәне бер караштан ук күренә. Хәтта өстәл өстендә сындырылып ашала башлаган ипи дә ята.

– Минем иптәш кызым яши монда. Бүген әниләренең туган көне. Бик ашыккандыр инде, өен дә җыештырып тормаган.

– Хәзер җыештырабыз аны, – диде Айрат һәм каяндыр бер таска охшаган, ләкин кырые кителгән савыт белән чүпрәк табып алды. Үзе Регинага дәште: – Регина, бу чүпрәк белән өстәл сөртсәм ярар микән, чиста микән ул?

Регина икенче бүлмәдә киемнәрен алыштыра иде. Ул өстенә биленнән пута гына бәйли торган гади халат киеп маташа икән. Аның нишләптер җиңе төйнәлгән булып чыкты. Ул шуның төенен чишә алмый азаплана икән. Регина, Айратның үзенә эндәшүен ишеткәч, яртылаш киенгән килеш, егет янына чыкты. Ул халаты белән түшләрен ябарга маташса да, нигәдер ул гел ачылып китә. Халат ачылган вакытларда «өлгереп җиткән алмалары» егет учына төшәрдәй булып сикерешәләр. Халат җиңен Айрат чишеп биргәч кенә, Регина аны өстенә киде.

– Син нәрсәдер сораган идең бугай? – диде кыз.

– Менә бу чүпрәк белән өстәл сөртсәм ярар микән, дип сораган идем.

Регина чүпрәкне иснәп карады да:

– Моңардан ис килә. Хәзер мин сиңа икенчене чыгарам, – дип, кухняга кереп китте. Аннан бер чите ертылып алынган сөлге алып чыкты.

Егет өстәлдәге клеёнкага ябышып каткан ризык кал-дыкларын кесәсендәге пәке белән кыра-кыра юды. Идәнне дә себермәкче иде, Регина аны туктатты:

– Тузан гына туздырасың, маташма. Әйдә бергә-бергә табын әзерлик.

– Әйдә алайса.

Алар бергәләп табын әзерләргә тотындылар. Нигәдер һәр хәрәкәте саен Регинаның халаты ачылып китте. Кыз халат путасын бәйләгән булып кыланды. Ләкин ул Ай-ратның җиленнән дә ачыла иде.

– Гафу, Айрат, – диде Регина, – кеше киеме башкаларны яратмый, күрәсең.

Регина ризыкның бик кыйммәтлеләрен алган. Өстәвенә бер коньяк та чыкты сумкасыннан. Бу коньякның үзе генә дә мең сумнан артык торганын белә иде Айрат, ләкин аны-моны әйтмәде.

Алар табынга утырдылар.

– Ир кеше буларак табынны син ачып җибәрергә т-иеш. Безнең әни, әти ашый башламыйча, ризыкка тотынмый.

Айратта кызга карата хөрмәт арта төште. «Тәрбияле гаиләдә үскән», – дип уйлады һәм торып басты:

– Мин матур сүзләргә оста түгел. Бүген бары тик шуны гына әйтә алам: безне менә бу мул сыйлы табын тагын да якынайтсын. Мин эчемлекләр белән дус түгел түгелен. Әмма шундый кыз кучтәнәченнән баш тартып булмас.

Айрат, коньякны ачып, яртышар рюмка эчемлек салды, ләкин Регина моңа канәгать түгел иде. Ул:

– Бәхетебез алай ярты-йорты гына булмасын, Айрат. – Регина мөлдерәмә тутырып салды. – Бәхетебез һәрвакыт ташып торсын. Синең кебек, мин дә мондый нәрсәләр белән бик дус түгел. Ләкин мин бу рюмканы киләчәгебезне

күз алдында тотып күтәрәм. Бәхетебез шулай мөлдерәп, ташып торсын. – Һәм Регина эчемлекне бер сулыш белән авызына аударды.

Айрат егет башы белән аңардан калышмас бит инде! Ул да эчеп куйды һәм бер конфет капты. Табында кыйммәтле сыр, ат колбасасы, кызыл уылдык һәм башка затлы ризыклар бар иде. Регина май яккан ак ипи телеменә кызыл уылдык салып Айратка каптырды.

Мондый игътибарга өйрәнмәгән Айрат:

– Юк, мин үзем, – дип карышып маташкан иде, Регина аның алдына менеп утырды да:

– Кунак – хуҗаның ишәге, – дип, Айратка озын бармаклары белән чеметеп-чеметеп әле теге, әле бу ризыкны каптырды.

Әллә алдында Регина утырганга, Айрат тирләп чыкты.

– Салып ташла әле шушы пинжәгеңне, син бит туйда түгел, – дип, Регина Айратның пиджагын салдырды. Изүләрен чиште. – Менә хәзер бераз кешегә охшый башладың. Кеше үзен аулак урында иркен тотарга тиеш. Без бит клубта утырмыйбыз. Без болай да гел богауланып яшибез. – Айрат аны аңлап җиткермәде. – Соң үзең уйлап кара: башкалар алдында яхшы булып күренер өчен эссе көннәрдә дә катлы-катлы киенәбез. Алтын-көмешләр асабыз. Ә бит кеше тәне бөтен нәрсәдән дә матуррак.

– Әйе, кеше матур. Шул матурлыкны мәңгелек итәр өчен рәссамнар юкка гына тырышмыйлардыр.

Айратларны, сигезенче сыйныфта укыганда, Мәскәүгә Эрмитажга алып барганнар иде. Егет шунда алган тәэсирләрен сөйләмәкче иде, ләкин Регина:

– Беренче күрешүдә үк без бөтенесен чәчмик, киләчәк очрашуларга калдырыйк, – дип, аны туктатты.

Айрат, бик сирәк эчкәнгәме, бер рюмкадан ук исерә башлавын сизде. Ләкин Регина янында «мәми авыз» булып күренмәс өчен, икенче рюмканы да бушатты. Аның эченә ут капкан кебек булды, ул нәрсә кабарга белми торганда, Регина аңа сок салып бирде. Әллә өй эсселегеннән, әллә эчемлек кайнарлыгыннан ул тирләп чыкты. Хәтта күлмәге юешләнде.

– Рөхсәт итсәң, мин күлмәгемне салам, Регина.

– Күптән богауларыңнан арынырга вакыт. Без бит икәүдән-икәү генә. Һәм ирекле кешеләр. Үзебезне катлы-катлы читлекләргә ябабыз. Кешегә бит, саф һава кебек үк, менә шулай яраткан кешең белән икәүдән-икәү калып бер рәхәтлек кичерү дә кирәк.

– Әйе, әйе, – диде Айрат, – тик минем өйдә әни ялгызы. Ул...

Регина Айратның авызын учы белән каплады.

– Әти-әниләр турында сөйләшмибез. Без бүген дөньяда икәү генә.

Алар төрлечә шаярыша башладылар. Авыру ана карап беркая чыкмый яшәгән егерме ике яшьлек егеткә бүген күк капусы ачылды. Регина кебек кызларны күргәне юк иде әле аның. Айрат үзенең чишенеп ташлаганын хәтерләми. Уянып киткәндә, алар уралышып йоклап яталар иде.

«Әни! – дип әрнеде Айратның йөрәге. – Ул бит берүзе. Ашатырга-эчертергә, тәннәрен бер яктан икенче якка борып яткырырга да кирәк. Бер як белән озак ятса арый, тәннәре кызара. Аһ, нишләдем мин?!»

Айрат Регинаның үзенә уралган ботлары арасыннан чыга башлады, тик шулвакыт Регина, уянып:

– Айратчик, эчәсем килә, су китер, – диде.

Айрат, кухняга барып, кызга су алып бирде һәм үзенең киемнәрен эзли башлады.

– Минем киемнәрне күрмәдеңме син?

– Күрдем.

– Табып бир әле тиз генә.

– Мин аларны ашап бетердем.

– Шаярма әле, – диде егет.

– Ә мин шаярмыйм.

Егет, ачуланып, бөтен нәрсәне актара башлады. Регина, аны үзенең кочагына алып:

– Бер иркәлә, шуннан соң киемнәреңне бирермен.

Айратның иркәләнешеп ятарга вакыты да, дәрте дә юк иде, ләкин яшь тән үзенекен итте. Регинаның йомшак куллары тиюгә үк, дәрт бармагы, командирыннан әмер алган солдат кебек, үз постына барып басты.

Регина, үз кирәген алгач кына, егетнең киемнәрен бирде. Алар икенче караваттагы матрас астында булып чыктылар.

Регина иртәнге наздан соң эреп йоклап китте. Айрат аның өстенә ябарга уйлаган иде, ләкин вакыты тыгыз булгач ябып тормады. Чөнки кичтән ябынган одеал, йомарланып, кызның астына кергән, аны тартып ала башласаң уянуы мөмкин иде.

Айрат тиз генә чыгып чапты. Әнисе әрләр дип курыккан иде, ләкин авыру ана яшьле күзләрен улыннан яшерергә тырышты. Айрат тиз-тиз генә әнисенең астындагы памперсны алмаштырды, аннары җылы суда чылатылган сөлге белән әнисенең битләрен, кулларын сөртте.

– Гафу ит, әни, – диде Айрат, – мин бик начар эш-ләдем.

– Гафу үтенмә, улым, – диде ана. – Син бит инде җиткән егет. Син үзең мине гафу ит: минем аркада беркая бара алмыйсың.

Айрат әнисен кочаклап алды:

– Син артыгын олы йөрәкле шул, әни!

Ана белән бала күпмедер вакыт сүзсез утырдылар. Аннары Айрат, тиз-тиз генә әнисен ашатып, эшенә китте. Ләкин ашыгып эшкә баруының файдасы булмады, чөнки Фатих, рульгә үзе утырып, каядыр киткән иде. Айрат, аның секретаре янына кереп:

– Фатих абый кая китте? – дип сорады.

– Ул үзенең дусты Расих янына китте. Бер конвейер ватылган. Детальләр кирәк. Кирәкле деталь Расихта булмаса, Туймазыга барам, Айрат, өенә кайтып, әнисен карасын, дип әйтте, – диде секретарь.

Секретарь кызның да Айратка күзе төшеп йөри, ләкин әнисенең авыру булуы куркыта.

– Әллә бүген су коеныргга барабызмы? – диде ул Айратка. – Начальство юк, көн кызу. Әниең сине эштә дип уйлар.

– Юк, юк, – диде Айрат, куркынгандай итеп. – Әнине юындырырга, өс-башларын алыштырырга кирәк.

– Юк икән юк, – диде секретарь кыз.

Айрат шатланып әнисе янына кайтты. Ваннада бик әй-бәтләп юындырды, чәчләрен тарады, өс-башларын алыштырды. Матрасы исләнә башлаган кебек тоелгач, икенче матрас җәеп, тегесен тышка чыгарып элеп куйды. Аннары әнисе яраткан ит белән бәрәңгедән бәлеш пешерде. Бәлешне икесе дә бик яратып ашадылар.

– Рәхмәт, улым, ярый әле син бар, – диде әнисе. – Минем аркада бик күп нәрсәләрдән мәхрүм калдың инде, балам.

– Алай димә, әни. Син өебезгә яктылык биреп торасың, син өебезнең нуры.

– Минем күңелемне күтәрә беләсең инде син, улым. – Ана нидер уйланып ятты. Аннары: – Улым, сиңа әйтәсе сүзем барые, – диде.

– Әйт, әни.

– Сүзем шул: син бит инде егет булып җиттең. Кызлар белән дә йөрисең киләдер. Кичен, мине ашатып-эчертеп, урыныма җайлап яткыргач, күңел ачарга чык.

– Сиңа бер-бер хәл булса...

– Шыгырдаган агач озак яши ул, улым.

– Син шыгырдаган агач түгел, әни. Үзеңә нинди авыр чакларда да мине елмаеп каршы аласың. Синең елмаюыңны күргәч: «Әле ярый, әнием, син бар, синсез өебезнең яктылыгы булмас иде», – дип уйлыйм.

– Рәхмәт, улым. Тик шулай да син өйгә бикләнеп кенә яшәмә. Яшьлек үтә дә китә. Мин аңлыйм: син мине кызганасың, ялгыз калдырып чыгып китәргә кыенсынасың.

– Мин сине бик яратам, әнием.

– Ышанам, улым. Ләкин аналарга булган мәхәббәттән башка да ярату барлыгын онытма. Язмыш кырысрак булган саен, бәгырь ката. Синең беркемне дә ярата алмый торган каты бәгырьле, салкын җанлы кешегә әверелүеңнән куркам, улым.

Әнисенең сүзләрендә хаклык барлыгын яхшы аңлый Айрат. Кайвакыт ул дөньясын каргап ташлый. Әнисен терелтә алырдай дару уйлап таба алмаган докторларны сүгә. Ә бит Айрат үзенең хезмәт хакын гел даруларга тота. Әнисенең пенсиясе фатирга түләргә һәм такы-токы ашарга гына җитә. Әйтсәң оят: Айратның кешелеккә кия торган костюм-чалбары да бер генә. Ярый әле күп вакыт футболка белән джинсы чалбар коткара. Яшьләрнең күбесе кыршылып беткән джинсылардан йөргәнлектән, ул алардан бик аерылмый.

Әнисе кичләрен чыгарга үзе куалап торгач, Айратның дәрте кузгалды. Күз алдына Регина килеп басты. Өч көн үтте бит инде, ул да сагынгандыр. Ул Регинаның адресын белми иде, теге йорт тирәсеннән әйләнеп йөри башлады. Бәхетенә, капка ачылып китте дә аннан Регина белән бер егет килеп чыкты.

– Миңа алмашка килделәр, мин киттем, – диде егет.

Егетнең сүзләрен Айрат аңламасын өчен, Регина, егет ераккарак киткәч: «Смотри, син анда әнинең сүзләрен тыңла, мин иптәш кызларымда бераз торам», – дип кычкырып калды. Айратның күңеленә шик төшә башлаган иде, кызның сүзләреннән соң шиге таралды.

– Энеңмени? – диде.

– Минем дүрт ир туганым бар. Икесе абыем, икесе энекәшләр. Мине урларлар дип куркалармы, ялгызым калуга килеп җитәләр.

– Мондый яклаучыларың булуы бәхет бит, – диде беркатлы Айрат.

– Ә-әйе... Ләкин...

– Ә нәрсә?

– Юк, болай гына. Алар, килсәләр, акча сорый башлыйлар. Бүген күңелем ни өчендер гел сине көтте. Ә энекәш китми дә китми.

Алар өйгә керделәр. Айрат Регинаны кочагына алып үбәргә тотынды.

– Мин сине бик сагындым.

– Мин дә, – диде Регина. – Ләкин ул кадәр түземсез булырга ярамый бит. Мин теге көнге хәлләр өчен дә оялам. – Регина керфекләрен түбән төшерде. Аягының баш бармагы белән идәнне чокыгандай итә башлады. Айрат аны күкрәгенә кысмакчы иде, ләкин кыз читкә тартылды: – Юк, юк, мин сиңа лаек түгел. Теге көннән соң бөтенләй килмәссең дип уйлаган идем...

– И-и, юләрем минем. Мин ул төнне күңелемнән кичереп саташып беттем. Телемдә гел синең исем, Регина. Синең исемеңдә үзенә тартып тора торган көч бар сыман.

Регина, тагын да ныграк оялган булып, күзләрен челт-челт йомып алды. Моның күз яшьләрен чыгарыр өчен махсус эшләнгән эш икәнен Айрат башына да китермәде.

Өйнең эче тәртипсез иде. Караватта мендәрләр изелгән, юрганнар йомарланган. Регина, акланырга теләп:

– Энекәшләр килсә, өйдә тәртип бетә. Әни аларны иркәләп өйрәткән. Өсләрен дә салмыйча, караватта ауныйлар. Җитмәсә, тәмәке тарталар.

Айрат, өйгә керү белән, идәндә аунап яткан тәмәке төпчекләренә игътибар иткән, аңа хәтта Регинадан да тәмәке исе килә кебек тоелган иде. Хикмәт энекәшләрендә икән.

– Мин өс-башымны алмаштырып, идәннәрне бераз сөртеп чыгыйм әле, тик син карап торма, яме.

– Юк инде, карамыйм, – диде егет һәм чытырдатып күзләрен йомды.

Регина, өстен чишенеп аткач, Айратка карады. Айрат һаман күзләрен чытырдатып йомып тора иде. «Дурак!» – дип уйлап куйды Регина һәм кинәт кычкырып җибәрде:

– Ай-ай-ай!

– Нәрсә булды? – диде Айрат.

– Аягыма шырпымы, энәме кадалды. – Регина, титак-лап, егет каршына килде.

– Карале, зинһар, нәрсә кадалды икән? Үтерә генә. Уф, үләм.

Айрат Регинаның аягыннан тотты:

– Түз инде, түз. Хәзер табабыз аны.

Регина, егылмас өчен, куллары белән егеткә тотынды. Егет кызның аягына кадалган чүпне эзләгәндә, аяк һаман югарырак күтәрелә барды. Айратның күзе бармактагы чүпне түгел, эчкәрәк яшеренгән «чүплек»не капшады.

– Ят әле, булмаса, болай чүпне күрү җайсызрак, – диде ул.

Кыз караватка ятты.

– Туктале, үзем карыйм.

Кыз, караватка утырып, бер аягын күтәреп «чүп» эз-ли башлады. «Чүп»не Айрат та эзләште.

– Менә мондарак бугай ул, юк, менә мондарак, – дип, кыз тәненең бөтен җирен капшатып чыкты.

Ниһаять, «чүп»не таптылар. Аны тартып чыгарыр өчен пинцет кирәк булды.

Берничә көн очрашып йөргәннән соң, Айрат:

– Әйдә өйләнешәбез, – диде.

Регинага егетнең тәкъдиме ошады. «Гел «энекәшләр» һәм «абыйлар» белән торып булмас. Алар белән өйләнеш-кәч тә очрашкаларга мөмкин бит», – дип уйлады ул.

Ләкин егет соңгы сүзен әйтеп бетермәгән иде әле.

– Тик алдан ук әйтеп куям: минем әнием авыру.

– Мине авыру әниеңне карарга алмакчы идеңмени?

– Бергәләп карарбыз.

– Нәрсә белән авырый соң ул?

– Нәрсә икәнен табиблар да әйтә алмый. Тиктомалдан аяк-куллары йөрми башлады.

– Фатирыгыз ничә бүлмәле?

– Ике.

– Әллә ни түгел дә, ярый инде.

– Димәк, син риза.

– Риза, тик бер шарт белән.

– Нинди шарт?

– Әниеңне инвалидлар йортына тапшырабыз.

Айрат өнсез калды. Регина шаяра яки Айратны сыный дип уйлады ул.

– Ә син, үз әниең авырып китсә, картлар йортына тапшыра алыр идеңме?

– Ә нигә тапшырмаска?! Анда алар үз ишләре белән. Сүзләре килешә. Өс-башлары чиста, тамаклары тук. Карт кешегә тагын ни кирәк?

– Минем әнием карт түгел, авыру гына.

– Авыруларга тем более җәмгыятьтә урын булмаска тиеш. Алар бит таза кешеләр эшләп тапканны ашап ятучы дармоедлар.

Егет артык түзеп тора алмады, кызның яңагына каты кулы белән берне сылады:

– Бүтән күземә күренәсе булма, йә ялгыш кандала урынына сытып ташлармын.

Кыз тәгәрәп китте.

– Син бу эшең өчен үкенәчәксең әле, – дип калды Регина, ирексездән чыккан күз яшьләрен сөртә-сөртә.

Кызның янавына Айратның бик исе китмәгән иде. Беркөнне караңгы төшеп килгәндә, аның каршысына өч әзмәвер чыгып басты. Аларны таптамас өчен, Айрат машинасының тормозына басты.

Машина туктауга, егетләр Айратны кабинадан сөйрәп төшерделәр. Берсе Айратка ни беләндер сугарга теләп селтәнгән иде, Айрат аның касыгына шундый каты итеп типте, теге мескен эчен тотып җиргә ауды. Ләкин шул арада егетләрнең икесе Айратның тез астына тибеп аудардылар. Әмма кечкенәдән эшләп үскән егетне болай тиз генә җиңү мөмкин түгел иде. Берсенең кулында пычак ялтырап китүен күргәч, Айрат, сикереп торып, ишеге ачык калган машинасына үрелде. Анда аяк астында гына монтировка ята иде, юлбарыс куянга ташланган тизлектә монтировкасын алып селтәнә башлады. Регина бандитларга: «Айрат, бер сугуга, көлчә булачак», – дигәч, алар мондый каршы торуны көтмәгәннәр иде. Ниндидер мизгелдә югалып калдылар. Айрат шул мизгелне файдалана белде: пычак тотып каршысына килүчегә монтировкасы белән каты гына тондырды. Маңгаена монтировка эләккән бәндә миңгерәп китте. Өченчесе, ялт кына машина эченә кереп, ачкычларга ябышкан, һәм машинага кергәндә сыңар туфлие төшеп калган иде. Айрат машинаны кабызырга маташкан бандитны үз туфлие белән уңлы-суллы яңаклады да, теге мәлҗери башлагач, аны утыргычтан тибеп төшерде. Һәм тегеләр искә-ушка килгәнче китеп барды.

Шушы хәлләрдән соң, бер кызга да күз салмам, дип, егет үз-үзенә сүз бирде. Ләкин сүз бирү – бер нәрсә, тән таләбе, йөрәк таләбе икенче икән.

Айрат беркөнне, директорны эшенә илтеп куйгач, тиз генә өенә кайтып килергә уйлады. Шунда аңа гади генә киенгән бер кыз кул күтәрде. Айрат тормозга басты.

– Мине әнә теге аяк киемнәре ремонтлый торган мас-терской янына илтеп куегыз, зинһар. Туфлиемнең табаны кубып төште.

Кыз хәзерге товарларның начарлыгыннан сукранып алды, ә Айрат: «Кая, туфлиеңне салып бир әле, бәлки, үзем кадаклап бирермен», – диде. Кыз, сыңар кулы белән машинага тотынып, туфлиен салды. Айрат, аны әйләндереп-әйләндереп караганнан соң, машинасының багажнигыннан машина төзәтү өчен куллана торган эш коралларын алып, берничә минут эчендә туфлине кадак-лап бирде.

– Рәхмәт инде сезгә, абый! Күпме бирим?

– Сез нәрсә, – диде Айрат, – шушындый пүчтәк эш өчен акча ала башласаң... – Һәм Айрат машинасына кереп утырды.

– Абый, болай булмый бит инде, – диде кыз.

– Исемегез ничек? – диде Айрат.

– Наилә. Моннан ерак түгел генә торам.

– Әйдә утыр, өеңә илтеп куям.

Алар юлда кайтканда сөйләшеп киттеләр.

Кызны сынар өчен, Айрат Наиләнең тезе өстенә кулын куйды. Кыз корт чаккандай чәбәләнә башлады:

– Сез нәрсә? Әллә мине урам себеркесе дип белдегезме? Туктагыз хәзер үк, юкса тәрәзәдән сикерәм.

– Туктыйм, сикермә, – диде Айрат. – Ә кыланышым өчен гафу ит. Ялгышлык белән.

Кыз тынычлана төште. Айрат машинасын әкренәйтте. Алар дуслар булып аерылыштылар. Айрат кыздан кабат очрашырга рөхсәт сорады.

– Ярар, очрашырбыз, – диде Наилә. – Ләкин менә шушында, безнең капка төбендә. Тагын бер нәрсә: минем янга машинаң белән килмә.

– Нигә?

– Безнең әти-әниләр гади эшчеләр. Машиналы егетләр әллә кая алып китеп мәсхәрә итеп ташларлар дип куркалар.

– Минем машина үземнеке түгел. Начальство йөр-тәм.

– Барыбер, автобус белән кил.

– Ярар, килештек.

Наилә Айратка бик ошап җитмәде җитүен. Кызның күңелендә үзенең ярлылыгы белән горурлану ята кебек тоелды. Аннары машина чокыр-чакырларда сикертеп куйса, кыз йомры-йомры сүзләр белән сүгенгәләп алды. Айрат аның сүзләрен ишетмәмешкә салынды. «Бер күрүдә үк кеше турында күңелеңә начар төен төйнәп куярга ярамый», – дип уйлады.

Аларның очрашуына тагын күрешеп сөйләшү нокта куярга ярдәм итте.

Эскәмиядә кочаклашып утырганда, Айрат:

– Миңа кияүгә чыгар идеңме? – диде.

Кыз бу сүзләрдән соң егеткә елышарак төште:

– Синең кебек егеткә дә чыкмагач...

– Алайса, риза?

– Риза. Тик бер соравым бар: кемнәр белән яшисез? Фатирыгыз ничә бүлмәле?

– Әни белән яшим. Фатирыбыз ике бүлмәле.

– Анысы әйбәт икән.

– Әйе, әйбәт, тик бер нәрсә бар.

– Нәрсә, әллә «машинаң» эшләмиме?

– Ансы әйбәт эшли.

– Тагын нәрсә комачауларга мөмкин соң?

– Минем әнием авыру...

Кыз өнсез калды. Болай да ул, каенана белән бергә ничек яшәрбез, дип утыра иде. «Менә сиңа мә! Әнисен карарга килен кирәк икән моңа». Кыз эскәмиядән торып китмәкче иде, ләкин күңеленә килгән бер сорау аны туктатып калды:

– Авыру кеше бер терелә, больницага салырга кирәк аны.

– Больницаларда күп ятты инде ул. Хәзер аны больницаларга да алмыйлар. Барыбер терелтеп булмый, диләр.

– Кыен хәл икән. – Кызның егетне дә югалтасы килми, авыру каенана белән яшәүне дә күз алдына китерә алмый. Ул бу юлдан чыгу юлын тапты: – Карале, Айрат, мин бер газетадан укыган идем: имеш, кайбер илләрдә мондый терелмәслек авыруларга йоклата торган укол бирәләр икән. Бернинди авыртусыз мәңгегә йоклый да китә.

Егет Наиләне сугып очырудан чак тыелып калды. Әйтерсең аның йөрәгенә пычак кададылар: чәнчеп-чәнчеп авыртырга тотынды. Ул бераз эскәмиядә утырды. Наилә аның утыруын үзенчә аңлады:

– Минем бер таныш шәфкать туташы бар, ул мондый эшләрнең җаен белә. Уколы кыйммәтрәк инде, ләкин гомерлек газаптан коткара. Караучыны гына түгел, авыручыны да. Бу бик гуманлы.

Айрат кызны, якасыннан гына күтәреп, бакчаларына ыргытты.

– Гуманлы эшеңне үз әниең белән эшләрсең, – диде һәм кызны тоткан кулын канистрдагы су белән юды. Кызның күңел пычрагы Айратка йоккан кебек тоелды. Кулын кат-кат юганнан соң гына ул машинасына утырып элдертте. Үз-үзенә ул: «Моннан соң бер кызга да сүз катмам», – дип сүз бирде.

Өенә ул ачуланып, ярсып кайтып керде.

– Нәрсә, улым, бер-бер хәл булдымы әллә?

– Булды инде, әни.

– Бездә үзгәрешләр бар, – диде күңеле күтәрелгән ана.

– Нинди үзгәреш?

– Өстемдәге күлмәгемне күрмисеңмени?

– Күрәм. Кем кидерде аны сиңа?

– Алсу!

Бу кызның исемен ишетү белән, дөньяда Регинелар, Наиләләр барлыгы онытылды. Баланлыга күченгән көн-нән бирле ул Алсу турында уйлады. Яңа җирдә беренче көнне үк Алсуның керүе, ә иң мөһиме аның авыру әнисенә ярдәм итүе, бернинди чирканусыз әнисенең йомышларын үтәп йөрүе сөендерде. «Нишләп мин, кыздан читләшергә теләп, үземне газаплыйм соң әле? Дөньяда бер Наилә, Регинелар гына түгел, Алсулар да барлыгын нигә күрмәмешкә тырышам?»

Айратның күңеле күтәрелеп китте. «Алсу белән ешрак очрашырга кирәк», – дигән нәтиҗәгә килде.

Айрат Алсуны бөтенләй көтелмәгән җирдә очратты. Ул ихатасын әйләндереп алу өчен урманга киртәләр ки-сәргә киткән иде. Шунда гөмбә җыеп йөрүче Алсуга юлык-ты:

– «Бирермен дигән колына чыгарып куяр юлына» дигәндәй, сине күрү өчен ничә тапкыр турыгыздан үттем, ә менә бүген бөтенләй көтмәгәндә...

– Мине күрәсең килгәч, нигә өйгә кермәдең? – диде Алсу бернинди тартынусыз. Айратны очраткач, аның да күңеле күтәрелеп китте.

– Кызлар белән өйдә очрашмыйлар бит инде...

– Кызлар белән махсус очрашу урыны бармыни?

– Бар!

– Кайда ул? Миңа да әйт әле.

– Җир белән күк арасында.

– И-и, мин чынлап әйтәсең дип торам.

– Мин чынлап әйтәм. Синең кебек кыз белән гап-гади әбиләр йөри торган урамда очрашып булмый бит инде.

– Мин дә бит, шул әби-чәбиләр төсле, җиргә басып йөрүче гап-гади кеше.

– Юк, син фәрештәләр нәселеннән. Сине очрату йол-дыз табуга тиң. Сине беренче күрүдә үк, мондый кызлар, дөнья ямьсезләнә башласа, аны матурлар өчен җи-бәрелгән затларның берседер, дип уйладым.

– Дөнья бик матур, минемчә.

– Дөнья матур, әмма аны ямьсезләүчеләр дә күп.

– Анысы дөрес.

Айратның хәтер күпере аша Регинелар, Наиләләр узды. Ләкин Алсу бөтенләй башка. Аның күңел балкышы йөзенә чыга, нурлары керфекләренә эленеп кала. Дөрес, Регинелар да чибәр иде. Әмма аларга инкубаторда туган этәч кирәк. Ә Алсу Айратның әнисенә карата мәрхәмәтле. Ул аны кызганып түгел, ничек бар – шулай кабул итә.

– Дөньяны синең кебекләр матурлый, – диде Айрат, уйларыннан арынып.

Кызга бу сүзләр ошаса да, ул аларны шаяру дип кабул итте. Ә егет исә кызга мактау сүзләрен сынау нияте белән яудырды: Алсу аларны ничек кабул итәр? Мактаулардан түбәсе күккә тимәсме? Ләкин Алсу тасма телләргә ышана торган кыз булып чыкмады. Ул, егетнең сүзләрен тыңлап бетергәч:

– Һәр кызга әйтә торган сүзләрегезне әйтеп бетердегез бугай, хәзер мәдхия укуларны калдырып, үзебезнең гади телебезгә күчик, – диде.

Егет Алсуның тапкырлыгына таң калды. Гадәттә, мон-дый сүзләргә кызлар ышаналар һәм үзләрен күккә йолдыз сибеп йөрүче фәрештәләрнең дә фәрештәсе дип саныйлар иде.

– Ярар, алайса, гади кешеләрчә генә сөйләшик, – диде егет. – Син чынлап та бик чибәр кыз. Минем сиңа беренче күрүдә үк күзем төште. Ләкин «яратам» дип әй-тергә куркам.

Кыз, гаҗәпләнеп, егеткә карады. Алсу да Айратны беренче күрүдә үк ошаткан иде. Аеруча егетнең авыру әнисенә карата булган мөнәсәбәте кызның җанына ниндидер бер җылылык сирпегән иде. Егет әнисенең күз карашыннан ук аңа ни кирәген аңлый, һәм ананың бер керфек сирпеп алуы егетне очындырып җибәрә иде. Мондый очракта җанында мәхәббәт яткан кеше ясалма була алмый. Димәк, Айратның күңеле чиста, намусы саф. Ә Алсуга карата әйтелгән мактау сүзләре бары тик үзенең егетлеген күрсәтеп алу, гадәти бер матур сүзләр яудыру гына.

Айрат «бу кызның күңеленә нинди ачкыч табарга икән?» дип барганда, сүз дилбегәсен Алсу үз кулына алды:

– Үзеннән соравы авыр, Тәнзилә апа күптән авырыймы?

Айрат кул селтәп куйды: янәсе, бу хакта нигә сорап торырга инде? Ләкин җавап та бирмичә булмый. Алсуның сүзне иң авырткан җирдән башлавы әйбәт тә. Чөнки барыбер бу сорауга кагылмый калу мөмкин хәл түгел.

– Җиденче елга китте инде.

– Гел берүзең карадыңмы?

– Аһ-ваһ итеп утырырга күрше-тирәләр кирә иде, ләкин мин андыйларны кертми башладым.

– Сөйләшеп утырырга да кеше кирәк бит.

– Гел бер сүзне болгатудан ни файда? Аннары кергән кеше бит ул авыруның тегенди-мондый йомышы барлыгын оныта. Әни, болар кайчан чыгып китәр икән, дип газапланып ята. Өстәвенә кергәне бере сүзен этине сүгүдән башлый. Ә мин этине гаепләмим. Ул кулыннан килгән ярдәмне күрсәтә. Авыргач ташлап чыгып киткән икән, аның да үз тормышын корырга хакы бар. Әни аны үзе чыгарып җибәрде бит. Берәүнең бәхетсезлегенә икенче кеше гаепле түгел, диде. Әти озак кына аның белән бәхәсләште, сине ташламыйм, диде. «Бер бәхетсездән ике-не ясыйкмыни? – диде әни. – Теләгәндә килеп йөрер-сең...»

– Әниең нинди олы йөрәкле кеше синең, Айрат.

– «Айрат улым, син барында мин үземне чирле кешегә санамыйм. Аяк-куллар эшләмәү аркасында ятып торам икән, бу минем яшәү рәвешем. Кешеләрнең яшәү рәвешләре төрлечә булырга мөмкин», – диде әни.

Айрат белән Алсу ешрак күрешә башлады. Айрат югында Алсу керсә, Тәнзиләнең йөзе балкый. Шушы бал-кыш бөтен өйгә тарала кебек. Тәнзилә үзе дә Алсуга:

– Син керсәң, өйләребез яктыра. Синең яктылыгың бөтен стеналарга, өйдәге әйберләргә сеңеп кала кебек. Үзең чыгып киткәч тә, нурың сүнми тора әле, – ди.

– Сез мине алай илаһилаштырмагыз, Тәнзилә апа, – ди Алсу, – мин гап-гади җир кызы бит. Ә менә сез философ, Тәнзилә апа.

– Без һәммәбез дә философлар. Дөньяга, яшәешкә һәркем үзенчә карый. Вакыйгаларга үзенчә бәя бирә.

– Сез язмышыгыздан зарланмыйсыз, беркемне каһәр-ләмисез.

– Язмышымны каһәрләсәм, оят булыр иде миңа. Шундый акыллы улым бар. Ул мине сабый баладай- карый. Кая теләсәм, шунда алып бара. Никадәрле курортларда булдык. Дөнья күрдек. Рәхмәт инде җитәк-челәренә, кеше хәленә керә беләләр. Күреп торам: син-нән җәмгыятькә бернинди файда юк, дип караучылар да бар. Андыйлар шуны аңларга теләмиләр: җәмгыять без бит ул. Әйе, кемнәрдер йортлар төзи, юллар сала, игеннәр үстерә. Алар менә безнең ише кешеләрне туендыра, киендерә, йортлы итә алулары белән бәхетле. Син үзең, Алсу кызым, кешеләргә белем бирәсең. Үзең укыткан балаларның һәр көн үсә, акыллырак була баруларын күреп сөенмисеңме?

Алсу, Тәнзилә әйткән сүзләр белән килешкән хәлдә, әңгәмәнең йомгагын көтте.

– Кыскасы, – дип сүзен дәвам итте Тәнзилә, – әгәр эшләгән кешенең эшенә сөенүчеләр булмаса, эшләүнең мәгънәсе калмас иде. Күп кенә кешеләр: «Аллаһы Тәгалә гарипләрне нигә дөньяга тудыра икән?» – дип, үз-үзенә сорау куя. Ә бит моңа җавап гап-гади: безнең кебекләргә карап, сәламәт кешеләр җиргә дөп-дөп басып йөрү бә-хетен тоя, эшли алу шатлыгын кичерә.

Алсу Тәнзиләнең фәлсәфәсе белән килеште дә, килеш-мәде дә. Ә, бәлки, тормыш мәгънәсен шулай гадиләштеребрәк күңеленә сеңдерсәң яшәү җиңелрәктер? Ә бит төп-тәнрәк уйласаң, Тәнзилә хаклы: дөнья җитештерүчеләр белән кулланучылардан тора.

Тәнзиләләргә кергән саен, Алсу аның күңел хөрлегенә соклана. Берни эшли алмаган хәлдә дә, һәр яңа туган көнгә, аннан да бигрәк узып киткән көнгә шатлануы гаҗәпләндерә Алсуны.

– Мин сезгә гаҗәпләнәм, – диде аңа Алсу көннәрдән бер көнне.

– Нәрсәгә гаҗәпләнәсең?

– Сез көннең тууына да, узып китүенә дә сөенәсез.

– Монда гаҗәпләнерлек нәрсә юк, – диде Тәнзилә. – Йокыдан уянып күзләреңне ачып җибәрүгә, яши-яши яратып өлгергән дөньяңны күрәсең. Үзеңне шушы гаҗәеп серле дөньяның бер кисәкчеге итеп тою сөенеч түгелмени? Ә инде көнең матур уйлар тудырып, җаныңа моңарчы син белмәгән кичерешләр дулкыны салып китсә, шуның нәтиҗәсендә күңелең байый төшсә, бу көнгә ничек инде рәхмәт укымыйсың?!

Алсу Айрат белән ешрак очрашкан саен, егет күңеленә әнисе сипкән орлыкларның үсеп, бу күңел кырының матурлана баруын күрә. Әмма Айрат кайвакыт тиктомалдан кырыслана. Алсу аның халәтен аңларга тели, әмма үз сорауларына җавап таба алмый.

– Сине аңлый алмыйм мин, Айрат: бер карыйсың – шат, шаян, икенче карыйсың, йөзең караңгылана.

– Әйе, – диде Айрат, авыр сулап. – Безнең болай йөрүебез юкны бушка алыштыру гына булмасмы, дип уйлыйм.

Алсу егетнең тел төбен төшенми торды.

– Нәрсә, кайбер кызлар кебек йоклап йөрүемне телисеңме? Хәзер бит шундый кызларны ныграк яраталар.

– Ачуымны китермә әле. Мин сиңа бергә йоклап йөрү турында берәр сүз әйткәнем булдымы?

– Бәлки, әйтергә кыюлыгың җитмәгәндер?!

– Аны сүз белән әйтми дә эшләп була. Мин шофёр кеше. Кызларның юлга ничек чыгып басуларыннан ук кемнең кем икәнен аңлыйм. Андый кызлар кирәк булса, мин синең белән йөрмәс тә идем.

– Алайса, нәрсә сине уттан алып суларга ташлый?

– Әгәр мин аны әйтсәм, сине югалтырмын дип куркам.

– Әйт! Мин нәрсә әйтсәң дә югалмам.

Айрат сүзсез торды. Алсу аның өчен шундый якын, кадерле кешегә әйләнде ки, хәтта кызның исеме генә дә аны кайнар тиргә сала иде. Ул һәр көнне, эштән кайтканда: «Алсу авылдан китмәгәнме?» – дип борчыла. Балалардан яки эскәмиядә утыручы карт-корыдан укытучы кызның авылда икәнлеген ишетсә, рәхәтлектән изүләрен чишеп җибәрә: «Мең-мең рәхмәт сиңа, Аллам!»

Ә, бәлки, бәхетне тагын бер кат сынап карарга дыр? Егет, Алсуның кулларыннан тотып:

– Алсу, син миңа кияүгә чыгар идеңме? – диде.

Алсу көлеп җибәрде:

– Шушымы синең миңа әйтергә куркып йөргән сүзең?

– Әйе.

– Әй җүләрем минем. Мин инде синнән бу сүзләрне беренче очрашкан көннән бирле көтәм.

– Син бит әниемнең авыру икәнен беләсең.

– Беләм. Әниең белән дуслашып беттек инде без. Ул шундый акыллы кеше. Аның белән сөйләшкән саен, күңелеңнең баеганын сизәсең. Күп кенә кешеләрнең аяк-куллары исән-сау. Ә башлары юк. Ни өчендер без башсызлыкны күрмибез. Дөрес, башсызларның өскә үрмәләү очраклары да бар, ләкин бит ул башсызлар белән акыллылар идарә итә.

– Димәк, син риза, Алсу?

– Риза. Өйдә Тәнзилә апа кебек акыллы кеше булу үзе зур бәхет.

– Авыруны карыйсы бар бит, Алсу.

– Карарбыз. Син берүзең дә карагансың бит әле.

Айрат Алсуны кочып алды да елап җибәрде:

– Нинди әйбәт кыз син, Алсу.

– Бер-беребезне алдан макташмыйк әле.

– Анысы да дөрес. Ә бүген без, дөньяның иң бәхетле кешеләре булып, әлегә унбер йорттан торган шушы авылыбыз урамын җитмеш җиде кат урыйк. Күктәге йолдызлар бездән көнләшсеннәр. Ай, безнең бәхетебезгә шаһит булып, туебызга килер.

* * *

Фатих завод эшләрен көйгә салгач, Нәркизә кабат эшенә чыкмады. Чәчәкләр үстерде, ә чәчәкләрнең иң затлысы аның өчен улы Рәсим иде. Нәҗия кызы Зөлфия белән Нәркизә улы Рәсим урамга хуҗа булып йөрүче кызыл әтәчне үртәүдән үзләренә рәхәтлек һәм кызык табалар иде. Зөлфия озын җепкә ит кисәге бәйләп йөгерә башлауга, кызыл әтәчнең күзләре уйный башлый һәм ул, алдын-артын карамый, җеп артыннан чаба. Шул арада Рәсим әтәчнең берәр каурыен эләктерергә өлгерә. Эскәмиядә утырган Зарифулла балаларга кисәтү ясый: «Ни үчегез бар ул әтәчтә? Нигә интектерәсез аны?» – дип дәшә, ә үзе урамда балаларның уйнап йөрүләренә бик шат. Кайчан гына әле Баланлы урамы буп-буш иде. Ә хәзер әнә тугыз бала бар. Аларның яшьләре төрле булганлыктан, уеннары да төрлечә. Кемдер туп тибәргә ярата, кемдер күккә самолётлар очыра. Зарифулла карт канәгать: «Бу Фатих бик үҗәт кеше булып чыкты. Тәки үзенекен итә. Әле бит әнә, чишмә суын торба белән авылга төшерәм, дип йөри. Төшерер дә. Нефтьчеләр белән дус: торбасын да табарлар, суын да төшерерләр. Дөрес булса, Баланлыга газ кертү артыннан чаба, имеш. Гадәттә, кеше баеган саен комсызлана. Шөкер, Фатихта бу сыйфатлар күренми әле. Уе аның авылны үстерү ягында.

Беркөн ул, эштән кайткач, Зарифулла янына чыгып утырды.

– Үсәбез бит, Зарифулла абзый, – диде Фатих, авылга сокланып.

– Әйе, үсәбез. Унбер йортлы Баланлы без хәзер.

– Җитмеш йортлы да булырбыз. Әле кеше җирнең кадерен белеп бетерми. Килер шундый вакыт: Баланлыда йорт салыр өчен шәһәр кешеләре үзләренең алтын сарайларын сатар. Авыллар яңа тамыр җибәрерләр. Безнең илнең үзәк тамыры авылда. Без икмәк белән көчле. Таш арасында таракан гына әйбәт яши, – диде Фатих.

– Әйе, – диде Зарифулла, аның сүзен раслап. – Безнең тамырларның берсе – зиратта, икенчесе – шушы нигезләребездә, өченчесе – балаларыбызда.

Фатихның һәр сүзенә Зарифулла карт:

– Әһе, әһе, – дип торды.

Шулвакыт болар янына Зөлфия белән Рәсим килде. Зөлфия Рәсимне ат итеп өстенә менеп атланган. Әтисе янына килгәч, Рәсим зарланып алды:

– Әти, карале, Зөлфия мине бахбай итте.

– Зарланма, улым. Син егет кеше.

– Менә күрдеңме? – диде Зөлфия. – Син егет кеше икәнсең бит.

– Ә син атаман, – диде Рәсим. – Үскәч, атаманнар баш-лыгы булырсың.

– Юк, мин укытучы булам.

Рәсим аңардан рәхәтләнеп көлде:

– Кызыл кар яуса гына инде.

Кызыл кар яуганны көтәсе булмады, Зөлфия – Казанда, Рәсим Мәскәүдә университет бетереп кайттылар. Алар һәр көнне теге серле күл буена төшәләр. Рәсим, сиздермәскә тырышып, Зөлфиягә карый. Зөлфия шундый чибәрләнгән. Аның яшел күзләрендә яшьлекнең яшел уты яна. Йөзендәге сипкелләре кызны матурлау өчен махсус сибелгән кебек.

– Сиңа Казан һавасы килешкән, чибәрләнгәнсең.

– Сиңа да Мәскәү һавасы файдалы булган, күзең ачылган. Ә миңа Казан һавасы түгел, серле күлгә чумып чыгуның дәвасы тиде.

Зөлфия белән Рәсим, бәхәсләшә-бәхәсләшә, бер-беренә якыная бардылар. Авыл халкы аларны күптән инде «өйләндереп» куйган иде.

Ә вакыт әле ак буранга әйләнеп далалар буйлап йөгер-де, әле агымсулар булып диңгезгә юл тотты, әле йолдыз булып офыкларда атылды. Зөлфия белән Рәсим, кышның бураннарын, җәйнең чәчәкле аланнарын, язның ярсулы ташкыннарын кичеп, бүгенгегә килделәр. Аларның уртак байлыклары күп, ә иң зурысы йөрәкне йөрәккә тоташтыручы мәхәббәт иде. Рәсим табигате белән бераз тәкәбберрәк, әмма Зөлфиянең чаялыгы ул тәкәбберлекне челпәрәмә китерә торды.

Алсу белән Айрат та өйләнешеп әйбәт кенә яшәп яталар. Зөлфияләр институт бетереп кайтканда, Алсу бала табарга җыена иде. Тиз арада аның урынына яңа укытучы кирәк булды. Салына башлаган мәктәпне дә төзеп бетерергә кирәк.

Бу эшкә Зөлфия белән Рәсим алынды. Авылда укучылар да күбәйгән иде. Рәсим, чит телләр факультетын тәмамлаган белгеч буларак, уку елы башлануга, балаларга инглиз телен укыта башлады, ә Зөлфия татар теле һәм кечкенәләргә барлык фәннәрне укытты.

Төрле сыйныф укучыларын бергә җыеп укыту кыен иде. Рәсим беркөнне мондый тәкъдим ясады:

– Зөлфия, әйдә болай эшлибез.

– Ничек?

– Мин олырак балаларга инглиз телен тирәнтенрәк укытырга, ә бераздан соң барлык фәннәрдән дә инглиз теленә күчәргә кирәк дип уйлыйм. Әтинең җиһаз белән шыплап тутырылган бүлмәсен бушаттырып, инглиз телендә укучыларны шунда күчерәм. Юкса такта белән генә бүленгән классларда укыту читен.

– Әти-әниләрең рөхсәт итәрме соң?

– Итми кая китсеннәр! Алар бит шушы Баланлы өчен җаннарын бирергә әзерләр.

– Авыл баласына инглиз теле кирәк булыр микән соң? – диде Зөлфия.

– Балаларны авылныкына, шәһәрнекенә бүлеп карарга кирәкми. Хәзер компьютер заманы. Ә компьютерлар инглиз теленә көйләнгән.

– Аларны татар теленә дә көйләргә мөмкин, – диде Зөлфия.

– Ләкин татар баласына татар телендә генә укырга димәгән. Алар, үскәч, төрле җиргә таралырлар. Ә компьютерны һәм инглиз телен белмәгән кешегә эш табу кыен.

– Анысы шулай.

– Ә нәрсә шулай түгел?

– Минем үз телебезне камил белгән балалар үстерәсем килә. Башка телдә тәрбияләнгән бала үз милләтеннән аерыла.

– Синең фикерең белән килешмим мин, Зөлфия. Татар баласы кая гына барса да югалып калырлык булмасын. Бер авызга ике тел сыймый, дисәләр дә, минем уйлавымча, бер авызга бик күп телләр сыя. Мин Мәскәүдә бер кыз белән таныштым. Ул Халыкара мөнәсәбәтләр инс-титутында укыды. Без аның белән башта инглиз телендә сөйләшә

идек. Бер күргәндә, ул иптәш кызы белән чип-чиста итеп татарча сөйләшеп тора. Без аның белән Мәскәү урамында Тукай, Такташ, Туфан шигырьләрен сөйләп йөрдек. Рус телен шәп белүе белән дә шаккатырды ул мине.

– Син анда әллә нинди кызлар белән танышып йөргәнсең икән әле, – диде Зөлфия.

– Мәскәүдә кеше күп бит.

Зөлфия белән Рәсим, сөйләшә торгач, бер карарга килделәр.

– Зурлар төркемен инглизчә укытырга. Кая гына барса да, татар үзенең татарлыгыннан кимсенерлек булмасын. Милләтебез белемлерәк булган саен, аны ныграк хөрмәт итәчәкләр.

Рәсим әтисеннән мәктәпкә компьютер кайтартты. Нәркизә соңгы вакытларда еш авырый башлады. Фатих белән Рәсим аны тау куышындагы ләмгә алып барып дәваладылар. Тау куышының сере ачылгач, Айрат белән Алсу да әниләрен шунда йөртә башладылар. Кем белә, бәлки, шифасы тияр. Без барыбыз да җир кешеләре. Тамырларыбыз җиргә тоташкан.

* * *

Вакыт әле болытларга уралып, әле кояш нурларына кушылып ага торды. Баланлыда яңа йортлар ишәйде. Балаларның чыр-чу килеп уйнаган тавышы, күкнең зәңгәр кыңгыравына бәрелеп, дөньяга яңгырады. Кызыл әтәч кайдадыр юкка чыкты. Аның урынына инкубатордан алып үстергән ак әтәчләр пәйда булды. Ә көннәрдән бер көнне, кара төнне ярып, әтәчләр кычкыра башлады. Таң алды булганлыктан, кешеләр каты йокыда иде, әмма әтәчләр хоры иң тирән йокыдагыларны да сикертеп торгызды. Әтәч кычкырудан туктап бераз тын алуга, яшь бала елаган тавыш ишетелде. Бу, әлбәттә, Алсу белән Айратның баласы иде.

Зарифулла карт тәрәзәдән карады. Күктә фәрештәләр офык чикләрен ачып, аның чикләренә бала бишекләре элеп йөри иде.

– Бәрәкалла, – диде Зарифулла карт, күзләрен угалап. – Тикмәгә түгел бу. Димәк, Баланлы авылында тагын балалар туачак. Халкыбызның үзәк тамыры авылда икәнлеген аңлый башладылар. Иншалла, Баланлыга карап башка авыллар да үсәчәк. Шулай булсын. Амин.

Һәм Зарифулла карт чиста келәм өстенә намазлыгын җәйде.

## ФАҖИГА

### I

Улы Нәзирдән берьюлы ике хат килеп төшкәч, Сәлимә апа хатларның кайсын башлап ачарга белмичә кулында әйләндергәләп торды, пичәтләрен карады, тик андагы числоны таный алмады. Аннары кулына калын тоелганын ачып укый башлады.

«Әни, мин кичәгенәк кенә сиңа бер хат язып салган идем, бүген тагын язарга булдым. Мин экзаменнарны быел алдан биреп бетерергә уйлыйм, колхозда печән өстенә өлгерәсе иде. Юкса ике ел инде рәхәтләнеп печән исен иснәгәнем юк. Кайтканда, үзем белән бер кыз да алып кайтам, аның да безнең якларны күрәсе килә...»

Сәлимә апа, хаттагы шушы сүзләргә җиткәч, укуыннан туктады. Аның башында төрле уйлар чуалырга тотынды. «Бер кыз да алып кайтам, дигән. Бу аның, өйләнеп кайтам, дигән сүзе түгел микән? Тукта, тукта, чынлап та шуңа ишарәли бит бу бала. Ах, малай актыгы, әзерләнебрәк тор, йөзгә кызыллык килерлек булмасын, дигән бит. Кырык биш ел яшәгән әнисен өйрәтеп маташа. Мондый эшләрдә әниең ни кирәген белә инде ул».

Сәлимә апа улының һәрбер сүзе белән бәхәсләшә-бәхәсләшә хат укыган вакытта, күршесе Маһирә килеп керде.

– Нәзирдән хат бармы әллә? – дип сорады ул.

– Әйе, берьюлы ике хаты килеп төшкәч, әллә бер-бер хәл булганмы дип куркып киткән идем, ул-бу юк икән.

– Ниләр яза?

– Печән өстенә кайтып җитәбез, дигән.

– Шулаймыни? Кайтабыз, дигәнмени? Безнең авылдан унберситеттә бүтән укучы юк түгелме соң? Әллә берәр марҗа ияртеп кайтамы?

– Син тагын бигрәк арттырып җибәрәсең инде. Ка-занда әллә бөтен халык марҗадан гына тора дип беләсеңме?

– Укыган кеше маржа алса да гаеп түгел, – диде Ма-һирә. – Ни чыкса, шул укыганнардан чыга бит. Безнең эше наданнарның башы житмәстәй эшне укыганнар эшли. Әнә теге «Маяк» колхозына килгән агранум да, ике баласы була торып, бырач кыз Дөя артыннан йөри, ди бит.

– Дөя түгел, Зоя, – дип төзәтте Сәлимә апа.

– Дөяме, төяме, йөрүләре хак булгач, минем өчен барыбер.

– Син, Маһирә, жыен юк-барны жыеп йөрисең инде. Күрше авылга агроном килгәнен мин ишетмәгән дә идем әле, ә син инде кем артыннан йөрүенә кадәр тикшереп өлгергәнсең.

– Мин тикшермәдем, андый хәбәр үзе дә бик тиз тарала бит. Беркөн картым аягын бәйләтергә дип шул Дөя янына барган иде, шунда күреп кайткан. Агранум белән бырачның авызлары авызда иде, ди. Мине күргәч, Дөясе юри тегесенең кулын бәйләргә тотынды, ди. Андый хәйләләрне генә беләбез инде без.

Сәлимә апа, Маһирәнең сүзе бетмәслеген күргәч, хатларын жыештырып, күптән бәйли башлап та соңгы вакытларда кулына тотып карамаган бәйләмен бәйли башлады. Ләкин Маһирәнең һаман да чыгып китәргә исәбе юк иде.

– Нәзирнең ниләр язганын әйтмәдең бит, – диде ул, өзелгән сүзне ялгарга теләп. Нәзир турында Сәлимәнең һәрвакыт горурланып, мавыгып сөйләргә яратканын бел-гәнгә күрә, Маһирә юри әңгәмәне шул якка борды. Аннары Нәзир белән кызыксынуы да көчле иде аның. Күршедә генә үскән бу акыллы, тыйнак, хәтта бераз юаш Нәзирне ул күңеленнән үзенең кияве дип исәпләп йөри иде. Нәзир, Казанга киткән елны, Камиләгә бер-ике хат та язып салды. Кызы Камилә өйдә юкта, Нәзирнең бу хатларын Маһирә әйләндерә-әйләндерә укыды. Бер укыганда – баштан ахырга, икенчесендә ахырдан башка таба, һәрбер сүздән яшерен мәгънә эзләп укыды ул.

Бик тырыша торгач, ике төрле мәгънә аңлата торган сүзләр дә тапты. Һәм Маһирә бу хатларны «изге эшнең башы» дип күңеленнән юрап куйды. Шуңа күрә дә Нәзирнең һәр адымын күзәтергә тырышты ул.

– Нәзирнең ниләр язганын да яшерә башладыңмыни инде? – диде Маһирә үпкәләгән тавыш белән.

– Нигә яшерим? Яшермим. Үзең бит төрле гайбәтләргә кереп киттең. Әйтсәм, тагын бише белән арттырып, авылга таратырсың.

– Таратмам, мин жил тегермәне түгел лә. Тотам дигән сүземне авызымда тота алам. Йә, әйт инде. Терәлеп торган күршеңнән сер яшермә.

Сәлимә өстәл тартмасына салган хатларын кире алды. Ләкин ул аларны сүзгә-сүз укуны кирәк тапмады, хатларны кире өстәлгә ташлады.

– Монда әллә ни әйтерлек сүз юк инде. Нәзир, бер кыз белән кайтам, әзерләнебрәк тор, дигән. Бары шул гына.

Сәлимәнең бу сүзләреннән Маһирәгә кызу булып китте. Ул өстендәге кофта төймәләрен ычкындырып ташлады, әмма бу юлы үзен тиз кулга алды.

– Бары шул гына, имеш. Тагын сиңа ни кирәк? Монда бит инде барысы да көн кебек ачык, юньле кыз егет өенә кайтып йөримени?

– Син, Маһирә, кешенең исемен дә белмәгән килеш, аңа пычрак атарга ашыкма. Бәлки, ул бик тәүфыйклы, бик миһербанлы, бик акыллы кыздыр. Нәзир бит, юаш булса да, теләсә нинди кызны муенына атландыра торган егет түгел.

– Нәзиргә минем бер сүзем дә юк, – диде Маһирә, үзенең әйткән сүзләрен бераз йомшартырга теләп. – Нәзир акыллы егет иде, ике ел шәһәрдә тору гына бозмаган булса.

– Кешеләр Казанга бозылыр өчен китмиләр, киресенчә, үсәргә, зур кеше булырга дип китәләр. Аннары, күңеле әйбәт кешене бернәрсә дә боза алмый. Нәзир хәзер сабыйлыктан чыккан инде, үзенең ни эшләгәнен белә торгандыр. Өйләнергә теләсә өйләнер, егерме яшендә безнең этиләр революция ясаганнар.

– Мин өйләнмәсен димим ләбаса, нигә болай чәпчеп киттең?

– Чәпчемичә. Бөтен сүзне начарга гына юрарга торасың бит. Синеңчә, дөньяда бер рәтле кеше дә юк. Кайсы хатыны өстеннән йөри, кайсы урлаша, кайсының нияте гел алдашуда.

Маһирә Сәлимәнең бу сүзләрен яратмады. Ләкин күр-шесеннән ишеткән яңалыкны карты Мөхетдингә, аннан да бигрәк кызы Камиләгә тизрәк сөйләп бирергә теләп, ашыга-ашыга чыгып китте.

Камилә, яңа гына фермадан кайтып, өстен-башын алышып тора иде. Маһирә ачуыннан аңа ташланды:

– Ничә тапкыр әйттем, шушы шакшы киемнәреңне алып кайтма, дип. Бөтен өйне тавык кетәге ясагансың бит. Ичмасам, тәрәзәләрне ачып жиллә. Өебез кызлар тора торган өйгә охшамаган. Чит кеше керсә оят, валлаһи.

Әнисенең юк кына нәрсә өчен дә кабынып китә торган гадәтен белгәнгә күрә, Камилә шаккатмады. Бары тик илтифатсыз гына сорап куйды:

– Нәрсәгә бик дулап кайттың, берәрсе йонынны кире якка сыйпап жибәрдеме әллә?

– Мин ишеткәнне ишетсәң, син дә дуларсың. Дулау гына түгел, утырып еларсың. Сәлимәнең теге бозавы Казаннан өйләнеп кайта, ди. Бүген генә әнисенә хаты килгән.

– Өйләнсә соң? Анда безнең ни эшебез бар? Теләсә, берне түгел, икене алып кайтсын. Минем аңа карап бер җирем дә кителми.

– Өйләнсен, имеш. Ә үзең аның моннан ике ел элек язган хатларын сандыгыңда саклыйсың. Сер бирмәгән була, имеш.

– Хатларын сакласам гаепмени? Терәлеп торган күр-шеләр бит.

– Күршеләр генә шул.

– Күршеләр булгач җиткән, аның белән безнең алыш-бирешебез юк.

– Сөйләнеп торасың тагы, ачык авыз. Шундый юаш, шундый әйбәт егетне кулдан ычкындыралармыни? Рәт-лерәк эштә эшләсәң, үзе дә болай булмас иде. Ябышып каттың бит шул фермаңа. Бөтен яшьләр шунда, имеш. Фермада тавыклар арасында йөргәнче, өйдә ятуың әй-бәтрәк булыр. Бер чиләк катык сатып кайтсаң да, өч көн эшләгәнеңне кайтарасың. Өстең дә чиста булыр, кесәң дә буш булмас.

Хатынының тавышын ишетеп, түр яктан Мөхетдин чыкты.

– Нинди базар оештырдыгыз, нәрсә бар? – дип, ул Маһирәгә дә, Камиләгә дә карап куйды.

– Нәрсә булсын, менә моның кияве өйләнеп кайта, ди.

– Нишләп минем киявем булсын ул? Син, әни, авы-зыңны үлчәп ач, кеше ишетсә, әллә ни дияр. Кайчандыр бер мәртәбә хат алышкан кеше кияү булса, андыйлар күп булыр ул.

– Күп ди менә, синең ише ферма тавыгына бик күп кияүләр әзерләп куйганнар ди.

Сүзнең болай озынга китүен, тиз генә бетмәслеген күр-гәч, Мөхетдин дә кушылмый булдыра алмады. Ул үзенең юаш, килешүчән тавышы белән, йомшак кына итеп:

– Син, анасы, бик арттырып җибәрәсең. Безнең Ка-миләкемнән ким? Төскә-биткә томрап тора. Телгә дә ма-һирлыгы бар, – дип сөйли башлаган иде, ләкин хатын аны тиз туктатты:

– Син, титак (аксак булганга, ул ирен шулай атый иде), нәрсә беләсең соң? Эш төстә-биттә генәмени? Хәзер ямьсез кызлар юк та ул.

– Эш нәрсәдә соң?

– Нәрсәдә булсын, шундый егетне кулдан ычкындыруда. Хәзер андый тыңлаучан егетләр бик күп дип беләсезме әллә? Яшьләр хәзер бар да бозылды. Берсенбер сүз тыңлатып булмый. Ә Нәзир ни кушсаң, шуны эшләп үсте: каз бәбкәсен карау дисеңме, бозау саклау дисеңме – барысы да аның өстендә булды бит. Хәзер андый бала табып кара син.

– Насыйп булганы Камиләгә дә табылыр әле, кызыбыз кырыкка җитмәгән. Кияүгә дә чыгар, бала да үстерер. Язмыштан узмыш юк.

– Язмыш менә монда, атаң башы. Авызыңны ачып торсаң, сиңа кияү китереп тоттырырлар. Көт Аллаңнан.

– Әни! Җитәр инде, телеңне тый. Мин синнән кияү сорамыйм, үзеңнең кияүләрең белән башымны катырма. Әгәр миннән туйган булсагыз, турысын әйтегез, бүгеннән үк чыгып китәрмен. Әнә Иркутск ягына язып йөриләр, язылдым киттем.

– Китәрсең абзар артына. Фермаңнан ерак китә алган булсаң, моңарчы киткән булыр идең. Бүгеннән шул тавыклар базына аяк басасы булма, ишетсен колагың. Әнә сыерның сөтен сат, мин картайганчы җилкәм белән ипи ташып сезне туйдырмам. Әле дә инде төннәр буе сызланып чыгам.

Маһирә, үзенең чынлап та авыру икәнлегенә ышандырырга теләп, йөзләрен җыерды, куллары белән биленә ябышты.

– Сызлана-сазлана катык сатып йөрергә сине кем мәҗбүр итә соң? – диде Камилә.

– Менә сезнең туймас тамагыгыз мәҗбүр итә, – диде Маһирә, еламсырап.

– Мин үземнең тамагымны туйдырырлык кына акча табам.

– Кайчан таба башладың соң әле? Егермегә җиткәнче сине кем карады? Егерме биш ел эшкә ярамаган атаңның тамагын кем туйдыра? Барыгыз да минем җилкәмдә бит. Әтиеңнең инвәлитлек акчасы нәрсәгә генә җитә?!

– Маһирә, җитте! Минем инвәлитлегемә кагылма. Мин аягымны мич башыннан төшкәндә имгәтмәдем, сугышта имгәттем. Минем медальләрем дә бер уч.

– Ул медальләр сандык төбендә күгәреп ятудан башкага ярамый шул. Сугышта аягың гына түгел, үзең дә дөмегеп...

Маһирә әйтә башлаган сүзен бетерә алмыйча тукталып калды. Ул үзенең артыграк ычкындырып ташлавын абайлап алды, ләкин соң иде инде. Мөхетдин, башкага бик түзем булса да, үзенең гариплегенә кагылсалар, түземен

жуя, сабырын югалта. Бу юлы да хатынының сүзләренә бик рәнҗеп, кияргә азапланып маташкан күн итеген кулына алып, Маһирәнең йөзенә атты. Тегесе чырылдап өйдән чыгып чапты. Хатыны чыгып киткәч, Мөхетдин Камиләне битәрләргә тотынды:

– Сиңа да анаңның сүзен тыңларга вакыт инде. Ул сине начарлыкка өйрәтми. Фермада пычранып, үлгән бер чебеш өчен кайгырып йөргәнче, бүтән эшкә кер. Эшлисең килмәсә, катык сат. Шәһәр якын, катык кыйбат. Эшләмәгән кеше дә ачка үлми әле.

– Ярар инде, икегез дә шуны тукымагыз. Һәр көнне бер үк сүзләрне тыңлый-тыңлый чукракка әйләнеп барам. Шуның белән генә дөньягыз түгәрәкләнсә, бүгеннән фермага бармам. Тынычланыгыз.

Камилә идәндә аунап яткан эш киемнәрен аннан-моннан гына төрде дә чоланга чыгарып ташлады. Ул шуннан соң фермага бармады. Ләкин әнисе аңарга эшсез боегырга ирек бирмәде, күкәен-маен, суганын-шалканын әзерләп кенә торды. Кызының эшеннән Маһирә бик канәгать иде.

**II**

Улыннан хат килгәннән соң, Сәлимә апа өчен тынгысыз көннәр башланды. Ул, өе әле чиста булса да, бөтен әйберләрен чыгарып, өйнең һәр бүрәнәсен кыра-кыра юды. Нәзирнең эшкә кия торган киемнәрен чистартты. Яңа гына алган костюмын элекке бөкләм эзеннән сак кына итеп үтүкләде. Ире кинәт кенә үлеп киткәннән соң, үзенең өс-башына бик әһәмият бирми башлаган иде, килен кайтасы булгач, аларны да рәткә китерергә кирәк тапты. Ят кеше алдында оятка калуың бар.

Аларның кайчан кайтып төшәселәрен тәгаен белмәсә дә, Сәлимә апа Нәзирләрне һәр көн көтте. Көннәр узган, үләннәр күтәрелгән саен, Сәлимә апа тәрәзәгә ешрак карады. Инде чәкчәкләр дә пешерелеп, зур савыт-ларда матурлап, баллап катырылды. Киленгә дип алган күлмәклекләр дә кат-кат тикшерелде. Колхозда печәнгә дә төштеләр. Башка елларда печәнгә төшү вакытын җиткерәсе килеп, көннәрне тартып алырдай булып көткән Сәлимә апа быел улы кайтмыйча печәнгә төшмәүләрен теләде. Колхозда иң тантаналы, иң күңелле эшнең беренче көннәрен улының, улыннан да бигрәк, булачак килененең күрүен теләде ул. Кичә яшьләр гармуннар белән, колхозның йөк машинасына төялеп, болынга кит-теләр. Сәлимә апаның шушы шат яшьләр арасында үзенең Нәзирен дә күрәсе килгән иде, булмады, кайтып өлгерә алмадылар. Күрәсең, экзаменнарын биреп бетерә алмый торганнардыр. Юкса ул үзе дә печәнгә өлгерим дип атлыгып торадыр. Болыннарның исен сагындым, дигән бит. Бигрәк нечкә күңелле бала булды шул.

Ана, бер минутка да исеннән чыгармыйча, улын көтте. Ул көнне иртәдән бирле яңгыр койды. Алар, суга манып алгандай, шәбәреп кайтып керделәр. Өсләре юеш булса да, күңелләре көр иде аларның.

– Менә, әни, бер кыз алып кайтам, дип язган идем бит, ул кыз шушы була инде, – диде Нәзир, өйгә кереп исәнлек-саулык сорашкач.

– Әйбәт кенә кайтып җиттегезме, балакайларым? Сез кайтасы булгач, көне дә бозылып китте, – дип сөйләнде Сәлимә апа. Ул ничектер каушап калган төсле күренә иде. Кулындагы сулы чүмечен кая куярга белми аптырап, чүмечле килеш килеп күреште кунаклар белән.

– Сынауларыгызны ничек бирдегез соң, балалар?

– Әйбәт бирдек, әни. Менә Сиринә бар экзаменнарын да бишкә генә бирде. Сине, әни, кунак белән таныштырмаганмын икән әле. Күрешү шатлыгыннан каушап киткәнмен бугай. Таныш бул, булачак журналистка Сиринә Җаббарова. Ул да минем кебек икенче курсны бетерде.

– Исеме дә үзе кебек матур икән, профессияне дә әйбәтне сайлаган, – диде Сәлимә апа. – Әйдәгез, балалар, чишенегез, юыныгыз. Юл кешесенең карыны ачкандыр. Мин хәзер өстәл әзерлим. Улым, син чыгып тор, булмаса. Сиринә дә юеш күлмәкләрен алыштырсын.

– Ярар, сез киенгәнче, мин елгага барып юынып, чистарынып кайтыйм алайса. Әни, өскә берәр чистарак күлмәк бирсәң әйбәт булыр иде.

– Бу яңгырда нинди елгага бару ди ул. Болай да өч көн суда торттаннан ким булмагансыз инде.

Нәзир әнисе әйткәннән соң гына тышта яңгыр икәнен исенә төшерде. Кайту шатлыгы беләнме, күңеленә якын, яраткан кешесенең беренче тапкыр үз өенә аяк басуыннанмы, ничектер югалып калган иде. Ул җилкәсенә сөлге салгач та тагын ни кирәген белмичә аптырап торды. Бары тик әнисе җиз комганны кулына китереп тоттыргач кына, юынып керергә кирәклеген аңлап, ишегалдына чыгып китте. Нәзир чыгып киткәч, Сәлимә апа Сиринәгә:

– Әйдә, кызым, тиз генә без дә чистарынып алыйк, күшеккәнсеңдер. Өстеңдәге күлмәгең дә бик юка күренә. Милон гына бугай.

– Юк, апа, нейлон түгел. Юешләнгәнгә шулай юка тоеладыр. Җәй көне шуннан да калынны киеп булмый инде. Аннары, без юлга чыкканда, көн дә бик кызу иде.

– Үзең кайсы якныкы буласың, кызым?

– Мин Казаннан, апа.

– Шулайдыр дип уйлаган идем үзем дә.

– Ни өчен?

– Кыяфәтең авыл кызларыныкына охшамаган.

Сәлимә апа шулай дигәч, Сиринә баштанаяк үзен күздән кичерде, ләкин бер дә авыл кешеләреннән үзгәлек күрмәде ул үзендә.

– Нигә алай дисең, Сәлимә апа? Авыл кызларыныкы белән шәһәрнекеләр арасында аерма бармыни?

– Нигә булмасын? Шәһәрнекеләр – бодай камырыннан, авыл кызлары арыш камырыннан әвәләнә, ди бит, – диде Сәлимә апа, сүзне шаяруга борып.

Сиринәгә Нәзирнең әнисе беренче күрүдә үк ошады. Аның тапкыр сүзе, якын итүе Сиринәгә кыюлык бирде. Сиринә, ят кеше алдында уңайсызланырмын, сөйләшергә сүз таба алмам, дип борчылган иде. Баксаң, бу Нәзирнең әнисе дә гел үз анасы кебек гади, ачык булып чыкты. Алар гомерләрендә беренче тапкыр гына күрешүләренә карамас-тан, күптән очрашмый торган якын танышлардай, бер-берләре белән бик тиз уртак тел таптылар. Күбрәк Сәлимә апа сораштырды. Ләкин ана күңелендәге бик күп сорауларны башка вакытка калдырды. Хатын-кыз сизгерлеге белән ул Нәзир һәм Сиринә арасында бары тик гади дуслык кына булмавын тоеп алды. Әмма, кайтып керү белән ярамаган сораулар биреп, мәгънәсезлек күрсәтәсе килмәде аның. Ул арада Нәзир юынып, чистарынып килеп керде. Сиринә дә өс-башын алышып өлгергән иде инде. Сәлимә апага Сиринәнең өлгерлеге, берничә минут эчендә чәчен тарап, пөхтә итеп киенеп алуы ошады. Битенә дә, башка шәһәр кызлары кебек, иннек-миннек сөртми икән. Бары үзенең табигый матурлыгы белән матур. Сүз юк, Нәзир кызның чибәрен эләктергән. Чәчләре дала кылганыдай аксыл һәм күпереп торалар. Күзләре, кояш төшкән чык тамчысы кебек, әллә нинди төсләр биреп җемелдәп, нурланып торалар. Һәм гаҗәеп тереләр, сөйкемлеләр.

Сәлимә апа белән Сиринә өстәл әзерләгән арада, Нәзир чемоданыннан күчтәнәчләр чыгарып өстәлгә тезә баш-лады.

– Менә бу лимоннарны, әни, Сиринә алды. Авыл апалары лимонлап чәй эчәргә яраталар, ди. Ә менә бусы син яраткан бөртекле чәй, үзеңә генә тотарсың. Безгә, яшьләргә, яфрак кайнатып эчсәк тә ярар.

– Мондый заманда яфрак чәй эчәләрмени, юләр?!

– Ә мин, әни, мәтрүшкәләрне, кырда карлыган яфраклары салып кайнатылган чәйләрне сагынып кайттым. Си-ринәнең шушы яшенә җитеп мәтрүшкәле чәй эчкәне юк икән. Мин сөйләп күрсәткәч, авызыннан сулар килде.

– Йә инде, Нәзир, телеңә салынып, кунакны оялтасың.Шәһәрдә мәтрүшкә үсми бит, күрмәве дә гаеп түгел. Ә син, балам, оялып торма, мин пешергән ризыклардан авыз ит. Шәһәр кешесенә авыл ашлары тансык була ул. Менә Нәзир дә, каникулга кайтты исә, ипине үземнән пешертә. Ул югында мин, берүземә мичкә ягып маташканчы дип, ипине кибеттән генә алам.

– Аш-суга бик оста икәнсең, Сәлимә апа. Бавырсак-лар авызга керү белән эреп китә, – диде Сиринә, тәмле ризыкны кабып.

– Безнең әни анысын булдыра инде ул. Берәрсенең малае өйләнсә яки кызы кияүгә чыкса, аш-су әзерләргә аны чакыралар.

– Алай бик мактамагыз әле, балалар. Масаеп китүем бар. Хәзер бит ни пешерим дип аптырап торырлык түгел. Кершәндәй оны, сөте-мае дигәндәй, барысы да бар. Пешерә-пешерә остарасың да, шомарасың да. Аллага шөкер, ризык мул, колхоз бай.

– Нинди эштә эшлисең, Сәлимә апа?

– Яшелчәчелек бригадасында. И, үзегез искә төшер-мәсәгез, бөтенләй онытып торам икән, сез кайтуга дип бераз кыяр әзерләп куйган идем. Иске авызга яңа аш булсын, алып керим әле.

Сәлимә апа яшьләрчә җитезлек белән шиңмәсен дип кар базына төшереп куйган кыярларын алып керде.

– Шулай кыярлар да өлгердемени инде? Без, университет бинасында бикләнеп ятып, яз үткәнен дә, җәй җиткәнен дә сизми калабыз, – диде Сиринә, шадраланып торган ямь-яшел кыярны алып.

– Кыярлар әле бик өлгереп җитмәде, берничә төпне парникта үстереп утырткан идем. Нәзир яңа җиткән кыярны бик ярата, ул кайтуга бер күчтәнәч булыр дип өлгертергә тырыштым.

– Син, апа, Нәзирне алай артык иркәләп җибәрсәң, капризланып китмәгәе.

– Тәртәгә тибә башласа, авызлыгын тиз тартырбыз, без бит хәзер икәү, – диде Сәлимә апа һәм Сиринәгә серле генә итеп карап куйды.

Алар шулай күңелле генә сөйләшеп чәй эчтеләр, сал-кын көндәге кар кебек шыгырдап торган кыярны ашадылар. Барысының да кәефләре әйбәт. Бигрәк тә Сиринәгә Сәлимә апаның шулай ачык, шат булуы ошады. Улына караганда әнисе сүзчәнрәк икән, йөзендә – бер караудa җәлеп итә торган сөйкемлелек. Хәтта битендәге җыерчыклар да бизи кебек тоелды Сиринәгә. Тамак туйдырып өстәл янынннан кузгалуга, көтү кайта башлады. Сиринә белән Нәзир көтү каршысына чыктылар, урамда яңгыр басылган, һава сафланган. Тирә-юньдә үсеп утырган тупыллардан яңа пешкән арыш ипиенеке кебек әчкелтем ис килә. Нәзир кечкенәдән таныш булган шушы тәмле һаваны киерелеп сулап куйды. Сиринәгә ул, үз авылы белән мактанырга теләгәндәй:

– Менә безнең авылның матурлыгына ышандыңмы инде? – диде. – Булачак журналистка өчен монда язар нәрсәләр күп булыр әле. Көтү кайтып, малларны япкач, Ык буена төшәрбез. Табигатьнең иң гүзәл урыны шушы икән дип торырсың.

– Нәзир, сезнең сыерыгыз бармы? – дип сорап куйды Сиринә, урамнан берәм-берәм үтеп китүче сыерларга карап.

– Бар. Авылда хәзер сыерсыз кеше юктыр.

– Карале, Нәзир, әниеңә әйт әле, сыерыгызны мин савыйм, ә?

– Безнең сыер бик усал шул, тибеп очырса нишләр-сең?

– Типмәсен өчен, син аякларыннан тотып торырсың.

– Ярылса, синең маңгай ярылсын, дисеңмени? Менә безнең мөгезбикә үзе дә кайтты. Таныша тор, бик теләсәң, хәзер синнән сыер саудырабыз. Авыл килене була аласыңмы икән? Сынап карыйк.

– Юк, Нәзир, син карап торма. Син карап торгач каушармын.

– Әле генә үзең, аякларыннан тотып тор, дигән идең. Инде, карап торма, дисең. Күземне йомып ничек сыерны тотып торыйм. Тибәргә җыена башласа, күрми калырмын бит.

Яшьләр икесе дә көлешеп алдылар. Ул арада Сәлимә апа да чиләген күтәреп килеп чыкты. Сиринә аның кулындагы чиләгенә үрелде:

– Апа, үзем генә савып карыйм әле. Булдыра алмасам, син өйрәтерсең, яме.

– И балам, аның нәрсәсен өйрәтәсең, имчәген тарткан саен, сөт чыга, шул гына. Теләгән эшне эшли алмаган кеше юк бит ул.

– Казанга бер һөнәргә өйрәнеп кайтып, кызларны кызыктырыйм әле.

Нәзир, Сиринәне оялтмас өчен, ишегалдыннан чыгып китте. Урамда ул бер класста укыган дус егете Вәкилне очратты. Исәнлек-саулык сорашкач, беренче сүз итеп Вәкил:

– Син, малай, кәләш алып кайткансың, ахры? Ишег-алдыгызда мәскәүски кебек ак башлы чибәр нәрсә күренә, – диде.

Нәзир дустының бу сүзләреннән оялып куйды. Ул Сиринәнең исемен кем дә булса искә алса кызара, шул ук вакытта башкалар авызыннан аның турында сөйләттерәсе, күңелгә якын булган исемне кабатлаттырасы килә иде. Бу юлы да ул, бераз тартынып:

– Кәләш үк булып җитә алганы юк әле. Просто үзебезнең авылны күрсәтергә алып кайттым. Шәһәрдә үскән кешегә авыл табигате тансык бит, – дип аклана башлады.

– Авылыбызның табигатеме, әллә егетеме – кайсы ныграк тансыктыр, анысы минем өчен караңгы, – диде Вәкил. Аннары, бераз тын торгач: – Малай, син эшнең кызу вакытына кайттың. Кичә генә печәнгә төштек. Быел печән каерылып уңган, чалгы тыгарлык та түгел. Сиңа да, кәләшеңә дә эш җитәрлек булыр, эшлә генә, – дип сөйләп китте.

– Мин үзем дә печән өстенә өлгерим дип ашыктым, – диде Нәзир. – Печән эшләре тансыклатты.

– Быел мин тракторга печән өйдергеч бер җайланма ясамакчы булган идем, тик, малай, нишләптер барып чыкмый. Газетада сызымнарын да күрсәткәннәр, әмма мин нәрсәнедер төшенеп җитмим бугай. Син мехматта укый торган кеше, аның ише сызымнарны яхшы аңлыйсыңдыр. Икәүләп эшләсәк, берәр файдалы әйбер китереп чыгара алмабызмы? Аның инде эше дә күп калмаган иде. Син минем янга килеп чык әле.

– Кулдан килерлек эш булса карап карармын. Тик минем трактор рычагы тотмаганга да ике ел бит инде.

– Монда куллар түгел, баш кирәк. Куллар минем үземдә дә бар. Син, Нәзир дус, ничек тә вакыт табып килеп чык инде.

– Ярар.

– Хәзергә хуш, малай, мин киттем.

– Хуш.

Нәзир ишегалдына кергәндә, Сиринә белән әнисе сыерны савып бетергәннәр иде.

– Ну, булдырып булдымы соң? – дип сорады Нәзир.

Сиринә урынына әнисе җавап бирде:

– Сыер савып караганым юк, дип, юри генә әйткән икән, куллары ябышып тора. Сыерыбыз башка кешеләрне якын җибәрми иде, Сиринәгә дулап та карамады.

– Чибәр кызларны сыер да ярата шул.

Сәлимә апа, ишегалдында яшьләрнең үзләрен генә калдырып, өйгә кереп китте. Нәзир, малларны абзарга ябып куйгач:

– Әйдә, Сиринә, Ык буена төшәбезме? – диде. – Хәзер суның иң матур чагы.

– Суның да матур чагы буламыни?

– Ник булмасын? Караңгыда чулт-чулт итеп көмеш балыклар сикерешеп куя. Яфраклардан елга өстенә тып-тып тамчы тама. Әйтерсең елганың йөрәге шулай туктаусыз тибеп тора. Су өстендә ак күмәчтәй ай йөзә. Елганың моннан да матур чагын тагын кайчан күрәсең?!

Сиринә Нәзирнең бирелеп һәм үз ягына сокланып сөйләвен элек тә ярата иде. Бүген дә егетнең мавыгып авыл табигатен мактавы ошады аңа. Ул, Нәзирнең рухланудан матурланып киткән йөзенә карап торганнан соң:

– Бу кадәр мактагач, бармый да булмас шул, – диде.

– Әйдә алайса, киттек.

Алар елга буена килеп җиткәндә, чынлап та, караңгы төшкән, су өстен җәйге төннең кара шәле каплаган иде. Яр буенда үсеп утыручы агачлар шөкәтсез карачкылар шикелле куркыныч һәм шомлы булып күренәләр. Кинәт искән җил ул агачларның яфракларын дәррәү генә шаулатып җибәрә, һәм шомлылык тагын да арта төшә кебек.

– Шушы да булдымы матурлык? – диде Сиринә. – Монда бер дә көмеш канатларын ялтыратып балыклар сикерешми, сандугачларың да караңгы төшү белән йоклап беткәннәр.

– Менә син суга озаграк карап тор әле, шунда күрерсең. Әнә бит, әнә, бер балык койрыгын шап итеп суга бәреп куйды, – диде Нәзир.

– Дулкын бит ул. Су өстендәге күбекләр дә сиңа балык булып күренәләр, ахры, – диде Сиринә. Ләкин үзе дә бу төнге матурлыкны күрә, шул серле матурлык тәэсиренә бирелә башлаган иде.

Сиринә белән Нәзир төнге суга карап бераз тын тордылар. Янәшә басып тору аларның икесенә дә рәхәт, икесенең дә күңелләре шушы якынлыкны тоюдан куаныч белән тулган. Әгәр алар шагыйрь булсалар, мәхәббәт турындагы иң җылы шигырьне шушында язарлар, композитор булсалар, иң уңышлы көйләрен шушында тудырырлар иде. Бу минутта аларның йөрәкләре бер хис, бер дәрт белән тибә иде.

– Сиринә, – диде Нәзир, озак кына шулай торганнан соң, – син көймәдә йөрергә яратасыңмы?

– Мин Идел буенда үскән кыз ла.

– Алайса, мин хәзер Нуретдин картның көймәсен алып киләм. Ул ерак түгел, ике генә бакча аркылы.

– Кирәкми, Нәзир, хәзер караңгы. Белмәгән җирдә батуыбыз бар. Мин, гомумән, төнлә суга керергә куркам. Син булмасаң, яр буенда басып торырга да куркыр идем.

Нәзир, Сиринәгә якынрак килеп, аның кечкенә учын үзенең учларына алды һәм сүзсез генә кызның кул аркасын сыйпый башлады.

– Сиринә, – диде ул, ниһаять, бер ят тавыш белән.

– Әү.

– Мин синең белән бик җитди нәрсә турында сөйләшмәкче идем.

– Моңа кадәр юк-барлар турында гына сөйләшә идекмени әле?

– Сиринә, шаярма инде. Үзең дә беләсең бит нәрсә әйтергә теләгәнемне.

– Син генә әүлияга санагач та, мин алай кешенең ни әйтергә уйлавына кадәр белмим.

Сиринә, сүзне шулай шаяруга борса да, Нәзирнең ни әйтергә теләвен сиземли иде. Шуңа күрә ул озак шаярып сөйләшмәде, җитдиләнеп, егетнең сүзләрен тыңларга җы-енды. Ләкин, Сиринә җитдиләнеп киткәнгәме, Нәзир кинәт кенә телен әйләндерә алмас булды. Әллә сүзен сөйли алмый азаплanудан, әллә үзенең шулай көчсезләнеп калу оятыннан, аның маңгаена тир бәреп чыкты. Ул аларны кул аркасы белән генә сыпырып төшерде дә, ни булса булыр дигәндәй, өметсез тавыш белән:

– Язылышыйк без, Сиринә, – диде.

Сиринәнең Нәзир учындагы бармаклары сизелер-сизелмәс кенә калтыранып куйдылар. Ул Нәзирдән кайчан да булса бу сүзләрне ишетәчәген белә иде. Әмма бу хакта үзең сиземләү бер, ә аны яраткан кешең авызыннан ишетү

бөтенләй икенче нәрсә икән. Бу сүзләрнең зурлыгы Сиринәне берничә яшькә үстереп җибәргәндәй итте. Яшен тизлеге белән аның хәтерендә Нәзир белән беренче очрашкан көннәре чагылып үтте.

...Яшенле яңгыр ява. Сиринә, яңгырга чыланудан һәм яшеннән куркып, ашыга-ашыга университетка килә. Шулвакыт бик каты күк күкри. Күкрәүдән шүрләп, Сиринә күзләрен йома һәм университет колоннасына килеп бәрелә. Шунда торучы егетләр, бу хәлне күреп: «Кызны яшен сукты», – дип шаярып, Сиринә янына киләләр. Алар арасында Нәзир дә була. «Яшен кызы, исемең ничек?» – дип сорый ул Сиринәдән. Ләкин кыз алар белән сөйләшеп тормый, үз аудиториясенә кереп китә. Шушы очрашудан соң Нәзир белән Сиринә исәнләшеп йөри башлыйлар, һәм шуннан танышлык, дуслык башлана. Шу-шы көннәрне исенә төшереп, Сиринә елмайды:

– Син, Нәзир, кызык кеше икәнсең. Моннан бер ел элек, әйдә киногa барыйк, дидең. Анысын тыңладым. Аннан кыш буе, җәйгә безгә кайтыйк, безнең Ык буйларын күреп китәрсең, дидең. Бусына да каршы килмәдем. Хәзер инде, язылышыйк, дисең. Монысын да тыңласам, син тагын әллә нинди таләпләр куя башларсың.

– Куймам, Сиринә, куймам. Синнән башка тора алмаганымны беләсең бит.

Кыз да, егет тә беразга сүзсез калдылар. Алар икесе дә бу эшнең никадәр җаваплы икәнлеген яхшы аңлыйлар. Икесе дә бер-берләрен яраталар, һәрхәлдә, үзләренә шулай тоела. Кызга Нәзирнең әнисе дә бик ошады, шулай да җавап бирергә ашыкмады ул. Нәзир, тагын да якынрак килеп, өмет белән янучы кара күзләрен Сиринәгә текәде:

– Чынлап, Сиринә, язылышыйк. Бер-беребезне яратышабыз, тагы ни кирәк, нигә сузарга?

– Эш яратышуда гына түгел бит.

– Тагын нәрсәдә соң?

– Әле бит безнең өч ел укыйсыбыз бар.

– Булса соң! Өйләнешкәч тә укып була.

– Укуын укып та булсын ди. Укып чыккач, мин авылга кайта алмыйм, авылга журналистларның кирәк-мәгънәлеген үзең дә беләсең.

– Укып бетергәч, мин дә авылга кайтмам инде. Авылга мехмат бетергән инженерлар да бик кирәк түгелдер, минемчә. Безнең бабайларның берсенең дә югары белеме булмаган: чәчкәннәр дә, урганнар да. Бабайлар гына түгел, хәзерге председательнең дә җиде генә класс белеме бар.

– Бөтен кеше дә синең кебек фикер йөртсә әйбәт түгел, Нәзир. Син үзең печән өстенә дигән булып ашыктың, тракторда эшләп йөргән чакларым төшләремә кереп йөдәтә, дисең, ә үзеңнең исәбең колхоздан китү икән.

– Дөресен генә әйткәндә, минем бу хакта уйланганым юк иде әле, Сиринә. Син әйткәч, үземә дә уңайсыз булып китте. Ләкин мин авылга кайткан очракта да безнең язмышка бу киртә булырга тиеш түгел, минемчә. Сиңа район газетасында эшләргә мөмкин. Район бездән сигез генә чакрым. Барып кайтырга сәгать саен машина йөреп тора. Мин дә, авылда булмаса, районда эш табармын.

– Анысы шулай...

– Тагын нәрсә соң?

– Әти-әниләргә дә әйтмәгән бит.

– И, эш анда гына булса, хәзер авиапочта белән хат язып җибәрәм. Ике көн дигәндә, үзләре үк килеп җитәрләр. Килештек алайса, Сиринә, яме?

– Безнең әти-әниләр монда хәтле килеп йөри алмаслар шул. Икесе дә эштә бит. Без, Нәзир, бу эшне беразга калдырып торыйк. Казанга кайткач язылышырбыз. Анда минем бөтен туганнар, дуслар. Монда шыпырт кына эшләп куйсак, һәммәсе үпкәләр.

– Казанга китәргә озак бит әле, – диде Нәзир. – Бүген генә аннан кайттык.

– Күпкә түзгәнне, азга түзәрсең, яраткан кешеләр бер-берләрен әллә ничәшәр ел көтәләр.

– Ә мин әнигә вәгъдәләшкәнебезне әйтимме соң? Ул бик кызыксынучан кеше, сорашмый калмас.

– Әгәр сиңа шулай ошый икән, әйт. Кәләшем, диген.

Нәзир, су буен яңгыратып, «кәләшем» дип кычкырып җибәрде. Аның шатлыктан йөрәге рәхәт кенә итеп кысылды, сулыш алырга күкрәге киңәеп киткәндәй булды. Бу минутта ул күкрәгенә бөтен дөньяны сыйдыра алырдай гайрәтле, барлык авырлыкларны җиңәрлек көчле, бернәрсәдән дә курыкмаслык батыр иде. Ул, хискә бирелеп, Сиринәнең дулкынланудан яшьләнгән күзләрен, җиңелчә генә дерелдәгән иреннәрен үбәргә тотынды. Су өстендәге дулкыннар, чулт-чулт итеп, яр читендәге ташларга килеп бәрелделәр. Якындагы тал башында бер кош сайрап җибәрде. Качып торган җиреннән ай килеп чыгып, яшьләрне беренче булып тәбрикләде. Әле генә шомлы булып күренгән яр буе кинәт кенә ямьләнеп, матурланып китте. Яфраклар әкрен генә җилдә лепердәштеләр, гашыйклар серләштеләр. Алар кайтырга чыкканда, таң нурлары елга өстендәге кара төн җәймәсен җыеп йөри иде.

– Иртәгә безгә болынга барырга кирәк, Сиринә, – диде Нәзир. – Син бераз ятып ял ит.

– Иртәгә? – дип кайтарып сорады Сиринә. – Син тагын бер көн әниеңнең күчтәнәчләре белән сыйланып ятмакчы икәнсең.

– Иртәгә түгел, бүген икән инде, – диде Нәзир, алсуланып торган офыкны күреп.

Сиринәләр кайтканда, әнисе сыер савып маташа иде. Ул шыпырт кына өйгә кереп баручы яшьләрне күрмәмешкә салышты.

**III**

Менә ике көн инде Нәзир колхозның ремонт мастерскоенда сабакташы Вәкил белән тракторга печән өйгеч җайланма кору эше белән мәшгуль. Инде аларның эшләре дә төгәлләнеп килә. Председатель дә, көненә берничә тапкыр кереп, аларның эшләре белән кызыксынып, ашыктырып чыгып китә. Бүген дә ул кабаланып мастерскойга килеп керде:

– Ну, егетләр, эшләр тәгәриме?

– Тәгәрәп маташа.

– Тәгәрәсә ярар.

– Ә нәрсә ярамас соң? – дип сорады Вәкил.

– Монда сиңа озаклап кунаклау ярамас, «ДТ» тракторы белән урман ташырга барырсың. Делянка бирделәр.

– Мидхәт «ДТ»сы беләнме?

– Әйе.

– Ә үзенә ни булган?

– Кичә сукыр эчәгесенә операция ясаткан.

– Һмм...

– Һмм шул менә. Ә син, Нәзир, үзең генә бу эшне төгәлли алырсыңмы икән?! Кеше җиткереп булмый, туганкай. Кайту белән сине эшкә җигү шәп түгеллеген дә беләм, тик кеше җитми, кеше.

– Монда башкарып чыкмаслык эш калмаган инде. Печән өйгеч иртәгәдән эшкә әзер. Тик миңа бу машинага утырырга рөхсәт итәрсезме соң? Минем бит «Беларусь» маркалы тракторга таныклык юк. Аннары, трактор йөртеп карамаганга да ике ел.

– Менә тагын иске авыздан яңа сүз. Синең ише егетләрне дә утыртмагач, кемне утыртырга кирәк. Ике ел Казанда укып кына машинаны онытып бетермәгән булсаң, тракторны куш куллап бирәбез. Хәзер бит бездә, үзең беләсең, бер кешене икегә ярырдай чак. Печәнне өя баш-ламыйсың, борчагы шартлап өлгерә, борчакны җыеп бетергәнче, арышка төшә башларга туры килә. Егетләр, алайса килештек.

– Мин килешеп бетмим әле, – диде Вәкил. – Һәр елны мине печән өстендә башка эшкә җибәрәсез дә, бер йөк тә печән әзерли алмый калам.

– Печәннең сиңа чабылганын бирербез.

– Эшкә кушканда, һәрвакыт бирәсез.

– Сыерыңның ачтан үлгәне юк бит, бирербез дигәч бирербез. Урманда делянка биргәндә ташып калмасаң, башка колхозларга бүлә башларлар. Фермаларны ремонтлау өчен агач кирәк, төзелеш бригадасы эшсез ята.

Нәзир, ялгыз гына калгач, тракторын тагын бер кат эшләтеп карады. Ул әйбәт эшли иде. Нәзир аннан бик канәгать булып калды. Җайланмалары уңышлы чыккангамы, аның тизрәк тәвәккәлләп карыйсы килде.

«Ә нигә миңа иртәгәне көтеп торырга? Бүгеннән үк тракторны сынап карарга кирәк. Иң кимендә эскерт янына илтеп куярга. Ят машинага күнеккәнче дә берничә көн үтеп китәр, эш кешесенең эштә булганы яхшы».

Ул тракторына ягулык салды да кырга юнәлде. Колхозның болынлыгы суның аръягында иде. Сай булганлык-тан, елга аша күпер-мазар да салынмаган, кешеләр сай урыннарны гына сайлап чыгалар. Нәзир дә, тәгәрмәч эз-ләрен карый-карый, суга керде. Ләкин, эчкә керү белән, эзләрне югалтты, чөнки агым андый урыннарны тигезләгән иде. Нәзир «Беларусь»ын кай якка юнәлтергә белмичә аптырап калды. Әллә туктап торудан, әллә ләмле урынга эләгүдән, тәгәрмәчләр әкрен генә төпкә бата башладылар, Нәзир каушаудан тракторын кинәт өченче тиз-леккә куеп кузгатып җибәрде. «Беларусь» борынына су кергән ат шикелле пошкырынып куйды һәм туктап калды.

– Менә сиңа мә! – дип куйды Нәзир, сукранып. – Колхоз тракторын суга батырып кайтсам, баштан сыйпамаслар. Ашыккан ашка пешкән шушы буладыр инде. Йә, берәрсен көтсәм ни була иде. Инде нишләргә? Сиңа кирәк чагында берәр машинасы да килеп чыкмый бит аның. Юлда барганда ук тракторны батыргач, миңа ничек итеп аны ышанып тапшырсыннар?

Нәзир өстен-башын чишенеп ташлады да суга төште. Кулындагы көрәге белән ул тәгәрмәч асларын казырга тотынды. Ләкин агымсу китереп өйгән ләмне көрәп кенә алып бетерерлек түгел иде. Нәзир, кире тракторына менеп утырып, моторны кабызып карады, мотор эшли иде. Әмма тәгәрмәчләр үзле балчыкка шактый тирән кереп утырган булып чыктылар. Тәмәке тарта торган кеше дә түгел бит ичмасам. Бер тартып җибәрсә, җиңелрәк булыр иде.

Ул шулай ике сәгатькә якын маташты. Тәмам елар чиккә җитеп нишләргә белми торганда, аның бәхетенә, колхозның йөк машинасы килеп чыкты. Ул печәнчеләрне алырга бара икән. Нәзирнең шәрә килеш трактор тирәсендә кайнашканын күреп:

– Әллә атыңны коендырасыңмы, Нәзир? – дип сорады.

– Баттым, Сабир абзый, юлны онытып җибәргәнмен, ахры.

– Авыл юлларын онытырга ярамый, энекәш. Каяле, ул кәҗәләгән хайванның мөгезеннән шушы аркан белән эләктереп карыйк. Без аны хәзер өстерәп чыгарырбыз. Ну-ка, моторыңны кабыз. Менә шулай, менә шулай. Хәзер әкрен генә артка чигендерик инде. Кузгаламы?

– Кузгала, Сабир абзый.

– Кузгалыр, минем «ЗИС»ның аны тартырлык кына көче бар әле.

– Бик рәхмәт инде, Сабир абзый. Син килеп чыкмаган булсаң, бөтен авыл халкы алдында оятка кала идем. Ярый әле бер кеше дә күрмәде.

– Авылда кеше күрмәгән эш юк ул, энем. Анысы өчен иртә шатланасың. Синең батып ятканыңны миңа Сәпәр малае кайтып әйтте. Балык тотарга барган икән. Шуңар мин печәнчеләрне алырга да иртәрәк чыктым.

Сабирның бу сүзләреннән Нәзир уңайсызланды. Үзенең шулай җебек булуына, кеше ярдәменнән башка кеч-кенә генә саздан да чыга алмавына үртәлде ул.

Ә Сабир аның хәлен сизмәгәндәй сөйләнә бирде:

– Эскертне теге башкорт әрәмәлегенә сала башладылар бугай. Син лутчы тракторыңны туры шунда юнәлт, Нәзир. Эскертчеләр әле анда пыр тузып эшләп яталардыр. Картлар көн сүрелгәчрәк эшләргә яраталар бит.

– Ярар, Сабир абзый, шулай итәрмен.

– Мин, чабучыларны җыйгач, эскертчеләр янына сугылырмын, – диде Сабир. – Бергә кайтырбыз.

– Минем бару да кайту гына булыр, ахры, бүген, – диде Нәзир. – Бер-ике сәнәк нәрсә күтәртеп карармын дигән идем.

– Бик хуп.

Сабир киткәч, Нәзир, тракторына утырып, башкорт әрәмәсе ягына китте. Болынга килеп керү белән, аның борынына чабып ташланган печән исе килеп бәрелде. Егетнең күңеле күтәрелеп китте. Ул, үзе дә сизмәстән:

Кайттым инде, кайттым
Туган ягыма,
Кырларыма, тугайларыма, –

дип җырлап җибәрде.

Туган як! Еракка киткән саен якыная баручы туган як. Имтихан вакытларында син, Нәзирнең уйларына кереп, фикерләрен чуалттың. Йоклаганда, төшләренә кердең. Егет, һәрвакыт сине күңелендә тойганга, үзен көчле сизде. Боек чакларда сине уйлау аның күңелен күтәрде. Шушы туган якларга, тәгәрәп үскән болыннарга әйләнеп кайту шатлыгы аны һәрвакыт җилкендереп, очындырып торды. Нинди матур, нинди киң син, туган як. Болыннарның киңлеге аның күңел офыгын зурайттылар, һавасының сафлыгы хисләрен сафландырдылар кебек.

Нәзир, эскерт янына килеп җиткәнче, күңеле нечкәреп, шушы болыннар, әрәмәләр турында уйлады. Ул килеп җиткәндә, кешеләр, эштән туктап, сәнәк-тырмаларын җы-ештыра башлаганнар иде.

– Бу нинди чикерткә килә дисәк, Нәзир туган, син икәнсең, – дип каршы алдылар аны эскертчеләр.

– Шушымыни инде Вәкилнең атна буе маташкан нәр-сәсе?

– Моның төягече тракторына караганда зуррак күренә, печән күтәргәч кенә арка сөяге сынмас микән?

– Үзе бәләкәй булса да, көче күптер аның, трахтыр кисәге бит.

– Гайрәтен сынамыйча бүген өйләргә кайту юк алайса, – диештеләр колхозчылар. Һәммәсенең бу ят машинаның эшен күрәсе килде.

– Әйдәле, ыстудин иптәш, эшләтеп кара чикерткәңне. Моңа ышанып иртәгә эшкә чыкмый калырга мөмкин микән?

– Син, Габделхак абзый, үзеңә җай эзлисеңмени әле?

– Телеңә салынма, күрше.

Нәзир, печәнчеләрнең кайбер сорауларына җавап кай-тарып, кайберләренә кайтармыйча, кире тракторына менеп утырды. Аның үзенең дә тизрәк эшкә тотынасы килә иде. Ул, авылдашларының сынаулы карашларын тоеп, эшкә кереште. Машина карап торуга бераз иләмсезрәк күренсә дә, колхозчылар аннан канәгать булдылар. Бер ат йөге печәнне ике генә күтәртеп, Нәзир иплəп кенә эс-керткә өя торды. Инде кайтырга дип киенә башлаган печәнчеләр дә, кире өсләрендәге күлмәкләрен салып ташлап, сәнәкләренә ябыштылар. Кайсылары таптады, кайсылары тигезләде, кайсылары төягечкә печән җайлап торды. Караңгы төшеп берни күренми башлагач кына эскертләүдән туктадылар.

– Бу булгач, безнең эше карт-корыларга эш тә калмас, – дип шаяртып алды Минетдин карт.

– Колхозның эше бетеп тормас.

– Менә тиздән борчак чаба башларбыз.

– Борчак чабарга да шушының ише әкәмәт уйлап табарлар әле, – диештеләр картлар.

Эскертчеләр трактор белән мәшәләнеп, үзләре янына чабучыларны һәм җыючыларны төягән машина килеп туктаганны да сизмәделәр. Сабир машинасының сигналын ишеткәч кенә, өйгә кайтырга күптән вакыт икәнлеген чамаладылар.

– Тикмәгә генә акыллы кешеләр машина уйлап тапмаганнар шул, – диде бер агай, «Беларусь»ның төягечен сыйпагандай итеп. – Арыгач, тагын бер көн эшләгән кадәр печән өелде.

Нәзирнең бу хуплау сүзләреннән күңеле күтәрелде. Үзенең кешеләр шатландыра алырлык файдалы эш эшли алуына сөенеп, башкалар утырган машинага менеп утырды ул. Машинадагы хатын-кызлар арасында Сиринә дә бар иде. Алар бүген иртән бер-берләре белән исәнләшергә дә өлгермәделәр. Чөнки Сиринә өйдә Нәзирнең әнисе белән йоклый, ә Нәзир үзе, хатын-кызларга рәхәтләнеп сөйләшергә, ныклабрак танышырга комачауламас өчен, печәнлеккә чыгып ята. Нәзирнең эше якындагы мастерскойда гына булганлыктан, ул печәнчеләрдән чак кына соңрак тора. Ә Сиринә дәртләнеп бөтен кешедән алда тора да, тырмасын алып, бригадага йөгерә. Нәзирне йоклатып калдыру аңа кызык, шул шуклыгы кызның күңеленә рәхәтлек бирә. Әз генә күрешми торсалар да, алар сагыныша башлыйлар. Шуңа күрә кыз тагын да ныграк сагынырга һәм шушы якынлыкны бер дә югалтмаска тели.

Машинадан төшкәч, Нәзир:

– Бик арымадыңмы? – дип, Сиринәнең хәлен сорашты.

– Ух, Нәзир, кулларны күтәреп тә булмый. Болай булса, иртәгә ничек итеп эшләрмен?!

– Ә син бармассың. Син кунак кыз гына бит, беркем дә көчләп эшкә кушмас.

– Син, Нәзир, үзең бөтенләйгә торырга чакырасың, ә үзең һаман мине кунакка санийсың. Минем дә бит синең авылдашларың алдында оятка каласым килми. Яңадан ни йөзем белән авылыгызга килен булып кайтырмын. Әле тәк тә минем бөтен адымымны күзәтеп кенә торалар.

– Анысы шулай. Авылга килгән яңа кешене башта бик нык сыныйлар, тикшерәләр. Әмма мин синең өчен курыкмыйм. Син сыната торганнардан түгел.

– Сынатмассың менә! Бүген кайтыр алдыннан буш тырма күтәрер хәлем дә калмады. Өстәвенә бер Маһирә исемле апа сораштырып теңкәгә тиде.

– Нәрсә сораштыра?

– Нәрсә булсын. Син Нәзирнең хатынымы, ди. Юк, кунакка килдем, дигәнгә ышанмый.

– Ә син аңа хатыны диярләр. Кабат-кабат сорашмас иде.

– Булмаганны ничек әйтим?

– Булыр.

– Булгач әйтермен.

Яшьләр кайтып кергәндә, Сәлимә апа өстәл әзерләгән иде. Сиринә белән Нәзир бер-берләренә су салышып юынып керделәр. Һәм барысы да парларын бөркеп утырган кайнар бәрәңге белән салкын сөт ашарга утырдылар.

– Сездә бәрәңге бигрәк тәмле, Сәлимә апа, яңа гына бакчадан казып алып кергән кебек, – дип, Сиринә мактый-мактый ашады.

– Без җәй көне бәрәңгене карлы базда тотабыз. Кар өстенә салам-солам яки кычыткан җәеп җибәрсәң, менә дигән әйбәт урын була, шиңми дә, өшеми дә, – диде Нәзир. – Казанда үз базың юк шул, ниндине китерсәләр, шуны аласың.

Бәрәңге ашап туйганнан соң, Сәлимә апа чәй әзерләде. Туй була калса дип пешергән чәкчәкләрен дә табынга китереп утыртты, чөнки инде ул туйның ике айдан да иртә булмаячагын белгән иде.

– Ашагыз әле, балалар, ашагыз. Тегендә бик сыйлый алмаганнардыр.

– Төшкелеккә бик тәмле аш пешергәннәр иде, – диде Сиринә. – Үземнең күпме ашаганымны да белми калдым. Тәлинкәдә аш кимегән саен, повар апа китереп өс-тәп тора, һич котылыр хәл юк. Монда күп ашарга өй-рәнеп кайтсам, әниләр шаккатар инде. Нәзберек син, дип тиргиләр иде.

– Кырда пешкән аш тәмле була ул, – диде Нәзир. – Ә мәтрүшкәле чәй авыз иттеңме әле?

– Юк, анда да шундый ук һинд чәе иде.

– Рәхәт күрер чакларың алда икән әле, алай булгач.

Ашап-эчкәч, бераз хәл җыйгач, Нәзирләр клубка киттеләр. Сәлимә апа аларның матур йөрүләренә сөенеп, яратып озатып калды.

**IV**

Камилә фермага эшкә йөрми башлагач, Маһирәнең аңа мөнәсәбәте шактый яхшырды. Кызының катык-сөт саткан акчаларының һәрберсен өшкереп-төкереп, тагын да күбрәк бәрәкәтләр теләп, сандыкка сала барды ул. Сандыкка кергән һәр тәңкә өчен шатланса да, Маһирәнең күңеле тыныч түгел. Аның ничек тә Камиләне Нәзир тирәсендәрәк чуалтасы килә. Кызына акыллы, әйбәт, юаш кияү табып бирүне ул үзенең бурычы дип саный. Шуңа күрә, җай чыккан саен, Нәзир турында сөйләргә тырыша. Менә бүген дә, Камиләнең кәефе әйбәт чакны туры китереп, шул турыда сүз башлады.

– Теге Нәзир апкайткан кыз печәнгә йөри башлады, – диде, нindидер гадәттән тыш вакыйга хәбәр иткән сыман. – Кылларын тарткалап караган идем, без Нәзир белән дуслар гына, дигән була. Әллә атаң-анаң юкмы, нишләп кеше баласына ияреп йөрисең, дигән идем, бар, заводта эшлиләр, ди. Укыган җиреннән практикага җи-бәргәннәрдер аны. Юкса кеше үз ирке белән кайткан көннән үк колхозга эшкә чыгамыни? Шәһәрдә үскән кыз булса да, эшкә маһирлыгы бар.

– Нәрсәгә миңа һаман Нәзирләр турында гына сөйләп торасың? Шуларның исемнәрен дә ишетәсем килми, – диде Камилә, турсаеп.

– Менә тагы, унсигез ел бергә уйнап үскән күршең турында да ишетәсең килмәгәч, сиңа нәрсә генә әйтим икән?

– Әйтмә, берни дә әйтмә.

– Ярар алайса, бик тыңлыйсың килмәсә сөйләмәм. Минем дә телем кычытып тормый.

Маһирә, телем кычытып тормый, дисә дә, озак сөй-ләшми тора алмады. Чөнки әле ул кызына төп сүзен әйтә алмаган иде. Нинди дә булса үзенә файдалы берәр эш кушасы булса, әнисенең һәрвакыт сүзне читләтеп башлавын белгәнгә, Камилә, шикләнеп һәм сагаеп, бу әңгәмәнең ахырын көтте.

– Кызым, сиңа да печәнгә йөрергә кирәк. Эше дә чис-та, әз булса да процентка печәне дә тияр. Юкса курмы әзерләве дә елдан-ел авырая. Быел атаң кыш чыккан тананы да калдырырбыз, дип тора, – диде, ниһаять, Маһирә. – Хәзергә базар юлын туктатып торырга туры килер. Шушы вакытта йокыны ачмасак, кышка кыен булыр.

– Ярар, йөрермен, тик, кеше буш кул белән кайтканда, печән күтәреп кайтмам. Бер тиенлек файдаң юк, дип кычкырынмаслык булсаң гына барам, – диде Камилә, әнисенең тел төбен аңлап.

Иртәгәсен Камилә печәнгә чыкты. Аның инде үзенең дә онытылып, бирелеп эшлисе, өйдәге шау-шулардан бераз тынып торасы килә иде. Бер эшкә тотынса, дөньясын онытып эшли торган гадәте бар аның. Андый вакытларда ул карыны ачуын да, аруын да оныта. Ләкин ялгызлыкны яратканга, мондый вакытлары сирәк була. Кешеләрнең шаярып әйткән сүзләрен ул үзенә төрттереп сөйләү дип аңлап, һәр шаяруга кәефе китә иде. Әмма бүген ул башкалар янындарак булырга теләде, чөнки сыңар күз белән генә булса да теге Казан кызын, аннан да бигрәк Нәзирне күрәсе килде.

Кайчан гына әле бергә уйнап, бергә каз бәбкәләре саклап үскән малай хәзер егет булган. Өйләнергә йөри. Камилә, беркемгә сиздермәсә дә, Нәзирне күңеленнән якын итә, башка егетләрдән артык күрә иде. Бу якынлык озак еллар буе күрше булып яшәүдәнме, Нәзирнең башка егетләрдән тыйнаграк, оялчанрак булуыннанмы, әллә бүтән берәр сәбәптәнме, моны кыз үзе дә белми. Шушы якынлык Камиләне кайчак тирән уйларга сала, тынычлыгын ала. Егетнең Казан тикле зур калада укып йөрүе, үзенең әнисе сүзенә карап укуын ташлавы кызның күңелен кимсетә. Тик мондый уйларга бирелергә яратмый Камилә. Маһирәнең «дөньяның рәхәте бай яшәүдә» дигән логикасы Камиләнең акылын торган саен йоклата бара, кешеләргә көнчелек белән карарга өйрәтә.

Камиләгә эштә Сиринә белән бергә булырга туры килде. Камилә аны сыңар күз белән генә түгел, ә пар күзе белән күрде. «Кыз, чынлап та, төскә матур икән, ләкин соры күзләргә аксыл чәч килешеп бетми кебек. Бәлки, чәчләрен водород перекисы белән буяп йөридер. Бу кадәр дә ак чәч булмас. Билгеле, шулай. Әнә бит төптә бер сантиметрлыгы бераз караrак төстә. Куллары кечкенә, авыр эшкә озак чыдамыйдыр. Барыннан да бигрәк елмаюы

матур. Нәзир кызның нәфисен сайлаган, минем ише чегән арбасыннан төшеп калганны түгел». Ул шулай әнисеннән дә болайрак Сиринәне энә күзеннән үткәрде. Инде аның Нәзирне дә күрәсе, ул гына да түгел, аларның икесен янәшә бастырып карыйсы килде. Әмма Нәзир, эскерт өюдә булганлыктан, алар янына килмәде. Камилә аны бары төшке аш вакытында гына күрә алды.

– Күрше, исәнме! – диде Нәзир.

– Исәнлегемне беләсең килсә, күршедән качып йөрмәс идең.

– Качып йөрмим, вакыт җиткерә алмыйм, Камилә.

– Анысы да мөмкин. Кәләшеңнән бушый алмыйсыңдыр.

Алар башка сүз сөйләшә алмадылар, эскерт куючы агайлар Нәзир янына килеп сузылып яттылар. Камилә дә иптәшләре янына китеп барды.

Көн бик эссе. Агач яфраклары, йомшап, түбән салынганнар. Үлән селкетерлек тә җил исми. Печәнчеләрнең күбесе куак күләгәләренә кереп посканнар, яшьрәкләр генә су буенда мәш киләләр. Су коенучылар арасында Камилә белән Сиринә дә бар. Сиринәнең өстендә тәненә сыланып торучы коену костюмы, ә Камилә эчке күлмәктән. Ул Сиринәнең оста йөзүенә, үзенә рәтләп таныш та булмаган кешеләр арасында берниндн тартынусыз шаяра, уйный белгәненә кызыгып тора. Камиләнең үзенең дә иптәшләре арасында дөньясын онытып шаярасы килә. Ләкин ниндидер бер күзгә күренми торган киртә аны яшьтәшләреннән аера. Нәрсә икәнен ул үзе дә белми, тик башкалар кебек дөньяга ачык чырай белән карый алмый ул. Кечкенәдән үк әнисе һәрбер кешедән шикләнергә, һәркайдан начарлык кына көтеп яшәргә өйрәтте аны. Әле дә хәтерендә: Камилә нәни кызчык вакытта, алачыкка барып, тимерченең кып-кызыл тимердән матур очкыннар чыгаруын карап торырга ярата иде. Шушы очкыннарны җыеп алырга, аларны учларына салып карарга теләп, ул берничә кат кулларын да пешерде. Тимерче аның бу сабыйлыгыннан, беркатлылыгыннан көлеп, «очкыннар җыярсың» дип, кечкенә чиләкләр ясап бирде. Кыз, әллә нинди байлык тапкан шикелле, шатланып өйләренә кайтты.

– Әни, күр әле, тимерче абый миңа нинди матур чиләкләр ясап бирде, мин аңа кып-кызыл очкыннар салып алып кайттым, менә ачып кара әле, – диде.

Әнисе кызның чиләген тотып та карамастан тиргәргә кереште:

– Сиңа кеше тиккә әйбер биргәндер дисеңме әллә? Ул бездән беркөнне акча алып торганые, мөгаен, шуның өчен ясагандыр. Бугазын эттән чәйнәтәсе нәрсә, ансат кына бурычтан котылмакчы була икән...

Әнисе ул көнне тимерчегә тагын күп кенә шундый сүзләр яудырды, ләкин кыз аларны тыңлап тормады. Ул үзен алданган, олылар тарафыннан кимсетелгән итеп тойды. Әкренләп кыз үскән саен, күңелендәге кешеләргә булган ышаныч чиләккә төшкән очкыннар шикелле сүнә барды.

Камилә, Сиринәнең чибәрлегеннән, шат булуыннан көнләшеп, су коенучылар яныннан китте. Әкренләп баш-ка яшьләр дә ярга күтәрелә башладылар. Ул арада биш чиләк сыешлы олы казанда чәй кайнап чыкты. Аш өчен дә, чәй өчен дә бер генә казан булганлыктан, аш ашаганнан соң, печәнчеләргә чәйне көтеп торырга туры килә иде. Шаулашып чәй эчеп алдылар. Чәй эчеп, бераз эчләрне шиңдергәч, һәммәсе үз эшләренә таралдылар. Олы казан янында аш пешерүче апа белән Сарбай гына калды.

**V**

Печәннәр чабылып, чүмәләләргә өелеп бетте. Хәзер инде барлык көчне эскертләргә куярга кирәк. Бригадир чалгычыларны борчак чабарга җибәрде, ә җыючы кызлар эскертчеләргә булышырга тиешләр иде...

Ул көнне иртәдән башлап җил булды, эскерт янына ташыган печәнне көчле җил, сүтеп ташлаган мендәр мамыгын туздыргандай, очырып йөртте. Очлап бетергән, бары тик башына таяклар гына кадыйсы калган кибәннең башын алып ташлады. Нәзирнең дә бүген эшенең рәте булмады, иртән тракторы ватылып никадәр вакытын бушка үткәргән иде, хәзер инде төягеченең печән каерып ала торган сәнәге сынып чыкты.

– Әллә соң бүгенгә маташмыйбызмы? – дип әйтеп куйды бер агай. – Барыбер җилгә он җилгәргән кебек кенә бит.

– Юк, монда бу кадәр печәнне таратып ташлау ярамас, – диде Минедтин карт. – Бу тикмәгә генә җилләмәс, яңгыры булыр. Печәннәрне әрәм иткәнче өяргә кирәк.

– Сәнәкне өскә күтәреп тә булмый бит, алып ыргыта. Менә Нәзирнең дә машинасы самый кирәк чакта ватылды. Аның төягечен җил очырып алып китә алмас иде, – диештеләр печәнчеләр.

– Минем машина ватылмаган да ул, – диде Нәзир. – Менә бу жиренә сәнәк сабы шикеллерәк ике таяк кирәк. Шуларны беркетсәк эшләп булыр.

– Соң, улым, күптән әйтергә идең аны. Менә бит сәнәкләр буш тора, икесенең сабын алабыз да куябыз.

Картлар әйткәнне генә көткәннәр икән, шунда ук сәнәкләренең сабын, алып, Нәзиргә тоттырдылар. Бергәләп керешкәч, Нәзирнең эше тиз бетте, бер-ике сәгать эчендә төягеч әзер булган иде инде. Чабучылар булмаганлыктан, бүген төшкә аш әзерләмәгәннәр, шуңа күрә һәркем үзе алып килгән ризык белән тиз-тиз генә тамак туйдырды да тагын эшкә керештеләр. Ирләрнең гәүдәлерәкләрен, авырракларын өскә менгереп җибәрделәр, кызлар таралган печәннәрне тырмалары белән җыештырып якынгарак китерә тордылар. Кызлар арасында Камилә дә бар, ул бүген көне буе Нәзир тирәсендәрәк булырга, кирәксә-кирәкмәсә дә аңа булышырга йөрде. Сиринә, бераз авы-рып- киткәнлектән, эшкә килмәгән иде, ул булмагангамы, Камилә бүген үзен иркенрәк хис итте: шаярды, көлде, юк кына нәрсәләрдән дә кызык тапты. Нәзир күршесенең болай ачылып китүенә гаҗәпләнеп берничә тапкыр кызның йөзенә текәлеп карап куйды. Аның карашын сизгән Камилә:

– Күрше, әллә мине танымыйсың инде. Өйләнәсең дә карыйсың, өйләнәсең дә карыйсың. Кара аны, миңа бик күз атсаң, Сиринәң көнләшер, – дип, Нәзир белән шаярып та алгалады.

Нәзир аның сүзләренә каршы:

– Бик төягеч астында йөрмә, Камилә, – дип кенә әйтте.

– Төягеч астында түгел, минем тирәмдә йөрмә, диген, шулай булса, дөресрәк булыр. Кешеләр, Казанда укып кайткач, авыл кызларын санга да сукмыйлар.

– Камилә, нигә алай бер дә юкка турсаясың инде? Мин бит сиңа яхшылыкка әйтәм: машина бик үк ышанычлы түгел, әллә ни булуы бар. Аннары, көне дә бик җилле, тормоздан ычкынып китсә, берни дә эшли алмассың. Каплар да куяр.

– Курыкма, берни дә булмас. Безнең ише шайтан таяк-ларына кырау тими. Шәһәр кызлары гына бер-ике көн эшкә чыксалар чирли башлыйлар.

Нәзир, Камиләнең кемгә төрттереп әйткәнен яхшы аңлаганга, сүз озайтып тормады. Ул ниндидер бер үҗәтлек белән машинасына кереп утырды да күп итеп печән күтәртте. Шулвакыт бик каты итеп җил китереп бәрде, тракторның кайсыдыр җире шартлап китте, Нәзир, тигезлекне саклап калыр өчен, тракторны алга кузгатты һәм үзе:

– Бу тирәгә якын килмәгез, күтәрткеч сынды, – дип, бар көченә кычкырып җибәрде. Ләкин җил белән аның тавышы ишетелмәде. Ул арада төягеч бер якка янтаеп өлгерде һәм, якында гына уралып йөрүче Камилә читкә китеп өлгергәнче, бер йөк печән төягән трактор төягече кызның өстенә килеп тә төште. Каушаудан, куркудан Нәзирнең куллары калтыранды, ул тракторның кайсы рычагына тотынырга белмичә озак маташты. Эскертчеләр, аста калган Камилә янына килеп, буталышып йөри башладылар. Кайсы Нәзиргә кычкырды, кайсы Камиләнең аякларыннан тарткаларга маташты.

– Нәзир, нәрсә карап каттың? Тизрәк кыз өстеннән төягечеңне ал, – дип кычкырдылар Нәзиргә.

– Кызны тартып чыгарырга кирәк, харап була бит бала.

– Тартып алырга ярамый, аяк-кулын имгәтүебез бар.

– Ягез әле, тиз генә менә шуны күтәреп алыйк. Син, Нәзир, эреп төшмә, күтәрт кеше үтергечеңне.

Нәзир кемнең нәрсә кычкырганын да, кемнең нәрсә эшләгәнен дә аңламады. Аның күзләре томаланды, башы миңгерәүләнде, чигәләре тартышты. Ул аңлап түгел, автоматик рәвештә генә кеше кушканны үтәде.

Камиләне астан тартып чыгардылар. Аның йөзе бераз күгәргән, бот турыннан күлмәк аркылы кан бәреп чыккан иде. Кыз аңын югалткан, сулышы да ничектер өзек-өзек чыга.

– Ясалма сулыш алдырырга кирәк, тыны беткәндер.

– Кирәкми, ул сулый, больниска җибәрергә кирәк.

– Хәзер генә машинасын каян аласың?

– Машина гына димәгән, ат белән илтергә була.

– Арбага печән түшәп, атка салырга үзен. Нәзир, син мәрткә китмә, арба әзерлә, больниска илтерсең.

– Ах, кызны харап иттең бит, җиләк кебек чакта гарипләнеп калса нишләр, ярый ла үлеп котылса.

Һәркем бу вакыйгага карата үз мөнәсәбәтен, үз карашын әйтергә ашыкты. Берәүләр Нәзирне, икенчеләр Камиләнең үзен гаепләделәр.

– Бүген бик очынып йөргән иде, үз башына җилкенгән икән, диючеләр дә булды.

Кызны печән түшәгән арбага салып, дилбегәне Нәзирнең кулына тоттырдылар:

– Мә, үзең имгәттең, үзең больниска да илт, аннары ата-анасына кереп әйтергә кирәк булыр. Аптырап торулары бар.

Нәзир бернинди каршылыксыз дилбегәне кулына алды һәм атны кузгатты. Селкетеп кызга кыенлык китермәсен өчен, ул атны мөмкин кадәр әкрен алып барырга тырышты. Юлда барганда, Камилә аңына килде һәм сыкранырга,

сызланырга тотынды. Кызның һәрбер сык-равы Нәзирнең йөрәген пычак белән кырып алган кебек авырттырды, сызлатты. Ул, Камиләне ничек тә юатырга теләп, туктаусыз сөйләнде:

– Түз инде, Камилә, түз. Менә хәзер больниска барып җитәрбез. Бару белән укол бирерләр үзеңә, хәлең җиңеләер. Син терелеп чыкканчы, мин һәр көн яныңа килеп йөрермен. Сиңа кыр чәчәкләре китерермен.

Кыз аның сүзләренә җавап кайтармады, шулай да ыңгырашуы бетте. Нәзир Камиләнең тынып калган йөзенә карады һәм ялварулы тавыш белән:

– Күршекәем, үлмә инде, – дип пышылдады. Һаман да Камилә өнсез яткач, ул, ни эшләргә белмичә, атын туктатты һәм кызның агарынып калган йөзенә, авыртудан тирләгән маңгаена кагылды. Әллә аның кагылуыннан, әллә әз генә хәле җиңеләюдән Камилә күзләрен ачты, кипкән иреннәрен ялмап, сабырсызланып Нәзиргә дәште:

– Атыңны куала ичмасам, үләм бит.

Нәзир атын кызулады, ләкин ат кызулаган саен, авыруга кыенлаша барды. Егет, атны үз иркенә куеп, кызны кулларына алды. Болай иткәч, селкенү бераз кимеде, Нәзирнең көчле беләкләрендә йомшак кына тирбәлеп бару авыруны шактый тынычландырды. Ул сыкранмыйча, күзләрен йомган килеш, тын гына барды.

Кызны врачлар кулына тапшыргач та, Нәзир тиз генә өенә кайтып китмәде. Больницаның баскыч төбендә озак кына утырды. Авылга кайтып, Камиләнең әниләренә бу авыр хәбәрне әйтергә батырчылыгы җитмәде аның.

Медсестра, чыгып:

– Өегезгә кайтыгыз инде, караңгы төшә бит, – дип әйткәч тә ул:

– Терелер микән, хәле ничек? – дип сорашырга тотынды.

– Хәле җиңелдән түгел, шулай да терелер дип өметләнергә кирәк, – диде медсестра. – Безнең врач бик әйбәт кеше, оста хирург, аның кулына эләккән кеше терелми калмый.

Медсестра бу сүзләрне Нәзирне юату өчен генә әйтте. Чөнки әле ул Камиләнең нинди хәлдә икәнен үзе дә белми иде. Бары тик кызның әлеге вакытта операция өстәлендә ятканлыгы һәм хирург Әсгать Шакировичның икенче сәгать инде баш та калкытмыйча аның гомере өчен көрәшкәнлеге генә мәгълүм иде.

– Бүген аның янына барыбер кертмиләр, – диде медсестра. – Операциядән соң безнең врач авыруны үзе сак-лап чыга. Ә сез кайтып ял итегез, хәлен белергә иртәгә килерсез.

Нәзир, исерек кеше кебек алпан-тилпән атлап, урамга чыкты. Ул, кая барырга белмичә, үзенең язмышын аяклары иркенә куйды. Аяклары аны кибет янына китереп туктаттылар. Бәхетсезлегенә, кибет ачык иде. Нәзир кесәсеннән өчлек алып, сатучыга сузды һәм, ярты литрлы шешәне кесәсенә тыгып, кибеттән чыкты. Кибеттән чыгуга, кулларына берлек тотып торучы ике кызыл борын очрады аңа. Алар, Нәзирнең кесәсеннән бүлтәеп чыгып торучы яртыга ишарәләп:

– Үтермә, егет, безне. Менә сиңа ике тәңкә акча, ә яртыңны бергәләп сындырыйк, – дип, Нәзиргә иярделәр. Һәм Нәзирнең рөхсәтен дә алмастан, икесе ике ягыннан эләктереп алдылар да бер өй почмагына сөйрәделәр. Нәзир аларга карышмады, киресенчә, ул тегеләрнең кулында стакан күреп сөенгәндәй булды. Аның әз генә вакыт булса да үз кайгысын онытып торасы, аракы томаны белән күңел ярасын тоныкландырасы килде.

**VI**

Нәзирне ул көнне Сиринә белән Сәлимә апа гына түгел, Мөхетдин белән Маһирә дә озак көттеләр. Көтеп-көтеп тә кайтмагач, артык хафаланмыйча йокларга яттылар. Алар кызларының үлем хәлендә икәнлеген белмиләр иде әле. Минетдин карт: кызыгызның аягы кысылды, больницага Нәзир илтә китте, дип кереп әйткәч тә, Камиләнең хәлен бик җитди итеп күз алдына китермәделәр.

Иртәгәсен соң гына торып, Маһирә больницага барырга җыена башлады. Ул кичә генә кайнатып куйган җиләк вареньесын бер банкага тутырды, берничә йомырка пешерде. Базга төшеп, стакан белән каймак та алып менде, ләкин каймакны төенчегеннән кире алып куйды: «Әллә ашый, әллә юк, әрәм булып ятмасын».

– Карт, син тавык-кошларны ашаткала, мин тиз генә кайта алмам. Ерак булмаса да, район җиренә баргач, тиз генә кайтып булмый. Кибетенә дә керәсе килә, базарына да. Аннары Сәлимәләргә дә кереп чык, Нәзир нишләп кайтып та әйтми йөри ул. Баланы имгәттем дә котылдым дип йөрмәсен. Тагын шуны оныткансын: оетырга куйган сөтне караштыр, оеп, өстенә су җыелып утырмасын. Базарга дигән катык.

Маһирә, картына тагын хәтсез генә вак-төяк йомышлар кушып, өеннән чыгып китте. Больницага ул тиз генә килеп җитте, ләкин килгәч кенә озак керә алмый торды.

– Анда обход әле, – диде ишек төбендә торучы няня.

– Обходында-чуртында минем эшем юк, анда минем кызым ята, – диде Маһирә, – тизрәк кертеп җибәр. Кичә дә килеп булмады.

– Шулайдыр да бит, безгә беркемне дә кертмәскә куштылар. Сез әллә кичә китерелгән кызның әнисеме?

– Әйе, кызның хәле ничек икән?

– Авыр бугай, кичә ике сәгать буе операция ясадылар. Сидек куыгы шартлаган. Нәзек җиренә дә зыян килгән, дип тордылар.

Няня, үзенең артыграк ычкындырып ташлаганын сизеп, сөйләвеннән туктады.

Нянының бу сүзләре Маһирәнең өстенә кайнар су койгандай тәэсир итте. Аягы-мазары гына кысылгандыр, дип уйлаганда, мондый көтелмәгән нәрсә килеп чыгу аны каушатып, куркытып җибәрде. Ул мондый күңелсез хәбәр әйтүче няняны кыйнап ташлардай булып ярсыды, ачуыннан калтыранды.

Озакламый обход бетте. Маһирә, нянының өйрәтүе буенча, врач кабинетына рөхсәт сорарга кереп китте. Врач аңа ун-унбиш минутка гына рөхсәт бирде. Маһирә, җилкәсенә ак халат салып, ашыга-ашыга Камилә яткан палатага юнәлде. Ишектән керүгә үк, аның күзенә алты караватчалынды, ләкин караватның кайсында Камилә ятканлыгын тиз генә абайлый алмады. Медсестра күр-сәткәч кенә, ул үзенең кызын таныды.

Камилә түр почмактагы караватта ята. Аның күзләре яртылаш йомык, бите шешенеп, ямьсезләнеп киткән. Аягын, ниндидер бер биек нәрсәгә салып, гер белән тарттырып куйганнар. Маһирә Камиләне бу хәлдә күргәч тетрәп китте һәм кычкырып җибәрде:

– Кызым! – Маһирәнең йөзе үлекнекедәй агарды, иреннәре дер калтырады.

Медсестра йөгереп аның янына килде һәм:

– Апа, менә урындыкка утырыгыз, – дип, Маһирәгә урындык китереп куйды. – Бик борчылмагыз. Ул әле операциядән соң хәлсез, сөйләштерергә дә ярамый.

Артык тәэсирләнүдән, Маһирә медсестра китереп биргән урындыкны таба алмый торды. Ул аны бер этте, бер тартты. Медсестра җилкәсеннән тотып утыртышкач кына, ипләп урнаша алды. Маһирә урындыкка утырып озак кына Камиләнең йөзенә карап торды. Кызының авыр итеп сулыш алуын, газаплы чыраен күр-гәч, Маһирәнең күңелендә кызгану һәм элек кызын рәнҗеткән өчен үкенү тойгылары кузгалып куйды. Ана һәм кыз сүзсез генә карашып тордылар. Маһирә бераздан алып килгән күчтәнәчләрен чыгарып салды.

– Менә сиңа, кызым, җиләк вареньесы белән йомыркалар алып килдем, ашарсың микән? Тамагыңа әйбер кабаласыңмы?

– Тамак кайгысы синдә, – диде Камилә еламсыраган тавыш белән.

– Юк, кызым, алай ашамыйча ятма. Сиңа хәзер ныгырга кирәк. Каныңны күп югалткансың. Төсләрең кит-кән. Менә вареньесыннан булса да авыз итәрсең. Элек бик ярата идең бит. Син яратканга күрә тизрәк өлгертим дидем.

Камилә, куй әле дигәндәй, кулын селкеп куйды. Аның ашарлык түгел, телен кыймылдатырлык та хәле юк иде. Шуңа күрә әнисенең, бик сызланасыңмы, дигән соравына да йөзен генә чытты. Маһирә яңадан үзе дә кызын артык сораулар белән борчымады, бары тик Камиләнең бер тәүлек эчендә үзгәргән йөзенә, герләр белән тарттырып куелган аягына карап уйланып кына утырды. Моңарчы ул ничектер үлем дигән нәрсәнең болай якын булуына, кайчан да булса аның белән йөзгә-йөз очрашасы барлыгына ышанмый иде. Кемнең дә булса авырганын яки үлгәнен ишетсә дә, ишеткән көнне үк оныта һәм мондый нәрсә үзләренең гаиләсенә дә бер килү мөмкинлеген башына китерми. Менә хәзер кинәт кенә Камиләнең дә башкалар шикелле авырырга, авыру гына түгел, үләргә дә мөмкинлегенә төшенгәч, ул тәмам югалып калды. Бу минутта аңарга печән дип, утын дип кайгырып йөрүләр артык вак мәсьәлә булып күренделәр. Маһирә җыйган малның, саклаган байлыкның башкалар кулына калуы, үзенә файдасы тимәү мөмкинлеге барын төшенде. Менә шуларны төшенү аны тетрәндереп, сискәндереп җибәрде. Кызына карата игътибарлырак, кайгыртучанрак булыр-га кирәклеген кисәтте. Шушы ачыш аркасында ул ва-кытның, санаулы минутларның үткәнен сизми дә калды. Медсестра, килеп:

– Сез озак утырдыгыз, авыруны ялыктыруыгыз бар, врач унбиш кенә минутка рөхсәт итте, – дигәч, Маһирә сискәнеп китте. Башка вакытта тиргәп туймаган кызы яныннан бүген чыгып китәсе килмәде.

– Тагын әз генә утырыйм инде, гел-гел килеп йөреп булмый, ерак бит, – дип үтенә башлады ул.

Медсестра:

– Алайса, мин баш врачтан рөхсәт сорап керим, бәлки, сезгә дежурга калырга рөхсәт итәр, – дип чыгып китте.

Маһирә, аның нәрсә әйткәнен дә аңлап җитмәстән:

– Эһе-эһе, – дип калды.

Бераздан медсестра урап керде һәм:

– Врач рөхсәт итте, кызыгыз янында төнгелеккә дә кала аласыз, – диде һәм башка авыруларның йомышларын үти башлады. Маһирә дә кызының мендәрен йомшартып салмакчы булган иде, ләкин, аз гына кагыла башлау белән, Камилә кычкырып җибәрде. Көчле авыртудан аның күзләренә яшьләр килде. Ана, кызын тынычландырырга теләп, кулларыннан, битләреннән сыйпады.

## VII

Бераздан больницага Нәзир килде. Егетнең йөзеннән, авыру кешенеке кебек, кан качкан. Башында дегеткә һәм пычракка манчылган кепка. Ул әле яңа гына айныту йортыннан чыккан һәм юынырга да өлгермәгән иде. Нәзирне больницага кертмәделәр. Теге няня: «Камилә янында әнисе утыра, башка кешеләрне кертмибез», – дигәч, Нәзир артык тарткалашып маташмады, чөнки аның Маһирә белән очрашырга әз генә дә теләге юк иде. Өенә дә ул кыенсынып кына кайтты. Нәзирнең йончыган, пычранган кыяфәтен күргәч, Сәлимә апа, бик борчылып:

– Кайда йөрдең, улым? Без Сиринә белән, төн йокламый, сине көттек. Кеше язмышына шулкадәр битараф карарга ярыймы соң? Кичә Маһирә безгә кереп йөдәтеп бетерде. Сиринә дә синең өчен аһ орып йоклый алмый чыкты, ул эзләргә дип чыгып киткән иде әле, – дип каршылады.

– Әни, мине гафу итегез инде, кичә тәмам дуңгыз булганмын, айныту йортында төн кунып чыктым.

– Шулай башыңны югалтырга ярыймы соң? Кешеләр әллә нинди кайгыларга да сыгылмыйлар. Нык булырга кирәк, кичә автоинспекциядән килеп тикшереп киттеләр, синең праваңны сораганнар иде, мин тапмадым, әллә үзең белән идеме?

– Үзем белән иде шул.

– Сөйләүләренә караганда, син гаепле түгел ди бугай.

– И әни, монда эш гаептә генәмени? Юридик яктан гаепсез булу гына вөҗдан газабын баса алмый шул. Мине гаепләмәсәләр дә, барыбер Вәкилне сөйрәп йөртерләр инде. Аның тракторы, аның уйлап тапкан нәрсәсе бит. Председательгә дә бераз эләкми калмас. Минем «Беларусь» тибындагы тракторларда эшләргә хокукым юк иде. Ул җаваплылыкны үз өстенә алып кына мине утыртты. Берсенең дә ышанычын аклый алмадым, менә шунысы начар.

Сәлимә апа белән Нәзир сөйләшеп торганда, Сиринә дә кайтып керде. Ул да борчулы, күзләрендә нindidер күләгә бар сыман.

– Нихәл, Сиринә? – диде Нәзир. – Мин әни белән сиңа бик зур борчу китердем инде. Бигрәк уйламаган, көтмәгән җирдән килеп чыкты бит бу бәла.

– Монда кемгә ныграк борчу килгәнен белгән юк, Нәзир, – диде Сиринә. – Әнә бит үзеңнең дә ничек төсләрең качкан, атна буе якты дөнья йөзен күрмәгән кешегә охшап калгансың.

Сиринә Нәзирнең таралган чәчләренә, талчыккан, мескенләнгән йөзенә карап торды. Бу минутта, чынлап та, Нәзир кызганыч кыяфәттә иде. Уйламаганда килеп чаккан бу бәхетсезлек кинәт кенә аның рухын сындырды. Көтелмәгәндә купкан давыл йомшак агачны бөккән кебек, бу фаҗига дә Нәзирне бөкте, үзенә булган ышанычын җимерде. Егерме яшькә җиткән кешеләрне ул җитлеккән, үз язмышларын үзләре хәл итә алырлык кешеләр дип саный иде. Менә бу вакыйга аның давылларга әзер түгеллеген, сабыйларча көчсезлеген күрсәтте. Хәзерге вакытта ул үзенең ни эшләргә тиешлеген, нәрсәгә тотынырга кирәклеген дә белмәде. Ярый әле янында Сиринә белән әнисе бар, алар да булмаса, бөтенләй башын югалтыр иде бит. Әнисе аңа:

– Маһирәләргә кереп чыгарга кирәк, аларга бит сиңа караганда да кыенрак, – дигәч, Нәзир:

– Мин кайтышлый больниска сугылган идем, Камиләнең әнисе анда дип, мине кертмәделәр, – диде.

– Камиләнең хәле ничек соң?

– Бик авыр бугай.

– Мин дә больниска барырга җыенып тора идем әле, – диде Сәлимә апа. – Син хәзер өс-башларыңны тәртипкә китер, юын, аша. Болай җебеп төшәргә ярамый. Мөхетдиннәргә кер, йә берәр ярдәм кирәктер. Маһирә дә больниста булгач, авыру кешегә ярдәм артык булмас.

Әнисе әйткәч кенә, Нәзир бүген тамагына берни дә капмаганлыгын хәтерләде. Ул тиз генә юынып, өс-баш-ларын алыштырды.

Ашагач-эчкәч, Нәзир Мөхетдиннәргә керде. Өйдә Мөхетдин агай үзе генә, идән уртасында тавыкларга бәрәңге төеп утыра иде.

– Син дә исән икәнсең әле, – диде ул, Нәзирне күргәч, – кызны имгәтеп ташлагач, әллә башыңны алып качтыңмы дигән идем. Йә, аптырап торма, кергәнсең икән, утыр. Әнә урындык шунда.

– Мөхетдин абый...

– Нәрсә, минем Мөхетдин икәнемне бүген генә бел-деңмени? Мин илле биш ел Мөхетдин инде.

– Мин... Ни... Сезгә берәр ярдәм итә алмаммы дип кергән идем.

– Тавыкларга бәрәңге төеш, булмаса. Ул синең ише тәти егетләр эше түгел инде түгелен. Сынап карыйк әле, ирләр эшен кушарга буламы икән үзеңә? Йә, нигә аптырап калдың? Булышырга кергәч булыш. Менә базда кыртлаган тавык бар, шуны йөздереп кайт. Бәбкәләрне тилгән алмасын, шуларны кара. Үрдәкләрне туендыр. Безнең эш менә шул инде, Нәзир туган.

Мөхетдин әллә Нәзирдән, әллә үзеннән шулай көлде. Нәзир аны төшенеп җитмәде. Шулай да Мөхетдин кушкан эшләрне эшләми чыгып китәргә кыюлыгы җитмәде аның.

– Кая, үрдәкләргә нәрсә ашатыйм?

– Әзерне аны мин дә ашатам. Менә сиңа кәрзин, бакчадан алабута алып кер. Шуны бәрәңгегә кушып болгатырбыз.

Нәзир бәрәңге бакчасыннан алабута орлыклары алып керде, тавыклар ашатты, абзарлар тазартты. Мөхетдин карт аңа юри шуның ише вак-төяк эшләр эшләтте, үгездәй таза егетнең балаларча күндәмлек, тыңлаучанлык белән йөгереп йөрүе аңа кызык тоелды. Моңа кадәр Мөхетдиннең сүзен беркем дә шул ук минутта, болай җиренә җиткереп эшләгәне булмады. Үзенең кемгә дә булса эш кушарга хаклы икәнлегенә, боерык бирерлек тавышы барлыгына ышангангамы, Мөхетдингә күңелле иде. Нәзиргә караганда үзендә өстенлек тою, Нәзирне үз алдында бурычлы итеп санау аңа көч кертеп җибәрде. Моңарчы һәрвакыт хатынына гына буйсынып, гариплеге аркасында кимсенеп яшәгән Мөхетдин кинәт кенә үсеп киткәндәй булды.

Алардан Нәзир кич белән генә чыкты.

## VIII

Маһирә, кызын саклап, өч тәүлек больницада кунды. Камиләнең үлем белән көрәшеп, вакыт-вакыт үзен үзе онытып кычкырып җибәрүләрен тыңлау аның өчен авыр һәм газаплы булды. Ул, кызына үзенең сулышын бирердәй булып, аның баш очында утырды. Кайвакыт шулай утырган килеш кенә йоклап, черем итеп алды. Врачлар никадәр генә кыстасалар да, Маһирәне урынга ятарга мәҗбүр итә алмадылар. Ул, беркемнең дә сүзенә карамыйча, коеп куйган сындай, өч тәүлек буе сүзсез-нисез кызын саклап чыкты. Бервакытта да тик тормаган теле авыз куышлыгында рәхәтләнеп ял итте. Ә дүртенче көнне кризис үтте. Камилә иң авыр көннәрне җиңде. Хәзер инде аның тереләчәгенә чынлап та өметләнергә була иде. Кызы беренче мәртәбә тамагына капкач, Маһирәнең күзләренә яшьләр килде. Ул җиңел сулап җибәрде һәм үзенең дә үлеп ашыйсы килгәнлеген тойды.

– Кызым, мин якын-тирәдәге берәр кибеткә барып киләм, тәмлерәк ризык очратсам алырмын. Синең теләгән нәрсәң юкмы?

– Әни, син кайт инде, әтинең берүзенә кыендыр.

– Бер дә аптырап тормыйдыр әле, чучка урынына эчеп йөридер. Ул бит минем чыгып киткәнне генә көтеп тора. Ә син борчылма, кызым. Күбрәк тамагыңа ашарга тырыш. Ашыйсың килмәсә дә аша, аннан зыян килмәс. Менә кайтсам, яңа аерткан сөт өсте алып килермен үзеңә.

Маһирә ашардайрак әйберләрне тумбочкага, Камиләнең буе җитәрдәйрәк җиргә куйды да кайтып китте.

Өендә ул эшләрен аннан-моннан гына эшләштерде дә Сәлимәләргә йөгерде. Маһирә кергәндә, Нәзир дә, әнисе дә өйдә иделәр. Маһирәнең кыяфәте шулхәтле таушалган, начарланган иде, башка вакытларда аның аһ-зарларына ышанмаган Сәлимә дә бу юлы аны чын күңелдән кызганды.

– Их, күршекәйләрем, кызымның хәлләрен белсәгез иде! Камиләнең аягына аскан герләрен күреп тә һушыңнан язарсың. Ул хәтле хәлгә кыз бала ничек түзсен, – диде Маһирә, күзләрен Нәзиргә текәп. – Ә син шуны кайтып та әйтмәгәнсең. Без Мөхетдин абзаң белән тынычлап ятабыз тагын.

– Ул көнне кайтып булмады шул, Маһирәттәй, – диде Нәзир, йөзен читкә борып. – Иртән больниска барган идем, янында әнисе утыра дип, кертми җибәрделәр.

– Менә үзем өчне кунып кайттым әле, – диде Маһи-рә. – Кызым яныннан бер генә минутка да китеп булмый. Йә тегесе, йә бусы кирәк. Ярый әле бырачлары бик әйбәт кеше икән, гел яныннан да китми.

– Әсгать Шакировичны яхшы кеше диләр шул, – диде Сәлимә, сүзгә кушылмый утыруны яхшысынмыйча. – Аның кулына эләккәч терелер.

– Терелсен иде инде, юкса безнең бер таянычыбыз да юк бит. Дөнья көткәч утыны да, курмысы да кирәк. Баланы үзеңә терәк булсын дип, картайган көнемә ярдәмчем булсын дип үстерәсең, – диде Маһирә. – Имгәнеп

гомер буйларына кеше күзенә карап ятмасын иде. Үземнең дә тазалыгым юк, Мөхетдин абзагыз турында әйтеп тә маташмыйм. Өйдә өченче имгәк тә артса нишләрсең?

– Булмас, Маһирәттәй, – диде Нәзир. – Хәзер медицина көчле, хирургия могҗизалар тудыра, йөрәккә кадәр күчереп утырталар.

– Шулай да бит, Нәзир энем, хәзерге көн турында да кайгыртмый булмый. Ачык авыз ач тормас дигәндәй, барысы да кирәк. Бүгеннән ишегалдыбызда бер кочак утыныбыз, абзарыбызда бер сәнәк печәнебез юк. Камиләм дә болай булып киткәч, без, ике имгәк, нәрсә генә эшли алабыз? Кыз кайчан терелеп чыга әле?

– Кулдан килгән ярдәмне мин дә итәрмен, Маһирәт-тәй, – диде Нәзир. – Сезне утынсыз да, печәнсез дә кал-дырмабыз анысы.

– Синең кебек арысландай егетләрнең кулыннан кил-мәгән эш буламыни? – диде Маһирә, Нәзирнең сүзләренә сөенеп. Чөнки ул үзе дә егеттән нәкъ менә шушы сүзне ишетергә тели иде. Сәлимәләргә керер алдыннан гына карты Мөхетдин белән алар Нәзирне ничек итеп үзләренә эшләтергә, кызлары больницада чагында ничек итеп егет-тән күбрәк файда күреп калырга кирәклек турында сөй-ләшкәннәр иде.

– Нәзир – трахтарис, әйбәтләп куша белсәк, бөтен нәрсәне йөге белән китереп аударыр, – диде Мөхетдин. – Аны хәзер тыңлатып була. Ни кушсаң, шуны үтәргә йөгереп йөри малаең, майлаган кебек. – Мөхетдин үзенең ничек итеп Нәзирне йөгертүен бик тәмләп карчыгына сөйләп бирде. Үзенең өстенлеге турында сөйләү аңа боерык бирү кебек үк рәхәт иде.

– Тыңламый булдыра алмый, койрыгы бозга каткан, – диде Маһирә. – Безгә шул койрыкка ныгракябышырга гына кирәк. Аннары, ул судка бирмәгәйләре дип тә шөлләп йөридер. Ябып куйсалар, уен эш түгел бит. Кемнең өтермәндә ятасы килсен?

– Суд дигәннән, анасы, мин болайрак уйлап торам әле. Андый-мондый эш кузгатырга уйласалар, егетне яклашырга кирәк, мәйтәм, хәзер закун үзебезнең кулда, егет акыллы, бу эше ялгышлык белән булган, дисәк, утыртмаслар.

Маһирә иренең нәрсә әйтергә теләгәнен аңларга тырышты. Үзе ул Нәзирне бераз өркетеп алу ягында. Судка бирәләр икән, әйдә, бирсеннәр. Гаебе булса, җәзасын да күрсен. Нигә аны яклап маташырга? Сәлимәсе идарә активы булып, ялкауларга көн күрсәтмәскә, дип бик кыч-кыра иде. Ул да әзрәк кайгырып карасын.

– Егетне утырту безнең өчен кулай түгел, – дип дәвам итте Мөхетдин. – Патаму што аның утырганыннан файда юк, ә без аны яклап алып калсак, икеләтә шәп булачак. Бердән, кешеләр алдында йөзебез ак була, икенчедән, ул трахтыры белән безгә ни кушсак, шуны ташыячак. Менә эш нәрсәдә, анасы.

– Ярый ла син кушканны тыңласа, – диде Маһирә, Мөхетдиннең бу фикере белән килешеп бетмичә.

– Егетне куркытып түгел, әйбәтләп тыңлатырга кирәк, анасы. Безгә бурычлы икәнен дә онытмасын...

Карты белән булган шушы сөйләшүдән соң кергән иде Маһирә. Нәзирнең үз авызыннан ярдәм сүзен ишеткәч, ул шактый тынычланды. Үзенең дә егеткә яхшылык итәргә җыенуын белгертәсе килде.

– Нәзир энем, булган эш булган инде. Үткән хәзер кире кайтмый. Син судка-фәләнгә бирерләр болар дип куркып йөрмә. Без Мөхетдин абзаң белән сөйләштек: сине обижать иттермәбез. Үзебезнең егет бит. Терәлеп торган күршең белән ачуланышып, ызгышып кеше көлдерер хәлебез юк. Кирәк чакта син дә безне ярдәмеңнән таш-ламассың әле.

Нәзир белән Маһирә сөйләшкән арада, Сәлимә самавырын, шаулатып, өстәлгә утыртты. Ләкин Маһирә, күр-шеләренең кыстауларына да карамастан, чәй эчеп тормады.

– Үзем бульнистә чакта өемнең асты өскә килгән, – диде ул. – Рәткә саласы бар. Юыласы керләрем көтеп тора. Мөхетдин абзагыз да бульниskә барырмын дигән иде, аны да әзерләп җибәрәсем бар. Ул бәләкәй бала кебек бит, бер генә эшнең дә рәтен белми, – дип, Маһирә чыгып китте.

**IX**

Нәзир соңгы вакытларда канаты сынган бәбкә кебек йөри башлады. Инспекциядән килеп, трактор йөртү хокукыннан мәхрүм итеп һәм штраф салып киткәч, ул бөтенләй аптырап калды. Эшкә кулы бармады. Җор теллелеге дә онытылды. Суд тикшерүчесе Нәзирнең гаепсез икәнен исбат иткәннән соң да аның хәле җиңеләймәде. Бары тик янында Сиринәнең булуы гына егетне бераз тынычландыра иде.

Ә Сиринә һәр көн эшкә йөри. Эштән кайткач, кешеләр арасында ишеткән мәзәкләрне, тапкыр сүзләрне үзенең блокнотына язып куя. Ул кешеләр көнделендәге һәрбер матурлыкка соклана, кешеләр эшләгән яхшылыкка балаларча шатлана. Шушы шатлык аның ару-талуларын онyттыра. Эштән кыл кыймылдатырлык та хәле калмыйча

кайтса да, берәрсе клубка дәшсә, анда китә. Менә бүген дә ул клубның стена газетасы өчен мәкалә әзерләп утыра. Аның янына Нәзир килеп, кызның иңнәренә үзенең арыган кулларын сала.

– Их, белсәң иде, Сиринә, миңа ничек авыр икәнлеген. Менә Камиләне имгәткәннән бирле бөтенләй дөньяда торасым килми башлады, – ди ул Сиринәгә.

Ә Сиринә аңа ни әйтсен:

– Беләм, Нәзир, беләм. Ләкин мин нәрсә эшли алам соң? Син юри таптатмаган бит, – дип, Нәзирне юатырга тырыша ул. – Ә син эшкә чык, Нәзир. Кешеләр арасында җиңелрәк була. Беләсеңме мин хәзер кем турында мәкалә язып утырам?

– Юк, белмим.

– Белмәсәң бел, Ибраһим бабай турында язам.

– Теге сиксән яшьлек Ибраһим турындамы?

– Әйе.

– Аны ни дип язасың?

– Их, Нәзир, – дип кызып китә Сиринә. – Син аның нинди кеше икәнлеген белмисең икән әле. Ул бит шул килеш тә бер көн калмый эшкә йөри. Печән чапканда да һәр көн йөргән иде, хәзер борчак чаба. Аның чалгысы үткән җирдән, елап эзләсәң дә, бер утырып калган үлән тапмыйсың. Мин аны башта тормышы җитмәүдән йөри дип уйлый идем. Баксаң, аның бар әйбере дә җитү икән. «Ялгызым өйдә яту авыр миңа, беләкләрем талганчы эш эшләсәм, күңелем күтәрелә, Ходай эштән аермасын», – ди ул.

Нәзир Сиринәнең язган мәкаләсен укый. Ибраһим бабай турында Сиринә белмәгән кайбер нәрсәләр өсти. Яхшы кеше хакында Сиринәнең ялкынланып сөйләве аны бераз тынычландыргандай итә. Ул Сиринәгә иртәгәдән эшкә чыгарга сүз бирә.

Алар икәүләшеп берничә көн борчакка йөрделәр. Си-ринәнең гомергә колхозда эшләп үскән кешеләр көенә эшләп йөрүе, никадәр арыса да сиздермәскә тырышуы Нәзиргә бик ошый. Сиринә көче җитмәстәйрәк итеп күтәрсә, йөгереп килеп җитә дә кызга ярдәмгә ашыга.

– Сиринә, ул кадәр күтәрмә, өзлегерсең.

– Өзлекмәм, Нәзир, менә минем беләкләрем нинди катыланды инде. Укыган вакытта камыр кебек йомшак мускуллар хәзер малайларныкыдай булды. Казанга кайткач, спорт белән шөгыльләнергә кирәк булыр әле.

– Син безгә килгәч ябыгып беттең инде, Сиринә. Танырлык та түгел үзеңне, – ди Нәзир, кызның каралган, тузанланган йөзенә карап.

– Кояшта каралганга шулай күренәмдер, үземә бер дә ябыккан кебек тоелмыйм.

Сиринә үзе белмәсә дә, колхоз эшенә йөри башлагач, бераз тартылып, чандырланып китте. Эшкә чыккан беренче атнада ул гел рәтләп йоклый алмады. Физик эшкә өйрәнмәгән сыек биле, көне буе иелеп печән җыюдан, тәннәре сызлап чыкты. Кысан туфли эчендә озак йөрүдән аяк бармаклары кабарды. Ләкин ул кабарып киткән бармакларын кемгә дә булса күрсәтүдән оялды. Сәлимә апа күреп, төнгелеккә нindидер үләннәр ябып яткырмаган булса, ул чиләнгән аяклары белән озак йөрер иде әле. Хәзер андый көннәр артта калды. Тәнең сау-сәламәт чакта әз-мәз ябыгулар гына күңелне борчыймыни? Киресенчә, тагын да сылуланып киткән ич!

...Беркөнне чабылган борчакларны комбайн сугар өчен җайлап пакуска салып йөргәндә, кырга председатель белән бухгалтер килделәр.

– Иптәшләр, берничә генә минутка машина янына җыелуыгыз сорала, – дип дәште председатель эшләп йөрүче колхозчыларга.

– Менә сезгә борчакта эшләгән биш көнегез өчен хезмәт хакы алып килдек, – диде бухгалтер. – Борчак беткәнче, шулай биш көнләп түләп барачакбыз.

– Монда бик кызык икән, – диде Сиринә, кешеләрнең акча алып киткәннәрен карап. – Эш хакын кырга китереп өләшкәннәрен ишеткәнем дә юк иде әле минем.

– Эшләгән кешеләрне кызыксындыру чарасы бу, сеңлем, – диде бухгалтер Сиринәгә. – Көнгә ике норма үтисең икән, рәхим ит, шул ук көнне икеләтә акчасын ал. Кызык бит. Аннары ялкауларга сабак та ул. Башкалар күрәп алганда, тиенләп алу гарьләндерә кешене. Ә менә, кызым, сиңа күпме акча тия икән. Карап карыйк.

– Миңа нинди акча тисен? – диде Сиринә, оялып.

– Сиңа печәндәге көннәрең өчен дә алып килдем әле мин. Идарәгә килеп алмадың үзең. Каяле, сеңел, алъяпкычыңны тот, учыңа гына сыймаса, шунда салыр-сың, – дип шаярып алды бухгалтер һәм Сиринәгә, өр-яңа өчлекләрне санап, егерме бер сум акча бирде.

Сиринә бу акчаларга бик сөенде. Нәзирнең әнисенә бернинди бүләк алып кайта алмавына борчылып йөри иде ул. Ә Сәлимә апа Сиринәнең үзенә әллә никадәр нәрсә бүләк итте инде. Алмасаң, хәтере кала үзенең.

Эштән кайтып юынып, чистарынып алгач, тиз генә кибеткә китте Сиринә. Авыл кибете шактый бай, сайлап алыр нәрсәләр бар. Кыз үз әнисе яратып бәйли торган төсле кәшемир яулык һәм чигүле чүәкләр алды. Тагын кибеттәге бик күп матур әйберләргә күзе төште аның, ләкин кесәдәге акча ягы такыр булганга, матур әйберләрне күбрәк хезмәт хакы алганга калдырып кайтып китте. Нәзир белән Сәлимә апа да хезмәт хаклары алганнар икән. Һәрберсе, башкаларга күрсәтмичә, күчтәнәчләрен яшерә. Өй эче бәйрәм алдыннан гына була торган ниндидер тантаналы төскә кергән. Дөрес, читтән караганда мондый үзгәреш сизелми, һәрнәрсә элеккеге урынында кебек, бу үзгәрешне бары тик кешеләрнең йөзләреннән, күңелләреннән генә укып була. Сәлимә апа башка вакыттагы сыман, тизрәк ашарга өлгертим дип, мич янында кайнаша. Ул пешерә торган коймаклар табада биешеп утыралар, күрәсең, майлары күбрәк төшкәндер. Ә Нәзир, зур сәхнәгә чыгарга җыенгандай, авыз эченнән нидер кабатлап йөри. Сиринә, кибеттән алып кайткан бүләкләрен ничек тапшырырга белми, тирән уйга төшкән. Менә Сәлимә апаның табыны әзер булды.

– Утырышыгыз, балалар, тамак ялгап алыйк, – диде ул. – Карыннарыгызны ачырдым сезнең.

Өчесе дә өстәл артына килеп утырдылар. Шулвакыт Нәзир торып басты да, Сиринәгә карап:

– Булачак журналистка Сиринә Җаббарованың Ленин юлы колхозына килеп эшли башлавына унбиш көн тулу һәм беренче зарплата алу тантанасын ачык дип бел-дерәм, – диде шаярып һәм өйдәге буш урындыкларга карап куйды. – Иптәш урындыклар һәм башкалар, сез рөхсәт итсәгез, Сиринә Җаббарованы без менә шушы блокнот һәм авторучка белән бүләкләр идек. Бу блокнот безнең авылыбызның яхшы кешеләре турындагы хәбәрләр белән генә тулсын.

Нәзир шаярып сөйләсә дә тирләп чыкты. Уйнап әйтелгән бу сүзләрнең чын күңелдән икәнлеген Сиринә дә, Сәлимә апа да әйбәт аңлыйлар иде. Бу кечкенә генә бүләк барысының да күңелен күтәреп җибәрде. Сиринә дә, уңай вакыттан файдаланып, бүләген Сәлимә апага тапшырды.

– И балалар, сездән миңа бүләк кирәкмени? – диде Сәлимә апа. – Сезнең шушындый матур итеп, ачык чырай белән өемә кайтып керүегез ана өчен иң зур бүләк. Рәхмәт, бәхетегез зур булсын.

Күңелле һәм озак итеп ашап-эчкәч, Нәзир белән Сиринә клубка чыгарга әзерләнә башладылар. Нәзирнең соңгы вакытларда болай чын күңелдән ачылып көлгәне юк иде. Егетнең кәефе әйбәт булгач, ана да, Сиринә дә бик куандылар. Сиринә үзенең иң матур күлмәген киде. Көзге каршысына килеп, әз генә көязләнеп тә алды. Үзенә Нәзирнең яратып һәм сокланып карап торуын сизү кызга әйтеп бетергесез рәхәт. Ул кырда эшләгән вакытта да, арып йокларга ятканда да шушы карашны тоя. Кулын да кыймылдата алмаслык булып арыганда, шушы караш аңа көч кертеп җибәрә. Шушы караш Казанны сагыну, әти-әниләрен сагыну тойгысын ераккарак яшерергә ярдәм итә.

Бер-берләре белән янәшә атлау шатлыгыннан куанып клубка барганда, аларга Маһирә очрады. Нәзирне Сиринә белән бергә күргәч, аның төсләре бозылды. Ул үзенең ачуын яшерергә дә тырышмады:

– Баланы гариплəндереп ташладың да хәзер авыз ерып гүләйт итеп йөрибезме? Камилә анда ут йотып ята, син шуның янына да бармыйсың.

– Бардым бит, Маһирәттәй. Әле бүген иртән генә барып кайттым.

– Иртән дә бар, кичтән дә бар. Авыру кеше ярдәмнән туймый ул. Күтәреп әзрәк һавага алып чыккала, йөзләре саргаеп беткән мескенкәйнең. Аның бит аягы гына түгел, күңеле дә сынык. Син, тәти егет, менә шул күңелне төзәт. Болай шәһәрнең тузгакбашлары белән йөрү рәхәттер дә бит, син екканга кыз елап яткач рәхәт түгел.

Маһирә шулай диде дә, кырт борылып, өйләренә кереп китте. Нәзирнең дә, Сиринәнең дә кәефләре бозылды. Алар бу хәлгә үзләре гаепле сыман, бер-берләренә күтәрелеп карарга да базмыйча, юлларын дәвам иттер-деләр.

## X

Маһирә кызы авыр вакытта дөнья мәшәкатьләрен онытып торган иде, ләкин Камилә бераз рәтләнә башлагач, тагын үзенең элекке сукмагына төште. Иртән тор-ды да шәһәргә сөтен сатарга чапты, аннан кайтты да печәнгә китте. Камилә янына барулар да сирәгәйде. Маһирә больницага картын яки Нәзирне җибәрергә тырышты. Ләкин Маһирә өчен Нәзирне больницага җибәрү бер яктан файдалы булса, икенче яктан зарарлы иде. Чөнки ул тыңлаучан егеттән быел күп кенә итеп печән әзерләтеп, сыеры янына кыш чыккан танасын да калдырырга исәпли иде. Шуңа күрә Нәзирне урамда күрде исә йә берәр төртмә сүз әйтеп китә, йә өенә чакырып зарланырга, мескенләнергә тотына:

– Дөньяны бик кыенлык белән көтәбез, энем, ирләр урынына да, хатыннар урынына да үзем чабам. Элек, ичмасам, Камиләм бөтен эшемә йөгереп тора иде, ул булмагач, канатым сынды. Менә быел кышка тананы калдырырга уйлаган идек, киләсе елга, шуны сатып, өйне сипләтергә иде исәп. Тик исәп белән хисап туры килеп бетми икән. Болай булып киткәч, сыерны да суярга туры килмәгәе.

Нәзир Маһирәнең һәр сүзенә ышанып бетмәсә дә, үзен бу хатын алдында гаепле санаганга, кулыннан килгән ярдәмне күрсәтергә тырыша.

– Аның өчен генә сыер суймассың инде, – ди ул. – Эштән кайткач көн саен бер бәләкәй арба печән алып кайтсам да, укырга киткәнче сыерыгызны кышлатырлык корма җыеп булыр.

– Казан тикле каланың үзендә укып йөргән ыстудин егеткә бәләкәй арба белән печән тарту килешәме соң? – дип каршы төшә Маһирә. – Әниең әктив, үзең кайткан саен умырып эшләп китәсең. Андый егеткә атын да, машинасын да бирерләр. Бирмәсәләр, синең үз трахтырың да бар. Төяп маташасы да юк, теләсә каян чумырасың да аласың.

– Минем трактор йөртү таныклыгымны алдылар шул. Ике айсыз бирмәячәкләр.

Маһирәгә егетнең бу сүзләре бик нык тәэсир итә. Ул бит Нәзирнең тракторына ышанып, бер яшерен чокырга күпме печән әзерләп куйган иде. Хәзер аны бәләкәй арба белән ташырга калса, бөтен кеше күрәчәк. Ул хәтле нәрсәне төнлә генә барып алып кайтып булмый шул. Аннары тикшерә башларлар.

Эшнең болай торганын белгәч, Маһирә тагын зарлана башлый. Бу юлы инде ул Нәзирнең иң авырткан җиренә, Камиләнең гариплегенә кагыла.

– Гарип калса, гомер буе бәхетсез булыр инде, рәтле кияү дә табылмас. Сау-сәламәт кешеләр дә утырып калгалый бит.

– Калмас, Камилә начар кыз түгел.

– Бульнистә ятып бозылып бетмәсә ярый. Медсестралар да зарланып торды әле үзеннән, теге йоклата торган даруны сорап җаннарына тия икән. Бик нервынныйланып китмәгәе дип куркам.

– Мин андый-мондый үзгәреш сизмәдем, – дип, Маһирәне тынычландырмакчы була Нәзир.

– И күрше, син барганда алай итәме соң? Ул бит сине әллә кем урынына күрә. Әйтсәм әйтим инде, ул синең Казаннан язган хатларыңны баш очында гына тота. Бульнискә дә соратып җибәргән әле, илтергә генә онытып йөрим.

– Син, Маһирәттәй, бигрәк арттырасың инде. Мин аңа берме, икеме генә хат яздым. Анда баш очында тотып, дога урынына укырлык сүзләр юк.

– Чәчрәп китим ялганласам. Йөргән егетем бар дип, никадәр яучыларны борып җибәрде. Юкса йөдәтеп бетерәләр. Имгәнер алдыннанрак Кара яр авылыннан бер егет килеп аякларына егылып елады, әмма Камилә күтәрелеп тә карамады. «Менә сөйгән егетемнең хатлары», – дип, синең хатларыңны борын төбенә генә китереп селекте.

– Минем хатлар булмагандыр алар.

– Мине юләргә санама, күрше. Минем дә яшь чакларым бар иде. Андый хәлләр башымнан үткән. Әллә син мине туганда ук кырык алты яшьлек булып, шушылай Мөхетдин хатыны булып тугандыр дип беләсеңме? Минем дә кура җиләге кебек матур, кыр кәҗәседәй җитез, сикергәләп торган чакларым бар иде. Гыйшык-мыйшык хәлләрен беләм мин.

Маһирәнең бу сүзләреннән соң Нәзир аның йөзенә карый. Ике катлы булып асылынып төшкән ияк, бот юанлыгындагы беләкләр, салмак кына селкенеп йөри торган авыр гәүдә Маһирәнең сүзләреннән соң ничек-тер көлке булып күренә. Маһирә өзелгән сүзен дәвам итә:

– Син, Нәзир, бу Маһирәттәй берни дә сизми йөри икән дип уйлама. Безнең Камилә юк-бар хатларны гына алай сакламас. Син өйләнеп кайта дигән сүзләрне ишеткәч, бичаракаем, кая керер урын тапмый йөрде. Их, әни, бигрәк яратам бит шул Нәзирне, ди. Шуның томрап торган күзләре, энҗедәй тезелеп киткән тешләре, дулкын-дулкын чәчләре төшләремә кереп саташтыра, ди, балакаем.

Нәзир, үзенең портретын болай тасвирлап бирүчене күргәне булмаганга, елмаеп куя. Гәүдәсенең тап-таза, сылу булуына ул кыенсынып кызара.

– Юкны сөйләмә инде, Маһирәттәй, – ди ул, тар-тынып.

– Нишләп юк булсын, барны сөйлим. Синең хатларың килмиме дип почтальонны күрсә, тиле шикелле каршысына йөгереп чыга. Синең шәһәрдән сары чәчле нәмәрсә алып кайтасыңны белгәч, көн-төн елады.

Нәзир Сиринәгә кагылган бу сүзләргә хәтере калып йөзен җыера һәм чыгып китәргә җыена. Аның кузгалуын күргәч, Маһирә тизрәк үзенең йомышын әйтергә ашыга:

– Күрше, сиңа әйтәсе сүз бар иде, тик әйтергә кыенсынам.

Ул, чынлап та кыенсынгандай, алъяпкыч итәген бөтергәли.

– Нәрсә? Әйт, Маһирәттәй.

– Иртәгә бригадирдан ат сорап тора алмассыңмы? Өченчекөн биргәндә, башка ат сорап килмә, дип кисәтеп куйды.

– Нәрсәгә ул ат?

– Бер-ике көлтә печән урып куйган идем. Озак тотсаң алып китүләре бар, хәзер кешегә ышаныч юк.

– Бер-ике көлтә өчен ат җәфалап йөрткәнче, күбрәк булгач барып алырбыз. Аннары, миңа ат та бирмәсләр, кеше өчен ничек бирсеннәр.

– Сиңа да бирмәгәч, кемгә бирсеннәр. Минем өчен дип сорамассың. Безне болай да күралмыйлар.

– Бирсәләр сорап карармын.

– Берүк шулай итә күр, юкса сыерсыз калабыз. Безнең бөтен карап торган нәрсә шул, аннан да язсак, бөтенләй аяк сузарга гына кала.

Иртәгесен Нәзир, бригадирдан ат алып, Маһирәнең печәнен кайтарып куйды. Бер-ике көлтә дигән нәрсәсе ике тапкыр ат тартымына төярлек булып чыкты.

## XI

Нәзир, больницага барган саен, Камиләнең кәефсез чагына туры килә. Нишләптер аның холкы көннән-көн бозыла бара. Ул, әз генә сызланса да, врачлардан, медсестралардан морфий сорый, бирмәсәләр, кычкырып еларга, елап кына да җиңә алмаса, дуларга тотына. Палатадагы иптәшләренә дә тынгылык бирми, минут саен кашыгы белән алюмин кружкасын кага. Медсестраларны, няняларны эт итеп сүгә. Керткән ашларын ашамыйча борып чыгара да тагын берничә минуттан сорап тинтерәтә башлый. Врачлар Камиләне больницадан куу белән дә куркытып карадылар, тик файдасы булмады. Нәзир мондый үзгәрешкә бик борчылды. Кызны нәрсә белән тынычландырырга белми аптырады. Ул, Камиләнең палатасында радио югын белгәч, кечкенә радиоалгыч алып, больницага илтте.

– Менә, Камилә, эчең пошканда, концертлар тыңларсың, – диде егет, бүләген кызга сузып.

– Синең уенчыгың нигә кирәк миңа? Мин бала-чагамыни? – диде Камилә. – Миңа сәламәтлек кирәк, сәламәтлек. Сынган аягым кыска булып ялганса, минем кемгә кирәгем кала? Аяк кына булса тагын бер хәл иде, аның башка ягы да бар бит...

– Мин нишләтим, Камилә? – диде Нәзир, ачынып. – Минем кулда булса, үземнең бөтен сәламәтлегемне бирер идем, кулдан килә торган эш түгел. Әнә синнән өлкәннәр дә сабыр гына ята, терелерсең әле, ул кадәр хафаланма.

– Алар кебек булсам, мин дә сабыр булыр идем. Ә миңа нибарысы егерме бер яшь. Алар дөньяның матурлыгын картайганчы күргәннәр, тормыш рәхәтен татыганнар. Аларга монда яту берни түгел. Мин гомеремне башлап кына җибәргән кеше, минем дә синең кебек тәти киенеп, үз ишләрем белән шырт-шырт басып рәхәтләнеп йөрисем килә. Җәй буе шушы базда тончыгып яту бик күңелле дип беләсеңме әллә?

– Син, Камилә сеңлем, дөнья күрмәгәнсең әле, – диде кырыйда ятучы әби. – Кеше авырмый тормый, бер ай больниста ятканга шулкадәр кыбырсырга ярамый. Әле синең терелүгә таба, Алла бирсә, бер йөреп китәрсең. Ә менә аяк очыңдагы апаң икенче елын ята, шулай да бу кадәрле сабырсызланмый бит. Әллә ул апаңның син әйткәнчә шырт-шырт басып йөрисе килми дип беләсеңме? Алай уйласаң, бик ялгышасың, Камилә. Бәндәләр бервакытта да җирдә йөрүдән, җир һавасы сулаудан туймыйлар. Кеше җирнең астында ятар өчен түгел, өстендә йөрер өчен туган.

Ләкин Камиләне мондый сүзләр белән генә тынычландыру кыен. Ул үзенең гипслы аягына карый да еларга тотына. Кечкенәдән үк әтисенең хәлен, сансыз тормышын күреп үскәнгә күрә, гарип калу турында уйларга да курка. Әз генә физик кимчелек тә гомер буе аның тормышына кара тап булачак. Нәзир аның кичерешләрен әйбәт аңлый.

– Камилә, тышка алып чыгыйммы үзеңне? – диде Нәзир, Камиләнең кәефен күтәрергә теләп. – Мин Әс-гать Шакировичтан сорадым. Иплән кенә алып чыксаң, рөхсәт, диде.

– Кая инде бу потлы гипсларны өстерәп чыгу, – диде Камилә өметсез тавыш белән. Ләкин үзенең саф һавага чыгасы килүе күзләреннән үк күренә иде.

– Ә бу куллар ни өчен соң? – диде Нәзир. – Синең кебек кызларны да күтәрмәгәч, икмәк чеgünтеп, егет булып йөрисе дә юк. Кил әле, иплән кенә чыгарыйм, чирәмдә ятып торырсың.

Нәзир Камиләне өстенә япкан одеалы белән бергә күтәреп алды да ишегалдына алып чыгып китте. Тышка чыгу белән, кыз әчке бер дулкынланудан башы әйләнеп, каты итеп егетнең муеныннан кысты. Бала чактан ук бер балчыкта уйнап үскән һәм күңелгә шул елларның матур истәлеге булып кереп калган егетнең дөп-дөп типкән йөрәк тавышын ишеткәндәй булды ул. Шушы йөрәк тавышы Камиләне әллә нишләтеп җибәрде. Ул үзенең авыру икәнен дә онытты. Аның әле гомерендә бер мәртәбә дә егет затын кочаклаганы, аларның сулышын тоярлык дәрәҗәдә якын булганы юк иде. Камиләгә бу сулышны тою, шушы йөрәк тавышын ишетү рәхәт тә, бераз куркыныч та иде.

Аны Нәзир ишегалдының иң матур җиренә илтеп куйды. Ә үзе, кыз ялгыш егылмасын өчен, куллары белән тотып торды.

– Әллә озак һавада булмаудан, кинәт кенә төсең китте, Камилә, – диде Нәзир, кызның агарган йөзенә карап.

– Шулайдыр, – диде Камилә, үзенең дулкынлануын сиздермәскә теләп. – Үтә ул, син борчылма, Нәзир.

– Ешрак чыгарга кирәк сиңа, Камилә. Моннан соң мин сине һәр көнне алып чыгармын. Тиздән гипсыңны да алырлар. Җилкәңнән тау төшкәндәй булыр.

– Гипсны алсалар да, мин элекке кебек чабып йөрерлек булмам инде, Нәзир. Шушы ай ярым вакыт эчендә мин йөрүне онытып барам бугай. Ничектер кабат аякка басарыма күңелем ышанмый.

– Шулхәтле төшенкелеккә бирелергә ярыймы соң, Камилә. Безнең бит бөтен тормышыбыз алда. Бу тәпиләр әле сине тагын йөз ел буе төрле юллардан атлатырлар. Сынып ялганган сөяк тагын да ныграк була икән дип ишеткәнем бар минем. Бу сүзләр, бәлки, дөрестер дә. Утта янгач, тимер дә ныгый бит. Һәрхәлдә, кеше авырлыкны бер татыганнан соң чыдамрак була.

– Син мине чыныктырыр өчен шулай иттеңмени? – диде Камилә, шаярып. Ләкин уйнап әйтелгән сүз усал, төрттереп әйтелгән кебек килеп чыкты. Баягы күңеллелек югалды. Шуннан соң әңгәмә ялганып китә алмады. Нәзир үзе алып килгән радиоалгычтан концерт тотты. Икәүләп тавышсыз-тынсыз гына концерт тыңладылар. Аннары Камилә: – Мине кертеп куй инде, Нәзир, туңа башладым, – диде.

– Чынлап та бераз салкынайтты шул, – диде Нәзир дә. Һәм Камиләне палаталарына кертте.

## XII

Сиринәне ындыр табагына икмәк үлчәргә куйдылар. Ул көне буе эшләп арып кайта да тизрәк урыннарын җәеп йокларга ашыга. Ләкин көне буе эт булып арыса да, йокыга китә алмыйча озак азаплана ул. Нәзирнең үзенә карата суына баруы, берәр сүз әйтсәң, гаепле кебек күзләрен яшерүе борчый кызны. Егетнең күңелендә нәрсә дә булса бар. Кайчан гына әле шушы күзләр аңа карап сокланып туя алмыйлар иде. Ә хәзер Сиринәгә караса да яшеренебрәк карый Нәзир. Ни булган аңа? Камилә язмышы шулай борчыймы, әллә башка берәр сәбәп бармы? Клубка да чыкмый. Больницага барып кайткан көнне бигрәк тә уйга бата. Камиләнең хәле яхшыруга таба бара шикелле. Камилә рәтләнә барган саен, Нәзир ныграк хафалана. Тукта, тукта, монда нинди дә булса бәйләнеш бар түгелме?

Сиринә беркөнне уйларын Нәзир белән уртаклашырга булды:

– Нәзир!

– Нәрсә, Сиринә?

– Син нәрсәдер миннән яшерә башладың. Безнең өйдә элекке төсле шатлык бетеп бара. Хәзер өчебез өч яктан кайтабыз да, ачуланышкан кешеләр шикелле, эн-дәшми-нитми йокларга ятабыз. Хәтереңдәме, бервакыт Сәлимә апа нәрсә диде? Сезнең елмаеп кайтып керүегез иң зур бүләк, дигән иде ул. Без аны менә шушы бүләктән мәхрүм итәбез.

– Бернинди дә яшерен серем юк минем, – ди Нәзир. – Әни белән сиңа шатлык китерә алмавыма үзем дә борчылам. Ләкин үзе аһ орып йөргән кеше башкаларга шатлык китерә аламыни? Камилә шундый хәлдә ятканда ничек шатланыйм?

– Камилә бит хәзер терелеп килә. Озакламый больнистан да чыгар. Син кулыңнан килгән ярдәмне күрсәттең инде.

– Ничек терелүен белгән юк әле, – диде Нәзир. – Мин врачлар белән сөйләшкән идем, сынган аягы бераз кыскарак булып калу куркынычы бар икән. Әгәр Камилә риза булса, таза аягыннан сөяк алып ялгыйсы булганнар, тик, бу аягымнан да язасым юк, дип, ул ризалашмаган. Хәзер инде аягы кыска булып калса, протез заводында эшләнгән ботинка киеп йөриячәк. Тиздән гипсын алалар, шунда бар да билгеле булыр инде.

– Кыз кеше өчен аяк аксак булу да зур кимчелек шул, – диде Сиринә.

– Их, Сиринә, – диде Нәзир, ачынып, – аягы гына алай булса тагын бер хәл иде. Аның бит башка җиренә дә операция ясалган.

Нәзир кызның «нәзек җиренә» димәкче иде. Сиринә алдында үз лексикасына ят булган сүзне әйтергә оялды. Ләкин Сиринә, Нәзир әйтмәсә дә, Камиләнең хәлең яхшы белә иде. Авылның бит авызын текмәгән: сүз анда тиз тарала. Камиләгә операция ясалган көнне үк инде: хәзер Камиләгә тормышка чыгарга ярамый икән, бала таба-нитә калса үләчәк икән, дигән хәбәрләр таралган иде. Яхшы хәбәр ялган булса да, начар хәбәр ялган булмый. Билгесез кешеләр авызыннан таралган бу сүзләрдә дә дөреслек бар иде.

– Син нәрсә эшләргә уйлыйсың соң? – дип сорады Сиринә.

– Камилә үзенең киләчәк тормышын берничек итеп тә күз алдына китәрә алмый, – диде Нәзир, Сиринәнең соравына каршы туры җавап бирмичә. Нәрсә эшләргә кирәклеген ачык кына итеп ул әле үзе дә күз алдына китерми иде. – Аны бернәрсә белән дә сөендереп булмый, – дип дәвам итте ул. – Кечкенә вакытта да шулай иде, хәзер бигрәк тә үз эченә йомылган. Гомумән, ул кешеләргә ышанмый. Күңелендә кешеләргә ышаныч тумыйча, башкаларның аңарга яхшылык эшләргә теләүләрен аңламыйча, кызның киләчәккә өмете булмаячак. Өметсез кеше – канатсыз кош, дигәннәр. Кызда кешеләргә ышаныч уятырга кирәк. Сынык рухны төзәтү сынган аякны төзәтүдән авыррак. Аны гипслап куеп булмый, аңа башка чара кирәк. Менә шул чараны табып булмый, Сиринә.

Нәзир «шул чараны табып булмый» дисә дә, Сиринә аның бер нияткә килгәнлеген сиземли. Бернинди карарга килмәсә, Сиринә белән сөйләшүдән качып, ул йокларга яткач кына кайтып йөрмәс иде. Димәк, Нәзир...

Ах, бу турыда уйлыйсы да килмәде Сиринәнең. Сөю газабыннан да ачырак газап бар микән дөньяда? Мәхәббәт үзенең канатларында кешене биеккә күтәрә-күтәрә дә кинәт кенә түбәнгә ыргыта. Биеккә күтәрелгән, бәхетең ташып торган чакта икәү буласың, ә канатларың сынып упкынга очканда ялгыз каласың. Менә шушы ялгызлык кечкенә генә кыенлыкларны да тау кадәр зурайта, горур башларны түбән идерә. Сиринә дә аерылышу ачысын татыр микәнни? Ичмасам, Нәзирне гаепләп, аңарга үпкәли алсын иде. Юк бит. Күңеле белән Нәзирнең хак-лы икәнен тоя торып аны ничек битәрлисең дә аңа ничек ачуланасың?

Әмма акылы белән егетнең изге ниятгә икәнен белсә дә, йөрәге үз мәхәббәтен югалтасы килми.

– Әйдә, Нәзир Камиләгә өйләнсен, – ди акыл. – Бу фаҗигагә егет үзе сәбәпче булды. Кызның язмышы хәзер аның кулында.

– Юк, берәүләрнең бәхете икенчеләрнең бәхетсезлегенә корылмаска тиеш, – ди йөрәк. – Мәхәббәт тә гомер төсле кешегә бер генә тапкыр бирелә. Аны югалтмаска, күз карасы кебек сакларга кирәк.

– Синең теләсә нинди егет карарлык чибәрлегең, аек акылың, бернәрсә белән дә тапланмаган саф йөрәгең бар, сиңа бәхетне табу җиңелрәк, – ди акыл.

– Йөземдәге чибәрлегем дә, күңелемнең сафлыгы- да, җор сүзләргә бай телем дә – барысы да янымда мәхәббәтем булганга иде. Аерылышу газабыннан йөземдә шатлык сүнәр, телем шаян сүзләрне онытыр, күзләремне кайгы сөреме каплар, – ди йөрәк.

– Син сөйгәнче дә шулай матур идең, матурлыгыңны берни дә тартып ала алмас. Кайгыларыңны еллар әк-ренләп оныттырырлар, хисләреңне тормыш җилләре суытырлар. Тормыш зур доктор ул, – ди акыл.

– Юк, мәхәббәтем онытырлык, хисләрем сүрелерлек түгел, – ди йөрәк.

– Мәхәббәт кешенең бердәнбер шатлыгы түгел, дөньяда хезмәт шатлыгы да бар. Синең башыңда – белемең, кулыңда һөнәрең бар, син зур юллар чатында торасың, – ди акыл.

– Эш кенә күңел бушлыгын тутыра алмый, шәхси тормышта бәхетсез кешеләр эшләрен дә әйбәт башкармый, – ди йөрәк.

– Ялгышасың, – ди акыл. – Киресенчә, кеше үз бәхетен хезмәттә тапмый торып, шәхси бәхет таба алмый, эштә туган шатлыкны синнән бер кеше дә тартып ала алмый. Чөнки ул синең үзеңнеке. Ул аерым кешеләрнең капризларына бәйләнмәгән.

Акыл һәм йөрәк шулай тартыштылар. Кайсы җиңде? Кайсы җиңелде? Әйтүе кыен. Һәр икесе үзен хаклы санады. Шушы каршылыклар арасында берничә көн адашып йөргәннән соң, Сиринә Казанга кайтырга булды.

Нәзир дә, Сәлимә апа да өйдә көн иде.

– Мин өйгә кайтам инде, – диде Сиринә. – Әти-әниләрне дә бик сагындым. Укулар башланырга да күп калмады.

– Нинди кайту ди ул? – диде берни белмәгән Сәлимә апа. – Нәзир белән бергә-бергә кайтырсыз. Күңеллерәк булыр. Бөтен авыл халкы яратты үзеңне. Кая барма, сине мактап торалар. Эшләргә иде әле. Акчасы да булыр, укыганда анысы да кирәк.

– Сәлимә апа, кыстама инде. Килгән кунакның киткәне яхшы. Озаграк эшләсәм, йә авылыгыздан бөтенләй китә алмам. Менә Нәзир дә, алданрак кайтып, тулай торакта урын белешеп куй, ди.

Сиринә үзенең ялганыннан үзе кызарып, кырын күз белән генә Нәзиргә карап алды. Нәзир, актык сынык икмәген югалткан ярлыдай, аптырап басып тора. Ул Сиринә белән аерылышуның бу кадәр кыен буласын хәзер генә

төшенгәндәй югалып калган. Сиринә аны кызганып куйды, ләкин егеткә берничек тә ярдәм итә алмады ул. Сәлимә апа да Нәзир белән Сиринә арасында нидер булганын төшенеп алды.

– Минем барасы җирем бар иде, хәзер кайтырмын, – дип чыгып китте ул.

Әмма егет белән кыз барыбер сөйләшә алмадылар, һәрвакыт сөйләнә торган сүзләр үзләренең мәгънәсен югалтты, һәммәсе кирәксез булып калды.

Ә икенче көнне Нәзир Сиринәне Бөгелмә аэропортына кадәр озатып куйды.

**XIII**

Нәзирнең трактор йөртү таныклыгын инспекция кайтарып бирмәгән иде әле. Шуңа күрә ул төрле җирдә йөргәләп торды. Ләкин һәр көнне диярлек эш урынын алыштырып тору Нәзирне туйдырды. Ул, берәр комбайнга ярдәмче комбайнёр итеп утыртуларын сорап, председатель янына килде:

– Баһау абый, миңа рәтлерәк эш бир әле. Акчасы да төшәрлек булсын, китәргә әз вакыт кала. Юллык нәрсә әзерлисе иде. Студент халкын үзең беләсең бит.

– Кыз да булсын, буаз да булсын, синеңчә. Акчалы да, әйбәт тә эшне мин сиңа каян табыйм? Андый эшне постоянно эшли торган колхозчыларга биримме, сиңамы? Син ике-өч көн эшлисең дә китәсең. Ә соң, синеңчә, тирес түгәргә, салам өяргә юләрләр йөрсенмени? Син бит студент, үзең безгә үрнәк күрсәтергә тиешсең.

– Студентның да тамагы бар, Баһау абый. Ашамый гына торып булмый. Үз малаең да Казанда укый бит.

Баһау, башта шулай тузынса да, Нәзирнең эш сорап килүен ошатты. Бу акыллы егетнең зур бәлага таруын да, Маһирәләргә хәтсез генә печән ташуын да белә иде. Шуның өчен характерының йомшаклыгы аркасында егетнең ялгыш юлга кереп китүеннән курка иде председатель. Ул, эш сорап килгән Нәзирне күргәч, җиңеләеп киткәндәй булды.

– Нindirәк эш табарга икән сиңа?

– Берәр комбайнга утыртмассызмы дип килгән идем.

– Комбайннар быел төнлә дә эшлиләр. Менә Ис-кән-дәргә ярдәмче кирәк булыр. Әмма ләкин безне подводить итмә, егет. – Председатель теге вакытта да синең өчен безгә җавап бирергә туры килде димәкче булган иде, Нәзирнең сынык күңелен тагын да сындырудан куркып әйтми калды.

Шушы көннән соң Нәзир Искәндәр комбайнында эшли башлады. Искәндәр телгә бик җор кеше. Нәзир, төнлә эшләргә өйрәнмәгәнлектән, йокымсырап китсә: «Чиертәме?» – дип, егеткә эндәшә. Нәзир, аның ни әйткәнен аңлап җиткермичә: «Нәрсә?» – дип сорый. «Кармак саласың түгелме соң? Басуны диңгез дисәләр дә, анда балык юк, туган, кармакны елгага төшеп салырсың», – ди. Икесе дә көлешеп алалар.

Комбайнда эшләү ошый Нәзиргә. Үз-үзеңне онытып, бөтен уйларыңны басуга юнәлтәсең. Төнге басуда комбайн алдындагы берничә адым җирдән башка берни дә күренми. Күктә йолдызлар җемелди. Әнә халык телендә Чүмеч йолдыз дип йөртелә торган Җидегән йолдыз. Беркөнне Нәзир Сиринә белән шул йолдызның койрыгы таңга таба борылганчы урамда йөрде. Шунда Нәзир, шаярып:

– Сиринә, мин сиңа әнә шул чүмеч белән бер чүмеч мәхәббәт бүләк итәм, – ди.

– Бер чүмеч мәхәббәт бер йотуда бетә ул, – ди Сиринә.

Аннан соң алар шул чүмечнең зурлыгын исәпли башлыйлар. Бере бер сан, икенчесе икенче сан чыгара. Бәхәс китә. Арыгач кына, сүз көрәштерүдән туктыйлар. Ул вакытта Нәзир нинди бәхетле булган. Әмма бу бәхет үзе артыннан күпме үкенеч, күпме газап, күпме борчу китерде. Әгәр Нәзир Сиринә белән очрашканчы мондый хәлгә төшсә, мәхәббәт белән вөҗдан көрәше арасында газапланмас иде. Кеше үзенең кайда егыласын белми шул, ә инде егылгач, ничек кенә булса да торырга кирәк.

– Ябалак очып киткән якларга карыйбызмы? – дигән Искәндәр тавышы Нәзирне сискәндереп җибәрә.

– Нинди ябалак?

– Нинди булсын, теге Казан ябалагы.

Тагын уйлар бүленә. Тагын хыял дөньясыннан чынбарлыкка кайта Нәзир.

...Сәлимә апа – көндез, үзе төнлә эшләгәнлектән, Нәзир әнисе белән шактый вакыт очрашмады. Ә очрашсалар, зур сөйләшү буласын белә иде ул. Сиринә Казанга кайтып киткәннән бирле, әнисе гел күңелсез йөри. Бик ошаган иде Сиринә Сәлимә апага. Шуңа күрә Сиринәнең кайтып китүенә Нәзирне гаепләп, күңеленнән улына ачу тота иде. Беркөнне, улы белән ныклап сөйләшү өчен, эшеннән калды ул.

– Улым, – диде Сәлимә апа, – миңа яшерми генә әйтеп бир әле. Ни өчен Сиринәне үпкәләттең?

– Мин үпкәләтмәдем аны, әни. Әниләрне сагындым, дип кайтып китте бит. Үзең дә шунда идең.

– Дөресен сөйләмисең, Нәзир. Сиринә синең белән генә китәргә тиеш иде. Сезнең арада ни дә булса бар. Ана кешегә, бәлки, бу эшкә тыгылырга да кирәкмидер. Ләкин мин читтән генә күзәтүче булырга теләмим. Борчуларың, кайгыларың бар икән, ярып сал, бергәләп күтәрербез. Ә болай үз эчеңә бикләнеп, әкәм-төкәмдәй күгәреп ятма. Йә, әйт?

– Соң, әни, үзләренә кайтмый нишләсен ул?! Укыр вакыт җитте, аңа да ял кирәк.

– Боргалама, улым. Юкса ачуны китерәсең. Син нәрсә дә булса эшләргә җыенасың бугай. Күңелем шулай сизә. Ана күңеле белми сизенми ул. Камилә аркасында чыктымы аңлашылмаучылыгыгыз?

– Беләсең бит инде, әни. Камиләне мин язмыш кочагына ташлый алмыйм. Ул гарип булып калудан, кешеләргә кирәксез булып калудан курка. Аның бу халәтен аңлап та була, чөнки ул әтисенең кадерсез, гариплеге аркасында әнисеннән теләсә нинди начар сүзләр ишетеп яшәвен күреп үскән.

– Ә син Камиләне бу хәлдән ничек коткармакчы буласың? Син врач түгел, сынган сөякне алар төзәтә.

Нәзир ни дияргә белми торды. Аның әле әнисе алдында да, башкалар алдында да мондый кыен хәлдә калганы юк иде. Егетнең Сиринәгә тәкъдим ясаганда каушап сүзен әйтә алмый торуы исенә төште. Бу юлы ул вакыттагыдан күп тапкырлар кыен хәлдә иде Нәзир.

– Камиләгә өйләнергәме әллә дигән идем, – диде ул, ниһаять.

– Ни сөйлисең син, улым? Нинди семья белән башыңны бәйләгәнеңне беләсеңме? Анда бит син икенче Мөхетдингә әйләнәчәксең. Маһирә җелегеңне суырыр үзеңнең. Синең өчен өзелеп торган Сиринәң кая кала? Мондый эшне капыл гына хәл итеп буламыни?!

– Мин, әни, капыл гына уйламадым. Камилә шулай булганнан бирле, шушы фикер башымны вата минем, – диде Нәзир, ләкин Сиринә турында анасы исенә төшергәч эсселе-суыклы булды. Сиринәнең кеше бәхете өчен үз шатлыкларыннан ваз кичәргә әзер торуын белә иде Нәзир. Аның кайчан да булса үз бәхетен таба алача-гына да ышана иде. – Сиринә Камилә түгел инде, – диде ул. – Нинди генә хәлдә дә ул киләчәккә ышанычын югалтмаячак. Алдына куйган максатына ирешмичә торып, тынычланып кала торган кеше түгел ул. Аның максаты зур, планнары матур. Теләсә нинди эштән дә тәм табып эшли, әз генә шатлыкка да зур итеп шатлана белгән бәхетле кеше ул Сиринә.

– Ә син үзеңне Сиринәдән башка бәхетле итеп күз алдына китерә аласыңмы? Камилә синең изге теләгеңне аңлый алырмы? Менә шулар турында да исеңнән чыгарма, улым. Вәгъдәләшкән кешеңә хыянәт итәсең бит. Бик көчле кешеләр дә кайвакыт хыянәтне күтәрә алмыйлар. Сиринәнең яхшы кыз икәнен бик беләм мин, әмма нинди генә кешенең дә үз мәхәббәтен кулыннан ычкындырасы килми.

Нәзир әнисенең сүзләре хак икәнлеген дә аңлый, шулай да аның белән килешәсе килми. Кечкенәдән һәрнәрсәгә гадел, турылыклы булырга өйрәткән әнисе бүген ничектер эгоистларча фикер йөртәдер кебек тоела аңа. Егетнең саф йөрәге Камилә өчен сыкрый, бәгыре кискәләнә. Ул әле Камиләнең үзен яратамы-юкмы икәнлеге турында да белми, тик ул шунысына шикләнми: Камиләне Нәзирнең тәкъдиме шатландырачак. Камилә аннан нидер көтә. Ә башка бернинди вәгъдәләр дә аны ышандырмаячак, хәлен җиңеләйтмәячәк.

– Мин, әни, башкача эшли алмыйм инде, – диде Нәзир. – Сиринә минем ниятемне төшенде, юкса мин аңа үзем әйтә дә алмаган булыр идем.

– Ай, улым, улым. Синең бу эшеңә бер генә дә күңелем риза түгел. Бигрәк авыр бурыч йөклисең үзеңә. Бик бәхетсез булырсың инде.

– Кешеләргә яхшылык эшләү үзе зур бәхет, дип өйрәттең бит, әни. Камиләне бу килеш ташлап китсәм, үзең үк риза булмас идең. Ә башка чара юк.

– Улым, син бу сүзләрне мине юатыр өчен түгел, үзеңне юатыр өчен генә сөйлисең. Кешеләр бит бер эшләгән эшләре белән гомер буе куанып яши алмыйлар. Ә син ул семьяга кереп батсаң, гомер буе иза чигәчәксең.

– Әни, ул нинди генә семья булса да, мин аларга бурычлы бит. Ә минем үз бурычымны үтәмәскә хакым бармы?

**XIV**

Маһирәнең тормышы гөрләп кенә барды. Печәнне, утынны җитәрлек итеп әзерләде. Кызы колхоз эшендә имгәнгәнлектән, гомергә аяк атлап керергә куркып йөр-гән идарәгә дә тартынмый бара башлады. Бригадир ат бирмәсә – председательгә, председатель дә бирмәсә, партоешма секретарена керде. Эшләре көйләнә барган саен, аппетиты үсте. Ул инде колхоздан һәр йомышы өчен ат сорау белән генә канәгатьләнмичә, акчалата ярдәмнәр дә таләп итә башлады.

– Кызым айдан артык бульнистә ята, – диде ул, председательгә килеп, – ә колхозның миңа бер тиен ярдәм иткәне юк. Ул бит өйдә каз бәбкәләре саклаганда авырмады, колхоз милкен арттырыйм дип җаны-тәне белән эшләп йөргәндә авырды. Бульнискә барган саен, мин әллә никадәр акча туздырам, юлына түләргә генә дә күпме китә. Кергән җире булмаса да, акча көн дә чыгып тора.

– Акча биреп булмас, Маһирә. Правлениегә ярдәм сорап килүче бер син генә түгел бит. Һәрберсенә акча тарата башласаң, берничә көндә колхозыңда берни калмас.

– Мин гомеремдә беренче мәртәбә сездән ярдәм сорап килдем, шуны да кире кагасыз. Минем ише тыйнак кешеләргә бер җирдә дә рәт юк шул инде. Мин кешенең күзенә кереп сорый алмыйм. Ачка аяк сузганда да «бир» дия белмәм.

Председатель Маһирәнең нинди кеше икәнлеген яхшы белгәнгә, бу сүзләреннән елмаеп куйды.

– Үзең килеп сорамасаң да, без сиңа ярдәм итеп торабыз, – диде председатель.

– Ничек? Кайчан сезнең миңа ярдәм иткәнегез бар?

– Ничек икәнен уйлап кара әле. Әгәр үзеңнең генә башың җитмәсә, исеңә төшерәм. Печән ташырга ат аласың, бу бер булдымы? Колхоз җиреннән утын әзер-лисең, бакчаңа бәрәңге чәчәсең, малларыңны колхоз болынында көтүдә йөртәсең. Болар, синеңчә, ярдәм түгел-мени?

– Һи, боларны ярдәмгә санасаң. Мал асрамаган, бәрәңге утыртмаган кем бар безнең авылда?

– Анысы шулай да, башкалар бит синең шикелле печән өстендә генә бер-ике көн эшкә чыкмыйлар, ел әйләнәсендә җигелеп эшлиләр.

– Минем инвәлит ирне дә карыйсым бар, менә хәзер кыз өстәлде. Духтырлар, терелүе икеле, диләр. Ул да гарип булып кайтса, минем өскә кала. Шулай булгач, мин ничек итеп колхоз эшенә йөри алыйм? Мин үзем эшкә чыгарга атлыгып торам да, дөнья мәшәкатьләре итәктән тарта.

Маһирә, шулай мескенләнә торгач, теләгенә иреште, председатель аның үтенеч кәгазенә кул куйды. Болай җайлы гына шактый акча кереп куйгач, Маһирә бик сөенеп кайтты. Идарәдән ярдәм сорап баруы турында картына да әйтеп тормады. Шулай да, акча алган көн итеп, тәмлерәк күчтәнәчләр алып, кызы янына барырга ниятләде. Ләкин Маһирә анда барыр өчен генә бу түгәрәк акчаны ваклап тормады, ә базындагы каймагы, келәттәге йомыркасы белән чыгышты. Боларны сумкага салып күтәреп карагач, бу әйберләр әзрәк тоелды, аннан, булган булсын инде дип, тавык та суярга булды. Күптән йомырка салудан туктаган ак тавыкны Мөхетдингә кертеп тоттырды ул. Мөхетдин, карчыгының юмартлануын күреп:

– Кояшлар бүтән яктан чыгарга булмасын, – дип, Маһирәне үртәп алды. Шул ук вакытта пычагын да кайрарга онытмады, чөнки Маһирәнең холкын артык яхшы белә иде Мөхетдин. Әгәр озак уйлаштырып торсаң, тавыкны кире алып чыгып китәргә дә күп сорамас Маһирә. Айга-елга бер эләгә торган тавык шулпасыннан да мәхрүм калырсың.

Ләкин Маһирәнең бүген саранланырга һич исәбе юк. Аның күңеле гаҗәп күтәренке күренә. Мөхетдин суеп биргән тавыкны да җырлап кына тазартты. Учагына да сукранмыйча ягып җибәрде. Башка вакытта утының чи дип булса да картына бер кагылмыйча калмый иде, бүген үзе коры утын табып керде. Мөхетдин хатынының мондый җайлы чагыннан үзенчә файдаланып калырга теләде. Ул:

– Карчык, син больниста чакта шикәр бетеп киткәч, мин күршеләрдән өч тәңкә акча алып торган идем. Шуларга түләргә акча кирәк иде, – диде, карчыгына күтәрелеп карамыйча гына. Ләкин Маһирә аңардан үткенрәк булып чыкты.

– Үзем генә кертермен, кемнән алдың? – диде ул.

– Кемнән дип... Теге ниләрдән инде...

– Ул ниләргә үземнең дә керәсем бар иде, шунда бирермен.

Мөхетдин, эшнең барып чыкмаганын күргәч, турыдан ярып салмакчы булды. Мондый чак яңадан кабатланмаячак иде.

– Аяклар үтереп сызлый, Маһирә. Шуларны басарга дарулык кына акча кирәгие. Бер кызыллык кына булса да бир инде. Явымнар булыр, ахры, һич түзәр хәл юк. Уф, ай-яй билне үтерә.

– Кинәт кенә үтереп авырта башладылармы? Бик сызлагач, бульнискә барырга кирәк. Кызга иптәш тә булырсың. Барырга иренсәң, үзем баргач дарулар алып кайтырмын, шуңынчы түзәргә тырыш.

– Ул дарулар басарлык булса, сиңа тел әрәм итеп тә тормас идем. Менә тавык шулпасы янына берәр кырлы стакан акны салып куйсаң, шул чакта басылыр. Ә син дару дисең.

Маһирә яулык читеннән генә елмайды:

– Тавык шулпасы сиңа түгел ул, тамагыңны сузма, мин аны Камиләгә алып барам. Бульнис боткаларыннан туеп беткәндер мескенем. Андый җирдә өй ашлары сагындыра.

Маһирә картын да бөтенләй буш итмәде. Тавыкның башын, бүтәкәсен һәм үпкә-бавырын, бер тәлинкә шулпага салып, Мөхетдингә бирде. Ләкин Мөхетдин моның белән генә канәгать түгел иде.

– Их, карчык, сызлануларны шулпа белән генә басып булмый шул, – диде ул. – Аңарга үз даруы кирәк. Бер очсызлы кызыллык кына бир инде, бу арада эчләр кортлап бетте. Шул кортларны басарлык булса да ярар иде...

Маһирә картының хәленә керде. Мөхетдин бик ялына, мескенләнә торгач, аңа бер сум акча сузды:

– Мә инде, миннән булсын яхшылык. Теге туксан ике тиенлек кызылны алырсың. Берәр буш шешә дә алып барсаң, үзеңә папируслык та кала. Әллә кемнәрдән әҗәткә алып йөрмә, әҗәт түләве кыен. Мин хәзер киттем. Син йортны ташлап әллә кая кермә. Бакчага кеше тавыклары кермәсен, бәрәңгенең төбен актаралар. Карлыганнарга күз салгала, җыеп алырга дип торганда гына тавык-кош чүпләп бетермәсен, үрдәк-казларны да онытма.

Мөхетдин һәр сүзгә дә: «Ярар, ярар», – дип торды. Ул тизрәк Маһирәнең чыгып китүен тели иде. Кесәгә килеп кергән берлек күптән «әтәч булып кычкыра» башлады. Ә хатыны чыгып киткәч, ул үзенең саклык кассасын – тиенлек акчалар җыя торган таш песинең колагын борып, кесәдәге берлегенә кушты. Һәм титаклый-титаклый кибеткә юнәлде.

Маһирә больницада әйбәт чакка туры килде. Авыруларга көндезге аш таратып кына торалар иде. Маһирә дә юлда бераз суынырга өлгергән ашын кайнарлатып алып керде.

– Менә, кызым, минем ашны да ашап кара әле. Тавык шулпасы үзе туксан төрле чиргә дәва була. Ите белән аша, кызым. Коры шулпа тамак туйдырмый. Кәефең дә ару күренә, әзрәк сызлануларың кимемәдеме?

– Ята башлаганнан бирле болай ашыйсы килеп ашаганым юк иде әле, – диде Камилә. – Бик тәмле булды.

– Терелергә ул, кызым, терелергә.

– Берсекөнгә гипсны алалар инде, әни.

– Бик әйбәт, кызым. Ә соң теге операция урыннарың бик авыртмыймы? Пычак урыны тиз төзәлми бит.

– Тышка чыгарга бик комачаулыйлар шул. Кайвакыт йокыдан уянган чакта бер җирем дә авыртмый уянам да, сикереп торыйм дисәм, эчемә пычак тыккан кебек була. Менә гипсны алгач, врачлар, басарга рөхсәт итәбез, диләр. Ничек булыр тагы, аякка басып булырмы? Хәзер миңа гомеремдә йөрмәгәнмендер кебек тоела башлады инде.

– Син, кызым, саксыз кыланмаска тырыш. Үз-үзеңне сакламасаң, сине беркем дә сакламас. Теләсә ничек сикереп торма.

Маһирә кызына төрле киңәшләр биреп кайтып китте. Камиләнең әйбәтләнә баруы, ачылып сөйләшүе аның кәефен күтәрде. Кысыр симез тавыгын суеп алып барганына үкенмәде ул.

## XV

Көннәр бер-бер артлы үтә тордылар. Эшкә ихлас белән йөргәнгәме, әллә күңеленнән бер карар кабул итеп ныклы фикергә килгәнгәме, Нәзиргә бераз җиңелрәк иде. Ул, вакыт тапкан саен, Камилә янына барды. Һәр барганда, нинди дә кызыклырак яңалык сөйләргә, кызның кәефен күтәрергә тырышты. Әмма ул һаман да үзенең уйларын Камиләгә чишә алмый иде әле. Менә бу килүдә, һичшиксез, шул хакта әйтергә карар кылып килде ул.

Палатага Нәзир килеп кергәндә, Камиләнең аягына салган гипсын алып бетереп торалар иде. Гипсын алып ташлагач, Камиләнең тизрәк йөгереп китәсе килде. Ул медсестраларның рөхсәтен дә көтмичә каударланып, кабаланып аягына басты. Озак урында ятканнан соң беренче тапкыр торуы булгангамы, башы әйләнде, күз аллары караңгыланды. Кызның агарып киткән йөзен күргәч, медсестралар аны тизрәк яткырырга ашыктылар.

– Син хәзер ят, Камилә, – диде өлкән медсестра, – операциядән соң, өстәвенә гипста да яткач, кинәт кенә йөреп китә алмассың әле. Аягыңа бераз массаж ясамый булмас. Каяле, тезеңнән бөкләнәме?

Камилә аягын тездән бөкләргә теләде, тик ике айга якын хәрәкәтсез яткан аяк бирешмәде. Кыз көчәнүдән тирләп чыкты.

– Уф, һава җитми башлады, – диде ул.

Шулвакыт Нәзир тәрәзәне ачып җибәрде, ә үзе Камиләне тышка алып чыгарга рөхсәт сорады.

– Тышка алып чыгу кирәк, әлбәттә, – диде медсестра, – ләкин аягына авырлык төшмәсен. Иң яхшысы, сез аны коляскага утыртыгыз, ә аягы ныгый төшкәч, үзе дә чыгар.

Нәзир коридордан бер коляска алып керде дә, Ка-миләнең ай-ваена карамыйча, күтәреп утыртты һәм урамга алып чыгып китте. Көн, август ае булуга карамас-тан, шактый кызу һәм бөркү иде. Нәзир кызны агач күләгәсенәрәк алып барды. Бүген Камиләнең дә кәефе әйбәт күренә. Күрәсең, ул үзенең терелүенә ышана башлагандыр.

– Тыш һавасы нинди тәмле, – диде ул, үпкәләрен тутырып сулап. – Матур җәйләр әрәм үтте таш больнисларда.

– Болай булгач, әрәм үтмәгән инде, – диде Нәзир, Камиләнең аягына ишарәләп. – Терелеп чыккач, больницада ятуларыңны да онытырсың әле. Тагын элеккечә сикергәләп йөри башларсың. Хәтереңдәме, бервакыт сез-нең каз бәбкәгезне тилгән күтәреп киткәч, очып киткән тилгән артыннан икәүләшеп никадәр чапкан идек.

Балалык хатирәләрен искә төшергәч, Камиләнең агарып киткән йөзендә бераз кызыллык, җанлылык барлыкка килде. Ул үзенең озын толымнарын беләгенә урап уйлап утырды.

– Ә шулай да бәләкәй чакта кызыграк иде, әйеме, Нәзир? Больниста ятканда, мин бөтен тормышымны яңадан күңелемнән кичереп чыктым, үскән саен, шатлыклар кими барган, дөнья баскан. Кайвакыт минем тагын элекке кебек бәп-бәләкәй булып, кулларга мунчаладан ясалган пумалалар тотып, каз бәбкәләре саклап йөрисе килә.

– Кечкенә чакны сагынырлык картайдыкмыни инде без? – дип сорады Нәзир. – Миңа калса, тормышта матурлык кимеми, ә арта. Без кайчандыр үзебез күреп тә әһәмият бирми йөргән нәрсәләрне аңлый башлыйбыз. Безнең офыгыбыз киңәя. Билгеле, сабый чак кеше күңелен гомер буе яктыртып тора, әмма кешедә бит көндәлек шатлыклар, көндәлек кайгылар да булып тора. Һәр яңа көн сиңа көтелмәгән шатлыклар китерер кебек. Кеше, минемчә, үтелгән гомерен түгел, үтеләчәген матуррак итеп күз алдына китерергә тиеш. Шулай булмаганда, яшәүнең мәгънәсе кими. Киләчәккә өмете сүрелә, ә өметсез яшәп булмый.

– Син, Нәзир, яшәүнең мәгънәсен нәрсәдә күрәсең? – дип сорады Камилә.

– Кеше бөтен тормышын алдан уйлап куя алмый, әлбәттә. «Яшәү мәгънәсе» дигән сүз – бик зур сүз ул. Минемчә, һәр кешенең үз максаты булырга тиеш, шул максатына ирешү өчен бөтен көчен куйса, шуңа ирешүдән үзенә тәм тапса, шатланса һәм эше белән башкаларны да шатландырса, ул кешенең гомере мәгънәсез үтмәгән. Тормышымның мәгънәсен мин бер генә кешегә булса да файдалы эш эшләүдә күрәм. Минем бу сүзләрем бераз китапчарак булып чыкты бугай, ләкин мин башкача әйтә алмадым.

Камилә Нәзирнең сүзләрен игътибар белән тыңлап утырды. Нәзирнең бу сүзләрне чын күңеленнән сөйләвенә ышана ул. Әмма аның фикерләре белән килешеп бетәсе килми. Аның тормышка үз карашы бар. Бу караш ана сөте белән кызның күңеленә сеңгән.

– Кеше иң беренче үзе турында уйларга тиеш, – ди ул. – Үзеңнән артмый торып, башкаларга берни дә биреп булмый. Ә кешеләрдән бервакытта да берни дә артмый. Мисалга ерак китәсе юк, безнең өй эченә күз салсак та җитә. Кешеләргә гел шулай ни дә булса җитмәгәч, димәк, һәркем үзе турында гына кайгырта. Оят булса да әйтим әле, мин үзем дә бер эштән дә тәм тапмыйм. Үзең яратмаган эшне башкалар яратырлык итеп башкарып та булмыйдыр. Шулай булгач, минем тормышым мәгънәсез булып чыга түгелме соң?

– Һәрнәрсәне гел үзең өчен генә дип эшләгәнгә тәм тапмыйдырсың син. Менә бер яхшылык эшлим дә берәүне сөендерим әле дип уйласаң, алай булмый. Кечкенә вакытта, әни эшкә киткәч, мин ишегалларын себереп, утыннар ярып, бөтен җирне ялт иттереп куя идем. Әни арып, әлсерәп кайтып керә. Күреп торам: йөзе кырыс, шулвакыт ул мин җыештырып куйган җирләрне күрә дә шатланып елмая. Менә шушы әнинең елмаюы мине канатландырып җибәрә. Әнине шатландыра алуым белән бәхетле булып йөрим мин ул көнне.

– Минем мондый тойгы кичергәнем юк, Нәзир. Күрәсең, без бөтенләй капма-каршы кешеләрдер. Үзем дип кенә яшәгәч, мин беркемгә дә кирәкле түгел инде, – дип нәтиҗә чыгарды Камилә һәм тирән итеп көрсенеп куйды.

– Алай дияргә ашыкма, Камилә, – диде Нәзир. – Дөньяда бер кеше дә артык түгел. Мин дә кирәк, син дә.

– Кемгә? – дип сорады Камилә. – Әнигә тиргәр өчен генә кирәк мин.

– Менә миңа, – диде Нәзир капыл гына. Күптән әйтергә теләп тә җай таба алмый аптыраган сүзнең җиңел генә ычкынуын ул үзе дә көтмәгән иде. Ә инде бу хәтәр сүз әйтелгәч, башкаларын сөйләү кыен түгел. – Камилә, мин сине имгәткәннән бирле шул турыда уйлап йөрим. Больницага синең янга килгән саен, ниятемне әйтермен дип киләм, ләкин йә синең, йә үземнең кәефем булмау аркасында әйтми китәм. Син риза булсаң, мин сиңа өйләнер идем, Камилә.

Нәзир Камиләнең йөзенә күтәрелеп карады. Кыз, йокысыннан кинәт куркытып уяткандай, бу сүзләр тәэ-сиреннән сискәнеп китте. Башта ул йөздә ниндидер аптырау, гаҗәпләнү чагылды. Соңыннан бу гаҗәпләнүне шатлык алыштырды. Берничә минут эчендә яшен яктысыдай ялтырап киткән шатлык чаткысы Нәзирнең эченә җылы кертеп җибәрде. Тик кызның сөенече озакка бармады, аның күңелендә ышанмау шиге кузгалды.

– Алдама, Нәзир, – диде ул көч-хәл белән. – Мондый нәрсәне алдарга ярамый.

– Мин сиңа ялганлап утырырга килмәдем, Камилә, – диде Нәзир. – Бик озаклап уйлаганнан соң туган фикер инде бу. Мин башкача эшли алмыйм.

Гомере буе анасыннан ишетеп килгән «кызлар өчен иң зур бәхет – тәүфыйклы кияүгә чыгу» дигән сүзләр кызның йөрәгенә нык сеңгән иде. Үзенең әле мәхәббәт хисен бер мәртәбә дә татып караганы, сөюнең тирән

диңгезендә йөзгәне юк. Мәхәббәт китаплары укып та мавыкмады ул. Дәреслекләрдән башка һични укымыйча, аннан-моннан сигез класс бетерде дә йортта эшли башлады. Җәй житү белән яшел суганын сату дисеңме, җиләк-җимеш җыеп киптерү дисеңме – һәммәсен эшләде, һәммәсе белән таныш Камилә. Һәрвакыт иптәшләреннән аерылып үз эченә йомылып яшәгәнгә, әрекмән яфрагы астындагы үлән кебек, кояш нурлары күрми яшәде ул. Ә менә хәзер, егерме бер ел каплап торган күләгәне ачып, йөрәгенә кояш нурлары керә. Моңа ничек шатланмыйсың да ничек дулкынланмыйсың? Нәзир бит Камилә өчен авылдагы барлык егетләрдән якын. Балачак елларының иң матур көннәрен күз алдына китергәндә, беренче булып Нәзир калкып чыга. Больницага килгәч Нәзиргә тырт-пырт торулары да шул якын кешесенә ышанмаудан иде бит. Инде йөрәген синең уч төбеңә салгач ничек ышанмыйсың.

**XVI**

Нәзирнең Камиләгә өйләнергә уйлавын ишетеп, кызыннан болай Маһирә шатланды.

– Менә бит, атасы, бер яманлык күрми, яхшылык күрмәссең, дигән сүз дөрес икән, – диде ул картына. – Кызның болай булып китүе безнең өчен файдага булды. Камиләнең аягы кыскарак калудан безгә ни зыян? Аның урынына үгездәй егет киявебез була. Майда йөзәр чак-лар алда икән әле.

– Майда йөздерерме, судамы, белгән юк инде, – диде Мөхетдин карчыгына каршы. – Мин бу сүзгә һаман ышанып җитмим. Нәзирнең әнисе бик әтчәйни кеше, улының ниятен хуплап тормыйдыр.

– Әнисендә безнең ни эшебез бар? Киреләнеп маташкан ди бугай. Әмма Нәзир дә әнисенең малае бит, сүзендә тора белә. Яшьләр үзләре килешкәч, булды дигән сүз инде ул. Безгә хәзер Камиләне тизрәк больнистән алып кайтырга да туй хәстәрен күрә башларга кирәк. Тимерне кызуында суккан яхшы. Нәзир укуына китеп барганчы язылышып куйсыннар. Бәлки әле, аны Казанына җибәртми калдырып та булыр.

– Ай-яй, карчык, синең авызыңа бер калҗа керсә, шуны йотып та җибәрмәстән икенчесе турында уйлый башлыйсың. Башта авызыңдагысын йотарга кирәк.

– Авыздагысы качмас.

– Чама дигән нәрсәне белмәсәң кача да ул.

Шушы сөйләшүдән соң Маһирә, бөтен җитезлеген, бөтен көчен куеп, булачак туйга әзерләнә башлады. Башка вакытта кулдан киткән һәр тиен өчен эче ачытып йөри торган Маһирәнең саранлыгын юып алдылармыни?! Аракысын да ящигы белән генә кайтартты, көне җиткәч суярга дип сарыгын да аерып ашата башлады. Бу тоткан расходларның соңыннан унысы белән кайтачагына чын күңеленнән инанганга, бернәрсәсен дә кызганмады ул. Аннары, саранлыгы белән Нәзирне беренче көннән үк өркетеп куймагаем дип тә уйлады.

Әнисе туйга әзерләнеп йөргәндә, Камилә дә больницадан кайтты. Ул бераз аксабрак йөри иде. Әллә аягы рәтләп төзәлеп җитмәгәнгә, әллә башка сәбәптән, Камилә боек күренә. Аның бу хәленә Маһирә дә игътибар итте.

– Нишләп болай борының белән җир сөрәсең? Бүгенгесе көндә очып йөрергә кирәк сиңа.

– Очып йөрердәй шатлык юк бит, әни.

– Менә тагын, иске авыздан яңа сүз. Моннан да зур шатлык буламыни? Яшь шул әле син. Юкса болай димәс идең. Үзеңә берәр матуррак күлмәк тектер. Шәһәр кызлары кебек милон-капрон күлмәкләр алып булмас, билгеле. Шулай да йөз кызарырлык булмасын. Бар, акча ал да кибеткә йөгер. Адашкан бәбкәдәй боегып йөрмә болай.

– Миңа берни кирәкми, әни. Син дә юкка мәшәкатьләнәсең. Бу туйның буласы юк.

Маһирә кызының бу сүзләреннән егылып китә язды. Кулындагы ашлы тәлинкәсе идәнгә төшеп ватылды.

– Ничек «буласы юк»? – дип сорады ул хәлсез тавыш белән.

– Мин әле Нәзиргә ризалык бирмәдем. Ул тәкъдим ясады дип кенә әйткән идем, кайтсам, син монда пыр тузып туйга әзерләнеп ятасың икән.

– Синең ризалык бирмәвең кечкенә нәрсә, бүген бирмәсәң, иртәгә бирерсең. Кыз чакта әзрәк ялындырып тору ярый ул, – диде Маһирә, иркен сулап. – Әллә мин Нәзир яңадан киреләнеп торамы дигән идем. Синең генә кирелекне сындырып була.

Әнисенең бу сүзләренә Камиләнең хәтере калды.

– Нәзир киреләнсә дә, мин киреләнсәм дә барыбер ич, – диде ул. – Туйны егет өйләнү дип кенә карама, кызыңны кияүгә бирү дип тә кара. Үз сүземне әйтергә минем дә Нәзир кебек үк хакым бар.

– Хакың юк дип әйтмим мин сиңа, кызым. Нәзир кебек егетне кире кагуың гына гаҗәпләндерә. Ул бит өйгә үз аягы белән килеп керергә торган хәзинә. Күктән теләгәнне җирдән бирде инде Ходай. Шөкрана кылып кына яшәр-лек. Буе-сыны дисәң, авылда бер. Кеше арасында ким-хур булырлык түгел. Аннары, үзеңнең нинди хәлдә икәнеңне дә онытма. Иң кадерле җирләреңне пычак белән тунатканнан соң, сине әллә кемнәр алам дип тормас.

– Алмасалар, кияүгә чыкмый калу гына зур бәла түгел икән әле ул. Бу турыда мин больниста ятканда бик озак уйладым. Башка вакытларда уйланып утырырлык вакытым булмагангамы, кешеләр белән аралашу йоклаган акылымны уяттымы, ничек кенә булса да, ачык беләм...

– Нәрсә беләсең?

– Иң зур бәхет тәүфыйклы кияү генә түгел икәнлеген беләм. Син, әни, больниста невропатолог булып эшләүче Евдокия түтине беләсеңме? Менә шул түти бер дә тормышка чыкмаган икән. Берчак шулай, сүз иярә сүз чыгып, мин аңардан ни өчен ялгыз яшәвенең сәбәбен сорадым. Тормышка чыгарга вакытым булмады, диде ул. Евдокия түтинең егерме яшьләрдә әнисе үлгән. Әтисе башкага өйләнеп, үги ана сеңелләрен җәберли башлагач, дүрт сеңлесен карап үстергән. Сеңелләре үсеп аякка басуга, Ватан сугышы башланып китә. Евдокияне, медсестра булганлыктан, фронтка алалар. Сугышның ахырына кадәр госпитальдән госпитальгә йөри. Тыныч тормышлар башлана, ләкин фронттан яраланып кайтучыларның күплеге, ә югары белемле врачларның аз булуы борчый Евдокияне. Соң булса да, ул институтка укырга керә. Институтны кырыгынчы яшендә тәмамлый. Хәзер инде ул алтмышның өске ягында, үзе һаман эшләп йөри. Бервакыт: «Сез бәхетлеме?» – дип сорадым мин аңардан. Ул уйлап торды да шундый ышаныч белән: «Әйе, – диде. – Минем бәхетем менә сездә, һәрбер терелеп чыккан авыру өчен авыруның үзенә караганда да ныграк шатланам. Кешегә шатлык китерүдән дә зуррак куаныч бармыни?» – диде ул. Евдокия түтинең шушы сүзләре бөтен тормышымны яңадан күздән кичерергә мәҗбүр итте.

Мәһирә кызына сәерсенеп карап куйды. Камиләнең әнисе белән бервакытта да болай ачыктан-ачык сөйләшкәне юк иде. Мәһирә кызының күңеленә нинди ачкыч табарга белми торды. Һәрвакыттагы кебек усаллык белән генә Камиләнең каршылыгын сындырып булмаслыгы көн кебек ачык иде.

– Евдокия кебек кешеләр бөтен Рәчәйгә берәү, син шуңардан үрнәк аласыңмы? – диде ул рәнҗегән тавыш белән. – Ул вакытта чыгыйм дигәндә кияве дә булмаган.

– Мин аңардан үрнәк алмыйм, әни. «Кияүгә чыкмый бәхет юк» дигән сүзләреңә генә җавап бирәм.

– Ана күңеле балада, баланыкы – далада, дип белми әйтмәгәннәр шул, – диде Мәһирә, еламсырап. – Баланы табасың, үстерәсең, картайган көнеңдә файдасын күрермен дип өметләнәсең. Ә алар кайда егылырларын уйламыйлар, киреләнәләр. Син Нәзиргә барсаң, тормышыбыз әллә бераз рәтләнерме дигән идем. Картайган көнебездә бигрәк таянычыбыз юк, син дә хәзер авыр эшкә ярамыйсың. Өебез өстебезгә аварга тора. Үзем яр-ты чиләк су да күтәрә алмыйм, картайдым. Атаңны әйткән дә юк.

Мәһирәнең үзен үзе кызганудан күзләренә яшьләр килде. Ул аларны юри сөртмичә, мөлдерәп торган яшьле күзләре белән кызына карады. Камилә әнисенең болай йомшап киткән чагын күргәне юк иде, мондый хәлдә күргәч бик кызганды. Өйләре чынлап та бик иске шул. Кешеләргә колхоз салып бирә. Ел саен авылда әллә никадәр яңа йортлар калкып чыга. Ә Камиләләрнең һаман шул дүртпочмаклы, кыйшая башлаган кечкенә өй. Бәлки, әнисе хаклыдыр. Нәзир әйбәт егет, аңа тормышка чыксаң бәхетсез итмәс. Әти-әниләргә дә ярдәме тияр. Камиләнең бит кулында бернинди һөнәре юк, өстәвенә тазалыгы да шуның хәтле. Шулай булгач, барыбер ул әллә нинди зур эшләр майтара алмас. Әгәр дә әниләренең хәлләре яхшы булса, бүгеннән берәр якка укырга китәр иде Камилә. Әнә бит кешеләр кырык яшьтә дә укып йөргәннәр. Хәзерге заманда сигез класс белем белән ерак китә алмыйсың шул.

Камиләнең төрле уйлардан башы катты. Бер яктан Нәзир, икенче яктан әнисе аның соңгы сүзен әйтүен ашыктырдылар. Нәзирнең үзенә өйләнергә ниятләвен ишеткәч, башта бик шатланса да, төрле яктан уйлый һәм күп нәрсәләрне акылы аша үткәрә торгач, тиз генә ризалаша алмады кыз. Шулай да, бер генә минутка булса да, үзен Нәзир белән янәшә куеп карыйсы килде аның. Ул, язылышырга барсам, кайсы күлмәгемне кияр идем икән дип, күптән ачылмаган сандыкны актара башлады. Хәер, аның әллә ни сайлар күлмәге дә юк. Әнисе аңа бер кечкенә яулык алып кайтса да, үз тамагымнан кысып, ашарымны ашамыйча алынган әйбер бу, дип басым ясап килде. Шуңарга Камилә әнисеннән кием-салым сорарга тартынды. Менә хәзер, сандык актарып утырганда, үзенең бер генә дә рәтле киеме юк икәнен күреп исе китте аның. Моңа ул беркемне дә гаепли алмады.

Сандык үзенә күрә истәлекләр дәфтәре кебек нәрсә. Анда әллә кайчан алынып, хәзер кияргә ярамаган әй-берләр дә, бала чакта туздыра алмый бәләкәйләнеп калган киемнәр дә була. Камилә дә сандыкта күңелендәге хатирәләрен яңартырлык хәтсез нәрсә тапты.

Менә аның беренчеме, икенчеме класста укыганда киеп йөргән күлмәге. Акка кызыл борчак төшкән шушы күлмәк аның иң яратып кигән күлмәге иде. Нишләп моңа кадәр сакланган соң ул? Камилә шушы күлмәген бөтен якын-тирәдәге күршеләрдән котлатып йөргән иде. Әле дә хәтерендә: иң беренче ул Гөлҗәннәт әбиләргә керде. Курчактай киенеп кергән кызны күргәч, Гөлҗәннәт әби:

– Кызым, күлмәгең бик матур икән, өстеңдә тузсын, – диде. – Менә котлап кәнфит бирер идем, аның өчен кибеткә барасы бар. Йомырка бирер идем, тавык-лар салмаган.

– Ояда маягыз бардыр әле, – диде Камилә, күп уйлап тормастан.

Кызның кыю җавабы карчыкка бик ошады, рәхәтләнеп көлде ул һәм ике йомырка биреп чыгарды. Гөлҗәннәт әби бу вакыйганы башкаларга еш кына кабатлап торганга, Камилә дә онытa алмады. Бүген шул истәлекләр тәэсирендә кулына алды Камилә күлмәк калдыгын. Аның инде җиңе генә калган икән.

Шулвакыт, төсе-бите бетеп, Маһирә килеп керде:

– Нишләп утырасың анда?

– Менә балачакны искә төшереп утырам.

– Тапкансың искә төшереп утырыр урын. Сандык актарырга сиңа кем кушкан? Йозаклы иде бит ул, ничек ачтың?

– Егерме ел торган йозакны да ачмаска!

– Монда синең бернисең дә юк. Китер әле аны... – Маһирә кызы кулыннан җиңне тартып алды. Шунда җиң эченнән бер кенәгә килеп чыкты. Маһирә, сугышырга килгән этәчтәй, кенәгәгә ташланды. Ләкин ул Камилә кулында иде инде. Камилә әнисенең сузылган кулын читкә этеп җибәрде дә кенәгәне ачып карады. Анда әнисенең исеменә салынган өч мең тәңкә акча бар иде...

Камиләгә бу ачыш яшендәй тәэсир итте. Әнисенең мескенләнеп әҗәткә акча алулары, йомырка-май ише нәрсәләрне авыздан өзеп сатып йөрүләре күз алдына килде. Әле яңарак кына өебез өстебезгә ава дип күз яшьләрен агызып торган әнисен уйлагач, Камилә аның комсызлыгыннан җирәнеп ни эшләргә белмәде. Үзен гомер буе алдап яшәгән әнисе янында моннан соң тора алмаячагын аңлады ул.

## XVII

Икенче көнне аларга Нәзир керде.

– Камилә, мин синнән җавап көтәм, – диде ул, кызның ялгызын гына очратып. – Минем хәзер укулар башлана. Соңарып барсам, институттан төшереп калдырырлар.

– Соңламассың, Нәзир, – диде Камилә. – Мин үзем дә синең кергәнеңне көтеп тордым. Алып кит мине, Нәзир. Бу өйдә яши алмыйм мин. – Камиләнең күзләре яшьләнде. Әллә үзенең мескен хәленнән, әллә шушы яшенә кадәр ялган белән чынны аера алмавына гарьләнеп елады. Күңеле бераз бушагач, Нәзиргә әнисенең кенәгәсе турында сөйләп бирде. Нәзир уйга калды.

– Сине Казанга алып барып кайда урнаштырырмын икән, эшкә керергә прописка кирәк. Минем стипендия үземә дә җитми.

– Мин синең стипендияңне ашарга бармыйм, – диде Камилә, үпкәләп. – Мине берәр җиргә укырга урнаштыр. Минем кулларыма һөнәр кирәк. Кешеләрнең кызганып сузган ярдәмнәре генә мине куандырмый. Син, Нәзир, бу укымаган кеше, берни дә аңламый дип уйлыйсыңдыр. Синең миңа өйләнергә теләвең дә шул кызганудан бит. Элекке авырмаган чагым булса, бу хакта уйламаган булыр идем. Больница мине күп нәрсәләргә өйрәтте. Күп кешеләр белән очраштырды.

– Нишләп кызганудан булсын, мин чын күңелдән...

– Юк, Нәзир, яшерми генә әйт әле, син мине ярат-мыйсың бит. Әйтмәсәң дә беләм, синең күңелеңдә Си-ринә. Мине кочакласаң да, назласаң да, син аны гына күз алдыңа китерәчәксең. Хыялыңда син мине ул итеп күрәчәксең. Шушындый хәлеңне белә торып, мин бәхетле булыр дип уйлыйсыңмы?

– Син, Камилә, бик эчкәре кердең әле, – диде Нәзир, тирләп чыккан битләрен сөртеп. Кызның бу сүзләреннән ул аптырап калган иде.

– Эчкәре кереп уйлый алмый дип уйласаң, минем турыда тагын да түбәнрәк фикердә булгансың. Теләсә нинди ачылган кочакка ташланырга җыенмыйм мин. Ир хатыны гына түгел, кеше буласым килә минем. Син шуны аңла, Нәзир. Менә синең сүзләреңә җавабым.

Өйдә тынлык урнашты. Нәзир дә, Камилә дә, яңа гына очрашкан ят кешеләрдәй, нәрсә сөйләшергә белмәделәр. Бигрәк тә Нәзиргә кыен иде. Ул үзен кыйнап ташлагандай хис итте.

– Теләгең бик матур, Камилә, – диде ул. –Укырга кайчан да соң түгел.

– Әгәр яратышмаган килеш семья корып җибәрсәк, бу безнең икебез өчен дә зур фаҗига булыр иде, – диде Камилә. – Мин, аягым сынгач, моннан да зур фаҗига юктыр дип йөри идем. Ләкин ул чакта ялгышканмын, авыруым вакытлыча гына булган. Хәзер менә аксаклап булса да йөрим. Тора-бара анысы да бетәр. Мин яшь әле, хәлемне аңлардай, үземне дә, үзем дә ярата торган кеше дә очрар, бәлки. Дөресен әйтергә кирәк, мин синең сүзеңә куандым. Әмма...

– Әйдә, әйтеп бетер инде, күңелең бушасын, – диде Нәзир.

– Әйтеп бетермәсәм дә аңлыйсың инде... Иң яхшысы – миңа укырга, кеше булырга кирәк. Миңа ярдәм итәсең килсә, берәр һөнәр алырга ярдәм ит.

– Берәр профессиональ техник училищега керсәң ничек булыр икән? Нindирәк һөнәр сине кызыксындыра?

– Нәрсә кызыктырганын мин үзем дә белмим әле. Тегүчелеккә керсәм әйбәт булыр төсле. Син бервакыт әйткән идең бит, эшең кешеләрне шатландырсын, шунда гына үзеңне бәхетле тоясың, дип. Матур тегелгән кием кигәндә, һәркем сөенә ич.

– Әйе, – диде Нәзир. – Ике ел укысаң, оста булып чыгасың. Бергә-бергә укулары да җиңелрәк булыр. Алайса әзерлән, Казанга китәрбез.

Тиздән Нәзир белән Камилә китеп бардылар, бер фаҗига икенчесен тудырмады.

## ӘЙТЕЛМИ КАЛГАН СҮЗ

– Әнкәй, бүген синең яныңа ятыйм әле, – дип, Лиза, анасының рөхсәтен дә көтмичә, мендәрләрен күтәреп килде.

– Утызга җиткәнче шул балалыгың бетмәде. Берәр әйтәсе сүзең яки үтенечең бардыр, болай сырпаланмас идең. Йә теге шкафтагы вазаны ватып куйгансыңдыр әле.

– Юк, әнкәй, бернәрсә дә ватмадым.

Лиза, утын сүндереп, әнисе янына килеп ятты. Аның тәне уттай кызыша, еш-еш сулый, әйтерсең каяндыр йөгереп кайткан да һаман тынычланып җитә алмый иде.

– Син, кызыкай, чирләп маташасың түгелме? – диде ана, борчылып. – Авызыңнан ялкын бөркелә.

– Юк, чирләмим...

– Алайса, нәрсә соң?

– Мин, әнкәй... ни, әнкәй... Ни... Тормышка чыгам.

Кыз, сүзләрен бутала-бутала булса да әйтеп бетергәч, тын да алмыйча әнисенең күкрәгенә капланды. Икесе дә уйга калдылар. Ананың күңеле тыныч түгел, ул шомлана иде. Шунлыктанмы кызының бу хәбәреннән күтәрелеп бәрелмәде. Бары тик:

– Кемгә? – дип кенә сорап куйды.

– Кемгә дип, шул нигә инде. Соң, әнкәй, үзең дә беләсең ич. Әгъләм үзебезнең авыл егете лә!

Егетнең исемен ишеткәч, ана кинәт әллә нишләп китте. Кызының кайчан да булса үз тормышын корачагын яхшы белсә дә, аның нәкъ менә Әгъләмне сайлавы ананы тын калырга мәҗбүр итте.

– Нигә, әнкәй, бер сүз дә әйтмисең?

Кызының бу соравыннан ана сискәнеп китте.

– Нәрсә әйтим соң? Син бәләкәй бала түгел, буй үстергәнсең, акыл утырткансың. Бөтен ягын да уйлаган-сыңдыр.

«Шушы булдымы инде ана сүзләре?» Лиза, хәтере калып, йомшап киткән борынын тартып куйды. Үз гомереңдә иң истә калырлык, иң көтелгән бу көнне бик тә матур, бик тә шатлыклы булыр дип көткән иде ул. Әнисенә әйтәсе сүзләрне дә кат-кат уйлап, күңеленә тәмам сеңдергән иде. Әмма һич тә көткәнчә барып чыкмады.

– Син минем Әгъләмгә чыгуыма риза түгелсең, ахры, – диде Лиза. – Мин моны күптәннән сизеп йөрим. Әгъләмнең турыбыздан үткәнен күрсәң дә, йөзең үзгәрә. Синең каршыда аның ни гаебе бардыр.

– Гаебе юк икәнен дә беләм, – диде ана, көрсенеп.

Бүлмәдә әгәр ут булып, әнкәсенең йөзен күрә алган булса, Лиза бу минутта аңардагы үзгәрешне күреп шаккатар иде. Әйтерсең Газимә апаны алыштырдылар: чыраена газап һәм сагыш бәреп чыкты.

– Әгъләмнең гаебе юклыгын да беләм, – дип кабатлады ул тагын, – шулай да алар белән туганлашасым килмәгән иде.

– Ни өчен? Әллә ул (Лиза Әгъләм дип әйтергә ни өчендер кыенсынды) сиңа берәр начарлык эшләдеме? Газаплама, әнкәй, мин барысын да белергә тиеш.

– Сөйләсәм, сиңа бик көлке тоелыр инде. Үз эчемә генә яшереп калдырырга иде дә бит. Нишлим соң, минем бит эчемдәге тышымда. Тик алдан ук сине искәртеп куям: сүз Әгъләм турында бармый. Ул яктан тыныч бул.

Син туганчы, әтиеңнәр сугышка киткән чакта ук булган хәл бу. Алар бер авылдан утыз кеше киттеләр. Әле дә хәтеремдә: яңгырлы, пычрак август көне иде. Сиңа сөйләгәнем дә бар: әтиең, киткәнче, авыл Советы председателе булып эшләде. Иртәгә китәм дигән көнне генә эшләрен Әгъләмнең атасы Касыймга тапшырды. Касыйм, бронь алып, сугышка китмичә калды.

Безнекеләр Ютазы стансасына тракторга утырып киттеләр. Без, хатыннар, басуга кадәр генә озата бардык та кире борылдык. Минем сиңа авырлы вакытым, көне дә яңгырлы булгач, эшкә бармадым, кайттым да яттым. Озак та үтмәде, кулына чыбыркысын урап тотып, Касыйм килеп керде.

– Нәрсә син хан кызыдай түшәккә җәелдең? Хәзер үк ындырга чап, юкса соңы начар булыр, – дип кычкырды.

– Авырыбрак торам, Касыйм, бүгенгә бара алмам инде, – дидем.

– Председатель хатыны булып иркәләнеп ятарга өй-рән-гәнсең. Ләкин моннан соң болай булмас.

Касыймның сүзләренә хәтерем калды. Ник дисәң, бер генә көн дә эштән калган кеше түгел мин. Авыр булса да, ул көнне эшкә чыктым. Вакыты шундый иде бит, наз-ланып торырлык идемени? Ә икенче көнне минем янга авыл Советында секретарь булып эшләүче Миңлегөл килде.

– Газимә апа, Гали абзыйлар Ютазыдан китмәгәннәр әле. Тагын өч көн торачаклар, ди. Гали абзый үзе шалтыратты.

– Кайчан?

– Кичә Касыйм абзыйга шалтыратты. Сөйләшкәннәрен үзем тыңлап тордым.

– Нәрсә диде икән?

– Минем атны җигеп, Газимә яныма килсен, бик зур сүзем бар, ди. Касыйм абзыйның төсләре үзгәреп китте: Хәзер синең атың юк, минем атым гына бар. Ә мин теләсә нинди назлыбикәләргә свиданиегә йөрер өчен ат бирә алмыйм, ди. Гали абзый тагын нидер әйтте бугай, анысын мин ишетмәдем. Касыйм абзый, аның сүзе беткәнне дә көтмичә, телефон трубкасын ташлап чыгып китте. Ул чыгып киткәч, мин шалтыратып караган идем дә, җавап бирүче булмады. Әйбәтләбрәк сораган булса, сүзен телефоннан да әйткән булыр иде, әйе бит?

– Нәрсә турында гына әйтергә теләде икән? Балалар турында берәр киңәш-мазар булдымы икән? Алай дисәң, үземне Ютазыга кадәр чакыртып тормас иде. Андый-мондыйга гына борчый торган кеше түгел. Миңлегөл, әгәр хәзер мин телефонга барсам, Галине чакыртып алып булырмы?

– Бер дә белмим, Газимә апа. Военкоматта алар бит меңләгән, кем генә эзләп торыр икән.

– Әйе шул. Кара әле, Миңлегөл, өч көн торабыз, дип әйткәнен үз колагың белән ишеттеңме?

– Ишеттем, Газимә апа. Бусын әйтмәм дигән идем, болай булгач, эчтә калмасын: «Өч көн түгел, Ютазыда өч ай ятсаң да, хатының белән эге-җөге килеп торалмассың», – диде Касыйм абзый.

– Алайса, аның янына үзем барыйм, егерме биш чак-рымны кем йөрмәгән?

– Шушы килешме?

Миңлегөл минем авырлы булуыма ишарәләде. Ләкин мине бу минутта берни дә тыярлык түгел иде. Биш баламны түшәктә ятучы әбиләренә калдырдым да юлга чыктым. Ютазы юлы таныш юл. Елның-елында шунда элеваторга икмәк ташыйбыз. Шоссе белән барганда, машиналар да йөрми тормый. Шулай булгач, нигә куркып торырга?

Юлга чыкканда әйтелми калган сүзнең тәэсиреннән бик җиңеләеп, алгысып чыккан идем, тора-бара арытты. Юлчы-мазар да очрамады. Җитмәсә, өстән дә явып тора иде. Барыбер машина очрамас дип, бераз баргач, турыдан гына, авыллар аша гына киттем. Александровкага җитәрәк, күкрәгемдә нәрсәдер өзелеп төшкәндәй булды. Шуннан авырып киттем. Көч-хәл белән генә авыл башындагы бер өйгә кердем. Мин кергәндә, өйләрендә башка кешеләре булгандырмы, анысын һич хәтерләмим, бары тик бер кечкенә кызлары гына күземә чалынды. Сине шул урыс авылында, Александровкада таптым.

– Исемемне дә шуңарга Лиза дип кушкансыңдыр, әйеме?

– Әйе, теге хуҗа кызының исеме шулай иде. Үзе бик тере нәрсә булып чыкты. Бәбине килеп күрү белән, миңа курчак китердеңме, дип сораштырырга тотынды.

– Курчак түгел, чын бала бу, – дим.

– Чын бала – курчак инде, алай булгач. Мин аның белән уйнармын. Син аны алып китмә, яме? – ди.

– Алып китәм, менә әзрәк тереләм дә алып китәм. Аңарга үсәргә кирәк әле, – дим.

– Алдыйсың, курчак үсми ул. Әнә минем курчагым әллә кайчаннан бирле тора, үсми бит, – ди.

Мин аны бәбинең курчак түгеллегенә һич тә ышандыра алмадым. Аларда миңа дүрт көн ятарга туры килде. Бишенче көнне хуҗа хатын, үзе ат җигеп, мине Ютазыга алып барды. Атаңнар киткәннәр иде инде.

– Әтинең нәрсә әйтергә теләгәнен тәки белә алмадыңмы?

– Каян белим. Китте дә суга төшкән кебек юк булды бит. Ичмасам, бер хат та салмады. Эшелоннары белән туп-туры фронтка озатканнар. Шулар арасыннан берсе дә исән кайтмады.

Аналы-кызлы икесе дә бераз сүзсез яттылар. Өйдә бары тик сәгать текелдәгән һәм чикерткәләр сайраган тавыш кына ишетелеп торды. Әтисен әллә бер мәртәбә дә күрмәгәнгәме, әллә әнисе буталчыграк, корырак сөйләгәнгәме, Лиза бу вакыйгага бик әһәмият бирмәде. Киресенчә, ул Әгъләмнең монда катнашы булмаганына шатланды гына.

– Шуның өчен генә Әгъләмне яратмыйсыңмы? – диде ул. – Мин берәр җитдирәк нәрсәдер дип шикләнгән идем.

– Менә әйттем бит, сиңа көлке тоелыр, дидем. Шулай булып чыкты да, – диде ана, бераз җәберсенеп. – Сиңа вак нәрсә булып күренгән шушы әйтелми калган сүзне мин егерме сигез ел буе уйлап йөрим инде. Ул миңа бер генә көн дә тынгылык бирми. Ичмасам, шул сүзен генә әйтеп китә алган булса да, үлгәндә күңеле тынычрак булыр иде. Ә син, җитди түгел, дисең.

– Әнкәй, хәтерең калмасын инде. Мин Әгъләмнең катнашы булмаганга сөенеп кенә әйтәм. Ә сезнең арадагы бу хәлне Касыйм абзый күптән оныткандыр инде...

Ана без сүз дә эндәшмәде. Ул инде, янындагы кызы турында да онытып, әйтелми калган сүз хакында уйлана иде.

## БОРЧЫЛМАГЫЗ, БАЛАЛАР, МИН ТИЗ ГЕНӘ КИТМИМ ӘЛЕ

– Әй, Казаныгызны әйтер идем: кая барма – шунда халык, кая кермә – шунда кысанлык! Тар чалбар кигән кеше кебек сизәм мин монда үземне. Һава җитми миңа монда, һава! Бөтенегез ысланган балык төсле булып беткәнсез. Җә, шушы уч төбе хәтле билет өчен ярты көнеңне әрәм ит инде.

– Билет алдыңмыни? – диде Суфиянның килене.

– Әйе, чират торып алдым. Уф! – Суфиян изүләрен чишеп җибәрде. – Урамда мәхшәр диярсең. Авыз-борыныңны кульъяулык белән ябып йөрмәсәң, тончыгып үләрсең, валлаһи. Машиналар авыз-борыныңны дегетле төтен белән сылап китә. Ничек яшисездер шушы төтен эчендә.

– Яшибез инде, – диде килене. – Сезгә иркенрәк булсын өчен авылдан киттек.

– Анысы шулай инде, – диде Суфиян карт, эчке көлүен тыя алмыйча. – Балалар ата-аналарына һәрвакыт «иркенлек» тели.

Килен кеше, картның сүзләрен ишетмәмешкә салышып, ягымлы тавыш белән:

– Билетыңны ала алдыңмы соң, эткәй? – дип сорады.

«Эткәй» сүзен килененнән беренче тапкыр ишеткәнгәме, Суфиян карт моңа кадәр тоймаган рәхәт халәт кичерде. «Моңа да акыл керә башлаган икән, – дигән уй йөгереп үтте башыннан. – Хәерлегә булсын!»

Килене соравын кабатлагач кына, карт ләззәтле хисләреннән айнып китте:

– Ә-ә, килен, билетны әйтәсеңме? Алдым мин аны, алдым. Олы башымны кече итеп, шәһәр буенча сакал сәлперәйтеп йөреп, билет алмый кайт, имеш. Карт булсам да, Аллага шөкер, күкрәктә гайрәт бетмәгән. Чиратта төрткәләшергә терсәкләр очлы.

Суфиян карт киерелеп куйды. Чынлап та, гәүдәгә таза иде әле ул.

Килене картны мактап куйды:

– Сезнең нәселне юкка гына Чакматаш дип атамаганнардыр.

Суфиян карт бөтенләй эреп китте. «Кара син аны, килене аларның кушаматларын да белә икән!»

Ә киленнең үз шатлыгы иде. Ул, эченнән песи мырлаган тавыш чыгарып, әкрен генә җырлап, аш салырга тотынды. Картның күчтәнәчкә алып килгән ярты түшкәгә якын сарыгы, вакланып тутырылган килеш, суыткычта тора иде, майлырак урыннарын сайлап (чөнки симез җирен Суфия үзе бик өнәп бетерми иде), аш салып җибәрде. Аш өлгергәнче, ялт кына каядыр чыгып керде. Бүтән вакытта мондый эшләргә бик ашкынып тормаучы килененең бөтерелеп йөрүе картны шактый гаҗәпләндерде. Тик ул ошбу үзгәрешнең асылына төшенер өчен төпченеп маташмады. «Күрәсең, моны малай бераз пыжгырткандыр», – дип кенә уйлады.

Теләгәндә Суфия киленнең өлгерлеге бар икән, тиз арада табын әзер булды.

– Әйдәле, – диде килен ягымлы тавыш белән, – җайлап кына утыр. Сыйлан. Юкса килгәнеңә атна инде, рәтләп кунак иткәнебез дә юк үзеңне. Дөнья мәшәкате белән көннәр уза да китә.

– Кхм, кхм, – диде Суфиян агай, – атна ук уздымыни инде? Мин тагын наданлыгым белән өч кенә көн кунак булдым дип йөрим. Шәһәрдә вакыт машинага утырып чаба, диләр иде, дөрестер, күрәсең.

Килене аның төрттереп әйткән сүзләренә үпкәләп тормады. Өстәлдәге ризыкларны каенатасының алдынарак этеп, кыставын дәвам итте:

– Җитеш әйдә, җитеш. Тартынып утырма. Син яраткан авыл токмачы пешердем. Камырын күкәйгә генә бастым. Авыл ашларын сагынгансыңдыр. Ашказанына авыр димәсәң, итләренә дә үрелгәлә. Иң әйбәт, симез җирләрен салдым.

Килен өстәлнең нәкъ уртасына совет заманыннан сак-ланып калган һәм ул чорда бәясе туксан тиен торган кызыл аракы китереп утыртты. Ул шешә кайлардадыр яшеренеп ятканлыктан, өстенә ябыштырылган кәгазе пычранган иде. Килен шешәне чиләктәге суга тыгып чыгаруга, ябыштырылган кәгазь юешләнде. Аны кубарып ату кыен булмады. Озак сакланганлыктан, шешә төбенә комга охшаган нәрсә утырган иде, әмма хәйләкәр килен монда да җаен тапты. Бервакыт Айратның начальниклары боларга кунакка килергә җыенгач, тартмага салынган затлы коньяк алып кайткан иде Суфия. Коньяк салынган ялтыравыклы кап ташланмаган икән, Суфия теге болганчык сыекча тутырылган шешәне шул капка тыгып, өстен ябыштырып куйды.

– Менә, әткәй, син килүгә дип бер коньяк алып кайтып куйган идем. Һаман шуның белән үзеңне сыйларга онытабыз. Бүген менә искә төште. Рәхим итеп сыйлан әле, әткәй.

Суфиян ага бер килененә, бер шешәгә карап:

– Син, килен, бик зурлап җибәрдең әле, – диде. – Алай ук кирәкмәс иде. Мин бит сездән мондый сый-хөрмәтләр өмет итеп килмәдем. Миңа якты йөз белән ипи-тоз җиткән. Шулай да дөресен әйтим: зурлавыңа күңелем булды. Рәхмәт, рәхмәт. Югыйсә әллә нинди шайтаный уйлар күңелне тырный башлаган иде.

Килен, еш-еш сәгатенә карап, картны кыстады:

– Бераз салып куй инде, әткәй. Утырма кыстатып.

– Рәхмәт, килен. Син мине артык кыстама. Һәммәсенә җитешеп утырам. Бу нәмәстәкәеңне бөтенләй алып куй.

Килен һаман саен кыстагач, ул ялтыравыклы кап эченнән шешәне тартып чыгарды. Бераз селкеткәләп карады. Селкеткәч, шешә эчендәге сыекча болганчык төскә керде.

– Коньяк... – диде ул, авыр сулап. – Хәзер кешене ничек кенә алдамыйлар. Алдаганнар сине, килен. Коньяк түгел бу.

Суфия нишләргә белмәде. Аракы сатучыларны сүк-те:

– Кулаклар, күпме акчамны түләп алдым бит. Акчасы да жәл түгел, синең алдыңда оятка калдым, әткәй. Айрат белсә үтерә инде мине.

– Ә без аны беркемгә дә әйтеп тормабыз, килен. Конь-ягы да, бусы да агу инде аның.

– Агу дип тормыйдырыегыз, эчә идегез бит әле. – Киленнең ни өчендер ачуы чыкты. Каенатасының фәл-сәфә сатып утыруы саруына тигәндер, ахрысы.

Суфиян карт кесәсеннән биш йөз сум акча чыгарып килененә бирде:

– Оныкка бирәр нәрсә алырсыз.

Килен кешенең йөзе ачылып китте. Шулай да ул:

– Юк, әткәй, безнең үз кирәгебезгә тотарлык акчабыз бар. Ә моны кире үз кесәңә салып куй! – дип әйтерлек көч тапты.

– Ярар, минем кулдан алырга теләмәсәң, менә монда салып куйыйк без аны. – Суфиян акчаны клеёнка астына тыкты. Карт икенче якка караган арада, акча Суфия кулына күчкән иде инде.

Ата кеше, улы кайтып җитмәсме дип, шактый гына озак ашады. Ниһаять, улы кайтты. Айрат үпкә-бавырлардан пешерелгән бәлешне бик ярата. Әтисе кунак-ка килүгә, ул хатыны Суфияга: «Бүген мин эштән кай-туга, бәлеш пешер», – дигән иде. Суфия, үпкә-бавыр ише нәрсәләрне яратмаганлыктан, аларны, кеше-кара күрмәгәндә, чүп-леккә чыгарып атты. Айрат, әтисе белән мәш килепме, бәлеш турында әллә оныткан, әллә, исендә булып та, бу сүзне олы кунак китүгә калдырган иде. Һәрхәлдә, үпкә-бавыр бәлеше хакында сүз кузгалмады.

Суфиян килене пешергән ашларны яратып ашады. Кабыргаларны хәтта кимерә-кимерә сыйланды. Килененең сөяк кимергән кешене яратмавын белми иде ул. «Эт нәселе, – ди иде Суфия Айратка, ачуы килгәндә. – Сөяк кимерәсез, тәлинкә ялыйсыз. Сезнең янда утырып ашарга да оят».

Әлбәттә, Айрат кайтканчы теге хикмәтле «коньяк» юкка чыккан иде. Хәер, эчемлеккә хирыслыклары булмагач, аны искә алучы да булмады. Суфия гына каенатасына:

– Соңга калмыйсыңмы, эткәй? – дип пышылдап алды.

– Кайгырма, килен. Мин бит җиде ел солдатта хезмәт иткән кеше. Киемем – өстемдә, билетым – кесәдә. Ялт чыктым-киттем.

– Син тагын, эткәй, куа дип уйлый күрмә. Күпме торсаң да, без шат кына.

– Юк-юк, килен. Мин берни дә уйламыйм. Кунак өчен хуҗалар кайгыртып торганда, нигә әле мин андый ямьсез уйлар уйлыйм.

Киленнең барыбер күңеле тыныч түгел иде. Әрле-бирле кыбырсынып йөри башлады. Ул арада каядыр чыккан җиреннән Айрат та кайтып керде. Суфия, очынып, ире каршына килде:

– Әткәй билет алган, – диде Суфия, йөзенә борчылу билгеләре чыгарып.

– Шулаймыни? – диде Айрат һәм этисе янына чыкты. – Билет алдыңмыни, эти? Торырга идең әле бераз.

– Әйе, – дип, иренең сүзен куәтләде килен, – җәй бар, кыш бар – ашыгып ни эш бар, диләр түгелме соң?

– Ашыкмый ярамый, балалар, – диде Суфиян карт. Ул малае белән килененең җанга ятышлы сүзләреннән бик канәгать иде. – Күпме ятарга була өй саклап? Көне буе чекерәеп каршыгызда утырсам, үзегез дә туяр-сыз...

– Юкны сөйләмә, эткәй, әллә нигә бер килеп, нинди тую ул? – Суфия, каенатасының сүзләренә рәнҗегән кебек, иреннәрен бүлтәйтте. – Син безне якын итмисең, эткәй. Килеп җитмисең, ашыга башлыйсың. Күрми дә калабыз үзеңне.

– Йөрисе җирләр күп бит, балалар. Зоопаркны, музейны карап чыгасы бар. Килгән-килгән, Камал театрына да сугылырмын дип торам. Билетын табып булса, операсына барсаң да мишәйт итмәс иде...

– Ни сөйлисең син, эткәй? – диде килене, һични аңламыйча. – Әллә исердеңме?

– Чәйдән исерә торган гадәт юк иде анысы.

– Алайса, нинди опера, нинди Камал театры турында лыкылдыйсың?

– Соң, «нинди» дип, Казанда Камал театры да, Опера театры да бер генә түгелме соң? Шуларны күрәсе иде дим. Ялан-ялан Казанга килеп йөреп булмый.

– Ә поездга алган билетың нишли?

– Ә-ә, сез аның өчен борчыласыз икән, – диде. – Курыкмагыз, мин әле сездән тиз генә китәргә җыенмыйм. Килгән-килгән, торам әле. Менә бүген циркка барам. Аннары театрларга йөрим... Әйе, әйе, китә икән бу, дип борчылмагыз... Тиз генә китәргә ният юк әле, балакайлар. Картаеп барабыз бит, яңадан әллә килеп була, әллә юк. Менә быел әнкәгезне дә апкилмәкче идем. Билен кузгатты. Килә алмады. Килә алмавы өчен сез аны кичерегез инде.

Каенатасының бу сүзләреннән соң Суфияның күз аллары караңгыланып китте. «Һай, башым!» – дип караватка аварга торганда, этиләре чыгып китте. Ул, мыек астыннан елмаеп:

– Борчылмагыз, балалар. Тиз генә китмим әле мин! – дип, ишекне япты.

Өйдә үле тынлык урнашты. Бу давыл алдыннан була торган тынлык иде.

## САРА ТҮТИ ШӘҺӘРГӘ БАРА

Маллар көтүгә йөрүдән туктап абзарга кергәч, җир өстенә кара ипигә ягылган ак май кебек ап-ак кар яткач, суеласы сугымнар суелып, түшкәләр келәткә урнаштырылгач, чистартылган эчәгеләр, үпкә-бавырлар аерым бауларга эленгәч, Сара түти шәһәргә барырга җыена баш-лый. Өйдәге байлык-бәрәкәт аның күңеленә нинди-дер бер олылык, канәгатьлелек хисе бирә. Шушы канәгатьлек хисе Сара түтинең күңелендә генә калмыйча, бөтен йөзенә чыга, йөрешенә, хәрәкәтенә күчә. Ул инде башка вакытлардагы кебек кабаланмый, адымнары үз дәрәҗәсен яхшы белгән кешеләрнекедәй салмаклана.

Шәһәргә бару Сара түти өчен олы бәйрәм, хәзинәңдә булган байлыгыңны балаларың белән уртаклашудан да күңеллерәк нәрсә бар соң бу дөньяда?!

Ә Казан каласында Сара түтинең кызы, кияве яши. Тату, күркәм яшиләр. Берсеннән-берсе матур ике бала үстерәләр. Өйләренең бусагасын атлап керүгә, ул балалар, атылып килеп, әбиләренең кочагына ташланалар. Чулт-чулт әбиләрен үбеп алганнан соң: «Әбекәй, тәмле жевачка апкилдеңме?» – дип, кайнар боткалы тәлинкәне әйләнеп йөргән мәче балаларыдай, карчык тирәсендә бөтерелә башлыйлар.

– Апкилдем, балалар, апкилдем, – дип, капчыгын чишеп җибәрә Сара түти һәм аннан пөхтәләп ак кәгазьгә төрелгән рамлы бал тартып чыгара. – Мәгез, балалар, рәхәтләнеп ашагыз, бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

Сара түти һәркемнең нәрсә өчен үлеп торуын белә, шунлыктан кирәкмәс чүп-чар төяп йөрми. Кияве аның әз генә тоз тәме сеңгән каз итен, аннан да бигрәк каз-ның бүтәкәләрен ярата. Казларын суйгач, Сара түти бүтәкәләрен һәрвакыт аерым җиргә куя. «Мәче-мазар урламасын, башка мал эчәгеләре белән бәлешкә туралмасын», – ди. Ә инде киявенә алып барасы казларга килгәндә, аларын ул, китәргә ике көн кала, тәменчә генә итеп тоз белән уа да чормада үтәли җилдә тота, юлга чыгар сәгате җиткәч кенә, чормадан алып төшә. Каз бүтәкәләрен исә бүтән әйберләрдән аерым, умарта эченә яба торган прополис сеңгән киндергә төрә. Аның белән төрелгән ит җәйге челләдә дә берничә көн яңа суйган кебек саклана, тәмен җуймый. Ә бүтәкә ише нәрсәгә бозылырга күп кирәкмени?

Сара түтинең шәһәргә барырга җыенуын ишетүгә, күрше-тирәләре агыла башлый:

– Җиңги, минем менә шушы кечкенә төенчегемне балаларга илтеп бирә алмассың микән? Дөнья куып, үзебез барырга вакыт тапмыйбыз.

– Илтермен, аяк-кулым исән чакта нигә илтмәскә? – ди Сара түти, авырсынмыйча.

– Берүк гаеп итмә инде, җиңги. Беләм, үзеңнең дә күчтәнәчләрең күптер. Дөньялар матур, ризыклар мул. И-и, онытып торам икән, җиңги, син бит: «Кызым кара бөрлеген вареньесын бик сагына», – дигән идең. Бер банка кара бөрлегән вареньесы апкергәнием. Быел үзең бөрлегәнгә йөри алмадың бугай. Кызыңа бездән күчтәнәч булыр, борын кычытмаслык кына...

Әйе, Сара түтинең кызы мәтрүшкәле чәйне кара бөр-легән вареньесы белән эчәргә ярата. Бала чакта ашап-эчеп үскән ризыкларның тәме күңелдән китмидер, күрәсең.

– Рәхмәт, килен. Үзем быел бөрлегәнгә йөри алмадым шул. Былтыргы вареньем барые барын. Тик бераз шикәрләнә төшкән. Кызга синең күчтәнәч икәнне әйтеп бирермен, Алла боерса.

Сара түтинең йомшак сүзләреннән кыюланып киткән хатын, кечкенә дигән төенчеген чишеп, әйберләрнең кайсын кемгә бирергә икәнлеген аңлата башлый:

– Үрдәкне, аннары менә бу оек кунычындагы кипкән җиләкне малайга илтерсең инде, җиңги. Бик еш салкын тидереп интегә. Җиләк кайнатып эчсә генә рәтләнә. Ул, үзең беләсең, институтта укый. Упшежитиясенең адресын аталары язып үрдәк эченә тыкты. Ә менә монысы – сарык ите, врачлыкка укыган кызга. Ит янына әз генә төш пешереп салдым. Шунда кызлар белән бергә-бергә чөкердәшеп чәй эчәрләр. Берүк, җиңги, һәркайсыныкын үз кулына тапшыра күр инде. Оят булса да әйтим: бер-берләре белән йөрешмиләр. Әллә кая куеп, ризыкларын әрәм итеп яткырмагайлары дим.

Бу хатын чыгып китүгә, аюдай алпан-тилпән басып, икенче күрше – Җәмилә әби килеп керә. Казанда Җәмилә әбинең малае тора. Күптәннән бирле яши инде. Җәмилә әбинең сөйләвенә караганда, зур гына урында эшли бугай. Дәрәҗәсе төшүдән куркамы, авылларына кайтмый. Җәмилә әби шәһәргә баручы һәр кеше артыннан улына-килененә күчтәнәч җибәрә. Былтыр аларга Сара түти бер банка сөт өсте илткән иде, быел тагын Җәмилә карчык яңа аерткан каймак күтәреп кергән:

– Син, Бибисара, малайларга минем сыер юклыкны әйтмә инде, яме. Борчылмасыннар. Үзебезнең сыерның каймагы дип ашасыннар.

– Тыныч бул, Җәмиләттәй, әйтмәм.

Сара түти самавыр тергезеп җибәрә, өстәлгә төрле-төрле тәм-том куя. Җәмилә әбинең чәй эчеп утырган җиреннән кинәт йөзе яктырып китә.

– Аягың-кулың сызлаусыз булсын, Бибисара, бик саваплы эш эшлисең. Былтыр шулай, тамагымнан аш үтми ятканда, син кайтып төштең дә: «Улың-килөнең җибәрде», – дип, балаларның күчтәнәчләрен өстәлгә тезеп салдың. И ул лимоннарның исләре! Ул тәмлелекләре! Шуннан соң гына авызыма тәм керде. Малайларның тормышын үземнең дә бер күреп кайтасым килә килүен. Чыгып китәргә йөрәк җитми. Син, ичмасам, Бибисара, урысчаны су кебек эчәсең. Безнең ише тел белмәгән кешегә читкә чыгып китүләре кыен шул.

Сара түтигә кая инде урысчаны су кебек эчү! Бөтен белгәне «знакум» да «ычпачиба». Ел саен юл йөргәнлектән генә ул һаман үткерләнә бара. Хәзер инде, беренче еллардагы кебек, урысча эндәшсәм көләрләр, татарча әйтсәм аңламаслар дип аптырап тормый, поездан килеп төшүгә, кырыйларына шакмак сурәте ясалган машиналар янына ашыга.

– Знакум, вәт тибә әдрис, – дип, таксистның кулына эре, аңлаешлы итеп язылган адресын тоттыра да, «әйдә пашул»ын әйтеп, алгы утыргычка кереп утыра.

Таксистка түләргә дигән акчаларын ул, алдан ук берлекләргә ваклатып, ике як оек кунычына кыстыра. Болай итүнең үзенә күрә сәбәбе бар. Сара түти иң башта бер оек кунычындагы акчаларны (ә анда өч тәңкәдән артык булмый) чыгарып бирә, әгәр таксистның йөзендә канәгатьсезлек билгеләре чалынмаса, «ычпачиба»сын әйтеп,

тиешле урында төшеп кала, ә инде әзсенеп чыраен сытса, икенче оек кунычыннан яңа берлекләрне алып өсти. Ләкин һичбер вакытта сатулашмый. Акчаның кергәненә дә, чыкканына да сөенеп яши белә ул.

Әлбәттә, кызларына алдан ук хәбәр итсә, һич авырсынмыйча каршы алырлар иде. Юк, хәбәр салмый Сара түти, кешене мәшәкатьләрмен дип коты оча. Аның күңеленә иң зур рәхәтлек бирә торган нәрсә: балалары көтмәгәндә килеп төшеп, тегеләрне чиксез шатландыру. Яхшылык эшли икән, ул инде кеше кулы белән эшләми.

Былтыр да, Җәмилә әбинең күчтәнәчен илтер өчен, күне буе Казан урады Сара түти. Юкса кызы: «Әйдә, бергә эзлик», – дип караган иде. Әллә кайда Горки посёлогында, урман буендагы галәмәт зур йортта яшиләр икән Җәмилә әбинең малайлары. Казанның бу тирәләрен Сара түтинең бөтенләй күргәне юк иде әле: исе китеп таудай дәү йортларга карап торды ул, аннары гына кирәкле фатирның ишеген какты. Ишек артында кемдер тупас тавыш белән:

– Вам кого? – диде.

Әллә русча эндәшүдән, әллә озак вакыт ишек ачылмаудан каушап, Сара түти:

– Знакум, знакум, – дип, кабат ак кнопкага басты. Шуннан соң гына өчәр кат борып бикләнгән ике йозак ачылды, шуннан соң гына Сара түти үзе белән сөйләшкән кешенең йөзен күрә алды. Бу унсигез яшьләр тирәсендәге бер егет иде.

– Знакум, – диде Сара түти, каушавын һаман баса алмыйча, – гәчтинче апкилгәнием, Кызыльярский дерев-нясенең Җәмилә әби малайкасы Фатих здис живётме?

Егет Сара түтигә акаеп карады да этисенә кычкырды:

– Пап, выйди-ка, тут какой-то интересный экземпляр. Что-то бормочет, не пойму.

Фатихны Сара түти шунда ук танып алды:

– Ай-яй ерак торасыз икән. Менә, улым, әниегез каймак җибәргәние. Төенчегендә тагын нидер бар бугай, чишеп карамадым. Ачый башлаганчы китерим дидем.

Ул күчтәнәчен Фатихның кулына тоттырды.

– Монда кешене ач яши дип беләләрме, – дип мыгырданды Фатих. – Хотя бы приличныйрак упаковкага салсыннар иде. Иске яулыкка төреп җибәрәләр...

Сара түти «упаковка», «приличный» сүзләрен төшенеп җитмәде. Шулай да Фатихның чыраена чыккан мән-сезлеккә үзенең ризасызлыгын белгертми кала алмады:

– Анда әниең сагына сине. Ичмасам, бер кайтып хәлен белер идегез. Картайды бит инде, мин киткәндә: «Авызымның тәме юк», дип калды. Дөньяныкын белмәс-сең...

– Барыбыз да картаябыз, – диде Фатих һәм шартлатып ишеген ябып кереп китте.

Үз гомерендә бер генә кешене дә чәй эчермичә чыгарып җибәрмәгән Сара түтинең йөзенә төкерделәрмени. Шундый хурланды, хәтта тез буыннары калтырый башлады.

Билгеле, ул аларга сыйланырга дип килмәде. «Керермен, тормышларын күрермен. Кайткач, Җәмиләттәй сорашмый калмас, бөтенесен истә калдырырга кирәк», – дип уйлаган иде. Баксаң, әнә ничек килеп чыкты. Хәзер ул: «Улың бик тупас икән, өйләренә дә кертмәде...» – дип сөйләсенме? Юк, Алла сакласын...

Сара түти, авылга кайтканда, базарга чыгып берничә лимон һәм өрек җимешләре алды. Дөрес, күчтәнәчне үзенең кызы-кияве дә күп итеп төядeләр, ләкин ул аларга да:

– Менә бу лимоннарны Җәмиләттәй малае китерде, – диде, чөнки Фатихны яманатлы итеп күрсәтәсе килмәде.

Авылга кайткач, ул иң беренче Җәмиләттәйләргә керде. Җәмилә әбинең:

– Фатихларым ниндирәк җирдә торалар? – дип соравына ул:

– Галәмәт зур йортта торалар. Бер якларында – урман, икенче якларында бер-берсенә безнең авыл сыярлык ташпулатлар тезелеп киткән, – дип сөйләнде.

– Тормышлары ничек соң, Бибисара? – дип төпченде Җәмилә әби. – Бөтенлек белән яшиләрме?

– Бик әйбәт, бик мул яшиләр.

Ялганлау дигән нәрсәне белмәгән Сара түти өчен Җәмилә әбинең һәр соравы газап иде, шунлыктан ул:

– Күчтәнәч таратасы кешеләрем күп иде, – дип, чыгып китү ягын карады.

Быел тагын Җәмилә әби пенсия акчасына кемнәндер каймак сатып алган.

– Берүк малайга сыерым юклыкны ычкындырма, Бибисара, борчылмасын, – дип, ничәнче кат инде Сараның колагына киртләде.

«И изге җанлы ана! Үз күңелең гел яхшылыкта булгач, башкалар күңелендә мәрхәмәтсезлек бардыр дип уйламыйсың шул син. Һаман балаңа артык борчу ясамагаем дип кайгырасың. Ә алар...»

Җәмилә әбине авыр уйлар белән озатып калды Сара түти. Билгеле, ул Җәмилә әбинең гозерен үтәячәк. Бәлки әле, Фатихы да былтыргы тупаслыгы өчен үкенеп йөридер. Адәм баласының нинди чагы булмый. Барыр Сара Фатихларга, һәркемгә үз хатасын төзәтергә җай тудырырга кирәк.

Җәмилә карчыкны озатырга чыккан җиреннән, бер малайны туктатып:

– Үскәнем, бар әле, йөгереп кенә Мәскүрә апаларыңа барып кайт. Сара түти Казанга китәргә җыена, диген. Күзлек таба алмый йөри иде бугай. Күзлеккә дигән язуын китерсен, – диде.

Малай чаптырып китеп барды. Сара түтинең йомышын үтәү малайлар өчен зур мәртәбә. Умарта караган саен, ул аларны тәмле бал белән сыйлый. Бакчасында кыярдыр, кишердер өлгерә башласа, иң беренчесен өзеп аларга бирә. Кара борынлы малайларның шатлыктан елтыраган күзләрен күрү, куян кебек керт-керт кишер кимерүләрен карап тору җанына рәхәтлек бирә аның.

Озакламый күзлеккә дигән язуларын күтәреп – Мәс-күрә, Мәскүрә артыннан Мәгъсүмә килеп керде.

– Өең өчен, мал-туарың өчен борчылма, – диделәр алар, берсен берсе бүлдереп. – Үзебез карарбыз. Сыерыңны үзем савармын.

– Ә нигә син? – диде Мәскүрә, илле яшьлек сеңлесен кечегә санап. – Монда синнән олырак апаң барын онытма.

– Булса соң! Бәлки, минем савасым киләдер Сараттәйнең сыерын, – диде Мәгъсүмә, бирешергә теләмичә.

Мәгъсүмә Сара түтине аеруча ихтирам итә иде. Өченче ел Мәгъсүмәләрнең тугыз яшьлек төпчек малайлары велосипедтан егылып аягын сындырган иде. Район врачлары маташтылар-маташтылар, тик сөяк кыек ялганды. Малай аксаклап йөрде. Аксавына, бәлки, күнеккән дә булыр иде, авыртуы басылмады. Әти-әниләре Казанга илтергә бик тырышып караганнар иде, район врачлары нигәдер язу бирмәделәр. Шуннан соң Сара түти:

– Малаегызны үзем алып барып карыйм әле, минем кияү «скурый пумыщ» машинасында шуфир бит, әйбәтрәк врачларга күрсәтмәсме? – дип, малайны калага алып китте.

Ике ай дигәндә малай, аягы бөтенләй сынмаган шикелле, дөбер-шатыр чабып йөри иде инде. Шуннан бирле Мәгъсүмә Сара түтигә нәрсә дә булса эшләргә атлыгып кына тора. Казанга китә башласа, таң тишегеннән уятып, сөт машинасында эшләүче малаен Сара түтиләргә җибәрә:

– Кара аны, бик каты селкетеп апбарма. Поездына утыртышмыйча кайтып китмә, – дип, күрсәтмәләр бирә. Ә үзе, Сара түти шәһәрдән әйләнеп кайтканчы, аның хуҗалыгын гөл итеп тота: ишегалларын себерә, миченә яга, идәннәрен юып чыгара, малларын карый.

Сара түти, өе өчен пошынмыйча, кызларында җаны теләгәнчә кунак була. Авылдашларының йомышын үтәп йөри. Берәрсе аңа:

– Әйбереoriginаль бигрәк күп инде, ничек алып барырсың? – дисә, ул:

– Поезд тартыр әле, – дип кенә җавап бирә. – Мин нәчәлник кебек йөрим бит. Кая барма, йомшак машина, стакан белән чәй эчеп барсаң, шул да түгелмәс. Авыл карчыкларын тәксиләр бик ярата. Капчыгың барын күрсәләр, шып туктыйлар. Эшләгәндә эшләдек, хәзер йөреп калыйк. Хәзерге заманда юл йөрүнең кыенлыгы юк аның, – ди.

Быел аны Мәскүрәнең олы малае яңа «Жигули»да озатып куйды. Сара түти, йомшак машинада изрәп, Бөгелмә вокзалына килеп җиткәнен сизми дә калды.

– Энем, – диде ул, поездга утырганда, – түбән оч Сәлим хатыны ниндидер дару табалмый иде бугай, язуын китереп җиткерә алмады, кызларымның әдрисенә салсын, яме. Барып әйт.

– Ярар, әйтермен.

Пыш-пыш итеп, поезд кузгалып китте. Тәгәрмәчләре һаман саен ешрак: «Сара түти шәһәргә бара, Сара түти шәһәргә бара», – дип тукылдый башладылар. Сара түти, үзе дә сизмәстән, тәгәрмәчләр җырына кушылды.

## КОЛХОЗ УМАРТАЛЫГЫНДА

Умарталыкның бер ягында тау, икенче ягында юкә урманы. Тау кортлар шәһәрен көчле җилләрдән саклаcа, юкәлек нечкәбилләрнең туену һәм бал җыю урыннары. Ә урманнан ерактарак карабодай кыры җәелеп китә. Ул, җәй көннәрендә ап-ак чәчәккә күмелеп, бал кортларын еракtan ук үзенә дәшеп тора. Беркем планы буенча да төзелмәгән, ә табигатьнең очраклы бүләге булган бу ышык култык чынлап та бик матур. Тау башына менеп карасаң, аның гүзәллеге тагын да ачыграк күренә. Бер-берләреннән аз гына ара калдырып рәт-рәт итеп тезеп утырткан умарталар югарыдан караганда кечкенә бер шәһәрчекне хәтерләтә. Ә бераз читтәрәк ак шифер белән ябылган умартачы келәте. Умарта араларыннан сузылган тар сукмаклар барысы да шушы келәтнең ишек төбендә бергә тоташканнар. Умартачының бу өе күп юллар чатында утыручы вокзал төсле. Аерма бары шунда гына: бу

вокзалдан сузылып киткән юлларда бернинди хәрәкәт юк. Бары тик умартачы Хәлим картның киң читле ак эшләпәсе генә күренеп киткәли.

Менә бүген дә, кояш көмеш чыбыкларын агач башларына суза башлау белән, Хәлим карт үзенең кечкенә вокзалыннан кортлар шәһәренә юнәлде. Кортлар тыныч күренә. Күбесе әле төнге йокыларыннан тормаганнар, ә кайберләре инде иртәнге физзарядканы ясарга – урманны әйләнеп кайтырга өлгергәннәр. Алар, ботларына саргылт сыекча йоктырып, өйләренә кереп баралар. Хәлим карт һәр көнне, иртүк торып, умарталыкны бер урап чыга. Сак кына колагын куеп, бал кортларының тавышын тыңлый. Көндезгелек өчен кортларның кереп-чыгып йөрү ишекләрен зуррак итеп ачып куя. Әгәр берәр умартада кортлар башкачарак гөжләсә: «Бу бүгеннән дә калмас, аерыр», – дип, ул умартаны билгеләп китә. Һәм көне буе ул аны күзәткәләп йөри. Унике ел шушында эшләү дәверендә Хәлим карт бер генә күчне дә читкә җибәрмәде.

Умартачы көндәгечә кортлар шәһәрчеген әйләнеп чыкты. Бүген сигез умартаны «шикле» дип тапты ул һәм алдан ук күчләрне яңа урынга ябу хәстәрлеген күрә башлады. Буш умарталарны янә бер кат карап, әз генә пычрак күренсә дә чистартып чыкты. Күчне җыяр өчен җиңел тубаллар да, ябар өчен яңа умарталар да әзер булуга карамастан, Хәлим картның күңеле тынычланып җитмәде. Чөнки бервакытта да болай сигез умартаның берьюлы аерганы юк иде. Өстәвенә аның иң якын ярдәмчесе, карчыгы Зәйнәпбикә дә кичә кич авылга кайтып киткән иде. Дөрес, кортларны аертмаска теләсәң, аерасы ояның карт аналарын гына алып ташлап була. Ләкин бер куышта шулкадәр эш корты калдыру файда китерми, киресенчә, алар бер-берләре белән сугышып кына бетәләр. Шуңа күрә, үзенә бераз кыенгарак килсә дә, тәҗрибәле умартачы күчләрнең аерылуына комачауламаска булды.

Кояш урман өстеннән югарырак күтәрелеп, көн кыздыра башлау белән, рәттән утырган ике умарта берьюлы гөжләргә тотынды. Яшь кортлар үзләренең кечкенә өйләренә генә сыеша алмыйча, пулемёттан сиптереп торган пулялардай атылып-атылып тышка чыктылар һәм, торган йортларын ташлап чыгып китәргә батырчылыклары җитмичә, бертуктаусыз шул тирәдә бөтерелделәр. Ләкин бала кортларның бу бөтерелүләре озакка бармады, умартадан аналары очып чыгу белән, алар һәммәсе бер тирәдәрәк тупландылар һәм бераз читтәрәк үсеп утырган юкә агачына килеп сардылар. Хәлим карт икенче күчнең дә кая сарганын көтеп торды да, кулына тубал алып, битенә челтәр битлек киеп, күчләрне җыярга китте. Җыйган күчләрне яңа умарталарга ябып торырга вакыты тар иде, шуңа күрә Хәлим карт аларны шул тубаллары белән генә үзенең келәтенә, кояш төшми торганрак почмакка куйды да бүтән умарталары янына китте. Кортлар бер-бер артлы аера тордылар. Кайбер күчләр – ераккарак, икенчеләре якынга гына сарды. Хәлим карт һәрберсен эзләп табып, тиешле урынга җыеп тутыргалый торгач тирләп чыкты. Ә кортлары тир исен бер дә яратмыйлар, шуңа күрә үзләрен кадерләп җыючыны усал-усал итеп чаккалый башладылар. Карт умартачының бармак очлары шешенеп китте, ләкин ул аңарга әһәмият бирмәде, һаман эшендә булды.

Менә, ниһаять, эш бетеп бара. Җиде тубал күч җыеп алынды. Хәлим карт та тынычланып киткәндәй булды. Ул тирдән юешләнеп, аркасына сыланган күлмәген салып ташлады. Тәнен сулы сөлге белән сөртеп, чиста күлмәген киде. «Хәзер күчләрне яңа йортларга күчерә башласам да ярар. Кортлар да кешеләр төсле, алар да, ишәя башласа, башка чыгалар, – дип уйланды ул. – Ләкин нишләп соң әле теге сигезенче умарта аермады? Әллә соң иртән ялгыш ишеттемме икән? Бер дә ялгышмый торган идем бит, колаклар начарлана башладымы әллә югыйсә? Шулай да ул умартаны карарга кирәк. Кортлар көн кызуында аеручан була. Ә хәзер көн сүрелеп бара бит. Әллә инде аерганын мин күрми калдыммы?»

Карт умартачы, борчылып, үзе иртән билгеләп киткән умарта янына килде. Кортлар бераз гадәттәгедән күбрәк күренсә дә, һәрхәлдә, бу аерырга маташу түгел.

«Чынлап та, күч аерылып чыккан булырга тиеш, – дип уйлады Хәлим карт. – Тегеләре белән мәшәләнеп абайламый калганмындыр. Хәзер эзләп табарга кирәк».

Һәм карт, иртән дә, көндез дә ашамаган булуын онытып, кирәкле коралларын алды да югалган күчне эзләргә китте. Башта якын-тирәдән агачларны карады. Ләкин корт сарырдай агачларның берсендә дә күч күренмәде. Күрәсең, төтеннән куркып ераккарак киткәннәрдер. Карт умартачы урман эченәрәк керде. Һәр агачны җентекләп карап йөрде. Тик эзләгән нәрсәсен генә таба алмады. Шулай каңгырып, кая барырга белми торганда, аның каршысына авылдашы Сәмигулла килеп чыкты. Сәмигулланың кулында нечкә талдан тыгызлап үргән кәрзин иде. Хәлим картны күргәч, Сәмигулла туктады һәм сөйләнә башлады:

– Нәрсә син агач башлары санап йөрисең? Эшләпәңне карга алып киткән дияр идем, башыңда күренә. Әллә берәр кош оясы мутарга йөрисеңме?

Хәлим картның Сәмигуллага ачуы килде.

– Юлыңда бул, – диде ул кырыс кына. – Мин, агач башлары санасам да, үз эшемдә. Ә менә син уттай эш өстендә нишләп йөрисең? Бөтен кеше болында, печән чабуда бит.

– Мин дә печән чабарга килдем.

– Колхозның болыны монда түгел иде шикелле.

– Колхозныкы булмаса, минем болыным монда. Минем сыерыма да печән кирәк бит.

Шулай сөйләнеп торганда, Сәмигулланың кулына тоткан кәрзиненнән бер бал корты бызылдап очып чыкты. Хәлим карт моңа шунда ук игътибар итте.

– Кәрзинеңдә нәрсә ул? – дип сорады.

– Ә-ә, – дип сөйләнеп китте Сәмигулла, – бирермен дигән колына чыгарып куяр юлына, ди бит. Менә печән чабарга килгән җиремнән бер күч тоттым. Ярый әле карчык әбитне кәрзингә салып җибәргән, юкса ул күчне кая куйган булыр идем. Ике умартам буш ята иде, бик шәп булды әле бу. Берсенә тагын Ходай бирер.

– Колхоз күче бу, – диде Хәлим, – мин кайчаннан бирле шуны эзләп йөрим, рәхмәт җыеп китерүеңә.

– Син, Хәлим кордаш, шаярма әле. Урманда нинди колхоз күче булсын? Кыргый умарта аергандыр.

– Безнең як урманнарында кыргый бал кортлары юк. Умарталыктан ике адым җир генә бит, үзең дә күреп торасың.

– Артыгын кыланма инде, – диде Сәмигулла. – Колхозныкы булса, көнгә ничә умарта аерганны кем белә. Монда бит эт тә килми.

– Менә мин беләм, – дип, умартачы Сәмигулланың кәрзиненә үрелде.

Ләкин тегесе шунда ук кулын тартып алды да китә башлады. Хәлим карт аның каршысына килеп басты:

– Күчне бирмичә беркая да китмисең. Умартам буш дип, син колхоз кортларын алып кайтып япсаң, келәтем буш дип, игенчеләр колхоз икмәген ташыса, колхозның нәрсәсе генә калыр иде?

– Ярый, мин киттем, – диде Сәмигулла, – бер күче ким булганнан гына колхоз ярлыланмас. Көз көне үземә чәй эчәргә килерсең. Югыйсә, умарталыкта торып, шикәр белән чәй эчеп ятасыңдыр. Зәйнәпбикә апага миннән сәлам әйт. Хуш!

– Тукта! – дип кычкырды Хәлим карт. Ачудан аның сакаллары дерелди башлады. – Беркайда эшләми ун умарта тотуың гына җитмәгән, инде колхоз милкенә үрелә башладыңмы? Минем белән генә исәпләшмәсәң, әнә председатель белән сөйләшерсең...

– Әллә, оялмыйча, шуны кайтып председательгә сөйләп йөрер иденме? Үзеңнән генә көләчәкләр. Төймәдән дөя ясап йөргәнче, кайтып ял ит, йә җаның чыгып китәр.

– Яхшылык белән бир, – диде умартачы.

– Яхшылык белән юлымнан кит, – диде Сәмигулла.

– Бир!

– Кит!

– Бир!

– Кит!

Ләкин берсе дә чигенергә теләмәде. Хәлим картның болай гына китмәвен күреп, Сәмигулланың җен ачулары чыкты.

– Мә, кортларыңны башыңа капла! – диде ул һәм күч тутырылган кәрзинне умартачының башына кидерде. Кәрзин авызын бәйләгән яулык та чишелеп китте һәм Хәлим картның бөтен битләрен, муеннарын, күзләрен кортлары сырып алды. Ул, көч-хәл белән башыннан кәр-зинне салып, җиргә ташлады һәм битендәге кортлар-ны сыпырып төшерде. Ләкин ачулары килгән кортлар аның саен зәһәрләнебрәк чактылар. Хәлим картның күз-гә күренеп битләре, күз кабаклары шеште. Аның инде шешкән күз кабакларын да күтәрер хәле калмады, ул хәлсезлектән һәм авыртудан җиргә капланып ятты.

Сәмигулланың үз хәле дә Хәлим картныкыннан ким түгел иде. Ул, умартачыны кортлар сырып алу белән, куркып читкә йөгерә башлады. Әмма ачулы бал кортлары аны бик тиз куып җитте һәм, бер дә кызганмыйча, укларын Сәмигулланың симез, йомшак тәненә батыра башладылар. Ул куллары белән селтәнде, чәбәләнде, ләкин барыбер алардан котыла алмады. Ахырдан ул, авыртуга түзә алмыйча: «Үтерәләр, коткарыгыз!» – дип кычкырырга тотынды. Ләкин аның тавышын беркем дә ишетмәде. Бары үз тавышы гына кайтаваз булып әйләнеп кайтты. Аның инде йөгерергә хәле бетте. Сулышын көчкә-көчкә генә алса да, туктап ял итәргә курыкты ул. Бал кортлары әкренләп артта кала башладылар. Бара-бара алар бөтенләй сирәгәйде. Бары тик кызу йөгерүдән Сәмигулланың колак төбендә җил генә выж-выж сызгырды. Ул көч-хәл белән авылга кайтып егылды һәм, көн үтереп кыздыруга карамастан, сырган юрган бөркәнеп ятты.

Ә Хәлим карт корт чаккан урыннары бик сызласа да түзде, кортлар тынычлангач кына урыныннан торды һәм, умарталыгына кайтып, салкын су белән юынды. Шешкән урыннарына судан компресс ясады. Аның бөтен тәне уттай кыза, сызлый иде. Ләкин тәненә караганда, әрәм булган кортларны кызганып, кешеләрнең комсызлыкларына сыкранып җаны сызлый иде.

## ӘЙТМИЧӘ ЯРАМЫЙ, КЫЗЫМ

Көзге төн. Салкынча яңгыр сибәли, йолдызлар каядыр качышып беткәннәр. Ай да, ялгыз йөрүдән ямь тапмыйча, болытларга төренеп йокларга яткан. Ай гына түгел, бөтен авыл изрәп йоклый. Төнге тынычлыкны бозучы бер генә җан иясе дә күренми. Хәер, болай дип расларга ашыкмыйк әле. Әнә пычрак юлдан арба тартып кемдер бара түгелме соң? Өстәвенә арбасы да шактый авыр, ахры, юлчының еш-еш сулаганы ишетелә, ул әллә йөге авырлыктан мыш-мыш килә, әллә җылы түшәгеннән кубарып чыгарган язмышына үпкәләүдән сулкылдап елый – белмәссең.

Менә арба авыл башындагы ындырга килеп керде, мышкылдаган тавыш та ишетелми башлады. Тик тынлык озакка сузылмады, ындыр каравылчысы Мөнәвир картның «Кем бар? Атам!» дигән бераз куркулы, бераз- янаулы тавышы ишетелеп китте. Каравылчы, янавы ыша-нычлырак чыксынгамы, кулындагы ботаклы таягын мыл-тык затворыдай шарт-шорт иттереп алды, аннан соң гына, йөрәкләнеп, төнге кунакка якынлашты.

– Кем бар анда? – дип кабатлады ул, фонарь яктысы белән бодай көшелләрен капшап.

Ләкин картка җавап бирүче булмады, җавап урынына тыелып елаган тавыш кына ишетелде. Мөнәвир карт фонарен тавыш килгән якка таба юнәлтте һәм каршында битләрен каплап басып торучы бөршәйгән бер кыз күрде. Кызның бәләкәй арбасында бер капчык бодай, капчыкның авызы чишелгән дә, кызның аяк астына шыбырдап бодай коела иде.

– Ачып җибәр әле йөзеңне, күрик синең кемлегеңне, – диде каравылчы һәм, батыраеп, кыз янына килде дә тегенең кулларына үрелде. Кызның куллары җепкә генә тагылган әйбер шикелле кинәт түбән салындылар.

– Бәрәч, әстәгъфирулла, әллә күзем ялгышамы, Әхмәтша кызы Рәмзия түгелме соң син?

– Әйе, – диде кыз, сулкылдавын басарга тырышып.

– Нишләп йөрисең бу кара төндә? Капчыгыңа нигә колхоз бодаен урлап тутырдың?

– М-мин урламадым а-аны, – дип сузды Рәмзия.

– Син булмагач, капчыгыңа бодай үзе тулганмыни? Һы, үлмәсәң, әллә ниләр ишетерсең, валлаһи. Көшелдәге икмәк үзеннән-үзе капчыкка кергән диген, ә? Вәт әкәмәт!

Мөнәвир карт, әллә карак тикле карак тота алганына күңеле булып, әллә кара төндә сөйләшергә бер җан иясе табылуга шатланып, Рәмзия тирәсендә сөйләнеп йөри бирде.

– Шулай да әйт әле, нәрсәгә дип тутырдың бу бодайны? Әллә атаң ашатмыймы?

Әтисен телгә алгач, кыз корт чаккандай сискәнеп куйды, ләкин җавап бирмәде.

– Миңа әйтергә теләмәсәң, идарәгә кайткач, председатель каршында җавап тотарсың, – диде карт кырыс тавыш белән, үзен санга сукмауларына ачуы чыккан иде аның. – Әйдә, капчык авызын бәйлә дә идарәгә киттек, мин сине рәтле кешегә санап йөрим тагын. Ә син менә нинди юлга баскансың. Әнкәң мәрхүм гаделлеге белән авылда берәү иде...

– Идарәгә апбарма инде, Мөнәвир бабай, – диде Рәмзия һәм тагын елап җибәрде: – Мин урламадым б-бит а-ны, китердем генә.

– Каян китердең? – диде Мөнәвир карт, чиктән тыш гаҗәпләнеп. Аның әле гомерендә бер мәртәбә дә ындырга үз өеннән ашлык китерүчене күргәне юк иде.

– Безнеке түгел ул...

– Алайса, нишләп сезгә килеп кергән соң?

Рәмзия икеләнеп калды. Күңелендә ниндидер көрәш барганлыгы күренеп торганга, каравылчы карт аны ашык-тырмады.

– Әй, Мөнәвир бабай, – диде Рәмзия әллә нинди әр-нүле тавыш белән, – шушы капчыкны гына бушатыйм да кайтып китим мин.

– Юк инде, кызым, сине болай җибәрергә хакым юк. Мин бит мондагы ашлык өчен җавап бирәм. Ә син, бушатыйм да китим, дисең. Берәүләр миңа әйтми-нитми төясә, икенчеләр бушатып китсә, минем монда кирәгем

нигә кала? Әле мин сине әйбәт кеше кызы булганга гына көчләп идарәгә апбармый торам. Бүтәннәр белән күп сөйләшеп маташмыйм мин. Мылтыгымны төзим дә әйдә, вәләй генә.

Үз гомерендә карак тотканы булмаса да, шулай дип сөйләнде каравылчы карт. Хәер, соңгы елларда карагы да бетеп китте бит аның. Кайсы өйгә керсәң дә муллык та байлык, кибетләрдә, киштәләрне сыгып, ак күмәч өелеп ята. Нигә урлашсыннар? Тик менә Рәмзиягә генә аптырады Мөнәвир. Кызый үзен бик сәер тота. Урлашырга килгәнгә дә охшамый. Бодайны ындырга китердем, ди бит. Вәт әкәмәт!

– Алайса бушат инде капчыгыңны, – диде Мөнәвир, кызны жәлләп. – Түлке шундый шарт белән: каян алганыңны сөйләп бирәсең.

– Әти урлап апкайткан аны, – диде Рәмзия кыенлык белән. Күрәсең, әтисенең бу яман эшен бер генә дә әйтәсе килми аның.

– Вәт әкәмәт! – диде Мөнәвир карт, тагын да ныграк аптырап. – Әхмәтша шул көнгә калганмыни? Колхоздан бодай урлап апкайткан диген, ә?! Каян алды икән ул аны?

– Белмим, – диде Рәмзия.

Кызның әтисе Әхмәтша соңгы вакытларда төрле эшкә йөри иде. Бер көнне тирес чыгарса, икенче көнне элеваторга грузчик булып китә ул. Бәлки, бу ашлыкны да шуннан урлагандыр? Әниләре үлгәннән соң бөтенләй әллә нишләде. Көн саен эчеп кайта башлады, хәтта кыяфәтенә кадәр үзгәрде. Мунча пәриедәй кап-кара, сакал-мыек басмыйча кырынмый, көчләп салдырып алмасаң, өстен алышмый.

Башта Рәмзия аңа сүз әйтмәде, әни үлгән кайгыдан эчәдер, дип кичерә килде. Ә инде эчү әтисенең гадәтенә кереп киткәч, дәшми кала алмады, ләкин ата кеше һәр очракта кызы алдында акланырга сәбәбен таба торды. Шулай итеп әкренләп өйдән кот качты. Әнисе барындагы шыплап тутырылган сандыклар күзгә күренеп бушады, кыйммәтле ашъяулык, келәмише нәрсәләр берәм-берәм юкка чыга барды. Өй әйберләрен сатып эчсә дә, кеше милкенә, дәүләт милкенә кул сузганы юк иде әле. Тик менә бүген кич әллә каян шушы бодайны алып кайтты ул. Рәмзия аның урланган икәнлеген дә белмәс иде – кызмача әтисе үзен бик шикле тотты.

Капка баганаларына күчәрен ордыра-бәрдерә, атын ишегалдына кадәр кертте. Аннары салам астына яшерелгән шушы капчыкны арба төбеннән сөйрәп чыгарды да кызына кычкырды:

– Нәрсә карап торасың, күтәреш, тизрәк келәткә кертеп куярга кирәк.

– Келәткә тавыклар яптык бит, әти. Капчыкны чукып тишкәләп бетерерләр, өйалдына гына куйыйк.

– Өйалдына? – диде әтисе, җикеренеп. – Әллә аны әбиеңнән калган милек дип белдеңме? Ул...

– Соң, эшләп алган бодайны өйалдына куюдан куркырга, – диде беркатлы кыз. Әтисенең яман эшкә кулы барырын күз алдына да китерә алмаганлыктан, ул һични төшенми иде.

Әтисе Рәмзия белән артык сүз көрәштереп тормады, капчыкны җәһәт кенә җилкәсенә салды да келәткә алып кереп китте, үзе:

– Иртәгә үк хуҗа табарга кирәк моңа, – дип сөй-ләнде.

Шушы сүзләрне ишеткәч, Рәмзия эшнең нидә икән-леген сизеп сискәнеп китте.

– Әти, – диде ул, ачынып, – әллә син аны урлап алып кайттыңмы?

– Синең башың яшь әле, күп сорашма, – дип кырт кисте әтисе.

– Мин нинди ипи ашаганымны белергә тиеш.

– Сиңа ашарга түгел ул, нәфесеңне сузма. Иртәгә үк бер яртыга очырам мин аны, эзе дә калмас.

– Урланган булса, атыңны тугарганчы урынына илтеп куй, әти. Юкса бөтен авыл каршында хурлыкка калырбыз.

– Җитте сиңа, шыңшыма. Телләшеп торганчы, менә бу акчага кибетче апаңнан бер ярты апкайт.

Әтисе Рәмзиягә таушалып беткән бишлек сузды. Кыз икеләнеп калды, шулвакыт аның башында бер план туды, һәм ул әтисе сузган акчаны алды да кибетченең өенә йөгерде. Кызының шешә күтәреп кайтып кергәнен күргәч, ата кеше йомшады.

– Хәзер, кызым, капкаларга берәр нәрсә әзерлә инде, – диде ул. – Ату иртәдән бирле валчык та капкан юк.

Рәмзия табын әзерләгәнче, әтисе инде теге шешәнең яртысын бушатырга да өлгерде. Шунлыктан кызы китереп куйган кыздырылган бәрәңгене бер генә капты да, авызы пешеп:

– Уф, шулкадәр кайнар итеп пешермәсәң булмый идемени? – дип, кашыгын атып бәрде. Авызы пешкән ачудан калган аракысын да салып эчте. Ә бераздан гырылдап йоклап та китте.

Рәмзия аның йоклаганын белгәч, өс-башына киде дә тиз генә ишегалдына чыкты. Аның бөтен тәне калтырый, буыннары хәлсезләнгән иде. Шунлыктан келәт ишеген ача алмый торды. Урам ягыннан ишетелгән һәр тавыш аны сискәндерде. «Тизрәк бу хурлыктан котылырга кирәк, – дип уйлады кыз. – Юкса көн яктысында кешеләрнең күзенә

ничек күренерсең?! Оят, билләһи, үз әтиең шундый түбәнлеккә төшсен инде. Ашарга җитмәүдән урласа, вөҗданың, бәлки, кичерер дә иде. Бер ярты аракы өчен бит».

Рәмзия келәттәге капчыкка барып ябышты, ләкин ул шактый авыр иде. Кыз тиз генә, капчыкның авызын чишеп, бераз бодайны чиләкләргә бушатты һәм җиңеләйгән капчыкны ишегалдындагы бәләкәй арбага чыгарып салды. Аннары чиләкләрдәге ашлыкны кире капчыкка тутырды, әзер булгач та, капкадан чыгып китәргә җөрьәт итмичә, шактый вакыт ишегалдында таптанды ул. Урамда тәмам аяк тавышлары басылып, соңгы утлар сүнгәч кенә, арбасын тартып юлга чыга алды ул...

– Инде нишлибез, кызым? – диде каравылчы, тынлыкны бозып.

– Берүк, Мөнәвир бабай, кешеләргә сөйләмә инде, – диде Рәмзия ялварулы тавыш белән. – Болай да әти эчә башлаганнан бирле дусларымнан аерылып беттем. Урамга чыксам да, әнә айнымас Әхмәтша кызы, дип төртеп күрсәтерләр төсле.

– Әйе, – диде каравылчы карт, үз-үзенә сөйләнгән-дәй, – Әхмәтшаның мондый хурлыкка төшүенә без дә гаепле. Әле беркөн генә карчык аңардан менә дигән келәмне унбиш тәңкәгә алып калды. Юкса Әхмәтша туп-турысын әйтте бит. Эчәргә акча кирәк, диде. Шунда тиргәп чыгарасы урында, шәп булды әле бу, дип сөенеп, келәмне алып калдык. Иртәгә ул шушы бодаен бер яртыга сатар иде. Безнең кебек бәрәр ачык авызы, очсыз хакка нихәтле ризык юнәтә алуына куанып, каракның кулына өч тәңкә тоттырып чыгарыр иде. Менә бит кеше ничек бозыла, кызым. Ә син, кешеләргә әйтмә, дисең. Бу хакта әйтү генә аз, бөтен авылга чаң кагарга кирәк.

Мөнәвир карт Рәмзияне бөтен йөрәге белән кызгана, әгәр мөмкин булса, үз баласы итәр иде. Менә ул кызның түбән салынган иңенә кулын куйды һәм, икеләнергә шик калдырмыйча:

– Ә син борчылма, кызым, – диде, – йөзеңә кара якмабыз. Хаклыкны кешеләр аңлар, ә начарлыкны яшерергә ярамый. Соң булуы бар. Болай да инде шактый соңардык бугай.

## ИҢ КАДЕРЛЕ БАЙЛЫК

Сибгат абзыйны авылда олысы-кечесе хөрмәт итә. Өлкәннәр каршында ул үзенең тынгысызлыгы, учында ут биетеп эшләве белән абруй алган. Чын мәгънәсендә типсә тимер өзәрлек кеше. Кырык елдан артык тимерчелектә эшләү дәверендә нинди генә корычны эретмәгән дә, нинди генә тырма-сабанның гомерен озайтмаган ул. Әмма ут-күз малайларның, күбәләк-җан кызларның хыялын- канатландырган, күзләрен яндырган нәрсә Сибгат абзыйның эш сорап кычыткан куллары түгел, ә матур итеп сөйләве. Юк, җиде башлы диюләр, сихерле карчыклар һәм тагын әллә нинди нәрсәләр турында сөйләми ул. Үз башыннан, ил башыннан үткәннәрне матур итеп хикәяләве белән нәни дусларының күңелен яулап ала.

– Беләсезме, оланнар... – дип сөйләп китә Сибгат абзый, сыңар күзен хәйләкәр кыса төшеп. Бармак юанлыгы кашлары мут кына сикерә башладымы, көт тә тор: нинди дә булса хикмәтле сүз, гыйбрәтле сүз әйтәчәк. – Беләсезме, оланнар, – дип янә кабатлый ул, – иң кадерле байлык нәрсә?

Балалар бер-берләренә карашып куялар. Кайсы – «алтын», кайсы «көмеш» ди. Җирдәге һәртөрле кыйммәт-ле нәрсәләр саналып чыга, әмма Сибгат абзый алар-
ның сүзләрен расларга ашыкмый. Тынгысыз җан малайлар:

– Нәрсә соң ул иң кадерле байлык? – дип, Сибгат абзыйның хәйлә белән кысылган күзләренә карый-лар.

– Алайса, мин сезгә бер нәмәстәкәй сөйлим әле. Бо-рын-борын заманда, кәҗә команда, саескан урәтник булып торган чакта түгел, ә саескандай йомырка эчеп симергән үрәтникләр, кәҗәдәй аңгыра губернаторлар, козгындай үләксәгә сусаучы патшалар әрбәлютсия җи-леннән җәһәннәмгә очкан чакта, фронтта өченче ел инде окоп салкыны имеп ятучы әткәйдән хат килеп төште. Әни авырып ята иде. Хатны күргәч, көч-хәл белән торып утырды. Аны, бик кадерле нәрсәдәй, саклык һәм олылау белән кулына алды, укый белгән кеше кебек, кәкре-бөкре хәрефләргә озак кына карап торды. Төрлечә әйләндергәләп һәр юлын күздән кичергәннән соң, сәке йөзлегенә тотынып, аягына басты.

– Кая кузгаласың, әнкәй? – дидем куркып.

– Мөгаллим абзаң янына барыргае, Сибгат улым, аннан башка хатны кем укысын?

– Мөгаллим абзыйларга үзем барырмын, сиңа бит урыныңнан кузгалырга ярамый, – дидем дә, хатны эләктереп, өйдән чыгып чаптым. Әмма Мөгаллим абзый өйдә юк иде. Хатны укытмаган килеш, әнкәй янына һич кенә кайтасым килмәде. Әткәйнең һәр хәбәрен ничек көтеп алганлыгын белмиммени мин. Бәлки әле, әйбәт хат булса, терелеп тә китәр.

Шул өмет белән ары бәрелеп, бире сугылып йөри торгач, Мирзагыл байларның тимерләп эшләнгән урыс капкалары янына килеп чыктым. Дәүләтҗан исемле бер малайларының әллә нинди гимназия дигән җирдә укып кайтканлыгы колагыма чалынганы бар иде. Капкаларын этеп карадым – бикле. Әмма сигез-тугыз яшьлек малай белән җил үтә алмаган капка бармыни дөньяда?! Башта якында гына үсеп утыручы талга, талдан коймага үрмәләдем дә шап итеп ишегалдына сикереп төштем, хәтта бозау хәтле этләре дә абайламый калды. Мин болдырларына барып җиткәч кенә, ул, бу нинди җанлы сөяк? дигәндәй, күңелен юатыр өчен бер өреп куйды.

Бәхетемә күрә, Мирзагыл абзый өйдә юк иде. Юкса ул этләреннән усалрак. Гимназиядән кайткан Дәүләтҗан ябык калҗага караган эт шикелле теләр-теләмәс миңа күз ташлады.

– Йолкыш, ни йомыш? Ха-ха-ха! Нинди әйбәт рифмалаша икән бу сүзләр, – дип ыржаеп алды ул.

Мин, курка-курка, хатымны суздым.

– Шушыны гына укып бирмәссеңме дигәнием, а-абы-ый. – Бу утын түмәренә «абый» дип дәшәргә телем бармаса да, йомышым булгач, теш арасыннан ул сүзне этеп чыгарырга туры килде.

Дәүләтҗан хатны җирәнеп кенә кулына алды һәм укый башлады: «Бу хатны мин Петербурдан язам, кадерлеләрем. Менә буржуйларның арка сөякләренә штык кададык, озак тыпырчына алмаслар...» Шушы сүзләрдән соң Дәүләтҗанның иреннәре бүртмәчләнде, маңгаенда кызыллы-зәңгәрле таплар барлыкка килде. Мин ник кергәнемә дер-дер калтыранып тордым, ләкин борылырга соң иде.

– Кычкырып укы инде, а-абы-ый – дидем, – әнигә кайтып сөйлисем бар, ул анда чирләп ята.

Ул, минем сүзләремне ишетмәгәндәй, һаман мыгырдануында булды. Менә бермәлне юләр кешедәй буылып-буылып көләргә тотынды. Әйтерсең ыштан төбенә кырмыска кергән дә ботларын кытыклап йөри.

– Ха-ха-ха! Кадерле байлык апкайта, имеш. Сезнең ише йолкышкаларга окоптан алтын тутырып җибәрәләр ди. Ха-ха-ха!

Аның сүзләреннән мин һични аңламадым, эчен тотып ыржаеп азапланган арада, хатны кулыннан тартып алдым да тышка атылдым. Кергәндә өрмәгән эт, баярак мине күрми калуының үчен алырга теләпме, тешләрен кайрап каршылады. Минем ише малайларның иң йомшак җире кайда икәнен белә, каһәре, сыйракны авыз итеп тә тормыйча, туп-туры шунда ябышты, чалбар төбе белән бер кабымлык итне эт авызында калдырып, урамга чыктым. Тәннең ямавы өстендә, әмма чалбар жәл иде. Канаган җирне кәләпүш белән каплап, әни янында ничек кайтып керергә белмичә, урамда озак йөрдем. Шунда Мөгаллим абзый очрады. Ятьрәк әтинең хатын аңа суздым. Әти, чынлап та, нииндидер зур байлык алып, бер айдан кайтачагын яза иде.

– Әни! – дидем, сөенечемнән авырткан җиремне дә онытып. – Әти баеп кайта икән! – Хатта ниләр язганлыгын сөйләп бирдем.

– И-и, балам, – диде әни, – үзе исән-сау кайтса, бүтәнен өмет иткән юк инде.

Әти алып кайтачак зур байлыкның ни икәнлеген уйлап гел баш ватып йөрдем. Иң соңыннан, өстәл хәтле түгәрәк ипидер ул, дип тынычланып яши башладым. Әтинең кайтыр көннәре якынлашкан саен, сабырлыгым бетә барды. Еракта, станция ягыннан поездларның кычкыртып үткәннәрен ишетеп, йөрәгем җилкенә иде. Хатта күрсәтелгән көн җиткәч, әнигә:

– Мин станциягә барыйм әле, әни, – дидем. – Теге түгәрәк ипине дә күтәрешеп кайтырмын, әтинең үзенә генә авырдыр.

– Нинди түгәрәк ипи? – диде әни, гаҗәпләнеп.

– Соң, әти апкайтачак байлык киселә дә башламаган ипидер инде ул.

Әни күзләрен сөртеп куйды. Аннан, мине җибәрәсе килмичә:

– Станция бик ерак бит, Сибгат улым, – диде.

– Ерак түгел, җиде чакрым нәрсә ул, минем тәпиләр Мирзагыл чабышкысына биргесез бит, – дидем.

Әнинең һаман да ризалашасы килмәде. Шулай да, мин балавыз сыга башлагач, өс-башларымны алыштырырга кушты. Бәйрәмнәрдә генә кия торган ситсы күлмәгемне һәм әтигә күрсәтергә дип саклап торган сырмамны киеп, станциягә киттем. Бу юл инде миңа бик таныш, әни белән тегенди-мондый вак-төяк сатарга гел шушында килә идек. Йөрәгем ашкынып-ашкынып типте. Тиздән әтине күрү дәрте адымнарымны кызулатты. Тамчы да арымыйча, станциягә килеп җиттем. Алай бик үк еш булмаса да, поездлар үтә торды. Кайсылары туктады, кайсылары юк. Туктаганы берсе янына барып, вагоннан төшүчеләрне күзәттем. Ләкин берсендә дә минем әти күренмәде. Бер вагоннан икенчесенә йөгереп йөри торгач, табаннарым ут яна башлады. Арып, өшеп, вокзалга кереп утырдым. Шунда җылыга изрәп йоклап киткәнмен. Ә уянганда караңгы төшеп килә иде инде. Әни миңа караңгы төш-кәнче тормаска кушкан иде бит. Ике-өч чакрым урман юлыннан кайтасы барлыгы исемә төшеп, йөрәгем жу итеп куйды. Станциягә туктамыйча ажгырып үтеп киткән поездга соңгы тапкыр күзләремне мөлдерәтеп карадым да кайтыр

юлга чыктым. Курку мине бөтен нәрсәдән дә ныграк чыбыркылады. Күз бәйләнер-бәйләнмәстә урман юлына килеп тә җиттем. Шулвакыт урман юлыннан чаптырып килүче өч атлы күренде. Юлбасарлардыр дип, куак артына постым. Атлылар выжт итеп минем яннан узып киттеләр. Берсе Мирзагыл абзыйның гимназиядән кайткан малае Дәүләтҗан иде.

Ат тоякларының тавышы ераклашкач, яшеренгән уры-нымнан чыгып, юлымны дәвам иттем. Инде урманны хәвеф-хәтәрсез генә үттем дигәндә, бер агач төбендә кара нәрсә абайлап алдым. Аякларым ни алга, ни артка атламады. Ул кара нәрсәгә карамаска тырышкан саен, муеным шул якка борылды. Шулвакыт көчсез ыңгырашу тавышы ишетелде. Кирегә чабарга да күп калмаган иде инде, ләкин нindider көч бу ниятемнән тыеп калды, үземне үзем белештермичә, аунап яткан нәрсә янына килдем. Ул – кеше иде. Өстендә солдат киеме, бите-башы кара кан. Ләкин әле үлеп җитмәгән күренә. Кызганудан куркуны онытып, аның канлы йөзенә, чабылып ташланган кул-аякларына текәлдем. Урмандагы караңгылык та, эчкә шом салучы ят авазлар да еракка китеп югалды. Нindider томан эчендә туракланган солдат белән мин генә калдым. Шунда солдат, нидер әйтергә теләп, иреннәрен кыймылдатты.

– Кем син, абзый кеше? Нигә болай турakladылар? – дип ачынып, солдатка карап каттым. Аның күзләрендә сүрән генә очкын кабынды да сүнде. Элек үлгән кешегә карарга курка идем, бу юлы кара урманда булуга карамастан курыкмадым. Күңелемдә – кызгану хисе, ә үтерүчеләргә нәфрәт иде.

Авылга ничек кайтканымны да белмим. Бары тик шунысы гына истә калган: «Урман юлында кеше үтереп ташлаганнар!» – дип, урам буенча кычкырып йөрдем. Бөтен авыл кубарылып, солдатны авылга алып кайттылар. Ул минем әти иде. Соңыннан гына белдем, әтине теге Дәүләтҗаннар үтергәннәр икән. Байлыгын эзләгәннәр. Кесәләрендә тәмәке янчыгы белән газета кисәгеннән башка нәрсә тапмагач, ачуларыннан тураклаганнар. Әмма дошманнар ул алып кайткан байлыкның күп укылудан тишелә башлаган газета кисәге икәнлеген белмәгәннәр.

Әйе, чыннан да, бик кадәрле байлык була ул, оланнар. Анда җирне халыкка бөтенләйгә бушлай бирү хакында язылган була.

Байлыкларның байлыгы, хәзинәләрнең хәзинәсе, бәхетләрнең бәхете ул җир. Дөньядагы бөтен матурлык, бөтен байлык, бөтен тереклек җирдән башлана.

## БӘРӘҢГЕ

Җыелышны оешма җитәкчесе үзе ачып җибәрде. Ул, кереш сүзләр сөйләп тормастан, үгезне мөгезеннән алды, ягъни турыдан-туры төп мәсьәләгә күчте:

– Иптәшләр, без бүген сезнең белән ачыкларга тиешле нәрсә бер генә: бәрәңге.

Башлыкларының сүзен тыңлап та бетермәстән, залда канәгатьсезлек белдергән тавышлар ишетелә башлады. Җитәкче кеше, кулын алгарак сузып, аларны тынычландырырга тырышты. Әмма зал өенә төтен кергән умартадай гөжләде: «Көз җитте исә шул хәл – бәрәңге», «Карлы яңгырда колхозның бәрәңгесен чүпләп чиләнәсебез килми әле», «Безнең планны колхозчылар килеп үтәми бит, нигә без аларныкын үтәргә тиеш?»

Җитәкче кеше, мыек астыннан гына елмаеп, залга карап торды. Кешеләр тынычлана төшкәч, ул болай диде:

– Нәрсә авызыгызда кайнар бәрәңге әвәләгәндәй мыж-мыж киләсез? Бәрәңгене беребез дә яратмыйбызмыни, ә? Бу тәмле ризыкка болай ук хөрмәтегез беткәндер дип уйламаган идем, ай-яй. – Ул, залдан ярдәм көтеп, тагын бераз карап торды, андагылар, начальникларыннан күз яшерергә тырышып, түбән карадылар. – Йә, иптәшләр, йә. Кайсыгыз сүз әйтергә тели? Синме, иптәш Идрисов? – Башлык үзенең урынбасарына карады.

Идрисов, авыр корсагын куллары белән күтәргәндәй итеп, урыныннан торды.

– Анысы ни инде... – диде ул, мыш-мыш килеп, – бәрәңге болай начар нәрсә түгел, гәҗитләрдә юкка гына «икенче икмәгебез» дип язмыйлар. Тик, иптәшләр, минем корсакка ярамый ул каһәре. Нәрсәсе бардыр инде. Врачларга да күренеп карадым, җүнле сүз әйтә алмадылар. Оят булса да әйтим, бәрәңге ашаган көнне үз йомышымнан кайтып керә алмыйм. Хатын миңа кырган кишер генә ашатып тора. Менә кишергә дисәләр, бәлки...

Идрисовның бу сүзләреннән берничә кеше тыелып кына көлеп алды. Кычкырып көләрләр иде, әле үзләренең колхозга китүчеләр исемлегеннән алдап-йолдап бул-са да төшеп каласылары бар. Әнә башлык, бармагы белән төртеп, берәм-берәм сорашып тора. Чират алдынгы саналып йөргән эшче Сөнгатуллинга җитте. Ул, баһадирныкыдай киң җилкәләрен киереп, урыныннан купты, аннары, көр тавыш белән рәхәтләнеп көлә-көлә, болай диде:

– Иптәш начальник, карагыз инде минем менә бу гәүдәмә. Рәзе бәрәңге ашап үскән кешегә охшыйм, ә? Бәрәңге белән генә норманы үтәп булмый ул. Бәрәңге бит, барганда алып барырмын, кайтканда, үзеңне үзең кара, дигән. Ә сез, бәрәңге яратасыңмы, дисез!

Сөнгатуллин, үзенең тапкырлыгыннан канәгатьләнеп гөрли-гөрли, урынына барып утырды. Аның артында карсак гәүдәле, олы башлы Шәвәлиев утыра иде. Начальникның карашы үзенә төшкәнне күреп, урындыгында бөтерелә-бөтерелә чәрелдәп җибәрде:

– Ә минем хатыным көнләшә, вәт шул.

– Нәрсәдән, бәрәңгедәнме? – дип кычкырдылар аңа.

– Бәрәңгедән дә, шалканнан да, – диде Шәвәлиев ачу белән.

Аның бу кыланышыннан зал бераз җанлана төште.

Шулвакыт арттагы рәттә утыручы Кадыйр карт торып басты:

– Иптәш нәчәлник, эспискеңә беренче итеп яз әле мине, – диде ул. – Бәрәңгене бәк яратабыз без. Безнең корсакка ярый ул. Балалар да, хатын да аның өчен үлеп тора. – Кадыйр карт, залга рәнҗүле караш ташлап, сүзен дәвам итте: – Кырган кишер яратучыларга дөнья терәлеп калмаган. Бәрәңге безне ачлык елларда үги итмәде, без дә аннан йөз чөермибез. Яз әйдә эспискеңә.

Залда утыручылар Кадыйр картка котырып кул чаптылар. Кул чабулар тынуга, җыештыручы апа трибунага йөгереп менеп китте:

– Яз мине дә, иптәш начальник. Без бәрәңгедән курыкмыйбыз. Казырга икән казырбыз, ашарга икән ашарбыз. Безнең үз семьябызга гына да кыш ашап чыгарга бер тонна бәрәңге кирәк. Дүрт балам, инвалид ирем бар. Бәрәңгене без дә алмасак, кем алсын...

Җыештыручы апага да гөрләп кул чаптылар. Бу апаның чыгышыннан соң тагын берничә кеше бәрәңгене бик ратуын һәм колхозга китәргә әзер икәнлеген белдерде. Сөйлисе кеше сөйләп бетергәч, башлык, кулындагы карандашы белән өстәлдәге графинга суккалап, халык тынычланганны көтте һәм сүзен йомгаклады:

– Ярый, иптәшләр, фикерләрегезне белдек. Шулай яшереп-нитеп тормастан турысын әйтүегез өчен рәхмәт. Югыйсә ул бәрәңге белән нишләргә икән дип аптырап беткән идем. Әйе, әйе. Безнең подшефный колхозыбызның бәрәңгесе быел бик уңган. Ике план үтәргә мөмкинлегебез бар, дигәннәр. Колхозчылар да тырышып эшләгәннәр, үз көчләре белән бәрәңгеләрен алып бетергәннәр... – Начальникның шушы сүзләреннән соң халык аптырап калды. – Менә шул, иптәшләр, колхоз безнең оешмага атап шактый бәрәңге җибәргән. Куяр урыннары юк икән. Кирәк кешегә бушлай өләшегез, дигәннәр. Исемлеккә язылган иптәшләргә иртәгә үк машина белән бәрәңгене илтербез. Турысын әйтүегез өчен тагын бер кат рәхмәт, иптәшләр!

## КНОПКА

Яшел эшләпәсен кыңгыр салып Сәләхиев килеп кер-гәч, конторадагы һәммә кешенең чырае сытылды. Ә Рифкать Назыймович, бөтен тешләре берьюлы сызлый башлагандай, ике куллап яңак сөякләрен кысып куйды. Шулай да, егерме ел эшләү дәверендә күнеккән гадәте буенча, элекке начальнигын аягүрә басып каршылады.

– Әйдүк, әйдүк, – диде ул, елмайган булып. Ә үзенең кыяфәте «кайчан синнән котылырбыз икән инде» дигәнне аңлата иде.

– Менә, – диде Сәләхиев, эшләпәсен өстәлгә куеп, – килдем әле. Өйдә нидер җитми. Рөхсәт итсәгез, тагын бераз-эшләп алырга иде исәп. Берәр бүлек-мазарда булса да...

Рифкать Назыймович, Сәләхиевне кабып йотарга җыенган төсле, зур итеп авызын ачты. Ачуыннан борын өстендә яшелле-зәңгәрле таплар барлыкка килде.

– О, күктән көткәнне җирдән бирде, әйдүк, Габбасыч, әйдүк, – диде ул, урынбасар булып эшләгәндәгечә ялагайланып. Хәер, бу сүзләр аның теленнән үз ихтыярыннан башка гына атылып чыкты. Чөнки бусагада Сәләхиев күренер алдыннан гына, Рифкать Назыймовичка:

– Сәләхиев тагын бераз үз урынында эшләп алсын инде, без монда приказны әзерләп куярбыз, – дип, тресттан Сәләхиевнең кияве шалтыраткан иде.

– Узыгыз, уз, утырыгыз менә үз урыныгызга. Эшлик әле тагын бергә-бергә кошлар кебек чөкердәшеп.

Рифкать Назыймович үзе утырып җылыткан кәнәфине, кулъяулыгы белән сөртеп, Сәләхиевкә тәкъдим итте.

– Бу сезнең күнеккән кәнәфиегез түгел, тик шулай да бик уңайлы. Үзем сайлап алдым.

Сәләхиев, чиксез канәгатьләнеп, кәнәфигә кереп утырды һәм уң кулының имән бармагы белән өстәл өстендәге кара кнопкага басты...

Шушы көннән алып Рифкать Назыймович аны ничек итеп өченче тапкыр пенсиягә озатырга икән дип баш ватарга тотынды. Әйе, Сәләхиев лаеклы ялга ике тапкыр китеп карады инде. Беренчесендә зурлап, бүләкләп озаттылар. Ләкин Сәләхиев, бүләкләрен карап туюга, өйдә нидер җитми, дип, кире үз урынына килеп утырды. Җаны эшкә атылып торганнан түгел, үз урынын артык яратканга килде ул. Сәләхиевнең шушы гадәтен яхшы белгән Рифкать Назыймович, икенче тапкыр начальнигын озатканда, коллектив исеменнән аңа утыз ел утырган үз кәнәфиен бүләк итәргә тәкъдим итте. «Кәнәфие-ние белән җибәрсәк, яңадан килеп буталып йөрмәс», – дип уйлаган иде. Әмма уйлаганча барып чыкмады. Сәләхиев, өендәге кәнәфидә утырып туйгач, менә өченче мәртәбә килде. Берәр курьер-мазар итеп олактырсаң, тиз гайрәте чигәр иде дә, тик моңа Сәләхиевнең тресттагы кияве һәм Рифкать Назыймовичның буйсынучан холкы каршы. Рифкать Назыймович инде Сәләхиевнең чөйдә эленеп торган эшләпәсенә дә иелеп-бөгелеп сәлам бирергә күнеккән. Хәзер менә шушы юашлыгы аркасында нужа чигә.

Әмма көннәрдән бер көнне, хуҗалыкта эшләр тәмам комга терәлде дигәндә, мәсьәлә үзеннән-үзе хәл ителде. Кинәттән генә Сәләхиевнең температурасы күтәрелә башлады.

– Ялга китегез, ялга! – диде аңа Рифкать Назыймович, йөзенә кайгылы кыяфәт чыгарып. – Үзегезне саклагыз. Сезнең кебек кешеләр киләчәк өчен кирәк.

Сәләхиев ялга китәргә атлыгып тормаса да, Рифкать Назыймович бу юлы катгый кыланды. Ул инде Сәләхиевкә бирергә бүләкнең дә искиткечен алып куйган иде.

Тантаналы җыелышны ачып, һәркем үзе белгән һәм кешеләрдән ишеткән мактау, зурлау сүзләрен Сәләхиевкә яудыргач, трибунага Рифкать Назыймович чыкты. Аның кулында кечкенә генә тартма иде. Тартмалы кулын югары күтәреп, ул:

– Иптәшләр! – диде. – Без бүген алыштыргысыз җи-тәкчебезне, сизгер күңелле дустыбызны мәңгелек ялга озатабыз. Һәммәбез дә яхшы беләбез: күнегелгән атмосферадан аерылу кыен. Бездән киткәч тә сөекле начальнигыбыз үзен шушы өстәл артында утырган кебек хис итсен өченгә, мин аңа үз исемемнән һәм сезнең исемнән дә, иптәшләр, менә шушы кнопканы бүләк итәргә булдым... Бу кнопка, иптәшләр, нәкъ Габбасыч өстәлендәге төсле кнопка.

Рифкать Назыймович елтырап торган ак кысалы кара кнопканы Сәләхиевнең уч төбенә салды. Ә икенче көнне, аны Сәләхиевнең өстәленә урнаштыру өчен, югары разрядлы ике монтёр җибәрде.

– Сигнал кыңгырауларын кухняга да, туалетка да, ваннага да урнаштырыгыз, – дип кисәтте ул монтёрларны. – Кнопкага басуга, карчыгы ваннада булса да, кухняда булса да, туалетта булса да атылып килеп чыксын. Сәләхиев тәртип ярата.

Рифкать Назыймович, чынлап та, зур психолог булып чыкты. Сәләхиев, «нидер җитми» дип, конторага кабат килмәде.

## АЕРЫЛЫШКАНДА

Әкрам сары күн чемоданны әйберләр белән шыплап тутырды да кухняда чаж-чож нәрсәдер пешереп ятучы карчыгына эндәште:

– Гөлгенәм!

– Әү, бәгърем?

– Менә мин бар әйберне дә әзерләп куйдым. Туебызга дусларыбыз бүләк иткән кыйммәтле сервизны посылка әрҗәсенә салдым. Ватылырлык түгел. Келәмнәрне төреп бәйләдем. Машинага төяргә җайлы булсын дидем. Китапларны унар-унар итеп төйнәдем.

– Ә чемоданга ниләр тутырдың? – диде Гөлгенә, кайнар пәрәмәчне Әкрам алдына куеп.

– Икебез өчен дә иң кадерле саналган әйберләр.

Гөлгенә картының ягымлы йөзенә яратып озак карап торды да болай диде:

– И кадерле картым минем, аерылышабыз бит инде.

– Әйе, – диде Әкрам, көрсенеп. – Ун ел вакыт узган да киткән. Шушы ун ел эчендә синең миңа бер генә тапкыр булса да авыр сүз әйткәнең булды микән? Юктыр. Никадәр тырышсам да хәтерләмим.

– Ә син үзең соң! – дип күтәреп алды Гөлгенә кар-тының сүзен. – Эштән кайтып керү белән билемнән кочып- алып үбәргә тотынуларыңны мәңге онытасым юк. Кая гына барсаң да, бүләкләр алып кайтып, мине иркәләп бетердең.

Ир һәм хатын ун ел эчендә бер-берләренең эшләгән яхшылыкларын хәтергә төшерделәр. Сүз арасында Гөлгенә кайнар пәрәмәчләрне иренең алдына этә торды. Әкрам да үз чиратында бурычлы булып калмады: карчыгының чәенә лимон турап, шикәренә кадәр болгатып бирде. Чәй эчеп туйганнан соң, чынаякларны әле берсе, әле икенчесе «мин юам да мин юам» дип озак тарткалаштылар. Алтын белән йөгертелгән кыйммәтле чынаякны идәнгә төшереп ваткач кына бәхәс тынды. Бәхәс тынды, ләкин юатышу башланды.

– Син борчылма, Гөлгенәм. Савыт-саба ватылмый тор-мый ул.

– Син дә борчылма, картым, дөньяныкы дөньяда бетү яхшы.

Һәм алар, ватылган чынаякка карап, шактый вакыт- кочаклашып утырдылар. Сүз белән бу кадерле минутларның бәһасен төшерәселәре килми иде аларның.

Менә бервакыт аларның капка төпләренә ике машина килеп туктады. Өйләренә килеп кергән шофёрларны күргәч, ир һәм хатын теләмичә генә кочакларыннан чыктылар.

– Җитте аерылышыр минутлар, – диде Гөлгенә һәм хисләренә түзә алмыйча елап җибәрде.

Әкрам ир булып калырга тырышты. Бугазына тыгылган кайнар төерне йотып җибәрде. Күкрәгенең еш-еш күтәрелеп төшүе генә аның да чиксез дулкынлануын күрсәтә иде.

– Мин синең әйберләреңне төйи башлыйм, Гөлгенәм.

– Юк, Әкрамым, миңа бер әйбер дә кирәкми.

– Ничек «кирәкми»? Сезнең бит яңа тормыш башлыйсыгыз бар. Ирең студент кеше...

– Ул эшләп укый. Дөрес, зарплатасы зур түгел. Ләкин икебезгә җитәрлек. Мин үзем дә эшләрмен әле. Ә менә сезгә әйберләр чынлап та артык булмас. Син аласы хатынның ике баласы бар бит.

– Ике баласын да, анасын да туйдырырлык хәлем бар, – диде Әкрам. – Берсүзсез бөтен әйберне синең машинага төйибез.

– Алайса, квартираны үзеңә аласың, – диде хатын, үпкәләп һәм бераз боерулы тавыш белән.

– Квартира хакында сөйләштек бит инде, гүзәлем, – диде ир. – Монда синең әти-әниләрең күчә. Картайган көндә аларның да рәтле квартирада яшәргә хаклары бардыр. Гомер буе су ташып, утын әзерләп азапланулары да җиткән.

– Ә сез кайда торырга уйлыйсыз? – дип сорады гаять борчылган Гөлгенә. – Әтиләрнең иске фатирына минем яңа өйләнгән энем кереп утырырга тора бит.

– Бигрәк шәп. Аларның бер кайгысы ким булыр. Мәхәббәт белән гомер итсеннәр. Ә безнең өчен бер дә борчылмагыз. Мин бит ир кеше, җаен табармын.

Әкрам белән Гөлгенә озак бәхәсләштеләр. Әйберләр әле бер машинага, әле икенчесенә күчте. Әкрам кыйммәтле һәм истәлекле нәрсәләрне Гөлгенә машинасына, Гөлгенә Әкрам машинасына ташыды. Арып хәлдән тайгач, өй каршындагы эскәмиягә килеп утырдылар. Әрле-бирле үтеп йөрүче кешеләргә дә игътибар итмичә, Әкрам кадерле кешесен соңгы тапкыр кочагына алды. Гөлгенә кочакта тәмам эреде. Мондый гүзәл күренешне хуплап, күгәрченнәр гөрләштеләр. Ишегалдында җыелышкан гай-бәтче хатыннар үзләренең шулай матур итеп аерылышкан чакларын искә алып көрсенделәр. Машина янында басып торучы Гөлгенәнең студент ире күңеле нечкәрүдән атылып чыккан яшьләрен Гөлгенә бүләк иткән кулъяулыкка сөртте. Ә Әкрамның булачак хатыны, ике баласын кочагына алып, баскан урынында һәйкәлдәй катып калды. Моңарчы елашып ишегалдын яңгыраткан балалары да шым булдылар.

Ә зәңгәр күктән: «Шыттыр, автор, шыттыр, бүген ярый», – дип, беренче апрель кояшы хәйләкәр елмаеп карап тора иде.

## МЕНӘ ШУЛАЙ, КОДАГЫЙ!

Туй бара. Кунаклар сыйның ачысын да, төчесен дә нык кына авыз иткәннәр, һәммәсе бик юмартланган: өстәл янында янәшә утырган табындашларын үтереп-үтереп кысташалар. Кешеләр төркемнәргә бүленгәннәр. Кодалар бер тирәдә, кодагыйлар икенче тирәдәрәк.

– Кызыбыз Җәмилә күз өстендә кара каш булып үсте. Гомер буе нужаның ни икәнен белмәде, – дип сөйли кызның әнисе. – Бүләкләрне дә бик әйбәт әзерләдек. Кеше алдында оятка калырлык түгел. Ул яктан Аллага шөкер. Атасы әйтә, кияү балакай балык тотарга бик һәвәс кеше, тотыйк та былтыр гына алган катерыбызны бүләк итик, ди. Мин каршы килмәдем. Ярар-ярар, мин әйтәм, яшь чакта дөньяның рәхәтен күреп калсыннар. Кызыбыз бик хыялый күңелле кеше, катерда йөрергә ул да каршы килмәс. Ие-ие, кодагый. Ә кияү кеше инде ул, мин әйтәм, үз балаңнан да якын була. Нигә дөнья малын җәлләргә? Үзебезнең кияү бит, дидек тә, ике дә уйламыйча, шулай ниятләдек.

– Анысы дөрес, кодагый, – дип сүзгә кушылды егетнең әнисе. – Без дә киленне бик яратып каршыладык. Сөйкемле бала. Күптән кавышуларын теләп йөри идем, Аллага шөкер, теләкләрем кабул булды. Миңа да, килеп керү белән, «әни» дип өзелеп эндәште. Яхшылыкны күрә беләбез, кодагый. Яхшылыкка яхшылык булсын дип, менә әткәсе белән уйлаштык-уйлаштык та без дә бүләкнең зурысын бирергә булдык...

– Йә-йә, кодагый, нинди бүләк? – Киленнең әнисе кодагыеның авызына текәлде. Әйтерсең аннан шалт итеп алтын чишмә атылып чыгарга тиеш иде.

– Әйе, кодагый, килен кеше инде ул үз балаң белән бер, бәлки әле, аннан да кадерлерәктер. Шундый якын кешеңнән дөнья малын жәлләп тормыйбыз. Әнә ике бүлмәле кооператив фатир, яшәсеннәр, дөньяның рәхәтен күрсеннәр.

– Ай, кодагый. Бигрәкләр дә киң күңелле кеше икәнсез. Балалар кушылганчы күпме күрешеп, күпме йөрешеп, бу кадәр юмарт дип белми идек. Ни арада барысын шулай җайлап өлгердегез? Каян акчасын таптыгыз да каян чиратын юнәттегез?

Киленнең әнисе бу минутта үзенең кодагыен кочаклап үбәргә әзер иде. Ул эчми эчкән кеше сыман туктаусыз сөйләнде. Йөгереп кенә кызы янына барып, бүләк турында аның да колагына пышылдап өлгерде. Аннары яңадан, кодагые янына утырып, болай дип сорады:

– Фатирлары кай тирәдәрәк булды? Шәһәр үзәгендә түгелме?

– Ничек инде «кай тирәдәрәк»? Менә шушы үзебез тора торган фатирны балаларга калдырабыз.

– Ә, шулаймыни? Ярый-ярый, бусы да ярый. Тик бераз ремонт кирәк кирәген. Анысын гына ничек тә үзегез күчеп киткәндә җайлап китәрсез әле. Без дә әз-мәз булышырбыз. Бер банка әйбәт буявым бар иде, ремонтлаганда хәбәр итәрсез, китерермен.

Киленнең әнисе бераз сүзсез торды. Тик аның күңелен бер сорау кыбырсытып тора иде, ахырдан ул түзмәде, соравын бирде:

– Балаларга бу фатирны калдырасы иткәч, үзегезгә бик шәбен бирәләрдер инде? Сер булмаса әйт әле, кодагый, каян, ничә бүлмәлене бирәләр?

– Аның нинди сере булсын, кодагый,– диде егетнең әнисе. – Без беркая да күчәргә җыенмыйбыз.

– Ничек инде? Ә балалар? Алар сезнең янда җәфа... торырлармыни?

– Юк, безнең белән тормаслар. Моны яшьләр үзләре үк теләмәс. Хәзер бит яшьләр бик үзбаш яшәргә ярата. Менә шуларны уйладык та, кодагый, фатирыбызны, үзебез үлгәннән соң, балаларга калдырырга ниятләдек. Нотариус белән эше беткән. Ышанмасаң, кәгазен күрсәтә алам. Ә балалар үзләренә берәр җирдән почмак табарлар әле. Менә шулай, кодагый!

Кодагый кеше, бу сүзләрне ишеткәч, кодагыеның бер җыерчык та кунарга өлгермәгән яшь-яшь чыраена карады да өнсез калды.

Ә бу вакыт егетнең әнисенең әнисе үз тирәсендәге яшьләргә, тип-тигез тешләрен күрсәтеп, мөлаем гына елмаеп, ниндидер мәзәк сөйләп утыра иде.

## КҮРШЕЛӘР

Сәлимә белән Галимә – терәлеп торган күршеләр. Фатирлары тик бер стена белән генә бүленгәнгә түгел, ә ниндидер рухи уртаклык якынайта аларны. Әйтик, һәр икесенең ире – ялкауның ялкавы. Бер кадак та какмыйлар. Әгәр Сәлимәнең җефете эшкә атлыгып торып, Галимәнеке диванда кырын ятып телевизор караса, мондый кайнар дуслык, ай-һай, булыр иде микән? Яки тормышларының икенче ягын алыйк: ир-ат телендә «чүп-чар» дип йөртелүче өй җиһазларын. Күршеләрнең кайсына гына кермә, хан заманындагы нәрсәләр. Берсенең шкафы аварга тора, икенчесенең диван арты күтәрелми. Кыскасы, берсеннән-берсе һич көнләшерлек түгел. Ә бит күршеләр арасындагы дошманлыкның төп чыганагы – үзеңдә юк әйбернең күршеңдә булуы. Син аягы какшаган урындыкта менә тәгәрим, менә тәгәрим дип котың очып утырганда, күршеләрең йомшак кәнәфидә җәелсәләр, син кыршылган якалы пальто кигәндә, күршең кыйммәтле туннан йөрсә, билгеле инде, аларны йомшак кәнәфиләре, кыйммәтле туннары белән ераккарак олактырасы килә. Яисә синең ирең күкнең җиденче катына җитәрлек булып салып кайтып, меңенче мәртәбә «Сарман буйларында яшел алан...» дип җырлап ятканда, күршеңнеке: «Әйдә, карчыгым, театрга барыйк, бүген әйбәт спектакль икән», – дип өтәләнә-өтәләнә хатынының өстенә киендерешеп йөрсә, андый кешегә ничек, хурланмыйча, эч сереңне чишәргә кирәк! Юк-юк, хатыннар ул кадәр үк исәр түгел, исерек иренең авызын мендәр белән томалап маташканда күршесе килеп керсә дә: «Менә икәүләшеп әзрәк кәеф ачып утыра идек

әле», – дип, бәреп үтерергә әзер ирен зур мәхәббәт белән кочаклап алыр. Тегесе һаман «Сарман буйлары»н кабатласа, үзен мәҗбүр итеп булса да, иренең җырына кушылыр. Шулай ул хатыннар.

Сәлимә белән Галимә, Аллага шөкер, бөтен яктан тигез. Шуңа күрә алар еш керешәләр, бер-берсен аш-судан калдырмыйлар, рәхәтләнеп эч серләрен бүлешәләр. Ир-ләренең булдыксызлыгына алар хәзер артык пошынмыйлар да кебек. Күбрәк кызык итеп кенә сөйлиләр.

– Беркөнне, – дип сөйләп китә Сәлимә, – кием элгечебез килеп төшкән иде. Кулына чүкеч тоттырдым, кадагын китереп куйдым. Мә, мин әйтәм, кагып куй шуны тиз генә. Әй маташа бу, әй маташа, бер суга – кадагы кәкрәеп чыга, икенче суга – бармагына китереп тондыра. Чак акырып еламый. Жәлләп куйдым үзен. Түзмәдем, кулыннан кадагын, чүкечен тартып алып, шартлатып үзем кагып куйдым. Хәзер ун пальто элсәң дә күтәрә.

– Ә безнекенең, – дип, Сәлимәнең сүзен куәтләп китә Галимә, – кулына һични тоттырырмын димә. Кырык төрле сәбәбен таба. Синеке әле чүтеки кадакны кагарга тырышып караган. Шулай бервакыт какшаган урындык, акыртып, ботымны кысып алды, мин сиңа әйтим, һуштан язам дип торам. Ботымны уа-уа ябыштым мин моңа: йә, мин әйтәм, идән ярыгына аягымны кыстырып инвәлиткә әйләнәм инде, йә аяксыз шкафың басып үтерә, дим. Ә ул авызын ерып утыра: «Үлмәссең, хатыннар алай тиз генә үлмиләр алар», – ди. Ирләр безне тимердән ясалган дип уйлый, ахры. Кайчак юри, шуларга ачу итеп, берәр көнгә генә үлеп куясы килә. Карап ятасы иде, ничек яшәрләр иде икән бездән башка.

– Без үлсәк, безнең кебек тагын берәр юләре табылыр, Галимә.

– Үләм дип әйтелгән сүз түгел инде. Иректе көннән кемнең кара җир астына керәсе килсен. Әлеге дә баягы бераз җаннарын кытыклап аласы килүдән әйтелгән сүз.

Галимә белән Сәлимә бу хәлгә түзмәсләр, бер баш күтәрерләр иде, тик аларны менә шушы берсен берсе якын итешү, эч серләрен бүлешү юатып яшәтә.

Беркөнне Сәлимә күршесе Галимәгә ашкынып килеп керде дә:

– Күршекәем, – диде, – без ирләрнең психологиясен белмибез икән. Менә безнең хатабыз нәрсәдә!

– Йә-йә, шуннан?

– Синең сынаганың бар микән, Галимәкәй, ә мин сынадым. Кеше хатыннарына безнеке шундый ярдәмчел, шундый итагатьле. Трамвайда утырып барса, торып урын бирә, авыррак сумка күтәреп кайтучыны күрсә, йөгереп барып ярдәм итә.

– Кара әле, Сәлимәкәй, минеке дә нәкъ синеке төсле бит. Бакча күршебез Сәкинәгә беркөнне уч төпләре кабарганчы җир казыды. Әллә кайдагы коедан су алып кайтып бирде. Үзебездә аның чиләк түгел, чүмеч тә тотып караганы юк иде.

– Менә-менә. Нәкъ шулай.

– Бүген минеке ял итә. Син кер дә, балконга гөл әрҗәләре генә ясап бирә алмассыңмы, диген. Алып куйган такталарым кибеп, ярылып ята, үзебезнекенең кулыннан килми, диген.

– Мин үзем дә балконга гөлләр утыртырга кызыгып йөрим, – диде Галимә, – әллә ничә тапкыр әйтеп карадым, йә такта юк, йә ышкы юк, дип, сылтау таба. Ясамый.

– Алайса, бигрәк шәп, – диде Сәлимә, сөенечен яшермичә. – Миндә такта җитәрлек. Хәзер үк алып чыгып куй. Әле ирем йоклый. Ярты сәгатьләрдән торырга тиеш. Шуңынчы һәммәсе әзер булсын. Ул йокыдан уянуга, мин өйдән чыгып китәм. Мин югында кереп, аның салпы ягына салам кыстырып сөйләш.

Галимә дусты Сәлимә кушканча эшләде: күршесенең йокыдан торып чаштыр-чоштыр йөрүен ишетү белән, аларга керде.

– Күрше, – диде ул, йомышын турыдан ярып, – гөл әрҗәләре генә ясап бирмәссең микән? Бик әйбәт такталарым бар. Үзебезнекенең кулыннан килми. Эшли алмаганын белдерәсе килми тагын, соңыннан, соңыннан, дип, гел-гел суза килә. Безнекенең зәвыгы юк шул. Югыйсә балконында гөлләр гөрләп үссә, шунда күршеләрең белән бергә-бергә чәйләр эчеп утырсаң, нинди хозурлык бит.

– Анысы шулай, – дип килеште Сәлимәнең ире. – Матурлыкны аңлап җиткермәүчеләр бар әле бездә. Югыйсә, гөлләргә карасаң, җаның рәхәтләнеп китә инде.

– Алайса ясап бирәсең, күрше?

– И-и, шундый пүчтәк нәрсәне дә ясамаска! Хәзер үк керәм. Гөлеңә генә түгел, савытына карап туймаслык булыр.

Сәлимәнең ире, эш киемнәрен киенеп, Галимәләргә кереп тә җитте. Ышкысыннан очкан йомычкалар диңгез ярына җыелган күбекләр төсле як-якларга таралыштылар. Кулында чүкеч уйнап торды. Кадаклар, камырга

кергәндәй, бер сугуда ук тактага кереп чумдылар. Гөл әрҗәләре искиткеч матур чыкты. Галимә күршесенә мең-мең рәхмәтләр укып калды. Сәлимәнең ире:

– Тегенди-мондый эшең булса тартынып торма. Кулдан килгәнне эшләрбез, – дип чыгып китте.

Икенче көнне Галимәнең ире ял итә иде. Алдан сөйләшенгәнчә, Сәлимә аның янына кереп гозерен чиште. Үз иреннән зарланып алды. Синең, ичмасам, кулыңнан эш килә, дип, күршесен мактады.

Галимәнең ире чынлап та төшеп калганнардан түгел иде. Балта-пычкыны кайсы башыннан тотарга белде. Сәлимә, аның эшенә чын күңелдән сокланып:

– Ай-яй, күрше, кулларың алтын инде үзеңнең! – дип торды.

Галимә белән Сәлимә, ирләре өйдә юк чакны туры китереп, гөл әрҗәләрен чагыштырып карадылар. Һәр-кайсына үз ире ясаганы әйбәтрәк тоелды, һәм алар бәхәссез-нисез гөл әрҗәләрен алмаштырып алдылар. Үзеңнеке – үзәктә!

Ирләренең шушы гадәтләрен белгәннән соң, ике хатынның тормышы җайга төште. Галимәнең урындык аяк-лары какшаса, иплә кенә Сәлимәләргә кертеп куя, ә Сәлимә, җаен туры китереп, Галимәнең ирен үзләренә чакырып, аларның урындыкларын кадаклаттырып ала. Ә аннары аулак чакта урындыкларны Галимәләре чыгарып куя. Сәлимәнең үтүге янса, Галимәгә кертеп ташлый. Галимә, Сәлимәнең ирен дәшеп, үтүкне рәтләттерә. Озак та үтми, Сәлимәнең үз ире төзәткән үтүк үзенә кайта.

Ә бит төзәтелгән әйберләр һаман ватыла тора...

## КҮҢЕЛЛЕ ЯЛ

Начальник кабинетына Хәмит белән Җәмит икесе берьюлы килеп керделәр. Аларның кабалана-кабалана сөйләвеннән начальник бары тик шуны гына төшенде: боларга отпуск кирәк. Һәм кичекмәстән!

– Нәрсә, янамы әллә? – диде начальник.

– Януын янмый да, тик бит, иптәш начальник, шунысы обидно, бүтәннәр гел җәй көне ял итә. Кырымына, Кавказына сыптыра, ә безнең ял һаман кыш көне дә кыш көне. Безгә дә адәм рәтле вакытта ял итү хәрәм түгелдер.

– Барыгызны да путёвка белән тәэмин итә алмыйбыз, моны сез үзегез дә яхшы беләсез, егетләр.

– Безгә путёвка кирәкми! – диделәр тегеләр. – Чирләшкәләр барсын путёвка белән. Безнең, Аллага шөкер, мускулларыбыз чуеннан нык, йөрәкләребез трактор моторына биргесез.

Начальник аларга сынаулы караш ташлады. Ул ниндидер уйлар каршылыгы кичерә идеме, икеләнә идеме, һәрхәлдә, кыяфәтеннән бер ныклы карарга килә алмаганлыгы күренә иде. Дуслар, аның икеләнүен ахыргача таратып ташларга теләп, актык серләрен чиштеләр.

– Без, – диде Хәмит, алгарак чыгып, – хатыннардан, бала-чагалардан качып, отпускыбызны берәр җирдә, табигать кочагында үткәрмәкче идек. Үзегез беләсез, иптәш начальник, хатыннар янында ял итеп булмый.

– Әйе, – дип эләктереп алды дустының сүзен Җәмит. – Идел буенда балык тотып, уха пешереп...

Начальник аларның бу ниятләрен ишеткәч җанлана төште:

– Балык тотып, табигать кочагында куна-төнә яту ифрат шәп нәрсә. Бигрәк тә хатыннарсыз...

– О-о, шәп булмаган кая, иптәш начальник! Оҗмахның үзе инде. Күктән җылы кояш елмаеп карый, судан алтын балыклар койрык болгап китә, агачларда чут-чут сандугачлар сайраша. Без бу ялга әллә кайчаннан әзерләнеп йөрибез. Хатыннардан яшереп, шыпырт-шыпырт консервысын-мазарын әмәлләдек, бераз ит киптердек, хәтта зәмзәм суына кадәр әзерләдек. Менә шуларга тотачак эсбежий балыкны да китереп кушсаң, хәзинә ничава җыела.

– Яхшы, яхшы. Запас кесәне тишми, диләр, алдан азык-төлекне әзерләп яхшы иткәнсез. Ә менә палатка ише нәрсәгез бармы соң?

Хәмит белән Җәмитнең чырайлары караңгыланып китте.

– Юк шул, иптәш начальник.

– И егетләр, самый главныен оныткансыз бит.

– Онытмадык. Истә ул безнең. Тик бит аны өйдә хатыннардан яшереп саклап булмый. Алар балак бөкләменә тыккан өчлекне дә табалар. Әле бу ашамлыклар белән дә иза чигеп беттек.

– Ярый алайса. Палатка мәсьәләсен җайларга үзем ярдәм итәрмен. Анысы өчен борчылмагыз. Прокатка алып торырсыз. Илтеп куярга машина бирермен.

Хәмит белән Җәмит, өнме бу, төшме, дигән шикелле аптырашып калдылар. Начальникның сүзләрен уенга юрарлар иде, бер дә уйнап әйткәнгә охшамый.

– Димәк, иртәгәдән Идел буена балык тотарга китә алабыз, иптәш начальник?

– Рәхим итегез, тимерне кызуында суккан кешеләрне яратам мин.

– Ой рәхмәт, иптәш начальник! Безне дөрес аңлавыгыз өчен рәхмәт. Бер айга булса да хатыннардан коткаруыгыз өчен рәхмәт.

– Ягез инде, ярар. Ирләрне ирләр дә аңламагач, кем аңларга тиеш соң? Диңгез буена яки авылга китәргә ял сорасагыз, сезнең белән сөйләшеп тә тормаган булыр идем. Үзебезнең табигатькә ни җитә! Әйе-әйе, бик дөрес уйлагансыз. Төнлә ай яктысында кармак салып, көндезләрен кайнар кояш астында кызынып ятарга мин дә каршы килмәс идем.

– Сез дә ял алыгыз, иптәш начальник. Бергә-бергә хозурланырбыз.

– Булмый, егетләр. Ярамый миңа, врачлар кушмый.

– Безгә куша, ә, Җәмит?!

– Әйе.

Хәмит белән Җәмит, кояшта кызынырга ярамаган начальникларын чын күңелдән кызганып, бераз ах-вах иттеләр дә ишеккә юнәлделәр. Тоткага үрелергә торганда, аларны начальник туктатты:

– Бер генә минутка, егетләр! Сез балта, пычкы тоту мәсьәләсендә ничегрәк?

– Кирәк чакта балтасын да, пычкысын да тотабыз, иптәш башлык.

– Әйбәт, әйбәт. Юкса хәзер палаткага казык юна белүчеләр дә бетеп бара.

– И-и, без казык юну гына түгел, кирәк булса, дворец салып керә алабыз. Әкияттәге җен-пәриләр кебек. – Дуслар бер-берсенә күз кысып, көлешеп алдылар. – Әллә соң Идел буена бер дворец салып җибәрик микән, ә?

– Вәт, вәт, – диде начальник. – Нәкъ менә шулай эшләгез. Күрсәтегез осталыгыгызны. Материалын актык шөрепкә кадәр китерермен.

Егетләр һични аңламадылар.

– Сез шаяртасыз бугай, иптәш начальник.

– Юк-юк, бернинди шаярту юк. Миңа Идел буеннан дача өчен участок бирделәр. Төннәрен ай яктысында балык каптырасыз, көндезләрен кызына-кызына өй салырсыз. Серегезне хатыннарга чишмәскә полный гарантия бирәм. Бик күңелле, бик романтичный ял булыр бу, егетләр, ә?

## РӘХМӘТ ЯУСЫН!

Газимә белән Рифнең үзләренә таба килүләрен күреп, Идрис коелып төште:

– Кадрия, бетте баш, Рифләр килә, – диде ул хатынына. – Нишләргә икән?

– Кач син, Идрис, кач, – диде хатыны. – Өйдә юк, диярмен.

Шәһәр өендә кая качасың? Идәнне ачып, рәхәтләнеп төшеп ятарга базың юк. Идрис ары сугылды, бире сугылды, тик башын тыгар урын тапмады. Шифоньер эченә чуммакчы иде, анда шыплап тутырылган кием икән. Өстәвенә, ишеген ачып җибәрүгә, борынга тончыктырырлык булып нафталин исе килеп бәрелде.

– Нафталинны потлап тутырмасаң! – дип сукранды ул хатынына.

Диван астына тыгылып караган иде, матур гына түгәрәкләнеп килүче корсагы сыймады. Ул шулай үзенең ике бүлмәле фатирында бер башына урын тапмый йөргән арада, Рифләр, килеп җитеп, ишектәге кыңгырау төймәсенә бастылар. Бу кыңгырау әйтерсең ишек өстенә түгел, Идриснең баш эченә кертеп урнаштырылган, чигәләргә бәреләбәрелә чыңлады. Идрис хәтта чайкалып китте.

– Тахтага сузылып ят, булмаса, – диде хатыны. – Өстеңә аяк астындагы келәмне ташлармын.

Ишектә шылтырау көчәйгәннән-көчәйде. Кадрия, борылып китмәсләрме әле дигән өмет белән, юри әкренрәк кыймылдады. Ләкин Рифләрнең китү ниятләре юк иде, күрәсең. Шылтыраттылар да шылтыраттылар. Ирен ыша-нычлы итеп яшергәч кенә, Кадрия ишекне ачты.

– Кадерле кунаклар бар икән, – диде ул ачык чырай белән. – Әйдәгез, әйдә! Бик вакытлы килдегез. Идрис тә өйдә юк. Ул югында аулак өй ясарбыз.

Кайбер кешене никадәр ныграк кыстасаң, шуның кадәр тизрәк китүчән. Кадрия әнә шул нияттән чыгып әйтте бу сүзләрне.

– Идрис өйдә юк икән, – диде Риф, ләкин аның кәефе бозылмады. – Ничава, исән кеше бер кайтыр, көтәрбез. Шулаймы, Газимә?

– Әйе. Безнең вакыт күп, – диде Газимә. – Озаклап утырырга килдек. Менә монда бераз күчтәнәчләр бар иде, алып куй әле шуларны, Кадрия дускай. Идрис кайткач ачарбыз.

Газимә иренең кулыннан күчтәнәчләр салынган портфельне алды һәм ахириенә тоттырды. Портфель Идрис корсагыдай кабарынкы иде. Аннан ике шешә шампанский, бер шешә виски, кыйммәтле шоколад-конфетлар белән эреле-ваклы кызыл һәм кара уылдык консервылары, тагын әллә ниләр, әллә ниләр килеп чыкты. Хәтта Кадрия ханымга зур чәчәк бәйләме алып килергә дә онытмаганнар иде. Бу кадәр күчтәнәчләрне күргәч, Кадрия куркуга калды.

– Сез нәрсә? Сез нәрсә? – дип кабатлады ул. – Нигә бу кадәр күчтәнәч төяп йөрисез? Нәрсә хөрмәтенә?

Газимә белән Риф бер-берләренә серле карашып, күз кысышып куйдылар. Янәсе, нәрсәгә икәнен без яхшы беләбез. Янәсе, сез әле күчтәнәчнең моннан зуррагына лаек кешеләр. Бусы әле баласы гына.

Кунаклар белән бераз тегене-моны сөйләшеп утыргач, Кадрия, кухняга кереп, чәй әзерләргә кереште. Аның кәефе юклыгы һәр хәрәкәтеннән күренеп тора иде. Газимә, Кадриянең күңелен табарга тырышып, бер алдына, бер артына төште. Узган килүдә «бигрәк шыксыз нәрсә» дип хурлаган кухня шкафын болай дип мактап алды:

– Карап-карап торам да, Кадрия, бу шкафыгыз бигрәк килешле булган. Бөтен савыт-саба сыйган үзенә. Шушындыйрагы очраса, без дә алырга дип торабыз әле.

Чәй кайнап чыкты. Кадрия табынны кухня ягына әзерләмәкче иде, Газимә каршы төште:

– Иркендә, зал ягында утырыйк. Тар җирдә кысылып туйган.

Идрис кайтканчы бераз җылына торыйк дип, бер шампанскийны ачтылар. Кадриянең күңелен шампанский да күтәрмәде. Риф белән Газимә генә гөрләштеләр. Аларның шатлыклары эчләренә сыймый иде. Ике сүзнең берендә - Кадрия белән Идрискә рәхмәт укыдылар. «Чын дөреслекне ничек әйтергә? Әгәр хәзер аны әйтеп салсаң, канатлары сыначак. Кешенең юкка шатланганын күрүдән авыр нәрсә юктыр. Идрисне качырасы калмаган. Үзе пешергән ботканы үзе ашасын иде», – дип пошынды Кадрия.

Табын кызып кына килгәндә, йокы бүлмәсендә бер-бер артлы әллә ничә тапкыр Идрис төчкереп җибәрде. Әйтерсең аның борынына песи баласы койрыгын тыгып болгап тора, һич тыела алмый. Кадриянең каушаудан кулыннан чынаягы төшеп китте.

– Бәрәч! – дигән булды ул. – Мин югында әллә Идрис кайтып ятты микән?

Дәррәү кузгалып, йокы бүлмәсенә кереп киттеләр. Анда калын келәм астыннан Идриснең аяклары тырпаеп тора иде. Риф сөенеченнән өйне яңгыратып кычкырып җибәрде:

– Менә бәхет, валлаһи! Син өйдә икәнсең. Тор, тор, хатыныңнан качып, көпә-көндез йоклап ятма. Хәйләкәр таз. Өстенә нәрсә ябынган.

Риф дусты өстендәге келәмне тартып төшерде. Идрис ирексездән торып утырды, күзләрен угалады.

– Йоклап кителгән шул, – дигән булды.

Риф аның аклануларын гел ишетмәгәндәй кыланды:

– Әйдәле, әйдә, – диде ул, үзен хуҗаларча тотып. – Анда безнең чәйләр, мәйләр суынадыр. Бер гөрләшеп утырыйк. Мондый җай гел-гел эләкмәс.

– Газимәләр зур күчтәнәчләр белән килгәннәр, – дип, сүз кыстырасы итте Кадрия. – Табын әзер, чыгыйк әйдә.

Кадриянең йөзе «болардан барыбер котыла торган түгел, иң яхшысы – язмышка буйсыну» дигәнне аңлата иде.

Өр-яңадан табынга утырыштылар. Риф тост әйтте:

– Мин матур сүзләргә оста түгел, – диде ул. – Бу рюмкаларны менә сезнең хакка, кеше хәлен аңлый белүче якын дусларыбыз хакына күтәрик. Рәхмәт сезгә, дуслар!

– Туктагыз әле, тукта, – дип, урыныннан күтәрелде Идрис. – Сез хәлне киресенчә аңлагансыз, ахры. Мин бит...

– Син шул, син, – дип бүлдерде Риф. – Менә шул синең хакка күтәрәбез инде. – Һәм ул, хуҗаларның ай-ваена карамыйча, салган рюмкаларны эчәргә мәҗбүр итте. – Менә шулай, дуслар. Сезнең кебек кешеләр булганда, дөньяда яшәүләре үзе олы куаныч.

Идриснең капкан кабымы бугазына аркылы утырды. Аңа чиктән тыш авыр иде.

– Мин, – диде ул үлемгә хөкем ителгән кеше тавышы белән, – башкача эшли алмадым инде. Үпкәләсәгез үпкәләгез, сүксәгез сүгегез.

– Нинди сүгү! Нинди үпкәләү! Рәхмәт яусын, бары шул гына! Мең-мең рәхмәт!

– Мин бит сезнең туганыгызның малаен институтка үткәрә алмадым. Математикадан өч сорауның берсенә җавап бирә алмады.

Әйтәсе хакыйкатьне әйткәч, хәзер мине теләсә ниш-ләтегез дигәндәй, хәлсезләнеп, урынына утырды Ид-рис.

– Менә-менә, шуның өчен килдек тә инде без, – диде Риф, сөенечен яшермичә. – Минем теге вакытта тел төбемне дөрес аңлагансың син. Рәхмәт, дускай. Әгәр ул малай институтка керә-нитә калса, безнең башка бәла була иде. Әниләре, квартирда сездә торыр, дип, әллә ничә хат яздылар инде. Коткардыгыз, рәхмәт! Монысын да коткаручылар өчен, сезнең өчен эчик, дуслар! Әйдәгез әле.

## МАЙ ТӨНЕ

Май төне.

Шомырт чәчәк аткан ап-ак йолдызлы май төне. Нинди генә матурлык юк та, нинди генә бизәкләр юк синдә! Кемнәрнең генә йөрәгенә мәхәббәт, дәрт, өмет алып килмисең син, май төне. Менә хәзер ул яңа гына яфракларын ачкан хуш исле юкә ышыгында беренче мәртәбә сөйгәнен көтәдер. Билгеләнгән вакытның тизрәк килүен көтеп ашкынадыр, һәр үткән минут аның дулкынлануын арттырадыр. Бәлки, ул бүген гомерендә беренче мәртәбә кесәсенә көзге салып чыккандыр һәм, очрашу минутлары якынлашкан саен, йөзен якты йолдызларга борып, көзгегә карыйдыр. Чибәр булса, ул үзенең чибәрлеген күреп шатланадыр һәм үзенең сөелүенә ышанычы артадыр. Хәер, яшь вакытта һәркем чибәр була. Яшьлек кешене үзе бизи. Бигрәк тә табигать үзе чәчәк аткан йолдызлы май төнендә. Мондый көндә дәртсез йөрәкләргә дәрт кабына, авыру күңелләр савыга. Картларны яшәртә, яшьләрдә мәхәббәт уты кабыза, сүлпән йөрәкләрне дәртләндерә, хыялсыз кешеләрне дә каядыр ашкындыра ул май ае.

Бәлки, аңар бүген унҗиде тулгандыр. Һәм бүген сөйгәненә багышлап беренче шигырен язгандыр. Унҗиде яшь чакта күңелдә шигырь, бары тик татлы хыялларга төренгән мәхәббәт хисләре генә булуын кем белми соң! Кем соң шушындый йолдызлы май төнендә сөйгәненә багышлап җыр җырламаган да, кем генә үзенең сөйгәнен күктәге якты йолдызларга тиңләмәгән. Кемнәрнең генә иреннәре татлы мәхәббәт сүзен пышылдамаган да, кем генә ул иреннәрнең кайнарлыгын йөрәгендә сакламаган!

Галәм биеклегенә күтәрелгән космонавтлар да, бәлки, иң беренче тапкыр шушы май төнендә балкыган йолдызларга гашыйк булгандыр. Йолдызларның шаярышып күз кысышулары аларны канатландыргандыр, үзләренә чакыргандыр.

Яшьлек кебек гүзәл, яшьлек кебек кыска син, май төне.

Кем белә, бәлки, шушы кыска май төнен дә уздыра алмаучылар күптер. Берәр тынгысыз агроном яңа гына шытып чыгып килгән уҗымнарын күзәтеп йөридер. Һәм үсеп килүче балаларын күреп шатланган анадай, уңышлары өчен куанадыр. Яшел басулар җирне генә түгел, аны да яшәртәдер.

Йә булмаса, берәр карт бакчачы, алма чәчәкләренә кырау төшмәсен дип, бакчасында, төтенли-төтенли, учаклар ягып йөридер. Ул вакытсыз коелган һәр чәчәк өчен борчыладыр, шул чәчәкләрне кыраудан саклый-саклый, үз чәчләренә кырау төшкәндер.

Бәлки, хәзер бер ана сабыеның елавыннан уянып киткәндер дә тәрәзә аша җемелдәшкән йолдызлар яктысында үзенең нәниенә әкрен генә җырлар җырлыйдыр. Ә ул сабый ананың йомшак кулларында изрәп кабат йокыга таладыр. Тынычсыз ана, кайдадыр ерактан ишетелгән беренче күкрәү тавышына баласы куркып уянмасын дип, тәрәзәләрен ябадыр. Ана үз баласының тәмле йокысын бернинди күкрәү тавышы бүлдермәвен тели. Баласының йөзендә яшен кылычларыннан төшкән шәүлә түгел, бары тик йолдызлар нуры гына уйнасын, ди. Күкрәүләрдән, шаулаулардан куркып уянмасын, бәлки, кошлар сайравын, гөрләп торган тормыш авазын ишетеп уянсын ул, ди. Һәрвакыт шат, һәрвакыт көләч йолдызлы төннәрне һәм хезмәт җыры яңгыраган гүзәл иртәне генә тели ана.

Ул гына да түгел, кырларын кайгыртып йөрүче агроном да, беренче мәртәбә гашыйк булган яшь йөрәк тә, алма чәчәкләрен кыраудан саклаучы карт бакчачы да – барысы да шуны телиләр. Барысы да шушындый май төнендә илебезнең тыныч уянуын телиләр. Алар һәммәсе дә тормышка гашыйклар, ә гашыйк булган кеше һәрвакыт яхшыны, һәрвакыт гүзәллекне генә тели.

## ШӨПШӘ

Авылга атаклы экстрасенс Зөбәеров килә икән дигән хәбәр тыныч кына яшәп яткан халыкны әсәрләндереп җибәрде. Тавык та чүпләп бетерә алмаслык эштән ярым миңгерәүләнеп, хыяллану, киләчәктән яхшылык өмет итү дигән нәрсәне тәмам онытып бетергән кешеләрнең күзләрендә өмет утлары кабынды. Ирләре эчкән хатыннар җәмәгатьләрен бу афәттән коткару турында хыялланды. Аяксызлар – аякка басу, күзсезләр – күрә башлау, чукраклар – ишетү, картлар яшәү өмет итте. Урамда ике-өч кеше очрашса, сүз гел шуңа күчте.

– Карале, ахирәт,– диде Минҗамал үзенең күршесе-нә, – бу экс-микс дигәннәре теш үстерә ала микән?

– Син бигрәк инде, – диде күршесе, – теш тә үстерә алмагач, нинди духтыр ди ул?! Мин әле, ахирәткәем, бер утыз яшькә яшәрергә дип торам. Пенсиям Аллага шөкер. Акчаны күбрәк төртсәң, япь-яшь кыз итәр дә куяр, боерган булса.

Аларның сөйләшкәнен ишетеп, ике аягын да Герман җирләрендә калдырып кайткан Мирвәли карт килде.

– Хыялланабызмы, кызлар? – диде ул.

Аның «кызлар» дигән сүзе карчыкларның күңеленә сары май булып ятты. Минҗамал түтинең тешсез авызы ерылып ук китте. Ул, бераз авызын җыяр хәлгә килгәч:

– Безнең ише «яшь кызлар»ның бөтен эше хыяллану инде, – диде.

– Ярый, ярый, – дип хуплады аны Мирвәли карт, – менә минем үземнең дә эчкә өмет корты кереп оялады әле. Кем белә, бәлки, картайган көнемдә мин дә шушы тәгәрмәчле «аяклар»дан котылырмын. Ходайның рәхмәте киң бит аның.

Бу хәл һәр капка төбендә диярлек кабатланды. Кеше-ләр бүтән, ләкин репертуар шул ук иде. Карт-коры, бала-чага бәрәңге бакчасында колорадо коңгызы чүпләүдән туктады. Авыл көтүе соңрак китте, иртәрәк кайтты. Күп кенә сыерлар савылмый калды. Тавык йомыркалары оядан алынмады. Бакчадагы кыяр-помидорлар су сипмәүдән көя башлады. Авыл тәмам чыгырыннан чыкты. Билетлар күптән сатылып беткән иде, аларны кыйбатрак бәягә яңадан сату-алу китте. Колхоз рәисе бу хәлгә нинди чара күрергә белмәде, чөнки авылда бөтен эш тукталды.

Ниһаять, көтелгән кунак килеп җитте. Авылның өч йөз илле кеше сыйдырышлы клубына тугыз йөз дә туксан тугыз кеше җыелды. Барлык күзләр сәхнәгә текәлде. Экстрасенс ни өчендер көттерде. Шаулап кул чабулар, төрлечә кычкырулар башланды. Бер почмакта бала еларга тотынды. Шул баланың елавын гына көткәндәй, әкрен генә пәрдә ачылды. Пәйгамбәр кебек көтеп алынган экстрасенс сәхнәгә чыгып басты. Аның ике ягына ике ярдәмчесе урнашты. Алар хуҗаларына тугрылык күрсәтеп, теге ни әйтсә, шуңа баш иеп, раслап тордылар.

– Мин, – дип башлап җибәрде сүзен могҗиза тудыручы, – дөньяны һәлакәттән коткарырга дип килдем. Күреп торасыз, дөнья бетүгә бара. Тегендә җир тетри, шәһәрләр җимерелә, монда су баса. Тегендә кояш тотыла, монда ай кителеп төшә. Ә мин шушы хәлләрнең буласын алдан ук белеп торам. Шуларны булдырмый калу өчен тырышам. Кичә Кокаду атавында җир тетрәргә тиеш иде, мин шуны булдыртмый калдым. Бүген сезнең Өемташ тавыгыз ишелергә тиеш иде, мин тауны урынына утырттым. Юкса бөтен өйләрегез белән ком вә таш астында калачак идегез.

Халык экстрасенска шаулатып кул чапты. Шау-шу тынгач, бер карт, сикереп торып:

– Син, энем, ятьрәк башласаң иде, – диде. – Менә минем ике күзем дә тома сукыр. Тизрәк күзләремне ачсаң, шундый кодрәткә ия кешене күрер идем.

Сукыр картның сүзенә бүтәннәр дә кушылды.

– Давай, энем, тизрәк дәвалый башла.

Могҗиза иясенең чырае сытылды.

– Сез нәрсә, – диде ул рәнҗүле тавыш белән, – миңа ышанмавыгызмы бу?

– Ышанабыз, энем, ышанабыз, – дигән тавышлар яңгырады.

– Ышангач, тыныч кына утырыгыз, – диде экстрасенс, – мин бит инде сезне каршыгызга чыгып басканнан бирле дәвалап торам. Күбегезнең аркасыннан чымырдап ток үткәндер. Ул ток кара тир булып тәннәрегез буенча агып төшәр...

Клуб бөркү һәм суларга һава җитмәгәнлектән, күп-ләр манма тиргә баткан иде. Экстрасенсның сүзләрен ишеткәч, бер йотым саф һава сулагандай җиңеләеп болай уйладылар: «Кара син аны, бөтенесен белә икән бит. Аркалар да чымырдап киткән иде шул!»

Экстрасенс дәвам итте:

– Мин сезнең тәннәрегезгә кагылмаган килеш теләсә нинди операция ясый алам. Йөрәкләрегезне бавыр, бавырларыгызны сукыр эчәге урынына утыртып кую минем өчен берни тормый. Мин инде кушылып туган сиксән сигез игезәкне аердым. Мең дә алтмыш алты кешенең йөрәген алып ташлап, өр-яңаны куйдым. Мин... мин...

Ул тагын нидер әйтергә уйлап авызын ачкан иде, фор-точкадан очып кергән галәмәт зур сары шөпшә аның теленә килеп кунды. Экстрасенс аһ итте, кинәт чәбәләнергә тотынды. Залдагы халык эшнең нәрсәдә икәнлеген аңламый торды. Могҗиза тудыручының яр-дәмчеләре генә хәлне бик тиз күреп алдылар һәм хуҗаларына ярдәмгә ташландылар. Шөпшәне куа башладылар. Шөпшә экстрасенсның бит тирәсендә шактый бөтерелгәч, аның кулындагы микрофон янында выжлый башлады. Залда шөпшәнең выжлаган тавышы яңгырады. Алдагы рәттә утыручыларның күбесе шөпшәнең үзен дә күреп алды. Залда: «Шөпшә! Шөпшә!» – дигән тавышлар ишетелде.

Күпләр бу шөпшәне күрер өчен торып ук бастылар. Ә шөпшә, могҗиза тудыручыны юри мыс-кыл итәргә теләгәндәй, һаман аның бит тирәсендә очты. Могҗиза тудыручы чәбәләнде, бәргәләнде, үрле-кырлы сикерде. Ярдәмчеләре, шөпшәгә сугам дип, хуҗаларына китереп-китереп сыладылар. Бу тамаша залда утыручыларга бик кызык тоелды. Көлеш, кычкырыш китте. Арттагы рәттәгеләр алдагыларга: «Иелебрәк утырыгыз. Бөтен кызыкны сез генә күрергә димәгән», – дип кычкырдылар. Халык, клубка ни өчен җыелуын да онытып, бу мәзәк хәлне тамаша кылды. Шунда берсе: «Әй син, бөек кодрәт иясе, бер шөпшәдән куркып торасың. Юк ит әле шуны һәммәбезнең күз алдында», – диде. Аны башкалар куәтләде: «Давай, давай! Синең өчен шөпшә нәрсә ул! Күрсәт нинди көчкә ия икәнеңне».

Экстрасенс аларның тавышын ишетерлек хәлдә түгел иде инде. Ул чәбәләнә, бәргәләнә торгач, хәлсезләнеп, сәхнәгә ауды. Аны ике ярдәмчесе, күтәреп, сәхнә артына алып чыгып китте. Халык, тамашаның болай тиз бетүенә канәгатьсезлек белгертеп, теләр-теләмәс кенә клубтан тарала башлады. Ә икенче көнне бөек тылсым иясе Зөбәеров турында район газетасында зур мәкалә чыкты. Анда мондый юллар бар иде: «Дәверебезнең бөек тылсым иясе Зөбәеров кичә К... авылында үзенең сәламәтләндерү сеансларын үткәрде. Сеанс вакытында ун кешенең күзе ачылды, өч кеше рак дигән зәхмәттән котылды, җитмеш җиде кешенең йөрәгенә операция ясалды. Бер генә көн соңарсалар да, алар инфарктган үләсе булганнар. Ә иң кызыгы шул: йөз яшьлек бер картның алтмыш ел буе йөрткән бүсере бака булып сикереп төште. Әйе, болары шулай. Тик менә бөек кодрәт иясе Зөбәеров үзенең артык тырышлыгы аркасында К... авылында зур казага тарыды. Бер хатынның телен дәвалаганда, тел, шөпшә булып очып чыгып, гасырыбызның иң атаклы кешесе Зөбәеровны чакты. Хәзергесе көндә Зөбәеров больницада ята. Аның тизрәк сәламәтләнеп чыгуын телик, кадерле милләттәшләр».

## «САНДУГАЧ»

Җәйнең матур көннәре. Илнур да әтисе белән апасы янына колхозның алма бакчасына торырга күчте. Һай, биредәге рәхәтлек: саф һава, кошлар тавышы, яшел алма-төймәләрнең көн саен зураюларын күзәтү, кояшта кызынулар... Җитмәсә, үзеңне хуҗа итеп тою гына да ни тора. Соңгы вакытларда ул бигрәк тә үсеп киткәндәй булды. Әтисе аңа үзенең куш көпшәле ау мылтыгын тоттыра башлады. Дөрес, ул мылтыкның бервакытта да корылганы юк. Шулай да мылтык мылтык инде. Аны тоткач, Илнур, олы абыйлардай җитдиләнеп, бер башка үсеп киткәндәй була.

Кулына мылтык эләккән көнне Илнур берәр карак тоту турында хыяллана башлый: кичен бакчаның иң караңгы почмакларына кадәр бара, агачтан төшкән күләгәләрне җентекләп күзәтә, куерак, шиклерәк утырган куаклар арасына керә. Әмма бер генә карак та очрамый.

Бүген, карак тотудан тәмам өметен өзеп келәткә кайтырга борылганда, ул якында гына өздереп-өздереп бер кош сайраганын ишетте. Ишетте дә тын да алмый туктап калды. «Бу нинди сандугач, август аенда тилергәнме әллә? Тукта-тукта, бу кеше ич». Кечкенәдән табигать кочагында үскәнгә, кайсы кошның кайчан сайравын яхшы белә иде ул. Шыпырт кына шул якка таба атлады да:

– Кем бар анда? Атам! – дип кычкырып җибәрде.

Һәм кемнеңдер кузгалганы ишетелде.

– Тагын бер адым атласаң атам. – Куркудан үзенең дә тез буыннары калтыранып куйды.

– Бу мин, Ришат абыең бит...

Илнурның эченә җылы йөгерде. Таза гәүдәле бу шофёр егетне ул бераз якын да итә иде. Машинасы белән очрады исә, Илнурны һич тә утыртмый калмый. Хәтта кул күтәрмәсә дә. Тик шунысы гына, Гөлүзә апаң фәләнме, Гөлүзә апаң төгәнме дип, гел-гел сораша. Илнур кечкенә малай түгел, белә ул аның ни өчен икәнен. Әле дә тикмәгә генә бакчага килмәгәндер.

– Ришат абый булгач, нишләп монда йөрисең?

– Менә эшләпәм, очып, агачка кунды, шуны алыйм дигән идем.

– Тик торганда эшләпә агач башына кунамыни? Хәзер үк үкчәңне күтәр!..

Келәткә кайткач, өчәүләшеп кайнар бәрәңге ашап утырганда, теге «сандугач» тагын сайрап җибәрде. Бу юлы ул бакчаның икенче ягыннан ишетелә иде. Әтисе әллә ишетмәде, әллә ишетеп, кызын кызартмас өчен, бөтенләй игътибар итмәгән төсле, һаман ашавында булды. Ә Гөлүзә үзе шундук ашавыннан туктады.

Кара, кара кыланышын гына, табынны да җыеп торасы түгел, урыныннан җәһәт кенә торды да чыгып китү ягын карый башлады. Ах, бу Ришат абыйны, кешене апасыннан яздырмакчы. Тукта, кай арада чыгып тайды әле Гөлүзә

апасы? Илнурның җен ачулары купты. Бу көзге «сандугач»ның юлына киртә булырдай берәр нәрсә эшләү турында уйлады. Ахырда, ныклы бер фикергә килеп: «Тотам да эти янына алып киләм үзләрен, – диде. – Ул ачуланып җибәрсә, янадан килмәс. Әле апага тормышка чыгарга иртә. Кем инде егерме икедән кияүгә чыга?»

Илнур ашыга-ашыга «сандугач» тавышы ишетелгән якка китте. Тегеләрне күргәч:

– Кулларыгызны күтәрегез! – дип кычкырды ул.

Ришат абыйсы көлеп җибәрде.

Ә Гөлүзә җитди иде.

– Мылтык белән шаярмыйлар, син бала түгел бит, – диде ул.

– Ә минем шаярырга җыенганым юк. Хәзер икегезне дә эти янына алып кайтам. Бакча таптап йөргәнегез өчен кирәгегезне бирер. Шагом марш келәткә!

Ришат, малайның кыюлыгына соклангандай булып, шаярулы тавыш белән Гөлүзәгә дәште:

– Әйдә, келәткә барыйк, юкса Илнур безне атмагае.

Илнур бу ике дәү кеше үзен тыңлар дип һич тә уйламаган иде, алар берсүзсез келәткә кузгалгач каушап калды. Шулай да мылтыгын төзәп, артларыннан иярде.

Ләкин келәткә кергәч, этисенә аңлатып торырга туры килмәде, Ришат шундук:

– Фазыл абзый, безгә ризалык бир, Гөлүзә белән күптән бер-беребезне яратышабыз, – диде.

Гөлүзә, оялып, шул ук вакытта шатланып, бер Ришатка, бер этисенә карады. Ә Илнур моны бөтенләй көтмәгән иде, мылтыгын аларга төзәгән килеш, шаккатып карап торды. Хәзер бөтен өмет этисендә генә калды.

– Мин нәрсә әйтим инде, балалар, – диде ул да, тамак кыргалап. – Алманы вакытында өзү мәслихәт эш. Әгәр үзегез килешсәгез...

Илнур нишләргә дә белмәде, йөгереп чыгып китте. Апасын бернинди мылтык белән дә саклап тотып булмаячагын ул инде ачык аңлаган иде.

## САБАН ТУЕНДА

Кызыл Тал авылында бүген Сабан туе икән. Дустым Хәмит безгә килде дә кыстапмы-кыстарга кереште:

– Әйдә, барып кайтыйк әле шунда, берүземә генә күңелсез...

Сабан туе дигәндә, аның исе китә инде. Мин дә аны бераз шаяртып алырга булдым.

– Юк, мин бармыйм, бер тамчы суга тилмереп йөргәнче, Ыкка төшеп, бер ухалык балык каптырсам да файда.

– Таптың кызыгыр нәрсә, күп сөйләнмә инде, әйдә, шушындый көнне балыкка йөреп әрәм итәргә... – Ул елга буенда калкавычка карап оеп утыруны бер дә яратмый иде. Аңа кул көче белән каерып алып, киерелеп эшли торган эш булсын. Шулай булмаганда, аның бик тиз эче поша, түземлеге бетә. Ә Сабан туйларында көрәшергә дигәндә, аны куш инде, үзеннән ике тапкыр зуррак кешеләрне сыртына сала. Шуңа күрә ул, якын-тирәдәге авылларның Сабан туйларын ишетсә, берсенә дә бармый калмый.

– Ярый алайса, дуслык хакына барырмын инде, – дидем мин. – Ләкин көрәшәсе булма. Кабырганы сындырырлар да миңа күтәреп кайтырга туры килер.

– Моңарчы кабырганы сындырганнары юк иде әле, моннан соң да булмас дип исәплә, – диде ул да, шаяртыбрак. – Киттек.

Без барып җиткәндә, Сабан туе башланган иде. Ха-лыкның бер төркеме бәйдәге атларны карар өчен юл буенарак җыелган. Бер төркеме – чүлмәк ваткан җирдә. Монда күбрәк карт-корылар һәм бала-чагалар. Без, алар янына тукталып тормастан, көрәш мәйданына таба киттек. Монда һәрвакыттагыча иң тыгыз божра иде. Озынрак кешеләрнең култык асларыннан, кечерәкләрне як-якка төрткәләп, көч-хәл белән көрәшүчеләр эргәсенә кереп бастык. Мәйданда әле малайлар гына көрәшә. Кара сакаллы аксаграк бер абзый, яшь әтәчләр сугыштырган шикелле, мәйдандагы малайларның икесенә дә көч биреп, әле берсен, әле икенчесен үчекләп ала. Аларның маңгайларыннан тир агып төшкән. Берсе борыны белән җир сөрергә дә өлгергән. Шулай да тегесенә караганда тererәк күренә, һәм менә ул иптәшенең билен боргычлап алды да бөтереп тә салды.

– Моңардан рәт чыгар, – дип куйды Хәмит тә.

Малайлардан соң мәйданга зурлар чыкты. Бусы инде тагын да кызыклырак булырга тиеш. Хәмит тә пинжәген салып миңа тоттырды. Ләкин үзе чыгарга ашыкмады. Чөнки беренче булып чыгучыларга авыргарак килүен белә ул. Башкалар да кабынып төшмәделәр. Теге кара сакал, ике егетне тарткалап чыгаргандай уртага чыгарып, кулларына сөлге бирде. Тегеләр, көрәшсәк ярый, көрәшмәсәк ярый, дигән сыман гына селкенгәләделәр дә туктадылар. Янә

тарткалап чыгарырга калды. Шулвакыт ак күлмәкле берәү атылып уртага чыкты. Халык гөж итеп алды. Аңа каршы бик таза бер егет чыккан иде, кара сакал аның колагына нидер килеп пышылдады да кире чигендерде. Башта ак күлмәккә каршы чыгучы булмаса да, бераздан егетләр кыюсыз гына кузгалгалый башладылар. Ләкин ак күлмәк чыккан берен бик тиз аркасына сала барды. Болай карап торуга әллә ни таза да күренми үзе. Әмма аңа тотынган бер кеше балавыздай эри дә төшә. Хәмитнең моңа каны кайный башлады. Ахры, түзмәде, күлмәген салып миңа бирде дә атылып мәйданга чыкты. Теге кара сакал аңа акаеп каршы төште:

– Син, егет, әллә айдан төштеңме? Без монда чит авыл кешеләрен көрәштермибез. Бу – Кызыл Тал Сабан туе, бүләкләр читкә китәргә тиеш түгел. Вәт шул!

Хәмитнең сөмсөре коелды, чуендай мускуллары калтырап куйды. Көрәшнең кызыгы бетте. Кайбер кешеләр тарала башладылар. Хәмит тә мине сөйри башлаган иде, ләкин минем бу көрәшнең ахыры ни белән беткәнен күрәсем килде. Хәер, ул озакка бармады, тагын бер-ике кеше теге ак күлмәк белән селкенгәләп алдылар да, шуның белән көрәш тә бетте. Ак күлмәк батыр булып калды. Теге сакал бик ялагайланып аның кулын кысты да беренче бүләкне тоттырды. Ак күлмәк, ак радиоалгыч тотып, сирәк кенә кул чабулар астында мәйданнан чыкты. Шунда мин янымдагы берәүгә:

– Бу ак күлмәкле агай бик көчле дә күренми, үзе чыккан берен ега, хикмәт көчтә генә түгел, ахры, – дидем.

– Әйе, хикмәт көчтә генә түгел, – диде ул ниндидер бер серле тавыш белән. – Ул безнең колхоз председателе, һәр елны шулай батыр кала. Өченче ел аны тимерче Ибрай еккан иде, авылдан ук китәргә мәҗбүр булды. Шулай ул, хикмәт көчтә генә түгел.

Аның бу сүзләреннән соң Сабан туеның яме тагын да китте. Хәмит тә гомерендә беренче тапкыр, ник барганына үкенеп, иңбашларын салындырып кайтты.

## ГЫЙЛЬМИНУР КАРЧЫК КУРОРТТА

Гыйльминур карчык йокысыннан уянганда бик иртә иде.

– Хәзер авылда көтү китәдер инде, – дип уйлады ул. – Килен сыерны сава алдымы икән? Бер дә башка кеше тотынганны яратмый шул, мүкләккәем. Үзе мөгезсез генә булса да, андый-мондый мөгезле сыерларыңа биргесез. Көтүдә дә янарал кебек гел алдан йөри. Ил-ла, тышаулап сауганны яратмый да инде. Аягында бау барын сизсә, котыра башлый. Андый чакта якын бармавың хәерле. Чиләгең-ниең белән үзеңне тибеп очырырга да күп сорамас.

Оныклар да ни хәлдә икән? Килен, фермага киткәндә, ашарларына калдырырга онытмаса ярар иде. Югыйсә көне буе ач йөрерләр. Фәрите бигрәк шук, бер генә дә тик тормый. Уйнарга гына булсын аңа. Ачыктым димәс, арыдым димәс, көне буе урамда чабар. Аягына кияргә оекбашының да рәте беткән иде бугай, ямап китәргә дә башыма килмәгән. Ярый ла әниләре вакыт табып, берәр нәрсә әмәлләп бирсә...

Карчык шулай пошынып ятты. Курортка баргач, бер туйганчы йоклармын, дип уйлаган иде, баксаң, бу йокы дигәннәре чит җирдә тиз туя икән. Кичтән дә иң соңгы кеше булып ул яткан иде, иртән дә беренче булып уянды. Ә башкалар бары да берни белми йоклый.

Гыйльминур карчык түзмәде, торып урын-җирен җыештырып куйды. Аннан соң каяндыр себерке табып, идәнне себереп чыгарды. Алай да башкалар торыр вакытны җиткерә алмагач, тыштан бер чиләк белән су алып керде һәм, итәкләрен кыстырып, идән юарга тотынды. Ул бу эшне бик бирелеп, сагынып эшләде. Ул шулай бүлмәне ялт иттереп, вазадагы чәчәкләрнең суларын алыштырып, чиләген түгәргә чыкканда, гөнаһ шомлыгына каршы, дежур медсестра очрады. Башта сестра Гыйльминур карчыкны үзләренең берәр санитаркасы дип уйлады булса кирәк, әһәмият бирми генә үткән иде, ләкин бераз киткәч, кире борылып килде. Ул аптыравыннан ни дияргә дә белми торды. Аннары:

– Нишләп сез монда чиләкләр күтәреп йөрисез? – диде.

– Идәннәрне юып чыгарган идем, балам, бер дә йок-лап булмый.

– Йоклап булмаса, дару сорарга иде, мин бирәдә бит.

– И кызым, йокламаганга да дару эч, бөтәнгә дә дару эч, кая китә ул. Авыл кешесе таң белән торырга үрәнгән инде...

– Сез дәваланырга килгән кеше, дарусыз гына дәваланып буламыни? – диде медсестра. – Монда идән юуыгызны онытып торырга туры килер. Врач билгеләгән режимны тотмасагыз, сәламәтләнә алмассыз. Башка андый эшегезне күрсәм, врачка әйтермен. Ә хәзер вакыт җиткәнче урыныгызга ятыгыз.

Гыйльминур карчык «режим»ның ни икәнен белмәсә дә, урынына барып ятты. Әмма, бәхеткә, озак ятарга туры килмәде. Кешеләр йокыларыннан тора башладылар. Аннары бар да, чыгып, физзарядка ясап керделәр. «Монда гел солдаттагыча икән, – дип уйлады ул. – Бары да Зарифулла мәрхүм сөйләгәнчә».

Менә иртәнге ашка барыр вакыт җитте. Гыйльминур карчык кына артык ашамады. Башкалар ашап туйсын әле, безгә, карт кешегә, калдык-постык та ярар дип уйлады ул.

Гыйльминур карчык ашханәгә кергәндә, өстәлләр бушый башлаган иде. Ул бер ишек янындагы өстәлнең кырыена гына килеп утырды. Өстәлдә чәйнек белән чәй һәм бер тәлинкә ипи тора иде. Гыйльминур карчык, миңа иртәнгелек шушыдыр инде дип, ипи белән чәй эчәргә кереште. Ул бер-ике кабарга да өлгермәде, аның янына официантка кыз йөгереп килеп җитте.

– Бик соңга калдыгыз, әллә, беренче көн булгач, йокыдан уяна алмадыгызмы? – диде кыз. – Яңадан кешеләр белән бергәрәк килергә тырышыгыз, юкса ашлар суына.

– Ярар, балам, шулай итәрмен, – диде карчык. Ә үзе, кызның бик күп ризыклар күтәреп янына килүен күргәч, куркынып китте.

– Әллә, балам, монда бүтән кеше урынымы? Нигә ул хәтле ташыйсың?

– Юк, әби, сез генә калдыгыз. Башкалар бар да ашап киттеләр.

– Шулай да күп тезмә, калып әрәм булыр бит. Миңа, карчык кешегә, ипи белән чәй дә ярар.

– Монда, әби, картына да, яшенә дә бертигез бирәбез.

Кыз китеп баргач, карчык тәгамнең кайсына тотынырга белмичәрәк торды. Ризыклар бик тәмле күренә, шулай да ул барысына да кашык тыгарга батырчылык итмәде. «Мин кашык тыкканны бүтән кеше ашамас, бүтәннәре чиста көе калсын», – дип, бары тик манный боткасын гына ашады. Ашап туйгач, карчык уч төбенә генә догасын укыды. Аннары ашаган тарелкасын да, чәй эчкән чынаягын да күтәреп кухня ягына кереп китт е.

– Кызым, монда савытларны кайда юалар? – дип сорады ул.

Аш ташучы кыз карчыкны күреп шаккатты. Аннары бу кызыкны башкалар да күрсен дип, бүтәннәргә дә әйтергә эчкә кереп китте. Күп тә үтмәде, кухня ягыннан берничә хатын-кыз атылып чыктылар һәм көлешә башладылар. Гыйльминур карчык, үзенең берәр җиренә аш тамганмы әллә дип, түшләрен сыпырып карады, ләкин алай көләрлек сәбәп тапмады.

– Миңа савытлар юа торган җирегезне генә күрсәтегез инде.

– Апа, без монда савытларны үзебез юабыз, – диде өлкәнрәк кыз. – Китерегез үземә. Башка алай итмәгез.

– Ашаган савытларны да кешедән юдырырга, әллә мин капрал хатынымы? – диде карчык кыза төшеп. – Тарткалашып та тормагыз, кая, юа торган җирегезне генә күрсәтегез дә... – Һәм ул зырылдап эчкә кереп китте. Бар да ах итеп калдылар. Ә Гыйльминур карчык беркемгә дә карамыйча, кран төбендә үзенең савытларын юып, эшен бетереп чыгып китте.

Ашханәдән кайткач, карчык тәмам уйга калды. «Әллә соң болар мине берәр нәчәлник хатыны дип уйлыйлар микән? Алай дияргә дә кыяфәтем килмәгән инде. Нигә бу кадәр кадерлиләр соң? Иртән торгач, үз бүлмәңне җыештырма, ашагач, савытларыңны юма, ул ни була инде. Мөгаен, болар минем җыештыручы гына булып эшләвемне белмиләрдер. Әллә кая кеше өлеше ашатып яткырмагайлары. Болай кадер-хөрмәт булгач, әйбәтен әй-бәт тә, соңыннан кыенга туры килер». Әмма ул кемгә дә бу пошынуын әйтергә белмәде.

Менә, ниһаять, Гыйльминур карчыкка сүзен әйтергә җай чыкты. Беркөнне шеф-повар кешеләрдән, нинди зарларыгыз бар, дип сорап йөрде. Гыйльминур карчык, бу форсаттан файдаланып, аны бер яккарак дәшеп алды да:

– Кызым, сиңа сүзем барые, – диде.

– Әллә заказыгызны бирмиләрме? – диде повар, пошынып. – Әйтегез, бер дә тартынып тормагыз.

– Юк, балам, барысы да әйбәт. Гел, ни язый к, ни ашыйсың килә, дип кенә торалар. Иртән торсаң, идән-нәргә хәтле юып чыгып китәләр. Менә шул артык кайгыртуларына шикләнәм мин. Әллә кая кеше өлеше ашатып яткырмагайлары дим. Мине алар әллә кем дип белделәр бугай. Мин бит җыештыручы гына.

– Ничек? Нәрсә җыештыручы? – диде повар, берни дә төшенмичә.

– Менә-менә. Мин үзем дә шулай булыр дип уйлаган идем, хәзер үзең дә шаккаттың. Мин идарә җыеш-тыручысы, вәт шул. Алар мине нәчәлниктән дә ким сыйламыйлар.

Ниһаять, повар аңлады. Кычкырып көлеп җибәрде:

– Монда, әби, бернинди начальниклар да юк, монда бар да дәваланырга килгән кешеләр, авырулар. Җы-ештыручымы ул, бозау караучымы, безнең өчен барыбер. Без барысына да кулдан килгән хәтле кадер-хөрмәтне күрсәтергә тиешле. Без шуның өчен куелган.

Гыйльминур карчык ышанырга белмичә башын чайкап куйды. Ә үзе, барыбер булса күрербез, иртәгә ничек карарсыз икән, дип уйлады.

Икенче көнне дә Гыйльминур карчыкны ашханәдә шундый ук ягымлы чырай белән каршы алдылар. Аш ташучы кызлар, бик якын кешеләрен күргәндәй, аның белән исәнләштеләр. Ә теге беренче көнне хезмәт күрсәткән кыз:

– Әби, заказыгыз нәрсә, ниләр китерим? – дип сорады.

– Заказым юк минем, – диде әби.

– Өегездә нииндирәк ашларны яратып ашый идегез соң?

– Кызым, мин бөтен нәрсәне дә яратып ашыйм, минем бит эчке якларым таза, Аллага шөкер. Тик менә бераз аяклар гына сызлый. Миңа ипи белән бәрәңге дә бик ярар, мәшәкатьләнмәгез.

– Юк инде, әби, ипи белән бәрәңге ашап кына тазара алмассыз. Аларны өегезгә кайткач та ашарсыз, монда тәрбияләнергә кирәк. Менә, әби, бик әйбәт сарык итеннән генә пешерелгән өчпочмак бар, әллә шуларны китеримме?

– Ярар алайса, китер.

– Ә икенчесенә ни китерим?

– Сөтле чәй.

– Чәйне китерербез, ләкин анысы аш санына керми.

– Чәй белән өчпочмак булгач, бүтән нәрсә кирәкми инде, кызым.

Гыйльминур карчык бүген бик әйбәтләп тамагын туйдырды. Башка көннәрдәге кебек, кеше ризыгын ашыйм дип тә шикләнмәде. Хәзер инде монда чынлап та бөтен кешегә дә оҗмах икән дигән нәтиҗәгә килде ул. Күңеле тәмам тынычланды.

Әмма күңеле тынычланса да, мондагы эшсезлеккә һич кенә дә күнә алмады. Башкасына өйрәнә дә башлаган иде, ләкин урын өстендә күпме генә аунаса да, көндезге йокысын йоклый алмады. Йоклый алмый ятканда, башына төрле уйлар килде. Оныкларының оекбашлары, бияләйләре тәмам тузып беткәндер кебек тоелды. Беркөнне ул башкаларга әйтми-нитми генә якындагы авылга китте һәм аннан бер төргәк йон алып кайтты. «Көндез барыбер йоклап булмый, ичмасам, бер эш булыр», – дип, балаларына оекбашлар бәйләргә кереште. Җеп эрләргә орчыгын да тапкан, кабасына да аптырамады, кешеләр күрмәгәндә үзенең караватъ башына бик әз генә итеп йонны бәйли дә әкрен генә җепне тартып ята. Әкрен эшләсә дә, эше үрчеп кенә тора. Кайтыр вакыт җиткәндә, Гыйльминур карчыкның чемодан төбендә дүрт пар оекбаш ята иде инде.

## ПОСЫЛКА

Аларның тормышлары тын гына, салмак кына аккан елганы хәтерләтә иде. Дөнья яңгыратып куанырлык шатлыклары, күз яшьләре түктерерлек кайгылары юк. Элегрәк берәр бик кирәкле дип санаган әйберләрен кулга төшерә алсалар, сөенечтән балкып, берничә көн гел шуның турында гына сөйлиләр иде. Тора-бара мондый шатлыклары да бетте, чөнки инде тормышлары өчен кирәкле һәммә нәрсәләре дә бар: менә дигән фатир, зәвык белән эшләнгән җиһазлар, мода үзгәргән саен яңарып торган өс-баш.

Эшләгән җирләрендә артык макталмасалар да, соңгылар рәтеннән саналмыйлар. Квартал саен диярлек пре-миясен алалар, отпускыларын бергә-бергә, җәйнең ямьле вакытында, көньякның иң матур курортларында үткәрәләр. Җыеп кына әйткәндә, дөньяның барча рәхәт-лек-ләреннән файдаланып, ала алганның һәммәсен алып, пошыну-бор-чылуларсыз яшәп, кайгының һәм шат-лыкның тәмен онытып барганда, авылдан посылка килеп төште аларга. Посылка Гыймайның абыйсыннан иде. Җибәргән бүләк-ләре нәрсә диген әле: авызыңнан сулар китерерлек, рамнан яңа гына кисеп алынган кәрәзле бал белән көйдерми, күгәртми киптерелгән җиләк. Һәм җиләге, һәм балы – Гыймайның кечкенә чактан ук үлеп яраткан ризыклары. Шәһәргә кил-гән елларда Гыймай, хатыны белән базарга чыгып, берничә тапкыр әнә шундый кәрәз-ле бал алырга омтылып караган иде, ләкин хатыны: «Базарда рәтле бал буламыни, кортларына шикәр ашатып җыйдырткан нәрсәдер», – дип, аның гайрәтен чигерде. Ә инде Гыймай җиләк сатучылар тирәсендә тукталса: «Әллә нинди әшәке тизәк суы сибеп үстерелгән җиләкне ничек җирәнмичә ашыйсың», – дип, йөз чөерә иде. Шуннан соң бу ризык-ларга Гыймайның нәфесе тартмый торган булды.

Ә авылдан килгән балның исләре үк икенче иде. Хәтта Гыймайның һичнәрсәгә гаҗәпләнми торган хатыны да:

– Менә ичмасам бал бу! – дип куйды.

– Каян безне исләренә төшергәннәр диген. Күптән хат алышкан юк иде бит, – дип, Гыймай посылка эчендәге хатны укый башлады: – *«Исәнмесез, килен һәм энекәш! Дөнья куып, тегесен җиткерим, бусын булдырыйм дип йөри-йөри, гомер үткәнен дә сизми яшибез. Хәтерем ялгышмаса, быел август аенда синең туган көнең бугай. Син дә кырык бишкә җитәсең. Әле яңа гына урамда яңгыр сулары ерып йөри идең сыман. Әйе, картаябыз. Бәләкәй чакларда бал өчен син үлеп китә идең. Әнкәй мәрхүм умарталарның балын суыртырга җыенса, тере балык күргән мәчедәй, әнкәй тирәсендә бөтерелеп йөри башлый идең. Исеңдә микән, бервакыт бал суырткан көнне борыныңнан ук балга чумып урамга чыккач, сине күче белән бал кортлары сырып алып, чакмаган җиреңне калдырмаганнар иде. Шунда мин сиңа: «Ну, Гыймай, моннан соң бал ашамассың инде», – дигән идем, син: «Авыз ачылса, бүген үк ашар идем әле», – дидең.*

*Быел безнең умартабыз бик баллады. Урманда җи-ләкләр дә җыеп бетергесез булды. Вареньелар кайнатып азапланмадык, җиләкне киптердек кенә. Менә сезгә дә авыз итәрлек күчтәнәч җибәрәбез. Шәһәр өегезгә бераз туган як исләре керсен. Ярый, туганнар, хушыгыз. Сәлам белән абыең, җиңгәчәң һәм балалар».*

Бу посылка аларны бик нык шатландырды дип әйтсәк, дөреслеккә туры килеп җитмәс иде. Шулай да, еракта вакыт томаны артында калган авыл хатирәләрен искә төшереп, бераз җанланып алырга сәбәпче булды ул. Шактый вакыт алар эчтән көрсенеп, нәрсәгәдер үкенгән кыяфәт белән утырдылар. Ләкин бу халәт озакка бармады. Күңелләрен башка уй биләде.

Бал һәм җиләктән хуш ис таралып борыннарын кытыкласа да, күчтәнәчләргә кагылмадылар. Нигә дисәң, аларның күңелендә шик туган иде: нишләп кинәт кенә абыйлары аларны исенә төшергән? Гыймайның кырык яшен уздырганда телеграмма да сукмаганнар иде. Хатны да оныткнда бер генә язгалыйлар. Бу посылканың төбендә бер-бер хәйлә яшеренеп ятмыймы?

Эчләрендәгесен кычкырып әйтмәсәләр дә, һәр икесе шулай уйлады. Егерме ел бергә яшәү аларның дөньяга карашларын, фикер сөрешләрен бертөсле иткән иде. Алар хәтта берсе ашамаган ризыкны икенчесе ашамый торган булдылар. Элек Гыймай тозы җиңелчәрәк итеп пешерелгән ашларны ярата иде, хәзер кыркурак итеп пешерелгәнне хуп күрә. Хатыны исә карлыган вареньесын өнәп бетерми иде, хәзер аннан тәмле варенье юк дип саный. Бик пар килгән кешеләр идеме болар, киресенчәме – анысын әйтү кыен. Пар килүне нинди күзлектән чыгып карыйсың бит. Хәер, нинди күзлектән чыгып карауны укучының үзенә калдырып, төп вакыйгага кайтыйк. Ә хәл четерекле иде. Һәрхәлдә, аларга шулай тоелды.

Посылка тирәсендә парлашып йөри торгач, Гыймайның хатыны, иренә әйтүдән бигрәк, үз-үзенә сөйләгәндәй әй-теп куйды:

– Аларның балалары өчәүме әле?

– Өчәү! – диде Гыймай, хатынының ни әйтергә теләгәнен тиз төшенеп. – Тик аларның Казанга килеп укырга керердәйләре юк. Зур кызлары, әллә кайчан Алабуга институтын бетереп, авылда укытып ята. Уртанчы малайлары хәрби кеше, үзең беләсең. Аның беркайчан да монда килеп сыеныр почмак эзлисе юк. Ә бәләкәй малайларын авылдан куып та җибәрә торган түгел. Атаклы механизатор. Рәсеме газеталардан төшми.

– Бүген механизатор, иртәгә инженер буласы килер.

– Юк-юк. Монда ниндидер башка сәбәп.

– Ә бәлки, алар минем кибеткә эшкә керүемне ишеткәннәрдер, – диде хатын.

– Язганыбыз юк бит, каян ишетсеннәр?

– Ишетелә ул. Хәтереңдәме, өченче ел 8 Март бәйрәменә миңа ниндидер билгесез кеше хезмәт күрсәтү бюросы аша чәчәкләр җибәргән иде. Нинди матур чәчәкләр дип куанып йөрдек, тыйнак кеше икән дип, җи-бәрүчесен мактадык. Шул тыйнак кешебез, атна-ун көн узуга, минем кибеткә кереп: «Берәр келәм табып бирә алмассың микән?» – дип тасма телләнде.

– Безнең абыйның әйбергә исе китә торган гадәте юк. Үзең беләсең, табарга теләсә, безнең ярдәмнән башка да бөтен нәрсәне таба ала.

– Алайса, нигә дип салганнар икән соң бу посылканы? Бәлки, берәрсе авыргандыр да синең аша әйбәтрәк больницага керергә телидер. Син бит атаклы профессорны йөртәсең. Анысын алар ишетми калмаганнардыр.

– Бусы инде бөтенләй тузга язмаган нәрсә. Үзебез газетадан укып, ишетеп торабыз лабаса. Абый ничәмә-ничә ел рәттән Верховный Советка депутат итеп сайланып килә. Ә депутатка барлык ишекләр ачык. Ә бәлки, бу чынлап та туган көн хөрмәтенә җибәрелгән күчтәнәчтер, ә? Безнең абыйның шулай исенә төшсә исе китә торган гадәте бар.

Гыймай бу сүзләре белән хатынының шикле уйларын тарата алмаслыгын яхшы белә, әлбәттә. Дөресен генә әйткәндә, үзе дә моның туганлык хисләреннән чыгып җибәрелгәнлегенә ышанмый. Чөнки үз күңелендә мондый

хисләр күптән мүкләнгән. Авылдан таныш-белеше килеп, берәр кич куна калса, сулышы кысыла башлый. Берәрсе ярдәм сораса: «Бик ярдәм итәр идек, кулыбыздан килми шул», – дип мескенләнеп күренергә тырыша.

Кыскасы, алар әлеге посылканың төбендә ни ятканын белә алмыйча гаҗиз калдылар. Тамакларыннан аш үтмәде, күзләренә йокы кермәде.

– Әллә соң кире җибәрәбезме? – диде хатыны, аптырагач.

– Кире җибәрсәк, абыйларны рәнҗетербез инде, – диде Гыймай.

– Безне рәнҗетергә ярый, аларны ярамыймыни?

Әйе шул. Гыймай бу хакта үзе белергә тиеш иде. Абыйлары аларны билгесезлек газабына салып рәнҗетмәдемени? Төптәнрәк уйлап карасаң, бу посылка, бернинди риясыз җибәрелгән күчтәнәч булган очракта да, Гыймайларны кимсетү бит. Янәсе, Гыймайларның бал алып ашарлык хәлләре юк.

Гыймай шундый акыллы фикергә килүенә сөенеп куйды. Ә бераздан алар, посылка әрҗәсен кире кадаклап, күчтәнәчләрне авылга җибәрделәр. Шуннан соң гына өсләреннән тау төшкәндәй җиңеләеп калдылар.

## КУЗГАЛАК

– Айдар улым, иртәгәдән син садикка йөри баш-ларсың, – диде Айдарның әнисе Рәхилә ханым. – Әтиең сөйләшкән.

– Садикка әти үзе барсын, – диде Айдар, киреләнеп. – Ә мин бармыйм, бармыйм...

– Нинди үҗәтлек бу, улым? Садикка бармагач, өйдә кем белән торырсың соң? Әбиең үлде...

– Үтермәскә иде. Сез үтердегез әбине.

Рәхилә ханым сискәнеп китте, әйтерсең искәрмәстән яка астына бер йомарлам кар тыктылармыни. Йөзе җы-е-рылды, күзләре кысылды. Ул кызган баштан Айдарга сугып җибәрде.

– Һы, кара син аны, оятсызны! Ни сөйләп тора. Әбиеңне нишләп без үтерик ди?

– Сез инде, сез. Әти апкайткан кузгалактан син әбекәй-гә аш пешереп бирдең. Әбекәй шуны ашады да үлде.

Рәхилә ханым хәлсезләнеп урындык аркасына сөялде. Күз аллары караңгыланып китте. Шактый вакыттан соң гына үзен кулга ала алды ул.

Каенанасы белән алар әйбәт яшәделәр. Ире Тәбрик: «Әнкәйне үзебезнең янга алып килик, аңа тәрбия кирәк», – дигәч, бишкуллап риза булды. Каенанасы үзе дә тыныч холыклы, сабыр карчык иде. Урамнан сүз ташымады, юк-барга бәйләнеп йөдәтмәде. Балаларының тегенди-мондый кимчелекләрен күргән очракта, хәтер калдырмаслык йомшак тавыш белән ипле итеп үз фикерен әйтә иде. Оныгы Айдарны бик яраткангамы, шәһәргә тиз ияләште. Кулыннан килгән эшне үз җаена гына эшләп, артык күзгә бәрелмичә яши бирде. Яше инде шактый бар иде, андыйларны авыру бер екса нык ега. Көннәрдән бер көнне Мөгелсем әбинең тамагыннан аш үтмәс булды. Күзгә күренеп сызды, кулындагы, битендәге тамырлары зәңгәрләнеп бүртеп-бүртеп чыкты, йөзендә нур кимеде. Әниләре кызыгып авыз итмәсме дип, бер яктан улы, икенче яктан килене кибетеннән, базарыннан тәмле-тәмле ризыклар алып кайттылар.

– Нигә шулкадәрле нигъмәтләр ташыйсыз? – диде Мөгелсем карчык. – Әпелсиннәрегез, лимоннарыгыз бозыла гына, әрәм була.

– Син аша, әни, аша, – диделәр балалары. – Синнән бернәрсә дә жәл түгел. Җәйләр җитеп, юллар төшкәч, үзеңне авылга алып кайтырбыз. Авыл һавасын рәхәтләнеп суларсың.

Авылы хакында сүз чыккач, Мөгелсем карчыкның йөрәгендә ниндидер бер кайнар чишмә кузгалгандай итте: «И-и, балалар, – диде ул, көрсенеп, – үзегез исемә төшермәсәгез, әйтмәм дигән идем, күптәннән инде катык каткан кузгалак ашы ашыйсым килә. Шуны ашасам терелер кебек тоям».

– Көт инде, әни, бераз, – диде Тәбрик. – Кузгалак-лар борын төртә башлау белән, урманнан кочагы белән җыеп алып кайтырмын.

– Урман кузгалагы төче була ул, улым. Үзебезнең як әрәмәләрендә үскән кузгалакка җитәме соң! Аның исләре үк икенче. Сугыштан соңгы елларда менә шушылай тик торганнан аш үтми башлаган иде. Күршебез Мәхтүмә карчык: «Катык каткан кузгалак ашы аша, терелерсең», – дигән иде. Сүзе дөрескә чыкты бит, Алланың рәхмәте. Кузгалакның файдасы тиде. Мин аны шаярып әйтә дип торам, нигә дисәң, ул вакытта безнең ипидән өзелгән юк иде. Шулай, улым, кайчагында өзелергә торган гомерне юк кына нәрсә ялгап җибәрә. Хәзер әрәмәләрдә акланнар кардан ачыла башлагандыр. И гомерләр...

Мөгелсем карчык әрәмәләрне, Ык буйларын күз алдына китереп уйланып ятты. Аннары, баягы сүзләре өчен оялгандай, болай диде:

– Карт кешенең сүзенә рәнҗемәгез, балалар. Үлем түшәгенә яткан кеше ни сөйләмәс. Кузгалакка барыгыз дип әйтүем түгел. Әҗәлдән кузгалак кына коткара алмас анысы. Үлем исереклеге сөйләтәдер. Әҗәл сөйләтәдер.

– Нинди әҗәл ди әле, әни! – диде улы Тәбрик. – Кузгалагын да алып кайтырбыз. Машинам гаражда тора, утырдым-киттем. Кирәк дисәң, туган яктан гына түгел, кузгалакны Себердән дә алып кайтырга мөмкин хәзер. Кыш көне җиләк ашыйсым килә дисәң, анысын да табарбыз.

Һәм Тәбрик сүзендә торды. Көннәр бераз рәтләнеп, җирләр яшәрә башлау белән кузгалакка барырга җыен-ды.

– Әти, мин дә синең белән барам, – диде Айдар, әтисенең юлга чыгарга әзерләнгәнен күреп.

Әтисе аңа:

– Сиңа ни калган анда? Юл ерак, арырсың, – дисә дә, Айдар үз сүзендә нык торды:

– Машинада утырып арыйлар димени? Машина бит ул выж-выж очыра гына.

– Озаграк йөрсәң, очасың килми башлар...

Айдар, әтисен болай гына җиңеп булмаса, шыңшырга исәпләп тора иде, ләкин эш аңа ук барып җитмәде, әбисе аны яклап сүз әйтте:

– Тәбрик улым, баланы нәүмиз итмә. Алып бар үзең белән. Гомер юлы бер генә карыш икән, күбрәк йөреп озынайтырга кирәк аны...

Ата белән ул тиз генә җыенып чыгып киттеләр. Шәһәр читендә заправкага туктагач, Тәбрик үзенең бер якын танышын очратты.

– О-о, күпме айлар, күпме еллар! – дип каршы килә башлады ул Тәбриккә таба. – Кая юл тотасың?

Тәбрик танышына хәлен аңлатып бирде. Танышы аңа чынлап сөйлисеңме дигән шикелле, сәерсенеп карап торды.

– Картларның бер чудачестволары инде бу. Кузгалак, имеш. Беткәнмени ул мондагы урманнарда. Җый да алып кайт капчыгы белән. Рәхәтләнсен.

– Ярамый. Әрәмә кузгалагы, Ык буенда үскән кузгалак кирәк. Урман кузгалагы төче була.

– Ә беләсеңме? – диде Тәбрикнең танышы, җанланып. – Минем бакчада нәкъ сиңа кирәкле кузгалак үсә. Хатын аны Мөслим ягыннан алып килеп чәчте. Ык буеннан. Ачылыгы телеңне өтә.

– Шулай да әллә ничек бит, – диде Тәбрик, икеләнә төшеп.

– Нәрсәсе әллә ничек булсын аның? Кузгалак кузгалак инде ул. Притом әниең үзе теләгән Ык буеныкы. Бу пычракта авыл юлларында бата-чума йөргәнче, Идел буенда рәхәтләнеп балык тотарбыз. Шундый шәп урын таптым мин. Балыклары капчыкка үзләре керергә тора. Ә кайтканда, бакчага кереп, Ык буе кузгалагын алып китәрсең.

Тәбрик танышының сүзләре белән килеште, әйе шул, бу пычракта авыл юлларына ышанып чыксаң, кайта да алмый ятарсың. Ә бит әнисенең гомере менә-менә өзелергә тора. Һәр сәгате, һәр көне исәптә. Ярамый авылга кайтырга, ярамый. Ерак юлдан көнендә әйләнеп килермен дип кем әйтә ала?

Алар ике машина белән Идел буена киттеләр. Тәб-рикнең танышы әйткән шәп урын балыкчылык сов-хозы икән. Аның инде бирегә беренче генә килүе түгел иде, ахрысы, балыкчылар белән кул биреп исәнләшеп чыкты. Өч балыкчы, майлы калҗа күргән маэмай кебек, гел аның тирәсендә бөтерелде. Бригадирларының каядыр китүеннән файдаланып: «Ну, алып килдеңме?» – дип, нәрсә турындадыр шыпырт кына сорашып алдылар.

– Килдем, килдем. Сезнеке әзерме?

– Әзер, әзер. – Балыкчылар Тәбрикнең танышын һәм Тәбрикне ияртеп бер читкәрәк алып киттеләр. Анда, вак таллар арасында юеш ком белән күмеп куелган балык өеме иде. Тәбрикнең танышы багажнигыннан әрҗәсе белән сыра алып тегеләргә тоттырды, ә үзе балык төйи башлады.

– Әйдә, карап торма, төя. Монда икебезгә дә җитәр-лек, – диде ул. – Яңадан килгәндә күчтәнәчләп килерсең. Хәзергә таныша тор.

Ул Тәбрикне балыкчылар белән таныштырды. Тегеләр ашыга иделәр, каш астыннан сөзеп кенә Тәбриккә карадылар да үз юлларына китеп бардылар.

– Хәзер безнең бакчага сыптырабыз, – диде Тәбрикнең танышы, балыкларны төяп бетергәч. – Сиңа барыбер тиз генә өйгә кайтырга ярамый. Ык буеннан урап кайтыр өчен иң кимендә ун-унике сәгать вакыт кирәк.

Алар бакчага килеп җитү белән учак тергезделәр, казан астылар. Балыкның иң шәпләрен сайлап уха пе-шерделәр. Тәбрикнең танышы арткы утыргыч астыннан бер ярты тартып чыгарды.

– Үземә дигәнен утыргыч астына яшереп калдырдым. Теге дуңгыз балыкчыларга ышаныч юк, багажнигыңның астын өскә әйләндергәннәрен күрми дә калырсың. Ярты литрга бөтен Иделне сатып җибәрергә әзер ул алкашлар.

Машинаң гына тартсын – җае чыкканда йөге белән төяп җибәрәләр. Мин инде чормага әллә ничә пот балык тозлап куйдым. Бүгенгеләрен дә тозларга туры килер, башкача нишләтәсең аларны?

Ашап-эчеп бераз кәефләнеп алгач, алар икәүләп балык тозларга керештеләр. Тозлагач, өстенә авыр әйбер бастырып куйдылар.

– Мин үземнекеләрне синдә калдырып торам, – диде Тәбрик. – Өйдә куяр урын юк. Аннары әни янына алып кайту да әллә ничегрәк.

– Калдыр, калдыр. Бер-ике көннән килеп, чормага элеп китәрбез. Кипкәч килеп алырсың. Кирәк булса, әнә кипкәннәрен биреп җибәрәм. Бәлки, әниеңнең авызына тәм кереп китәр. Минем әни гомерендә авызына балык капкан кеше түгел иде, үләр алдыннан кипкән балык сорап алды. Мә, сайла үзең иң шәпләрен генә. Менә болары бик катып җитмәгән, тешсез кешегә суырып ятарга әйбәт.

– Рәхмәт, дускай, рәхмәт, – диде Тәбрик һәм берничә балыкны сумкасына салды.

– Әнә свежийларын да ал. Җаны тартканын ашар. Картларныкын белмәссең. Әллә нинди әкәмәтләр уйлап чыгаралар алар.

Тәбрик белән танышы бакчада озак хозурландылар. Көн кичкә авыша башлагач кына, бакчадан кузгалак җы-еп, кайтырга чыктылар. Тәбрик учак корымына пычранган битләрен юмакчы иде, танышы аны туктатты: «Кирәкми, юынма. Юлдан кайткан кешегә охшыйсың болай».

Танышларыннан аерылып, үзләре генә калгач, Айдар әтисенә болай диде:

– Әти, без бит кузгалакны әбекәй әйткән җирдән җыймадык.

– Син шыпырт, улым. Бу турыда берүк кешегә, бигрәк тә әбиеңә ычкындыра күрмә. Үзең ишетеп тордың бит, кузгалакның орлыгын Ык буеннан алып кайтып чәчтек, диде. Менә ашап кара әле. Үтеңне сытарлык ачы.

Тәбрик улына берничә кузгалак сузды. Үзе дә чыраен сыта-сыта чәйнәргә тотынды. Айдарга кузгалак бик ачы тоелды, тик барыбер ул күңелсез иде. Өйгә кайткач та кәефе күтәрелмәде. Әнисе аңардан:

– Нишләп, улым, болай чыраең качкан, әллә юлда бик арыттымы? – дип сорады.

Айдар әнисенә җавап бирмәде. Әнисе кузгалак белән аш пешерә башлагач кына аның янына йөгереп килде:

– Әни, ул кузгалактан аш пешермә, без аны әрәмәдән түгел, бер абзыйның бакчасыннан җыеп кайттык, – диде.

Әнисе башта аптырап калды, аннары, имән бармагын иреннәренә куеп:

– Чү, улым, чү, – диде, нәкъ әтисе төсле итеп. – Әбиең алдында андый сүз ычкындырып ташлама тагын. Менә күрерсең, әбиең шушы ашны ашагач терелер дә китәр...

Ашны Мөгелсем әби бик яратып ашады. Ике сүзнең берендә олыларны санга санап шулхәтле ерак җиргә баручы балаларын мактады. Улына, килененә рәхмәтләр укыды.

– Безнең як кузгалагының исләре үк икенче шул. Әллә каян борыннарны ярып керә. Әҗәлгә тимәгән чир булса, Ходай кушып, терелеп тә китәрмен. Кем белсен...

Әнисенең күңеле күтәрелүен күреп, Тәбрик бик шатланды. Сумкасындагы балыкларын чыгарырга оныткан икән, исенә төшеп, аларны бирде.

– Болары, әни, Ык балыклары. Балыкчылардан ялынып кына алдым. Ашап җибәр әле, файдасы тияр, – диде.

Мөгелсем карчыкның балык ашыйсы килми иде, улының хәтерен саклап кына бер кипкән балыкның койрыгын ялап куйды.

– Балыкларың да бик тәмле, улым, – диде ул. – Карт кешенең сүзен аяк астына екмавың өчен рәхмәт. Ходай үзегезгә озын гомер бирсен.

Кузгалак ашы Мөгелсем әбинең җыясы соңгы ризыгы булган икән. Шуннан соң ике генә көн торып, үлеп китте.

## СОҢГЫ БАЛКЫШ

Мөслах карт озак кына бастырылып, саташып ятты. Өстенә ябынган юрганы, кымшанырга теләгән саен, картны түшәгенә ныграк кыса барды. Картның тыны бетте, сулышы өзек-өзек булып гыжлап чыкты. Ул инде йоклап ятмый иде, тик йоклаганда башына кереп тулган куркыныч сурәтләрне, буталчык уйларны куып таратырлык хәлдә генә түгел иде.

Шактый ыңгырашып, аңгы-миңге ятканнан соң, кинәт аның күкрәгенә кайнар һава кереп, йөрәген нидер яндырып алды. Картның аңы ачылды, әйтерсең уйламаган-көтмәгән җирдән көчле җил чыкты да күктәге болытларны «әһ» дигәнче таратып ташлады. Ул көч-хәл белән торып утырды. Иреннәрен ялап куйды, шунда ул телендә тоз тәме тойды. Аның иреннәре ярылып канаган иде. Вәт адәм көлкесе. Тап-таза килеш урынга ят та хасталанып уян, имеш.

Мөслах карт, яше җитмешкә якынлашып килсә дә, үз гомерендә бер мәртәбә дә ятып чирләмәде, алай да кәефсезләнеп, хәлсезләнеп йөргән чаклары булмады түгел анысы. Бигрәк тә соңгы биш ел эчендә бетереште. Гомер дигәнең кочле давыл гына икән: үтә дә китә. Давыл узгач ни кала? Каерылган түбә, егылган агач... Ә бит йортның түбәсе очса – нигезе, агачның, үзе егылса, тамыры кала. Ә кешенең?..

Җитмеш яшькә кадәр яшәп (картның үз сүзләре белән әйтсәк, бер көн калмый яшәп), гомере буе алны-ялны белми эшләгән кешенең киләчәк буынга калдырыр нәрсәсе юкмы әллә? Кеше үз гомерендә бер генә агач утыртып үстерсә дә, тиккә яшәмәгән, диләр. Ә Мөслах карт үстергән җимеш бакчасы заманында колхозның гына түгел, районның горурлыгы иде.

Сугыштан соңгы авыр елларда тотынды Мөслах карт бу эшкә. Авылның авызы ипигә туймаган чакта. Сугышта йөргәндә, ул Украинадагы бакчаларны күреп аһ иткән иде. «Әгәр шушы гарасатлардан исән-имин котылсам, кайткач авылыбызга бакча утыртам. Бездәге җирләр Украинадагыдан кимме әллә? Их, исән калсам...» Мөслахның сүзләре фәрештәнең «амин» дигән чагына туры килде, ахры, сугыштан исән-сау, хәтта яраланмыйча да кайтты. Кайту белән аны председатель итеп куйдылар. Бакча турындагы уйлар бер мәлгә онытылып торды, чөнки авылның тишек-тошыгы артык күп иде. Көндәлек мәшәкатьләргә күмелеп, хыялының һаман ераклаша барганын тойган чакларда ачынып-ачынып куйгаласа да, башлап җибәрергә җай чыкмады.

Ә бер елны корылык килеп, икмәкләр сабакта килеш саргаеп катты. Урып-җыярлык нәрсә булмады. Менә шул елның көзендә бакчага тотынды Мөслах. Бөгелмә питомнигыннан алмагач һәм чияләр кайтартты. Тау итәгендә ике гектарга якын җир сайлап алып үсентеләрне шунда утырттылар. Бакча өчен монда урын гаҗәп шәп иде. Төньяктан биек тау ышыклап тора, тауның күкрәгеннән кайчандыр чишмә бәреп чыккан. Дөрес, чишмәнең исеме генә калган. Аны элекке хәленә китерер өчен шактый тырышырга туры килде. Ул вакыттагы техника белән көч түгүләр генә, белмим, файда бирер иде микән? Чишмәнең юлын нинди әмәл белән әрчергә белми йөргәндә, сугышта сапёр булган Мөслахның башына шундый уй килде: шартлатырга кирәк!

Мөслах урманчылыкка китте. Анда киселгән делянкалардагы агач төпләрен аммонал белән шартлатып, яшь үсенте утыртырга җир әзерлиләр иде. Мөслахның гозерен кире какмадылар: сораган кадәр аммонал биреп җибәрделәр. Чишмә юлын шартлатып, инде ташлардан арындырырга гына калган иде, шулвакыт аны райкомга чакырдылар.

– Син анда нинди авантюра белән шөгыльләнәсең? – дип каршыладылар Мөслахны райкомда.

– Авантюра белән шөгыльләнмим, бакча утыртам. Ә бакча сусыз үсми, – диде Мөслах тыныч кына. Ул үзенең бик кирәкле эш башкаруына тамчы да шикләнми иде.

– Синнән кем бакча сорый? Крестьянмы? Юк, иптәшкәй, крестьянга бүгенге көндә алма кирәкми. Аңа ипи кирәк, ипи! Ә синең арышың сабакта килеш көйде.

– Минеке генә көймәде, бөтен районында корылык... – Мөслах шулай дип аклана башлаган иде, аны сүзеннән бүлдерделәр:

– Бу аклану өчен сәбәп түгел, иптәш Хаҗиәхмәтов. Быелгы хәлдән сабак алырга кирәк. Ә сез, тизрәк туңга сөрүне бетерер чакта, бала-чага эше белән маташасыз.

Мөслах райкомнан авыр уйлар белән чыкты. Туңга сөрергә кирәклеген ул үзе дә белә. Бөтен көч шуңар туп-ланган, әмма көч дигәне сабыйныкы хәтле генә шул. Атлар хәлсез. МТС артык машина җибәрә алмый. Бакчаны бит ул карт-корылар белән атсыз, техникасыз утырта. Крестьянга алма кирәкми дисәләр дә, кирәк бит алма. Кирәк. Юкса олысы-кечесе әнә шулай атлыгып торыр идемени? Бакча ул иген түгел, бер елда гына үсми. Алма кирәккәндә генә үстерергә керешсәң, соңга калуың бар.

Ул елны Мөслах туңга сөрүне үтәп чыга алмады. Шуның өчен аны председательлектән төшерделәр.

Яшелчәчелек бригадиры итеп куйдылар. Алмагачлар утырткан тау итәгендә урын күп иде. Җимеш агачлары янына яшелчә утырттылар. Мөслахның яшелчәчелек бри-гадасында җыенысы җиде-сигез хатын-кыз иде. Шулар белән ул чишмәнең юлын ачты, яшелчәсен үстерде. Әк-ренләп тау янындагы бакча зурая, үсә барды. Колхозлар эреләнеп, тернәкләнеп киткәч, Мөслахның да эшләре җайланды. Техниканы да, кешеләрне дә жәлләмәделәр. Шулай итеп, бакча үзен ашаткан кешеләргә ашын бирә башлады.

Мөслахның укымышы зур түгел иде. Бу якларда бакча үстерү белән бик шөгыльләнмәгәч, киңәш бирер кеше дә табылмады. Шуңа күрә ул күбрәк белемне китаплардан алырга тырышты. Бакчачылык турында, яңа сортлар китереп чыгару турында бик күп китаплар укырга туры килде аңа.

Эшләр шулай көйләнеп, Мөслах бакчасы мул итеп уңыш бирә башлаган чорда бу тирәгә нефтьчеләр килеп чыктылар. «Килеп чыктылар» дип әйтү бик үк урынлы да булмас, чөнки Татарстанның бу төбәгендә күптән нефть табылган һәм колхоз басуларында кукраешып утырган буровойлар һичкем өчен яңалык түгел иде. Баштарак җир

астындагы нефть диңгезе бетмәс-төкәнмәс булып тоелса да, соңрак җир астының да төпсез кое түгеллеге беленде. Скважиналар нефтьне фонтан белән атмый башладылар. Бу байлыкны җир куеныннан насослар белән суыртып алырга керештеләр. Элек кечкенә дип бораулэмый киткән ятмаларны тишкәләргә тотындылар. Мөслахның бакчасы әнә шундый нефть күле өстендә утырганлыгы беленде. Нефтьчеләр акылсыз түгел, гөрләп үсеп утырган бакча эченә буровой утыртмадылар: нефть ятмасына кыеклап керергә булдылар.

Менә бермәлне бакчаның тау ягыннан җирне үкертеп бораулый башладылар. Нефтьчеләрдә техника һәм көч җитәрлек. Алар, әкияттәге батырдай, ай үтәсен көн үтеп, җир астындагы катламга якынлаштылар. Тик җир өстенә нефть түгел, әшәке исле сасы су бәреп чыкты. Бу су бакчаны сугара торган чишмә юлына төшеп, бакчага куркыныч янады. Коты очкан Мөслах, кулына көрәк тотып, нефтьчеләр янына йөгерде.

– Нинди нәмәрсә агызасыз сез минем бакчама? Кайсыгыз башлык? Нигә агызасыз бу әшәке суны?

Мөслах янына бораулаучы мастер килеп басты.

– Шаулама әле, абзый. Нигә юкка паника куптарасың? Ботканы май бозмый, диләр бит. Бакчаңны бушлай сугарганга рәхмәт әйт.

– Әйтермен, мин менә бу көрәк белән башыңа кундырсам. – Мөслах үз каршында тыныч кыяфәт белән басып торган мастерга ярсыганнан-ярсыды. – Хәзер үк туктат бу шакшыңны, юкса, кантурыгызга барып, бөтенегезне пыр туздыртам. Бакчаны харап иткән өчен башыгыздан сыйпамаслар. Һәрбер үсемлеккә хөкүмәтнең законы бар.

– Тукта әле, абзый, алай зурдан кубып сөйләшмик, – диде мастер, Мөслахны тынычландырырга теләп. – Хөкүмәт законнарын мин дә беләм.

– Белгәч, бозмаска кирәк.

– Беркем дә бозмый. Без бит сасы су чыгарыйк дип бораулмадык. Хәзер бульдозер килеп җитәр, пычрак суны чишмәңнән читкә борырбыз.

Мастерның бу сүзләреннән соң бераз тынычланса да, күңеле бөтенләй үк утырып җитмәгән иде әле Мөс-лахның.

– Синең бульдозерың килгәнче минем бакчаны су басып бетерер, – диде ул.

– Каналларыгызны ябып торыгыз, – дип киңәш итте мастер.

– Әйтүе җиңел ул. Хәзер генә мин кешеләр каян табыйм? Суы да бит ташу суыннан ким түгел.

Мастер үз бригадасын бирергә булды. Бульдозер килеп башка урыннан юл ерып җибәрде. Пычрак су берничә көн буена бакча кырыеннан агып ятты. Тиешле кешеләр, килеп, суга анализ ясадылар. Моның күкертле су икәнлеге беленде. Бораулаган скважинаның авызын томалап куйдылар. Менә шуннан соң инде Мөслах бакчасына зур афәт килде. Күкертле су, өскә чыгар урын тапмагач, җир астындагы чишмәгә килеп кушылган. Ә бакчачылар, аны-моны абайламыйча, җимеш агачларын, яшелчәләрне шул су белән сугардылар. Өлгермәгән килеш алмагачларның алмалары коелды, яшелчәләр сабакта корыды. Нефтьчеләр килеп яңадан шактый эш башкардылар, әмма чишмәнең элекке сафлыгы кайтмады. Бакча әкренләп һәлак була барды. Бакча өчен колхоз нефтьчеләрдән шактый сумма алса да, Мөслах сугыш кырында армиясен югалткан генерал шикелле гаҗиз калды. Аны башка эшкә куеп карадылар – күңеле ятмады.

Ә тиздән бу күкертле су чыккан урынга нефтьчеләр өч катлы ак бина салып куйдылар һәм профилакторий, безнеңчә әйтсәк, дәвалау урыны ачтылар. Дәвалау урыны тиз арада зурайды, күкертле судан зарарланмый калган җимеш агачларын да кысрыкладылар. Аларның күбесе тәрбия җитмәүдән уңыш бирми башлады. Бу хәлгә йөрәге әрнегән Мөслах беркөн баш врач янына килде.

– Синең җаның бармы-юкмы? – диде ул, ачынып. – Врач аңа сәерсенеп карап торды. – Ул бакчаны нигә караткмыйсың?

– Ә-ә, сез менә нәрсә турында икән, – диде врач, төшенә башлап, – бакчаны карыйбыз аны, карыйбыз. Минем бик укымышлы бакчачым бар. Хәзергә әле ул авырып тора, менә шул терелеп чыгу белән чакыртып алачакмын.

Мөслах «алайса, беразга мин эшләп торыйм» димәкче булган иде дә, нефтьчеләргә үпкәсе артык зур булганлыктан кул гына селтәде. Шуннан соң аның өчен тормышның кызыгы бетте. Башка эшләрдә бераз селкенгәләп йөрде дә пенсиягә чыкты. Әмма аңа карап җаны тынычланмады. Татлы йокыларын йокламыйча зыр-зыр түшәктә әйләнүен, алай гына да түгел, җиде төн уртасында сикереп торып утыруларын бары тик карчыгы Мәрьямбикә генә белә иде. «Яшисен яшәгәнсең, ашыйсын ашагансың, инде тынычланырга вакыт», – дип, Мәрьямбикәсе еш кына сүгеп тә ташлый иде үзен. Мөслах акланмый, үзенең мондый хәлгә төшүенә кешеләрне гаепләми (дөрес, башта үпкәләп йөрде йөрүен), чөнки күреп тора: аның бакчасы урынында кешеләр өчен бик тә кирәкле нәрсә салып куйдылар. Анда елның-елында ничәмә авыру сәламәтлеген ныгытып китә. Бер уйласаң, Мөслахның җимеш бакчасы аның кадәр файданы гомер буе да китерә алмагандыр. Җимеш бакчалары хәзер кайда

гына юк! Базарларга чыксаң, кибетләргә керсәң искитмәле: җәй көннәрендә җиләк-җимешне куяр урын тапмыйлар. Алманың бәясе бәрәңге бәясе белән бер.

Карчыгы Мәрьямбикә көтмәгәндә дөнья куйгач: «Ич-масам, чир дә эләкми. Бәхетле бәндә вакытында үлә белә. Сузылып ятасы иде дә шул ятудан тормыйсы иде. Әҗәл дигән нәрсә гадел түгел икән шул: кирәкле кешеләрне, җир җимертеп эшләп йөрүчеләрне алып китә, кирәксезләрне калдыра», – дип сукранды.

Мөслах карт чир эләкмәгәнгә уфтанып йөри торгач, бая әйткәнебезчә, уттай кызышып уянды. Йөрәген тотып карады: яңа гына йөгереп килгән кешенеке төсле дөп-дөп тибә иде. «Шөкер, вакыт җитте. Тик менә малайга хәбәр итәргә иде бит. Үпкәләр, рәнҗер. Әнкәсен җирләшергә кайта алмавына да сызланып йөри. Әйе, малайга хәбәр җибәрергә кирәк».

Авырлык белән урыныннан кузгалды. Өй төнлә суынып өлгергән иде, юрганын бөркәнеп, кече якка чыкты. Самавыр өстендә кукраеп утыручы чәчәкле чәйнектән йот-лыгып-йотлыгып салкын чәй эчте. Бераз хәл кереп кит-кәндәй булды. Мич янына тәбәнәк эскәмиягә утырып, учакка ут төртеп җибәрде. Коры утын дәртле тавыш белән янып китте. Мөслах карт тагын элекке уйларына кайтты. «Кызык! Бу гомер дигәнең давыл түгел, учак икән. Янасың, дөрли-дөрли күккә күтәреләсең. Ә нәрсә кала? Төтенме? Көлме? Без бит учакны төтен чыгарыр өчен якмыйбыз. Җылылык кирәккә ягабыз. Әйе, җылылык кирәккә!»

Мичтәге утыннар янып бетүгә, өйгә рәхәт җылылык тарала башлады. Оешкан тән язылып, җиңеләеп китте. «Малайга хәбәр җибәреп маташмаскадыр, ахрысы. Үтә торган чиргә охшый бу». Ул баш бармагын бер-ике минут чамасы муен астына куеп, ияге белән бастырып торды. Тәннең кайнарлыгы артык күп тоелмады.

Тик кич җитүгә, тагын авыраеп китте ул һәм урамнан үтеп баручы күрше кызын күреп тәрәзә какты:

– Кызым, малайга тилиграм биреп кайт әле. Әзрәк сырхаулап торам бугай.

Кыз Мөслах картның йөзенә карады: ул кызарган, тимгелләнгән иде.

– У-у, бабай, разве шулай чирләргә ярый инде. Хәзер үк доктор чакыртам.

– Юк-юк, кызым. Духтыр килгәнче кызуым бетә минем. Эшле кешеләрне эшеннән бүлеп маташма. Элек тә бер духтыр чакыртып оятлы булдык.

Кыз Мөслах картларга шактый еш кереп йөри иде, тиз генә Казанга телеграмма сукты. Почтадан кайтышлый фельдшерга кереп, аны да үзе белән ияртеп килде.

Мөслах карт шул чирләүдән атна буе ятты. Улы Хафиз икенче көнне үк кайтып төшкән иде, көне-төне әтисенең баш очында утырды. Әтисе рәтләнә башлагач, ике уйларга урын калдырмыйча:

– Давай, әткәй, җыен, Казанга алып китәм, – диде. – Квартирабыз иркен, Дамира синең өчен үлә язып тора.

– Үләр вакыт җиткәч инде...

– Юкны сөйләмә әле, әткәй. Нинди үлү ул? Хәзерге заманда җитмешкә дә җитмәгән килеш үләләрмени?

Ата һәм ул шактый тарткалаштылар, ахырдан Мөслах улы янына китәргә ризалык бирде, чөнки ялгызлыктан, тормышның максатсызлыгыннан нык ялыккан иде.

Әтисенең бер иске-москыны да калдырмыйча аерым-аерым төйнәгәнен күргәч, Хафиз түзмәде, болай дип әйтеп салды:

– Нәрсәгә кирәк, әткәй, бу чүп-чарлар? Калсын барысы да, әллә Казанда әйбер беткәнме. Түшәк-ястыкларның өр-яңаларына яткырырбыз. Юрганның каз мамыгыннан сырганын бирербез. – Аннары Хафиз балта-пычкы ише кораллар салынган әрҗә янына килде. – Боларның да анда кирәге чыкмас. Калдырыйк. Анда безнең утын кисәсебез юк.

Хафиз берәм-берәм әйберләрне шулай юкка чыгара барды. Мөслах карт гомер буе файдаланып, кинәт кенә кирәксезгә калган әйберләр өеменә барып утырды да кәефсезләнеп калды. Ул яшьсез генә елый иде.

– Алай үзеңә кирәк булыр кебек тоелса ал, әткәй, – диде улы, йомшап. – Мин бит сине рәнҗетергә теләмәдем. Үзең сыйган җиргә әйберләреңне дә сыйдырырбыз.

Мөслах карт улы юаткан саен ныграк үртәлде. Юк, ул монда калдырган әйберләрне генә жәлләми, менә шушы әйберләр кебек, кешенең дә бервакыт кирәксезгә чыгуы, шуңа каршы төшәрлек чара таба алмавына гаҗизлектән күңелсезләнүе иде аның.

Күңелен басарга теләп, ул ишегалларына чыгып керде, абзар капкаларының күгәне шыгырдый иде, аны майлап куйды. «Өйне Габбас малаена калдырырга кирәк булыр, тиктомалга череп ятмасын. Габбас малайлары, чуалышып, башка чыгарга йөриләр иде бугай», – дип уйлады һәм шулай эшләде дә.

Хуҗалыкны таркатмыйча бөтен килеш әйбәт кеше кулына тапшыргач, картның күңеле күтәрелеп китте.

– Әйдә инде алайса, – диде ул улына, – сезнеңчә яшәп карыйк.

Килене Дамира каенатасын бик җылы каршылады.

– Әллә кайчаннан үзебезгә килеп яшәмичә соң, анда япа-ялгыз нишләп ятарга кирәк, – диде ул һәм этисенең өс-башларын чишендерешергә кереште. Картның аягына җылы башмак кигертте, диванга йомшак мендәр ташлап, шунда кертеп утыртты. Шул арада, газ колонкасына ут төртеп, ваннага кайнар су агыза башлады.

– Хәзер, эткәй, ванна бераз җылынсын да юынып чыгарсың. Арыганың бетәр.

– Самолёттан төшүгә такси, таксидан төшүгә өй, нинди ару ди ул, – дип каршы килә башлаган иде карт, ләкин Дамира аның ай-ваена карамады.

– Әйдә, әйдә, эткәй, җылы суда сөякләрең язылыр. Без үзебез һәр көн кич ваннага чумып чыкмасак йоклый алмыйбыз, – диде һәм Хафизга эндәште: – Син, Хафиз, эткәйне юындырыш. Ә мин ашарга әзерлим.

Дамира, ирләр ваннага кереп китү белән, тиз пешерә торган кәстрүлгә аш салып куйды, аннары иттарткыч аша ит чыгарып, кәтлит әвәли башлады. Каенатасы ваннадан чыгуга, аның инде ашы өлгергән, табын түрендә авыздан суларны китереп бу бөркеп утыра иде.

– Әй уңган да инде син, килен, күз генә тимәсен, – дип мактады Дамираны Мөслах карт.

Әтисенең мактавына Дамирадан бигрәк Хафиз шатланды. «Минем хатын бит ул» дигән сыман ярату һәм соклану белән Дамирасына карады. Табын гөр килде. Хафиз суыткычтан биш йолдызлы коньяк алып табын түренә утырткач кына тавыш бер мәлгә басылып алды.

– Әйдәле, эткәй, – диде Хафиз, – мунчадан чыккач искиткеч шәп нәрсә. Сразы утыз елга яшәреп китәрсең.

– Син нәрсә? – диде Мөслах карт. – Шушындый күркәм табынның ямен җибәреп, аракы куясың. Каян алсаң, шунда яшер – күзем күрмәсен.

– Син артыграк инде, эткәй. Бу бит дару өчен генә.

– Алай булгач бигрәк тә. Даруны теләсә кайчан эчмиләр...

Мөслах карт килене биргән салфетка белән шешәнең өстен каплап куйды. Хафиз, эткәсе эчмәсә дә, бер-ике рюмка җибәрергә исәпләп тора иде, картның бу кыланышыннан соң кәефе китте. Ашын яртылаш кына ашады, ә икенчегә куйган кәтлиткә кагылмады да. Ә ата кеше улының кәефсезләнүенә игътибар бирмәде: тирли-тирли ашады, ашап туйгач, рәхәтләнеп лимонлап чәй эчте.

– Рәхмәт, кызым, – диде ул соңыннан, Дамираның җилкәсеннән кагып, – карчыгым Мәрьямбикә дөнья куйганнан бирле болай тәмләп ашаганым юк иде. Кулыңнан куан, кызым.

Мөслах картның тормышы көйләнде. Иртән торуга ашарына пешкән, өе җылы. Дамира кием-салымны да бик чиста тота. Керләнгәнне көтми, алыштырырга ашыга. Әткәләренә берьюлы әллә ничә пар күлмәк-ыштан алып кайтып куйды. Шыгырдап торган әйбәт тукымадан костюм-чалбар тектерде, аның өстәвенә чигүле түбәтәй алып җибәрде.

– Нигә минем өчен шулхәтле расхутланасыз, балам? – дип каршы төшеп карады Мөслах карт. – Миңа нәрсәгә бу чаклы кыйбатлы кәчтүмнәр. Ярамаган Хафизның берәр искесе.

– Юк, эткәй, синең иске-москы кияр вакытың үткән... Тормышыбыз әйбәт. Сине карарлыгыбыз гына бар.

Әйе, Хафизларның тормышы бар яктан да түгәрәк күренә. Өч бүлмәле иркен фатир. Идәннәргә калын-калын келәмнәр җәелгән, йөргәндә бернинди аяк тавышы ишетелми!

Картны оныгы Рәзил бүлмәсенә урнаштырдылар. Рәзил – сигезенче класста укып йөрүче буй җиткән егет. Бабасын бик ярата. Җәйге каникул вакытында авылга кайтып, бабасы янында озак-озак торып киткәли иде.

– Бабай, – диде ул беркөнне, – синең любовь крутить итеп караганың бармы?

– Белмим шул, улым. Ничек крутить итәләр соң аны?

– Ну, бабай, рәзве синең яшькә җитеп любовь крутить итмиләр? Мин и то инде өч мәртәбә по уши влюб-ляться иттем.

– Йә-йә, сөйләп кара, бәлки, миңа да кызык булыр. Юкса эшсезлектән эч поша башлады.

– Аның нәрсәсен сөйлисең инде, бабай. Просто тотасың да влюбиться итәсең. Аннары аны свиданьега чакырасың.

– Шуннан, шуннан...

– Шуннан целоваться итәсең. И өенә озатып куясың.

– Әллә ни кызык түгел икән.

– Сезнең заманда кызыграк идемени, бабай?

Мөслах карт оныгына бармак янады: күп белсәң, тиз картаерсың. Ләкин Рәзилне болай гына тынычландырып булмый иде, ул һаман төпченде:

– Йә, әйт инде, бабай, кроме бабушки берәрсен ярат-тыңмы?

– Ярату ул, улым, бакыр акча түгел. Аны теләсә кемгә өләшмиләр.

– Матур кызлар күргәч, ничек инде яратмый түзәсең.

– Ә тагын да матурраглы очраса?

– Анысын да яратасың.

Әнә шундый сораулар белән башын катырып бетерә Рәзил. Ләкин бабасы аңа ачуланмый. Нишләсен, Рәзилнең әле шундый вакыты, һәрбер ошаткан, сокланган кешесен яратам дип уйлый. Әйдә уйлый бирсен. Аңардан кемгә зыян? Тик менә Рәзилнең бер ягы ошамый Мөслах картка: малайның һәрнәрсәгә саксыз каравы. Бигрәк тә ризыкны әрәм-шәрәм итүе.

Бу йортта Рәзил генә түгел, ата-аналары да ризыкны хөрмәтли белмиләр. Көн саен күпме ипи чыгарып ташлана. Баштарак Мөслах карт искерергә дә өлгермәгән ипи телемнәрен чыгарып ташларга жәлләп аш вакытларында гел үзе ашый иде. Тик күпме тырышса да, боларны берүзе генә бетерә алмады. Ә беркөнне Рәзилнең туган көнен уздырганнан соң калган пирогларны, тортларны кочагы белән чүп чиләгенә чыгарып салуларын күргәч, түзмәде карт, оныгының якасына барыпябышты:

– Нишлисең син, җүнсез? Шулкадәр ризыкны исраф итәргә синең ни хакың бар?

Рәзил бабасының болай ярсыганын күргәне юк иде, картның йөзендәге бөртеп-бөртеп чыккан җыерчыкларга, дерелдәгән сакалына гаҗәпләнеп карап торды. Ул үзенең гаебен аңламаса да акланырга кирәкле тапты:

– Соң, бабай, боларны кая куясың? Бөтен кеше дә чыгарып түгә бит.

– Ә син менә шушы бер кисәк тортка күпме кешенең көче кергәнен беләсеңме? Аны үстерер өчен авыл халкы син мыш-мыш йоклап ятканда тузанга батып җир сөргән, кызуларда кояш сукмасын дип, җаныннан саркып чыккан тир белән сугарган, көзге яңгырларда, черетмичә, сулышы белән киптергән.

Оныгы бабасының сүзләренә каршы килмәде. Бәхәс-ләшер кеше булмагангамы, карт үгет-нәсыйхәтен озакка сузмады. Ләкин бу әле аның килешүе түгел иде. Өл-кәннәрнең өйдә чагын туры китереп, ул башлаган сүзенә яңадан кайтты.

– Менә бу нәрсә? – диде Мөслах, бер телем ипине кулына тотып.

– Ипи!

– Әйе, ипи. Ә ипине ашар өчен үстерәләр, чыгарып ташлау өчен түгел. Ә сез кершән кебек оннан пешкән нигъмәтләрне рәнҗетеп, ашап та карамаган килеш чыгарып ыргытасыз. Әнә Рәзил ташлаган тортның өстендәге мае гына да ай буена бәрәңге кыздырып тотарлык иде...

– Син бигрәк инде, әткәй, – дип каршы төште Хафиз, – калдык-постыкны ашый торган чакмыни?

– Ә кемнән калган соң ул? Дуңгызданмы әллә?

Дамира, ата белән ул арасындагы сүз тирәнгә китмәсен дип, бәхәскә кушыласы итте:

– Әйе, әткәй, без – шәһәр халкы, ризыкны сезнең кебек үк кадерләп тота алмыйбыз шул әле. Бу нәрсә үзебез икмәк үстереп карамаганнан киләдер инде. Ләкин, әткәй, без дә икмәкне эшләп табабыз.

– Анысына сүзем юк, эшлисез, – диде Мөслах карт, килененең сүзләреннән бераз йомшап. – Тик менә шул үзегез эшләп тапкан малның кадерен белергә кирәк. Менә син, улым Хафиз, заводта эшлисең инде. Ялгышмасам, тимер-томыр кырасың, шулардан самолёт, машина частьлары ясыйсың. Тимер-томыр белән эшләгәндә артык-портыгы да каладыр. Аларын кая куясыз?

– Аларын җыеп алып пресслыйбыз да өр-яңадан эретәбез.

– Завод чүплегенә чыгарып ташламыйсызмыни?

– Нигә ташлыйк, ул бит менә дигән чимал.

– Шул шул менә. Яңадан эретәсез, өр-яңадан файдаланасыз. Өйдәге ризыкка гына андый кадер юк. Ә бит пешкән ипи синең тимер йомычкаң гына түгел, ул яңадан пешермәгән килеш тә ашарлык.

– Юк өчен борчыласың син, әткәй, ул ипиләрнең берсе дә әрәмгә китми. Аларны дуңгызлар симертер өчен сов-хозга җыялар. Күрәсеңдер бит, һәр көн машинага төяп алып китәләр.

– Күмәч белән дуңгыз симертәбез диген, – диде карт, рәнҗүен яшермичә.

– Каткан ипи кимереп булмый инде, әткәй. Хәзер тамак турында уйлар вакыт үткән. Кеше ашар өчен яшәми, яшәр өчен генә ашый.

Мөслах карт бәхәсләшүнең файдасыз икәнлеген аңлады. «Малайга вакытында тәрбия бирә алмаганмын. Хәзер инде ана сөте белән кермәгәнне тана сөте белән кертеп булмас», – дип, үз-үзенә ачуы килде.

Шәһәр тормышының кайбер якларын күңеле белән кабул итеп бетерә алмаса да, монда авылдагыдан көй-ләрәк. Күңеле күтәренке, сәламәтлеге әйбәтләнгән чак-ларда кулга тотарга берәр эш тә булса, картның тормышы түгәрәкләнер кебек. Әмма шул эш юклык теңкәсенә тия дә. Беркөнне ул балалары өйдә юкта тамып торган кранны

рәтлим дип тотынган иде, кранны борып алу белән чаптырып су ага башлады да түбәнге катка төште. Түбәндә яшәүче кешеләр Мөслах картны эт итеп сүгеп төшеп киттеләр. Хафиз кайткач, ул да әткәсен шелтәләп алды:

– Юкка эчең поша синең, әткәй. Краннан аккан су кемгә дә зыян итми иде бит.

– Тамызмаска мөмкин нәрсәне нигә әрәмгә тамызырга?

– Бүтәннәрнеке әле чыжлап агып та утыра, аннан су бетми.

Картның тагын хәтере калды. «Бетеп беткән дөньяга нигә соң әле мин генә пошынып йөрим?» – дип, һәммәсенә кул селтәде.

Әнә шулай ата белән ул бер-берләренә үпкә саклап йөргәндә, Дамира өйгә яңа хәбәр алып кайтты.

– Безгә җир бирәчәкләр. Алабызмы, Хафиз? – диде ул.

Хафиз җилкәсен сикертеп куйды:

– Нәрсәгә кирәк булыр икән ул?

– Ничек «нәрсәгә»? Дача салырбыз. Җәйне шунда уздырырбыз.

– Болай да бик әйбәт уздырабыз бит әле. Теләсәк, ял йортына, теләсәк, курортына китәбез. Ә бакча ул – аякка тышау, муенга муенчак булачак. Бакчалы кешеләрне беләм мин. Алны-ялны белмичә шунда чабалар. Ашаула-ры – аш, йокылары йокы түгел. Юк, көйләнгән дөньябызның көен җибәрмик.

– Артык гамьсезлек үзе әшәке чир түгелмени? – диде Дамира. – Бигрәк уйсыз, борчусыз яши башладык.

– Сиңа борчу кирәкмени?

– Кирәк шул. Әнә язучылар, композиторлар җәй буе дачада ята!

– Аларның эше башка. Каләмнәре түшләрендә. Алмагач төбенә сузылып ятып шигырь язарга мин дә каршы булмас идем. Ә без болай да көне буе аяк өсте станок артында.

– Син дә физик эш белән җәфаланмыйсың әле. Көн буе станок янында утырып әнә корсак үсә башлаган инде үзеңә.

Хафиз белән Дамира, бәлки, бәхәсләшеп тә киткән булырлар иде, моңарчы читтә тыңлап кына торган әткәләре сүзгә килеп кушылды:

– Нинди җир ул, Дамира килен? Бакча, бакча, дисез, миңа да аңлатып сөйләгез әле.

– Бакча дип... Бакча түгел әле ул, әткәй. Бер ташландык җирдән өчәр сотый участок бирәләр. Безнең укытучыларның телендә гел шул хәзер. Җир алабыз да җир алабыз, диләр. Мин дә гариза язып керттем.

«Җир» сүзен ишеткәч, картның күңелендә өмет чаткылары ялтырап китте. Күз алдында үзе кайчандыр кадерләп үстергән бакчасы пәйда булды. Менә йодрык-йодрык алмалар ботакларын сыгып төшергәннәр, Мөслах карт агач ботаклары сынмасын өчен терәүләр куеп чыккан, имеш. Чык тамчылары белән юылган алмаларның һәрберсенә кояш тулган. Берсен өзеп алып учыңа салсаң, кайнарлыгы кулларыңны өтеп алыр төсле. Икенче якта балалар иренедәй алсу чияләр пешеп утыра. Җил искән саен, алар әкрен генә нәрсәдер пышылдашалар, кемнедер чакыралар сыман.

– Алырга кирәк ул җирне, балалар. Җир бит ул, җир... – Ул нидер әйтергә теләгән иде, күңеле нечкәрүдән бугазына кайнар төер килеп утырды да, сүзләр шул төер белән кире йотылдылар.

– Алай бик теләсәгез алырбыз, – диде Хафиз да.

Ял көннәренең берсендә «Казан–Васильево» поезды белән булачак дача урынын карарга киттеләр. Поездтан төшкәч, урман сукмагыннан өч чакрымнар чамасы араны тәпиләп, көчкә эзләп таптылар җирләрен.

Бакча өчен дип бүленеп алынган бу җир сугыш кырын хәтерләтә иде: кайда тирән-тирән чокырлар, кайда балчык өемнәре, кайда актарылып ташланган ташлар тәгәрәп ята. Мөслах карт «бакча өчен җир»не ниндидер чирәмлек итеп күз алдына китергән иде. Ул күзләренә ышанмагандай, аптырап сакалын сыйпады. Аңа балалары шаярталар сыман тоелды.

– Ә безнең дача кая соң монда? – дип сорады Рәзил. Ул «дача» сүзен көлеп әйтте, ләкин аның шаяруы башкалар күңелендә хуплау тапмады. – Бәлки, әнә теге ике этажлы зур-зур тәрәзәле йорт безнекедер. – Рәзил шык-раеп каткан бер балчык өеменә күрсәтте.

– Авызыңны ерма әле, ачу китереп, – диде Дамира улына. Дөресен әйткәндә, ул үзе дә мондый ук күренешкә тап булырмын дип көтмәгән иде. – Әйдәгез әле, председательне күрик, ул кемнең участогы кайда икәнен беләдер.

Алар председательне эзләп киттеләр. Юл янындарак бер-ничә ир-ат бура күтәреп маташа иде, шулар янына туктадылар.

– Ә-ә, алма җыярга килдегезме? – дип шаяртты арадан берәү, боларның сәламен алгач. – Без дә менә шул ният белән килгән идек тә, бәхетебез булгач, өмәгә юлыктык.

Болар каравылчы өчен бура күтәреп ятучылар иде. Сөйләшә киткәч, бакчачылык җәмгыятенең председателе дә шушында икәнлеге беленде.

– Бик ашыкмасагыз, бераз бурачыларга булышыгыз, аннары җирегезне күрсәтермен, – диде ул Хафизларга.

Хафизның ачудан күңеле ярсый башлаган иде, сөй-ләнеп-нитеп тормастан, бер бүрәнәнең юан башына килеп ябышты. Мөслах карт белән Рәзилгә дә эш табылды: алар мүк түшәп тордылар. Көн артык җилле булганлыктан, бүрәнә өстенә түшәлгән мүк һич кенә дә тормый: оча да төшә, оча да төшә. Аптырап беттеләр.

Бура тирәсенә әкрен-әкрен яңа кешеләр җыела торды. Осталар арасындагы теге җор телле егет уен-көлке белән һәммәсен эшкә җикте, йорт тирәсендә кешеләр күбәеп, бер-берләренә файдадан бигрәк зыян итә башлагач, председатель Хафизларны читкәрәк алып китте:

– Фамилиягез ничек әле сезнең?

– Хаҗиәхмәтов.

Председатель җирдә аунап яткан олы корсаклы портфелен алды, аннан төрле сызымнар, саннар белән чуарланган табаклы кәгазь тартып чыгарды. Бу бакчаның картасы иде. Картада бармагын шудыргалап йөрткәннән соң, бер урынга төртеп: «Сезнең менә унөченче участок», – диде. Барысы да карта өстенә иелделәр, тик кәгазьдән карап кына һични төшенерлек түгел иде.

– Сез безгә җирнең үзен күрсәтеп бирегез инде.

– Әйдәгез, алайса киттек.

Председатель аксаграк кеше икән, аксак булса да шәп элдертә, үзе артыннан өлгермәле түгел. Түмгәкләр өстеннән сикергәләп, чокыр-чакырларны читләтеп теркелди торгач, алар бер урынга килеп туктадылар.

– Менә сезнең участок, – диде председатель, тракторлар белән тапталып, таштан ныграк каткан җиргә күрсәтте. – Әнә анда казыклар кагылган. Бүгеннән бакчагызны эшкәртә башлый аласыз.

Председатель киткәч, Хафизлар үз участокларында аунап ятучы кәкре торба өстенә тезелешеп утырдылар.

– Бу нинди җир? – диде Мөслах карт, чиксез аптырап. – Минем ничә еллар сугышта йөреп тә мондый җир күргәнем юк иде. Йә, карагыз инде, монда бит көрәк түгел, кадак та кермәячәк.

– Бигрәк әйбәт, – диде ни өчендер сөенгән Хафиз. – Җире шәп булса, аласы килер иде әле, ә моны тамчы да җәлләмичә калдырып китәргә мөмкин.

Олылар сөйләнгән арада, Рәзил әнкәсенең сумкасыннан бер газета алып җиргә җәйде. Газетасын җил очырып китмәсен өчен, дүрт почмагыннан да таш белән бастырып куйды, аннары ашамлыклар чыгарып газета өстенә тезә башлады.

– Дачада саф һавада аппетит ачылды, әйдәгез әле, ашап ташлыйк, – дип теленә салынды ул. – Юкса алма исләре борынга кереп авыздан сулар китерә башлады.

Барысы да газета өстендә турап куелган сыр белән ипигә ябырылдылар. Ашарга керешкәч, һәркем үзенең ныклап ачыкканын тойды. Тиз арада ризыкларны ялт иттереп куйдылар.

– Дачаның файдасы хәзер үк күренә башлады, – диде Рәзил. – Ипинең валчыгы да калмады. Әгәр без бу җирне казый да башласак, өйдәге каткан ипиләрне дә алып килеп ашап бетерербез әле.

– Теләге бар кеше казысын, әмма минем беренче һәм соңгы килүем бу, – диде Хафиз.

Аның сүзләреннән Дамира кызып китте. Ул, участокны алуда үзе башлап йөргәнгәме, үзен гаепле сизә иде.

– Гел кирегә сукаларга торма әле, Хафиз. Бүтән кешеләрнең дә җирләре безнекеннән әйбәт түгел, алалар бит. Эшкә яраклы җирне бакчачыларга бүлеп тә бирмиләр.

Җилкәсенә көрәк күтәреп үтеп баручы бер агай болар янына туктады:

– Әйе, рәтле җирне бакчачыларга бирмиләр, – диде ул. – Башта бу җирнең өске кара туфрагын яшелчәчелек совхозы алып китте. Аннан ары ун ел буе кызыл балчыгын кирпеч заводы ташыды. Дөресен әйткәндә, безнең бу җиребез әйбер утыртыр өчен бер савыт кына. Ә савытны тутыру һәркемнең үз эше.

– Алайса, чуртымамы бакчачылык җәмгыяте төзеп маташалар. Шул җирне рәтләп бирерлек тә булмагач? – диде Хафиз.

– Ансыз ярамый, туган. Без монда үзебезгә күрә бер колхоз кебек. Менә күрерсез әле, бер биш елдан монда гөрләп үсеп утырган бакчалар булыр. Торбалар сузып, суын үткәргәч, җирен әйбәтләп тиресләп, ашлап җи-бәр-гәч үсә ул әйбер, үсә. Матурлык өчен кеше үз көчен җәлләми. Юлда яткан сыер тизәген дә кесәсенә салып килә башлarлар әле.

Агайның бу сүзләреннән елмаеп куйдылар, ләкин бу «без ул кадәрле үк юләр түгел» дигән мәгънәдәге елмаю иде.

Хафизлар ул көнне соң гына кайттылар. Берни эш-ләмәсәләр дә, шактый арыганнар иде. Тавыш-тынсыз бер-гәләшеп ашарга әзерләп ашадылар да йокларга яттылар. Атна буе бакча хакында сүз кузгатучы күренмәде, һәркем, башкалар ни уйлый икән дигән кебек, бер-берсен күзәтте. Шулай да иртәгә ял дигән көнне Рәзил шаяртып аласы итте:

– Безнең андагы яшелчәләрне көзге кырау сукмагае. Әллә иртәгә җыйнаулашып барып җыеп кайтабызмы? – Ул, сүзенә ихласлык бирергә тырышып, үзенең походларга йөри торган рюкзагын киштәдән тартып төшерде. – Мин әзер, һәрвакыт әзер!

– Әзер булсаң, бар әле, тиз генә кибеткә йөгер, – диде аңа әнкәсе. – Өйдә продуктлар беткән. – Һәм Дамира нәрсәне күпме алырга кирәклеген улына аңлата башлады.

– Иртәгә дачага алып барырга да ашамлык кирәктер әле, – диде Рәзил, һаман шаяртуын дәвам итеп.

– Телеңә салынма, әйткәнне эшлә.

Рәзил чыгып киткәч, өйдә шактый вакыт тынлык хөкем сөрде. Бераздан Мөслах карт тамак кыргалап болай диде:

– Әллә соң, балалар, иртәгә тагын тәвәккәлләп карыйбызмы? Мин юләр башым белән уйладым-уйладым да җирдән болай гына отказ бирергә ярамас дигән фикергә килдем.

Хафиз белән Дамира бер-берләренә карашып куйдылар. Аларның үз күңелләрендә дә шундыйрак уй бутала башлаган иде, күрәсең. Ләкин, төп җаваплылык беренче башлап ризалыгын биргән кешегә төшүдән куркыпмы, фикерләрен әйтергә ашыкмыйлар иде. Ә беркатлы Мөслах карт сүзен болайрак очлады:

– Бәлки әле, җире дә ул чаклы ук каты түгелдер, казып карамадык бит. Безгә, өч ир-атка, өч сутый җир нәрсә ул. Ә инде җирне ашлауга килгәндә, аңа җитәрлек кенә тиресне кесә белән дә ташырбыз, Алла боерса.

Мөслах картның бу сүзләре бик вакытлы әйтелде. Эшне кемнең дә булса әнә шулай җиңеләйтебрәк, га-диләштеребрәк әйтүе кирәк иде, чөнки башта ук авыр итеп күз алдына китерсәң, тотынырга куркып калуың мөмкин. Кеше бит ул һәрвакыт үзенә берәр биеклек билгеләп куя да шул биеклегенә баскычлап-баскычлап менә. Ваклап-ваклап атлау, һәр очраган кыенлыкка яңа чишелеш эзләү җиңелрәк.

Безнең бакчачыларыбыз икенче көнне иртүк торып тагын юлга әзерләнә башладылар. Вокзалга барышлый, хуҗалык кирәк-яраклары сата торган кибеткә сугылып, көрәкләр алдылар. Мөслах карт, көрәк йөзенә бармагын тидереп карады да:

– Игәү дә алыйк, – диде.

Барып җиткәч, Мөслах карт бу көрәкләрне кайрап җибәрде.

– Аллага тапшырыйк, булмаса, – диде ул һәм учына төкереп эшкә ябышты.

Бүтәннәр дә аның үрнәгенә иярделәр. Башлаганда бик шәбәеп, тиз арада бөтен җирне актарып ташламакчы иделәр, әмма җиргә беренче тапкыр көрәкне тыгып карау белән болай гына теш үтмәслеген аңладылар. Көрәк, барлык авырлык белән сикерә-сикерә басканга, бармак калынлыгы да керми иде. Көз коры килгәнлектән шыкраеп каткан үзле балчыкның бирешергә һич исәбе юк иде.

– Моны казырга лом кирәк, – диде Рәзил.

– Монда лом да уймак-уймак кына эз калдырыр, – дип, Хафиз сукранып алды. – Бер мичкә динамит күмеп шартлатсаң, бәлки, берәр көрәк җирне каерып чыгарыр.

– Ә башкалар ничек казый икән соң? – дип, Дамира тирә-ягына каранып куйды. Болардан шактый еракта берәү күлмәкләрен салып ташлаган да киерелеп-киерелеп кәйлә белән җир казып ята, ә хатыны авыр китмән белән ире актарып чыгарган кәсләрне ваклап тора иде.

– Кешеләр җаен тапкан, – диде Дамира, әллә көрсенеп, әллә аларны кызганып. – Иртәгә без дә кәйләләр алып килик.

– Бу җирне, балалар, бәндә түгел, Аллаһы Тәгалә үзе дә игә-җүнгә китерә алмас, – диде Мөслах карт, күңеле кайтып.

– Монда бик романтично бит, бабай. Әнә анда күл бар. Балык тотарбыз, уха пешерербез. Их, бәрәңге алып килгән булсак, учак ягып бәрәңге пешерер идек.

Рәзилнең ярым шаярып, ярым җитди әйтелгән бу сүзләренә беркем әһәмият бирмәде. «Нишлибез соң инде?» дигән сыман, Дамира белән Хафиз бер-берләренә карашып алдылар. Хафиз эткәсенең үзләренә килгәннән бирле җанына урын таба алмыйча һәрбер вак-төяккә бәйләнүен күз алдына китерде. «Әлбәттә, бакчаны бер җайга салып җибәрсәк, эткәйгә юанып ятарга әйбәт нәрсә булыр иде. Эшсезлек интектерә картны. Авылдагы бакчасы юкка чыкканнан бирле үзенә урын таба алмый. Бөтенләй бетерешә. Юкса бит әле яшәрлеге бар аның. Үзеге таза».

Ә Мөслах карт исә болай уйлады: «Җирләрен ялгыш хурлап ташладым, телемне корт чаккыры. Маташа торгач барып чыгар иде әле. Атнасына ике ялын кая куярга белмичә аптырап шешәгә барып ябыша. Бакчасы булса, кыек төяп йөрергә вакыты калмас иде».

Дамира тегенди-мондый хыялларга бирелмәде. Аның бары тик үз бакчасыннан шыгырдап торган кыярлар өзеп ашыйсы, поезда кайтканда үзе үстергән чәчәкләрне кочагы белән күтәреп кайтасы килә. Тик бу уйлар бер дә тормышка ашар төсле күренми шул.

Тагын икеләнеп калдылар. Күңелләрнең икеләнгәнен сизеп, көрәкләр дә салмаграк кыймылдый башлады. Шулай да берничә сәгать маташтылар һәм зуррак өстәл чак-лы җир казыдылар.

– Бара бит, – дип куйды Мөслах карт, баягы сүзен йомшартырга теләп.

– Без болай башны күтәрми эшләп, кеше җиренә кереп китмик тагын, – диде Рәзил.

– Әле өй урынын да билгелисебез бар икән, – диде Дамира.

Дамираның бу сүзләре куллардан көрәкләрне ташларга җитди сәбәп иде, җыйнаулашып, кайда һәм ничек итеп өй салу турында гәп корып җибәрделәр.

– Өен иркен итәрбез, – диде Дамира.

– Әйе, өе зуррак булса, казырга җире әзрәк калыр, – диде Хафиз.

– Ике этажлы итәргә кирәк, – диде Рәзил. – Өске катта үзем йоклыйм. Кояш чыгышы ягына балкон ясап җибәрербез, мин шунда раскладушкага ятып кояшта кызынырмын. – Ул, салыначак өйне күз алдына китереп, телен шартлатып куйды.

– Өй салу җир казу гына түгел, балалар, – дип әңгәмәгә кушылды Мөслах карт та. Аның инде үз гомерендә берничә өй салганы бар иде, шуңа күрә юк-бар хыялга бирелергә ашыкмады.

– Ничего, әткәй, салырбыз. Ир кеше үз гомерендә бер өй салып карарга тиеш инде.

Хафизның теләсә нинди эшкә кулы ябышып тора. Заводында аны алтын куллы дип йөртәләр. Үз келәймәсе бар. Менә ничә ел инде аның бер генә тапкыр да брак җибәргәне юк. Агач эшен дә, тимер эшен дә бердәй ярата. Өч бүлмәле фатирга күчкәннән соң, залның ике як стенасын тутырып китап шкафы ясап җибәрде. Дамирасы китаплар җыярга һәвәс. Казанда гына тапмаган китапларын әллә кайсы шәһәрләрдән кайтарта иде. Элегрәк аңа төрле китап сөючеләрдән хатлар агылып торды. Тик менә соңгы елларда аларның тормышлары күңелсезләнеп китте. Хафиз ясаган киштәләр китаплар белән тулды. Дамира баштарак һәр яңа китапны укып, һич югында, өстән-өстән караштырып чыккач кына киштәгә куя иде, ләкин тора-бара нишләптер кызыксынуы кимеде, өлгерә дә алмый башлады. Ә Хафизга өйдә эш бетте. Тормышлары үзеннән-үзе салмак агымга кушылды. «Картаю шулдыр инде», – дип юатырга тырыштылар алар үзләрен. Менә бакча алырга чын-чынлап карар кылынгач, һәркайсы ничектер яшәреп киткәндәй булды. «Әйе, җирдән баш тартырга ярамый, хәзер, шәһәрләр зурайган саен, күңел табигать белән икәүдән-икәү калуны күбрәк теләр».

Бергәләшеп киңәш-табыш иткәч, алар «туңганчыга кадәр бакчаны ничек тә казып калдырырга кирәк» дигән нәтиҗәгә килделәр.

– Көз көне казып калдырган җирдә әйбер яхшырак үсүчән, – диде Мөслах карт.

Өй турындагы уйларны киләсе елга калдырып, бөтен көчне җир казырга тупладылар. Алга шуны максат итеп куйгач, эшләре бераз җиңелрәк бара башлады. Ә беркөнне атна уртасында шактый көчле яңгыр явып узгач, җирнең ярыйсы гына йомшарганы беленде.

Октябрь ахырлары якынлашуга карамастан, көннәр җылы торды. Хафизлар гына түгел, башка бакчачылар да көзнең матурлыгыннан файдаланып калырга тырыштылар. Берничә чакрым ераклыкта суы кипкән күл бар икән. Бакчачылар бергәләшеп шуннан торф чыгарырга тотындылар. Шимбә, якшәмбе көннәрендә тирә-юнь чыр-чу килгән кешеләр тавышыннан, выж-выж чапкан машиналар гөрелтесеннән шаулап торды. Тыныч кына аккан шәһәр тормышыннан соң монда ничектер бөтенләй башкача, кызык та, рәхәт тә иде. Кешеләр бер-берләре белән тиз арада танышып өлгерделәр, адреслар алмаштылар, шәһәргә кайткач, кунакка йөрешергә вәгъдәләр бирештеләр. Беркем дә бакчадан ниндидер табыш алу турында уйламады, һәркем күңелендә тик бер генә ният – ничек тә көздән бакчаны эш итеп калдыру иде.

Маташа торгач, Хафизлар үзләренең җирләрен ярыйсы гына ермачлап чыктылар. Казылган түтәлләр өстенә торф та китереп түшәгәч, җир күрер күзгә үк матураеп китте.

– Моның өстендә хәзер рәхәтләнеп йокларга була, – диде Рәзил һәм иң йомшак күренеп торган түтәл өстенә менеп ятты. – Карагыз әле, җирнең исе шундый тәмле икән. – Рәзил кушучлап торфлы туфракны алды да бабасына, әти-әнисенә иснәтеп чыкты.

– Җирдә, улым, бөтен нәрсә бар, – диде Мөслах карт, хискә бирелеп. – Авызда шикәр кебек эрүче кавын-карбызлар да, учыңа салсаң уттай янучы чияләр дә тәмне җирдән алалар.

– Болай булгач, монда әйбер үсәр, эти, ә? – диде Хафиз.

– Үсәр, балалар, үсәр. Җир үзен кадерләгән кешене коры калдырмый ул.

– Нәрсәләр утыртырбыз икән, эти?

– Әлбәттә, чия, – диде барлык җимешкә караганда чияне ныграк яратучы Рәзил.

– Чәчәкләр, – диде гүзәллеккә гашыйк Дамира.

Мөслах карт кына үзенә бирелгән сорауга җавап тотарга ашыкмады. Ул төрле урыннан туфрак алып учында кыскалады. Шуннан соң:

– Нәрсә утыртырга икәнлеген менә җирдән сорарга кирәк. Иң дөрес җавапны ул гына әйтә ала, – диде.

– Ә җир нәрсә әйтә соң, бабай?

– Җир бик тыгыз. Авыр. Урыны да түбәнлектә. Яз көне су басмагае. Мондый җирдә чия үсмәс, балалар. Чия ул кашлактарак, кояшта кызыныбрак үсәргә ярата. Монда, мөгаен, җир асты сулары да тирәндә түгелдер. Җир асты суы метр ярымнан да өстә булса, чияне утыртып маташасы да юк.

– Анысы да бар икән әле, – диде Хафиз, бераз аптырабрак. – Ә алмагач үсәме соң?

– Алмагачка суның тагын да тирәндәрәк булуы хәерле. Ну, җирне ныклап тикшермичә берни дә әйтеп булмый әле, балалар. Алмагач ул – бакчаның күрке, бик үссен иде дә бит. – Һәм Мөслах карт алма сортлары турында мавыгып сөйләргә тотынды. Алмагачларны ул барлык агачларга караганда да ныграк ярата. Алар турында күңелендә күп кенә матур хатирәләр саклана. Бервакыт ул, әле яңа бакча утырта башлаган чорда, карчыгының туган авылы Тәмтедә әллә нинди, моңарчы үзенә таныш булмаган алмагач күрде. Алмалары яшькелт, бераз очлаебрак төшкән һәм уртача эрелектә иде. – Нинди алма болар? – дип сорады ул бакчачы хатыннан.

– Белмим, – диде хатын. – Аларны мәрхүм ирем утырткан иде. Аның бөтен белгәне шушы бакча булды. Тик менә җимешен үзенә авыз итәргә язмаган икән, алмагачы беренче чәчәк аткан елны сугышка китте дә шуннан кайтмады.

Мөслах, бу хатынның кайгысын уртаклашып, фронт истәлекләрен сөйләп алды. Аннары ят алмагачның төшен сорады.

– Төшен генә түгел, көз житкәч төпләп алырсың, – диде хатын. – Минем картым үзе дә кайда ят җимеш агачы күрсә, шуны алып кайта торганые.

Мөслах алмагачны төпләргә кызганды, төшен генә алды. Кайткач үз бакчаларына утыртып үстерде. Аннары шуны Бөгелмә питомнигына алып барып сортын билгеләтте. Белгечләр аның «Крюднер ренеты» икәнен ачыкладылар, аның кайсы авылда табылганын сорадылар. Бу сорт алма әле Татарстанда таралмаган икән, шуңа күрә төшләрен үз питомникларына кайтарту чарасын күрделәр. Ә Мөслах бакчасында ул елдан-ел ишәйде, һәм Мөслахның иң яраткан алмагачларыннан берсенә әйләнде.

Башка сорт алмагачларның да әллә никадәр хатирәләре саклана Мөслах карт хәтерендә. Ул хәтта гомер исәбен дә «фәлән алмагач утырткан елны фәлән вакыйга булды» дип исәпли иде. Ләкин бакчасы һәлакәткә очрагач, һәммәсе буталды. Әйтерсең гомер йомгагын кемдер кинәт чуалтып ташлады да, хәзер шуның очы-кырые югалган иде. Яшьрәк чагы булса, бәлки, өр-яңадан башлап җибәрерлек көч табар иде, тик яшең җитмешкә җиткәндә кая инде ул хакта уйлау. Бары тик тирән итеп көрсенергә генә кала. Хәер, менә бу җир белән мәшәләнә башлагач, күңеле тырпылдап куйды картның, ләкин ул белә – бу инде күкрәп утырган колхоз бакчасы түгел. Бакча иркенлекне ярата. Аңа җәйнең йомшак канатлы җилләре, мул холыклы кояшы теләсә кайчан кереп йөрергә тиеш. Ә бирεдә һәркемнең ашъяулык кадәр җире. Биек-биек өйләр дә салып җибәрсәләр, агачларны күләгә каплар. Язларын җир озак вакыт җылынмыйча ятар. Үсемлекләр үз вакытында өлгерә алмаслар. Бигрәк тә җирнең түбәнлектә булуы куркыта картны, чөнки түбәнлектә салкыннар аеруча озак саклана. Дөрес, Мөслах карт үзенең шик-шөбһәләрен балаларына әйтми. Аның әле үз күңелендә дә «Бәлки, барысы да әйбәт булыр. Агачлар алар, кешеләр кебек, тормышка тартылучан» дигән өметләр йөри.

Алар ул көзне җирләренә әйбер утырта алмый калдылар. Көз бер килә башлагач коры тотты, ишеп-ишеп кар яуды һәм шул явудан эретмәде. Бакча эшләреннән туктагач, тормыш тагын шул талгын агымына төште. Хафиз үзенең ял көннәрен ничек үткәрергә белмичә төшкә кадәр урын өстендә ауный торган булды. Ул да арытып җибәрсә, кибеткә чыгып салгалап кайтты. Үз гомерендә әче балдан башка исерткечне авызына алып карамаган Мөслах карт ярты чакрымнан улының эчкәнлеген сизә иде.

– Тагын сасып кайттыңмы? – ди ул кырыс кына.

– Мин, әткәй, чама белән генә бит.

– Болай итеп йөргәнче, бакчагызга өй салу турында уйларга иде.

– Кыш көне кем инде катып-туңып өй салып йөри? Язга чыккач та өлгерербез әле, аның бөтен кызыгы шунда.

Моңа каршы Мөслах карт ни әйтсен, сүзе бетә. Шулай да ул мыгыр-мыгыр бу эшсез тормышны сүгә. «Йә, ничек инде шулай гамьсез итеп дөнья көтәргә кирәк. Табын тулы сый-хөрмәт. Өс-башка әллә ничә кәчтүм. Борын астына мыек чыкмаган Рәзилнең генә дә өч пәлтәсе бар. Җүнлегә бара микән бу дөнья?»

Мөслах картның уйлавынча, хөкүмәт артык юмарт кылана. Атнасына биш көн эшләгәнгә уч тутырып акча бир инде. Болай барса, кешеләр бозылып бетмәгәе. Авырлык күрми үскән кеше тормыш кадерен белми башлый бит. Ничек соң боларның күңелләрен тынгысызлап торырлык эш табарга?

Шул хакта шактый баш ватып йөрде карт. Һәм эзләнүе бушка китмәде. Үзләре яши торган урамнан ерак түгел Савиново бистәсендә сүтелергә тиешле йорт барлыгын белде ул. Башта балаларына әйтмичә үзе барып карады. Йорт, тактадан гына корыштырылган булса да, шактый таза күренә иде. Мөслах карт үзенең очлы таягы белән һәрбер почмагына төрткәләп чыкты һәм бик канәгатьләнеп өенә кайтты.

– Дачагыз өчен шундый хәтәр өй таптым, – диде ул тантаналы рәвештә. – Кыйбат та сорамыйлар.

– Нинди өй ул, эткәй? – диде Хафиз, этисенең кысылып йөрүенә ачуы килеп.

– Соң, сез бит берәр вакыт бакчагызга өй салачаксыз инде. Хәзердән үк чарасын күрә торырга кирәк дим.

– Вакыты җиткәч тә өлгерер иде әле.

– Син эзләгәндә генә табылмый ул.

Аш-су әзерләп йөрүче Дамира да сүзгә кушылды:

– Син, Хафиз, эткәйнең сүзенә колак сал әле. Өе әйбәт икән, уйлап карау ярый.

– Йортны мин аны өр-яңа тактадан, үзем теләгәнчә итеп эшлим, – дип каршы төште Хафиз. – Карап торырлык булсын. Шәһәрдә дә бертөрлелектән туйган.

– Үзеңчә салырсың, – диде Мөслах карт, – анысына минем сүзем юк. Мин сөйләшеп кайткан өй тактадан корылган. Сүтеп, ышкылап җибәрсәң, яңадан мең елга түзәрлек.

Үгетли торгач, Мөслах карт улын өйне барып карарга тәки күндерде. Йорт чынлап та таза иде. Сүтеп, өр-яңадан эшләгән очракта менә дигән дача чыгачак. Тик хуҗалары сүтәргә ашыгалар, язга тикле көтәргә мөмкинчелекләре юк икән. Хәер, эшкә атлыгып торган Мөслах карт монда да җаен тапты. Шул ук Савиново бистәсендә яшәүче берәү белән сөйләшеп, сүтелгән такталарны шулар ишегалдына куеп торырга килешеп кайтты. Хафиз эткәсеннән болай гына котылып булмаслыгын аңлады, һәм бер ял көнне үзенең берничә хезмәттәшен чакырып өйне сүтеп ташлады.

Өй сүтелеп, такталар тиешле урынга ташылгач, Мөс-лах карт бөтенләй тынычлыгын югалтты, иң беренче эш итеп үзенең авылда калган эш коралларын китертте. Аларның һәрберсен чәч пәкесе кебек итеп үткерләп куйды. Аннары, һәр көн иртән, барлык кешедән алдарак торып, такталар шомартырга китә торган булды. Хафиз, аның сәламәтлеге өчен борчылып:

– Син, эткәй, ул кадәр тырышма әле, – диде. – Өзлегеп китәрсең. Такталарны без Рәзил белән дә шомарта алабыз. Шулай бит, улым?

Рәзил буш вакытларында болай да бабасына ярдәмләшә иде. Ул үзенең эшкә сусаганлыгын аңлый башлады. Таза тән, ташып торган көч туктаусыз хәрәкәт таләп итә иде. Урамда шар сугып йөрүләр, үзе кебек малайлар белән җыелышып мәзәк сөйләнүләр җанга да, тәнгә дә ял бирми. Рәзил шуны аңлады: эштән алган рәхәтлек бөтенләй башка төрле икән. Син ышкылаган такталарның ялт итеп агарып китүе, син салган сырларның мәңгелек булып такта өстендә уелып калулары, гап-гади кораллар белән агачны үзең теләгән рәвешкә кертү – болар күңелдә горурлык тудыралар, хыялларга җирлек бирәләр.

Хафизга килгәндә, ул эшне элек тә ярата иде, ял көннәрендә рәхәтләнеп такта каезлады. Тактаның эше беткәч, алар бергәләшеп салыначак өйләренең сызымын сыздылар. Бу нәрсә шактый вакытны алды, чөнки һәркем үз күңелендә туган төзәтмәләрне өсти иде.

Язны алар ашкынып көттеләр, ләкин яз бакчачыларга шатлык китермәде. Бөтен кешенең җире су астында калган иде.

– Булмады, – дип кул селтәде күңеле төшкән Хафиз.

– Ашыкма, – диде Дамира, – язгы су әллә нигә бармас, сеңәр дә бетәр. Шулай бит, эткәй? – Дамира яшерен өмет белән каенатасына карады.

– Әйе, – диде Мөслах карт, киленен тынычландырырга теләп. – Су ул начар нәрсә түгел. Су җыелган җиргә лай утырып калучан, ә лайда әйбер бик уңа.

– Беләсезме нәрсә чәчик? – диде шаян телле Рәзил. – Дөге. Дөгене бит су эченә чәчәләр.

– Ат аягын дагалаганда, бака ботын кыстырган, ди.

– Ә нигә, эти? Бөтен дөнья су булгач, бигрәк романтично инде. Өйне свайларга утыртырбыз. Бакчада көймә белән йөрербез. Көймә ясарга такта җитәрлек, бабай, ә?

– Сиңа кайда да романтично, улым.

– Исегез киткән икән иске чикмәнгә. Ачуымны китерсәгез, берүзем дачагызны салырмын да куярмын әле.

– Синең ачуыңны ничек китерергә икән соң?

Хафизның бу сүзләре чытыкланган йөзләрдә елмаю уятты. Бакчаны бер мәлгә телгә алмый йөрделәр. Ләкин ул хакта сөйләшмәсәләр дә, күңелләре саф һа-вадагы күмәк эшне сагына иде. Бүтән бакчачылар да бергәләшеп сөйләшә-киңәшә торгач, бакчачыларның гомуми җыелышында җирне туфрак китертеп күтәртергә дигән карар чыгардылар.

Ул елны җәй бик яңгырлы килде. Инде юллар кипшерә башлар дип көтсәң, өр-яңадан язгы көннәрдән дә ныграк пычратып ташлый иде. Шулай да бакчада шактый эш эшләнде. Кешеләр председатель кыймылдаганны көтеп ятмадылар, мөмкинчелеге барлар үз участокларына җир ташытып күтәртә башладылар. Кайберәүләр өй дә салып җибәрде. Ә инде җәй ахырларында көннәр аязып киткәч, өйләр, әкияттәге патша сарайлары кебек, ниндидер тылсым белән төн йоклап торганчы калкып чыга башлады. Бу могҗизаны күреп, Мөслах карт шаккатты:

– Ай-яй-яй! Нәрсә эшләтә икән шулкадәр кешене? Комсызлыкмы? Алай дисәң, бөтен кеше комсыз була алмый. Көнчелекме? Ләкин көнләшер өчен кемнәндер күрергә кирәк. Ә болар япа-яланда әнә ниләр кылалар. Бәлки, шәһәр тормышының бертөрлелегеннән тую, аңардан котылырга теләү шулай дәртләндерәдер. Кешегә кергән көч ничек тә чыгарга тиеш. Тормыш әйбәт, тамак сыйлы, кул белән эшләү бетеп бара. Ничек чыгарсыннар көчне? Ә бәлки, кешегә бәләкәй генә булса да үз дөньясы кирәктер, һәркем тормышны, андагы матурлыкны үзенчә аңлый. Әнә шул күңелдәге матурлыкны үзе теләгәнчә эшкә ашырырга кирәктер. Шәһәр тормышында мондый мөмкинчелек юк. Анда һәркем ниндидер бер кысага кысылган. Ә җан дигән нәрсә чикләрне сөйми.

Мөслах картның күңелендә шуңа охшашлы уйлар йөрде. Соңгы вакытларда ул, гомумән, хыялга бирелергә ярата башлады. Әллә инде эш юклыктан, әллә картлык галәмәте. Ул үткән гомеренә ешрак әйләнеп кайткан саен, үз тормышыннан ниндидер мәгънә эзләде.

...Бераздан аларның участоклары да кипшерде. Мөслах картның кушуы буенча, былтыр таратып ташланган торфны һәм язгы сулардан утырып калган ләмне бер өемгә өйделәр.

– Болар китерткән туфрак астында калмасын, – диде карт. – Соңыннан, җирне күтәрткәч, кире таратырбыз.

Бу киңәш чынлап та бик урынлы иде. Җирне күтәр-тергә дип китерелгән туфрак әйбер үсәрлек түгел иде.

Ташылган җирне тигезләп, ашламаларны өскә тараттылар.

– Хәзер бу җиргә теләсә нәрсәне курыкмый утыртырга була, – диде Мөслах карт. – Карагыз инде, түшәк кебек бит. Җир асты сулары да түбәндә калды.

Өй саласы урынны трактор белән тигезләтеп, өйгә тотындылар. Әллә кыштан ук бөтен нәрсәне әзерләп куйганга, әллә җирләренең кибүен көтеп күптәннән кыҗрап йөргәнгә, эшләре әйбәт барды. Бер шимбә-якшәмбе көнне өйнең кысасын утырттылар. Яңа гына кадаклап төшкән тактага пар чыпчык килеп кунгач, сөенечләре чамадан ашты. Ул чыпчыкларны иң беренче Рәзил күреп алды.

– Карагыз әле, безнең хәзер үз чыпчыкларыбыз да бар, – диде ул.

– Ничек матур утыралар, – дип куәтләде аның сүзен бабасы. – Алла боерса, өйләребезнең коты булыр.

Дамира белән Хафизга да бу чыпчыклар бүтән чыпчыкларга караганда матуррак күренде.

– Өйне салып бетергәч, ике як кыекка сыерчык оясы ясап куям, – диде Хафиз.

– Иң беренче үзебезнең чыпчыкларга оя ясыйк, – диде Рәзил. Аннары өлкәннәрдән җавап көтмичә үз-үзенә сөйләнде: – Кешеләр ни өчен сыерчыкларны ныграк яраталар икән? Язларын гына килгәнгәме? Ә бит ныклабрак уйлап карасаң, иң кыен чакларда ташлап китмәүчеләр, кыш салкынын синең белән уртаклашучылар кадерлерәк булырга тиеш. Чыпчык турында шагыйрьләр җыр язмыйлар. Шигырьләр, җырлар сандугач, торна, аккош турында. Кошлар да кеше төсле, ахры. Кешеләрнең дә бит күбесе гомере буе эшләп тә макталу ишетми. Ә икенче берәүләр кинәт кенә ялтырап алалар да шуның белән гомер-гомергә дан-дәрәҗәгә күмеләләр. Кызык кына бу тормыш дигәнең...

– Тормышта кеше әллә нинди хәлләргә төшә, – дип, Мөслах карт оныгының фикеренә сүзен ялгап китте. – Бервакытта да мин бөтенесен эшләдем инде диярге ярамый. Менә минем бакчамнан ни калды? Ә бит мин аңа бөтен көчемне, бөтен тырышлыгымны салган идем. Минем ул тырышлыгымнан хәзер кемгә файда? Менә син, Рәзил улым, кешеләрнең кайберләре гомере буе эшләп тә макталу күрми, дисең. Мине нәрсәгә мактасыннар? Мин кешеләргә ни калдырам?

Рәзилгә бирелгән сорауга Дамира җавап бирде.

– Син, әткәй, ялгышасың, – диде ул. – Дөньяда бер эш тә эзсез калмый. Ярый, синең бакчаң юкка чыксын ди. Ә бит ул шаулап утырганда, аңардан күпме кеше файдаланган. Синең хезмәтең кулларына алма тотып йөгергән сабый шатлыгында, табыннарның муллыгына рәхмәт укыган кешеләр куанычында яши. Ә макталу яки макталмау икенче нәрсә. Уйлап карасаң, әнә шул кешеләрнең шатлыгы иң зур мактау түгелмени?

– Сез, укытучылар, һәрнәрсәдән шулай хикмәт чыгарасыз инде, – диде Мөслах карт. Ләкин Дамираның сүзләре аның күңеленә ятты. Килененең шулай акыллы, төпле фикер йөртүе картка бик ошады.

Ә Дамира сүзен болай очлады:

– Әгәр синеңчә уйласак, без киләчәк буынга нәрсә калдырабыз соң? Без бит бакчалар утыртмыйбыз, сарайлар салмыйбыз, ачышлар ясамыйбыз. Бары тик кешеләр салган белем сарайларында кешеләр ачкан ачышларны гына өйрәтәбез.

– Ә син минемчә уйлама, кызым. Үзеңчә уйла. Синең эш белән безнең эшне чагыштыра торган түгел. Җир белән күк аермасы.

Мөслах картның укыган кешеләргә гомумән ихтирамы зур. Ә Дамираны ул үз баласыннан да артыграк ярата. Казанда ни гомер торып, авылга кайтып китмәве дә әнә шул Дамираның татлы теле, йомшак мөгамәләсе аркасындадыр. Хәер, авылы турында бөтенләй онытты дип булмый. Беркөнне ул хәтта китәргә җыена язып калды. Ләкин аның шундый карарга килүенә Дамира түгел, улы сәбәпче иде. Хафиз әкрен генә кухняда коньяк чөмереп утыра иде.

– Нәрсәгә дип эчәсең шуны? – диде Мөслах карт, чыгырыннан чыгып.

– Эшләр әйбәт бара бит, әткәй. Күңел күтәрелеп китте. – Хафиз төзелеп килүче өйне күз алдында тотты. – Шундый матур өй салабыз.

– Һы, – диде Мөслах карт. – Эшләр әйбәт бара дип тә эч, эшләр тукталып тора дип тә эч. Аннан ни була?

– Синең эчкән кешеләрне күргәнең юк әле, әткәй, шуңа мине битәрлисең. Моның хәтле генә министрлар да эчә. Әнә телевизордан күрәсең бит. Эчмәгән, тартмаган кино бармы?

– Телевизорда да шул синең кебек кешеләр инде. Шуны әйбәткә саныйлар. Килер әле бервакыт шундый заман: кешеләр янында тышка чыгарга оялган кебек, кешеләр эчүдән дә оялырлар.

– Син бигрәк инде, әткәй.

– Бер дә «бигрәк» түгел.

Картның сүзләре, туктаусыз тамган тамчы кебек, Хафизның күңеленә тәэсир итә тордылар. Ул инде хәзер кәеф күтәрелде дип тә, эч поша дип тә шешәгә тотынмый башлады. Бакчадагы өйнең һәр такта кадаклаган саен матурлана, хыял җимешеннән чынбарлыкка әверелә баруы тегенди-мондый уйларны читкә куа иде.

Хафиз быелгы ялын шушында үткәрергә булды. «Корсак та бераз җыелыр, ял йортына бармыйм», – диде ул. Дамираның шулай ук укыту эшләре башланмаган иде әле. Алар өйләренең тышкы ягы бетү белән урын-җирләрен төяп китерделәр һәм шунда яши башладылар. Ирләр өй белән мәшәләнде, Дамира аш-су әзерләде. Рәзил, олылардан күз яздырып, балыкка сыптыру ягын карады. Балыкның әллә ни эресе эләкмәсә дә, ул бик шат иде. Хәтта өлкәннәр дә бармак буе балыкларны кылчыгын да калдырмыйча мактый-мактый ашадылар.

Төннәрен алар учак ягып җибәрәләр иде. Кап-караңгы төндә учак каршысында әкрен генә гәп сату үзе бер рәхәтлек. Төн ничектер кешеләрне бер-берләре белән якынайтты сыман. Дамира белән Хафиз икесе бер кешедәй булып сөялешеп утырганнар. Алар инде соңгы елларда шулай якын итеп, кочаклашып утыруны онытып баралар төсле иде. Мөслах карт шарт-шорт янган учакка текәлеп үз уена чумган. Барыннан ди бигрәк Рәзилгә рәхәт. Ул болай да дөрләп янган утка утын өсти. Учак кайнарлыгын гомергә күкрәгенә җыеп калырга теләгәндәй, колачларын җәеп җибәрә яки ачык пиджак изүләре белән үз-үзен кысып кочаклый.

– Берәр вакыт менә бу учак урынында йодрык-йодрык алмалар үсеп утырыр әле, – ди ул, хыялга бирелеп. – Мин ул алмагачның иң югары ботагына менәрмен дә сезгә алма коеп төшерермен. Сез, алма пеште, авызга төште дип, агач төбендә ятарсыз. – Рәзилнең сүзенә җавап кайтарып тормыйлар, чөнки һәркем моның шулай буласына ышана. Ә Рәзил сүзен сорау белән тәмамлый: – Бабай, өйне салып куйгач, җимеш агачларын утыртып чыксак, монда эш бетәр, аннан соң нишләрбез икән?

– Бакчада бервакытта да эш бетми, улым. Бакча ул яшь бала кебек, гел карап, тәрбияләп торганны ярата. Монда әле эш башлана гына.

Мөслах карт тирә-ягына каранып куйды, һаман үз җирләрен килеп карамаучылар бар икән әле. Бөтен кеше бертөсле түгел шул, дип фикер йөртте ул. Юкса менә башкалар белән бергә-бергә кайнашканда күңеллерәк бит. Һәркем берьюлы утыртса, монда тоташ зур бакча барлыкка килер иде. Сукмаклар, ызыннар ярылып ятмас иде.

Хәер, сукмак дигән нәрсә кеше белән кешене аерыр өчен түгел бит, ә тоташтырыр өчен дә. Кешеләрне тоташтыра торган сукмаклар күбрәк булсын иде җирдә.

Хафизның ялы бетәргә атнадан артык калганда, өйгә соңгы кадак кагылды. Озакка сузмыйча аны матур сары төскә буяп җибәрделәр. Ул яңа туган чебеш төсенә керде.

Куллардан балта-чүкеч төшкәч, эш кимер кебек күренгән иде дә, Мөслах карт әйтмешли, өй ул эшнең бисмилласы гына булып чыкты. Бакча эшләре башланды. Монда инде таякның юан башы Мөслах картка төште. Хәер, карт моңа куанды гына. Ул өр-яңадан дәртләнеп, рухланып китте: йокысы – йокы, ашы аш түгел. Тизрәк бакчага чабарга гына тора. Арча питомнигына үзе барып, җимеш агачлары сайлап алып кайтты, һәр агачка тиешенчә чокырын казып, ашламасын салып, тәфсилләп утыртты. Мөслах карт янына еш кына киңәш сорап килә башладылар. Андый вакытта карт, үз шөгылен онытып, ярдәмгә ашыкты. Тиз арада аның белгеч дигән даны таралып өлгерде. Ә беркөнне бакчачылык җәмгыятенең председателе Мөслах янына килеп мондый тәкъдим ясады:

– Мөслах ага, киләсе якшәмбедә җыелыш җыярга ниятләп торабыз. Шунда менә җир турында, бакчачылык турында берәр лекция укып ташламассыз микән?

– Лекция укырга мин галим түгел, – диде Мөслах карт. – Тел белән сөйләүгә караганда, кул белән күрсәтү җиңелрәк миңа.

– Шулай да, булдыра алган кадәренчә, бакчачылыкның нидән башланганын сөйләсәгез әйбәт булыр иде. Без анысы ниеннән тормас идек, түләр идек.

Акча турында сүз чыккач, Мөслах картның кәефе кырылды.

– Яхшылыкны акчага эшләмиләр, юкса ул яхшылык булудан туктый, – диде ул, төксе итеп. Аңа инде моңарчы да киңәше яки утыртышкан агачы өчен акча биреп караганнар иде. Андый кешеләргә ул чын йөрәгеннән рәнҗеп яңадан аяк атламады. Берсе яшерен рәвештә моның кесәсенә акча салып җибәргәч, тәмам дошманлашты.

...Тагын салкыннар якынлашты. Кошлар өере-өе-ре белән җылы якка китә башладылар. Мөслах карт бак-чада эшләп арыганнан соң бераз билен язарга дип көрәгенә таянып тора иде, шулвакыт, биектә торна тавыш-лары ишетеп, кулын маңгаена куйды. Гаҗәп, ничә ел инде аның торналар күргәне юк иде. Бар икән әле торналар, бар икән. Әнә ничек матур итеп, тезелешеп очалар. Матурлыкны күрер өчен маңгай күзе генә җитми шул, күңел күзе дә кирәк. Ә күңел күзе белән күккә карарга аның вакыты булмады. Дөнья үзенең мең төрле мәшәкате белән бөтереп алып һаман җиргә бөгәргә тырышты. И гомеркәйләр!.. Шушы тезелеп очкан торналар кебек, тезелешеп көннәр очкан. Кайберләреннән шатлык булып ак каурыйлар төшеп калган. Көннәр-торналар төбәп очкан җирләренә һәммәсе дә барып җитә алганмы соң? Мөгаен, күбесе юлда салкын җилләргә очрап һәлак булгандыр. Әйе, кош кына түгел, адәм баласы да кайчагында юлда егылып кала.

Картая барган саен, Мөслах карт кышны авыррак кичерә башлады. Кыш үзенең салкыннары белән генә түгел, ә кулдан бөтен эшне берьюлы тартып алуы белән дә рәхимсез иде. Кыш аңа әрәмгә үткән вакыт булып тоела. Эшсезлектәнме, карт тәненең тузуыннанмы, ул еш кына авыргалый башлады.

– Әллә, эткәй, больницада бераз дәваланып чыгасыңмы? – ди Хафиз. – Әнә бит врачлар, килгән саен, тыныч кына дәваланырга кирәк, диләр.

– Врачлар ни әйтмәс! Алар әйткән саен больниска йөгерә башласаң.

– Алар синең белән миннән күбрәк белә.

– Әгәр миннән бик туйсагыз, турысын әйтегез, авылыма кайтып китәм. Әмма больниска керергә кыстамагыз.

Хафиз больница хакында яңадан авыз ачмады. Бары тик Рәзил генә вакыт-вакыт үсмерләргә хас шаяру белән:

– Бабай, кыш көне тракторларны да капитальный ремонтка куялар, – ди иде.

Мөслах карт инде үзен бернинди дә «капитальный ремонт» коткара алмаячагын сизә. Шуңа күрә ремонтка керергә ашыкмый. Коткарса, аны яз гына коткарыр кебек. Тик язга ерак әле. Кыш башланды гына.

– Бакча шулай бетерештерде сине, – ди Хафиз, әтисенең сулып киткән йөзенә карап. – Ул каһәр суккан җирне аласыбыз калмаган.

– Җирне каргама, улым. Җирнең гаебе юк. Кешене эш бетерми.

– Соң, әти, ул җирдән гомергә безнең файда күрәчәгебез юк. Нәрсәгә тотынганбыздыр.

Хафиз әтисенә шулай дисә дә, үзенең хаклы түгеллеген аңлый иде. Зур дөнья белән чагыштырганда кулъяулык кадәрле җир, әллә ни булмаса да, алар тормышына ниндидер җанлану кертеп җибәрде, өй эчендәге кешеләрне бергә туплагандай итте. Бәлки, бу хәл җирдән түгел, ә бер генә минутка да тынып торуны белмәгән Мөслах карт килүдәндер. Ничек кенә булмасын, элекке пошмаучанлык юкка чыкты. Хафиз да, Дамира да кайдадыр шәһәр читендә бакча үстерүне мещанлыкка, һич югы, комсызлыкка саныйлар иде. Ныклабрак уйлап карасаң, ул кешене эшчәнлеккә өйрәтә икән. Гомерендә кулларына балта-пычкы тотмаган кешеләргә балта тоттырып өй салдыра,

ипине агач башында үсә дип уйлап йөрүче шәһәр балаларына җир исе иснәтә, чәчәкләрне кеше бакчаларыннан йолкырга яратучыларга чәчәк кадерен төшендерә, кып-кызыл җиләкләрне үз кулларың белән өзеп алу бәхетен татыта, ташландык урыннарны яшеллеккә күмдереп, киләчәк буыннарга җирне бизәтеп калдырта, шәһәр тузаны иснәп үпкәләре ысланган кешеләрнең күкрәкләренә ислемайдай тәмле һава өрә, туктаусыз чапкан машина тавышыннан колаклары тонучыларга бераз вакытка булса да тынлык бүләк итә.

Әйе, барысы да әйбәт иде, тик менә эткәләренең авырып китүе генә күңелгә төер ясады.

Менә, ниһаять, көтелгән яз җитте. Агач бөреләрен кояш кылычлары берничә көн эчендә урталай ярып чыктылар.

Балаларының «өйдән чыкмаска» дигән катгый сүзенә карамастан, Мөслах карт артык түзеп тора алмады, эш киемнәрен киеп, бакчага китте. Озак килде ул урман сукмагыннан, үз җирләренә килеп җиткәндә, йөрәге атылып чыгардай итеп тибә, буыннары дер-дер калтырый, ә аркасыннан шыбыр тир ага иде.

Ул, ял итәргә дип, үзе утырткан алмагач төбенә чүгәләде. Урмандагы агачларның яфраклары өч тиенлек акча зурлыгында булса, болар әле бөредә генә иде. «Быел чирләячәкләр әле алар, – дип уйлады карт. – Ә бәлки, үлүләредер. Юк, юк! Үлмәсләр, үсәргә тиешләр. Җир кеше хезмәтен һичбер вакыт буш калдырмый».

Әнә шулай уйланып утырганда, кинәт гаҗәеп хәл булды: алмагачлар берәм-берәм чәчәк ата башладылар. Алардан соң чияләр ап-ак чәчәккә күмелде. Әле бер кешенең, әле икенче кешенең бакчасында яңадан-яңа агачлар үсеп чыкты. Алар йортларны, кешеләрне бер-берләреннән аер-ган сукмакларны каплап киттеләр. Әкияттәге тылсым белән эшләнгәндәй, бу ташландык җир тоташ бакчага әверелде. Ботакларда кошлар сайрады, җилләргә кушылып яфраклар шаулады.

Мөслах карт изүләрен чишеп җибәрде, башын артка ташлап күккә карады. Күктә зур ак йомгактай кояш нур җепләрен Мөслах картка таба сузган, ә карт шуларны ашыга-ашыга бармагына урый. Менә җепнең очы да күренә башлады. Аның бер башы Мөслах карт бармагында, икенче башы ул утырткан алмагач ботагында эленеп калды.

## АВЫЛГА ТЕАТР КИЛГӘЧ

– Әнием бәгырем, көнең ничек узды, бик ялыкмадыңмы? – дип, кояштай балкып кайтып керде Таңсылу. Һәм сумкасыннан төрле-төрле күчтәнәчләр чыгарып өстәлгә тезә башлады. – Менә монысы чикләвекле шоколад конфет, син аны бик яратасың бит. Рәхәтләнеп чәй эчәрсең. Бу пакетта солы печеньесы, авыл кибетләренә ул сирәк кайта, бусында югары сортлы он. Чәкчәк пешерергә җыена идең бугай. Чәкчәгеңне пешергәч, әбиләр җыярсың. Ә менә болары йөзем, өрек ише тәм-томнар. Тамагыңнан өзмә, капкалап йөр.

Таңсылу – Фатыйма карчыкның килене. Авыл Советында секретарь булып эшли. Ягымлы, тәмле телле хатын. Каенанасына һәрвакыт «әнием» дип өзелеп тора. Кибеткә кыйммәтле конфетлар кайтканын яки колхоз идарәсендә бал биргәннәрен ишетсә, акчасын кызганмый, күпләп алып кайта. Бигрәк тә нәни кызын калдырып берәр җиргә барасы булса юмартлана ул. Килененең шушы гадәтен яхшы белгән каенана чикләвекле конфетларга әллә ни исе китмәде.

– Кич белән берәр яры барасың бармыни, килен? – дип кенә сорап куйды.

– Ни, әнкәй, – диде Таңсылу, кызара төшеп, – чакырылган җир юк югын. Тик ни икән, бүген Казаннан артистлар килгән икән. Рафаэль белән театрга барсак дигән идек. – Таңсылу, каенанасының йөзендә салкынлык билгесе күреп, сүзен болай дип очлады: – Әгәр син каршы төшсәң бармыйбыз. Күрмәгән артистларыбыз түгел.

– Нишләп әле мин каршы төшим ди?! Каян алдың бу сүзне? Авылга Казан артистлары көн саен килеп тормый. Барыгыз, Гөлчәчәк өчен кайгырма, карармын. Беренче көн каравым түгел.

Каенанасыннан рөхсәт алгач, Таңсылу, өстеннән тау төшкәндәй, җиңеләеп өй эшләрен караштырырга тотынды. Тиз генә идәннәрне юып чыгарды, ашарга пешерде. Ул арада ире Рафаэль эштән кайтып җитте. Таңсылу алып кайткан тәм-томнар белән бергә чүкердәшеп чәй эч-теләр. Алмаш-тилмәш Гөлчәчәкне кулларына алып сикерт-кәләделәр. Һәм, карт кешенең акылы керделе дә чыктылы, кире уйлап куймагае, дип, спектакль башланырга әле иртә булса да, тизрәк өйдән чыгып таю ягын чамаладылар.

Дөресен әйтергә кирәк, Фатыйма карчык Гөлчәчәкне сыкрап-сыктап кына алып калды. Юк, оныгын яратмаганлыктан түгел, Гөлчәчәк дип үлеп тора Фатыйма карчык, әмма театрны да оныгыннан ким яратмый шул. Ничек соң әле ул Казан артистларының килгәнен ишетми калган? Ишетсә, килене авыз ачып өлгергәнче, Гөлчәчәкне аның кулына тоттырып, берәр карчыкка кич утырырга барам дигән хәйлә белән театрга сыптырган булыр иде. Их, шундый тамашадан колак как инде! Бүтән вакытта алдан ук радиодан хәбәр итә торганнар иде, әллә соң ишетми калды микән?

Фатыйма карчык, театрга бара алмый калуына бик уфтанып, килене алып кайткан күчтәнәчләр белән өр-яңадан чәй эчәргә керештe. Тик, гаҗәп хәл, тамагыннан ризык үтмәде: көчләп кенә биш-алты чынаяк чәй эчте. Башкалар ирешкән рәхәтлеккә үзеңнең ирешә алмавы кимсетә шул җанны, кимсетә. Андый чакта тамагыңнан ничек аш үтсен! Ичмасам, Гөлчәчәге дә еламый, шуны юаткан булып, хәсрәтеңне онытып торыр идең.

Әнә шулай газаплы уйларга батып өстәлне җыештырып торганда, Фатыймаларга Сәрбиҗиһан карчык килеп керде.

– И Сәрбиҗиһан абыстай, – диде Фатыйма карчык, аны күргәч, – гомерең озын булыр әле. Сине генә уйлап утырадыруем. Кемне генә җибәртеп, чәй эчәргә чакыртырга икән, мин әйтәм. Килен мәгәзиннән тәмле-тәмле җимешләр алып кайткан. Әйдә, Сәрбиҗиһан абыстай, менә монда мендәргәрәк утыр.

– Рәхмәт, Фатыйма килен. Кая, бер дога кылып алыйк, булмаса. Йортларга бәрәкәт, илләргә иминлек бирсен Ходаем. Ярабби, амин.

Дога кылганнан соң, Сәрбиҗиһан абыстай урындыгын өстәл янынарак шудырып китерде. Тагын чәй эчү башланды. Авызына тәмле конфетлар кергәч, Сәрбиҗиһан абыстайның теле ачылды: кемнең кызы кем белән йөри, кемнәрнең малайлары башка чыккан – һәммәсен бәйнә-бәйнә сөйләргә керештe. Фатыйма карчык бүтән вакытларда мондый гайбәтләрне куертырга яратса да, бүген Сәрбиҗиһан абыстайның сөйләгәненә эче пошып утырды. Аның сүзгә кушылмавын Сәрбиҗиһан абыстай да сизеп алды:

– Кәефең начаррак күренә, Фатыйма килен, чирләмисеңдер бит?

– Нигәдер башым түнебрәк тора, – диде Фатыйма карчык, үзенчә бер хәйлә уйлап. – Духтырның өенә барып кайтсам, берәр дару бирерие инде. Баланы калдырып торыр кеше юк.

– И-и, юкка аптырагансың икән. Үзем карармын. Бар духтырыңа, бар. Шунда миңа да берәр дару сорарсың. Билләр сызлаштыра, елан агуы юк микән. Бик файдасы тия торганые шуның.

– Сорармын, абыстай. Авыр нәрсә түгел. Берне түгел, икене алып кайтырмын.

Фатыйма карчык, кәефе күтәрелгәнне Сәрбиҗиһан абыстайга сиздермәскә тырышып, җәһәт кенә өстен-башын алыштырды.

– Нигә шулхәтле атлас күлмәкләреңне киясең?

– И Сәрбиҗиһан абыстай, урам буйлап барасы бар бит. Кем очрамас!

– Анысы шулай, Фатыйма килен. Ярлы заман түгел, урамга чыкканда начар кием киясе килми. Үземнең күлмәкләрем дә тагын бер гомергә җитәрлек.

Фатыйма карчык чыгып киткәч, Сәрбиҗиһан абыстай өстәлдәге ризыкларның төрлесеннән янә бер авыз итеп чыкты. Ошамаганрак конфетларны кәгазенә кире төргәләп куйды. Аннары өстәлдән савыт-сабаларны җы-ештырды. Гөлчәчәкнең асты юешләнгән икән – аны алыштырды. «Нигәдер озаклады әле бу Фатыйма, – дип уйлады ул, эшләр эше калмагач. – Баш даруы кесәмдә дә барые, шуны гына бирәсем калган икән».

Көтеп-көтеп тә Фатыйма кайтмагач, бер эшем кими торыр дип, тәһарәт алып, намаз укырга ниятләде. Әмма намазга утыруы булды, колхоз радиоузелы сөйли башлап, намазын бүлдерде. «Тыңлагыз, тыңлагыз, колхоз радиоузелы сөйли, – диде ягымлы хатын-кыз тавышы. – Иптәш колхозчылар, бүген безнең авылыбызга Казан артистлары килде. Алар безгә «Давыллы мәхәббәт» дигән спектакль күрсәтәчәкләр. Спектакль кичке сигездә башлана. Ашыгыгыз, иптәшләр!»

Белдерүне ишеткәч, Сәрбиҗиһан абыстай җәйгән намазлыгын кире җыеп алды. «Каһәр төшкере Фатыймасын әйтер идем. Духтырга барам дигән булып, тиятергә сызгандыр әле. Исән кеше духтырда шушы гомер ятамы... Их, тиятере мәхәббәт турында, ди бит. Үләт кыргыры, күрә алмый калам инде. Кеше баласын саклап. Үземнекеләрдән качып монда кергән идем. Ах, бу елан Фатыйманы, ничек суфи булып кылана. Әйтәм аны атлас күлмәкләр киеп маташа. Ә мин, ачык авыз, шул еланга ышанып утырам».

Нык рәнҗеде Сәрбиҗиһан абыстай. Ник кергәненә үкенде. Үкенеп тә берни кыра алмыйсың шул. Бармак башы хәтле баланы ялгыз калдырып җавапка тартылыр хәле юк. Әнә бәхетле кешеләр, тырт-тырт басып, тиятергә баралар. Чигүле читекләр кигәннәр, ефәк чуклы шәлләр ябынганнар. Туксан тугыз яшьлек Мәрфуга да түшен киереп малае машинасында китте.

Сәрбиҗиһан көрсенеп урамны күзәтте. Инде театрга баручылар да кими башлады. Урамда туп тибүче малайлар гына калды. Шунда Сәрбиҗиһан карчыкның башына бер фикер килде, тәрәзәне ачып, малайларга кычкырды: «Малайлар, тиз генә берәрегез монда керегез әле. Конфет бирәм».

Малайлар конфетка алданырга теләмәделәрме, туп уйнаудан тукталасылары килмәдеме, кул гына селектеләр. Бары тик ни сәбәпледер уенга катнашмаган кечкенә малай гына өйгә керде.

– Бир конфетыңны, абыстаттәй.

Сәрбиҗиһан, малайның аркасыннан сөеп, кулына бер уч конфет салды.

– Кем малае әле син?

– Әмин абзыкайныкы.

– И-и, Әмин малае Дәмин икәнсең. Кара син аны, танымый торам, бигрәк зур үскәнсең. Ничә яшь әле сиңа?

– Әнә теге өстәлдәге конфетлар чаклы.

Малай ымлап конфет савытына күрсәтте. Сәрбиҗиһан аның ымын тиз аңлады. Савыттан тагын бер уч конфет алып бирде. Әйдә ашасын, үзенеке түгел – Фатыйманыкы.

Малай әйбәт кенә сыйлангач чыгып таймакчы иде, Сәрбиҗиһан абыстай аның җиңеннән эләктерде: «Дәмин улым, Фатыйма әбиең кайтканчы гына Гөлчәчәкне карап тора алмассың микән? Ул хәзер кайтыр, духтырга гына киткәние».

– Ю-ук, абыстаттәй. Мин бала карый белмим. Әнкәй дә «апаеңны акыртма» дип өйдән куып чыгарды.

– И улым, берүк тыңла инде сүземне. Клубта тиятер була, ди. Шунда барырмын дигәнием. Билетым әрәм була. Менә үзеңә өч тәңкә акча бирәм, гуртка баргач, маружный алып ашарсың.

– Бала карыйсы килми бит, абыстаттәй.

– Әгәренки сүземне тыңласаң, тагын бер әйбер алып бирермен.

– Нәрсә?

– Бүтән малайларның төшенә дә кермәгән берәр нәр-сә.

Малай мондый вәгъдәләрдән соң икеләнә башлады. Сәрбиҗиһан, аның икеләнүен күреп, тагын да юмартлана төште. Ниһаять, малай күнде. Шуны гына көткән Сәрбиҗиһан, яшь киленнәр җитезлегендә, клубка чапты.

Спектакль гаҗәп җанлы үтте. Һәр кызык сүз саен гөрләтеп кул чаптылар. Спектакль тәмамланганнан соң, залдагы утлар кабынуга, Фатыйма карчык урыныннан сикереп торды. Киленнәре кургәләгәнче тизрәк өйгә кай-тырга, ә Сәрбиҗиһан абыстайга, духтыр өйдә булмады, шуны көтеп торырга туры килде, дияргә иде исәбе. Ләкин Фатыйма карчык кешеләрне ерып-ерып ике атларга өлгермәде, ашыга-ашыга ишеккә юнәлүче Сәрбиҗиһан абыстайга килеп төртелде. Ә Сәрбиҗиһан абыстайның күзләре Гөлчәчәкне төреп күтәргән Әмин малае Дәминдә иде.

## ЫШАНСАГЫЗ ЫШАНЫГЫЗ...

Бик тыныч каршыларга булдым мин быелгы Яңа елны. Хатынны өч көнлек путёвка белән Мәскәүгә җибәрдем. Әйдә рәхәтләнсен Мәскәү карап. Сыйлансын башкала сыйлары белән. Ә мин, өйдә берүзем калганда, чикмәнле бәрәңге белән тозлы балык койрыгына да риза. Ичмасам, җаның тыныч: ятасың килсә ятасың, саласың килсә саласың. Унике тулганны көт дип, мөлдерәп түгелергә торган рюмкаңны кулыңнан тартып алучы юк. Шушы тынычлык хакына җан дустыма да ялганларга туры килде. «Яңа елны бергә-бергә бездә каршылыйк, дигән иде, юк, мин әйтәм, хатын белән авылга китәбез. Аның сүзе – сүз!»

Суыткычта шәрабларның төрледән төрлеләре. Ул яктан эшләр көйле. Кирәккән саен салкынга чыгып йөгерәсе юк. Хатын тәм-томнарны да шактый әзерләп киткән икән. Үземнән башка артык ямансуламасын дигәндер инде. Хәтта дерелдеккә кадәр бар. Рәхәтләнә җаның теләгәнен ашап, кырын ятып бәйрәм ит.

Шатлыктан кулларымны угалап, кухняда йөрим. Хатын пешереп киткән тәм-томнарны капкалап китәм. Сирәк-мирәк сәгатькә карап алам. Әкренләп өстәл әзерли башласаң да ярыйдыр. Шөкер, көтәсе кешем юк. Өлешемә тиешлесен салып, ятып йокласам да гөнаһ булмас.

Их, каһәр генә төшсен, кемдер килде: ишектә милиция сыбызгысыннан да әшәке булып звонок шалтырады. Өйдә җан иясе барлыкны белдермичә, тып-тын торам. Сулаганда бер як борын тишегем сызгыра иде, аны бармагым белән кысып тоттым. Ә звонок шалтырапмы-шалтырый. Болай гына ачмагач, ишеккә тибә үк башладылар. Берәр кыбырсык җан кич җиткәнне дә көтмичә лыкын булгандыр, мөгаен, арт сабагын укытып, ләхәүләсен исенә төшереп җибәрим әле.

Шартлатып ишекне ачып җибәрүем булды, яшь баласын күтәргән күрше хатыны кочагыма килеп тә ауды. Иреннәребез иренгә тиеп китте. Күңелне вәсвәсәләндереп, маңгай чәчләрен юри минем бит тирәсендә уйнаткалый, каһәре. Әллә нинди хушбуй исләре килә үзеннән. «Шәп, шәп, – дип уйлап куйдым мин эчемнән, – күрше хатыны үз хатының түгел инде. Аның белән чүтеки күңеллерәк. Баш әйләндерерлек чибәр тагын».

– Әллә Рөстәмең кунакка киттеме? – дип сорадым, нәрсәгәдер өметләнеп.

– Әйе шул, – диде чибәр ханым. Ул, тагын нидер әйтергә теләп, авызын ача башлауга:

– Бер дә кайгырмагыз, бергә-бергә бәйрәм итәрбез, – дидем. – Минем хатын да Мәскәүдә сиптерә.

– Ни бит әле, – диде ул, күзләрен мутландырып. Бу минутта аның теләсә нинди әмерен үтәргә әзер идем. – Ни бит, – диде ул янә, – кунакка безне Рөстәм белән бергәләп чакырганнар иде. Синең балаң белән анда мин нишләп утырыйм, ди. Әгәр сез карап торсагыз...

Ханым, минем ачылган авызыма баласының имезлеген каптырып, кулыма җанлы төргәген суза ук башлады. Үзе, «ыгы-ыгы»дан башканы белмәгән баласы белән сөйләшкән булып, минем салпы якка салам кыстырып маташа:

– Без аббаны би-ик яратабыз. Аб-ба тәти. Аб-ба белән без бәү-бәү итәрбез. Без инде зур үстек, еламыйбыз. Әйеме? Яле, яле, Гөлнара кызым, аббага бер көлеп күрсәтик.

Гөлнара, тешсез авызын ачып, нindидер ысылдауга охшаш аваз чыгарды.

– Менә шулай, кызым, менә шулай... Ә хәзер аббаны кочаклап бер пәп итик тә, мин киттем.

Ханым баласының юеш борынын минем битемә тидереп алды. Чыраема канәгатьсезлек билгеләре чыкты, ахры, күңелемне йомшарту өчен ханым үзенең хушбуй исе аңкытып торган кулъяулыгы белән битемдәге юешлекне сөртте.

– Зинһар, борчылмагыз, – диде ул, чыгып киткәндә. – Елый торган бала түгел. Төне буе изрәп йоклар. Хәзер коляскасын кертәм, шунда салып йоклатырсыз. Пес-пес итсә, аптырамагыз, алмаш ыштаннары баш очында булыр.

Идән уртасында бала арбасын калдырып, ханым кунакка китеп барды. «Без озак тормыйбыз», – диде ул, мине юатып. Беләм мин кунакка киткән кешенең күпме торганын. Ничу юатырга.

Әнисенең аяк тавышы басылып җитмәстән, «елый белми торган» бала, авызын шакмакландырып, разбой салырга тотынды. Имезлеген авызына каптырып карыйм, дөя кебек төкерә генә. «Ә-ә» итик дип, арбасын селкеткәләп алам, юрганын ук тибеп очыра. Бер кулым белән бишеген тирбәтәм, икенче кулым белән идәнгә төшкән юеш имезлеген, чалбар төбенә сөртеп, авызына каптырам, тешләрем белән өстеннән шуышкан юрганын тартам, аякларым белән тук-тук иткән тавышлар чыгарам. Әмма «елый белми торган» бала туктый белми акыра. Нишләргә, кемнән ярдәм көтәргә? Әһә, кемдер ишек шакый. Ходайның биргәненә шөкер, кем булса да, бала карарга ярар әле. Мондый чакта кан дошманың керсә дә сөенәсең. Әнә шундый өметләр белән ишекне ачып җибәрәм. Ә анда – хәтта әйтергә куркыныч – бала күтәргән икенче күршебез басып тора.

– Рөстәмнәрнең Гөлнараларын алып калгансыз икән. Менә безнең Алмазикны да алып калыгыз инде. Алар икесе бик дуслар. Икесе бергә чакта елауның ни икәнен белмиләр. Шулай бит, Алмазик? Без дәү абыйны да, Гөлнараны да би-ик яратабыз. Еламыйбыз...

Шулай гөрләп бу күршем дә Алмазигын кулыма тоттырып чыгып тайды. «Былчыракка тездән баттың ни дә, билдән баттың ни» дип, каршы килеп маташмадым, алып калдым. Алмазик белән Гөлнараның арбаларын янәшә куеп, үзем диванга аудым. Гөлнараның акыруы ул әле пүчтәк кенә булган икән, менә ичмасам Алмазикның тавыш дисәң дә ярый. Ун Шаляпиныңа торырлык. Ул акырганда, хәтта люстралар зыңгылдый. Ике куллап колакларымны каплыйм, тик кая ул – тавыш, бармакларымны аралап, колак элпәләрен ярып мигә керә. Башым буш театр залында эт өргәндәй яңгырый. Боларга тыныч кына карап утыру мөмкин түгел. Ике аягым белән икесенең арбасын дыңгылдатырга тотынам, кулларым туктаусыз боларның авызларына буш имезлек каптырып тора. Хәрәкәтләрем цирктагы жонглёрларныкыннан җитезрәк, әмма барыбер авызларын томалап өлгереп булмый. Кырыйда гына хатынның тәрәзә пәрдәләре шудыра торган озын колгасы тора икән, секундның йөздән бер өлешендә, кулым буш арада шул таякны эләктереп, телевизорны кабызам. Анда Аркадий Райкин, нindидер мәзәк сөйләп, залда утыручыларның эчләрен катыра. Ә минем үлеп елыйсым килә. Үземне кызганудан күзләрдән яшь чыга, бугазда кайнар төер урала.

Әй, төкерим лә дөньясына! Ник шунда акырудан шартламыйлар. Кухняга кереп берәр стакан төшереп чыгыйм әле. Алмазик белән Гөлнараның арбаларын телевизорга таба борып, телевизорны бар көченә ачып куйдым. Китап шкафы өстендә транзисторым тора иде, аны да җырлатып җибәрдем. Хәзер инде өйдә, дирижёрсыз калган җырчылар хорыдай, нindидер буталчык, аңлаешсыз авазлар гына ишетелә иде.

Кухняда озак юанмадым, ни әйтсәң дә үз өстеңә йөкләп алып калгач, балалар өчен мин җаваплы. Ярый әле сөт бар икән, бер литр сөт җылытып, ике шешәгә тутырдым да, шешә башына имезлекләр кидертеп, җанкисәкләрнең авызларына каптырдым. Җылы сөт тегеләрнең кирелеген сындырды бит, чулт-чулт суыра башладылар. Бәлки, йок-лап китәрләр дип, телевизорым белән транзисторымны да сүндердем. Тавыш басылгач, күңелем күтәрелеп китте. Кухня ягында бераз кабып чыгу ярдәм иткәндер, бәлки. Ә күңел күтәрелгәндә минем җырлый торган гадәтем бар. Тотындым җырларга:

Сибелә чәчем, сибелә чәчем,
Сибелә чәчем давылда;

Үзәкләремне өзәрлек
Ярым калды авылда!
Сибелә чәчем, сибелә чәчем,
Сибелә чәчем – сыпырам;
Җиде төн урталарында
Сине уйлап утырам.

«Сибелә чәчем»гә башланган җырларны җырлап бетергәч, «Кулымдагы йөзегемнең» дип башланганнарына күчтем. Гөлнара белән Алмазик мин «Сибелә чәчем»не җырлаганда, сөт шешәләрен бер якка куеп, тыныч кына тыңлаганнар иде. «Кулымдагы йөзегемә» күчкәч, синең репертуарың озын икән әле диделәрме, үзләре башладылар. Мин тагын кухняга кереп киттем, аларның тавышы кухняга да бик матур ишетелә иде. Шул дуэтны тыңлый-тыңлый, үземне әйбәт кенә итеп сыйладым. Хәзер инде Алмазикларның да тавышлары ничектер ягымлырак ишетелә иде. Әйбәт кәеф белән алар янына чыктым да:

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр кәпәчләр;
Үзең монда, ярың кайда,
Дип кычкыра этәчләр, –

дип җырлый-җырлый, диванга сузылып яттым.

Әнә килә автомобиль,
Утырырмын, китәрмен...
Әнә килә... утырырмын, китәрмен...

Һәм мин йокыга киткәнмен. Күпме йоклаганмындыр, анысын Алла белә. Бервакыт өйдә дөбер-шатыр килгән тавышлар ишетеп уянып киттем. Күзләремне ачып карарга куркып ятам. Өйгә хулиганнар кереп тулган икән, мәйтәм. Шулай да бик саклык белән, кәгазь сыярлык кына итеп, күзләремне ачам. Йә Хода, ни күрәм: өнемме бу, төшемме? Алмазик белән Гөлнара, өйнең астын өскә китереп, биеп яталар. Шкаф өстендәге минем транзистор адәм аңламаслык телдә тамак төбе белән көйсез-нисез акыра. Ә теге бәләкәчләр колготкиларын муеннарына кадәр күтәреп куйганнар да транзистордан акырган көйгә сикерепме-сикерәләр. Арбалары әллә кайда почмакта тора. Буш имезлекләрен арбаларының ыргагына элгәннәр. Яртылаш бушаган сөт шешәләре идәндә аунап ята. Тагын ниләр булыр икән дип, уянганымны сиздермәскә тырышып, тигез генә мышныйм. Менә бервакыт транзистордагы җырлаучы тамагы бетеп туктады. Бәләкәчләрем, кара-каршы креслога утырып, әңгәмә корып җибәрделәр. Алмазик итләч бармагы белән миңа таба ишарәләде:

– Бу картлач шыр исәр икән. Безне Райкин белән алдамакчы.

– И-и, – дип элеп алды Алмазикның сүзен Гөлнара,– картларның кайсының акылы бар соң? Беркөн минем мам алып кайткан миңа Чистайда тегелгән распошонка. Әй кидерергә маташа, әй азаплана. Маңгаеннан тирләр агып-агып төшә. Ә мин кимим, үрле-кырлы сикерәм. Тәки кимәдем. Польскины алып кайткач кына кидем.

– Рәзе бу синең польски? – дип, Гөлнараның распошонкасын тотып карады Алмазик.

– Әлбәттә, – диде Гөлнара, бераз һаваланып. – Күр-мисеңмени, язуын да түшеннән алып ташламаган.

Аннары сүз мәхәббәткә күчте.

– Мәхәббәтне син ничек аңлыйсың? – диде Гөлнара.

– Мәхәббәт ирекле булырга тиеш! – диде Алмазик, күкрәк кагып. – Телим икән, мин сезгә керәм, теләмим икән кермим.

– Фи, кермәсәң, бик исем киткән иде. Беркөн әни мине урамга алып чыккач, күрше подъезддагы Айратик янында калдырып торды. Менә ичмасам джентльмен. Минем кәефем китүне күрү белән, ике дә уйлап тормастан, авызындагы сагызын миңа каптырып куйды.

Алмазикның күрше подъезддагы Айратиктан көнләш-кәнлеге күренеп тора иде. Ул шактый вакыт турсаеп утырды. Бары тик Гөлнара аңарга иркәләп караганнан, Алмазикның якасындагы сөт табын бармагы белән кырып алганнан соң гына турсаюы бетте.

– Мин сине беренче күрүдә үк яраттым, – диде Алмазик, Гөлнараның игътибарына җавап итеп. – Синең начармы-яхшымы үз капризларың бар. Ә егетләргә, между прочим, капризлы кызлар ошый. Бу безнең профессиональ секрет, әлбәттә. Безгә моннан соң ешрак очрашырга кирәк.

– Ничек итеп?

– Син капризлана беләсең. Урамга арба белән алып чыкканчы акыр. Тавышың да матур чыга.

– Синекенә җитми инде, – диде Гөлнара, тыйнакланып.

Алар шулай бер-берләренең матур сыйфатларын санаша башладылар. Комплиментлар әйтешүне күпме дәвам итәрләр иде, әйтүе кыен, шулвакыт сүндерелми куелган транзистордан тагын колакка ят музыка яңгырады. Алмазик, Гөлнара алдында джентльменнарча баш иеп, аны биергә чакырды.

Сикерә-сикерә биеп киттеләр. Мин чытырдатып күз-ләремне йомдым, колакларыма мендәр капладым. Шулай җәфаланып ята торгач йоклаганмын. Ә иртән уянганда инде Гөлнара белән Алмазикның арбалары идән уртасында тора, үзләре, сөт шешәләрен кочаклап, урман кисеп кайткан кешеләрдәй озын-озын сулап йоклыйлар иде.

Менә, дуслар, Яңа елны каршылаганда нинди хәлләр дә була икән. Әгәр миңа ышанмасагыз, хатыныгызны берәр җиргә җибәреп, күрше балаларын алып калыгыз. Шунда минем сүзләремнең дөресме, ялганмы икәнен белерсез.

## ХӘЙЛӘ

– Әнкәсе, ә, әнкәсе, – диде Заһидуллин, йокыга кит-кән хатынының кабыргасына төртеп.

– Нәрсә бар? – диде хатыны, күзләрен ачмый гына.

– Безнең Ирек авылда берәр кыз-кыркын белән чуалмый микән, ишетелгәне юкмы?

– Таптың йокыдан уятып сорар нәрсә! – Хатын, юрганын башына кадәр тартып борылып ятты, ләкин аның йокысы ачылган иде инде. – Теге югароч Мөгелсем кызы Зөмәрә белән күргәләгәннәр бугай. Ә нигә кирәк булды әле сиңа аның кем белән йөрүе?

Заһидуллин һәммәсен хатынга сөйләп торуны кирәк дип тапмады, ә нияте аның бик изге – Иректне авылда калдыру иде. Юкса, председатель башың белән малайларыңны шәһәргә таратып ятасың дип, авызыңны ач-тырмаслар. Болай да инде ике малаен кулдан ычкындырды. Ирек – төпчекләре. Бусын, бәйләп булса да, авылда тотып калырга иде. Ә егет кеше – өйрәтелмәгән тай. Тайның йөгәне – кызлар. Заһидуллин андый нәрсәләрне яхшы белә. Инде менә озакка сузмый гына Зөмәрәсенең кылларын тарткалап карарга кирәк.

Зөмәрәнең чырт-чырт басып урамнан үтеп баруын күрүгә, Заһидуллин, идарәнең тәрәзәсен ачып, кызга кычкырды:

– Матурым, бер генә минутка кереп чык әле!

Зөмәрә, горур башын артка ташлап, Заһидуллин каршына килеп басты:

– Нәрсә, абый?

Заһидуллин кыеклап-мыеклап маташмады:

– Син, сеңлем, быел унны бетердең бугай. Исәбең ничегрәк: берәр җиргә укырга китәргәме, әллә колхозда калыргамы? – диде ул.

Зөмәрә әле үзенең киләчәген үзе дә хәл итмәгән иде, ахры, ык-мык килде. Ә Заһидуллинга шул гына кирәк иде дә.

– Синең кебек кызлар колхозда калсамы... – диде ул, сокلануын яшермичә. – Әйе, эшләр гөрләячәк. Фермада бик әйбәт урын бар. Иң сөтле, иң юаш сыерларны сайлап бирербез үзеңә. Рәхәтләнеп, сау.

– Миңа, бәлки, сыерларның усалраклары кирәктер, – диде Зөмәрә, шаянланып.

– Усалларын да табарбыз. Мөгезлесе кирәкме, мүк-ләгеме, аклысы кирәкме, каралысымы – җаның теләгәнен сайларсың. Ни кирәксә, шуны сорарсың. Кал, сеңлем, колхозда, үкенмәссең.

Үгетли, алтын таулары вәгъдә итә торгач, Зөмәрә берәр ел фермада эшләп карарга булды. Эшли башлавына күпме вакыт үткәндер, Зөмәрә идарәгә килеп керде. Тулган айдай йөзен кара болытлар баскан, кашлары җыерылган, иреннәре турсайган.

– Эшләмим, китәм, – диде ул, елап җибәрүдән чак-чак тыелып.

– Нәрсә булды?

– Сыерлар әллә нинди тавышлар чыгарып мөгриләр. Шуларның мөгрәүләренә күңелем тула да, кулымнан эш төшә.

– Алар мөгрәмәсен өчен, сеңлем, әйбәтләп карарга, ашатырга-эчертергә кирәк.

– Улакларын буш тотканым юк инде, абый. Тик һаман мөгриләр бит. Ни әйтә, Нәҗия апа әйтә, аларга музыка кирәк, ди. Элек сыерларны саварга утырганда магнитофонны җибәрә идек, шул музыкага сыерлар күпме сөт биргәннәрен белмичә саудыралар да саудыралар иде, ди. Ә хәзер магнитофон ватык...

– Ярар, сеңлем, аңлашылды, – диде Заһидуллин, җиңел сулап. – Иртәгәдән магнитофонның иң шәбен, стереосын кайтартырбыз.

Заһидуллин сүзен җилгә ташлый торган кеше түгел иде, икенче көнне үк беренче класслы магнитофонны терлекчеләргә үз куллары белән китереп тоттырды. Савымчы кызлар эштән туктаган чакларда рәхәтләнеп музыка тыңладылар. Председатель үзенең яхшылыгыннан үзе дә канәгать иде.

Әмма аңарга музыка белән озак ләззәтләнеп йөрергә туры килмәде, күктән очып төшкән фәрештәдәй, Зөмәрә тагын аның каршысына килеп басты.

– Эшләмим, китәм, – диде ул, ирен китү белән куркытырга өйрәнгән яшь килендәй. – Эшләгән кешегә кадер юк. Дүрт чакрымдагы фермага җәяү барабыз, җәяү кайтабыз. Ярый ла Саниятттәйләр, Наҗия апалар гомер буе җәяү йөреп өйрәнгәннәр. Мин бит андыйга күнекмәгән. Мин яшь кеше. Эштән кайткач, минем клубка чыгып танцевать итәсем бар.

Заһидуллин Зөмәрәгә бармак янады. Янәсе, беләбез без синең хәйләңне. Сиңа йомшак караганымны белеп, мөгаен, әнә шул карт төлке Санияләр җибәргән үзеңне.

Ничек итсә итте Зөмәрә, әмма председательнең «Ярар, машина бирермен» дигән вәгъдәсен алды.

Бераз вакытка эшләр көйләнде. Савымчыларны фермага машина алып барды, машина алып кайтты. Зөмәрә Заһидуллинның ни өчен үзенә карата болай юмарт кылануын белми һәм белергә дә теләми иде. Аңа йомышын үтәсәләр, шул җиткән. Ә йомыш дигәнең һәр көн диярлек килеп чыга торды. Егерме ел фермада эшләгән Гөләндәм түтинең өен рәтләтергә бүрәнә юллау дисеңме, Сания апага путёвка табышу дисеңме... Кыскасы, тормышның санап бетергесез мәшәкатьләре яшәгән саен өстәлә барды. Председатель киреләнә башласа, кыз аны «китәм» сүзе белән куркытты. Бу сүздә нindидер тылсым көче барлыгын сизгән иде инде ул. Заһидуллин Зөмәрәдән тәмам туйды. «Әллә идарәдән куып чыгарыйм микән үзен?» – дигән чаклары да булмады түгел. Ләкин төпчек улы Ирекнең соңгы вакытларда колхоз эше дип өтәләнеп йөрүләре, ватык тракторны төзәтеп, шуның белән пыр туздырып җир сөрүләре күз алдына килеп, ата кешенең күңелен йомшарта иде. «Зөмәрә булмаса, күптән очкан идең инде син», – дип, мыек астыннан елмаеп куя иде Заһидуллин.

Көн артыннан көн үтте. Көтүче чыбыркысын шартлаткан саен, яңа таңнар туды. Ирек, чын-чынлап тәртәгә кереп, колхоз йөген тарта башлады. Заһидуллинның җаны тынычланды. Ә инде көннәрдән бер көнне Ирек үзенең өйләнәчәген әйткәч, ата кешенең түбәсе күккә тиде.

– Шәп уйлагансың, улым, молодец, – диде ул, Ирекнең җилкәсеннән кагып. – Кызы кем диген, кызы ут бит!

– Син кемне әйтәсең, эти? – диде Ирек, гаҗәпләнеп.

– Шаярма! – диде Заһидуллин, улына бармак янап. – Кемне әйтәсең, имеш. «Зөмәрә» дип авыз сулары корытканыңны белмиләр дисеңме әллә?

Ирек тәгәри-тәгәри көләргә тотынды. Көлеп туйгач:

– Разведкаң начар эшли икән, эти, – диде. – Сүзең дөрес, Зөмәрә шәп кыз. Әмма мин күрше авыл кызы Дамирага өйләнәм.

– Дамирага? Нindирәк кыз соң ул?

– Сыер савучы.

– Ә Зөмәрә?

– Соң, ул ике ел бит инде бер солдат белән хат алыша. Солдаты авылга кайтмакчы, ди. Керергә өй булса...

Заһидуллин шатлыгыннан улын кочаклап алды:

– Кайтсын, менә дигән йорт салып бирәм үзләренә. – Ул канәгатьләнеп тагын бармак янады: – Ах сез, хәйләкәр төлкеләр, нинди эшләр эшләп яталар. Мин үземне алардан хәйләкәррәк дип йөрим тагын. Уздырырсың яшьләрне.

## ЗӘЛИФӘ ИРЕ

Минем хәзер үз исемем юк. Чын-чын, мине Зәлифәнең ире дип кенә йөртәләр. Баштарак мин үз исемемнең онытылуына хурлана идем, төптәнрәк уйлап карагач, моның белән хурланырга түгел, горурланырга кирәклеген аңладым. Нигә горурланмаска? Минем Зәлифәм Казанда иң мәртәбәле кешеләрнең берсе. Аның янына керү өчен, министрга язылгандай, алдан ук чиратка язылалар. Чиратлары җитсен өчен, кайберәүләр мине юмалый, коньяк ише нәрсәләр алып килеп, саллы якка салам кыстыра. Ни әйтсәң дә, мин хатынның секретаре сыманрак кеше. Ә зур начальниклар янына секретарь рөхсәтеннән башка үтеп кара син! Кайсы ишектән кергәнеңне онытырырлар. Билгеле, сез минем Зәлифәмнең кем булуы белән кызыксынасыздыр. Күпләрегез аны атаклы артист яки даны ерак таралган язучы дип уйлыйдыр. Юк, минем Зәлифәм янына автографлар сорарга килмиләр. Тегүче ул, тегүченең дә нindие әле. Ә бит бар иде аның да энәгә җепне ничек сапларга белмәгән чаклары.

Серне чишкәч чишим инде, Зәлифәмнең бу сәләтен ачуга мин сәбәпче булдым. Ничек дисезме? Сөйлим-сөйлим, барысын рәттән сөйлим...

Иң беренче шуны әйтеп китим, Зәлифәм минем бик кечкенә буйлы. Бер йомарлак май кебек кенә. Кесәгә сал-саң – кесәгә сыя, учка йомарласаң – учта югала. Шуңа күрә мин аны яратып «бәләкәчем» дип йөртәм. Үзегез беләсез, кечкенә гәүдәле хатын-кызга кибетләрдән рәтле-башлы әйбер табармын димә. Буе туры килсә, иңнәре ярамый, иңнәре таман икән, фасоны балаларныкы була. Кибеттән кием-салым алып кайткан саен өебездә күз-яшь. Хатын күзендәге яшь минем йөрәктәге таш инде ул. Йөрәктәге ташка күпме түзәргә мөмкин? Юк, мин әйтәм, Зәлифүш, ярамый болай. Алып кайтам тегү машинасының иң кәттәсен. Үзеңә кирәкле киемне тек үзең.

– Син нәрсә? – ди Зәлифәм. – Көләсеңме? Кием тегү түгел, ямау ямый белмәгәнне.

– Ничава, – дим, – аюны да өйрәтәләр.

– Өйдә кол иткәнең генә җитмәгән, инде өч тиенлек күлмәкне дә үземнән тектерер идеңме?

«Кол» дип арттыра Зәлифәм. Бу сүзләрне ул үзе әйтми, ачуы әйттерә. Өй эшләрен без гел икәүләп башкарабыз: бәләкәчем кер юса, су җылытыр өчен колонкасын мин кабызам. Шырпысын-ниен сызып. Телевизор, суыткыч ише нәрсәләр ватылса, телефоннан мастерны мин чакырам. Балалар тәрбияләүне әйткән дә юк, көндәлекләренә гел үзем кул куям. Менә бит ул дөнья ничек бара. Мин фәлән эш эшләдем дип күкрәк кагып йөрмәгәч, хатын-кыз аны аңламый. Ярар, аңламыйлар икән, алар эше. Шулай да мин тегү машинасының иң кыйбатлысын алып кайтып куйдым. Егерме алты төрле эш башкара торганын. Текмәсә текмәс, ашарга сорамас. Кешеләр укымаганга да китаплар җыя бит, минем кай ягым бүтәннәрдән ким?

Машинаны алып кайтуын кайттым, ләкин соңыннан үкенергә туры килгәләде. Зәлифәм шуны алган көннән урынны аерым җәя башлады. Бераздан аерым ашауга күчтек. Ул үзенә коймак пешерсә, мин йомырка кыздырам. Ә борынга коймак исе керә генә бит, каһәре. Чыдар әмәл юк. Шулай да сер бирмим. Тәмләп ашаган булам. Үзем әле хатын белән килешеп булыр дип юанам. Күңелен йомшартыр өчен, хезмәт хакы алган саен, ефәгеннән, -йоныннан дигәндәй, матур-матур күлмәклекләр бүләк итәм. Рәхмәтен иртәгә әйтергә калдырып, күлмәклекләрне шкафка куя бара бу. Шкаф тартмаларында алып кайткан- тукымаларыма урын калмагач, Сигезенче мартка дип алган бик матур ефәкне өстәлгә җәеп салдым:

– Карале, Зәлифүш, – дим, – боларга көя төшмәс микән?

– Синең нефтьтән ясалган нәмәрсәңне нишләп көя ашасын? – ди бәләкәчем зур ачу белән.

– Алай димә, матурым, – мин әйтәм, – современный көяләрнең ояты юк. Нефтен-йонын тикшереп тормыйлар, рәттән сыпыралар. Әрәм булмагае.

– Кызгангач алмаска иде, – ди бу.

– Кая инде кызгану! И юләрем минем. Телисеңме, күз алдында бөтенесен тотып утка ыргытам.

– Үзеңнеке булгач ыргытырсың. Хәзер мин аларны ательега илтеп ташлыйм...

Һәм Зәлифәм, күлмәклек тукымаларның иң матурларын сайлап, Казан каласының югары класслы ательесына китте. Ике арада боз эри башлаганны күреп, минем күңелгә җылы йөгерде.

– Бер айдан күлмәкләрне киеп карарга килергә куштылар, – дип, чуртан эләктергән балыкчыдай сөенеп кайтып керде ул. Әйтерсең без яңа гына үбешеп аерылышкан, миңа карата шундый ягымлы.

Ләкин бәләкәчем иртәрәк сөенгән икән әле, бер ай түгел, йөгерә-йөгерә ике ай үтеп китте. Көннәр күбрәк үткән саен, Зәлифәмнең чыраенда хәсрәт буразналары тирәнәйде.

Көннәрнең исәбен, айларның чутын югалткач, ниһаять, бәләкәчемнең күлмәкләрен тегеп бетерделәр. Зәлифәмнең ательедан кайтканын ул көнне озак көттем. Кич җитте, караңгы төште. Күктәге йолдызларны хәтерләтеп, шәһәр утлары кабына башлады. Көтеп-көтеп карчыгым кайтмагач, эчкә шом йөгерде. Әллә, мин әйтәм, күлмәкләренә кызыгып берәр җирдә бәреп үтерделәрме? Беткәнмени шәһәр җирендә хулиганнар!

Эзләргә чыктым. Инде ательелар ябылган. Каян эзләргә? Бала чакта бозау эзләп йөрүләрем исемә төшеп, күңелем тулып китте. Шәһәр эче авыл болыны гына түгел шул, әмма таптым бәләкәчемне. Бер аулак тыкрыкка кергән дә елап утыра бу. Үкси-үкси шешенеп беткән. Йөрәем жу итеп китте:

– Ни булды, бәләкәчем, әллә күлмәкләреңне хулиганнар тартып алдымы? – дим.

– Чуртым алсынмы ул ательеда теккән күлмәкләрне, – ди күгәрченем, мышкылдавыннан көчкә тыелып. – Күл-мәкмени болар. Капчык! Хәтта капчыкка да ярарлык түгел, җир битләр. Җитмәсә, никадәрле акча түләттеләр.

Сабыр төбе сары алтын, дип юкка гына әйтмиләр шул. Басылды Зәлифәм, тынычланды. Күлмәкләрен юеш-лән-мәгән күз белән карарлык хәлгә килде. Ләкин ничек кенә карама, өч күлмәкнең берсенең рәте-чираты юк иде. Берсенең җиңен кыек утыртканнар, икенчесенең якасын. Өченчесе иңгә эләгеп торырлык түгел, муен уемтасына минем Зәлифәм кадәрле өч кеше сыярлык. Бил дигән нәрсәнең кайдан башланып, кайда беткәнен теккән кешесе үзе

дә әйтә алмас, мөгаен. Бу күлмәкләрне киеп бер-ике сәгать каршыңда йөрсә, фәрештәдәй хатының җен булып күренә башлар.

– Бәлки, сиңа гына шундый начар тегүче туры кил-гәндер, калган күлмәкләреңне икенче остага илтсәң... – ди башлаган идем, пианинога караган малаебыз төсле итеп миңа карап куйды:

– Илтәм, көтеп тор. Аннан бөтен кеше акырып чыга. Боларын илткәнгә дә үкенеп бетә алмыйм әле.

Һәр яманлыкның бер яхшы ягы була дигәндәй, күлмәкләрен боздырып кайту ярады тагын: елап туйгач, ачуы басылгач, бәләкәчем мин алып кайткан тегү машинасын ипләп-ипләп ачып карый башлады. Баштарак яңа абзарга керергә курыккан сарык сыман өркебрәк маташкан иде, тора-бара кыюланды. Иң элек яулык читләре бөкте. Ертылган-искергән җәймәләрен рәтләде.

Келтер-келтер әйләнгән машина тавышы ошап киттеме, әллә бу эшне булдыра алырына күңелендә ышаныч тудымы – Зәлифәм ательеда тектергән күлмәкләрен сүтеп ташлады. «Барыбер шуннан артык бозылмас, ничу куркырга», – диде ул.

Чынлап торып еласаң, сукыр күздән яшь чыга. Ә минем Зәлифәм, шөкер, сау-сәламәт кеше. Кулы бар, аягы бар. Теләк кенә җитми иде. Инде менә теләк дигәне дә дөрләп кабынгач, кулында ут уйнатырга тотынды. Кайчакларда шикләнеп карап куям моңа: әллә, мин әйтәм, элек тә теккәне булды микән, дим. Әнә ич, куллары ничек ябышып тора. Ательедан алып кайткан теге капчык рәвешле нәрсәләр күлмәк рәтенә керә башлады тәки.

Әйе, бер дигән иттереп тегеп чыкты ул аларны. Алар гынамы соң: өйдә Зәлифә сүтеп текмәгән нәрсә калмады. Аның бу осталыгын күршеләр дә белеп алдылар. «Зәлифүш, миңа да үзеңнеке кебек матур итеп бер күлмәк тегеп бир әле», – дип, ял көннәрен көтеп торалар. Зәлифәм минем кеше сүзен аяк астына сала торганнардан түгел, һәркайсының әйберен алып кала.

Менә шулай тарала башлады Зәлифәмнең даны. Хәзер минем урамга чыгар хәлем юк: «Әнә Зәлифәнең ире», – дип төртеп күрсәтәләр. Төртеп күрсәтүчеләре кемнәр диген әле? Казанның иң чибәр, иң модный хатын-кызлары! Менә эшләр кая китте бит, ә?!

## ӘЙБӘТ КЕШЕ

Безнең өйдә бүген иртәдән бирле ыгы-зыгы. Әни чыж да пыж таба ашлары пешерә. Кухнядан бәреп чыккан кызган май, кызган суган исләренә чыдый алмыйча, аяк астында песи урала. Ләкин аңа әһәмият бирүче юк. Сәрбиназ апа өйләрне җыештыра. Сәрбиназ миңа туган апа түгел. Ул кайчандыр мине карап үстергән, ә инде мин ай үсәсен көн үсеп, чын-чынлап адәм рәтенә кергәч, Сәрбиназ апа бөтен көчен тузан белән көрәшкә түгә башлады. Сәрбиназ апаның кулында һәрвакыт ике чүпрәк булыр: чүпрәкләренең берсе юеш, берсе коры. Әгәр дә көзгеләр, тәрәзә пыялалары ышкыганга туза торган булсалар, безнең өйдә тишелмәгән көзге, ертылмаган тәрәзә өлгесе калмаган булыр иде. Ә инде Сәрбиназ апа идән паркетын ялтырата башласа, ул көнне аяктан егылмый туктамый ул.

– Җил тегермәне белән сугышучы Дон Кихот син, – дим мин аңа.

– Шулайдыр, шулайдыр, – дип килешә ул минем белән һәм эшен дәвам итә.

Кайвакыт мин, аның ачуын чыгарырга тырышып, бер бүлмәдән икенче бүлмәгә футбол тубы куалап йөри башлыйм. Тубымны пирамида итеп өеп куелган мендәрләргә дә юнәлтәм, шкаф башына да кундырам. Ул коты очып миңа карап тора, ләкин ачуланмый. Әйберләрне ватмый-җимерми генә туктасам, җиңел сулыш алып җибәрә.

– Мин начар малай, әйеме? – дим мин.

– Алай димә, наныем, – ди ул, чын күңеленнән сүз-ләремне кире кагып. – Яхшыдан яман тумас. Әти-әниләрең бик әйбәт кешеләр бит синең. Ходай үзләренә гомер генә бирсен.

Сәрбиназ апага безнең әти фәрештәләрнең фәрештәсе булып тоела. Чөнки әти аңа үзебезнең йорттан ук бик шәп фатир алып бирде. Аның фатиры миңа да бик ошый, чөнки ул иң югары катта. Аның балконыннан бөтен Казан күренә. Сәрбиназ апа үзенә фатир алып биргәннән бирле әтигә рәхмәт укудан туктамый. Хәтта беркөнне мәчеткә барып, бер мулладан әтигә багышлатып Коръән укытып кайткан. Юләр дә инде ул. Әйтерсең әти аның өчен тырыша. Безгә йорт караучы кирәк! Без өчәүләшеп җылы якларга ялга киткән чакларда яки җәйләрен дачаларда яшәп ятканда өйдә кем кала дисез? Әлбәттә, Сәрбиназ апа! Аннан да шәбрәк каравылны дөнья бетереп эзләсәң дә таба алмыйсың. Аннары өй җыештыру, аш-су әзерләшү кебек эшләрдә аның кебек өлгер, аның кебек чиста кеше тагын кем генә бар икән? Менә бүген дә ул иртәдән бирле бездә маташа. Артык тырышудан битләре яшь кызларныкы кебек кызарып чыккан. Гомерен безгә багышлап үзе кияүгә дә чыга алмады, бичара. Ә бит заманында

бик чибәр иде ул. Аның белән урамга чыксак, борылып карамаган кеше калмый иде. Яучылап та карамадылар түгел үзен, әмма этинең шундый тугрылыклы хезмәтчене һич тә кулыннан ычкындырасы килмәде. Тора-бара ялгыз яшәргә ул үзе дә күнекте: «Хәзер аның әйбәт кешесе бармыни!» – дип кул селти ул, сүзне озынга сузмыйча.

– Әйбәт кеше синеңчә нинди була? – дип сорыйм Сәрбиназ ападан. Ул кулындагы чүпрәкләрен әвеш-тәвеш китереп уйланырга тотына.

– Әйбәт кешеме? Әйбәт кеше бервакытта да көчсезләрне рәнҗетми, ярдәмчел була. Хәрәм ризык ашамый, алдашмый. Синең этиең төсле инде...

Сәрбиназ апаның әйбәт кешене тасвирлавы шуның белән тәмамлана. Мин дә артыгын төпченмим.

Бүгенге ыгы-зыгы шушы «әйбәт кеше»ләрнең берсе, ягъни минем этием Габдрахман Зарипович хөрмәтенә.

Безнең эти, Сәрбиназ апа әйтмешли, бик зур кеше. Һәм ул бүген тагын да зуррак булып кайтачак. Нигә дисәң, бүген сайлау көне. Илнең иң югары органына депутат булып сайланачак безнең этиебез. Аның сайланачагына беребезнең күңелендә дә шик юк. Шулай да Сәрбиназ апа, пошынып: «И Ходаем, сайлаулар әйбәт кенә үтсә ярар иде инде!» – дип, вакыт-вакыт үзенең тынычсызлануын белдергәләп куя. Аңа беребез дә сүз әйтмибез, һәркем үз уйлары белән мәшгуль. Ә Сәрбиназ апа, күңелен юатыр өченме, сөйләнүен дәвам итә: «Бар да әйбәт булыр әле, Алла боерса. Фәрештәдәй кешене сызып ташларга кемнең кулы барсын? «Габдрахман Зарипович» дип бөтен кеше үлеп тора бит. И-и, аны белеп кенә бетермиләр әле. Белсәләр, Мәскәүнең дә иң биек җирендә утыра торган кеше ул Габрахман Зарипович!..»

Әтине күрше-тирәләр дә ярата шикелле. Кайда да аны мактап торуларын ишетәсең. Бер уйласаң, кеше күңелен яуларга күп кирәкмени: исемнәре белән дәшеп, хәл-әхвәлләрен сорашсаң, шул җитә. Бигрәк тә безнең эти кебек зур кеше үзе башлап синең белән исәнләшкәч, эремәс җирдән эрисең. Әни әйтмешли, эти безнең оста психолог. Бала-чаганы да игътибарсыз уздырмас: йә башларыннан сыйпап китәр, йә, менә нинди зур үстең, дип, эскәмиягә бастырып куяр. Үзенә таба тәгәрәп килгән тупны хуҗаларына таба тибеп җибәрүдән дә тайчынып калмый ул. Нәкъ менә шушы гадилеге өчен яраталар аны. Машинасы ишек төбенә килеп туктауга, күршеләр, берсен берсе уздырып: «Берәр ярдәм кирәкмиме, Габдрахман Зарипович?» – дип йөгереп чыгып җитәләр. Әгәр этинең берәр әйберен күтәрешеп кертешсәләр, ул көнне этигә ярдәм итә алган кеше үзен бәхетле саный, бу эш аның өчен зур горурлыкка әйләнә. Әмма күршеләргә мондый «бәхет» еш эләкми. Чөнки эти тегене-моны алса, күрше-тирә эштә чакта шофёры ялт кына өйгә кайтарып китә. Әтинең шофёры Ирек абыйның күренмәс кешегә әверелдерә торган бүреге бар диярсең, әле генә урамга карыйсың, беркем булмый, ә инде икенче карауга кап-кап әйберләр күтәреп ишек төбенә менеп җиткән була. Күп вакыт күршеләр түгел, үзебез дә сизми калабыз аның нәрсә китереп киткәнен. Әти Ирек абыйның менә шушы сыйфатын мактап бетерә алмый.

Дөньялар шулай әйбәт кенә барган чакта әллә каян гына «үзгәртеп кору» дигән нәрсә килеп чыкты. Һәрвакыт үзенә үзе сокланып канәгать йөз белән йөргән этинең чырае караңгыланып китте. «Кара халык ул – кара сарык, ә кара сарыкка чыбыркы гына кирәк», – дип сөйләнде ул. Бигрәк тә, өстәгеләргә өстенлекләр бетсен, дип кычкыручыларга ачуы килде аның.

– Бу иң юләр сүз инде! – диде ул, бу хакта өйдә бервакыт сүз кузгалгач. – Өстәгеләрнең ничек инде өстенлеге бетсен? Өстә утыру үзе өстенлек бит ул. Ке-шенең кулыннан властьны тартып алмый, өстенлеген бетереп булмый. Беркөн газетада бер юләре болай дип яза: имеш, җитәкчеләр генә файдалана торган санаторийларны сугыш ветераннарына бирергә кирәк. Сугыш ветераннарына бирсәң, шул ук гап-гади санаторий булып калачак бит ул. Анда без дәваланмый башласак, дарулары да килмәячәк, ашау-эчүе дә такы-токыга әйләнәчәк. Ә алар өстенлекне бетерергә дип өрәләр.

Борыны белән бозга төртсәләр дә, безнең эти аптырап кала торганнардан түгел. Һәр очракта җаен табар, барыбер үзенекен итәр. Үзе әйтмешли, ике тапкыр үзгәртеп корсалар да, югары эшелоннан төшеп калырга исәбе юк аның. Һи, башы булган кешегә җайлашып булмаган заман бармыни?! Бүген коммунизм коралар икән – коммунизмга, капитализмга күчәләр икән, капитализмга хезмәт итә ала ул. Аңарга коммунизмнан капитализмга күчү бер бүлмәдән икенче бүлмәгә керү кебек кенә. Бүлмәдән бүлмәгә күчкәндә әле әйберләр ташыйсы бар, ә монда анысы да кирәкми. Эшләпәңнең алдын артка әйләндереп ки дә, кер дә кит.

Һәм беркөнне безнең эти шулай эшләде дә. Кичә генә гаделлек, тигезлек таләп итүчеләрне эченнән сүгеп йөри иде, бүген барган да махсус алар өчен генә билгеләнгән кибеттән үзенең исемен сыздырып кайткан.

– Бүгеннән һәрнәрсәне шәһәр кибетләреннән алырсың, өргән этләрнең авызы тыгылсын, – диде ул әнигә.

Әни аны-моны әйтмәде, бары тик бераз көлемсерәп кенә куйды. Әнине безнең тирәдәге кибет сатучылары яхшы беләләр иде, әгәр әни кибеткә килеп керсә, ни кирәк тә ни кирәк, дип, янында бөтерелергә генә торалар. Бер атна дигәндә, әнинең нинди ит яратканын, нинди каймак, нинди күмәчләрне артыграк күргәнен барлык кибетчеләр

белеп бетергән иде инде. Ул керүгә, һәрнәрсә үлчәнеп, пөхтәләп төреп куелган була башлады. Әнигә яки миңа бары тик акчасын түләп, кирәк нәрсәне алып чыгып китәргә генә кала иде.

Беркөнне әни хәтта болай дип тә сөйләнеп алды:

– Бу кибетчеләрне әйтәм әле, нәрсәгә шулай ялагайланалардыр. Җир тишегеннән булса да мин сораган әйберне тапмый калмыйлар. Кибетләрдә әйбер юк, дибез, бар икән бит ул әйбер. Мин ул кибетчеләргә беркем дә түгел бит югыйсә.

Әти әнигә бармак янап куйды:

– Син шаярма, әнкәсе, халык бик хәйләкәр ул. Аларның үз тактикасы бар. Туктале, ди ул, хатын белән ир – бер ишекнең ике тоткасы, кайсы тоткадан тартсаң да шул ук ишек ачыла. Син тотынган тоткадан тартып, алар минем ишекне ачарга тырышалар. Әмма минем ишек бик калын, алай тартканга гына ачылырлык түгел. Ә алар тартсыннар, керү юлын эзләсеннәр. Мин нәкъ менә шуңа исәпләп махсус кибеттән баш тарттым да. Урының югары булганда аның нигә кирәге бар? Болай хәтта шәбрәк тә. Йә, әйт әле, элеккегә караганда начарайдымы синең тормышың?

– Соң, шуны әйтеп торам бит, – диде әни. – Фәлән нәрсә әзерләп куйдым дип, өйгә дә шалтыраталар.

– Шулай шул! Ә кайбер юләр башларның өстенлекләр-дән арынырга көче җитми... Ә-ә, мин сиңа шуны да әйтергә онытып торам икән: хәзер без дәваланырга махсус поликлиникага йөрмәячәкбез. Мин үз поликлиникабызның баш врачына шылтыратып куйдым. Ул, кирәк булса-нитсә, үземә әйтерсез, диде. Әле беркөн вакыт табып, үзебезнең район больницасына да сугылдым. Эчәкләрне тикшерә торган аппаратлары юк икән. Бу кварталда рес-публика больницасына кайтачак япон аппаратын боларга җибәрергә сөйләштек. Әйдә кинәнсеннәр. Бәлки әле, ул больницаны бераз гына үзгәртеп салдырырга да туры килер. Үзгәртеп корулар заманы бит. Дөнья хәлен белеп булмый, кереп ятуың бар. Алдан күреп бер-ике люкс палата эшләтеп куйсаң, бер дә зыяны тимәс.

Шулай итеп, без больницаның да гап-гадиенә йөри башладык. Әни беркөнне юри генә, башым авыртып тора, грипп түгел микән, дип шылтыраткан иде, ун минут эчендә врач килеп тә җитте. Махсус больницадан әле ярты сәгатьсез килмиләр иде. Шул турыда этигә әйткәч:

– Менә күрдегезме инде, махсус больницада безнең кебекләр йөзәрләп, ә монда берүзем. Башыңны эшләтә белергә кирәк, башыңны! – дип мактанып куйды.

– Әгәр бөтен кеше дә синең кебек эшләсә? – диде әни. – Ул чакта нишләрсез?

– Ул чакта да җаен табарбыз. Нишләргә кирәген заман үзе әйтә ул.

Әтинең үз теләге белән менә шундый «майлы кал-җа»лардан баш тартуын очлы күзле журналистлар бик тиз күреп алдылар. Әле бер газетада, әле икенчесендә эти турында зур-зур мәкаләләр чыгып торды. Шушы мәкаләләрнең файдасы тидеме, этине илнең иң югары органына депутатлыкка кандидат итеп күрсәттеләр. Дөрес, аның моңарчы да депутат булганы бар иде. Әмма хәзер, үзе әйтмешли, заманасы башка. Депутатларның бәясе көнләп түгел, сәгатьләп арткан чак. Аннары шунысы да бар: этинең яше түгәрәкләнеп килә. Әгәр инде депутат итеп сайлана аласың икән, димәк, тагын биш елыңны кыңгыраулы атларда чабып үтәсең дигән сүз. Депутатны пенсиягә киткәндә дә ким-хур итмиләр. Калган гомереңне иң яхшы курорт-санаторийларда йөреп, кем әйтмешли, чәчкә утлап уздырырга була. Менә бит ул дөньяның нинди яклары бар!

Ләкин этинең эчен пошырган бер нәрсә турында әйтми китсәң ярамастыр. Ул да булса бер округтан өч кешенең бу майлы калҗага үрелүе. Бер урындыкка, әлбәттә, өч кеше сыймаячак. Көчең җитеп, башкаларны этеп төшерә алсаң гына урындыкка син хуҗа булачаксың. Тик, көрәш башлаганчы, кем белән көрәшәчәгеңне ачыкларга кирәк бит әле.

Дөресен әйткәндә, кемнең кем икәнен белер өчен әллә ни баш ватасы булмады: газеталар этигә ярдәм иттеләр. Берсе зур заводның директоры икән, ә икенчесе гап-гади бер укытучы. Җитмәсә әле, хатын-кыз. Монысы этине куркытмады. Укытучыларны җырларда мактап җырласак та, аларны түр башына менгерергә беркемнең дә ашкынып торганы юк. Исемен журналистлар бераз иләп йөртерләр дә, төшеп калыр. Ә менә икенчесе этине чын-чынлап куркыта. Завод директоры уен эш түгел инде ул. Заводы нинди диген әле: безнең республикага гына түгел, Мәскәүнең үзенә буйсына торган завод. Мондый кеше белән бил алышу җиңел булмаячак.

Сайлаучылар белән очрашуга барган саен, этинең кәе-фе кырылып кайта. Хәтта ябыга ук башлады. Төннәрен сикереп тора да әрле-бирле йөрергә тотына. Гадәттә, имезлеккә өйрәнгән баланы имезлектән аерсаң, чиргә сабыша, этинең дә хәле менә шундыйрак иде.

Бик теләгән кешенең учына йолдыз төшә, диләр. Безнең эти дә, күрәсең, бик теләгәндер инде, аның да учына йолдыз төште.

Болай булды ул: теге завод директорының бер кызы нindидер начар юлда йөри икән. Менә шуны журналистлар каяндыр белеп алган да, үз кызын да тәрбияли алмаган кешенең депутат булырга хакы юк дип, газетага язып чыктылар. Сайлаучылар белән очрашу вакытында әтинең ышанычлылары да бу хәбәрне бик оста кулланды, ахры. Теге директорның баш очында давыл куерганнан-куера барды, һәм ул бичара көннәрдән бер көнне үзенең кандидатурасын алырга мәҗбүр булды. Моны ишеткәч, әтинең шатланганын күрсәгез! Минем уйлавымча, бу уенда әтинең дә катнашы булмый калмагандыр. Әтине мин бар кешегә караганда да яхшырак беләм.

– Туганда ук авызыңа бәхет җимеше кабып тугансың, ахры, син, Габдрахман, – диде әни, сөенеченнән балкып. – Техникум белемең белән зур-зур эшләрдә эшләдең.

– Институт та бетердем мин, әнкәсе. Алай минем дәрәҗәмне киметмә.

– Институтны ничек бетергәнеңне беләбез инде. Алтын чүмәләсе өстендә утырганда диплом алу авыр эш түгел.

– Менә шул син әйткән алтын чүмәләсендә утыра да белергә кирәк бит әле.

Әти белән әни күңелле генә сөйләшеп киттеләр. Әти нинди дә булса уңышка ирешсә, алар шулай күтәрелү бас-кычларына кабат менеп төшәргә яраталар. Үткәннәр-не искә төшерү, яуланган дәрәҗәләрне өр-яңадан хәтер-дә яңарту аларның икесенә дә әйтеп бетергесез рәхәтлек бирә иде. Мондый чакларда алар ничектер матураеп, яшәреп киткәндәй булалар. Хәтер учакларының көле астыннан калкып чыккан, янып бетмәгән күмер кисәкләре аларның йөзенә нур сипкәндәй итә.

Берничә көн әтинең йөзеннән шушы нур китмәде. Баштарак нindидер бер укытучы үзенә көндәш була алмас дип санаса да, тора-бара эченә шик йөгерә башлады. «Хәзерге заман кешесен белмәссең, – дип сөйләнде ул, – бөркетне тавык чукып атарга да мөмкин. Хәзер бүрегә көчек ташлана торган чак, чөнки көчекне өстереп торучылар була. Нәрсәдер эшләргә, вакыт үткәнче нидер кылырга иде».

– Әллә үзе белән әйбәтләп күзгә-күз сөйләшеп карарга микән, әнкәсе, ә? Нindирәк кеше икән, син белмисеңме аны?

– Юк шул, – диде әни. – Без бит кеше белән аралашмыйбыз. Аралашсаң да, шәһәр тиклем шәһәрдә кемне генә белеп бетермәк кирәк.

– Мин беләм аны, әти, – дидем мин, сүзгә кушылып.

– Син?

– Әйе, мин.

– Сезнең мәктәптә укытмыйдыр бит?

– Юк, ул кайдадыр француз телен укыта бугай.

– Нишләп соң әле син беләсең аны?

– Кайчагында сез белмәгәннәрне дә беләм мин шулай, – дип, әтиләр алдында мактанып куйган булдым.

Ә аннары Кадрия Сабитовна белән ничек танышканымны сөйләп бирдем.

Узган ел Май бәйрәме алдыннан берничә малай күрше йортның ишегалдында Айратның мопедын рәтләп маташа идек. Мопед инде тузган, артыннан этеп йөрсәң генә кабына. Этеп-этеп арыгач, без аны бала-чага шуышып уйный торган калай шугалакка алып менеп, шуннан утырып төшә башладык. Төшеп киткәндә генә бөтен өйләрне дер селкетеп мопедыбыз кабынып китә, хәтта һавадагы кош-кортларга кадәр очып килгән җирләреннән кире якка борыла. Бу безгә бик кызык тоелды. Калай шугалактан чажлап килеп төшәбез дә ком көртенә чумабыз.

Шулай дөнья кубарып мопед белән мәшәләнеп ятканда, безнең янга бер апа килеп басты. Тавышланасыз, дип, безгә вәгазь укый башлар инде бу дип көткән идек, тик ул сүзсез генә безне күзәтүендә булды.

– Моның уе җүнлелектә түгел инде, – диде Айрат минем колакка, – әллә читкәрәк таябызмы? Погонлы түти булмагае бу.

Без, өч малай, мопедны өстерәп читкәрәк китә башладык. Шулвакыт теге апа безнең каршыга басты да:

– Егетләр, туктагыз әле, – диде.

Без туктап калдык. Теге апа ашыгып сөйләргә тотынды:

– Сез әйбәт малайларга охшагансыз. Сезгә минем бер үтенечем бар иде...

«Үтенеч» сүзен ишеткәч, безнең чырайлар бозыла башлады, бер урында таптанып куйдык. Өлкәннәрнең уен белмәссең: кечкенә генә үтенеч дип, әллә нинди эшкә кушарлар.

Безнең күңелдә нинди шикләр уянганы йөзләребезгә язылган иде, ахрысы, әлеге апа безне тынычландырырга ашыкты.

– Үтенечем шул иде, егетләр, миңа бер яхшылык эшләмәссезме дигән идем.

– Яхшылык? Яхшылыкны теге дөньяда оҗмахка керергә теләгән кешеләр генә эшли, ә без оҗмахка керергә җыенмыйбыз әле, – диде Саша.

Аңа үз сүзләре бик кызык тоелды, ахры, шыр-шыр көләргә тотынды. Теге апаның күзләрендә ниндидер кичерешләр чагылып китте. Бәлки, рәнжү, бәлки, өметсезлек, бәлки, мин белмәгән бүтән кичерешләр булгандыр алар.

– Танышыйк әле башта, – диде апа кеше. – Мин Кадрия Сабитовна Зөфәрова булам. Укытучы. Менә сезнең кебек егетләргә француз телен өйрәтәм.

Аның укытучы икәнен белгәч, бу безгә акыл өйрәтергә тотынганчы читкәрәк таюың хәерлерәк дип, таралыша башладык. Шунда теге апа әллә нинди әрнүле тавыш белән:

– Егетләр! – диде – Минем дә сезнең кебек малаем бар, ләкин ул авыру, урамга чыга алмый. Иртәгә менә Май бәйрәме. Берәр сәгатькә генә булса да шуның янына кереп утыра алмассызмы дигән идем. Мөгаен, сез гитараларда уйныйсыздыр, магнитофоннарыгыз да бардыр. Уйнагыз, җырлагыз, теләсә нәрсә кыланыгыз, тик аның күңелен ачыгыз бераз.

– Кеше күңелен ачып йөрергә без бит артист түгел, – диде Саша. – Аннары, артистлар да бушка эшләмиләр.

– Ә мин түлим, түлим, – диде Кадрия Сабитовна һәм кабаланып кечкенә сумкасын актара башлады. – Менә акчасын бүген үк биреп куям, тик берүк үтенечемне аяк астына салып таптамагыз.

Кадрия Сабитовна сумкасыннан егерме биш сум акча алып Сашага сузды:

– Үзегез тигезләп бүләрсез шунда. Ә без менә монда торабыз.

Ул ике катлы искереп беткән бер өйгә күрсәтте һәм квартира номерын атады.

– Тик, зинһар, Артурга – минем улымның исеме Артур – үзегезне мин чакырганны әйтмәгез. Шушы ишегалды малайлары буларак хәл белергә генә кердек, диегез.

Кадрия Сабитовна, безне кире уйламасыннар диптер инде, ашыга-ашыга китеп барды.

– Бирермен дигән колына чыгарып куяр юлына, – диде Саша, куанычыннан кулларын угалап. Болай булгач, бәйрәмдә авыз чылатырга була.

Айрат белән мин бер сүз дә дәшмәдек. Күңелдә ниндидер авыр тойгы калды. Саша, безнең кәефләребезнең үзгәрүен күреп:

– Нәрсә әле сез борыннарыгызны салындырдыгыз? Шул гарип малай янына кереп утырырга җыенмыйсыздыр бит? – диде. – Бу акча инде безгә күктән төшкән бәхет. Аны безнең кулдан беркем дә тартып алалмый. Без талап алмадык, үз куллары белән бирде. Шулай булгач, бетте-китте.

– Юк әле, бетмәде дә, китмәде дә! – диде Айрат, катгый итеп. – Иртәгә гитараңны алып киләсең. Ә син, Ирек, магнитофоныңны онытма.

Май бәйрәме көнне без Артурларга киттек. Кадрия Сабитовна безне бик гаҗәпләнгән булып каршы алды.

– Улым, Артур, – диде ул, дулкынлануын яшермичә, – синең яныңа егетләр килгән. Бергә-бергә күңелле генә утырыгыз.

Кадрия Сабитовна өстәл әзерләде. Ниндидер тәмле-тәмле ризыклар пешергән иде, һәрберебезне кыстый-кыстый ашатты. Артур гел ятып кына тора икән. Кулларын да бик авырлык белән генә кыймылдата. Кадрия Сабитовна аның аркасына берничә мендәр куеп, шуңарга улын сөяп утыртты. Өстәлдә бер кызыл аракы да бар иде. Саша берничә мәртәбә аңа үрелеп-үрелеп куйгаласа да, Айратның кырыс карашыннан шүрләпме, шешәне ачмады. Безнең тартынып утыруыбызны күреп, Кадрия Сабитовна чыгып китәргә җыенды:

– Сез утырыгыз, егетләр, минем бер җиргә барып кайтасым бар, – диде ул.

Мин магнитофонның кассетасын алыштырдым. Анда чит-ят телдә карлыккан тавыш белән бик популяр бер артист җырлый иде. Барыбыз да аңа кушылган булдык. Саша шунда күзләрен майландырып янә әлеге шешәгә карап куйды һәм:

– Артур каршы килмәсә, мин бу нәмәрсәне сындыру ягында, – диде.

– Ачыгыз, ач, – диде Артур, – эчәргә дип куелган инде ул.

Саша күз ачып йомганчы шәрабны рюмкаларга бүлеп тә куйды. Ничек башына килгәндер, беренче рюмканы ул Артурга тоттырды.

– Син хуҗа кеше, башлап җибәр әле, – диде.

Артурның моңа кадәр эчкәне булгандырмы, белмим, әмма ул ялындырып тормады. Аның артыннан без дә рюмкаларны күтәрдек. Ул арада Айрат электр самавырын яңадан токка тоташтырып куйды. Әллә мәйдән, әл-лә өй җылысыннан йөзләребез кызарып китте. Артур да җанлана төште. Аның битендә бармак башы кадәр тимгелләр барлыкка килде.

Сәгать-сәгать ярым чамасы утыргач, китәргә җыена башладык. Без чыгып киткәндә, Артур:

– Тагын шулай кереп утырыгыз, егетләр, – дип калды.

– Әниең акчасын җәлләмәсә, керербез, – диде Са-ша.

Шул чагында ирексездән минем карашым Артурга төште: ул кәгазь кебек агарган иде. Мин Сашаны төртеп диярлек ишектән чыгарып җибәрдем. Һәм Артурга:

– Тыңлама син аны, аның бераз башына киткән бугай, – дидем.

Ә урамга чыккач, Айрат белән икәүләп Сашаны эт итеп ярдык. Шуннан соң инде Кадрия Сабитовналар ишегалдында күренмәскә тырыштык.

Мин әтигә кыска гына итеп шуларны сөйләп бирдем. Әти минем сүзләрдән соң җанланып китте. Аның күңелендә ниндидер план туды, ахрысы.

– Әйдә, җыен, – диде ул, – Кадрия Сабитовналарга барабыз. Магнитофоныңны да ал, Артурга калдырып торырсың.

Без, тиз генә киенеп, Кадрия Сабитовналарга киттек. Озак-озак звонок биреп торсак та, ишек ачучы булмады.

– Артур өйдә үзе генәдер, – дидем мин әтигә, – башка вакытта килербез.

Без китәргә җыенып торганда, Кадрия Сабитовна кайтып керде.

– Әллә безгә кунаклар килгән инде, – диде ул, бер әтигә, бер миңа карап. – О-о, кунакларның да ниндие икән әле. Габдрахман Зарипович! Караңгыда танымый да торам. Әйдәгез, әйдә, өйгә узыгыз.

Кадрия Сабитовна ишеген ачып безне алга уздырды да коридорларының утын кабызды. Әти эшләпәсен салып чөйгә элде.

– Менә кайда яшәп ята икән безнең булачак депутатыбыз. Күршеләр үк икәнбез бит.

– Депутат булулар безгә тәтемәс инде ул. Сезнең кебек көндәшләр барында бездәй гади бәндәләргә тавыш биреп тормаслар, – диде Кадрия Сабитовна.

– Алай димәгез, Кадрия Сабитовна, укытучылар булмаса, без беребез дә юк. Шагыйрь әйтмешли, дөньяда иң галим, иң гүзәл кеше – сез. Кая әле, кая, эчкә дә үтик. Ничегрәк яшәп ятасыз икән?

Әти эчкә узды. Күптән белгән кешесе кебек, Артур белән дә исәнләште. Аның шулай кеше белән тиз арада уртак тел табуына гаҗәпләнеп карап тордым.

– Матур гына икән дөньягыз, – диде ул, бер бүлмәле фатирны баштанаяк күз йөртеп чыкканнан соң. – Кая карама пөхтәлек, чисталык. Ничек шулай барысына да өлгерәсез, Кадрия Сабитовна? Авырдыр бит? Укытасыз, өй мәшәкатьләре, тагын менә депутат та булып кит-сәгез...

– Җиңел түгел инде, – диде Кадрия Сабитовна, көрсенеп. – Ә депутатлыкка килгәндә, коллектив сүзенә каршы килмим дип кенә ризалыгымны биргән идем. Аннары көрәш ничектер үзенә тарта башлады. Күңелгә төрле уйлар килде. Нигә әле, мин әйтәм, гел бер үк кешеләр генә сайланырга тиеш? Без алардан киммени?! Иң ачуны китергәне шул: үзең сайлап куйган депутатка үзең йомыш белән дә керә алмый башлыйсың. Озак торса, бал да ачый дигәндәй, гел бер үк кешеләр сайлана килгәч, бозыла шул. Заманның болгануы да менә шуннан бит, Габдрахман Зарипович.

– Әйе, әйе, – диде әти, – эш-эш дип, кешеләрне онытып җибәрәбез. Әти як-ягына каранып куйды: – Әллә телефоныгыз да юк инде, Кадрия Сабитовна?

– Әй ул телефон! – диде Кадрия Сабитовна, авыр көрсенеп, – телефон гына түгел, бәгырьгә утырган таш булды инде ул. Күпме җирләргә яздым, күпме түрәләрнең бусагасын таптадым, юк, диләр, өегезгә кабель кермәгән, диләр.

– Ничек инде шушындый хәлдә телефонсыз яшәргә мөмкин? Әгәр төнлә «ашыгыч ярдәм» чакыртырга кирәк булса? Ялгыз калган чакларда авыру кешегә нәрсә кирәк булмас. – Әти бик озак тузынды.

– Нигә соң аны миңа язмадыгыз? – диде.

– Яздым, Габдрахман Зарипович, сезгә дә яздым. Хәтта бер генә мәртәбә дә түгел.

Кадрия Сабитовна тиз-тиз шкаф тартмаларын актарырга тотынды. Тартмадан кульяулыкка төреп куелган бер төргәк хатлар тартып чыгарды.

– Менә алар, Габдрахман Зарипович, болар бар да «телефон куеп булмый» дип килгән җаваплар. Монда сезнең кулыгыз куелганнары да бар.

Әти бик үкенгән кыяфәт белән хатларны караштырып утырды.

– Эш-эш дип, бер әйләнешкә кереп китәбез дә, кешеләр язмышы турында кайгыртырга вакытыбыз калмый, – диде әти, хатларны хуҗасына тапшырып. – Ярар, соң булса да уң булсын, ди бит халык. Иртәгедән сезгә телефон кертерләр. Үземнең өй телефонын сезгә күчерттерермен. Ярамый болай, ярамый. Тешлерәк тә булырга кирәк, Кадрия Сабитовна. Хәзер заманы шундый. Бар нәрсәсе җитеш кешене генә тыйнаклык бизи.

Әти, кешеләргә миһербан, шәфкать бетеп бара дип, озак кына тузынды. Киткән чакта мин Артурга магнитофонымны калдырдым. Ул тарткалашып маташты, алмас-ка теләде. Беркөн килеп магнитофоныңны

уйнатып торган өчен акча сорасаң, каян алырмын, диде. Миңа теге көнге вакыйга өчен кыен иде, битемнең кызыша башлавын сизеп, тизрәк чыгып киттем.

Өйгә кайту белән әти кемнәргәдер шылтыратты: берәүләрне эт итеп сүкте, икенче берәүләргә урыныннан очыру белән янады. Ахыргы сүзе шул булды: «Хәзер үк минем өемә ике телефонистыңны җибәр, минем номерны әнә Зөфәровага күчер. Алар йортына кабель кермәгән, дисеңме. Ә син безнең йорт белән алар йорты арасында ничә метр ара икәнен беләсеңме? Вәт шул! Кабель кермәсә, түбәдән чыбык сузарсыз. Бер түбәдән икенче түбәгә мәче сикерерлек ара, шуңа җитәрлек кенә чыбык табарсыз дип уйлыйм. Әйе, әйе, дөрес аңлагансың. Нәкъ менә минем телефонны Зөфәровага керт, башкасы турында соңыннан сөйләшербез».

Бер сәгать үткәндерме-юкмы, безгә монтёрлар килеп тә керде. Түбәдән чыбык сузып, безнең телефонны Кадрия Сабитовналарга күчерделәр.

– Монысын ничек аңларга инде? – диде әни.

– Шаулама, әнкәсе, шаулама. Димәк, шулай кирәк. Уйлаган эшләрем әйбәт кенә барып чыкса, соңыннан үзең үк башымнан сыйпарсың әле.

Әтинең ни уйлаганын белергә безгә озак вакыт кирәк булмады. Ул тагын берничә мәртәбә Кадрия Сабитовналарга барып кайтты, ә тиздән Зөфәрованың үз кандидатурасын кире алуы турында газеталарда хәбәр иттеләр.

– Карале, Габдрахман, – диде әни соклану һәм гаҗәпләнү белән. – Син, бөтен кошчыкларны этеп төшереп, чит ояда хуҗа булып ялгыз калган күке баласына охшап киттең. Хәзер барлык җим синең авызыңа гына эләгәчәк.

– Дөнья ул үзе дә зур бер оя, әнкәсе, анда һәркем берсен берсе этеп төшерергә тырыша. Кем көчлерәк – ояга шул хуҗа. Әмма оядан этеп төшерүнең дә үз хәйләсе бар. Үзең этеп төшергән кош баласы түбәнгә тәгәрәгәндә, бөтен кошка караганда да ныграк кычкыр, җәлләгән бул, күз яше түк. Бүтәннәр синең өзгәләнгәнеңне күреп, үзеңне җәлләсеннәр. Вакытын, җаен туры китереп, үз ризыгыңны бүтәннәргә бир, саранланма. Синең бер юмартлыгың бервакыт мең рәхмәт булып үзеңә кайтачак. – Әти рухланып озак кына сөйләнде. Аннары болай дип сүзен тәмамлады: – Ә теге Кадрия Сабитовна хәзер гомере буе рәхмәт укыячак. Малаена коляска табуда булыштым. Хәзер ул үзе үк минем кандидатураны яклап кешеләрне агитацияләячәк. Хәер, агитацияләргә өлгерә алмастыр да, чөнки аның малаена ике айлык путёвка таптык. Икәүләп санаторийга китәчәкләр. Эшне шулай эшләргә кирәк аны, әнкәсе, кеше, сиңа рәхмәт укый-укый, үз бәхетеннән баш тартсын. Бүре дә тук, сарык та исән. Иң бәхетле кеше – дошманы юк кеше. Нигә үзеңә дошман арттырырга?!

Менә, ниһаять, бүген сайлаулар көне. Әтиебезнең сайлануына беребезнең дә шиге юк. Тиздән ул өйгә балкып кайтып керер. Инде табын әзер. Затлы ризыклар, татлы шәраблар белән өстәл тулган. Сайлау нәтиҗәләре билгеле булуга, әтинең дуслары котларга килә башлар. Кичә телефон куярга дип тә килгәннәр иде, ләкин әти әлегә куйдыртмады. Чөнки моннан берничә көн элек кенә әтинең үз телефонын бер инвалидка керттерүе турында газетага зур итеп мәкалә язып чыкканнар иде. Менә шул шаукым бераз сүрелсен, шуннан соң барысын да эшләтәчәк безнең әти. Телефонын да керттерер, бүтәнен дә. Безнең әти ул тау астыннан бәреп чыккан күкертле чишмә кебек. Андый чишмәне таш белән бастырып куеп кына агуыннан туктатып булмый. Бастырсаң – таш астыннан чыгар, юлын бусаң – урап үтәр. Аның суы эләккән барлык үсемлек саргаеп калыр, үсүеннән туктар, ә күкерт чишмәсе агар да агар.

## СӘЕР КУНАК

Бал суырткан вакытта умарталыкка кунаклар ешаюына Мөдәррис абзый күнеккән иде инде. Шуңа күрә колхоз рәисенә ияреп килгән ят кешене күргәч, ул гаҗәпләнмәде: «Бал исе борынына кергәндер», – дип, ризасызлык белән уйлап кына куйды. Рәис: «Менә бу безнең атаклы умартачыбыз Мөдәррис абзый була, районда аның кадәр бал алучы юк», – дип, алып килгән кунагына умартачыны мактый башлады. Бу мактаудан Мөдәррис абзыйның чырае тагын да караңгыланыбрак китте. Чөнки белә: председатель аны мактадымы, димәк, кунакның аппетиты зурдан булачак. Димәк, ул баллы чәй эчеп кенә китмәячәк.

– Йә-йә, – диде председатель, Мөдәррис абзыйның иңеннән кагып, – шырпыларыңны кабартырга ашыкма. Әхмәт Дилүсович, – ул кунагына елмаеп карап куйды, – синең умарталыгыңны күтәреп китәргә дип килмәде. Аңа бераз саф һавада йөреп ял итәргә кирәк. Башын җилләтергә, уйларыннан арынырга...

«Башын казык башына элеп җилләтсен иде, – дип уйлап куйды Мөдәррис абзый. – Беләм мин сезне: башыгызны бушатып, савытларыгызны тутырып китәргә яратасыз. Машинагызда, мөгаен, банкаларыгыз бардыр әле, фляга ук булмаса».

Председатель тагын бер мәртәбә умартачының җилкәсеннән какты:

– Келәтеңнең берәр почмагында кадерле кунакка урын табарсың инде, – дип китеп барды.

– Мондый матур җирдә тышта куыш корып та ятарга мөмкин, – диде кунак.

Әйе, умарталык табигатьнең бик гүзәл җиренә урнашкан. Әнә умарталар торган аланны җиллärдән ышыклап утыручы сабый кулыдай йомшак яфраклы юкәләр. Әнә тезелешеп мәктәпкә баручы үсмер кызлар төсле ак каеннар, әнә кышын да катмый торган Зәңгәр чишмә.

Мөдәррис абзый күптән искәреп килә: матурлыкны кешеләр тизрәк яулап алырга, үзенеке итәргә телиләр. Бигрәк тә кулларында көч һәм власть булган бәндәләр нык тырыша. Умарталыкның иң гөрләгән чагында Зәңгәр чишмә буендагы каенлыкка бер вагон-йорт китереп куйдылар. Кышның салкын көннәрендә ул вагон-йортның миченә Мөдәррис абзый ягып торырга тиеш булды. Кайчагында һич көтмәгәндә-уйламаганда урман аланы өстендә вертолёт пытырдый башлый. Иң элек ул, чебеш эзләгән тилгәндәй, әйләнә-тирәне бер урый, аннары карлар очырып төшеп утыра. Аның эченнән мылтыклы кешеләр чыга. Мөдәррис абзый белә: болар олы түрәләр. Алар килдеме – урмандагы тынлык иң ерак почмакларга кереп поса. Ә төлкедер, куяндыр ише мәхлук җаннар ерак почмакларга качып та котыла алмый: ядрәнең тәпие озын, әллә кая качсаң да куып тота.

Ә бераздан Мөдәррис абзый ягып җылыткан вагон-өйдә шау-шулы мәҗлес башлана. Мөдәррис абзыйның төшенә дә кермәгән ят эчемлекләр табынга менеп кунак-лый. Ризыклар тезелә. Берәрсе видеомагнитофонны кабызып җибәрә. Экранда шәрә кызлар пәйда була.

Ашап-эчеп, кәеф-сафа корганнан соң, түрәләр верто-лётларына төялеп кайтып китәләр. Күп вакыт үзләре аткан куян-бүреләрне дә вагон-йортта ташлап калдыралар.

– Алып китәрлек булмагач, нигә җан кыеп йөриләр-дер, – дип сукрана Мөдәррис абзый.

– Аларга кәҗәсе түгел, мәзәге кыйммәт, – ди колхоз рәисе. – Куян кирәклектән йөриләр дип beläсеңме әллә син аларны.

Мөдәррис абзыйга бу тормыш мәңге шулай үзгәрешсез барыр, түрәләр сунарга вертолёт белән һәрвакыт килеп-китеп йөрерләр кебек тоела иде. Әмма кинәт кенә дөньялар болганды. Көннәрдән бер көнне теге вагон-йорт та үзеннән-үзе янып юкка чыкты. Шуннан бирле умартачылыкка килүче кунаклар сирәгәйде. Килсәләр дә, район тирәсеннән генә киләләр иде.

Ә бу кунак район кешесенә охшамаган. Үзе бик йомыкый. Күп сөйләшми. Мөдәррис абзыйның:

– Бал белән чәй эчмисезме? – дигән соравына ул:

– Балга минем аллергия. Бер кашык бал капсам да, бөтен тәнем кызарып чыга, – дип табынга утырмады.

– Алай, алай, – диде Мөдәррис абзый, үзе эченнән: «Әгәр кодрәтемнән килсә, бөтен начальствога шул аллергия дигән нәмәстәкәйне бирер идем. Колхоз балын күбрәк капкан саен, ныграк кызарсыннар иде», – дип уйлады.

– Ә сез үз эшегезне карагыз, – диде Әхмәт Дилүсович, умартачының сабырсызланып китәргә ашыгуын, ләкин үзен ташлап китәргә батырчылыгы гына җитми торуын күреп. – Мин бераз урманнарны әйләнеп киләм. Гомумән, мине юк дип уйлагыз.

– Ярый алайса, – диде Мөдәррис абзый, җиңел сулап. Бәлки, чынлап та, бу бәндә башын җилләтергә чыккандыр. Кыяфәтенә караганда түрәгә охшаган. Әмма үз-үзен тотышы, тыйнаклыгы, сабырлыгы ничектер сәеррәк иде.

Һәм Мөдәррис абзый кунагын сиздермичә генә күзәтә башлады. Кем бу? Нишләп йөри? Чакырып китермәсәң, ашарга-эчәргә дә килми. Берәр җиргә барып утыра да уйга чума. Нәрсә турында уйлана, җанын нәрсә талкый, һич аңлармын димә. Инде умарталыкта яши башлавына атнага якын вакыт үтте. Ә Мөдәррис абзый аның исеменнән башка берни белми әле. Кайсы көнне ул урманга мылтыгын күтәреп чыгып китә, ләкин берни дә атмый. Мөдәррис абзый аның бидоны, банкалары юклыгын күргәч, җиңел сулап куйды. Бал ашамавы чындыр, күрәсең. Әнә бит чәй эчкәндә хәтта балның савытын да читкәрәк этеп куя. Исе борынга керсә, төчкертә башлый, ди. Мөдәррис абзый гаҗәпләнгәннән гаҗәпләнә: бал ашарга яратмагач, ни өчен соң аны председатель монда китереп куйды икән? Эчендә берәр хәсрәте бардыр. Мөгаен, шулайдыр. Ә бәлки... Ә бәлки әле, ул берәр олы урыннан төшерелгән түрәдер. Әйе, әйе, нәкъ шулай. Бөтен кыяфәте шул турыда сөйли ләбаса. Хәзер бит түрәләр очып кына тора.

Мөдәррис абзый үзенең бу ачышына сөенеп куйды һәм кунагын тагын да ныграк күзәтә башлады. Беренчедән, дип нәтиҗә чыгарды ул күңеленнән, Әхмәт Дилүсович дигәнебез кеше сүзен тыңлый белми, тыңлаган төсле итеп баш кагып утыра гына. Мөдәррис абзый кайчакларда юри сүзен иң кызык җирдә өзә дә, бераздан: «Кайда туктаган

идем әле мин?» – дип сорап куя һәм әңгәмәдәшенең берни тыңламаганына төшенә. Димәк, боерырга гына өйрәнгән. Кешене тыңларга өйрәнеп җитмәгән. Икенчедән, өстәл янында утырган чакларында сәер кунак үзе дә сизмәстән кулы белән капшанып нидер эзләнә башлый. Башта Мөдәррис абзый аның бу гадәтен нәрсәгә юрарга белми аптыраган иде, уйлана торгач, анысына да җавап тапты: түрәләр бит, гадәттә, үзләренең секретарьларын кнопкага басып кына чакыралар. Монда да ул, онытылып китеп, кемнедер чакырырга, кемгәдер боерык бирергә омтылып куйгалый бугай.

Шулай итеп, Әхмәт Дилүсовичның урыныннан төшерелгән кеше икәнлеген аңлар өчен әллә ни зирәклек кирәкми иде. Әнә ич, председатель китерде дә онытты үзен. Эшли торган башлыкларны онытмыйлар алар. Аларга карата ай-һай сизгер булалар. Мөдәррис абзый, кунагының кем икәнлегенә төшенгәч, ничектер тынычланып калды. Әхмәт Дилүсовичны ул чын-чынлап кызгана ук башлады. Ул яраткан ризыкларны пешерергә тырышты. Кунак бәрәңгене шашлык кебек итеп турамы-турамы белән тимерчыбыкка тезеп учакта кыздырып ашарга ярата иде. Мөдәррис абзыйның үзенә дә бу аш ошап киткәнлектән, кич җитә башладымы, чишмә буенда учак ягып бәрәңге шашлыгы әзерләргә тотына ул. Әхмәт Дилүсович коры чыбык-чабыклар җыя. Менә бермәлне бәрәңге әрчелеп бетә, учак чырт-чырт янарга тотына. Картының нәкъ шушы вакытта урман аланында сәер кунагы белән бәрәңге пешереп ятканлыгын белеп алган Хәерниса түти яңа гына сепараттан чыккан каймагын әзерләп куя. Учакта кыздырылган бәрәңгене каймакка мана-мана сүзсез генә ашау башлана.

Ул арада инде ут өстендә кура җиләге яфраклары, мәтрүшкәләр салган чәй кайнап чыга. Маңгайдагы тирләрне тастымал очы белән сөртә-сөртә, озаклап чәй эчелә. Мондый вакытларда кунакның да кәефе күтәрелеп китә. Ул Мөдәррис абзыйдан фронтта йөргән чакларын сораштыра башлый. Ә фронтта булган кешенең ашарына бирмәсәң бирмә – бары тик сораштыр, бары тик игътибар белән тыңла гына. Мөдәррис абзыйның сүзгә әллә ни маһирлыгы юк югын, әмма сугыш вакыйгаларын сөйли башласа, теләсә кемне авызына карата да куя.

– Инде хәзер аны туктатырмын димә, – ди Хәерниса түти, – таңга кадәр сөйләячәк.

– Сөйләсен әйдә, – ди кунак.

– Фронттан кайтып төшкәч, өч төн буе тоташ сөйләде ул, – ди Хәерниса түти. – Алай да сугыштагы өч көнен генә сөйләгән булып чыкты. Хәзер инде сугыш беткәнгә дә илле елга якынлаша, тик һаман сөйләнеп бетми әле.

– Бетми шул, – диде Мөдәррис абзый, карчыгына хәтере калып. – Беләсең килсә, сугышның бер көне бер елга тора аның.

Карт белән карчык үзара җиңелчә генә әйткәләшеп алалар. Картын яратып кына үрти Хәерниса түти. Дөресен әйткәндә, Мөдәррисенең әллә нинди түрәләрне авызына карата алуы белән горурлана әле ул.

Инде Мөдәррис абзый сәер кунагына ярыйсы ук күнеккән, Әхмәт Дилүсович үзе дә ачылып сөйләшә башлаган иде, беркөнне председательнең шофёры аңа ниндидер хат китереп бирде. Әхмәт Дилүсович бу хатны укыгач, тагын элеккечә үз эченә йомылды, ашарын ашамас булды. Мөдәррис абзыйның: «Әллә берәр күңелсез хәбәр бармы?» – диюенә җавап кайтармады. Ә бераздан капыл гына юлга җыена башлады. Сумкасына сөлге ише нәрсәләрен салгач, нидер исенә төшкәндәй бераз еракка карап торды да: «Киткәнче тагын бер мәртәбә урманнарны карап килим әле, булмаса», – дип, мылтыгын чехолыннан салдырып җилкәсенә элде.

Ул урманга кереп китеп озак та тормады, мылтык шартлаган тавыш ишетелде. Мөдәррис абзыйның сис-кәнүдән кулындагы баллы тустаганы төшеп китте. Ерак та түгел, өере белән каргалар очканы күренә башлады. Алар әллә нинди тавышлар чыгарып каркылдаштылар, кемгәдер ачуланалар иде бугай. Мөдәррис абзыйның күнеленә шомлы уй йөгерде: «Әллә инде... Әллә... Алла сакласын».

Билендәге озын алъяпкычын барган уңайга гына чишеп агач ботагына элде дә мылтык тавышы ишетелгән якка йөгерде ул. Әхмәт Дилүсович белән алар маңгайга маңгай бәрелешә яздылар.

– Син... син исән, – диде Мөдәррис абзый, кунагының теп-тере килеш агачлар арасыннан килеп чыкканына сөенеп. Ул үзенең кабалануы аркасында Әхмәт Дилүсовичның кулындагы әйбергә дә әһәмият бирмәгән иде.

– Менә! – диде Әхмәт Дилүсович. – Әллә каян гына агачлар арасыннан килеп чыкты. Чакмага басканымны сизми дә калдым.

Ул Мөдәррис абзыйның аяк астына җансыз төлке гәүдәсен ташлады.

– Ялкын, – диде Мөдәррис абзый, төлкене танып. – Безнең Ялкын!

Мөдәррис абзыйның кинәт тез буыннары калтырап китте. Ул чүгәләде дә җирдә сузылып яткан төлкенең йомшак йоннарын сыйпарга тотынды. Әхмәт Дилүсович исә, һаман акланырга теләгәндәй:

– Мылтык астына үзе килеп керде. Аякка уралыпмы-урала. Төлке атарга дип ниятләп чыкмаган идем, – дип сөйләнде.

– Мылтыкны кулга алдыңмы, ата инде ул, – диде Мөдәррис абзый, чүгәләгән җиреннән торып. – Мылтык астына үзе килеп керде, имеш. Ә беләсеңме ни өчен ул мылтык астына үзе килеп кергән?

Әхмәт Дилүсович, ни өчен соң дигәндәй, Мөдәррис абзыйга текәлде.

– Аның әнә анда оясы бар, ә оясында өч баласы. Балалары янына якынлашып килүеңне күргән дә сине туктатып калу өчен атылып каршыңа чыккан.

– А-лай! – диде Әхмәт Дилүсович, бераз сузып. – Балаларын коткарып калу өчен диген, ә?

Карт умартачының «балаларын коткару өчен» дигән сүзләре Әхмәт Дилүсович күңелендә нindидер уйлар кузгатты бугай, ул озак кына җирдә сузылып яткан үле төлке гәүдәсенә карап торды. Аннары, Мөдәррис абзыйга күтәрелеп:

– Менә сез, Мөдәррис абзый, бик күзәтүчән кешегә охшыйсыз, әйтегез әле: аналарына яки аталарына үлем куркынычы янаганда берәр җәнлекнең баласы, аны коткарыр өчен, үзе мылтык астына килеп кергәне бар микән?

– Андый нәрсәне күрергә туры килмәде, – диде Мөдәррис абзый.

– Димәк, кешеләрдәге мондый сыйфатлар кыргый җәнлекләрдән үк килә икән. Димәк, бу – инстинкт, – дип, үзенчә нәтиҗә ясады Әхмәт Дилүсович.

Тагын байтак вакыт сүзсез утырдылар. Соңыннан Әхмәт Дилүсович, төлкегә таба ымлап:

– Инде моны нишләтәбез? – диде.

– Тунарга кирәк, – диде Мөдәррис абзый. – Рас җан кыйгансың икән, берәр файдасы булсын.

– Юк-юк, – диде Әхмәт Дилүсович, – мин андый эшнең рәтен белмим. Тунаган очракта да аның тиресе белән мин нишлим?

– Хатыныңа яки кызыңа якага булыр.

Кунак нindидер сәер караш белән Мөдәррис абзыйга карап куйды. Аның күңелендә кайнаган уйларын карт умартачыга түгеп саласы килә, әмма горурлыгы җибәрми иде бугай.

– Әйдә, булмаса, моны җиргә күмик, – диде Мөдәррис абзый. – Балаларының күзенә чалынмасын.

– Күмәргә?

– Әйе. Чөнки тиресен тунарга минем дә кулым бармый.

Алар, умарталыктан көрәк алып килеп, төлкене күмеп куйдылар. Бераздан Мөдәррис абзый болай дип сүз башлады:

– Бу төлкене мин өч ел беләм инде. Бервакыт шулай кыш көне подвалдагы умарталарның хәлләрен белергә дип бирегә килгән идем. Эшләремне бетергәч, келәткә дә сугыласы иттем. Келәткә якынайгач, эчтә нindидер тавыш ишетеп, сагаеп тәрәзәгә килдем. Тәрәзә аша карасам, ни күзләрем белән күрим, бер төлке почмакта балавыз ялап маташа. Әйе, келәттә минем балавызлар сак-лана. Шунда кергән бу. Келәт тәрәзәсенең бер бүлкәсе ватылгач, полиэтилен кадаклап куйган идем, шуның бер почмагын ерткан да кергән. Тома балавызның исе бик көчле бит аның...

– Тома балавыз?

– Әйе, китапча итеп әйтсәк, прополис була инде.

– Ә, ишеткән бар андый нәрсәне.

– Күрәсең, бу көлтә койрыкның эчендә туктаусыз бор-чучы берәр авыруы булгандыр. Ә җәнлекләр алар үзләренә үзләре доктор. Тома балавызны ашарга килгән. Мин аның белән берничә мәртәбә күзгә-күз дә очраштым. Тора-бара ул миннән бөтенләй курыкмый башлады. Күзгә күренеп тазарып, матураеп китте. Җәйгә чыккач, бермәлне югалып торган иде, балалап яткан икән. Көн-нәрдән бер көнне бу, өч баласын ияртеп, минем келәт турысыннан ике әйләнде. Янәсе, күр, менә минем нинди балаларым бар.

Әхмәт Дилүсович көрсенеп куйды:

– Әйе, сезнең өчен кадерле җан иясе булган бу. Кем уйлаган аны мылтык астына керер дип.

– Күрәсең, вакыты җиткәндер, – диде Мөдәррис абзый. – Аның каравы ул үзенең балаларыннан тыш тагын бер гомерне коткарып калды.

Әхмәт Дилүсович, умартачының сизгер күңеленә исе китеп, сүзсез калды. Аннары ул капыл гына урыныннан торды да:

– Ярый, – диде, – юл кешесенең юлда булуы яхшы. Сезгә барысы өчен дә рәхмәт.

Сәер кунак күңел төенен чишми китеп барды. Киткән вакытта ул, үз-үзенә сөйләнгәндәй: «Димәк, җәнлек балалары да ата-анасын коткару өчен үлемгә ташланмый», – диде. Бу сүзләрнең эчкәреге мәгънәсенә Мөдәррис аб-зый, әлбәттә, төшенмәде һәм бервакытта да төшенмәгән булыр иде. Ләкин беркөнне теге төлке оясы яныннан

үткәндә, аның күзенә йомарланып ташланган бер кәгазь кисәге чалынды. Мөдәррис абзый кәгазьне алды. Ул ярты ягы каядыр юкка чыккан хат кисәге иде.

«*Әти,* – дип язылган иде анда, – *сине агартыр өчен, мин карала алмыйм, бигайбә. Кем әйтмешли, синең инде җырың җырланган, ә минем яшисем бар әле. Бүтән миңа...*»

Хат шушы урында өзелгән иде. Мөдәррис абзый көрсенеп куйды. «Әй балалар, балалар! Ата-ана өчен берегез дә үләргә тормый шул. Бәлки әле, күп очракта үлү түгел, таяныр өчен иңегезне кую да җитәдер. Әмма түбән тәгәрәгән кешегә иңемне куйсам, югарыдагылар үземне яратмас дигән курку күңелегездәге шәфкатьне үтерә. Шул куркуны эчтән куалап чыгармый торып игелек эшләү авыр, бик авыр».

## ИТЕКЧЕНЕ ЧИТЕКЧЕ

Мәгъсүмгә әнисе бик матур сары ботинкалар алып бирде.

– Әнкәй, – диде Мәгъсүм, – мин бу ботинкаларны бик саклап кына киярмен. Табаны кыршылганчы итекчегә алып барып дага кактырам.

Әнисеннән акча алып итекчегә китте ул.

– Дагалап җибәрергәме, энекәш? – диде итекче, малайның кулындагы өр-яңа ботинкаларга ишарәләп.

– Әйе, түлке дагасы әйбәт булсын, караңгыда таш юлдан барганда ут чыга торган булсын, – диде Мәгъсүм. Чөнки ул күптәннән шундый «ут чәчә» торган ботинкаларга кызыга иде.

«Эһ» дигәнче ботинка әзер булды.

– Күпме бирим, абзый? – дип сорады Мәгъсүм.

– Илле тиен, энекәш.

– Ничек илле булсын? Сез бит бер абзыйга шундый ук дагаларны биш тиенгә кактыгыз. Аныкылар хәтта бераз зурраклар да иде әле.

– Их, энекәш, энекәш. Син берни дә белмисең икән: үзең әйтеп торасың бит, аңарга зуррагын кактың, дип. Зур нәрсә очсызрак, кечкенәсе кыйбатрак була. Примергә сәгатьләрне генә алып кара: стена сәгате нинди зур да, бәясе чыпчык төкреге генә. Кул сәгате сандугач күзе хәтле генә, ә бәясе синең бу ботинкаларыңнан ун тапкыр артык. Миңа гына ышанмасаң, кешеләрдән сора.

Малай ышанмый булдыра алмады. Чөнки мондый эшне белми иде ул.

Бу вакыйгадан соң ун ел үтте. Мәгъсүм телеательеда мастер булып эшли башлады. Язмыш кушуы буенча аңа беркөнне теге итекче килде. Җор сүзле, шаян табигатьле, шул ук вакытта үз файдасын да онытмый торган бу итекчене ул урамда еш күрә. Күрү генә түгел, кыйшайган туфлиләрен дә төзәттергәне бар. Кыскасы, бик таныш кеше иде итекче.

Телевизорының әллә ни ватык җире юк икән: бары предохранителен генә алыштырасы бар. Эш беткәч, аңардан итекче:

– Күпме бирим, энекәш? – дип сорады.

– Биш тәңкә, абзый кеше, – диде Мәгъсүм.

– Ничек инде биш тәңкә булсын, син бит бер кечкенә предохранителен генә алыштырдың. Моннан элек килгән мастер лампасы янгач та болай ук алмаган иде.

– Их, абзый, абзый. Син шуны да белмисең икән: кечкенә нәрсә һәрвакыт кыйммәт була ул. Миңа гына ышанмасаң, әнә кешеләрдән сора.

Итекче ышанмый булдыра алмады, чөнки ул бу эштә берни дә аңламый иде.

## КАРШЫЛАУ

– Ихсан абый, миңа машина кирәк, – дип килеп керде беркөнне колхоз идарәсенә агроном Рәис. – Хатынымнан телеграмма бар, Бөгелмә аэропортына каршыларга барам.

Колхозга быел гына килгән яшь агрономның тизрәк гаиләсен китертеп, төпләнеп калуын теләгән председатель бу хәбәрне бик хуплап каршы алды.

– Хатыныңның кайтуы әйбәт, – диде ул. – Ләкин, үзең беләсең, безнең җиңел машина ватык.

– Берәр йөк машинасы булса да ярар иде.

– Йөк машиналары урманда. Менә «Бензовоз» буш, шул барсын.

– Аның кабинасына ике кеше сыймый бит, – диде Рәис. – Мин үзем бармасам, хатынымны шофёр ничек танысын?

– Буен-сынын, төсен-битен сөйләп күрсәткәч таныр әле.

Рәис «Бензовоз» шофёрын эзләп тапты. Аның моңарчы беркемгә дә хатынының портретын сурәтләп күрсәткәне юк иде, ничек тасвирларга белми аптырап бетте.

– Матур гына йөзле, какча гәүдәле, егерме биш яшьләрдәге хатынны күз алдыңа китер инде, – дип башлап китте ул. – Чәче бакыр төсле, гәүдәсе какча булса да, йөзе тулы. Сөйләшкәндә бераз елмаебрак сөйләшә. Инде бу кадәр аңлаткач, бер күрүдә таныйсың син аны. Минем хатын үзенә бертөрле чибәр, әллә каян аерылып тора.

Рәистән шундый күрсәтмәләр алгач, «Бензовоз» шофёры Нур юлга чыкты. Аэропортка ул телеграммада күрсәтелгән вакытка килеп җитте. Буфетта тамак ялгап алганчы самолёт та төште. Нур самолёттан төшүче пассажирларның һәрберсен энә күзеннән үткәргәндәй җентекләп күзәтеп торды. Пассажирлар төшә тордылар, такыр җиргә сипкән борчактай тарала тордылар. Нур аларның һәрберсенең йөзенә карарга да өлгермәде. Тагын шунысы да бар, унсигезне яңа тутырып килүче яшь егеткә таныш булмаган кешеләрнең йөзләренә текәлү килешми бит. Боларга тагын Нурның хатын-кыз җенесенә бик үк туры карый алмавын да әйтсәк, аның аэропортта Рәис хатынын очрата алмавы бик яхшы аңлашылыр.

Әйе, Нур Рәиснең хатынын очрата алмады. Болындагы печән чүмәләләре ничек бер-берләренә охшаш булса, самолёттан төшүче кешеләр дә шулай бертөсле булып күренделәр аңа. Ялт-йолт карана торгач, шулай да ул Рәис сөйләп күрсәткән төслерәк бер кыз күреп алды һәм шатланып янына килде дә болай диде:

– Мин сезне алырга килгән идем.

– Что?

Кызның русча эндәшүен Нур үзенчә аңлады. «Рәиснең хатыны рус кешесе икән, нигә инде аны миңа әйтмәгән?» – дип уйлады ул. Аннары үзе дә русчалатып:

– Я за вами приехал, – диде.

– А кто вас послал? – диде кыз.

– Ваш муж...

Нурның «ваш муж» дигән сүзен ишеткәч, гаҗәпләнүдән кызның зур күзләре тагын да зурайдылар һәм ул, ачуланып:

– Что вам надо от меня? Уходите, ради Бога, не оскорбляйте девушку, – дип, Нурны куып җибәрде.

Шофёр егет үзе матур дип тапкан тагын берничә хатын-кыз янына барып карады. Ләкин аларның берсе дә Рәйсә булып чыкмады. Хәтсез вакыт шулай каңгырап йөргәч, кайту ягына борылды ул. Аэропортны чыгу белән, аңа берән-сәрән пассажирлар очрый башлады. Егетнең берсен дә утыртырга исәбе юк иде, ләкин үзеннән зур ике чемодан күтәреп, артыннан килүче машинага да борылып карамыйча баручы хатынны күргәч туктамый булдыра алмады.

– Утырыгыз, – диде ул ачулы гына һәм ишекне ачып куйды.

– Сез кайсы якка кайтасыз? – дип сорады хатын.

– Баулы ягына.

– Миңа да шул якка кирәк иде, бик әйбәт булды әле.

Чемоданның кечерәген кабинага урнаштырып, ә зурысын тышкы якка бәйләп кайтырга чыктылар. Шактый вакыт икесе дә сүзсез бардылар. 35–40 чакрым араны, бәлки, шулай бөтенләй сөйләшми дә кайткан булырлар иде, тик пассажир сүзчәнрәк булып чыкты.

– Нигәдер бик ачулы күренәсез, – диде ул Нурга.

– Эшең эш булмагач, ачулы буласың ул.

– Кәеф кыра торган нинди эш иде соң?

– Бер кеше каршыларга барган идем, тапмадым.

– Минә мине дә берәү каршы алырга тиеш иде, килмәде, – диде хатын, көрсенеп.

– Баулының үзенә кайтасызмы? – дип сорады егет.

– К. авылына, – диде хатын.

Ят кеше авызыннан үзләренең авылы исемен ишеткәч, Нур текәлебрәк хатынның йөзенә карады. Ләкин хатын искитәрлек матур булып күренмәде аңа. Ә Рәис абыйсы сөйләве буенча аның хатыны гүзәлләрнең гүзәле булырга тиеш. Шулай да ул:

– Ул авылда кемгә киләсез? – дип сорады.

– Ирем шунда эшли.

– Иregез кем соң?

– Сез аны белмисездер, яңарак килде әле ул, агроном, исеме Рәис.

Бу сүзләрне ишеткәч, егетнең рульдәге куллары ычкынып китә язды.

– Мин бит сезне каршыларга барган идем, – диде ул һәм ни өчен Рәиснең килә алмавын сөйләп бирде.

Кайта-кайта хатынны күзәтте Нур, әмма барыбер аны чибәр дип тапмады. Чөнки егет кешеләрдәге матурлыкны үзенең сөйгән кызы Әкълимә белән чагыштыра, ә сөйгән кешең барыннан да матуррак булып күренә дигән сүзләрне ишеткәне булса да, аның турында уйлап караганы юк иде.

## КАЙГЫРТУ

Мәрхәбә тормышка чыгуының беренче көннәреннән үк ире Сабирҗан турында кайгыртырга тотынды. Үзе больницада санитарка булып эшләгәнлектән, сәламәтлекнең иң зур байлык икәнлеген дә, аны таза чактан ук сакларга кирәклекне дә врачлардан һәр көн ишетеп тора иде. Үзенең тазалыгы Аллага шөкер, һәр әгъзасы сәламәт булганлыктан, аңа үзе турында кайгыртырга туры килми. Хәтта ул кайчакларда: «Ичмасам, берәр грипп вирусы да эләкми, һәркемгә тия торган чир дә мине читләтеп үтә», – дип зарлангалап та алгалый. Ә тормышка чыккач, Мәрхәбәгә үзенең врачлардан өйрәнгән осталыгын күрсәтергә җай чыккалап кына тора. Сабирҗаны кайвакыт ялгыш кына төчкереп җибәрсә дә, салкынрак су эчеп тамагы карлыкса да, Мәрхәбә таблеткаларын күтәреп килеп чыга һәм Сабирҗанның ай-ваена карамыйча, бик кадерләп төреп урынга яткыра, аннан инде ул даруларны кайнаган суда гына изеп сәгать саен иренең тамагына сала башлый. Йөргәндә дә аяк очларына гына басып, Сабирҗанына комачауламаска тырышып йөри. Ә инде Сабирҗанының бер генә градуска булса да температурасы күтәрелсә, эш харап. Ул чакта Мәрхәбәнең тамагыннан аш үтми, йөзеннән елмаю китә. Ул салкын суга манып алган тавык кебек бөрешеп, кечерәеп кала. Ләкин хатын үз хәсрәте белән үзе генә бикләнеп яши торган кеше түгел. Аның күңелендәге тышында. Өендә берәр чынаяк кына ватса да, шул ук көнне аны барлык күрше-тирә белгән була. Ә инде Сабирҗанның төчкерүе гадәттәгедән артыгракка китсә, Мәрхәбә, танышы саен кереп, ул хакта сөйли һәм авыруның хәлен белергә керергә куша.

Беркөнне Мәрхәбәнең сөекле Сабирҗаны эштән кәефсез кайтты. Иренең сытык чыраен күрү белән, Мәрхәбәнең йөрәге жу итеп куйды.

– Нәрсә булды, Сабирҗаным? – диде ул, түзем-сез-ләнеп.

– Берни булмады, – диде ире, – бераз арыткан, шул гына.

– Кая әле, температураңны үлчик, арыганныкы гына булырга охшамый бу. Бөтенләй төсең киткән бит. И Ходаем, чирләп кенә китмәсәң ярар иде. Тагын машинаңның тәрәзәләрен ачык йөрткәнсеңдер әле. Ничә тапкыр әйттем инде мин сиңа, кабина тәрәзәләреңне ачып куйма, дип. Тыңламыйсың бит, тыңламыйсың.

– Тәрәзәләрне ябып йөргәнгә шулай баш авырта да, – диде ире. – Көн буе бензин төтене сулап йөрисең, машинаның да рәте юк. Әз генә таудан менә башласаң да, котырган ишәк тавышлары чыгарып акырырга тотына, кабинага төтен тутыра.

– Ничә тапкыр әйттем инде, шул машинаңны ташла, дип. Бүтән эш тә бетмәс иде әле.

– Юк инде, нишләсәм дә машинамны ташламам.

– Шул машина дип бөтен сәламәтлегеңне югалтасың инде. Кая, градусникны бир әле, температураң күтәрел-мәдеме икән? – Ул градусникны алып карады. – Температураң юк икән югын, шулай да бернинди дарусыз ярамас. Әнә бит күзләреңә кадәр кызарып тора. Хәзер үк җылы су белән юын да юрганга төренеп ят. Минем монда тиешле даруларым бетеп киткән икән, йөгереп кенә аптекага барып кайтам.

Ире:

– Юкка йөрмә инде, минем авырган җирем юк бит, – дип караса да, Мәрхәбә аның сүзен тыңламады.

– Авыргач соң була ул. Безнең профессор, авыруны терелтүгә караганда булдырмау җиңелрәк, ди.

Мәрхәбә тиз генә киенеп аптекага китте. Юлда аңа Сабирҗанның дусты Хәким очрады. Мәрхәбә аны күрү белән хәлне сөйләп бирде һәм ахырдан:

– Син, Хәким абый, аның хәлен белеп чык инде, авыру кешенең күңеле китек була бит. Боегып ятмасын. Мин күрше Николайлар белән Габбасларга әйткән идем, алар, керербез, дип калганнар иде. Ләкин аларныкын белмәссең, әллә керәләр, әллә юк, – дип сөйләп китте.

Хәким шимбә көн итеп иптәше Михаилга барырга чыккан иде, Мәрхәбәнең сүзеннән соң үзенең мар-шрутын үзгәртмичә булдыра алмады. Михаил әзерләнеп көтеп тормасын дип, юл уңаенда телефон будкасына кереп, аңар

шылтыратты. Тегесе, эшнең нәрсәдә икәнен белү белән, үзе дә Сабирҗаннарга килергә булды. Ул Сабирҗан белән якын дус булмаса да, аны берничә мәр-тәбә Хәкимнәрдә очратканы бар иде. Дустының дусты авырып киткәч, хәл белергә бармасаң яхшы түгел дип, кибеткә кереп бераз күчтәнәчләр алды да Сабирҗаннарга китте.

Хәким килеп кергәндә, Сабирҗан янында ике ир кеше, ике хатын-кыз утыра иде. Сабирҗан, күршеләре хәл белергә керә башлагач, «чирле кеше»гә аяк өсте тору яхшы түгел дип, юрганга төренеп урынга ятты. Күршеләре керү белән, берәм-берәм дә, бергәләшеп тә аның хәлен сораштылар, кайда һәм ничек авырып китүе турында һәм тагын мең төрле сораулар бирделәр. Сабирҗан аларның барсына да бертөрле җаваплар бирә барды.

– Безнең, шофёр кешенең, – диде ул, – үзегез беләсез инде, эш шундыйрак. Салкында йөрисең. Машинаң ватылса, җиргә ятып төзәтергә дә туры килә. Бензин төтене дә иснисең. Өстәвенә машинам да бик яңадан түгел. Күрәсең, салкын тигәндер, баш авыртып тора. Менә хәзер бераз гына тамак та карлыккан төсле...

Сабирҗан янына кешеләр өзлексез килеп-китеп торды. Хәким килгәндә, аның янына 15 кеше килеп киткән иде инде, Хәким 16 нчысы булды. Сабирҗан хәзер, кешеләрнең сорый башлаганын да көтмичә, үзенең ничек һәм кайчан авырганлыгын сөйләп бирә. Хәкимгә дә ул теге күршеләренә сөйләгән сүзләрне сөйләп чыкты. Килгән бер кеше гомуми сораулар өстенә өстәмә сорау-лар һәм киңәшләр бирде. Һәркемнең соравына җавап бирә торгач, Сабирҗанның тамагы бөтенләй карлыкты, киңәшләрен тыңлап башы чатнарга тотынды. Ул тизрәк хатынының дару алып кайтуын көтеп ята башлады. 25 нче кеше булып хатынының дусты Сабира килде. Сабирҗан аңарга бары тик:

– Шофёр... машина... тамак... – дигән сүзләр генә әйтә алды. Башка сүз әйтергә аның теле дә әйләнми башлаган иде.

Озакламый аптекадан хатыны Мәрхәбә кайтты. Иң беренче эш итеп, өстен дә чишенеп тормыйча, Сабирҗаны янына килде һәм куркуыннан кулындагы даруларын төшереп җибәрде. Әйе, Сабирҗанның төсе, чынлап та, куркырлык иде, аның артык талчыгудан күзен ачарлык та хәле калмаган, авызыннан сүз урынына ниндидер гыжлау гына ишетелә.

– Ах, – диде Мәрхәбә. – Менә бит үз-үзең турында кайгыртмау нәрсәгә китерә кешене. Минем бер җирем дә авыртмый, нәрсәгә ул дару, дип торды бит, җитмәсә. Ах, бу ирләрне, үз-үзләрен саклый белмиләр дә.

## КЕШЕГӘ ДИП

Гыйльметдин карт кайтып кереп балтасын куярга да өлгермәде, карчыгы Гыйльмениса чәчрәп ире каршына килеп басты:

– Нишләп яттың шул гомер? Тагын берәрсендә әче балга чумып кайткансыңдыр әле. Яле, өр! Ә-ә, кур-касыңмы? Бүген әллә әзрәк эләктеме? Күбрәк тигәндә бик батырланасың бит.

– Ярар, карчык, чәпчемә әле. Мин бер стакан бал эчкән-гә дөнья җимерелмәгән. Лутчы самавырыңны яңарт, – диде ире, тыныч булырга тырышып.

– Самавыры качмас!

– Ә нәрсә качар соң?

– Менә син чыгып качарсың дип куркам, – диде карчыгы. – Теге Гөлзифа ничә көн килеп сине очрата алганы юк инде. Шуның өен эшләп бетерергә була бит. Бер бәп-бәләкәй өйне җәй буена сузасыз. Инде салган кысасы тузып килә, ә тәрәзәләрен куеп, шул карчыкны өй белән куандыра алганыгыз юк. Кем эчерә, шуныкын гына тырышып эшлисез.

– Соң, ул Гөлзифаның материалы да җитми бит. Аннары, хезмәт көненә кемнең эшлисе килсен. Бүтәннәргә эшләсәң, рәхәтләнеп ашап-эчәсең, акчасы була. Ә Гөлзи-фага колхоз эшләтә. Өйгә акча белән кайтканны үзең дә яратасың бит.

– Акчаны кем дә ярата инде аны, – диде Гыйльмениса карчык, йомшап. Үзе Гыйльметдиннең кирза итеге белән самавырын өрдерергә тотынды. Күп тә үтми, самавыр, чыпчык тавышы чыгарып, өзек-өзек сызгырырга тотынды. Озакламый ул сызгырулар ялганып, тоташ чыжлауга әйләнде, һәм самавыр бөтен тишекләреннән пар бөркеп кайнап чыкты.

Табын янында андый каты сүзләр әйтелмәде. Гыйльмениса карчык дәшми генә чәй эчәргә тотынды. Картының да әче балдан соң тамагы ярыйсы ук коргаксыган икән, ул да, аны-моны сөйләнмичә, берничә чынаяк кайнар чәйне каплап куйды. Чәй белән кипшергән тамакны юешләгәч, аларның тагын әкренләп телләре ачыла башлады.

– Атасы, – диде Гыйльмениса, эчә торган чәеннән дә кайнар итеп. – Үзебезгә дә өй салу турында кайгыртырга вакыт бит. Кешегә саласың да саласың, ә үзебезнең өебез җимерелергә тора. Идән ярыкларына мәче сыярлык, һәр көн абынып егылмыйча калганым юк. Көзгә керә башласаң, тишек-тошыкларны сылап бетермәле түгел.

– Мин үзем дә бу турыда күптән уйлыйм, анасы, – диде Гыйльметдин. – Уйлау белән генә эш барып чыкмый бит әле ул. Бүрәнә юк, бүрәнә. Персидәтел Садыйкның теңкәсенә тиеп беттем инде. «Менә озакламый колхозга диләнке алабыз, шул чакта карарбыз», – дигән була. Ә бригадир Салих: «Рәтләп колхоз эшенә чыкканың юк, сиңа бүрәнә бирәсе юк», – ди.

– Соң, атасы, чыккаларга кирәк. Хәзер бит инде колхозда эшләүчеләр дә начар яшәми. Акчасын да, икмәген дә бирә. Һич югы, өйлек бүрәнә алганчы әйбәт кенә эшләргә кирәк инде, – диде Гыйльмениса һәм, бераз уйланып торганнан соң: – Бүрәнәне колхоз биргәнне көтеп торганчы, үзебез генә сатып алабызмы әллә, атасы? Акча бар бит, – диде.

– Син нәрсә, әллә юләрләнә башладыңмы? Акчаның кирәк җире табылыр. Колхоз үзе бирәм дип торганда, акчага бүрәнә сатып алалармыни? Акча турында теш араңнан да чыгарма. Кеше ишетсә, идарәгә барып җитәр, аннан персидәтел дә кире уйлый башлар.

– Чыгарса, ул бит синең гомер буена балта чабып тапкан акчаң, урланган түгел, – диде карчыгы.

– Балтаны ничек чапсаң булмый аны, – дип каршы төште Гыйльметдин. – Шабашник дип, гәҗиткә төшерүләрен оныттыңмыни әле? Мескен булып кына йөрергә кирәк. Акча сандык төбендә ята бирсен, өй череп ауса да, алар череми. Өй тормаслык хәлгә килсә, колхоз үзе салып бирә ул.

Алар ирле-хатынлы икесе дә, акча турында теш арасыннан да чыгармаска кирәк, дип сүз беркеттеләр һәм, сүзләрен тагын бер чынаяк чәй белән ныгытып, табыннан тордылар. Шушы сөйләшүдән соң, Гыйльметдин карт сирәк-мирәк кенә булса да колхоз эшенә чыккалый башлады. Гөлзифа карчыкның да йортына тәрәзә яңаклары ясап бирде. Озак көтә торгач, Гөлзифа карчык яңа өйле булды. Салынуы әллә ни әйбәт салынмаса да, яңа өй яңа өй булыр әле дип, Гөлзифа аның ипләнеп бетмәгән тишек-тошыкларын балчыклар белән сылады. Утырып җитмәгән тәрәзә яңаклары арасына мәрхүм картының иске пальтосын сүтеп тутырды. Ишектән бик җил өреп тормасын дип, бозау тиресе кадаклатты. Идән сайгакларының ярыкларын да тычкан йөрмәслек итеп сылаштыргач, өй бер дигән булды.

Ләкин Гөлзифа карчыкка ул өйдә кыш чыгарга туры килмәде. Өйне тәмам өй итеп бетердем дигәч кенә, аның шәһәрдәге улыннан хат килеп төште. Улы яңа гына өч бүлмәле фатир алган икән. Әнисен моңа кадәр үзе янына алдыра алмавы өчен гафу үтенгән һәм хатны алу белән юлга җыена башларга кушкан. Вакытым булу белән, үзем кайтып алырмын, дигән.

Озакламый Гөлзифа бөтенләйгә улы янына торырга китте, ә өй хуҗасыз калды. Гыйльметдин карт бүрәнә сорап председательнең теңкәсенә тигәч, председатель шушы бушап калган йортны аңа бирергә булды.

– Менә, – диде ул, – синең бәхеттән җай чыгып тора. Гөлзифага салып биргән теге йортны үзеңә бирәбез. Барыбер тик ята. Әзер өй, саласы да юк. Рәхәтләнеп яши бирегез.

Ләкин Гыйльметдин карт бу хәбәргә шатланмады. Өенә дә ул тәмам бүселеп кайтып керде. Карчыгы, аның мондый кыяфәтен күреп, сорашырга тотынды:

– Нәрсә булды, атасы? Нигә авызың-борының салынган?

– Теге Гөлзифага салган йортны безгә бирәләр.

– Бигрәк әйбәт булган, аның өчен шатланырга кирәк.

– Син ни сөйлисең? – диде Гыйльметдин. – Ул өй-не без рәтләп эшләдек дип беләсеңме әллә. Аның бит бүрәнәсенең юнылганы юнылды, юнылмаганы юк. Мүге дә эләккән җиргә эләкте, эләкмәгән җиргә юк. Их, үземә буласын алдан белгән булсам, ничек итеп эшләргә белгән булыр идем мин аны.

– Сүтеп яңадан эшләрсең, – диде карчыгы.

– Сүтеп эшләсәң, сүзе була. Кешегә булгач яраган, ә үзенә ярамый, диярләр. Их, үземә буласын белмәдем шул.

## КАЧУ

– Хатын, коймагыңны майда йөздерә башла, мин кайттым, – дип килеп керүче ирен күргәч, Зөләйха тәгәрәп китә язды.

– Әстәгъфирулла! Әллә качып кайттыңмы? – диде ул.

– Син нәрсә? – диде Хәйбулла, үпкәләгән булып. – Исәнлек-саулык сорашу юк. Качып кайттыңмы, имеш. Үзеңне күрсәтә белсәң, кайда да кешене таныйлар икән. Менә кара: отпускы бирделәр.

– Үлмәсәң әллә ниләр ишетерсең, валлаһи, – диде Зөләйха, ире сузган кәгазьне карап, – төрмәдән дә отпускыга җибәрәләр диген, ә!

– Кешесе кем соң аның, – диде Хәйбулла, күкрәк кагып. – Син генә мине бәяләп бетермәгәч тә...

Хәйбулла үзен Берлинны алып кайткан солдаттай тот-ты.

– Мине, – диде ул, – гөбәдияләр, чәкчәкләр белән сыйлан, сары майда йөздерелгән коймак аша, сөтле кофе чөмер, сарык билдәмәсеннән пешерелгән токмачлы ашны умырып, хәл җыеп кил, дип җибәрделәр. Их, ял итеп күрсәтим әле!

– Бик әйбәт, – диде Зөләйха, – менә минем дә нәкъ син әйткән ризыклар белән рәхәтләнеп сыйланасым килә иде. Бәлки, без ресторанга гына барырбыз?

– Шәп фикер, шәп, – диде Хәйбулла, күзләрен елтыратып. – Баш бар үзеңдә. Тавык ботын кимерербез, мәен чөмерербез. Юкса тегендә өч ел буе андый нәрсәләр күрмичә эчләр кортлады. Әйдә, хатын, киенә башла. Мин дә өс-башны алыштырыйм.

Хәйбулла тиз-тиз генә юынып чыкты да кием шкафын ачты.

– Хатын! – диде ул бераздан. – Минем теге яңа соры кәчтүм күренми, әллә берәр яры алып куйдыңмы?

– Әйе, – диде Зөләйха, – еракка очты синең яңа кәч-түмең.

– Кая?

– Синең корсакка.

– Аңлатыбрак сөйлә әле, хатын. Йә ачуландырыр-сың.

– Нәрсәсен аңлатасың инде аның. Син бит тәмле ашарга яратасың. Әзме ташыдым мин сиңа передачалар. Әллә син акча җибәреп тордыңмы?

– Ярар, ярар, искеләрне искә төшермә. Теге кара кәчтүмне генә бир дә.

– Кара кәчтүм дә үтүт.

– Ансы кайда тагын?

– Бәләкәйләттереп, малайга тектердем.

– Малай кайда соң?

– Авылда, әниләрдә.

– Уф! Мине кайтмаска китте дип уйладыңмы әллә? Ну бу хатын-кызны! Бер дә үзеңнекеләрне сатмагансыңдыр әле.

Хәйбулла шкафтан хатынының кием-салымнарын бар-лый башлады.

– Синең чәшке якалы зәңгәр пәлтәң кая?

– Адвокатыңнан сора.

– Теге калын йон күлмәгең дә күренми.

– Сүтеп, кызга свитер бәйләдем. Мәктәпкә шәрә йөр-теп булмый бит.

– Син нәрсә, – дип кызып китте Хәйбулла, – өч ел эчендә бөтен тормышны пыран-заран китергәнсең. Мин-мин дигән буласың тагын. Дөньяңны мин генә тотып торганмын икән. – Хәйбулла, кызуын баса алмыйча, ишекле-түрле йөрде. Шулай йөргәндә, аның башына бер уй китереп сукты: – Ә-ә, – диде ул, – син бөтен әйберне сатып акчага әйләндереп барасың. Синең эчеңә акча корты кергән. Акча хатын-кызның бер чире инде ул.

– Акча? Нинди акча? – диде Зөләйха.

– Нинди булсын?! Кәгазь акча. Хатын-кызга гомер буе шул җитми бит.

– Булса җитәр иде, кулга сирәк керә шул ул.

– Сирәк керсә, ресторанга гына барып ашыйк, димәс идең әле.

– Ә мин бит тавык боты кимереп, коньяк чөмереп, гөбәдия, чәкчәкләр белән чәй эчәргә дигәч, син бик баеп кайткансыңдыр дип уйлаган идем.

– Баерсың анда. – Хәйбулла, хыялларының җиме-релүен күреп, диванга сузылып ятты. – Кәнсә кәнис берәр нәрсә бардыр бит инде ашарга.

– Бардыр.

Зөләйха дөбер-дөбер бәрәңге юарга тотынды. Бераздан өйгә бәрәңге исе таралды. Борыннарны ярып суган исе керде.

Ярып пешерелгән бәрәңгене суган белән ашап, артыннан чәй эчеп куйгач, Хәйбулланың күңеле күтәрелеп китте.

– Кайгырма, хатын, – диде ул, – тагын ике елдан мин бөтенләйгә кайтам. Менә шунда яшәп күрсәтербез ичмасам.

Хәйбулла ике көн кунак булды: хатыны пешергән бәрәңге, макарон белән сыйланды. Өченче көнне хатыны аңа:

– Кунак көне – өч, өчтән артса – көч, моннан соң ашарга-эчәргә үзең әзерләрсең, – диде. – Мин эштән кайтуга аш пешкән, өй җыештырылган булсын.

– Ә акча?

– Акча әнә шунда, тартмада. Бөтен айлык акча шул, саклабрак тот.

– Болай булгач, эшләр пешә, – дип сөенде Хайбулла һәм, хатыны чыгып китүгә, тартмадагы акчаны тартып чыгарды. – Тизрәк кибеткә барып, бер савыт белән бер тавык апкайтырга кирәк. Кәеф күтәрелгәч, бәлки, кино карап кайтырмын. Хәзер секс-микс турында кинолар күп диләр. Ирекле тормышның кадерен белеп калырга кирәк. Их, шәп бит, ә? Төрмәдән хатын янына ялга җибәрәләр. Менә килде заман. Рәхмәт ил башлыкларына.

Хәйбулла шундый уйлар белән кибеткә китте. Әмма кибеттәге әйберләрнең бәяләрен күрүгә үк кикриге шиңде аның. Әле кесәсендәге акчага, әле кибеттәге әйберләргә карап озак йөрде ул. Нәрсә генә алсаң да, акча бетәр сыман. Ә Хәйбулланың хатыны алдында булдыксыз күренәсе килми иде. Шул ук вакытта тәмле итеп ашыйсы да килә. Ысланган колбасалар, әллә нинди чит ил ризыклары тутырылган пакетлар, консервылар яныннан күзен йомыбрак үтте Хәйбулла. Сөттер, ипидер ише нигъмәтләр алганга да кәшилүк җиңеләеп китте. Ярый әле Зөләйханың өйдә бер шешә көнбагыш мае бар иде, хатыны кайтуга шул майда макарон кыздырып куйды Хәйбулла.

– Пешерергә осталыгың бар икән, – дип мактый-мактый ашады Зөләйха. – Иртәгә дә мин кайтуга берәр нәрсә әзерләп куй.

Хәйбулла кибеттән кибеткә чапты. Бәрәңге, кишер, кәбестә ише нәрсәләрнең арзанрагын эзләде. Майдыр, шикәрдер ише әйберләрне читләтебрәк үтәргә тырышты. Тик барыбер кәшилүк юкарганнан-юкарды. Җитмәсә, йортлар идарәсеннән дә кәгазь килеп төште. Фатир өчен түләү арткан икән. Шуны ашыктыралар. Аннан элек кенә электр белән радиога акча сораганнар иде.

– Уф! – диде Хайбулла, – түзәр хәлем калмады, качам. – Һәм ул кәгазь-каләм алып язарга тотынды.

«Хатын, миңа үпкәләмә. Мин болай яши алмыйм. Ялым беткәнне дә көтмичә кире төрмәмә китәм. Анда, ичмасам, тегесенә-бусына акча ничек җиткерим дип баш ватасы юк. Ашаталар, эчертәләр. Өс-башны карыйлар. Кием-салымнарны саткан өчен бик ачуланган идем, гафу ит. Син гаепле түгел, ил башлыклары гаепле икән моңа».

Кәгазьне өстәлгә булавка белән кадап, төенчеген җилкәсенә асты да Хәйбулла төрмәсенә сыптырды.

## КҮҢЕЛЛЕ СӘЯХӘТ

Сүз куешкандай, өч алкаш аракы кибете янына берьюлы килеп басты. Алар, бер-берләренә карашып, кесә төпләрен кармаладылар. Кесәләрнең төрлесен кабат-кабат актара торгач, өчесенә бер яртылык акча җыелды.

– Шә-әп! – дип куйды зәңгәр борынлысы, телен ялмап. – Башын башларга булды.

– Глауный эшне башлау, аннары үзеннән-үзе китә ул, – дип хуплады интеллигент кыяфәтле, алтын кысалы күзлек кигәне.

– Киттек! – диде күн курткалысы һәм, җыелган халыкны ерып, кибет эченә атлады.

Аның артыннан тегеләре иярде. Әмма аларның юлы уңмады: аракының бәясе күтәрелгән иде. Алар киштәгә тезелешкән шешәләргә авыз суларын корытып карап тордылар. Күзләреннән мөлдер-мөлдер яшьләр тәгәрәде.

– Егетләр, – диде зәңгәр борын, җиңе белән күзен сөртеп, – безнең әтиләр Берлинны алганнар, неужели без бер җаен тапмабыз?

– Табарбыз, без батырлар токымыннан, – дип җөпләде аны алтын кысалы күзлек.

– Мин таптым да инде, – диде күн куртка.

Һәммәсе аңа борылып карады. Телләр авыз эчендә әйләнеп алды. Күзләрдә өмет чаткысы кабынды.

– Беләсезме, – дип дәвам итте күн куртка, – Уфада аракы очсыз икән. Кичә хатын Уфадагы сеңлесе белән телефоннан сөйләшкән иде. Анда безнекенең яртысы гына, ди. Бу акчаларга без анда бер литр алабыз. Киттек Уфага!

– Киттек! Киттек!

– Ә юлга акча? – диде зәңгәр борын.

– Менә моны күрдеңме? – диде күн куртка, интеллигент кыяфәтле ахириенең алтын кысалы күзлегенә карап. – Хәзер күзлекләр ярты автомобиль бәясе.

Алар, вокзалга барып, күзлекне бик әйбәт бәягә сатып җибәрделәр.

– Моның кадәр акча булгач, Уфага барып йөрисе дә юк инде, – диде берсе.

– Барабыз! – диде икенчесе. – Мондагы ярты бәясенә анда бер литр алып булганда ничек инде бармаска?!

– Дөрес сукалыйсың, – диделәр аңа һәм, өчесенә бер билет алып, Уфага киттеләр. Вагон сәкесенә сузылып яткач, берсе җыр башлады:

Уфаларга барам әле,
Уфа юллары ачылса...

– «Барам» түгел, «барабыз» дип җырла, монда бит син берүзең генә түгел. Нигә ул кадәр эгоист булырга? – диде күзлексез калган интеллигент.

– Ярар, ярар, – диде җыр башлаучы. – Күңелегез булсын.

Уфаларга барабыз әле,
Уфа юллары ачылса.
Уф, йөрәгем, димәбез әле,
Янулары басылса.

– Менә шулай! – дип хупладылар аны. Хуплау сүзе ишеткәч, җырчыбыз дәртләнеп китеп яңа җырга тотынды:

Уфаларга барган чакта
Бәләбәйләр сул якта...

Әмма ул җырның яртысына җитүгә, күн куртка урыныннан сикереп торды.

– Юк, – диде ул, – Уфаларга барган чакта Бәләбәйләр уң якта.

– Син үзең уң якта, – диделәр аңа.

Вагонда бәхәс купты.

– Сул якта!

– Юк, уң якта!

– Ә, шулаймы, уң яктамы?

Болар бер-берләренең якасына ябышырга торганда, вагонга кондуктор кыз килеп керде.

– Билетларыгыз? – диде ул.

Күзлексез калган интеллигент кесәсеннән билет чыгарып, кондукторга сузды.

– Ә сезнеке? – диде кондуктор.

Тегеләр ык-мык килеп торган арада, күзлексез интеллигент:

– Иптәш мадемуазель-туташ-ханым, – диде кондукторга, – алар бит кешеләр түгел, шуңа күрә билетлары юк.

– Ничек «кешеләр түгел»? – диде яшь кондуктор кыз. – Ә кемнәр соң алар?

– Алар – минем багажым!

– Багажыгыз?

– Әйе. Нигә аңа аптырадыгыз? Багажның ниндие булмас?! Дөнья бит бу!

– Юк, бу номерыгыз үтмәс! Хәзер милиция чакыртам да багажыгыз-ниегез белән шунда тапшырам!

– Моя милиция меня бережёт, – диде бер «багаж», җанланып.

– Я – гражданин Советского Союза, мой дом Советский Союз, – диде икенче «багаж».

Интеллигент аларның кабыргаларына төртеп алды һәм, кондуктор кызга карап:

– Аларның сөйләшүенә аптырамагыз, мадемуазель-туташ-барышня. Алар – кеше төсле итеп ясалган магни-тофоннар. Әнә кнопкаларына баскач туктадылар, – диде.

Кондуктор кыз вагоннан чыгып китте. Бәладән башаяк дигәндер, күрәсең. Өч ахир җырлап арыгач йоклап алды. Бер тәүлек дигәндә, Уфага килеп җитте алар. Аракы монда чынлап та арзан икән. Күзлектән калган акчаны кушып җибәргәч, тап-таман ике шешәлек булды.

– Менә бит ул башың эшләсә, – диештеләр алар. – Хәзер боларны протокол язып тормыйча гына оформить итеп куярга кирәк. Тизрәк стакан табарга!

– Туктагыз әле! – диде интеллигент. – Болай ярамый бит инде. Моның кадәр байлыкны кулга төшергәч, чын рәхәтен күреп, тәмле кабымлыклар белән, берәр җылы җирдә озаклап, ләззәтләнеп утырырга кирәк. Яратмыйм мин голт-голт кына йотып куярга.

– Юк инде, – диде зәңгәр борын, – минем бүтән түзәрлегем калмады. – Һәм ул шартлатып шешәнең төбенә китереп сукты. Шешәнең бөкесе, һавада дуга ясап, күзлексез интеллигентның маңгаена килеп чәпәлде. Шешә бер кулдан икенче кулга күчеп ике әйләнеш ясауга, безнең сәяхәтчеләребезгә җан керде.

– Син нәрсә кабып эчмәкче идең? – диде зәңгәр борын интеллигент дустына.

– Нәрсә белән дип... Беткәнмени ысланган колбаса, маринадланган балык ише вак-төякләр.

– Ә-ә, син шулай баймыни әле? Алайса бар, кибеткә кер дә теләгән нәрсәләреңне алып чык. Икенче яртыны синеңчә ләззәтләнеп, җырлый-җырлый эчәрбез.

– Менә бит акча, – диде интеллигент, күн курткалы дустының җилкәсеннән сыпырып. – Бу минем күзлектән кыйбаткарак китәр, пожалый.

Күп уйлашып тормастан, күн курткалы дусларын чишендерделәр. Куртка чынлап та шәп бәягә китте. Кулларына моның кадәр акча кергәч, өч ахири нишләргә белми аптырап калды. Ниндидер каткан колбасага, черегән балыкка акча әрәм итәселәре килмәде аларның.

– Бу Өфе каласында ашамлыклар артык кыйбат икән, – диде күзлексез интеллигент, ашаудан өметен өзеп.

– Әйе, – дип раслады курткасыз дусты.

– Ярар, борыннарыгызны салындырмагыз әле, – диде зәңгәр танау, – мин барында югалмассыз. Ә беләсезме ашау-эчү әйберләре кайда очсыз?

– Кайда?

– Ульянда!

– Алайса әйдәгез, киттек Ульянга!

– Туктагыз, тукта, ашыкмагыз, – диде зәңгәр танау, – моннан тагын бер-ике ярты алыйк, вагонда аларны кагарбыз, ә Ульянда кабымлыгын кабарбыз. – Ул үзенең шагыйрьләрчә сөйли белүенә сөенеп кеткелдәп көлеп алды.

Кеше башына тагын берәр шешәне кесәгә салгач, алар вокзалга юнәлделәр. Билетка акча җәл иде.

– Әллә соң бу юлы бөтенебез дә багаж гына булабызмы? – диде берсе.

– Юк! Хуҗасыз багажны бик тиз чәлерләр. Бер билет алмый булмас.

Ярты сәгать киңәшеп, бер шешәне бушаткач, бер билет алып, Ульянга киттеләр.

Юл хәвеф-хәтәрсез үтте. Билет тикшерүче булмады. Ахирләр, Ульян каласына килеп җиткәч, чак чәкәләшми калдылар. Берсе, билетны син алдырдың, ди. Икенчесе, юк, син, дип, якасына ябышты.

Өч ахири арасында шешә бер әйләнеш ясап алгач кына, кызулыклары сүрелде. Ульян каласының үзәк урамында, «Сарман» көенә җырлый-җырлый, очсызлы ризыклар сата торган кибет эзләде алар. Биредә Казан белән Уфага караганда ашамлыклар, чынлап та, шактый арзан икән. Ике тәүлеккә якын ризык күрмәгән корсакларын шыплап тутырдылар. Корсак ныграк тулган саен, кесәләре бушый төште. Ләкин моңа аларның һич исләре китмәде. Чөнки күңелләрдә бик шәп план туган иде. Планны әлеге дә баягы зәңгәр борын уйлап тапты.

– Егетләр, – диде ул, – сез минем иң күп белүче икәнлегемне күрдегез инде. Хәзер минем акыллы башка шундый фикер килде. Әйтимме?

– Әйтәсең килсә әйт әйдә.

– Әйтәсем килә, потому чты сез минем иң якын туганнарым кебек. Аның үз сүзләреннән күңеле йомшап, күзе яшьләнде. – Әйтәм алайса. Йә, әйтимме?

– Әйт инде, әйт, юкса йокы килә.

– Менә-менә! Минем дә нәкъ сезнеке шикелле йокым килә. Әмма ләкин мин Ульян урамына сузылып ятарга җыенмыйм. Минем караватта йоклыйсым килә.

– Безнең дә караватта йоклыйсыбыз килә.

– Ә сез беләсезме иң очсызлы... – Зәңгәр борынны очкылык тота башлады. Дуслары аның чикылдаудан туктавын көттеләр. Ниһаять, зәңгәр борын сүз әйтерлек хәлгә килде. – Иң очсызлы кунакханә... Тфү, шайтан, телгә әллә ниләр килә. Иң очсызлы «Айныткыч» кайда?

– Кайда?

– Чабаксарда! Минем хатынның әнисенең тутасы шунда яши. Ул белә. Әйе, ул белә. Киттек Чабаксарга! Тик карагыз аны: билетка акча әрәм итәсе булмагыз.

Алар, кочаклашып:

Зимагурлар талчукта,
Кайгырмыйлар мал юкка, –

дип җырлый-җырлый, вокзалга киттеләр. Юллары- бу юлы да уңды. Билетсыз утырган өчен кондуктор аларны милициягә тапшырды, ә милиция туп-туры «Ай-ныткыч»ка озатты. Иртәгәсен Чабаксарның иң очсызлы «Айныткыч»ында кунган өчен зәңгәр борынның ботинкасын сатып түләделәр дә, соңгы тәңкәләрен җыеп, хатыннарына телеграмма суктылар. Өч телеграммада да бер үк сүзләр иде: «Сөекле хатынкаем, синең газиз иреңне

кораллы бандитлар заложник итеп Чабаксарның вокзалында тоталар. Тизрәк коткарырга килеп җит. Бөтен нәрсәне сатсаң сат, мине бу явызлар кулыннан гына коткара күр!»

Шул ук төнне өч гаиләдә өч хатын, кораллы бандитлардан алып ил башлыкларына кадәр нәләт яудыра-яудыра, Чабаксарга таба юл тотты.

## САГЫНУ

Эшкә барганда да, кайтканда да мин кырык яшьләр тирәсендәге бер ирне күрәм. Аның өстендәге киеме эш өчен артык кыйммәтле, ә бәйрәмнәрдә яки кунакка барганда кияргә шактый пычранган һәм таушалган күренә. Соры костюмның затлы материалы, автобуста эшкә баручы-кайтучы дегетле киемле нефтьчеләргә ышкылып, күптән үзенең төсен югалткан, бары тик култык асларында калган чиста урыннар гына бу костюмның кайчандыр әйбәт тукымадан эшләнгәнлеген әйтеп тора. Һәр күргәндә бер үк киемнән булгангамы, әллә автобуста буш урыннар барында да шофёр янында басып йөргәнгәме, бу ир минем күңелемне тиз җәлеп итте. Кайчакларда урыным шушы ир янына туры килгәндә, аңа сүз катмакчы булып авызымны ачам, ләкин ирнең йөзендәге игътибарсызлык, сүзләремә битарафлылык мине туктатып кала. Вакыт узган саен, бу ир белән сөйләшү теләгем арта бара. Аның беркем белән дә сөйләшмәскә ант иткәндәй ныклап кысылган иреннәрен, юлдан нидер эзләгәндәй һәрвакыт алга төбәлгән күзләрен күргән саен, шушы ниятем көчәя. Очраклы рәвештә килеп чыккан бер күңелсез хәл булмаса, мин, бәлки, аның белән озак сөйләшә алмый йөргән булыр идем әле.

Ул көнне автобуста галәмәт кысан иде. Безнең мар-шруттагы бер скважинада узган төнне авария булган. Төн-лә шушы аварияне төзәтергә барган эшчеләр бер тукталышта өерләре белән безнең автобуска кереп тулдылар. Машинада этеш-төртеш китте. Берәүләр тозлап-борычлап шофёрны сүктеләр, әйтерсең машинаның тыгынлыгына ул гаепле. Икенчеләр шофёр янында басып торучы теге иргә ябырылдылар.

– Син дә монда буталып йөрисең, җылы өеңдә ятсаң ни була? – диде бер ачулы йөзле, чәрелдек тавышлы ир.

– Ул бит шофёрның тән сакчысы, – диде икенче калын тавыш. – Ул йөрмәсә, безнең Баһавины урлап качулары бар.

– Куып төшерергә кирәк үзен, – дип кычкырды беренче тавыш. – Кеше монда ирексездән йөри, ә ул ирекле көннән үзенә эш тапкан. Берәр вакыт эчәкләрен сытып чыгарсалар, йөрүдән туктар иде инде.

Башка вакытта, бәлки, бу сүзләргә беркем дә игътибар итмәгән булыр иде, әмма бүген машинада искиткеч тыгын, сулыш алгысыз тынчу, шуның өстәвенә эшчеләрнең күбесе тынгысыз сменада эшләп арыган булганлыктан, артык пассажирга ачулары чыкты һәм, бер дә тартынып тормыйча, аны куып төшерделәр. Күңелемдә бу кешене кызгану тойгысы туды. Төнге сменада эшләп шактый арыган һәм йончыган булсам да, автобустан төшеп калдым.

Башта бераз сүзсез генә бардык. Һәрвакыт бу кешене басып торган килеш кенә очратканлыктан, аның йөргәнен күргәнем юк иде. Ул аягын көчкә генә сөйри, сул як кулы да хәрәкәтсез килеш, тагып куелган авыр әйбердәй җилкәдән асылынып төшкән. Мин, аның кыенлык белән генә атлавын күргәч:

– Сезгә җәяү йөрү читен бит, машина көтик, – дидем.

Ул, миңа борылып карамый гына:

– Мине һәрбер шофёр таный, минем янда бер машина да туктамаячак, сез дә юкка төшеп калгансыз, – диде. – Хәзер инде никадәр араны җәяү кайтачаксыз.

– Минем аякларым сау, берничә чакрым ара кайту миңа берни тормый, – дидем мин. – Сезгә генә кыенрак-тыр.

Ул дәшмәде.

– Кая барган идегез? – дидем мин, соравым бик урынлы булмаса да.

– Кая барыйм мин?! – диде ул гаҗәп бер төшенке тавыш белән. – Минем кебек кеше эшкә йөрми инде. Күрмисезмени бу кулны, сөяксез нәрсә шикелле асылынып төшкән. Ә бит мин шушы куллар белән кайчан гына әле авыр «МАЗ»ларда баранка әйләндерә идем... – Ул сүзеннән туктап көрсенеп куйды. Аннары үз-үзенә сөйләнгәндәй әкрен, тонык тавыш белән сөйләп китте: – Балаларның, бигрәк тә ир балаларның, үсмер чакта хыяллары зурдан була. Күкне ярып үткән самолётны күреп, үзләренең дә очучы – зәңгәр биеклекләрне буйсындыручы, хыял җитмәслек киңлекләрне иңләүче буласылары килә. Яки ерак диңгезләрдә йөзүче, йөзләре салкын җилләрдә каралган капитаннар күңелләрен били. Балалар аларга охшарга тырышалар, корабль мачталарыннан да биегрәк агачларга менәләр, елга сулары җылынып та җитмәстән су коеналар. Мин дә шундый малайларның берсе идем, самолёт күрсәм – очучы, машина күрсәм – шофёр, трактор күрсәм, тракторист буласым килде. Ба-ла-чага гел күреп, һәрвакыт очрап торган нәрсәләрдән йә тәмам туя, йә аңа бик нык ияләшә. Малай чакта миңа иң күп күрергә туры

килгән нәрсә машина булды. Туган авылым матур елга буенда утыра иде, ә су буенда вак таш-гравийның чутсыз-хисапсыз иканлеген беләсездер. Менә шушы табигый байлыкның оясына урнашкан авылыбызга бензин исләре, машина гөрелтеләре һәм төрле телләрдә төрлечә җырлана торган шофёр җырлары алып, бер авторота килеп урнашты. Алар безнең су буеннан каядыр еракка гравий ташый башладылар. Белмим, кемгә ничек тәэсир иткәндер, әмма минем өчен боларның килүе зур бәйрәм булды. Мин, үземә карарга тапшырылган каз бәбкәләрен комсыз тилгәннәр һәм туймас тамак каргалар иркенә калдырып, көннәр буе машиналар янында чуала башладым. Алардан таралган бензин исләре миңа иң тәмле хушбуйлардан тәмлерәк тоела иде. Мин, чын шофёрлар сыман, дегеткә батып, киемнәремне буяп йөри башладым. Моның өчен әнинең тиргәүләрен аз ишетергә туры килмәде, билгеле, ләкин абыйның солдат каешы белән сыртымны каезлавы да, әнинең елый-елый ачулануы да, ашарга бирмичә өйдән куып чыгаруы да минем машинага булган мәхәббәтемне сүндерә алмады. Әйе, мин мәхәббәтемне димен. Бер тапкыр да руль тотып карамаган, бер мәртәбә дә юлда йөрү рәхәтен тоймаган килеш машинага мондый мәхәббәт бала йөрәгенә ничек һәм каян килеп урнашкандыр, белмим. Әмма һич арттырусыз әйтәм, әгәр миңа шулвакыт «бәрәңгене дегеткә манып ашасаң, шофёр буласың» дисәләр, бернинди икеләнүсез, куркусыз ашаган булыр идем.

Юлдашым әллә тәэсирләнеп сөйләүдән, әллә арудан тирләп чыкты. Ул маңгаеннан бәреп чыккан эре тир бөртекләрен учы белән сыпырып ташлады һәм, юк-бар-ны сөйләвем өчен гафу итегез дигәндәй, миңа ялварулы, нәүмиз караш ташлады. Мин аңа бераз ял итәргә тәкъдим иттем. Юлдашым карышмады, без икәүләп юл буендагы чирәмгә утырдык.

– Юк-бар белән сезне туйдырган булсам, мине тыңламагыз, – диде ул, – мин сездән дә бигрәк үземә сөйлим. Үзем яраткан нәрсә турында мин шулай кайвакыт кычкырып уйларга яратам. Янымда сез булмасагыз да, мин барыбер сөйләнеп кайтыр идем. Шулай берүзем тыкылдап йөрүем өчен мине хәзер бала-чагалар гына түгел, кайбер зурлар да тилегә саныйлар. Санасалар, әйдә санасыннар, мин анысы өчен бер кешегә дә рәнҗемим. Әйе, бер кешегә дә үпкәм юк, ләкин кулларымнан машина рулен тартып алып, минем бөтен киләчәгемне чәлпәрәмә китергән язмышыма рәнҗим. Шушы язмыш киртәләрен җимереп ташларлык көч булмавы мине гаҗиз итә.

– Кайчан болай авырдыгыз соң? – дип сорадым мин.

Юлдашым минем соравымны әллә ишетмәде, әллә ишетеп тә җавап бирмәде. Юл буенда үскән бәбкә үләненә сузылып ятты да, болытларга карап, сүзен дәвам итте:

– Машина кабинасында шофёр белән рәттән утырып, йөгереп артта калучы юл тасмасын күзәтеп баруның ни-кадәр рәхәтлек биргәнен белсәгез иде. Ләкин шофёр янына эләгер өчен, бердән, русча белергә кирәк, чөнки шофёрларның күбесе руслар; икенчедән, рөхсәт сорарга кыюлык кирәк. Аннары, сорап та сине утыртырга тормыйлар. Әмма баланың йөгерек акылы һәркайда җаен таба. Без дә, машина яратучы берничә малай, кабинага утыру җаен таптык. Кайбер шофёрларның чәчәк яратуларын белеп алдык та аларга әрәмәдән кочагы-кочагы белән чәчәкләр ташый башладык. Менә шушы чәчәкләр безнең тел белмәвебез аркасындагы аңлашылмауларга да, кыюсызлыгыбызга да чик куйды. Олы юлга чыгып- чәчәк бәйләме күрсәтсәң, сине аңлаучы тиз табыла. Чәчәк яратмаучы шофёрлар яннан тузан туздырып үтеп китсәләр, чәчәк яратучылары шып туктап, чәчәгең-ниең белән күтәреп алалар да көннәр буе үзләре янында йөртәләр. Шулвакыт ашыйсы килүләрең дә, ару-талуларың да, өйгә кайткач әниләрнең орышулары да онытыла. Син үзеңне машинаның бер детале кебек сизә башлыйсың: үргә мен-гәнгә мотор үкереп-көчәнеп тартса, син дә көчәнәсең, түбән төшсә, мотор тигез эшләсә, синең дә күңелеңдә җи-ңеллек туа, сулышың тигезләнә...

Үсмер чакның шушы мавыгулары минем бөтен тормышыма юнәлеш бирде. Мин шофёрлыктан башка һөнәрне күз алдыма китерә алмадым. Җиде классны тәмамлау белән, колхоз идарәсенә барып, берәр шофёрга йөк төяүче итеп куюларын сорадым, чөнки, яшем җитмәгәнлектән, шофёрлар курсына укырга алмыйча җибәргәннәр иде. Ә колхозда һәр эшче өчен бригадирлар үзара сугышырга әзер тора. Шуңа күрә минем гәүдәмнең кечкенәлеге дә, яшем җитмәү дә киртә була алмады. Шушы тотынудан ике елга якын йөк төяүче булып эшләдем. Сабанга тотынып тәпи баскан, буразнада буын ныгыткан авыл кешесе өчен бу эш авыр тоелмады. Ә инде курсларга керергә яшем җиткәндә, мин машина моторын биш бармагым кебек белә идем, шуңа күрә курсларда укуы бик җиңел булды. Армиягә киткәндә беренче класслы шофёр идем, ләкин анда бөтенләй башка частька эләккәнлектән, беразга баранканы ташлап торырга туры килде. Чик буенда сакта торганда, машинамны сагынып, нишләргә белми, кулларымны уа идем. Төшләремдә үземне руль артында күрәм, йөрәгем, Сабантуйны ашкынып көткән чабыш атыдай, машинага утырасы көннәрне җиткерә алмый интегә. Бәхет бар икән: анда да, бераз хезмәт иткәч, машина бирделәр. Батальон командирын йөрттем.

Хезмәтемне тутырып кайткач, менә бу нефтьле як-лар-га эшкә килдем. Бу якларда мин бармаган буровой, машинамның эзе төшмәгән юл юктыр. Мактанып әйтүем түгел, юлның иң кыенына мине җибәрәләр иде. Мин үзе-

мә күрсәтелгән мондый ышаныч белән горурлана идем. Миндә авырлыкларны җиңү горурлыгы, профессиям белән горурлану тойгысы туды. Шушы эшче горурлыгы, пычрак җирләрдә батып ятканда, таулы юлларда тәгәрәп төшү куркынычы туганда, миңа көч бирде, салкын җирләрдә җылытты.

Сез минем ничек авырып китүем турында сорадыгыз. Эш ничек авырып китүдәмени? Эш тормышта үз урыныңны югалтуда. Менә йөрәкне иң әрнеткәне шул. Кулларыңда эшең булмагач, аяк астыңдагы җирнең катылыгын тоймый башлыйсың, кешеләргә карата ышанычың кими. Кешелек горурлыгыңны югалтасың. Менә, туган, аның шунысы авыр.

Мин юлдашымның йөзенә карадым, ул газаплана иде. Моңа чаклы шофёрлыкның шулкадәр мавыктыргыч эш икәнлеге турында уйлап та караганым булмады. Гомумән, кешеләр үз һөнәрләрен бу кадәр яраталардыр, профессияләре белән горурланалардыр дип башыма китерми идем. Эшче горурлыгы турында газета-журналлардан күптән ишетеп килгән сүзләрне бу эшләү бәхетеннән, хезмәт рәхәтлегеннән мәхрүм ителгән кеше авызыннан ишеткәч, мин бөтенләй тетрәп киттем, үземнең җиңел генә оператор булып китүем, ата-ана кул астында ун класс бетерүем исемә төште, операторлыкны мин шунсыз тора алмаганга түгел, ә нинди дә булса эш эшләргә кирәк булганга гына сайладым. Моңа кадәр минем күңелемдә үз профессиям белән горурлану да, эшем белән ләззәтләнү дә булмады. Шуңа күрә мин бу кеше алдында оялдым, үземнең ташып торган көчемнең, сәламәтлегемнең азын гена булса да аңа бирәсем килде. Ләкин ул шушы килеш тә миннән көчле иде, мин шуны аңладым: ул үз һөнәрен яратуы белән, горурлана белүе белән миннән өстен иде. Без тагын кузгалып киттек. Хәзер инде аның асылынып төшкән хәрәкәтсез кулы да, сөйрәп атлаган аягы да миңа элеккеге кебек килбәтсез тоелмады. Ул, үзен бик игътибар белән тыңлаучы булгангамы яисә эчен җилләргә булса да бушатасы килгәнгәме, сөйләде дә сөйләде. Мин, аның тонык кына агылган тавышын тыңлап, үзем турында уйланып бардым. Ничек авырып китүе турында сөйли башлагач кына уйларымнан арынып, кабат юлдашымны тыңлый башладым.

– Ничек авыруым турында сораган идегез, – диде ул, кабатлап. – Әнә теге урман артындагы тауны күрәсезме? Анда өч йөз кырыгынчы буровой урнашкан. Оператор булгач, үзегез беләсез, нефтьчеләр, нефть исен сизсәләр, буровойларыннан кайтмыйча көне-төне чокынып ята башлыйлар. Алтмышынчы елның кышкы буранлы көнендә миңа шул буровой эшчеләренә ашарга илтергә туры килде. Өч көн рәттән буран булганлыктан, юллар бөтенләй кар астында калган. Бораулаучыларга алмаш килмәгән, бер смена эшләргә барган кешеләр икенче көн-нәрен эшләп яталар. Мин, машинама кайнар аш тутырылган зур термослар салып юлга чыктым. Берничә чакрым юлны әйбәт кенә үттем, әмма, урманга керү белән, машинам карга борынын төртеп туктап калды. Тирән карны машинам белән ерып барып булмаячагы көн кебек ачык иде. Күп уйлап тормастан, өстемдәге тунымны салып, машинама капладым да, унар литр керешле ике термосны ике култыгыма кыстырып, юлга чыктым. Ара ничә чакрым булгандыр, һәрхәлдә, бик ерак түгел иде. Шулай да билдән кар ерып бара торгач арытты. Урманнан чыгып тауга күтәрелә башлау белән, җелеккә үтәрлек көчле җил мине куырып алды, тик кулымдагы авыр термослар гына бераз җылылык бирде. Мин, тәмам хәлдән таеп, будкага килеп җиттем. Бораулаучылар мине күтәреп алырдай булып шатландылар. Мин аларның талчыккан, арыган йөзләрендәге шатлыкны күреп аруларымны оныттым. Кып-кызыл булганчы ягылган тимер мич янына чүгәләп, тәмәке тарттым. Җылы будкада утырып бераз хәл алгач, кире машинам янына юнәлдем, радиатордагы су тәмам туңганчы машина янына барып җитәргә кирәк, мин ябып калдырган тун гына үзәкләргә үтәрлек салкын җилдән радиаторны саклап кала алмаячак, ә суны агызып калдырсаң, машинаң-ниең белән төнлә урманда кунып калуың бар.

Термослар күтәреп барганда артык салкын кебек тоелмаган иде, ләкин, буш кул белән чыккач, җиңелчә киемнән җил бик тиз үтеп керә башлады. Мин дер-дер калтырандым. Тамырлардагы каным бозга әйләнгән кебек тоелды. Ә машинам янына килеп җиткәндә, бөтенләй хәлем бетте, хәтта кулларымның мотор өстенә ябылган тунны күтәреп алырлык та егәре калмаган иде. Бәхетемә, машинада су туңмаган булып чыкты. Мин тимер өстендә торып салкынайган тунымны өстемә киеп кабинага кереп утырдым да моторны кабыздым. Ләкин кайтып җиткәнче җылына алмадым. Аннан соң больницага керергә туры килде, шул көннең гомерлек истәлеге булсын дигәндәй, күп тә үтмәде, аяк-кулым параличланды. Әзрәк йөрерлек рәткә килсәм дә, руль артына утырудан гомергә мәхрүм калдым.

Сөйләшә торгач, без эшчеләр посёлогына килеп җиттек. Юлдашымның мин исемен дә белдем. Идрис икән. Саубуллашканда, адресын сорап алдым.

Берничә көн Идриснең сөйләгәннәре минем миемдә чуалды. Аның карлыккан тавышы колагымда яңгырап торды. Радиаторны саклап калыр өчен өстендәге тунын япкан, яраткан эше өчен бернәрсәсен дә кызганмаган шушы кешегә карата соклану да, гаҗәпләнү дә, ярату да тойдым. Идриснең күзләренә кадәр чыккан эшен сагыну, машинасын сагыну сагышы мине әллә нишләтеп җибәрде.

Саубуллашканда, мин Идрискә берни дә әйтмәдем, шулай да күңелемдә аңа бер яхшылык эшләү теләге туган иде. Теләгемне эшкә ашыру нияте белән, танышым Саматларга киттем. Саматның үз «Москвич»ы бар, бәлки, аның белән бергәләп, Идриснең руль сорап кычыткан кулларына, зур юлларга ашкынган йөрәгенә, күңелен кимереп торган сагышына берәр чара табарбыз. Сигез ел буе баранка тотып карамаган шофёр кулына бер генә сәгатькә булса да машина тоттырып карасаң, Идриснең түбәсе күккә тиячәк.

Мин килгәндә, Самат өйдә иде. Аңа кичектермичә ни өчен килүемне сөйләп бирдем. Мин сөйли башлау белән, танышым сүзнең кем турында барганын төшенде.

– Юләр бит ул, юләргә ничек ышанып машина тот-тырасың, – диде танышым.

– Синең белән миннән акыллырак әле ул, – дидем мин, Саматка үпкәләп. – Кешенең бөтен гомере, бөтен тормышы машина белән хыялланып үткән. Руль артында гына ул үзен көчле тойган, машина йөртү белән горурланган, шуннан башка нәрсәне күз алдына да китерә алмаган. Хәтта аның авыруы да шул машинасын саклап калу өчен бит. Шундый кешене син юләр дисең.

– Ярый, ярый, синеңчә булсын, – диде Самат. – Минем бүген беркая барасым да юк. Хәзер гаражга барып машинаны заправить итәбез дә Идрисеңне утыртып берәр якка барырбыз. Бәлки, чынлап та, күңеле тынычланыр, кешегә бит кайчагында бик кечкенә нәрсә дә зур шатлык китерә.

Саматның болай йомшавы мине шатландырды. Без озак тормыйча Идрисләргә киттек. Идрис, безнең капка төпләренә килеп туктавыбызны күрү белән, ашыгып килеп чыкты. Аның күзләрендә сорау һәм гаҗәпләнү чагыла иде.

Мин, аны тизрәк сөендерергә теләп:

– Идрис абый, әйдәгез машинада бераз йөреп киләбез. Бу – минем дустым Самат, «Москвич»ы үзенеке, күпме йөрсәк тә сүз әйтүче булмас, – дидем.

Бу сүзләрне ишетүгә Идрис куаныр, рәхмәтләр әйтә башлар дигән идем, ләкин ул, киресенчә, кинәт кенә куырылып төште. Искәртмәстән артыннан китереп суккандай, бер мизгелгә миңгерәүләнеп китте. Аннары, бик нык рәнҗетелгән кешедәй, күзләреннән яшь тәгәрәп төште. Мин ни әйтергә дә белмичә аптырап калдым.

– Их, егетләр, – диде Идрис, безнең аптыраулы йөзебезгә карап. – Мин хәзер бала-чагамыни? Уенчык тоттырып балаларны гына алдап була. Ә минем яшем аннан узган инде. Минем кулларыма чын эш, йөрәгемә шул эш шатлыгын тою ләззәте кирәк. Сез мине уенчык тоттырып юатмакчы буласыз.

Идрис шулай диде дә, авыр-авыр атлап, өенә кереп китте. Шушы вакыйгадан соң мин Идрисне автобуста күрми башладым.

## ТУЙ АЛДЫННАН

Туйга инде бөтенесе дә әзер иде. Кыз ярәшелгән һәм ата-анасы белән килешенгән, чәкчәкләр пешерелгән, кунаклар чакырылган, бүләкләр алынган иде. Ләкин...

Беркөнне колхоз председателе комсомолларны үз янына җыйды да болай диде:

– Комсомол иптәшләр, төнлә безнең күлдән кемдер балык урлый. Кичә дә яр буенда әллә никадәр үле вак балыклар таптым. Үзегезнең арагыздан төнгелеккә сак куярга һәм колхоз милкенә кул сузучыны эләктерергә кирәк. Хәзер карпларның уылдык чәчү вакыты, әгәр вакытында карамасак, никадәр байлык әрәмгә китә.

– Карыйбыз аны, – диделәр комсомоллар һәм кемнең нинди көннәрдә каравылга чыгасын билгеләп тә куйдылар.

Беренче көнне секретарь үзе чыкты. Әмма каракны эләктерә алмады, икенче көнне механизатор Сабир каравыллады, тик ул көнне дә балык сөзәргә килүче булмады. Күрәсең, карак күлгә сак куюларын ишетеп алган да, хәтәр вакытлар үтеп китсен дип, посып кына ята.

Өченче көнне чират Кирамга җитте.

– Кәләш куенына керергә торганда сине каравылга кую бик әйбәт түгел инде түгелен, – диде секретарь. – Тик нишләмәк кирәк, комсомолларыбыз санаулы, ә алда көн-нәр күп. Тиздән Зәнияңне күрү генә түгел, җылы кочагында ук йоклый башларсың, хәзергә күлне сакларга кирәк.

Секретарь болай сүз озайтып тормаса да, Кирам үз бурычын аңлаган иде инде. Шуңа күрә ул секретарьның әйтеп бетергәнен тыңлап та тормады, күл буена китте.

Колхоз күле авылдан ерак түгел. Авылны чыгып, әз генә бару белән, әрәмәлек башлана. Ә әрәмә артында, камыштай зифа талларга, куак-куак булып утыручы карлыганнарга төренеп, Бака күле җәелеп ята. Кайчандыр

монда көне-төне бакалар сайрашкан, балык дигән нәрсәнең әсәре дә булмаган. Яз көннәрендә Ык елгасы бик нык ташып, әрәмәләрне су белән күмеп киткән чак-ларда гына бу күлгә, ташу белән адашып, бераз балык керә торган булган. Ләкин ул әлсерәгән балыкларны бала-чагалар һәм үрдәкләр бик тиз тотып бетергәннәр. Ә хәзер бу Бака күлендә колхоз карп балыгы үрчетә.

Кирам килеп җиткәндә, күлдәге бакалар җыры да тынмаган иде әле. Ул яр буенда үсеп утыручы талларның төзен сайлап кисеп алды да сырлап таяк ясады. Кечкенә энесенә бер сыбызгы юнып кесәсенә салды. Ләкин вакыт бик әкрен үтте. Кирам инде сырлы таягы белән тал башларын кыя-кыя берничә тапкыр күлне әйләнеп чыкты, ә Җидегән йолдызның койрыгы да борылмый әле. «Их, хәзер Зәния янына, җәйләүгә китеп барасы иде». Кирам Зәнияне уйлагач елмаеп куйды.

Зәния Кирам армиягә киткәндә кечкенә кыз иде әле. Яше унөч белән барса да, «р» хәрефен рәтләп әйтә алмыйча җәфаланып йөргән чагы. Сакаурак булуына карамастан, гаҗәеп тере һәм сүзчән кыз булып үсте ул. Кирамнардан берничә генә йорт аркылы яшәүче бу кыз, егет армиягә киткәндә: «Килам абый, миңа әлмиядән нәстә апкайтасың?» – дип калды. Кирам абыйсы, шаярып: «Сиңа еррактан «р» хәрефе алып кайтам, ризамы шуңа?» – диде. Ә Кирам дүрт ел флотта хезмәт итеп кайтканчы, Зәния инде буйга җиткән, сылуланып, өлгереп килүче кыз иде. Кирам белән ул элекке кебек теләсә ни сөйләнмәде. «Р» хәрефен дә җиренә җиткереп әйтә.

Сөйгән кыз турында уйлый башлагач, вакыт тизрәк үткәндәй булды. Шулай да таң атарга иртәрәк иде әле. Таң ата башласа инде кайтып китәргә дә була дип торганда, кайдадыр куаклар чыштырдаган тавыш ишетелде. Кирам таллар арасына посып сагаеп калды. Аяк тавышлары һаман саен якынлаша барды. Менә җилкәләренә брәтник күтәргән ике кеше сөйләшми генә күл ягына киттеләр һәм тиз генә өс киемнәрен салып ташладылар да күлгә керделәр. Кирам, посып торган урыныннан чыгып, тегеләрне танырга тырышты, ләкин, ләм-мим сөйләшмәгәч, кем икәннәрен аера алмады. Хәзер инде аларның балык сөзеп чыкканнарын көтәргә дә балыклары-ниләре белән идарәгә алып барырга гына калды. Шунда танырлар.

Караклар эшнең җаен белеп кенә эшләделәр: суны чыпырдатмыйча, үзара сөйләшмичә. Читтән карап торучыга аларның башлары гына күренә. Алары да вакыт-вакыт камышлырак урынга кереп югалып тора.

Кирам тегеләрнең киемнәрен яшереп куйды: үзләре качса-нитсә, киемнәре калыр, авыл кешесен киеменнән дә танып була. Аннары шәрә көе бик ерак китә дә алмаслар. Озакламый караклар, брәтникләрен тартып, ярга чыктылар. Тонык кына төшкән ай яктысында балыклар ялтырый башлады. Кирам да, таягын күтәреп, атылган уктай болар каршысына килеп чыкты.

– Хәзер балыкларыгызны капчыкларыгызга тутырыгыз да идарәгә киттек, – диде ул, катгый итеп.

Тегеләр бер мәлгә югалып калдылар. Кулларыннан брәтникләре төшеп китте. Берсе, һушына килү белән, куаклыклар арасына торып йөгерде, икенчесе дә аның артыннан чапмакчы булган иде, ләкин Кирам аны эләктереп өлгерде.

– Кача алмассың, – диде ул, тимердәй куллары белән каракның шәрә беләгеннән кысып.

– Бәрәкәт, Кирам кияү, син икәнсең, – диде карак.

Кирам да Зәниянең әтисен танып алды. Аның келәшчә кебек кысылган куллары ирексездән язылып киттеләр. Карак та, эшнең җайланганын күреп, иркенрәк сулыш алды.

– Берүк, кияү, хур итә күрмә инде. Гомеремдә беренче тапкыр килүем. Үзең беләсең, безнең өйгә балыкның маймасы да кергәне юк. Бу юлы да шайтан гына котыртты.

– Теге йөгергән шайтан кем? – диде Кирам.

– И-и, аны сорама, кияү, аны мин үзем дә белмим. Бөтенләй таныш кеше түгел, юлда гына очраштык.

– Ничек юлда очраштыгыз? – диде Кирам, ышанмыйча. – Юлда гына очрашкан кеше белән сөйләшми-нитми балык сөзәргә кереп китәләрмени? Ә бу брәтник кемнеке?

– Брәтник тә шуныкы, – диде Зәниянең әтисе. – Ярый, кияү, мине тоткарлама. Таң ата башлаганчы китим.

– Хәзер икәүләп кузгалабыз, – диде Кирам. – Ба-лыкларыңны күтәр, идарәгә баргач, иптәшеңнең кем икәнен әйтерсең.

– Ә, син шулаймыни? – диде Зәниянең әтисе. – Әгәр мине болай адәм хуры итсәң, кызның төсен дә күрмәячәксең, начармы-яхшымы, мин аның атасы әле. Ул минем сүздән чыкмый.

Ике ут арасында бик озак көрәште Кирам. Шундый үз, шундый якын булып киткән Зәнияне күз алдына китерүгә, югалту ачысын тоеп калтыранып китте ул. Дөрес, Заниянең әтисе сүзенә карап тормаячагын белә Кирам, әмма карак белән туганлашуны башына сыйдыра алмый. Зәнияләргә кергән саен, мондый кыйммәтле мебельләр боларга каян килгән дип аптырый иде, менә кайда икән эшнең асылы.

– Ярый, балыкларыңны суга җибәр, тере чакта китсеннәр, – диде Кирам, ныклы карарга килеп. – Мин сине бу юлга җибәрәм, ләкин шул шарт белән: башка монда эзең дә булмаска тиеш.

– Яңадан киләмме соң, Аллам сакласын, – диде әти кеше.

– Аннары тагын бер шарт... – Кирам бусын әйтә алмыйча озак азапланды. Исерек кешенеке кебек, телләре көрмәкләнде, йөзе кызарды. – Аннары шул, бүгеннән мине киявең итеп санамыйсың. Зәниягә үзең теләсә ничек аңлатырсың, анда минем эшем юк. Ә мин моннан соң синең белән бер табында утырып ашый алмаячакмын. Әнә теге куак төбендә киемнәрең, ал да тай! Күзем күрмәсен.

Зәниянең әтисе кайтып киткәч, Кирам су буенда утырып калды. Ул бу гамәленең яхшымы, яманмы икәнлеген белерлек хәлдә түгел иде. Аның эчендә Зәниянең әтисенә карата ачу, үпкә кайный иде.

## ИКЕ КҮРШЕ

Кинәт кенә йөрәге чәнчеп куйгач, Кәримә карчык чынаяклар юып маташканда егылып китә язды. Ул, хәле бетеп, ике куллап стенага килеп ябышты. Бераз чәнчүе басыла төшкәч, шкаф тартмаларын ачып, эреле-ваклы шешәләрне тотып карады. Ләкин алар бар да буш булып чыктылар. «Күршеләрдә валерьянка ише нәрсә юк микән, аларга кереп чыгыйм әле», – дип, юылып бетмәгән савытларын бер яккарак өеп, юеш кулын итәгенә сөртеп алды да тагын әллә никадәр аркылы яткан эшләрен торкылы салганнан соң гына күршеләренең ишеген шакыды.

Кәримә карчык берничә мәртәбә шакып та чыгучы булмагач, өйдә юклардыр, ахры, дип китәргә җыенганда гына, көлүенә буыла-буыла, күршесе Гөлзифа килеп чыкты. Кәримә карчыкның сыкранулы йөзен күргәч тә, ул бөтен битенә җәелгән авызын җыя алмый торды. Кәримә карчык: «Вакытсыз кердем, ахры», – дип, кире чигенә башлагач кына, Гөлзифа үзенең симез куллары белән күршесен эләктереп алды һәм сөйләнә-сөйләнә өйләренә сөйрәде.

– Бик вакытлы кердең, бик вакытлы, әгәр хәзер кермәгән булсаң, бу кызыкны күрми кала идең, – дигәч, Кәримә, бик кызыклы нәрсә күрермен дип уйлап, бусагадан атлады. Алар ишекне ябып та өлгермәделәр, кухня ягыннан кабарынкы йонлы зур бохар песие атылып килеп чыкты һәм, идәндәге урындыкларга бәрелә-сугыла, караватка менеп китте. Ләкин ул урынны да бик ошатмадымы, кире аннан атылып төште дә тәрәзәгә сикерде. Тәрәзә коелып төшүдән чак калды.

Кәримә карчык, бу ни бу дигәндәй, күршесенә карады. Әмма Гөлзифа, артык тәэсирләнүдәнме, көлү пристубын баса алмый торды. Бер почмактан икенче почмакка чабулап йөрүче мәчегә куллары белән күрсәтә-күрсәтә күршесенә нидер аңлатырга теләсә дә, тегесе берни дә төшенмәде. Куллары белән авызын үз урынына җыеп куйгач кына, Гөлзифа бераз сөйләр хәлгә килде. «Менә, – диде ул, бераз тотлыгып, – песиемнең бүген туган көне. Нәкъ сигез яшь тулды бохаркаема. Үлеп валерьянка ярата бохарым. Туган көне булгач, бер туйганчы эчсен әле дип, бер шешә валерьянка салып биргән идем, исерде дә куйды бит, бичаракаем. Картаюы шулдыр, күрәсең. Элек алай эчкәнгә генә бер дә исерми торган иде. Әллә инде закускасы әзрәк булдымы. Бер килограмм әйбәт колбаса алып кайтып биргән идем югыйсә. Тик нигәдер бик ашамады. Бер-ике кисәк кенә капты да валерьянкасына тотынды. Картайды шул, картайды. Тешләренең дә рәте калмады хәзер. Сөяк-мазар бирергә дә куркам. Әллә инде шикәр-конфет ашау ярамады үзенә. Бик яшьли конфет ашарга өйрәнде шул. Ятим песи баласы иде ул. Урамнан табып алып кайттым мин аны. Ятим дә булгач, мин аңардан берни дә кызганып тормадым инде.

Кәримә карчык, бу әкәмәткә карап, үзенең йомышын әйтергә авызын ача алмый торды. Берәр сүз әйтергә авызын ача башласа, күршесе үзенең мәчесен мактарга тотына да, тегесе ачкан авызын кире ябарга мәҗбүр була.

– И күршекәем, – дип сөйләп китте Гөлзифа тагын, – бигрәк рәхәт заманда яшибез инде. Кибетләрдә ни алыйм дисәң, шул бар. Хөкүмәтебез безнең ише карчыкларга рәхәтләнеп яшәрлек итеп пенсиясен бирә. Минем дә менә пенсиям мул торырга җитә. Акчаны үлгәч үзем белән алып барып булмас, менә песиемне сыйлыйм әле, дип, бохарым яраткан ризыкларны күп итеп сатып алдым. Ашасын-эчсен. Аның да җаны бар бит.

Кәримә карчык, сүзгә кушылмый гына, күршесенең сүзләрен җөпләп утырды. Ул ни дияргә дә белмичә аптырап калган иде. Үз гомерендә бер мәртәбә дә песиенең туган көнен уздырып карамаган, алай гына да түгел, ул турыда хәтта ишеткәне дә булмаган, авылдан килгән карчыкның аптырап калуы гаҗәпмени? Ул идәндә аунап яткан колбаса кисәкләрен дә чын күңеленнән кызганып утырды. Артык мул тормышта үсмәгәнлектән, ул һәр нәрсәгә сак карага өйрәнгән. Ипи валчыкларын да ул, гөнаһ булыр дип куркудан гына түгел, ә ипигә хөрмәте зур булганга күрә

һәрвакыт җыеп ала. Күгәрченнәр булса да ашасын дип, аларны аерып җыя, чүп-чар арасына салып түкми иде. Ә монда колбаса телемнәре кадерләрен югалтып идәндә ауный, күңелең рәнҗеми нишләсен.

«Була бит шундый юмарт кешеләр, песиләреннән дә берни кызганмыйлар, – дип уйлап утырды ул. – Ә без гомер буе кысып тотарга өйрәнгәнбез инде». Хәер, аның, Гөлзифа карчыкныкы кебек, саклык кенәгәсенә салырлык акчасы да булмады инде. Шулай ул үзен бервакытта да ярлыга санамыйча, булганына шөкер итеп яшәде.

Кәримә карчык, ниһаять, үзенең йомышын әйтә алды. Әмма күршесенең ул сораган нәрсәсе булмады. «Бөтен валерьянканы песигә биреп бетергән идем шул», – диде ул. Кәримә карчык «алай икән» дип чыгып китте.

Ул чыгып китеп күп тә үтмәде, Гөлзифаларга тагын бер күрше килеп керде. Ул Гөлзифаның песи кәмитен дә карап тормады, песи турында ләззәтләнеп сөйләгәнен дә тыңламады, чөнки ул аларны күп ишеткән иде инде, туп-туры йомышын ярып салды:

– Коридорга куярга лампочка кирәк, – диде ул. – Бу юлы сезнең чират. Теге юлы да сезнең өчен үземнекен куйдым...

Гөлзифа аңарга акаеп карап куйды, ничек итеп әйтсәм үтемлерәк булыр микән дип уйлады, ахры.

– Нәрсә, сез миндә әллә әндри казнасы бар дип беләсезме? Кирәсез дә миннән лампочка сорыйсыз, кирәсез дә лампочка сорыйсыз.

– Коридордан сез дә файдаланасыз бит, – диде күршесе, – шулай булгач, сезнең өчен кем бирсен. Лампа бит ул янмый тормый.

– Минем кич белән коридорга чыгып та караганым юк. Анда сезнең кызларыгыз свидание куеп, егетләрен чакырып ята. Алай бик яктыда үбешәселәре килсә, үзләре сатып алып кайтсын. Мин барлы-юклы пенсиямне әллә кемнәргә тарата алмыйм. Бигайбә.

– Мин сездән хәер сорарга дип кермәдем, – дип, күршесе чыгып китте. Аннан ул туп-туры Кәримә карчыкларга керде. Кәримә карчык эшнең нәрсәдә икәнен төшенү белән, ашыга-ашыга чемодан төпләрен актарырга тотынды. Ләкин анда лампочка калмаган икән. Ул, гаепле кеше кебек, күршесенә карап куйды. Тегесе инде чыгып китәргә җыена башлаган иде, шулвакыт Кәримә карчыкның исенә нидер төште, ахры. Шап итеп ботына сугып куйды һәм кухня ягына чыгып китте. «Кухня лампочкасыз да торыр, коридорда һәрвакыт кеше йөреп тора», – дип сөйләнә-сөйләнә, яңа гына сүндерелгән җып-җылы лампочканы күршесенә сузды. Күршесен буш кул белән чыгармавына ул чын-чынлап сөенгән иде.

## СОҢГЫ ХӘБӘРЛӘР

Зәмһәрияне якыннан белүчеләр барысы да «соңгы хәбәрләр» дип кенә йөртәләр. Җитмәсә әле, исеменең дә «м» хәрәфен төшереп калдырып, «Зәһәрия» диләр. 80 фатирлы йортта аны белмәгән кеше юктыр дисәм дә, ялган булмастыр. Чөнки ул һәркемне «үз» итә, «үз» кешем булганга, сиңа гына сөйлим дип, иң яңа, иң соңгы хәбәрләрне сөйләп чыгып китә. Кешеләрнең ул үзенә кырынрак карауларын да белә, хәтта аның кайберәүләргә бик каты ачуы да килә, ләкин үзенең теле кычытуын берничек тә баса алмаганлыктан, ачуын тыеп тотарга мәҗбүр була. Ул нинди дә булса бер сүз ишетсә, аны тизрәк башкаларга ишеттерергә ашыга. Авызына корт күче алгандай, һәр очраган кешегә бар белгәнен бушатып ташлый. Менә әле дә ул үзе кебек үк күпне ишетергә яратучы ахирәте Йөзембикә янына кереп бара.

Зәмһәрия килеп кергәндә, Йөзембикә кухняда бәрәңге кыздырып маташа иде. Ахирәтен ул бик сүлпән генә каршылады. Ләкин Зәмһәриянең нindидер гадәттән тыш вакыйга әйтергә теләвен күргәч, кызыксынуы артып, чырае сер тыңларга әзерлекне белдергән кыяфәткә керде. Зәмһәрия, бер алдына, бер артына каранып, кухня ишеген ныклабрак ябып куйды, кастрюль эчендә кеше качып утырмыймы дигәндәй, савыт-сабаларга күз төшерде. Аннан соң, эчендәге хәбәрне артык тыеп торырга тәкате калмыйча, карбит салынган су кебек, тегесенең колагына пышылдарга тотынды:

– И-и, күршекәем, без монда берни дә ишетми ятабыз икән, – диде ул, – безнең кырыйдагы теге музыкант тилергән, ди!

– Кит аннан? Болай үзе карап торуга бик әдәпле, акыллы кешегә охшый иде бит.

– Әдәп дигән нәрсә юк иде инде аңарда, ахирәт. Бервакыт шулай каяндыр кайтып килә бу, мин сиңа әйтим. Күзләре пыялаланган, авызын кыеш-мыеш китереп, үз-үзенә сөйләнә. Миңа бәрелә язып үтте, мине күрмәде дә. Ә-ә, хәзер терәлеп торган күршең белән дә исәнләшми башладыңмыни инде, дим. Күрмәдем, гафу итегез инде, дигән була. Күрмәдем, имеш...

– Әйе, бу чүмәлә чаклы гәүдәне дә күрми башлагач, эше шәптән түгелдер, күрәсең.

– Син, күрше, минем гәүдәгә кагылма әле. Чыра агачыдай шылтырап тормыйм мин. Кочам дигән кешегә – кочарлыгым, сөям дигәнгә сөярлегем бар. Күргән бер ир-ат кызыгып китә үземә...

Алар, башка вакыт булса, үзләренең гәүдәләре турында шактый тирән бәхәскә кергән булырлар иде, ләкин бүген, Зәмһәриянең хәбәре артык мөһим булганлыктан, ачуларын башка вакытка калдырып торырга ниятләделәр.

– Менә, – дип дәвам итте Зәмһәрия, – шул пыялаланган күзен күрү белән, бу музыкантка нәрсәдер булган дип карап калган идем аны. «Теге якка» авыша башлаган бугай ул, дип, иремә дә әйткән идем, юкны сөйләмә, дип сүгеп ташлады үземне, ышанмасагыз, менә ышаныгыз инде.

– Әллә юләрләр йортына алып киткәннәрме үзен? – дип сорады Йөзембикә, кызыксынуына түзә алмыйча.

– Юк, алып китмәгәннәр әле.

– Ә кайда соң ул хәзер?

– Кайда булсын, өендә. Берүзе сөйләнеп утырадыр әле шунда.

– Ә син аның юләрләнүен каян белдең соң?

– Болай булды бу: кичә шулай дөңгер-доңгыр кил-гән тавышка сискәнеп уянып китсәм, теге музыкант бүл-мәсендә тавыш. Кем беләндер сөйләшә дә әллә ниләр дөңгердәтеп ала, сөйләнә дә дөңгердәтеп ала. Тыңлап ят-тым-яттым да, түзмәдем, ишеге янына килдем. Эчтә хатын-кыз тавышына охшаган тавышлар да ишетелеп кит-кәндәй була. Туктале, мин әйтәм, безнең монахка әллә берәр хатын ияләштеме, дим. Ишек ярыгыннан берәр нәрсә күреп булмасмы дип караган идем, каһәр төшкән ютәлем кузгалды, җитмәсә, төчкереп җибәреп, борынымны ишек тоткасына бәрдем. Әллә минем тыңлап торуны ишеттеләр: тындылар болар. Мин ишекләрен кагарга тотындым. Нишләп, мин әйтәм, кешеләргә йокы бирмичә, төнлә хатын-кызлар җыеп тавышланасыз? Оят дигән нәрсәгез кайда? Син кешеләр арасында гына мыштым булып йөрисең икән, белдем эшеңне, дим. Шулай дигәч, ишеген ачты бу. Ә-ә, Зәмһәрия апа, син икәнсең, ди. Барып керсәм, берүзе бу. Шатланган. Керү белән булды бит, апакаем, дип, мине кочып алды. Нәрсә булды соң? димен. Үзем, минем кергәнемне генә көтеп торган икән бу, мине күргәч шулай шатлана инде, дип уйлыйм. Кочагы да җылы гына үзенең. Ни әйтсәң дә, егетләр кочагы егетләр кочагы инде. Йөрәгем дөп-дөп тибәргә тотынды. Ник кергәнемне онытып тордым бераз. Миндә күңелең булгач, нигә аны алданрак әйтмәдең, дигән идем, музыкантым шундый акаеп карады, котларым очты. Шулай да, алай булгач, нәрсә таптың соң, дип сорый алдым. Ә ул өстәлдәге кәгазьләргә күрсәтә. Күптән эзләгән финалымны таптым, ди. Финал дигәнең кем соң ул, хатыныңмы? Хатының югалган идемени, дим. Теге кәкре-бөкре итеп язылган язулары шуның хатыдыр инде дип уйладым. Кая әле, мин әйтәм, ниләр яза хатының? Кулыма теге язуларны алып карасам, хәрефләре хәрефкә охшамаган моның. Әллә нинди кисәү агачлары тезеп чыккан шунда. И-и, рәтләп яза да белми икән хатының, дим. Ә ул көлә. Буылып-буылып көлә. Кып-кызыл булып, бәбәкләре бүртенеп чыкты, мин сиңа әйтим. Тилергән икәнлеген шунда гына белдем. Ничек ул баштарак башыма килмәгән. Акыллы кеше берүзе төн уртасында сөйләнеп утырыр идемени?!

– И-и, бичара, әрәм булган икән, – дип куйды Йөзембикә. – Әйтәм ул картайганчы өйләнми йөри, акылы зәгыйфь икән мескеннең. Югыйсә төскә дә ярыйсы гына бит үзе. Минем кызым да аңа гыйшык тотып йөрде бугай. Кереп әйтүең бик әйбәт булды әле. Дөнья хәлен белеп булмый, кызны хәзер ул тирәдән еаграк йөртергә кирәк булыр. Ул бичараның алай булуын эшләгән җирендә беләләр микән соң?

– Аның нинди эшләгән җире булсын. Көн саен өйдә бит ул.

– Алай дип кырт кисмә син, күрше. Алар халкы, барып эшләмәсә дә, берәр җирдә спискедә торадыр. Менә шунда язып җибәрергә кирәк үзен. Эшкә барам дип, әллә кайда трамвай астына-мазарга эләгүе бар. Юләр булса да, җан иясе бит, кызганыч.

– Психлар йортына гына олактырырга кирәк аны. Килсеннәр дә аяк-кулын бәйләп алып китсеннәр. Йә мондагы хатын-кызга ябыша башлар. Кичә мин кергәч тә буып үтерә язды бит, чак котылдым.

– Алайса, тот та шылтырат, синең телефон бар бит.

– Юк инде, рәхмәт. Башымны юләрләр белән бәйлисем килми әле. Әнә телефон, кер дә шылтырат.

– Юләрләнүен башлап син күргәнсең бит. Шулай булгач, син шылтыратырга тиеш. Бик курыксаң, исемеңне әйтмәскә дә мөмкин ич. Безнең өйдә шундый-шундый кеше бар, тиз генә бер-ике тазарак санитар җибәрегез, диген.

– Кемнән куркыйм мин? Шул юләр музыканттанмы?

– Курыкмагач, хәбәр ит, сузма.

– Алай бик белдекле булгач, үзең генә хәбәр ит инде.

Алар шулай күпме бәхәсләшкән булырлар иде, билгесез. Ләкин шулвакыт болар йорты янына янгын сүндерү машинасы килеп туктады. Күп тә үтмәде, берсе, бу хатыннар кычкырышып торган кухня тәрәзәсеннән озын шланг

тыгып, бик каты басым белән су сиптертергә тотынды. Шунда ук брезент киемле кешеләр йөгереп болар янына керде, һәм шунда гына хатыннар эшнең нидә икәнлеген төшенеп алдылар. Чынлап та, алар кухнясында ут чыга язган иде. Кыздырырга куйган бәрәңгеләре тәмам көеп, кап-кара төтен чыга башлаган. Плитә тирәсенә киптерергә куйган киемнәренә ут капкан.

Янгын сүндерүчеләр эшләрен бетереп акт төзеделәр һәм, Зәмһәрия белән Йөзембикәдән кул куйдырып, үз юллары белән китеп бардылар. Салкын су хатыннарның да кызуын бераз сүрелдерде, ахры, алар да тынып калдылар. Шулай итеп, күршеләр ул көнне шылтырата алмый калдылар. Ә икенче көнне музыкант каядыр киткән булып чыкты.

Берничә көн узды. Музыкант өендә күренмәде. Зәм-һәрия еш кына ачкыч тишегеннән күз төшергәләсә дә, юкка гына, өйдә бернинди дә хәрәкәт сизелмәде. Зәмһәрия белән Йөзембикә вакытында бу музыкантны «тиешле урынга» җибәрә алмауларына уфтанышып, йомшаклык күрсәтүдә бер-берләрен гаепләп йөри башладылар. Шулай битәрләшеп, тагын ничәдер тапкыр бәрәңгеләре көйгәнче бәхәсләшкән чаклары да булгалады. Боларның әйткәләшүе әле тагын да дәвам иткән булыр иде, ләкин беркөнне радио болар өчен бик мөһим хәбәр китерде. Аны да беренче булып ишетүче Зәмһәрия булды.

– Композитор Гыйлаҗ Әбүзәровның яңа симфониясен радиодан тапшырдылар бүген, – дип йөгереп керде Зәмһәрия Йөзембикәләргә.

– Кем соң ул Гыйлаҗ Әбүзәров? – диде Йөзембикә.

– И-и, кем дип сорап торган буласың тагын. Үзең этеп-төртеп кызыңны бирергә йөрисең шуңар. Белмәмешкә салыша, имеш...

– Ярар инде, ярар, чәпчемичә генә сөйлә. Мин аның фамилиясен сораганым юк бит. Шулай булгач, белмәү гаепмени.

– Белсәң, менә шул: безнең музыкант Мәскәүдә яшь музыкантлар арасындагы ярышта беренчелекне алган. И-и, баш та бар икән үзендә. Мин, аны күрү белән, моңардан бер нәрсә чыгар дигән идем, дөрес тә булды.

– Син аны тилеләр йортына озаттырырга йөргән идең бит. Нишләп соң әле бик әйбәтләнеп китте ул?

– Юкны сөйләмә әле, ахирәт. Иң беренче бит, үзең шылтырат, дип, мине кыстый башладың. Мин шылтыратмагач, минем телефоннан син шылтыратмакчы булган идең дә, ярый әле мин тыеп калдым. Югыйсә оятка калдыра идең бөтен йортны.

– Ах оятсыз, ни сөйләп тора бит. Телеңне корт чаккыры. Моннан соң өемә аяк басасы булма...

Шуннан соң ике ахирәт бер-берләренә сүз катмас булдылар, ә композитор, боларның дошманлашуына үзе сәбәпче булуы турында уйлап та карамыйча, илһамланып яңадан эшкә кереште.

## ШИКЛӘНҮЧӘН ТИМЕРБУЛАТ

Яңа фатирга күчкәч, Тимербулат картның иң беренче эше ишектәге йозакны тикшерү булды. Төрле ысуллар белән җентекләп караганнан соң, ишек йозагын бернигә дә яраксыз дип тапты ул. «Авыррак гәүдәле кеше килеп кагылса да ачылып китәргә тора бит, җитмәсә, күршеләрнеке дә шундый ук йозаклар икән, – дип уйлады ул. – Бөтен кешенеке дә бертөсле булгач, ишекләргә йозак куеп та маташасы юк. Бер-береңнең әйберен рәхәтләнеп шудыра бир, кемнән шикләнергә дә белмәссең, барысының да ачкычлары кесәсендә! Иртәгәдән кибеткә барып, теге англичан йозагын алып кайтырга кирәк. Аны теге Сафиулла бик мактап торган иде беркөнне. Аның белмәгәне юк».

Өйне бик ныклап ныгыту нияте белән, Тимербулат карт иртәгесен кибетләргә чыгып китте. Ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, эзләгән йозагын таба алмады. Нинди генә йозак алса да, нык түгелдер кебек тоелды. Кайсы артык кечкенә, кайсы артык зур күренде аңа. Казанның барлык кибетләрен йөреп чыккач, ул заводта эшләүче кордашы Сафиуллаларга юл тотты.

Күптән күрмәгән иске дустын күргәч, Сафиулла кычкырып ук җибәрде:

– О-о, нинди җилләр ташлады әле сине безнең якларга? Яңа фатир алгансың дип ишеткән идем, котлы булсын! Пенсиягә чыккач әллә дусларын да оныта башлады инде бу дип йөри идем әле, ярый килеп чыктың, югыйсә пыр тузып үзем барырга исәпләп тора идем.

Алар шулай шактый гына гәп сатып утырдылар, ул арада Миңсылу карчыкның чәе дә кайнап чыкты. Картлар, чәй белән генә канәгать булмыйча, графин төбендәге «кызыл»ны да бүлеп салып куйдылар. Шуннан соң гына Тимербулат карт үзенең йомышын әйтте:

– Мин сиңа, туган, бик зур йомыш белән килгән идем бит әле, – диде ул. – Менә шул яңа фатирның йозагы бик хөрти, шуңа ныклырак йозак куясы иде бит. Югыйсә әллә ни булуы бар, гел өйдә генә торып булмый бит. Көне буе кибеттә йөреп тә тапмагач, сиңа килдем менә.

– Эш йозакта гына калса, берне түгел, бишне табарга була, – дип, Сафиулла ниндидер тартма актарырга тотынды. – Менә җаның теләгәнен сайлап ал, барын да үзем ясадым. Берсе дә синең англичан йозагыннан ким түгел. Синең ишегеңне генә түгел, теләсә нинди сейфны шикләнмичә бикләп куярга була.

Тимербулат үзе әйбәт дип тапкан өч йозакны алды да кайтып китте. Чөнки аны начар йозакка бикләнгән ялгыз фатиры борчый башлаган иде. Тимербулат, өенә кайткач та, бу йозакларга бик әйбәтләп тикшерү ясады. Ул аларны бер ачты, бер бикләде. Тәмам яхшы икәнлекләренә ышангач кына, өстен-башын чишенеп, ишеккә куярга тотынды. Эшсез ятып бераз тутыга башлаган өтерге белән чүкеч бер-берләрен сагынышып сөйләшергә тотындылар. Чүкеч бертуктаусыз «тук-тук» диде, ә өтерге «сук-сук» диде. Күрше хатынның яшь баласы кычкырып елауга да, бер авыру картның сыкрануына да исе китмәде чүкечнең, һаман тукылдавында булды. Бары тик өч йозакны да яхшылап беркетеп, соңгы кадак кагылгач кына, алар тукылдап сөйләшүләреннән туктадылар. Өч йозакны да өчәр кат борып, ишекне әйбәтләп бикләгәч кенә, Тимербулат иркен сулап куйды. Төнлә дә ул бүген бернинди төш күрмичә, тынычлап йоклады. Башка вакыттагыча баскычтагы аяк тавышына да дерт итеп уянмады. Иске фатирында йокылы-уяулы йоклап бөтен нервысын бозып бетергәнгә күрә, монысында эшне коры тотты ул. Аның күңеле бераз тынычлангандай итте. Өстеннән ниндидер зур эш төшкән кебек булды. Ләкин шикләнергә өйрәнгән күңел үзенекен итте: һаман пошынды, гел җитешсезлек эзләде.

Шулай уйланып йөри торгач, уйлап тапты ул: почта ящигын да әйбәт калай белән тышлатырга кирәк! Югыйсә малай-шалай әллә нишләтеп куяр. Газета, хат ише нәрсә килмәсә дә, ул бит аңа тигән әйбер. Шулай булгач, почта ящигына да ул җаваплы.

Башына бер уй килсә, аның тәмам йокысы кача, аппетиты югала. Шуңа күрә ул бу ниятен дә тормышка ашыруны озакка сузмады. Ящикны калын калай белән тышлатып, ышанычлы йозак белән бикләтеп куйды.

Эшләгән кешегә эше дә табылып тора бит аның! Тимербулат карт та эшсез тормады. Почта ящигы белән беррәттән коридорда тора торган электр счётчигын да тимерләп куйды. «Дөнья хәлен белеп булмый, күршедә генә майлы күзле малай тора, борыр да алыр», – дип уйлады ул. Әмма алай да тынычлык таба алмады. Кая барса да, гел куркып, шикләнеп яшәде. Базарга-нигә барырга чыкса, ишеге бикләнмәгәндер кебек тоелып кире кайтты. Кунакка чакырсалар, тизрәк кайту ягын чамалады.

Ә бервакыт ул, бер дустына кунакка баргач, бөтенләй кыен хәлгә калды. Кунак хөрмәтенә дип хуҗалар сыйны мулдан әзерләгәннәр, сирәк кунак булгач, кыстый-кыстый сыйладылар. Тимербулат Камырбулатка әйләнеп мәлҗерәп төште. Хәтта, төн җиткәнне дә көтмичә, утырган урынында йоклап та китте. Ләкин йокыга китүе бик аянычлы булды аның. Төн урталарында уянып китте дә үзенең кайда йоклавы турында уйлана башлады. Кешедә икәнлеген белгәч, йөрәге ярсып-ярсып тибәргә тотынды. Ул, ярсып типкән йөрәген учы белән кысып, әкрен генә торып утырды. Як-ягына каранды: хуҗалар бар да йок-лыйлар. Ә йөрәк туктаусыз «фатир, фатир» дип тибә. Чынлап та, фатиры ачык калган булса? Тизрәк киенергә дә кайтырга кирәк!

Ул шулай уйлап, караңгыда кармалана-кармалана киемнәрен эзләп, ашык-пошык киенергә тотынды. Хуҗа-лар аның чыгып китүен сизми дә калдылар.

Урамда инде барлык төр хәрәкәт тукталган, сәгать икеләр-өчләр тирәсе булса кирәк. Урамдагы дөм караңгылык та, берничә сәгатьлек юл да Тимербулатны куркытмады. Ул кызу-кызу атлавында булды. Тора-бара, атларга җиңелрәк булсын өчен, аяк киемнәрен дә салып- кулына тотты. Болай атларга җиңелрәк икән, ләкин иртәнге дымлы юл гына бераз салкынча. Хәер, табаннары кызгач, ул юл салкынын да сизми башлады. Тыны бетеп, яныппешеп өенә кайтып җиткәндә, трамвайлар да йөри башлаган иде инде. Тимербулат карт баскычтан ашыгып менгән уңайга ук ишегенә килеп бәрелде, ишекнең бикле икәнен белгәч кенә, ул, арып, кузгалыр хәле дә калмыйча, лып итеп ишек төбенә утырды. Шактый вакыт шулай утыргач кына, өч йозакны ачып, эчкә кереп ауды.

Шушы төнге сәяхәттән соң ул бөтенләй аяктан егылды. Күптән үзен сиздергәләп килгән «ырматизы» аны тәмам аяктан екты. Һәрвакыт ни булса да эшләп, көннәр буе шыкылдап йөрүче Тимербулат күренми башлагач, күршеләре дә сагаеп калдылар. Баштарак аны үзара гына сөйләштергәләп искә алсалар, соңыннан берәм-берәм хәлен белергә керә башладылар! Ә беркөнне теге «майлы күз» малай аңа врач чакыртып китерде. Врач, Тимербулатны бик яхшылап караганнан соң, курортка барып дәваланырга кирәк дигән нәтиҗәгә килде.

– Кая инде ул безгә курортларга барып йөрүләр?! – диде Тимербулат. – Шушында эчәргә генә дару бир инде син. Үлсәм, өйдә үләрмен. Курорт бит ул нәчәлства өчен генә. Безнең ише прастой кешегә больнис та ярар.

Врач язып биргән рецепт буенча, күршеләре аңа даруханәдән дарулар алып кайтып бирделәр. Кайсы аның керен юып чыгып китте, кайсы кайнар аш пешереп кертте. Ә теге «майлы күз»не әйткән дә юк инде. Ул гел аның янында булды. Тимербулатны шашка уйнарга өйрәтеп, укыган китапларын сөйләп чыгып китте.

Тимербулат картның әкренләп кешеләргә карашы үзгәрә башлады. Шулай да әле ул элекке фикерләреннән кайтып җитмәгән иде. Тик бер нәрсә аның кешеләргә карата булган күңелендәге бозын тәмам эретте.

Беркөнне, көтмәгәндә, Тимербулат картка райсобестан ике вәкил килеп керде. Алар картның хәлен сораштылар. Кем белән яшәве турында кызыксындылар. Врач биргән рецептны һәм курорт направлениесен карадылар.

Шуннан соң өлкәнрәге:

– Күршеләрегез безгә килеп авыруыгыз турында әйткәннәр иде. Күршеләрегез белән бик дус яшисез, ахры, әллә ничәсе, килеп, путёвка таләп итеп китте инде.

Тимербулат кызарып чыкты. Бераз ни әйтергә дә белми торды. Бераз дулкынлануы басыла төшкәч кенә:

– Әйе, бик тату яшибез, – дип әйтә алды.

Райсобестан килгән вәкилләр Тимербулаттан гариза яздырып, айның унбишләре тирәсенә путёвка булырга мөмкин, дип, Тимербулатның күңеленә өмет һәм кешеләргә ышану чаткысы салып чыгып киттеләр.

Озакламый аңа, путёвкаңны килеп ал дип, хәбәр дә җибәрделәр. Ул, гомерендә беренче тапкыр таксига утырып, райсобеска путёвкага китте. Путёвканы кулына алгач, тәмам курортка баруына ышанып, курорт карталары тутырырга тотынды. Ә киткән чагында аны озатырга барлык күршеләре чыкты. Ул, аларның бөтенесенә дә рәхмәтләр укып, ишек ачкычын теге «майлы күз»гә бирде:

– Мин өйдә югында, бәлки, слесарь-мазар керер, килсәләр ачып кертерсең, – диде ул. Һәм үзе, фатиры өчен бер дә борчылмыйча, тыныч күңел белән беренче тапкыр айлык юлга чыкты. Аның күңелендәге шик тамыры белән йолкынган иде.

## ЯРАЛЫ КҮҢЕЛ

Һәдия чибәр кыз түгел. Аның җәенке кашлары, озынча яңагы, калын иреннәре көзгегә караган саен ачуын китерәләр. Шуңа күрә дә ул көзгегә сирәк карый. «Озынча яңакларны иннек-пудра белән генә түгәрәкләп булмас, иреннәр помада булганга гына юкармас», – дип, ул бизәнү әйберләренә әллә ни әһәмият бирми. Гомумән, Һәдия үзенең ямьсезлеге турында онытырга тырыша. Әйе, тырыша, ләкин булдыра гына алмый. Тулай торактагы башка кызлар артыннан өерләре белән егетләр йөргәндә, алар чытлыкланып егетләре белән паркка, киногa киткәндә, Һәдиянең күңеле кымырҗып кала. Мондый вакытта көзгегә карамый да үзенең нинди икәнлеген яхшы белә ул. Миңсылуларга, Рабигаларга табынырдай булып ялварып, аларны йотардай булып комсызланып караган күзләр, Һәдия ягына борылдылар исә, тыкрык почмагына утыртылган ташка караган шикелле салкынаялар. Алардагы соклану чаткылары шунда ук сүнә. Ә бит Һәдиянең дә мәхәббәт шәрабыннан исерәсе, сөю канатларында югарыга күтәреләсе, уттай кайнар иреннәрнең тәмен татыйсы килә. Аңар бит хәзер егерме ике яшь. Аның яшендәге кайбер кызлар тормышка чыгып, бала үстереп яталар.

Менә бүген дә Һәдия тулай торакта ялгызы гына калды. Иптәш кызлары киногa киттеләр. Кызлар аңа:

– Әйдә син дә безнең белән, тавык та кунакламас борын ятып йоклаганчы, бераз җилләнеп, күңел ачып кайтырсың, – дигәннәр иде.

Ләкин Һәдия аларның сүзен чынга алмады.

– Үзегезнең мин иярмәсә ярар иде дип котыгыз очып йөридер әле, – диде ул.

Тегеләрнең бу сүзләргә хәтерләре калды. Миңсылуның хәтта күзләреннән яшьләр чыкты:

– Их син, өй тавыгы, – диде ул, – башкалар клубка чыккан саен егетләр белән үбешергә генә чыга дип беләсеңме әллә син.

– Синең йөрәгең йоклагандыр, йөрәге уяу кеше шул-кадәр гамьсез булмас, – диде Рабига.

– Сезнеке уяу булгач яраган инде...

Һәдия иптәшләренә рәнҗеп калды. Үзен алар тарафыннан кимсетелгән итеп тойды, хәтта, ялгызы гына калгач, бераз балавыз да сыгып алды. Иптәш кызларына үч итеп, аларның ачуын китерерлек нинди дә булса бер эш эшләп ташлыйсы килде аның. Башында әле бернинди ачык уе булмаса да, Һәдия киенә башлады. Матур капрон яулыгын, ияк астыннан ук алдырып, башына бәйләде. Болай иткәч, яңакның озынчалыгы бераз кимегәндәй, битләр түгәрәкләнебрәк киткәндәй булды. Ләкин иреннәрнең калынлыгы бернинди косметикага да буйсынмады. Һәдия үзенә иң килешә торган киемнәрен киенеп урамга чыкты һәм, бераз икеләнеп торганнан соң, кинотеатр бинасына таба китте. Кулында билеты булмаганлыктан, ул керергә өмет тә итмәде. Һәдия килеп җиткәндә, кино башланган, кинотеатр янында кеше

сирәкләнгән иде. Ул теләмичә генә афишалар карый башлады. Шулвакыт Һәдия үзенең артында кемдер басып торганын тойды. Һәм әкрен генә борылып карады. Караса, кулына билетлар тоткан бер егетне күрде. Һәдиянең аның белән сөйләшәсе, бу күңелсез вакытның берничә генә минутын булса да гамьсез үткәрәсе килде.

– Килмәгәнмени? – диде ул, егетнең кулындагы билетларга ишарәләп.

– Кем? – дип сорады егет.

– Кем икәнен каян белим? Берүзегезгә ике билет алмагансыздыр бит.

– Ә мин кайвакыт берүземә дә ике билет алам, бер урынга гына сыймыйм. Әгәр теләсәгез, берсен сезгә дә тәкъдим итә алам.

– Рәхмәт инде, сезне тыгызлыйсым килми. Аннары, минем бу картинаны караганым да бар.

– Алайса әйдәгез, бераз йөреп килик, киче дә бик матур.

– Сезне кинодан калдырырмын бит, – диде Һәдия. Ләкин үзенең егет тәкъдименә каршы түгеллеге күзләренә чыккан иде.

– Барыбер кинога соңга калдык, башын карамагач аңлап та булмас, – диде егет.

Һәдиянең бу якты урыннан тизрәк китәсе килде. Караңгыда ямьсезлеге беленмәс иде, ичмасам.

– Әйдәгез алайса, – диде ул, – йөргән кызыгыз очрап, чәчемә ябышса, яклашырсыз түлке.

– Ә минем беркемем дә юк. Мин бу билетны дус егетемә дип кенә алган идем.

– Шулай диегез инде. Егетләр алар бервакытта да кызларга дөресен сөйләмиләр, алар бар да алдакчылар.

– Әллә алдаганнары бармы?

– Юк. Алдарга, минем беркем белән дә йөргәнем юк. Егетләр бит чибәр кызларны гына яраталар.

– Минемчә, сезне дә табигать ким-хур итмәгән. Талчыбыктай буегыз, тулган айдай йөзегез.

– Әгәр алай көлә торган булсагыз, мин хәзер үк китәм.

– Мин көлмим, дөресен әйтәм. Сезнең кай җирегез ямьсез булсын! Сез бит юри мине үчекләр өчен генә үзегезне кимсетәсез.

– Әгәр мине көндез күрсәгез, куркып качар идегез әле.

– Шулай дигәч, минем сезне көндез дә күрәсем килә башлады инде. Хәер, монда да ямьсез белән матурны аерырлык кына яктылык бар бит. Ягез әле, йә, лампага табарак борылыгыз. Нигә оялмыйча үзегезгә яла ягасыз. Өстәвенә шуңа мине дә ышандырмакчы буласыз.

Һәдиянең бу сүзләрдән башы әйләнеп киткәндәй булды. Ул шушы таныш түгел егетнең мактавыннан моңарчы бер дә татып карамаган җан рәхәте тойды. Күңелендәге яшерен өметләре, яшерен хыяллары кинәт кенә өскә калкып чыктылар, хисләре, тау өстеннән тәгәрәтеп җибәргән таш шикелле, алга, каядыр билгесезлеккә ашкындылар, йөрәк, бәхетнең якынлыгын сизгәндәй, шашып-шашып тибәргә тотынды. Һәдия йомшак кына итеп үзенең култыгыннан алган шушы таныш түгел чибәр егетнең барлык сүзенә дә ышана башлады. Аның бер генә көн булса да бәхетле буласы, ул гына да түгел, үзенең бәхетен башкаларга да күрсәтәсе килде. Миңсылуларга, Рабигаларга, Мөнирәләргә үзенең дә егетләр белән йөри ала икәнлеген исбат итәсе килде.

Алар ул көнне озак йөрделәр. Кайтканда, егет аны тулай торакка кадәр озата барды.

– Әгәр мөмкин булса, мин башка көннәрне дә килер идем, – диде ул.

Һәдия, ризалык биреп, башын какты. Кыз татлы сүзләрдән исерә барган саен, егет тә андый мактауларга юмартлана барды, шул ук вакытта аның кыюлыгы да артты.

– Йә көндез килсәм таный алмам, тагын бер йөзегезгә карыйм әле, – дип, ул, Һәдиянең иягеннән тотып, кызның йөзен үзенә таба борды.

– Алай туры карамагыз инде, оялтасыз бит, – дип, Һәдия читкә борылмакчы булган иде, егет аны җайлы гына итеп кочагына алды да мөлдерәп торган күзләреннән, үбү көтеп торган иреннәреннән үбәргә тотынды. Һәдия бөтенләе белән егетнең кочагына кереп эреде, инде үзенең барлыгын да тоймый башлады. Аның гәүдәсе авырлыгын югалтты, башы рәхәт кенә әйләнде, иреннәре татлы гына сызлады. Һәдия «Безнең ишек төбенә килеп үбешмәсәгез, башка җир беткәнмени?» дигән тавышка гына айнып китте. Ул җинаять өстендә тотылган карактай сискәнеп куйды һәм тавыш килгән якка борылып карады. Анда кинодан кайтып килүче бүлмәдәш дуслары иде.

– Бәтәч, безнең Һәдия бит бу, – диде Миңсылу, гаҗәпләнеп.

– Тәгәрәп үлим, шул.

– Менә сиңа өй тавыгы.

Бу сүзләрне кызлар кычкырып әйтмәделәр. Һәрбер сүзгә турсаерга торган Һәдияне тагын да җәберлиселәре килмәде аларның. Кычкырып әйткән булсалар да, Һәдия аларга бүген ачулана алмас иде. Шатлыгы артык зур, уйлары чуалган иде шул.

Кызлар:

– Һадия, егетең белән безне дә таныштыр әле, – дигәч, ул коелып төште. Чөнки егетнең исемен сорарга моңарчы башына килмәгән иде. Ярый әле егет югалып калмады, Һадиянең исемен беренче тапкыр кызлардан гына ишеткән булса да, тегеләргә җавап табып өлгерде:

– Һадиянең дуслары белән танышырга мин һәрвакыт шатмын. Таныш булыйк: Һашим. Әгәр профессиям кызыксындырса, анысын да әйтергә мөмкин: таксист мин.

– Болай булгач, эшкә соңга калган көннәрдә илтеп куяр кеше булды, – диештеләр кызлар.

– Әйе, соңга калсагыз, туп-туры үземә килегез. Мин күбесенчә Мәскәү районында йөрим. Шул тирәгә килеп эзләрсез.

– Алай ерак түгел икән, җәяүләп барсаң, бер көндә урап кайтып була. Троллейбуста бер сәгатьлек юл.

– Ә сез мине таксига утырып эзләрсез.

Барысы да көлешеп алдылар. Һашим:

– Ә сез кайда эшлисез соң, кызлар? – дип сорады.

– Һадия әйтмәдемени әле?

– Юк, мин әйтмәдем, – диде Һадия, һаман да сүзсез торуны яхшысынмыйча. Ул Һашимның башка кызлар белән сөйләшүенә бераз көнләшә дә башлаган иде инде. – Ярый, бик миннән әйттерәсегез килсә әйтим: без – медиклар. Әнә теге больницада эшлибез.

Һашим Һадия күрсәткән якка борылып карады.

– Мин берни дә күрмим. Әллә, кызлар, алып барып күрсәтәсезме?

– Берәр вакыт Һадия күрсәтер әле, хәзер соң инде, шулай бит, Һадия?

Һадия кызларга җавап бирмәде. Ул аларның тизрәк кереп китүләрен тели иде, ләкин кызлар үч иткән шикелле торалар да торалар. Һашимы да, чибәр кызларны күргәч, Һадиясе барын онытты. Кызның мондый илтифатсызлыкка ачуы килде. Ул кырт кына борылды да: «Сау булыгыз!» – дип, ишектән кереп китте. Ләкин Һашим җитез булып чыкты, тегесе подъезд ишеген ябып өлгергәнче, кызның артыннан куып җитте.

– Әллә ачуландың инде, Һадия? – диде ул, беренче мәртәбә кызга исеме белән дәшеп.

– Ачуланырга син минем кемем соң? – диде кыз.

Алар шулай тиз генә «син»гә күчтеләр

Йөгерә-йөгерә баскычтан Һадиянең иптәш кызлары менеп киттеләр. Алар кереп киткәч, Һашим кызны тагын кочагына алды. Монда тыштагыга караганда якты иде. Коридордагы лампа туп-туры Һадиянең битенә төшә. Башка вакыт булса, ул битен караңгырак якка борган булыр иде, ләкин шатлыгы бүген аңын томалады. Ул хәтта үзләре яныннан сукранып үтеп киткән швейцар карчыкны да күрмәде.

– Монда чит кешеләр алып керергә ярамый, Һадия, үзең дә беләсең бит, – дип килеп әйткәч кенә, щвейцарны күрде. Ул теләмичә генә Һашим белән саубуллашты.

– Ниндирәк вакытларда өйдә буласың? – диде Һа-шим.

– Безнең эш сменалы. Төнлә дә эшлибез, көндез дә. Иртәгә кич өйдә булырмын.

– Алайса, иртәгә кадәр, – диде егет һәм, швейцар карчык каядыр киткән арада, Һадияне үзенә таба тартып бер үбеп алды да йөгерә-йөгерә чыгып китте.

Һадия ул көнне озак йоклый алмый ятты. Аның күз алдыннан озын буйлы, чем-кара кашлы, ягымлы йөзле Һашим китмәде. Колагында Һашимның бераз карлыкканрак тавыш белән әйткән сүзләре яңгырап торды. «Син үзеңә яла ягасың, буй-сының бер дә кешедән ким түгел», – диде бит. Бу сүзләрнең дөреслегенә Һадиянең бик дә ышанасы килде, йөрәге белән инде ул аларга ышанды да, ләкин акыл гына һәрбер матур сүзгә ышанмаска куша. Әмма гашыйк булган кеше акылга түгел, йөрәккә күбрәк таяна шул. Мәхәббәтнең үз логикасы, үз фәлсәфәсе бар. Ә йоклап китәр алдыннан Һадия Һашим сөйләгән сүзләрнең чынлыгына шикләнми иде инде. Ул бүген гомерендә беренче мәртәбә дөньядагы иң бәхетле кешеләрнең берсе булып, иң тәмле төшләр күреп йоклады. Бүлмәдәге кызларның пышын-пышын сөйләшүләре дә, урамдагы фонарьның тәрәзә аша күзгә төшеп торган яктылыгы да тәмле йокысын бүлә алмады.

Көн артыннан көн үтте. Хәзер Һадиягә Һашим белән гомере буе таныш булганнардыр кебек тоела башлады. Ул инде башкалар кино-театрларга киткәндә бүлмә каравыллап калмый, иң беренче кеше булып җыена башлый, Һашим билетлар күтәреп алар бүлмәсенә килеп кер-сә, горурланып куя. Элекке төртмә теллелеге дә кимеп бара. Үзенең өс-башына да күбрәк игътибар итә баш-лады. Бу көннәрдә ул үзенең ямьсез икәнлеген дә онытты. Әйе, моңарчы җанын козгындай чукып торучы әлеге уй кызның күңеленә килеп дә карамады. Эшендә дә аңардагы бу үзгәрешкә игътибар иттеләр. Врач Евдокия Якимовна, кызның балкып торган күзләрен күрү белән:

– Безнең Надя әллә гашыйк булган инде, күзләре төнге учак шикелле балкый, – диде.

Һәдия аңа бер сүз дә әйтмәде, бары тик йөзендәге алсулыгы гына бераз куерды. Авыруларга да Һәдия мөмкин кадәр ягымлырак булырга тырышты. Кулына кашык тотты исә куллары калтырап бөтен ашын түшенә түгеп бетерә торган Сәрби карчыкның янына утырып иплəп кенә ашатты. Операциядән соң мунча сорап сестраларның теңкәләрен корыткан Шакир абзыйның бөтен тәнен спирт белән ышкып чыкты.

– И балам, яңадан туган кебек булдым бит, – диде Шакир абзый, шаярып. – Әле бу тәнне тышкы яктан сөрткәнгә шулай, спирт дигән нәрсә эчкә керсә, бөтенләй баһадир итәр мине.

Һәдия, Шакир абзыйның элек андый нәрсәләрне кулланганлыгын белгәнгә:

– Менә, Шакир абзый, шул эчемлекләр аркасында «баһадир» булып больницага кергәнсез бит инде. Ашказаныгызны шуның белән бозгансыз, – диде.

– И кызым, аның бер йотымы өчен бер ашказанын җәлләмәссең. Каткан сөякләрне камыр итә бит ул.

– Ул турыда хәзер сезгә уйларга да ярамый, Шакир абзый.

– Беләм, кызым. Мин бит шаярып кына. Шуның исемен генә телгә алсам да, рәхәт булып китә. Нишлим соң?

Һәдия башкаларга да шундый ук игътибар, шундый ук ягымлылык күрсәтте. Башка вакыттагы кебек даруларны да авыруларның тумбочкасына гына куеп чыгып китмәде, ә үзе, кайнаган суын алып кереп, эчереп чыгып китте.

* * *

Бәхетле көннәр тиз үтәләр. Һашим белән танышканга да ике атна вакыт үтте. Ләкин ул ике атна Һәдия өчен ике сәгать кебек кенә булды. Шушы вакыт эчендә алар берничә тапкыр пляжга төшәргә, паркларга барырга, әллә ничә кино карарга өлгерделәр. Һашим бигрәк тә су коенырга ярата икән. Һәдиянең ничә ел Казанда торып егетләр белән түгел, кызлар белән дә пляжга барганы юк иде. «Оялмыйча үз тәнеңне ничек кешеләргә күрсәтеп йөрергә кирәк», – ди иде ул. Ә менә Һашим килеп чакыргач, бармый булдыра алмады.

– Кешеләрдән оялсаң, читкәрәк китеп кызынырбыз, – диде Һашим. – Анда бөтен кеше дә шулай бит. Күлмәкчән кызынып булмый лабаса. Үзең медик була торып, нинди дәвага каршы киләсең.

– Мин кызынуга каршы түгел. Тик бер дә бармаган җир булгач, әллә ничек.

– Бер дә исең китмәсен. Оялсаң, кешеләр күрмәсен өчен, күзләреңне үзем кулларым белән каплап торырмын. Мин бәләкәй чакта, өйдә ялгыз калсам, мине кеше күрмәсен дип, күзләремне йомып утыра идем.

Алар икесе дә көлешеп алдылар.

– Алай булгач бармый да булмас шул.

Беренче барганда кешеләр алдында чишенергә тартынып торган иде Һәдия, ләкин Һашимның комплиментлары аның тартынуын җиңәргә ярдәм итте. Һәдияне беренче мәртәбә коену костюмыннан күргәч, ул:

– Шушындый сылу гәүдәне кешеләргә күрсәтүдән оялалармы соң, юләр. Рәссамнар сине күрсә, тәнеңә карап гаҗәеп әсәр тудырырлар иде, җәл, үзем рәссам яки скульптор булмаганмын. Юкса шушы кайнар комнан синең сыныңны ясап, пляжның кеше иң күп кызына торган җиренә бастырып куяр идем.

– Син рәссам булмасаң да, шагыйрь була алыр идең, – диде Һәдия. – Бигрәк матур итеп сөйли беләсең, бәлки, шигырьләр дә язасыңдыр әле, миннән генә яшерәсеңдер. Мин бит синең турыда берни белмим.

– Юләрем минем, шигырьләр язсам, синнән яшереп маташыр идеммени? Тизрәк сиңа килеп мактаныр идем әле.

– Син миңа берни дә сөйләмисең, Һашим. Хәтта мин синең кемнәр белән һәм кайда торганлыгыңны да белмим.

– Мин бер җирдә дә тормыйм.

– Машинаңда гына йокламыйсыңдыр бит?

– Анда йоклаган чаклар да булгалый... Һәдия, әгәр мин сине үзем торган җиргә чакырсам барыр идеңме?

– Нигә бармаска, тотып ашамассың әле.

– Алайса килештек, ярыймы?

– Ыһы.

– Бүген үк барабызмы?

– Бүген үк.

– Кая әле, шул әйбәт сүзең өчен бер үбим үзеңне.

– Юләр, шушы кадәр кеше алдында...

– Кеше карап торса, аны без менә болай да итә алабыз бит. – Һашим шулай диде дә, газета белән йөзләрен каплап, Һәдияне үбеп алды. Аннары кайнар комны учлап алып, Һәдиянең җилкәсенә әкрен генә агыза башлады.

Һәдия әллә кытыгы килүдән, әллә Һашим шулай якын булу рәхәтлегеннән шаркылдап көлде. Үз-үзен онытып шаярды. Ә Һашим, пляждагы йөзләгән кешегә дә игътибар итмичә, һаман саен Һәдия белән уйный бирде.

Алар кайтырга чыкканда, көн сүрелә башлаган иде инде. Һашим юл уңаеннан йөгереп кенә бер кибеткә сугылды. Аннан кәгазьгә төрелгән ниндидер әйберләр алып чыкты.

– Бераз капкалар нәрсә алдым әле, – диде ул. – Юкса мин тора торган җирдә елап эзләсәң дә ашамлык таба алмыйсың.

– Юкка мәшәкатьләнмәскә иде, Һашим. Ачыкмадык бит әле.

– Әле ачыкмасак, тора-бара ачыгырбыз. Анда берни дә табып булмый.

– Син кайда торасың соң?

– Мин абыйларның дачасында яшим әле. Кыш көне бер әбиләрдә фатирда торган идем. Җәй монда килдем. Хәзер барып җитәбез анда. Мин йөгереп кенә такси алып киләм.

– Таксига акча әрәм иткәнче, болай да барып җитәрбез әле.

– Әй, юләркәем, үзем таксист була торып таксига акча түлиләрмени?

Һашим бик тиз генә такси алып килде. Таныш шофёры түгел иде бугай, аны читкәрәк алып китеп нидер аңлатты. Шофёр ризалык белән баш какты һәм, тиз генә машинасына утырып, җилдәй элдереп алып китте. Машина шәһәр читенә чыгып, Идел ярына таба юл алды. Озак та үтми, төрле такта-тордалардан корыштырган дачалар күренә башлады. Шофёр белән янәшә утырган Һашим юлны күрсәтеп барды. Менә алар ун-унбишләп төп алмагач арасында утырган бер будкага килеп туктадылар.

– Менә минем вилла шушы инде, – диде Һашим. – Әгәр килешмәгән җире булса, гаеп итмәссең. Кайчаннан Казанда торып фатир ала алганым юк.

– Күптәнме син Казанда?

– Хәтсездән инде...

– Ә минем монда тора башлавыма биш ел, – диде Һәдия. – Дүрт ел медицина училищесында укыдым, менә эшли башлаганга да бер ел тула.

Алар, сөйләнә-сөйләнә, будкага керделәр. Тышкы яктан кечкенә күренсә дә, эче ярыйсы гына иркен булып чыкты аның. Өйнең уртасында такталардан тупас кына итеп ясалган өстәл, почмакта җыелмалы карават тора. Караватн өстендә керле генә бер одеал һәм бер мендәр. Матрас-фәлән күренми.

Һәдия эчкә кергәч тә урын-җирне рәткә китерде, ә Һашим, өстәлгә газета җәеп, табын хәзерләргә кереште. Кибеттә алган ашамлыклар арасыннан ике шешә дә килеп чыкты. Һәдия, аларны күргәч:

– Боларны нигә алдың инде, Һашим? – диде. – Бу кадәр нәрсәне эчсәң, бүген моннан бөтенләй дә кайта алмассың.

– Кайтмасак, шушында гына кунарбыз. Саф һавада йокы бигрәк тәмле була ул.

– Барган бер җирдә куна башласаң...

– Ә син барган бер җирдә кунма, монда гына, минем янымда гына кун. Йә, ярый, Һәдия, ул хакта соңыннан сөйләшербез, хәзергә бераз тамак ялгап алыйк. Монда стаканнар һәм савыт-саба ише нәрсәләр булырга тиеш.

Ул почмактан чәнечкеләр һәм тузанланган ике стакан тартып чыгарды, аларның берсенә әз генә вино агызды һәм шуның белән бер стаканны чайкагач, виноны икенче стаканга салып, анысын да чайкап түкте.

– Бигрәк оста икәнсең үзең, – диде Һәдия. – Мин булсам, ничек юарга белми аптырап торган булыр идем әле.

– Тормыш өйрәтә ул, – диде Һашим. – Ялгыз кеше бөтенесен дә белергә тиеш.

– Нигә соң моңарчы өйләнмәдең?

– Менә синең кебек кызлар очрамады.

– Сиңа ничә яшь инде?

– Миңамы? Миңа егерме тугыз яшь. Әйдәле, Һәдия, өстәл янына утыр. Ашлар «суына». Иң беренче менә шушы стаканнарны күтәреп куйыйк. Башкаларын күтәрергә җиңелрәк булыр.

– Син, Һашим, әллә мине исертеп екмакчы буласың инде. Бу кадәр эчсәң, үрмәләп йөрергә генә калыр.

– Моның бит сыраныкы хәтле дә градусы юк. Мин аларны су урынына дип кенә алдым. Консервыларны коры килеш ашап булмый бит инде, әзрәк чылатырга кирәк.

– Минем бер дә аның ише нәрсәләрне эчеп караганым юк шул, Һашим. Мәлҗерәп төшәрмен дә үзеңә бәла генә булырмын дип куркам.

– Бернидән дә курыкма. Кулларымда күтәреп алып кайтырмын. Исертә торган нәрсә түгел дидем бит инде.

– Ярый алайса, кабып карыйк. Нишләптер мин синең сүзләреңә каршы килә алмыйм. Училищеда укыган вакытта бер иптәш кызым кияүгә чыккан иде, шуның туенда никадәр кеше кыстап та эчеп карамадым. Туйдан соң да шуның өчен үпкәләп йөрде миңа.

– Әйдә, Һәдия, дуслыгыбыз хөрмәтенә төбенә кадәр күтәреп куй әле.

Һәдия вино тутырып салынган стаканны кулында әйләндергәләп торды да капыл гына эчеп җибәрде.

– И-и, мин моны бик ачыдыр дип уйлаган идем, тәмле икән үзе, – диде ул, стаканның яртылабын эчкәч.

– Әйттем бит мин, газлы су кебек кенә дип. Әйдә инде, яртыга калгач кыстатма, бәхетең ким булыр.

– Әйе, Һашим, мин бәхетемнең ярты гына булуын теләмәс идем. Шушы яшемә җитеп, минем чын бәхетне татып караганым юк әле. Әниебез безне әти кулында калдырып, башка кешегә тормышка чыккан. Әти өйләнгән дә безне детдомга биргән. Миңа башкалар кебек ата-ана назы күреп үсәргә туры килмәде. Шуңа күрәме, мин кешеләргә ышанмыйчарак карыйм. Бөтен кеше дә миңа дошманнарча карыйдыр төсле.

– Ә миңа ышанасыңмы соң? – диде Һашим.

– Ышанмасам, өеңә килеп, шулай тезләреңә утырып, гомердә авызыма алып карамаган нәрсә эчеп утырыр идеммени?

Һәдия стаканындагы виноны эчеп бетерде. Һашим аңа консервыдан бер балык алып каптырды һәм тагын стаканнарны тутырып куйды. Эчкән вакытта бер дә гайрәтле кебек тоелмаса да, Һәдиянең башына китте. Аның битләре кызарды, күз алды бераз томалангандай булды.

– Ай, башым әйләнә, – дип, ул Һашимның муеныннан кочып алды.

Һашим аны аракыдан да ныграк исертерлек итеп үбәр-гә тотынды. Ләкин Һәдиянең җиңелчә баш әйләнүе үтте булса кирәк. Ул, егетнең кулларыннан ычкынып, кочактан чыкты.

– Кирәкми, Һашим, ипле генә утыр, – диде ул.

Һашим, Һәдиянең сүзләренә каршы берни дә әйтми генә, өстәлдәге бер стакан виноны күтәреп эчеп куйды. Аннары ул, акланган сыманрак итеп:

– Кичке салкын төшә, ахры, өшетеп җибәрде, – диде.

– Ай, кич тә була икән, миңа кайтырга вакыт, – диде Һәдия.

– Нинди кайту ди ул, – диде аракыдан исерә башлаган Һашим. – Бүген шушында гына кунабыз инде. Мин сине беркая да җибәрмим. Әйдә, Һәдия, син ашап эч әле. Килгәннән бирле авызыңа валчык та капканың юк бит. Менә бусын да күтәреп куй. Беренче эчкәндә бераз исерткән кебек итсә дә, икенчесендә айныта гына ул.

– Ә минем бүген айныйсым да килми, Һашим. Синең белән танышканнан бирле мин гел исерек төсле йөрим. Бөтен дөнья алсу томан эчендә.

Һәдия шулай сөйләнеп теге стаканны да күтәреп куйды. Бусын эчкәч, ул чынлап та айнып киткәндәй булды. Ләкин бу хәл озакка бармады, ул исерә башлады.

– Әллә монысы бая эчкән вино булмады инде, – диде ул Һашимга. – Бик ачы тоелды.

– Юк, шул ук, – диде Һашим.

Һәдия өстәл астыннан яңа гына Һашим куйган шешәне алып карады. Аның этикеткасына «коньяк» дип язылган иде. Ул Һашимга бармак янады, ләкин ачуланмады. Һашим шешәләрне өстәлдән алып куйды.

– Уф, бигрәк кызу булып китте, – диде Һәдия.

– Кызу булса чишен, – диде Һашим.

– Чишенергә минем өстә болай да күлмәк кенә бит.

– Ә син пляждагыча гына кал. Мин синең мәрмәрдәй матур сыныңа карарга яратам. Шундый гәүдәне күлмәк эчендә яшереп йөрү гөнаһ.

Ул, шулай сөйләнә-сөйләнә, Һәдиянең изүләрен чиште. Аракыдан, бәхеттән, мәхәббәттән исергән Һәдия аңа каршылык күрсәтмәде.

– Йә-йә, кашларыңны җыерма инде, – диде Һашим, – сиңа ачулану бер дә килешми бит. Менә шулай елмаеп та җибәрсәң, бөтенләй матурланасың.

– Һашим, син мине яратасыңмы? – дип сорады Һәдия. – Мине моңарчы беркемнең дә яратканы юк иде. Мин бит ямьсез. Син дә мине яратмыйсыңдыр. Әнә ничек кашларым чабатадай киң, иреннәрем бәлеш кебек калыннар...

– Юләрем, кашларың киң булу бигрәк әйбәт. Киңне тарайту җиңел ул, менә син тарны киңәйтеп кара. Иреннәрем калын дип тә кайгырма, ирене калын кеше усал булмый, ди. Аннары...

– Аннары нәрсә?

– Аннары үбәргә әйбәт димәкче идем.

Һашим шулай диде дә коену костюмыннан гына калган Һәдияне кочаклап алды. Ул үзе дә күлмәген күптән салып ташлаган иде. Һәдия Һашимның эссе тәненнән, аракы исе килеп торган сулышыннан тагын да исерә төште. Алар, кочаклашкан килеш, почмактагы караватка барып аудылар.

Күпме вакыт үткәндер, анысын Һәдия тәгаен генә белә алмады. Ул күзләрен ачып караганда, тәрәзә аша иртәнге яктылык иңә башлаган иде. Һәдия баштарак ни булганын төшенә алмый торды. Янында авызын яртылаш ачып йок-лап ятучы Һашимны күргәч кенә кайдалыгы исенә төште. Ул кичәге хәлләрне берәм-берәм күңеленнән кичерергә тырышып карады. Ләкин әз генә уйлау белән, башы чатнап авыртырга тотынды. Күңеле болганды. Ләкин үкенү, газаплану дигән нәрсә аны артык борчымады.

«Һашим әйбәт егет, – дип уйлады ул, – барырбыз да язылышырбыз. Кызлар белсәләр шәп түгел инде түгелен. Әй, язылышмый торып аларга кем әйтә».

Һәдия шулай уйлап өстендәге одеалын ачып ташлады. Шунда гына ул үзенең күлмәксез ятуын күреп алды һәм тиз генә торып күлмәген киде, чәчләрен рәтләде, кечкенә көзгесен алып, йөзен карады. Күз кабаклары бераз шешенеп киткән икән, хәер, нигә борчылырга, Һашим аны ничек булса да ярата ич.

Һашимның гамьсез йөзенә карады. Тыныч кына гырлап йоклап ятучы Һашимны күргәч, Һәдиянең йөрәге сулкылдап куйды, күңеле ниндидер бәхетсезлек сизгәндәй тынычсызланырга, борчылырга тотынды. Һәдия, мондый күңелсез тойгыларга бирелмәскә теләп, Һашимны уятырга кереште. Ләкин Һашимның йокысы ачылмады. Ул бер яктан икенче ягына әйләнеп ятты да тагын гырларга тотынды. Һәдиянең ачуы килә башлады, ул, сабырсызланып:

– Һашим, тор инде, мин туңам бит, – дип, Һашимның муенын кытыкларга тотынды.

Һашим күзләрен ачты һәм гаҗәпләнгәндәй Һәдиягә карады, аннары сикереп торып киенеп куйды.

– Да, кичә күбрәк эчелгән, ахры, баш шаулап тора, – диде ул, Һәдиягә бөтенләй күтәрелеп карамыйча.

– Һашим! – диде Һәдия, бераз каушап.

– Нәрсә?

– Хәзер мин нишлим инде?

– Ничек инде «нишлим»? Хәзер кайтырга кирәк, менә шул, минем дә эшкә барасым бар.

– Ә мин ничек итеп өйгә кайтыйм бу килеш? Кызларның күзенә ничек күреним?

– Менә тагы, юкны сөйләмә. Сиңа нәрсә булган?

Һәдия, Һашимның аңламаганга салышып торуын күр-гәч, әрнеп елап җибәрде. Хәзер генә ул үзенең нинди фаҗигагә таруын төшенде. Һашим кызның елавын күреп бик йомшап төшмәде, тик шулай да юату теләге белән Һәдиянең башыннан сыйпады.

– Бала булма инде, Һәдия, – диде ул, – мин хәзер генә нишли алам. Өйләнергә өем юк. Үзем дә кеше өстендә генә торам бит. Анда сине алып кайтып бәхетсез итәсем килми.

– Өең булмаса, менә шушында торырбыз, – диде Һәдия.

– Их, балакаем минем. Хәзер бит бер айдан тышта йок-лап булмый башлый. Салкыннар җиткәч нишләрбез?.. Ярый, Һәдия, хәзергә сүзне озакка сузмыйк әле, синең дә, минем дә эшкә барасы бар. Машинам буш торса, башымнан сыйпамаслар. Ул мәсьәлә турында берәр иркенрәк чакта сөйләшербез. Хәзер өйне беләсең инде, килгәләп йөр. Ачкыч менә ишек башында. Әгәр мин кайтып җитмәгән чак булса, ачып керерсең.

Һашим, шулай сөйләнеп, Һәдиягә авыз ачарга да ирек бирмәде. Һәдия, башын түбән игән килеш, игътибарсыз гына Һашим артыннан атлый бирде. Бакчадагы чут-чут сайраган кошлар тавышы да, алма исләре алып килгән иртәнге рәхәт җил дә аның күңелен күтәрә алмады. Ул тулай торакка кайтып кергәндә, кызлар өйдә юк иде.

«Ярый өйдә юклар әле, юкса, кайда булдың, дип сорашып теңкәгә тиярләр иде, – дип уйлады Һәдия. – Өс-башларны да алыштырырга кирәк. Ләкин каһәр төшкән баш бик авырта, кузгаласы да килми. Бу вино дигән нәрсә бик яман була икән. Эт иткән кешене. Әллә соң бераз йоклап алыргамы? Төнгә дежурга да барасы бар. Бу килеш ничек эшләрмен? Чынлап та ятып алырга кирәк. Рәтләп йокламаганга да баш авыртадыр».

Һәдия, үз-үзенә шулай сөйләнеп, караватына ауды һәм шунда ук йокыга да китте. Икенче ягына да әйләнеп ятмыйча, кичкә кадәр йоклады ул. Һәдия уянганда, Мөнирә белән Рабига эштән кайтканнар иде инде.

– Безнең Һәдиягә гыйшыкның катысы эләкте, ахры, төнлә дә үз яныннан җибәрми, – диде Рабига.

– Яныннан китсәм, егетемне башка кызлар урлар дип куркадыр ул, – диде Мөнирә.

– Авызыгызны ермагыз, зинһар, күңелемне болгатасыз.

– Артык татлы мәхәббәт күңелне болгатуы да ихтимал.

– Әллә көнләшәсезме?

– Көнләшмәгән кая! Ул кадәр татлы мәхәббәт һәркемгә эләгәмени?

– Җитәр сезгә! Сез егетләрегез белән чырык-чырык килешеп чытлыкланып йөргәндә, мин бер сүз дә әйтмәдем бит. Бик көнләшсәгез, сез дә барып куныгыз, кешедә эшегез булмасын, мин теләсә нишләрмен. Мин сезнең кебек егерме яшькә хәтле ана куенында үсмәдем, миңа мәхәббәтнең һәр минуты кадерле. – Һәдия кызларга ачуланып киенә башлады. – Әгәр мине бик күпсенсәгез кайтмам, – дип, шап итеп ишекне ябып чыгып китте.

Кызларга шулай сер бирмәскә тырышса да, үзенең күңелендә дә Һашимга рәнҗү һәм ачу бар иде аның. Һашимның берни булмагандай гамьсез булуы, төрле юк-бар сөйләп сүзне икенчегә борырга теләве исенә төшеп, сызлаган йөрәкне әрнетеп җибәрде.

«Бүген үк Һашимны күреп хәлне ачыкларга кирәк. Бер көн эшкә бармаганнан гына дөнья җимерелмәс. Барыбер эшләрлек рәтем юк. Кыйнап ташлаган кебек бөтен тәнем авырта».

Һәдия автоматтан больницага шылтыратты.

– Башым бик авырта, бүген эшкә килә алмыйм, көн-дезге сестра минем урынга калып торсын инде, – диде. Телефон будкасыннан чыккач, Һәдия туп-туры Һашим янына китте. Башында аның төрле уйлар кайнады, күңеле алда упкын барын тойгандай шомланды, сыкранды, сызлады.

«Иртәрәк килдем, ахры, Һашим эштән дә кайтмагандыр әле. Урамда булса да бераз йөрисе калган», – дип уйлады ул, дачага килеп җиткәндә. Килеп җиткәч, ялгызы бу шыксыз бүлмәгә керәсе килмичә, озак кына ишек төбендә утырды. Аннары, Һашим кайтканчы бераз урын-җирләрне җыештыра торырмын, ичмасам, дип, эчкә керәсе итте. Үрелеп, ишек башындагы ачкычны эз-ли башлады, ләкин ачкыч иртән куйган урында юк иде. Һәдия шикләнеп як-ягына каранды һәм аптыраганнан гына ишекне тартып карады. Аның гаҗәпләнүенә каршы, ишек ачык булып чыкты. Ул кыяр-кыймас кына эчкә керде һәм, караватта йоклап ятучы Һашимны күреп, баскан урынында туктап калды. «Мин, Һашим эштән кайтмагандыр дип, керергә куркып торам. Ул мине көтә-көтә йоклап киткән инде. Кызык итим әле үзен», – дип уйлады.

Һәдия үлән алды да Һашимның бите буйлап йөртә баш-лады. Һашим күзләрен ачмый гына битенә сугып алды. Һәдия тагын-тагын шулай итте һәм Һашимның «чебен»ләнүенә түзә алмый көлеп җибәрде. Аның көлүе Һашимны йокысыннан уятты.

– Һәдия, син нишләп монда?

– Килгәләп йөре, дидең бит үзең. Менә сине сагындым да килдем.

Һашим Һәдиягә нидер әйтмәкче булган иде дә, тыелып калды. Бераз үзен кулга алгач:

– Килгәч, бик әйбәт булган, – дигән булды. – Мин дә сине сагынып беткән идем. Йә, ни хәлләр бар, сөйләп җибәр.

– Ни булсын инде, менә бүген эшкә бармадым, шул. Һашим?!

– Нәрсә?

– Ни... Мине монда кунган өчен кызлар ачуландылар.

– Ә син, юләр, мин Һашим белән йокладым, дип кайтып сөйләдеңме?

– Сөйләсә ни булган?

– Һәдия, син кайчак бигрәк бала-чага кебек кыланасың. Әзрәк акыллырак булырга кирәк, син бит хәзер хатын кеше.

Ул «хатын кеше» сүзенә юри басым ясап әйтте. Һәдия аның ирониясен сизде, ләкин ни дияргә белми аптырап калды.

– Үзең кичә генә мине «акыллым» дип ярата идең, хәзер юләргә әйләндеммени? – Һәдиянең күңеле тулып китте. Ул читкә борылып мышкылдарга тотынды.

– Йә, ярар инде, юкка ачуың килмәсен, – диде Һашим, аны юатырга теләп. – Үткән эшкә салават, ул турыда синең белән миннән башка беркем дә белми.

– Ә мин аны яшерергә теләмим.

– Теләмәсәң, бөтен кешегә сөйләп йөр алайса.

– Сөйләрмен шул.

– Нәрсә дип?

– Кияүгә чыктым, дип.

– Өйләнергә минем өем юк, шуны аңла син, Һәдия. Кыш көне монда тора алмабыз бит.

– Кышка фатирга чыгарбыз.

– Алай ансат кына фатир табып булса, мин монда да ятмас идем.

– Ә соң кайчан язылышабыз?

– Күз күрер әле, – диде Һашим. – Хәзергә бер дә рәт юк. Язылышсаң, туй кирәк, туй ясарга сый кирәк. Кесәдә сукыр бер тиен булмаганда эшли торган эш түгел бит бу. Ә син, Һәдия, бер дә кайгырма, бер җае чыгар. Хәзер менә тагын төн җитте, берүзем йокларга куркып тора идем, килеп әйбәт иткәнсең.

– Моңа кадәр курыкмагансың бит.

– Моңа кадәр бит ул. Ә хәзер менә синсез йоклый алмыйм. Кил әле, яныма утыр. Бүген урынны да йомшак иттереп җәйдем. Матрас урынына зур капчыкка үлән тутырып аска салдым. Бераз капкалап алган булыр идек тә, ашардай нәрсә калмаган. Кибеткә барып кайтыйммы?

– Кирәкми, Һашим, берни дә ашыйсы килми.

– Алайса әйдә, яныма кил.

Шушы күрешүдән соң Һәдия Һашимны атнага якын күрмәде. Ул төнлә больницада дежур торды, ә көндезләрен барса, Һашим эштә булыр дип уйлады. Менә бүген Һәдиянең ял көне, ул әйбәтләп төзәтенде, Һашимны беренче күргәндәге киемнәрен киде, бергә ашарга булыр дип, бераз тәмле ашамлыклар да алды һәм очынып-очынып өйдән чыгып китте. Аның бүген күңеле күтәренке, йөрәге ашкынулы, ул Һашимга бик яхшы сюрприз әзерләде: фатир тапты. Больницадагы санитарка Сәрбикамал апа аларны үзләренә кертергә ризалык бирде. Ну шатланыр да инде Һашим! Ярый ла сөенеченнән йөрәге ярылып үлмәсә.

Һәдия, Һашимны шатландырырга теләп, шул уйлары белән үзе дә куанып барды. Һашим да аны теге көнгә караганда ягымлырак каршылады. Һәдия килеп керү белән, аның кулындагы сумкасын алып куйды, табын әзерләде. Беразы эчелгән аракы шешәсе дә өстәлгә менеп утырды. Һәдия, ул шешәне күргәч:

– Бүген син моны эчмәскә тиешсең, – диде. – Мин сиңа бик зур шатлык алып килдем. Шатлыгыңнан исерерлек.

– Нәрсә?

– Йә, үзең уйлап кара әле, Һашим. Иң зур теләгең нәрсә икән.

– Минем теләкләрнең барысы да зурлар.

– Шулай да.

– Шулай дамы?.. Бер дә белмим шул. Йә, Һәдия, интектермә, тизрәк әйт. Берәр «Москвич» отмагандырсың бит?

– Шофёр кешенең бар уе машина булыр инде.

– Алайса, нәрсә соң? Заемга акча оттыңмы?

– Алайсамы?..

Шулвакыт дөп итеп болар янына 28–30 яшьләр тирәсендәге бер хатын килеп керде. Аның ишек какмый-нитми килеп керүеннәнме, әллә башка нәрсәдәнме, Һашим бөтенләй коелып төште. Кергән хатын, Һәдияне бөтенләй игътибарга да алмыйча, Һашимга карап сөйли башлады:

– Эзли-эзли җаным чыкты, бигрәк эчкәре кунаклагансың. Менә повестка килде, иртәгәгә безне судка чакырганнар.

– Йә, нәрсә лыкылдап торасың, – диде Һашим, – язуыңны калдыр да тай.

– Өченче кәләшкә мишәйт итәмме әллә?

– Нәрсә сөйли ул, Һашим? – дип кычкырып җибәрде Һәдия. – Нинди өченче кәләш ул?

– Әле син Һашимга әйләнденңмени? Мин сине Мөдәррис дип йөри идем. Синең белән өч ел яшәп, чын исемеңне дә белмәгәнмен икән. Әллә хатын алыштырган саен исемеңне дә алыштырасыңмы?

– Сөйләнеп торма монда, хәзер үк чыгып кит, – дип кычкырды Һашим.

– Кумасаң да, мин монда тормыйм, яныңда торырлык булсам, судларга биреп аерылырга йөрмәс идем. Ә син, килен, ни исемле буласың соң? Бик яшькә охшамыйсың, ә шул кабахәтнең тырнагына килеп капкансың. Хәер, аның ал теле әллә кемнәрне алдарлык. Ул сиңа тамак ялына абзыйларының бакчасын саклавы турында да әйтмәгәндер әле, берәр җирдә эшлим, дигәндер. Типсә тимер өзәрлек килеш, алимент түләүдән куркып, эшкә керми йөри, оятсыз.

Һәдия бу сүзләргә ни диярге дә белмәде. Аның бөтен өметләре, бөтен хыяллары кинәт яшен сугып яндырган агач кебек юкка чыктылар. Ул Һашимга да, үзе өчен җан тетрәткеч хәбәр алып килгән хатынга да берни эндәшә алмады. Мәхәббәт шәрабыннан исереп, бәхет канатларында биектә-биектә очканда, кинәт кенә аның канатларын кистеләр. Ул бик каты бәрелеп җиргә егылып төште, артык каты бәрелүдән башы миңгерәүләнеп китте.

Теге хатын повестканы өстәлгә ташлап чыгып китте. Һашим белән икәүдән-икәү генә калгач та, Һәдия тиз генә аңына килә алмады. Исенә килгәч, аның беренче уе тизрәк бу өйдән китү, бу оятсыз кешедән котылу булды. Ләкин дәлилләр нихәтле генә чын булмасын, Һашимның начар кеше булуына бөтенләй үк ышанып бетми иде әле ул. Кызның күңелендәге яшерен өмет бөтенләй сүнеп бетмәгән иде. Ул:

– Чынлап та болар бар да дөресме? – дип ачыргаланып сорады.

Һәдиянең шикләрен дөресләгәндәй, ачык калган ишектән кергән җил өстәлдәге теге кәгазьне очырып төшерде. Кыз аны кулына алып карамады, аягы белән Һашимга төртеп җибәрде:

– Җирдә аунатма, кесәңә сал!

Һашим кәгазьне кесәсенә бөкләп тыкты, аннары:

– Нәрсәгә бәбәкләреңне акайттың? – дип кычкырына башлады. – Әйдә, булган булсын, син дә җикерен.

– Мин сиңа ачулана алмыйм, күбесенә үзем гаепле, – диде Һәдия. – Ләкин син миңа шуны әйт әле: яраттыңмы син мине, юкмы?

– Ха-ха-ха! Мин сиңа кайчан «яратам» дип әйттем? «Яратам» димәсәм дә әле атылып кочагыма ташландың бит? Әйткән булсам, сагыз кебек ябышкан булыр идең.

Һәдиянең күңелендәге соңгы өмет чаткылары да сүнде. Әгәр Һашим «яратам» дисә, гафу үтенеп аягына егылса, ул, бәлки, кичерә алган булыр иде. Әмма Һашимның авыз ерып мәсхәрәләвен күтәрә алмады, бар көче белән селтәнеп, Һашимның ерык авызына берне кундырды да аны бөтенләйгә ташлап чыгып китте. Ул бүген Һашимга да, үзенә дә, яман хәбәр китергән хатынга да чиксез ачулы иде. Аның дөньядагы бар кешедән үзенең бәхетсезлеге өчен үч аласы килде. Һәм ул моннан соң беркемгә дә ышанмаска, мөмкин булган кадәр ачуын кайтарырга үз-үзенә сүз бирде.

## АНА ҺӘМ БАЛА

Бала үскән саен мәшәкате арта дигән сүзләргә ышанмый иде Рәҗибә. Баксаң-күрсәң, чынлап та шулай икән. Бердәнбер Фәйрүзе бәллүдә вакытта әнкәсе янында булса, шуңа риза иде, теле ачылып, тәпиләре теләгән җиргә йөртә башлагач, таләпләре бермә-бер артты. Сөйләшмәгән чагындагы таләпләрен аңламаганга салышып булса да, теле ачылгач, сүзен ишеттерерлек итеп әйтә башлады. Бишектә чакта калдыргалап чыксаң, үз тәпиләре белән җирдә йөрү рәхәтен татыган баланы алай калдырып та булмый икән. Бала үзенең «нигә?», «ни өчен?»нәре белән атлаган саен йөдәтеп тора. Шул «нигә»ләрнең һәрберсенә җавап табарга, җавабыңны бала төшенерлек итеп әйтә белергә кирәк.

Фәйрүз иртән тора да сораулар яудыра башлый:

– Әни, ни өчен юыналар?

– Ап-ак булыр өчен, улым.

– Нигә соң юып-юып та минем атым ап-ак булмый?

– Чөнки ул үзе кара, шуңа агармый.

– Ә ни өчен ул кара?

– Карадан ясалганга кара.

– Ә ни өчен чәч кара, бит ак? Нигә чәч югач та агармый?

Мондый «ни өчен»нәрне Рәҗибә ярыйсы ук ерып чык-са да, сораулар катлаулана, күбәя барган саен, җа-ваплары әзәя бара аның. Чөнки нинди сорауга ничек җавап бирергә белми, ә белмәгән килеш баланы бозып куюың бар. Шуңа күрә дә Рәҗибә Фәйрүзен чын-чынлап «китапча» тәрбияләргә тотынды. Башта ул радиодан сөйләнгән төрле киңәшләргә, әңгәмәләргә колак салды, тора-бара болар гына җитми башлады. Берәүләр аңа Ян Коминскийны, икенчеләр Макаренконы, кайберәүләр Крупскаяны укырга киңәш иттеләр. Рәҗибә һәркемнең сүзенә колак салды, тәкъдим ителгән китапларны бик җентекләп укыды. Газета-журналлардан тәрбия темасына язылган мәкаләләрне, кисеп алып, аерым альбомга ябыштыра барды. Шуңа да улының «ни өчен»нәренә җавап табып бетерә алмады.

«Пединститутка кер, системалы белем алсаң әйбәт булыр», – диделәр аңа дуслары.

«Чынлап та, ник соң мин башта ук шулай итмәдем? Улым тугач та кергән булсам, инде ике курс бетерә идем. Минем профессиям әйбәт әйбәтен, ләкин бит һәр педагог укытучы булырга димәгән. Үз эшемдә дә эшләрмен, читтән торып укырмын да», – дип уйлады Рәҗибә.

Рәҗибә институтка керде. Фәйрүзенең сорауларына да, үзенең сорауларына да җавап эзләде. Ә инде улы җиде яшькә җитеп, мәктәпкә кергәндә, Рәҗибә институтны бетереп йөри иде.

Фәйрүз музыканы бик яратучан бала булды. Башта әнисеннән гармун алдырды, ләкин ул гармунның төй-мәләре астындагы пружиналары бик тиз сынып, күреген әз генә тартсаң да төрле тавышлар чыгарып акыра башлагач, аннан туйды. Инде пианино кирәк иде. Рәҗибәнең чын пианино алырлык акчасы булмаганлыктан, уенчыкны гына алып бирде.

Улының музыкага дәрте барын күреп, Рәҗибә аны җиде яше тулу белән музыка мәктәбенә илтте. Фәйрүз до-ре-ми-фа-сольләр эченә чумып, чыгар юл тапмый утырган чакларда, үзенең музыкадан белеме юклыкка бик пошына иде Рәҗибә, бармак буе баланың дәресләрен карашырлык, белмәгән урыннарында этеп җибәрерлек тә белеме булмагач, ул нинди ана инде.

Тотты да бер профессордан үзе дә дәресләр ала башлады Рәҗибә. Пединститут бетерүе һәм баласына булган мәхәббәте артык көчле булуы нотадагы кәкре-бөкре таякларны тиз аңларга ярдәм итте аңа. Бармаклары да фортепьяно өстендә шактый җитез бии башладылар.

– Сезгә чак кына элегрәк тотынырга иде, талантыгызны тутыктыргансыз, – дип, профессор аны шелтәләп тә алгалады.

– Миңа баламны өйрәтерлек кенә кирәк, – дип котыла иде андый чакта Рәҗибә.

Улына музыкадан бирелгән мәсьәләләрне, өйгә бирелгән эшләрен төшендерерлек көч сизгәч, Рәҗибә иркен сулап куйды. Фәйрүзенең дә дәресләре күзгә күренеп әйбәтләнде, хәтта класс җитәкчеләре: «Бөтен укучылар да менә Фәйрүз кебек булсыннар иде», – дип мактап та җибәргәли. Анага шуннан башка ни кирәк тагын?

Бала тәрбияләүдә шактый тәҗрибә туплап, бик күп әдәбиятлар укып йөри торгач, Рәҗибә үзе дә шул темага мәкаләләр язгаларга кереште, киңәш сорап килгән хатлар да күбәйде. Вакыты тыгыз чакларда да Рәҗибә мондый хатларны җавапсыз калдырмаска тырышты, хәер, соңгы вакытларда ул шактый бушады. Алты-җиде ел буе бер генә минутка да тик тормаска өйрәнгән ана, укулары беткәч, ничектер җиңеләеп калды. Вакыты артык күбәйде. Ләкин аңа болай озак йөрергә туры килмәде. Уйламаганда Фәйрүз чирләп китте.

Врач малайга уколлар язды. Гомерендә бер мәртәбә дә тырнак белән дә чиртмәгән улына юан-юан энәләр белән укол кадауларын карап тору аңарга авыр иде. Җитмәсә, медсестралары да бик җайсыз эшли, уколны авырттырып кадый. Энәсе бик тупас, ахры, йоп-йомшак тирегә дә кертә алмый азаплана. Үзе кадаса, җайлап кына, йомшак кына итеп кадар иде дә бит Рәҗибә, юк шул, медик булмаган. Әллә соң?.. Әллә соң медицина училищесына кереп укыргамы?

Фәйрүз терелеп беткәч тә, Рәҗибә училищелар белеште.

Институтка ук кермәкче иде, ләкин бер танышы: «Рәҗибә җаным, институтына караганда училищесы әйбәтрәк аның, нигә дисәң, врачлыкка укып чыккан кешеләр берсе дә рәтләп укол кадый алмый, ә училищеда настоящий практиклар әзерлиләр», – дигәч, тегенең сүзләрен тыңлады.

Хәзер инде Рәҗибә эштән кайта да кичке укуга йөгерә. Авырсыну дигән нәрсәне белми ул. Авыр булса соң, барысы да үз баласы өчен бит. Тагын әллә ничә институт бетерерлек көч сизә әле ул. Үзенә әле аның кырык та юк, ә улына унике генә.

## УРМАНЧЫ КЫЗЫ

Боз китә. Су буе балалар шау-шуыннан, агачлар шау-лавыннан һәм бер-берләренә бәрелеп шартлап ярылуыннан гөр килеп, шаулап тора. Елгыррак малайлар яр буена килеп бөялгән бозларга сикереп менәләр дә, тирес һәм төрле чүп-чар өеп, ут төртеп җибәрәләр. Зурраклары, ятьмәләрен болганчык суга тыга-тыга, балык эләктерү ягын карыйлар. Ә яр өстендә, бераз читтәнрәк өлкәннәр карап тора. Алар берни белән дә мәшгуль түгел, бары тик ярсып-ярсып аккан елганы гына күзәтәләр. Ә бозлар ага да ага. Бер караганда, алар әлсерәгән сарык көтүе кебек тыныч кына торсалар, икенче караганда, ачудан ярсыган дошман гаскәредәй, тыныч торган ярларны штурмларга тотыналар. Калын бозлар тешләрен ыржайтып ярларын кимерәләр. Елга ачулы, әйтерсең ул кыш буе хәрәкәтсез яткан ачуын кемнәндер алырга тели.

Ә ярның теге ягында, зур, ялгыз зирек агачын кочак-лап, бер кыз басып тора. Аның күзләре моңсу, йөзендә чиксез зур сагыш һәм хәсрәт чагыла. Җил аның тыгыз, йомры гәүдәсен күтәреп алып китәргә теләгәндәй шашып-шашып исә. Кысып бәйләгән зәңгәр яулык астыннан чыгып торган маңгай чәчләрен тузгыта. Кыз маңгаена төшкән чәчләрен дә рәтләп куймый, әйтерсең ул ярсып искән җилне дә, үкерешеп аккан бозларны да күрми. Давылда сыгылган яшь каен кебек, аны үз кайгысы сыгып төшергән. Ул елгага карап шатлана алмый, бозлар үзләренең озын тешләрен ярларга китереп батырган саен, кыз да тешләрен кысып куя. Әйтерсең лә бозлар ярларга түгел, ә аның йөрәгенә китереп кадыйлар.

Әйе, аның кайгысы зур. Кызны үлемнән коткарган кешенең гомерен урлады бу елга. Моннан соң кыз бервакытта да табигатьнең бу ярсу көченә тыныч күңел белән карый алмас инде. Быелгы яз аның йөрәгендә төзәлмәс яра калдырды.

Өченчекөн генә әле ул нинди шат, нинди бәхетле иде. Кар астыннан яңа калкып килүче умырзаялар җыеп, букет ясады. Кәкре каен ботагына асылынып, туйганчы атынды, елгалар ерды. Бабасына агачлардан төрле кортлар чүпләшергә ярдәм итеште. Инде көн шулай шатлыклы гына үтеп барганда, ул бәхетсезлеккә юлыкты. Берни уйламый йөгерә-йөгерә өенә кайтып килгәндә, карлы чокырга чумды. Чокыр ярыйсы ук тирән, ә төбендә су иде. Кыз озак маташты. Салкыннан тәнен көзән җыерды. Барлык киемнәре, манма су булып, аны һаман аска сөй-рәделәр. Тотынган саен җепшек кар ишелеп, чыгарга ирек бирмәде. Кыз актык көчен куеп кычкырып җибәрде һәм янындагы бер агачның сузылып торган ботагыннан эләктереп алды. Салкын кар суы аны җелекләренә кадәр өшетеп өлгергән иде инде. Ул, дер-дер калтырап, бабасы янына, урман йортына чапты. Ә кичкә таба аның бик нык тәне кызыша башлады. Бабасы кызның тәнен спирт белән ышкыды, җәй көне җыеп киптергән ниндидер яфраклар алып кереп аркасына япты. Болардан соң кыз калтыравыннан бераз туктады, йокымсырап алды. Ләкин аның тынычлыгы озакка сузылмады, бөтен тәнен көзән җыерырга тотынды. Кыз бөтенләй бөреште, тартышты. Бабасы үзенең бердәнбер оныгының үлем белән тартышып ятканын тыныч кына күзәтеп тора алмады, тиз генә якындагы авылга хәбәр итәргә чапты. Иң якын авыл Умарталы авылы иде, ләкин анда барыр өчен елга аркылы чыгарга кирәк, ә елгада боз күтәрелеп килә. Харис бабай үзе өчен кайгырмады, үзе ул мондый гына елгаларны түгел, моннан ун тапкыр зурракларын да кичкәне бар. Ә менә врач бер белмәгән урманчы оныгы өчен күрәләтә үлемгә барырмы соң? Менә шул сорау борчыды аны. Чынлап та, бу бик хаклы борчылу иде. Яз кояшының кайнар карашы астында эреп таркалырга торган калын бозлар менә-менә бөтенләй убылып төшәр кебек. Кайбер урыннарда боз өстенә су чыккан да бөтенләй бозы булмагандай агып ята. Харис бабай мондый урыннардан бик сакланып, таягы белән бозның ныклыгын тикшереп кенә атлый. Алай да вакыт-вакыт аягы ярылган боз араларына төшеп киткәли. Аның итек кунычларыннан аягына су үтеп кергән һәм атлаган саен лачтор-лочтыр килеп эчне пошыралар. Харис карт, ниһаять, ярның икенче ягына чыгып җитте һәм, итегендәге суны да түгеп тормыйча, авылга ашыкты.

Авылга килеп җиткәч, Харис карт туп-туры медпунктка юнәлде. Ләкин юлы уңышсыз булып чыкты, медпункт-та җыештыручы карчыктан башка кеше юк иде.

– Духтырыбыз Каенлыкка китте шул, – диде җыештыручы карчык. – Киткәненә ике көн инде, нишләптер кайтып җитә алмый әле. Юллар өзелеп, тоткарланып ятамы?!

– Алай икән! – диде Харис карт, көрсенеп. – Инде кая барыйм микән соң?

– Духтыр бик кирәк булса, теге Зарифуллага барып кара, – диде җыештыручы. – Ул пенсиядә булса да, кеше йомышын аяк астына салып таптамый.

– Аларның өйләре кай тирәдәрәк?

– Моннан әллә ни ерак түгел, чыгу белән калай түбәле йорт, аннан соң рәттән дүрт шифр түбәле, аларны үткәч, тагын алты чүлмәк түбәне үтәсең дә, җиденчесе Зарифулла абзыйлар.

Харис карт, җыештыручы карчык өйрәткән буенча, түбәләр санап Зарифуллаларга китте. Ул килеп кергәндә, карт фельдшер балык тотарга ятьмәләр үреп маташа иде. Аларның бөтен өйләре җеп белән чорналып, үрмәкүч оясына охшап калган. Картның җыерчык баскан, ләкин ягымлы йөзендә үз эше белән бик нык мавыгу сизелә. Ул хәтта Харис карт кергәнне дә сизми калды. Ә күреп алгач, акланган сыман:

– Менә яз җитте бит, балыкка йөрергә иде исәп, – дип куйды. – Хәзер безнең ише карт-корыга шуннан башка эш тә калмады инде.

– Эшләгән кешегә эш бар инде анысы, – диде Харис карт. – Менә мин дә сиңа бик зур йомыш белән килгән идем әле. Кыз чирләп китте. Пунктка барган идем дә, духтырлары күрше авылга китеп, кайта алмый ята икән.

– Алай?! – диде Зарифулла, Харисның хәленә кереп. Үзе шунда ук кулына чорналган җепләрне сүтеп ташлады. – Ә соң безнең Микулай фельдшер миңа ачуланмас микән? Аның эшенә тыкшыну була бит бу. Мин бит хәзер правасыз кеше.

Шулвакыт эчке яткан чыгып килүче хатыны сүзгә кушылды:

– Нәрсә сүләнеп торасың инде, кеше анда ут йотып ярдәм сорарга килгән, ә син «правам юк» дип маташасың. Кешегә ярдәм итү правасын синнән беркем дә алмаган. Пенсиягә чыктым дип, мич башына менәргә ашыкма әле.

Карчыгының бу сүзләрен ишеткәч, карт, бераз рән-җеп:

– Мин бармыйм дип әйтмәдем бит әле. Син бигрәк төптән каера башладың. Минем мич башына менәргә җыенганым юк, – диде. Һәм үзе чуалган җепләрен дә җыештырып тормыйча җыенырга тотынды.

Ул никтер каушап киткәндәй күренә. Пальтосын кулына алгач, әллә никадәр вакыт җиңнәрен табалмыйча торды. Пальтосын өстенә кигәч, кулындагы бүреген эзләп мәшәләнде. Белмим, нәрсә аны шулай дулкынландыргандыр. Бәлки, үзенең тагын кешеләргә кирәклеген тоеп шатланудан каушагандыр. Бәлки, моннан 40

ел элек беренче тапкыр авыруга ярдәм күрсәтергә баруы исенә төшкәндер. Ничек кенә булмасын, карт дулкынланган иде.

Елганы кичү хәвеф-хәтәрсез генә үтте. Харис бабасы карт фельдшер белән килеп кергәндә, Роза, мәк чәчәгедәй кызарып, урын өстендә ята иде. Картлар килеп кергәч, ул аз гына башын калкытып карады да тагын да бөркәнебрәк ятты. Бик нык калтыраудан кызның тешләре тешкә тими. Калтырануын басар өчен, ул тешләрен кысып карый, ләкин файдасы юк. Зарифулла авыруны карар алдыннан башта бик әйбәтләп сабынлап юынды, операциягә әзерләнгәндәй кат-кат сөртенде, тик шуннан соң гына, ак халатын киеп, кыз янына килде. Авыруның диагнозын ул Харис картның сөйләве буенча ук чамалаган иде. Ләкин тагын җентекләп ничек авырып китүе турында сорашты, пульсын тыңлады һәм тәненең кайнарлыгын үлчәде. Кызның хәле җитди иде. Кичекмәстән пенициллин ясарга кирәк!

Зарифулла алып килгән медикаментлары арасыннан шприцын табып кайнатырга куйды да даруларын бар-ларга тотынды. Кечкенә чемоданда үзенә кирәкле даруның булмавын күргәч, карт куркып китте. Ул берьюлы бөтен нәрсәсен бушатып ташлады. Ләкин пенициллин бик аз, бары берничә мәртәбә укол ясарлык кына алынган иде. Пенициллин урынына карт шуңа охшашлы башка шешәләр алган булып чыкты. Карт гайрәте беткән күзләрен шелтәләп алды. Нишләргә? Кызга дүрт сәгать саен укол ясап торырга кирәк. Ә аның даруы бер көнгә җитәрлек кенә. Кызның ике як үпкәсе дә шешкән булырга тиеш, кимендә бер атна өзлексез дәваларга кирәк. Больницага җибәрү турында уйларга да мөмкин түгел – елгада боз күтәрелергә тора. Мондый чакта күрәләтә кешене үлемгә җибәрү генә булачак...

Шприц күптән кайнап чыкты, ләкин карт фельдшер артык борчылуыннан аны күрмәде. Бары тик ул турыда Харис карт исенә төшергәч кенә айнып китте. Харис карт, аның кинәт бик күңелсезләнеп китүен күргәч, үзенчә юрады: «Розаның хәле бик куркыныч, ахры», – дип уйлады ул һәм, фельдшерның икенче якка чыккан вакытын туры китереп, ни өчен кинәт борчуга төшүен сорады.

– Кирәкле дарулар алынмаган, – диде фельдшер.

– Алайса, мин барып кайтыйм, – диде Харис.

– Син барып берни дә чыгара алмассың шул. Менә үзем дә пенициллин урынына бүтәнне алганмын бит. Ярый әле берничә уколлык булса да пенициллин килгән. Югыйсә йөрүемнең файдасы шуның кадәр генә булыр иде.

– Алайса нишлибез соң?

– Әлегә берни эшләргә дә кирәкми, – диде фельд-шер. – Бер тәүлеккә җитәрлек дару бар. Авыруны врачсыз калдырырга ярамый, ә иртәгә, дарулар беткәч, үзем кайтып алырмын.

– Мин боз кузгалганчы сезгә барып килим, – дип карады Харис тагын.

Ләкин фельдшер:

– Минем даруларны кеше табарлык кына түгел, – дип каршы төште. Шуның белән бу турыда башка сүз булмады. Карт фельдшер белән Харис, төне буе йокламыйча, кызны саклап чыктылар. Авыруның хәле куркыныч иде, ул вакыт-вакыт саташып кычкырды яки үзен белештермичә сикереп торды. Бары тик иртәнгә таба гына бер-ике сәгать йоклап алды.

Икенче көнне төштән соңга дару бетте. Тизрәк авылга ашыгырга кирәк иде.

– Мин сине озата барыйм, – диде Харис фельдшерга. – Елганы берүзең кичүе кыен булыр.

– Юк-юк, авыруны ялгыз калдырырга ярамый, – дип каршы төште Зарифулла карт. – Юлны мин үзем дә табармын.

Зарифулла карт теге якка чыкканда елганы хәвефсез генә үтте. Өенә кайткач, ул карчыгының әзерләгән чәен дә эчеп тормады, тизрәк юлга ашыкты. Карчыгы аның муенындагы шарфын рәтләп бәйләде, аннан картының өстендәге пальтосына бераз карап торды да:

– Өстеңдәге пальтоңның җылысы калмаган, яңасын ки, хәзер кичке салкын төшәргә тора, – дип, картына яңа пальто кидерде.

Зарифулла карт чыгып китте, тышта караңгы төшә башлаган иде инде. Ул, елга өстен караңгылык каплаганчы дип, ашыга-ашыга атлады. Кызу барганлыктан, аның йөрәге сикереп-сикереп тибәргә тотынды. Аркасыннан тир бәреп чыкты. Карт пальто төймәләрен ычкындырып җибәрде, болай иткәч, бераз җиңелрәк булып китте. Менә ул, ниһаять, елгага килеп җитте. Язгы кичнең кара канатлары киң елга өстенә җәелгән. Тонык кына су аккан тавыш ишетелә. Ара-тирә бозлар ярылып киткән тавышлар ишетелеп, болай да шомланган күңелгә шом сала. Зарифулла карт кырыйда гына үсеп утырган бер талны сындырып алды, аны таяк итеп, бозларга төрткәләп алга атлады. Ашыкканлыктанмы, еш кына аягы таеп китә. Озын кунычлы итегеннән су кермәсә дә, пальто итәкләре инде манма су булган. Ул шулай, таягы белән кармаланып, елганың уртасына килеп җитте. Хәвеф-хәтәрсез генә шулкадәр юл

үткәч, Зарифулла батыраеп китте. Күңеле күтәрелеп, тәне җиңеләеп киткәндәй булды. Хәзер теге як ярга да күп калмады, инде турыга гына барса да куркыныч юктыр. Тизрәк авыру янына кайтырга кирәк. Зарифулла карт беренче тапкыр эшкә чыккан көндәге кебек канатланып, эчке бер җиңеллек белән тиз-тиз бара башлады. Шулвакыт аның бер аягы чокырга туры килде, Зарифулла карт кинәт кенә читкә тайпылды. Ләкин икенче аяк та боз ярыгына кереп китте. Ул талпынып алга атлаган иде, язгы боз кинәт кенә убылып, Зарифулла картны үз эченә йотты. Аның колакчын бүреге генә боз өстендә утырып калды. Бөтен елга өстен кара шәүлә каплады.

Харис карт белән Роза аны ул көнне озак көттеләр, ә иртән Харис карт аның бозга ябышып каткан бүреген табып кайтты. Ике көннән боз кузгалды. Бар кеше боз киткәнен карарга су буена төште. Роза да, хәле авыр булуга карамастан, карт фельдшерга соңгы сәламен ирештерер өчен су буена килде. Ул, ялгыз зирек агачын кочаклап, аккан бозларны күзәтә. Тик ул үкерешеп аккан бозларны да, көләч балаларны да күрми. Аның күз алдында мөлаем йөзле, аңар иң авыр чакта ярдәм кулы сузган Зарифулла карт тора. Бик күп тапкыр бозлар китәр, бик күп тапкыр язлар килер, ләкин бу яз бервакытта да аның күңеленнән чыкмас.

## АВЫЛ АПУШЫ

Такси шофёры Хәми машинасына күбрәк авылның Апушларын, Хөббелнисаларын утыртып йөрергә ярата. Шәһәрнең тәти киенгән, кулын кесәсенә тыккан «шома егетләре» тирәсеннән туксан белән узып китә дә капчык яки зур сигезле санылай төенчекләрне аллы-артлы аскан авыл Апушы янына килеп шып туктый. Моның үзенә күрә профессиональ сере бар. Чөнки Хәминең күптәнге күзәтүләре буенча, авыл Апушы шәһәргә бер килсә берәгәйле килә. Капчыгы да, кесәсе дә шыплап тутырылган була аның. Ул инде шәһәрнең «тәти егетләре» кебек биш тиен өчен сатулашып маташмый, «ысдача не нада» дип, бишлеген төртә дә китә. Менә шушы профессиональ күзәтүчәнлеге нигезендә, Хәминең кесә төбе бервакытта да буш йөрми. Бүген дә ул җилкәсенә пар капчык аскан «Апуш» янына килеп туктады.

– Әйдә, Апуш абзый, утыр минем бахбайга. Тәрәзә төбеңә кадәр илтеп куярмын, – диде ул ачык йөз белән.

– Ай, рәхмәт, энекәш. Шәһәрдә йөреп бик йончыткан иде, – диде абзый кеше.

– Менә синең кебек йончыган кешеләрне өенә илтер өчен уйлаганнар инде таксины. Капчыкларың бик дәү күренә, нәрсә тутырдың шулхәтле?

– Барысы да бар инде...

– Әллә Бөгелмә базарына чабаталар сатарга килгән идеңме? Чабаталарның вакыты үтте, Апуш абзый. Алып килсәң дә кире төяп китәрсең. Муса Җәлил әйтмешли, «сувенир чабаталар» гына ясамасаң.

– Сувенир чабаталар турында Муса Җәлил шигырен бер дә хәтерләмим. Ялгышмасам, аны Шәүкәт Галиев язган бугай, – диде авыл Апушы.

– Шул шагыйрьләрнең кайсы нәрсә язганын һич хәтерләп бетереп булмый, укыганда да хәтерем начар иде. Аннары күп укыган саен, ныграк буталасың. Сез анда авылда айга-елга бер шигырь укыйсыз да шуңа онытмыйсыз. Ә безгә, бигрәк тә такси йөрткән кешегә, барысы белән дә танышып барырга кирәк. Нигә дисәң, төрле кеше белән эш итәргә туры килә. Төрле кеше төрле тел ачкычы сорый. – Ул, үзенең шулай оста сөйләвенә сок-лангандай, вакыт-вакыт тел шартлатып куя. Сүзләренең тәэсирен сынап, авыл Апушына караштыргалый. Ләкин тегесе никтер ачылып җитми. Үзе әйтмешли, бик йончыган, ахры.

– Апуш абый, үзең нинди эштә эшлисең соң?

– Терлекләр карыйм, энекәш.

– Значит, көтү көтәсең?

– Җәй көннәрендә көтәргә дә туры килә. Хайваннарның да үзләренә күрә холыклары була, җәен бер кеше, кышын бер кеше караса, шул холыклары бозыла...

– Ха-ха-ха! Апуш абзый, син кызык кешегә охшыйсың, яратам мин шутник кешеләрне. Мин сине башта механизатор-мазар дип уйлаган идем, ә син хайваннар холкы турында әйтеп көлдердең.

– Ни өчен механизатор дип уйладың соң?

– Кулларың майлар, бензиннар белән эшләүчегә охшаган.

– Син ялгышмадың, энекәш. Мин – механизатор.

– Әллә сарыкларны трактор белән көтәсеңме? – Хәми кычкырып-кычкырып көләргә тотынды. Шушы абзыйның, зур тракторга утырып, кечкенә бәрәннәр артыннан дөбер-шатыр чаптырып баруын күз алдына китерү аңа чынлап та кызык тоелды. Үзенең авылда рәтләп булганы юк. Сугыштан соң, әле биш-алты яшендә чакта,

берничә җәй әбиләрендә кунакта булган иде. Әбисенең өшегән бәрәңгене кырып коймак пешереп йөрүләре, бәрәңге коймагын катыкка манып ашаулары хәтерендә калган да яңгыр көннәрне түшәмнән аккан суга барлык савыт-сабаларны утыртып куюлары онытылмаган. Шуннан башка ул авылны белми. Аны һаман да элеккечәрәк күзаллый. Аның уйларын төшенгәндәй, Апуш абзый сөйләп китте:

– Син, энекәш, терлек караучының кулында чыбыркы да өстендә брезент плащ дип кенә уйлыйсың булыр. Хәзер терлек караучы – механизатор да. Нигә дисәң, заманы шул: утлыкларга кочаклап салам ташулар, малны чыбыркы белән куулар бетте ул. Бөтенесен машина эшли: сыерын да машина сава, кормасын да китерә.

– Кызык, – диде Хәми, ышанып җитмичәрәк. – Татарстан колхозларында да шундый хәл бармыни? Минем газеталардан укып ишеткәнем бар барын, ләкин андый колхозлар бармак белән генә санарлык дип уйлыйм.

– Колхозларның төрлесе бар, әлбәттә. Ул турыда бәхәс булуы мөмкин түгел. Ни генә дисәң дә, чыбыркы белән генә коралланган көтүчеләр бетеп бара.

– Ә хезмәт хаклары төшәме соң бераз?

– Алай зарланырлык түгел. Семьяны алып барырга җитә.

– Семьяң зурмы?

– Уртача. Биш бала, хатын да мин. Әле менә шуларга кием-салым, уенчык ише нәрсәләр алып кайтуым. Кечкенә малай – анысына өч яшь, гармун алып кайт, дип теңкәне корытты. Уенчык гармун гына алырмын дигән идем, бер кибеттән дә тапмадым каһәрен. Аптырагач, чынны алдым. Анысы да әллә ни кыйбат түгел икән, әйдә шыңгырдатсын.

– Да, Апуш абзый, дөрес әйтәсең. Әйдә шыңгырдатсын. Һади Такташ әйтмешли:

> Саратский яшел гармун,
> Көмеш кыңгыраулары,
> Шул көмеш кыңгырауларның
> Кичке яңгыраулары
> Әллә нишләтә күңелне...

Мин үзем дә гармун күрсәм үлеп китә торган кеше.

– Бу шигырьне Фатих Кәримнеке дип йөрим тагы. Такташныкымыни ул? – диде Апуш абзый.

– Чуртым белсенме аның кемнеке икәнен, – диде Хәми, бераз ачуланып. – Бөтен шагыйрьне ничек белеп бетермәк кирәк.

Бераз вакыт сүзсез кайттылар. Шофёрның бу Апуш абзыйга нигәдер ачуы килде. Юлның начар булуына карамастан, машинасын бөтен тизлегенә куа башлады. Менә алар Бәйрәмле авылына да кайтып җиттеләр. Авылга килеп керү белән Хәминең күзенә ташланган нәрсә яшел чирәмле киң урам һәм ике яклап тезелеп киткән төзек, матур йортлар булды. Һәр йортның түбәсендә телевизор антенналары күренә. Урам якка караган тәрәзәләр матур итеп буялган.

– Апуш абзый, авылыгыз ярыйсы икән, – диде Хәми. – Бу авылга бер дә килгәнем юк иде.

– Авыл авыл инде ул, туган, – диде абзый кеше. – Ту тегесе җитми, ту бусы. Әле өйләрне һаман да утын белән җылытабыз, суга дисәң, әллә кая чишмәгә барырга кирәк. Шәһәрне куып җитәргә ерак әле.

– Анысы шулай, Апуш абзый. Авыл шәһәр артыннан җиткәнче, без картаербыз әле, – диде шофёр. Аннары: – Өегез еракмы? – дип сорады.

– Ерак түгел. Килеп җитәбез инде.

– Кайткан-кайткан машина белән авылны уратыйммы үзеңне?

– Нигә кирәк ул?

– Менә безнең Апушыбыз такси белән генә йөри, дисеннәр. Авыл кешеләре алдында дәрәҗәң күтәрелер.

– Кирәкми, туган. Үзенең «Волга»сын шушы хөрәсән «Москвич»ка алыштырган, дип көләрләр үземнән.

Бу сүзләрне ишеткәч, Хәми әллә нишләп китте. Ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Шулай да Апуш абзыйны авыл уратырга базмады, бер тыкрык турында туктатты да, тиешле акчасын алып, юлын шәһәргә борды.

## ЧИГҮЛЕ КҮЛМӘК

Ишек кактылар. Җәүһәр барып ачты.

– Җәүһәр җаныем, үзең генәме? – дип сөйләнә-сөйләнә, Илсөяр килеп керде.

– Үзем генә булмый, кем белән булыйм тагы? Дамир көндез эшли, мин төнлә. Өйдә безнең икәү чагыбыз бик сирәк.

– Шулай шул, җаныем. Эшлим дип, гомер буе ялгыз яшисез инде.

– Болай, ичмасам, сагынышып торабыз. Өч ел бергә гомер итеп әһ иткәнебез дә юк.

– Синең хатын-кыз горурлыгың юк, Җәүһәр, – дип элеп алып китте Илсөяр. – Әзрәк горурлыгың булса, Дамирыңа шулхәтле вуле бирмәсиең. Берүзе кинога йөри, берүзе...

– Йә, җитәр, Илсөяр, йөрсә соң? Гомер буе өйдә бикләнеп яшәмәс бит, – диде Җәүһәр, ирен яклап. Кеше алдында якласа да, Дамирның соңгы вакытларда эштән соңарып кайтуына эче поша иде аның. Ә беркөнне, өч көнлек туристик путёвка белән каядыр Мәскәү ягына китеп баргач, бигрәк тә көяләнеп калды. Дөрес, ул чакта Дамир: «Минем Мәскәүдә бик зур йомышым бар, турист буларак кына бармыйм мин анда», – дип акланып маташты, ләкин үзе ни өчен баруын аңлатмады.

– Ә беләсеңме, Җәүһәр җаныем, – диде Илсөяр күршесенә, – мин сиңа начар хәбәр әйтергә кердем бит. Әйтмәм дип уйлаган идем дә, күрше хакы – Алла хакы, дип яшермәскә булдым.

– Нинди хәбәр ул, Илсөяр?

– Әйтергә телем дә бармый, җаныем. Беркөн синең Дамирың... Әй, калсын ла.

– Әйтә башлагач әйт.

– Шулай беркөн кибеткә керсәм, күзем шакмактай булды. Синең Дамирың бер хатынга күлмәк алып бирде. Чигүле күлмәк. «Таман булырмы, таман булырмы» дигән сүзләрен үз колакларым белән ишеттем.

– Юкны сөйләмә, Илсөяр. Әллә кемнәргә күлмәк алып бирергә Дамирның акчасы кычытып тормыйдыр.

– Акчасы кычытамы-юкмы, анысын мин белмим. Әмма күлмәк сайлаганнарын үз күзләрем белән күрдем. Әгәр ялганласам, баскан урынымда тәгәрәп үлим менә.

Җәүһәр, бу сүзләрдән исе китеп, ни уйларга белмичә катып калды. Шикләнү корты гаҗәп үткен тешле бит ул. Чак кына йөрәгеңә үтеп керергә ирек бирдең исә, ачыттырып-ачыттырып кимерергә тотына. Әһәмиятсез булып тоелган вак-төяк аңлашылмаулар кинәт һава эреп тутырган куыктай кабаралар, үсәләр. Әмма Җәүһәр үзенең шикләнү кортына ирек бирмәде.

– Булмас, юкны бар итеп йөрмә, – диде дә Илсөярне куып чыгаргандай итеп чыгарып җибәрде. Ә үзе, күңелендәге ямьсез уйларны куарга теләп, хатирәләр сандыгын, Дамирның армиядә чакта язган хатлары саклана торган сандыкны ачты.

Дамиры аның лирикага гаҗәп бай кеше. Хатларны искиткеч матур яза. Аның һәрбер хатын, самими сөюнең бер билгесе итеп, төзәтүсез-нисез матбугатка чыгарырлык. Дамирдан хат килгән көннәрне Җәүһәр мәхәббәт шәрабын коштабаклап эчкәндәй тилереп, шашып йөри иде. Армиядән кайтып өйләнешкәч, Дамирда җылылык кимегән кебек сизде Җәүһәр. Чөнки егетнең мәхәббәт сүзләрен шулай матур итеп бары тик хатка гына яза алганын белми иде ул. Шул югала башлаган җылылыкны эзләгәндәй, ялгыз калып боеккан чакларда, Җәүһәр шул хатларны актара. Шулардан ләззәт таба иде. Әмма бүген аңа хатлар укырга туры килмәде. Сандыкны ачып җибәрү белән, аның күзенә ят бер хатын-кыз сумкасы ташланды. Ә сумка эченнән чигүле хатын-кыз күлмәге килеп чыкты. Өстенә түшәм җимерелеп төшсә дә, Җәүһәргә бу кадәр кыен булмаган булыр иде.

«Ни өчен бу әйберләр безнең сандыкка кергән? Әллә юкса... Әллә юкса теге Илсөяр әйткән хатын мин югында өйгә үк килеп йөриме? Ах, оятсызлар, ах, оятсызлар. Дамир болай булыр дип кем уйлаган...»

Җәүһәр ачудан сумканы алды да шунда гына яткан балта белән тураклап та ташлады. Чигүле күлмәк һәм крокодил тиресеннән эшләнгән сумкадан бары тик кисәкләр генә калды. Бу шулхәтле тиз арада булды, хәтта шакылдаудан курыккан мәче дә караваттан сикереп төшәргә дә өлгермәде. Җәүһәр кулындагы балтаны һәм идәндә аунап ятучы кисәкләрне күргәч кенә айнып киткәндәй итте. Үзенең ни эшләгәнен төшенгәч, исе китеп идәнгә чүгәләде.

Ул еларга да, көләргә дә белмичә озак утырды. Әй-терсең күлмәк түгел, аның йөрәген тураклаганнар да, шуның кисәкләре идәндә аунап ята. Әйтерсең аның бөтен тәнен өзгәләгәннәр дә аяк астына ташлаганнар. Ләкин никадәр генә кыен булса да, җиңәргә, бер карарга килергә кирәк. Әмма акыл бернәрсә турында да уйларга теләми. Бөтен мие таш кебек каткан.

Озак, бик озак утырганнан соң, Җәүһәр сумка һәм күлмәк калдыкларын җыеп кире сандыкка тутырды да диванга сузылып ятты. Бер генә кешене дә күрәсе, бер генә авыз сүз дә сөйләшәсе килми иде аның. Ләкин, үч иткәндәй, ире Дамир кайтып керде.

– Нәрсә булган минем төн сандугачыма? – дип сөйләнә башлады ул. Җәүһәр балалар бакчасында һәрвакыт төнлә генә эшләгәнлектән, Дамир аны «төн сандугачы» дип атый иде. – Нишләп вакытсыз кайттың дип тә сорамый,

бик үпкәләткәннәр, ахры, моны. Ә мин, артык горур кеше түгел, сорамасалар да әйтәм: мин өч көнгә отгул алдым. «Бәйрәмдә әнкәйләргә кайтып килик», – дип йөдәтә идең, менә кайтырбыз инде.

Җәүһәр һаман шулай берсүзсез ята бирде.

– Нәрсә, әллә сиңа ял бирмиләрме? Бәйрәм көннәрне яслегез эшләми түгелме соң?

Җәүһәр җавап бирмәде. Дамир да аптырап калды. Юләр шикелле ялгызы сөйләнеп йөрүенә үзе үк оялып куйды. Өйдә нindидер күңелсез тынлык урнашты. Бу хәлдән котылу өчен, Дамир төрлечә кыланып карады: Җәүһәрнең табанын килеп кытыклады, маңгаена төшеп торган бөдрәләре буйлап мендәр мамыгы йөртте, тик берсе дә Җәүһәрне көлдерә алмады.

– Ә мин сиңа бер нәрсә алдым. 8 Март җитмичә бирмәм дигән идем, болай булгач бирим инде. Башкача сине юатып булмады. Мин аны беләсеңме ничек алдым? Буе-сыны белән нәкъ синең кебек кешене эзли-эзли җаным чыкты. Алгач-алгач әйбернең таманы булсын, дидем. Бусы да күңелеңне күтәрмәсә, нишләргә дә белмим инде...

Дамир барып сандыкны ачты да телсез булып шаккатып калды. Аның хатынына бүләккә дип алган чигүле күлмәге һәм Мәскәүләргә бара-бара алган крокодил сумкасы урынына эт теле хәтле кисәкләр генә аунап ята иде. Шунда гына Җәүһәр, үзенең ни эшләгәнен белеп, ачынып елап җибәрде.

## КЫРЫС МЕДСЕСТРА

Төн. Палатада бар да йоклыйлар. Утлар сүндерелгән, ишеккә корып куелган яшел пәрдә аркылы гына эчкә яктылык төшә. Пәрдә аша төшкән ут палатадагы бар нәрсәне яшел итеп күрсәтә, авыруларның йөзләре дә, өсләренә ябынып яткан одеаллары да, хәтта аларның чәчләре дә нindидер тонык яшел төскә кергән. Больница бөтенләй тынып калган. Бары тик авыруларның сирәк-мирәк ыңгырашып куюлары һәм медсестраның ак шәүләдәй үтеп-сүтеп йөрүе генә бу тыныч йортның больница икәнлеген белгертә.

Кинәт, урамдагы караңгылыкны икегә аерып, больница янына фараларын яктырткан «ашыгыч ярдәм» машинасы килеп туктады. Йокымсырап утырган медсестра Хәлимә, ычкынган халат төймәләрен эләктерә-эләктерә, машина янына чыкты.

– Нинди авыру китердегез? – дип сорады ул.

– Бер чибәр егет кайнар суда коенган, – диде санитарка, бик әһәмиятсез нәрсә турында әйткәндәй.

Авыруны носилка белән кабул итү бүлмәсенә алып керделәр һәм чишендерә башладылар. Егетнең өстенә япкан одеалны ачып җибәрү белән, Хәлимә кинәт агарынып китте, күз алларын томан каплагандай итте. Аның шулай кисәк үзгәрүен күреп, перевязкага әзерләнүче врач:

– Нәрсә булды, Хәлимә Сәгыйтовна? Нигә төсегез китте? – дип сорады.

– Юк, болай гына, Пётр Серафимович, – диде Хәлимә. – Күземә күренә дип торам, бигрәк минем улыма охшаган бит. Әллә инде миндә галлюцинация башлана: 16–17 яшьлек егет күрсәм, улыма охшатам да һич шуннан күземне ала алмыйм.

– Сез алай артык борчылмагыз инде, Хәлимә Сәгыйтовна, – диде врач. – Үлгәннәрне кайтарып булмый бит.

– Беләм дә, 16 яшьлек егетнең үлгәненә ышанасы килми бит. Үз кулларым белән улымның җансыз гәүдәсен машина астыннан тартып чыгармаган булсам ышанмас та идем.

Медсестра һәм врач, әкрен генә сөйләшеп, аңсыз яткан авыру егеткә перевязка ясадылар. Эш бетеп, аны палатага кертеп салганда, таң аткан иде инде. Тиздән көндезге медсестралар килеп җиттеләр, ләкин Хәлимә, таң атуын да күрмичә, смена алыштырырга вакыт җиткәнен дә тоймыйча, яңа китерелгән авыру егетнең баш очында утыра бирде. Аның кипшергән иреннәрен юеш марля белән чылатты, урыннарын рәтләде. Хәлимәне алыштырырга килгән медсестра, кереп:

– Хәлимә Сәгыйтовна, пятиминуткага керегез! – дигәч кенә, ул исенә килде. Сөекле улын хәтерләткән йөзгә тагын бер карап алды, тик шуннан соң гына врачлар һәм медсестралар җыелган бүлмәгә китте.

Бүлмәдә сүз шушы яңа авыру турында бара иде.

– Авыруның кан группасын ачыклап, кан җибәрергә кирәк, – диде врач, сүзен дәвам итеп. – Больницада барлык төр кан да җитәрлек, анысы безнең өчен проблема түгел, әмма егетне кеше итү өчен кан җибәрү генә җитми. Берәрсеннән тире күчереп утыртырга кирәк. Юкса пешкән урыннары төзәлгән очракта да бик ямьсез булып калачак.

– Тирене туганнары бирсен, алар гаебе аркасында пешкән бит, – диде бер медсестра.

– Әнисен чакырырга кирәк!

– Юк, әнисен җәфалау кирәкмәс. Ул болай да улыннан ким газапланмыйдыр инде.

– Берәр завод яшьләренә мөрәҗәгать итсәк ничек булыр. Хәзер бит яшьләр сознательный.

Шулвакыт Хәлимә Сәгыйтовна торып басты:

– Әгәр кан группаларыбыз туры килсә, мин аңа үземнең тиремне бирер идем, – диде ул. – Бик тә терелтәсем килә шуны.

Беразга бар да тынып калдылар. Кайберәүләр сәерсенебрәк, кайберәүләр хуплап Хәлимә Сәгыйтовнага карадылар. Врач каршы килмәде, чөнки ул Хәлимә Сәгыйтовнаның сүзен әйткәнче кырык кат уйлап эш итә торган кеше икәнен яхшы белә иде. Авыру егет Маратның улына охшаганлыгын да Хәлимә Сәгыйтовнадан бүген генә ишетте. Медсестралар пятиминуткадан таралдылар. Хәлимәнең күптән кайтып китәр вакыты җитте, ләкин ул өстеннән халатын салырга ашыкмады. Бүлмәдә баш врач ялгызы гына калгач, аның янына керде ул.

– Кайтып ял итегез инде, Хәлимә Сәгыйтовна, – диде врач. – Арыгансыз, күзләрегезнең хәле беткән.

– Никтер бүген бер дә өйгә кайтасы килми.

– Алайса, менә диванга ятып торыгыз. Мин обходка чыгам.

– Рәхмәт.

Врач чыгып киткәч, Хәлимә диванга барып ятты. Шушы көннән соң үзенең ялын да, көчен дә кызганмыйча Маратны терелтүгә бирде ул. Маратның хәле әз генә авырайса да, кайтып китәргә тиешле вакытта китмәде. Ә егетнең хәле бераз яхшыра башлагач, Маратның үз анасы кебек шатланды, йоклап киткән чакларда баш очына утырып озак кына Маратның тигез сулыш алып йок-лавын күзәтеп утыра торган булды. Хәлимә апа шушы мөлаем йөзгә төннәр буе карап торыр, шушы маңгайга төшеп торган чәчләреннән туйганчы сыйпар иде. Тик ул Марат уянып китүдән курка. Ләкин кайвакыт, үз-үзен тыя алмыйча, калтыранган куллары белән сак кына итеп аның чәчләреннән сыйпый. Ниндидер йомшак кул маңгай чәчләренә тиюдән Марат уянып күзләрен ача башласа, Хәлимә тизрәк палатадан чыгып китә. Һәрвакыт үз янында бу кырыс йөзле медсестраны күргәч, Марат уйлана башлады: «Нишләп бу 40 яшьлек апа минем тирәмдә сырпалана? Әллә югыйсә миңа гыйшкы төштеме? Шулай булса, кызык булыр иде. Ха-ха-ха! Анночка килгәч сөйләп көлдерергә кирәк әле. Әллә миңа әйтәсе сүзе бармы икән аның? Алай булса, мин күзләремне ача башлау белән нигә чыгып китә ул? Нинди дә булса сер бар монда. Тикмәгә генә хатын-кыз төнлә егетләр янына кереп утырмый».

Ә беркөнне ул, сак кына басып килүче Хәлимә Сәгыйтовнаны күргәч, йоклаганга салышып ятты. Хәлимә апа аның янындагы урындыкка утырып озак кына тын торды. Бераздан Марат үзенең чәчләренә йомшак бар-макларның кагылганын сизде һәм кинәт күзләрен ачып җибәрде. Аннан шундый ук кискенлек белән торып утырды. Маратның шулай көтмәгәндә уянуыннан каушап, Хәлимә апа урыныннан торып китә алмый торды.

Маратның башыннан яшен тизлеге белән берсеннән-берсе ямьсез уйлар йөгереп үтте. Ул кисәк кенә үрелде дә Хәлимә апаны кочып алды. Хәлимә апа бер мизгел Маратның ихтыярына бирелеп югалып калды. Ә Марат, аның саен кыюлана барып, Хәлимә апаның күкрәкләренә үрелде, кысып кочаклаган килеш, үзенең караватына аудара башлады. Хәлимә апа аңын югалткан кешедәй, хәлсезләнеп, Маратның урынына егылды, аннары пружинадай кинәт кенә сикереп торды һәм терелтер өчен көчен генә түгел, тиресен дә биргән авыруына сугып җибәрде, үзе, Маратка күтәрелеп тә карамый, алпан-тилпән атлап, палатадан чыгып китте.

Бу вакыт палатадагы башка кешеләр дә уяндылар. Ләкин монда нәрсә булганлыгын аңламыйча, Маратка текәлделәр.

– Нәрсә бәбәкләрегезне акайттыгыз? – диде Марат.

– Кабахәт кеше икәнсең син, – диде Марат белән янәшә ятучы карт. – Анаң кебек кешегә ябышасың. Акланма, акланма, мин һәммәсен күреп яттым. Хәлимә Сәгыйтовнаның нинди кеше икәнен яхшы беләм мин. Син кеше булсын дип, ул айлар буе яныңнан китми баш очыңда утырды. Тәнеңне ямар өчен үз тиресен бирде. Син нинди кешене рәнҗеттең бит, нинди кешене.

– Ә мин каян белим аны? Мин бит аңардан тире сорамадым, бирмәсен иде.

– Ах, оятсыз, сөйләнеп маташа тагын. Ыштаныңны төшереп бик яхшылап ярасы бар сине, шунда белер идең.

– Эт симерсә иясен тешли, ди бит.

– Палатадан куарга кирәк аны.

– Бар, хәзер үк гафу үтен, юкса арт ягыңа тибеп чыгарып җибәрәбез. Пешкән корсагыңны өеңдә дәваларсың.

Ай буе бергә яткан палатадаш кешеләрнең болай каты бәрелүләрен көтмәгән иде Марат. Ул кинәт коелып төште. Киемнәрен аннан-моннан гына киенде дә коридорга чыкты. Коридорда беркем дә юк иде. Медсестралар бүлмәсенә кереп гафу үтенергә батырлыгы җитмәде, як-ягына карана-карана, ишеккә таба китте. Ә иртәнге обход вакытында аның караваты буш иде.

## ШИКЛӘНҮ БӘЛАСЕ

Казан каласындагы иң чибәр кызларның берсенә өй-ләнеп җибәргәч, сөенеп бетә алмады Зәбир. Сөенмәс-лекмени?! Аның Нәзирәсе елмайса, алсу таңнарың кирәкми, офык яктыра; өздереп бер карап куйса, йөрәгеңдә йолдызлар кабына; телен тибрәтеп бер сүз әйтсә, күңелең ярларын рәхәт дулкыннар кага башлый; йомшак куллары белән муеныңнан урап алса, дөньяңны онытасың. Күзләре – пар зәңгәр күл, кашлары – шул күлләр өстендәге салават күпере. Менә шундый кызны кәләшлеккә ал да сөенмә, имеш?!

Әмма Зәбир иртәрәк шатланган икән әле. Сөенеченә караганда көенече күбрәк булып чыкты чибәр хатынның. Ник дисезме? Соң, билгеле инде: урамга чыксаң, Нәзирәнең якты йөзен кояш дип белеп, җылыга сусаучылар аның тирәсенә җыела; саф күл суын сагынучылар күзләрендә коенырга тырыша, гөлләр сөйләшүен ишетергә теләүчеләр аның авызыннан бер сүз чыкканны көтә. Баштарак Зәбир Нәзирәсенең чибәрлеге белән горурлана иде, тик хәзер горурлыгы ачуга алмашынып бара. Бигрәк тә күршеләрендә бер фырт егет пәйда булгач. Ул егетен әйт инде син: кар кебек ак күлмәк киеп, сакал-мыегын көн дә кырып йөрүе нигә кирәк?! Костюмына бер тузан кунса да сыпырып алыр, каршы очрасаң, баш иеп исәнләшер. Мондый нәзакәтлелек сылу хатынлы ирнең күңеленә яра түгелмени? Яраның ниндие генә әле. Әгәр кодрәтеннән килсә, Зәбир үзеннән башка бөтен яшь ир-атларны ямьсезләтеп чыгар иде. Ә иң беренче итеп менә бу фырт егетнең борын очына төзәлми торган чуан үстереп куяр иде. Әмма кеше дигәнең андый сихри көчкә ия түгел шул әле. Шуңа күрә чибәр егетләрдән качуның бүтән юлын эзләргә кала. Эзли торгач, Зәбирнең дә башына бер уй килде: фатирны алыштырырга. Калсын пөхтә егетең костюмын щёткалап.

Бер карар кылгач, озакка сузмады Зәбир, эзләде, тапты, күченде. Нәзирәсенең: «Бу фатирыбыз да бик әйбәт иде бит әле, нигә күчеп-тузып йөрибез?» – дигән соравына сылтавын да әзерләде. Янәсе, эшкә ерак. Ләкин иртә уңмаган кич уңмас, кич уңмаган һич уңмас, диләр бит. Уңмады Зәбир яңа фатирыннан: монда да бер майлы күз очрады. Моңардан Нәзирәсен качырыр өчен тагын икенче җиргә күченергә туры килде. Бу фатир инде элеккеләренә караганда эшкә дә ерак, стеналары да юка панельдән генә эшләнгән иде. Кышларын бик җылынып та җитми икән. Хәер, җаны тыныч булса, аларына түзәр Зәбир. Аның берүзенә бер кояш бит. Шуның белән җылыныр.

Монда күченеп килгәч, чынлап та, күңеле тынычланып китте Зәбирнең. Чөнки бу йортта күпчелек пенсионерлар яши иде. Кайсы ике кат күзлексез күрми, кайсы колак аппаратсыз ишетми. Комплиментлар әйтеп хатыныңның башын әйләндерерлек түгелләр. Кыскасы, нәкъ Зәбир теләгәнчә инде. Ләкин йөрәк бер кузгалса, аны тиз генә басып буламыни? Инде тынычланып яшим генә дигәндә, бер тавыш ишетте Зәбир. Җитмәсә, йокының иң тәмле чагында. Стена артында ир-ат тавышы: «Нәзирә, Нәзирә, вакыт җитте», – дип пышылдапмы-пышылдый, мин сезгә әйтим.

Зәбирнең колаклары сакчы этнекедәй үрә торды. Бер тавыш килгән якка, бер йоклап яткан Нәзирәсенә карады ул. Нәзирәсен әйт тагын: сизмәмешкә салышып йок-лап яткан була. Ә стена артындагы теге тавыш һаман Нәзирәнең исемен кабатлый. Кабатлаган саен, «сөеклем», «матурым» кебек эпитетлар да куша әле.

Бу хәлгә түзеп тора алмады Зәбир, тупас итеп хатынын уятты:

– Тор, әнә сиңа эндәшәләр! Майлы күзләрең артыннан килеп җиткән.

Нәзирә йокы аралаш берни аңламый азапланды. Ниһаять, ул ныклап уянып китте.

Зәбир, эчендә җыелып килгән бөтен шик-шөбһәләрен әйтеп, Нәзирә өстенә ташланды. Әйтерсең чокырда җыелып торган яман суны ерып җибәрделәр дә, ул тирә-юньгә пычрак чәчрәтеп агарга тотынды.

– Бүгеннән минем өемдә эзең булмасын! – диде ярсыган Зәбир.

Нәзирә акланып маташуны кирәк тапмады, өстенә киенде дә чыгып китте. Мондый хурлаудан соң ул, кал дип ялынсалар да, бу өйдә кала алмас иде. Ә җанына тынычлык тапмаган Зәбир ишекле-түрле йөренде. Үзе, тагын теге тавыш ишетелмәсме дип, стена ягына да колак салгалады. Гөнаһ шомлыгына каршы, тавыш тагын кабатланды:

– Нәзирә, тор инде, вакыт җитте бит, соңга калабыз!

– Нәзирәң үтүт шул инде, – диде Зәбир, усал елмаеп. – Әнә урамнан эзлә син аны хәзер. Бик кызгансаң, өеңә алып кер.

Стена артында кемнеңдер аяк тавышлары ишетелеп куйды, әйтерсең Зәбирнең сүзен ишеттеләр дә Нәзирә артыннан чыгып чабарга җыендылар. Зәбирнең ачуы чиктән ашты, ул, теге пышылдаган ирдән үч алырга теләп, дөп-дөп итеп күршеләренең ишеген какты.

Ишекне бөкрәеп беткән бер карт ачты.

– Кем буласыз? – диде ул, гайрәте беткән күзләрен чет-чет йомып.

Зәбир ул картны этә-төртә эчкә үтте. Эчтә картыннан да ныграк бетеренгән карчык ашык-пошык киенеп маташа иде. Аны күргәч, Зәбир артка чигенде.

Карт, көтелмәгән кунакка карап:

– Гафу итегез, егет кеше, сезне түргә чакырып тора алмыйбыз, юлга җыена идек, – диде. – Менә Нәзирәмнең киенгәнен генә көтәм...

– Нәзирә? – диде Зәбир, чиктән тыш гаҗәпләнеп. – Нинди Нәзирә?

– Хәләл җефетем...

Әйтерсең Зәбирнең башына күсәк белән китереп тондырдылар, кинәт чайкалып китте ул, йөзе аклы-зәңгәрле булды.

– Сез авырыйсыз, ахры, хәзер «ашыгыч ярдәм»гә шылтыратам, – диде карт, моның агарып киткән йөзен күреп, һәм кабалана-кабалана карчыгы киенеп маташа торган бүлмәгә үтте.

Тик карт әйләнеп килгәндә, Зәбир юк иде инде. Ул Нәзирәсен эзләргә чыгып чапкан иде.

## ИГЕЛЕКЛЕ БӘНДӘЛӘР

Кайгы агач башыннан түгел, адәм башыннан йөри дип, белми әйтмиләр икән. Әле моннан атна-ун көн чамасы элек кенә Фәтхиҗан профкомга күз яшьләрен агызып килеп кергән иде.

– Бердәнбер улым чирләп больницага керде, хәле бик мөшкел. Врачлары, монда гына эш чыгарырлык түгел, Мәскәүгә илтергә кирәк, диләр. Акчаның беткән чагы, үзегез беләсез, әз-мәз «төшергәләргә» яратам бит. Малайның чирләсен белгән булсам, получканың бер тиененә дә кагылмаган булыр идем, – дип уфтанып һәм үкенеп утырган иде ул.

Профком әгъзалары Фәтхиҗанның «зәмзәм» суы белән дус икәнен ишетсәләр дә, болай бала җанлы ата икәнен белмиләр иде. Гомумән, аның малае барлыгы-юклыгы турында да хәбәрдар түгелләр иде. Алар хәлне тиз төшенеп алдылар һәм Фәтхиҗанны юатырга ашыктылар:

– Бер дә кайгырма, агай-эне, заводыбыз бай, малаеңны Мәскәүгә илтерлек кенә акча табарбыз, – диделәр һәм Фәтхиҗан кулына шактый гына сумма тоттырып чыгардылар.

– Рәхмәтләр яусын сезгә, Алланың изге бәндәләре, – дип чыгып киткән иде ул чакта Фәтхиҗан.

Кайгысыннан кара көеп, тагын таныш бусаганы атлады Фәтхиҗан. Сүзен әйтә алмый бик озак мышык-мышык килеп утырды.

– Ни булды, агай-эне? – дип сорадылар аңардан. – Әллә малаеңның хәле авыраеп киттеме?

– Малай үтүт инде, – диде Фәтхиҗан гаять өметсез тавыш белән.

– Ничек «үтүт»? – дигән сөаль бирелде.

– Ничек булсын, очты-китте фәрештәләр янына, инде мәрхүмкәйне җирләгәнгә биш көн була. Мәскәүгә дә килеп җитә алмаган, балакаем, юлда җан биргән. – Ул тагын борынын сызгыртып, күзләрен ышкып алды. Аннары: – Хәзер малай кайгысыннан карчык түшәккә егылды инде, – дип үкси башлады.

Фәтхиҗанны башыннан сыйпадылар, юаттылар. Хәленә кереп, кемнәрнеңдер шулай вакытсыз дөнья куйган малайлары турында сөйләнеп алдылар.

– Карчык лимон белән әпилсиннән башканы тамагына да китерә алмый. Әллә кемнәргә бурычка батып беттем инде, – диде, бераз тын алгач, Фәтхиҗан.

– Хәсрәтләнмә, агай-эне, нык бул, – диделәр аңа. – Бурычлы булу зур каза түгел, анысын түләп булыр. Хәзер хатыныңның тазалыгы кыйммәт. Менә сиңа акча, лимонын да, апельсинын да кирәк кадәр ашат.

– Ашатам-ашатам, – диде Фәтхиҗан һәм ашыгып чыгып китте.

Шушы чыгып китүдән айга якын күренми йөрде. Профком кешеләре аның кайгысы турында онытa да башлаганнар иде, Фәтхиҗан таныш бүлмәдә тагын пәйда булды. Авызы кыйшайган, күз төпләре күгәргән, чырае сытылган.

– Ни булды, агай-эне, әллә машина астына эләктеңме? – дип сорадылар.

– Әйе, – диде Фәтхиҗан, – кайгы машинасы астында калдым, туганнар. Сөекле карчыгымны җирләдем.

Бүлмәдәгеләр барысы да ах иттеләр. Кайсы Фәтхиҗанга стакан белән су бирде, кайсы урындык тәкъдим итте, кайсы йомарланган бүреген идәннән алып хуҗасына сузды. Бераздан җиңелчә генә итеп, вакытында кайгысын килеп әйтмәгәне өчен, Фәтхиҗанны орышып алдылар. Күмәргә кеше җибәргән булыр идек, диештеләр.

– Күмүен күршеләр белән дә күмдек, – диде Фәт-хиҗан, – тик бурычлар күбәеп китте әле, шуларны түләргә...

Аның сүзен әйттереп бетермәделәр. Ул хакта кайгырмаска куштылар. Юаттылар, кулына акча тоттырдылар һәм, Фәтхиҗан чыгып киткәч, җиңелчә сулап куйдылар.

Шуннан соң Фәтхиҗан күздән югалды.

Ә озакламый завод дирекциясенә бер хат килеп төште. Анда Фәтхиҗанның, хатыныннан һәм малаеннан качып, бер ел инде алимент түләми йөрүе хакында әйтелгән иде. Шунда тагын барысы да ах иттеләр. Бу юлы инде Фәтхиҗанны кызганудан түгел, ә үзләренең төп башына утыруларыннан ахылдадылар.

## ДӨНЬЯСЫ – ЭТ ОЯСЫ

Без ундүрт катлы, туксан тугыз фатирлы эт абзарында яшибез. Тормышыбыз бик күңелле: кичтән туксан тугыз тавышлы этләр ансамбленең гүзәл җырына оеп рәхәтләнеп йоклап китәбез. Иртән тагын шул тавышларга уянабыз. Нindие генә юк бездә этләрнең: койрыклысы, койрыксызы, кәрләсе, гиганты, дуңгыз яки бүре төслесе, нәселлесе, нәселсезе, буазы, кысыры, кыскасы, җаның нindиен тели – барысы бар. Ул тавышларының матурлыгы дисеңме! Моны аңлату өчен музыка белгече булырга кирәк. Ә мин музыка белгече түгел, шуңа күрә, тавышлар турында озак сөйләп тормастан, төп сүзгә күчәм. Ә төп сүзем минем шәһәрнең затлы этләре хакында түгел, ә гап-гади авыл кәҗәсе турында. Шәһәр этләре арасына авыл кәҗәсе ничек килеп керде дисезме?

Болай булды бу. Көннәрдән бер көнне хатынга мин катгый рәвештә болай дип белдердем.

– Туксан тугыз фатирның туксан сигезендә эт бар, нигә без генә дурак кеше сыман яшибез? Алыйк без дә эт, – дидем.

Мине малай да яклап чыкты:

– Урра, эт алабыз. Безнең дә этебез була!

Ләкин хатын безнең кызган йөрәкләребезгә шартлатып салкын су сипте:

– Эт туйдырып ятарга Әндри казнасы юк миндә. Ә өрергә эт кирәк булса, эт хәтле генә үзем дә өрә алам мин.

– Анысы шулай, – дидем мин, – өрү ягына килгәндә, син теләсә кайсы этне көнләштерерлек. Әмма ләкин этне бит өрер өчен генә асрамыйлар. Этнең бүтән файдалы яклары да күп.

– Сасысымы? – диде хатын.

– Нәселле этнең нинди сасысы булсын! Без бит нәселле эт алачакбыз. Ә файдасына килгәндә: хәзер, үзең беләс-ең, жуликлар заманасы. Тегендә-монда киткәндә өеңдә этең калса, җаның тыныч була. Этле өйгә жулик керми.

– Кермәс, – диде хатын. – Жулик ул эт янына үз дустына кергәндәй керә. Патамушты алар икесе бер нәселдән.

– Һәр көн иртә-кич этне прогулкага алып чыгасың. Саф һава сулыйсың, – дидем мин.

– Көн саен прогулкага чыгып йөрисең килсә, мин сиңа авылдан бер кәҗә алып килермен. Ичмасам, сөте булыр.

– Кәҗә? Шәп идея бу! Кара син аны, хатын-кызның да башына кайчагында акыллы фикер килә икән.

Шулай итеп, без кәҗә алып җибәрдек. Балкон зур. Ашатырга ризык җитәрлек. Чөнки шәһәрнең затлы эт-ләре ипи ашамый. Бөтен кеше калдык-постыгын урамга чыгарып ташлый. Кәҗәңне күмәч белән күмәрлек.

Авылда коры үләннән башка сый күрмәгән кәҗәкәй рәхәтләнде. Мин чүплектән ипине чиләк белән ташый торам, ул ашап тора. Сөткә кибеткә чыгып йөрүләр бетте. Кәҗәкәй көн саен ике литр сөтне биреп тора. Кибет сөте дәрәҗәсендә сыекландырсаң, безнең ике литр сөтебез дүрт-биш литрга барып баса. Эшләр хутка китте. Кәҗәкәемне җитәкләп прогулкага да алып чыгам. Беркөнне шулай кәҗәкәйне саф һава сулатып йөрткәндә, эт җитәкләгән кешеләр яныма килеп туктый башлады, һәрберсе:

– Какая порода? – дип сораша.

– Кәҗәкинская порода! – дип кенә җиффәрәм тегеләргә.

– Первый раз видим такую породу, – дип, минем- кәҗәкәемне баштанаяк карарга тотынды болар. Хуҗа-ларыннан бигрәк этләре кызыксынды ят хайван белән. Олы авызлы койрыксыз эткә кәҗәбез аеруча ошады, күрәсең, әле алдын, әле артын иснәде. Моңарчы мондый игътибар күрмәгән кәҗәкәйгә бу бик ошап китте. Койрык астын рәхәтләнеп иснәтте. Олы авыз танавын чөереп өрә башлагач, кәҗәкәй, рәнҗеп, авызын күтәреп өреп торучының маңгаена арт тәпиләре белән гаярь генә берне менеп төште. Олы авызлы эт бияләй хәтле телен салындырып һуштан язды. Хуҗасы исә:

– Придержите свою собаку, – дип, миңа ябышты.

Икенчесе дә, аның сүзен хуплап:

– Почему без ошейника? – дип, миңа ырылдарга тотынды.

Мин тизрәк моннан таю ягын карадым. Берничә көн прогулкага да чыкмадым. Әмма кәҗәкәй балконда ябылып яту белән килешмәде, «бәә-бәә» дип протест белдерә башлады. Алдына деликатес ризыклар, ягъни кавын-карбыз кабыклары, кәбестәсен-кишерен, ипиен-күмәчен өеп куйсам да, һичберсенә борын төртмәде, һаман «бәә-бәә» дип кычкырып ятуын белде. Күршеләр: «Ваша собака странно лает», – дип аптыратып бетерделәр. Андыйларга: «Каждая собака по-своему лает. Не только собака, даже каждый артист поёт по своему. В этом их вся прелесть», – дип җавап кайтара тордым. Безнең этебезнең, тфү, этебез түгел инде, кәҗәбезнең ипи, кәбестә ише нәрсәләрне ашавына да күрше-тирәләрнең эче пошты. Пошмыйча! Аларның нәселле этләре ипигә борын төртми, аларга майлы кабырга яки чит ил консервылары кирәк. Ә безнеке калдык-постык ашый.

Безгә файда булмасын дип, күрше-тирәләр хәзер ипи калдыкларын теләсә-кая ташламый башладылар. Кайсы, авылдагы туган-тумачасының тавыгына күчтәнәчкә алып кайтырга дип, киптереп балконына җыйды, кайсы, дачасына ташып, җиләк түтәлләренә ашлама итеп сипте. Без кәҗә алгач, подъезд алларыбыз чистарып калды. Әмма чисталыкка өйрәнмәгән халыкка бу ошамады: безнең өстән шәһәр башлыкларына шикаять яздылар. Имеш, без ипи, бәрәңге, кәбестә ашый торган ят токымлы эт асрап ятабыз. Имеш, безнең этебез сакаллы.

Шикаять язганнар икән, әлбәттә инде, аны тикшереп чара күрми ярамый. Безгә көннәрдән бер көнне нечкә сыйраклы, олы күзлекле яшь бер кыз килеп керде.

– Что за собака у вас, покажите, – диде ул.

Мин аны балкондагы кәҗә янына алып чыктым. Кәҗәбез, бүтән ризыклардан туеп, иске газеталар туп-ланмасын кимереп ята иде. Моны күргәч, тикшерүче кызның күзләре, күзлек астыннан чыгып, маңгаена менеп китте. Аңына килгәч, ул да һәркем бирә торган сорауны бирде:

– Что за порода?

– Англо-германская! – дидем мин.

– Почему она бородатая?

– Спросите у англичан, борода английская, – дидем мин.

– А рога?

– Рога германская!

Шулай дигәч, кызның соклануы йөзенә чыкты.

– Чего только не придумывают эти немцы и англичане, – диде ул киткән чакта.

Әгәр дә мин балкондагы мәхлук җанның гап-гади татар кәҗәсе икәнлеген әйтсәм, миңа карата рәхим-шәфкать булмаячак иде, ә чит илдән кергән һәр нәрсәгә хөрмәт зур бит бездә. Шушы көннән һич курыкмый йөртә башладым кәҗәкәемне урамда.

Эт этлеген иткәндәй, кәҗә дә кәҗәлеген итми калмады: агачларны кимерде, үзенә охшамаган этләрне төр-лечә рәнҗетте. Аптырагач, моның башына түбе тишек- капчык кидереп чыгара башладым. Әмма кәҗәм хо-лыксызланганнан-холыксызлана барды. Агач кимерүенә исем китми – анысы минеке түгел, хөкүмәтнеке. Ә менә гел «бәә-бәә» килеп акырып торуы тәмам нервыга тиде. Соңыннан гына белдем: тәкә сорап кычкыруы булган икән мескенкәйнең. Ләкин шәһәрдә тәкәсен каян табасың аның. Аптырагач, үз җаеңны үзең кара инде дип чыгарып җибәрдем. Өч көн югалып торды бу.

Инде бүтән кайтмас дип күңелне тынычландырып бетергәч кенә, кара төндә кара кәҗәбез балкон төбенә килеп кычкырмасынмы?! Нишлисең, чыгып алып керергә туры килде үзен.

Кәҗә, чынлап та, үз җаен үзе күреп кайткан иде, ахрысы, кычкырудан туктады. Ни бирсәң, шуны ашады. Күзгә күренеп түгәрәкләнде. Һәм купмедер вакыттан эт башлы, кәҗә тояклы дүрт бәти тапты. Бәти-көчекләребезне, ике атна дигәндә, «англо-французо-германская порода» дип, ике миллионнан сатып җибәрдек. Үзләренә бәти-көчек җитмәүчеләр үпкәләп тә йөрделәр хәтта.

Менә шулай, дуслар. Кәҗәбез һаман исән-сау. Аллага шөкер, корсагы тагын түгәрәкләнеп килә. Бусында нindирәк бәтиләр табар?! Хәер, дөньясы эт оясы булгач, эт тапмый нишләсен инде. Бәлки, үзе дә озакламый эт булып өрә башлар әле.

## ДУСЛЫК ШУННАН БАШЛАНДЫ

Бибинур белән Әлфинур озак кына уртак тел таба алмый йөрделәр. Ни дисәң дә, каенана белән килен бит. Каенана белән килен арасындагы хәлләрне сөйләп торасы юк инде, ул хакта бик күп китапларда язылган. Башка якларына тукталмыйча, мин бүген каенана һәм килен арасындагы дуслык турында язмакчы булам.

Бу дуслык көтмәгәндә, гел юктан гына башланды. Хәер, юктан гына дию дөрес үк булмас. Моңа сәбәпче булган нәрсә – төлке бүрек! Әйе, әйе! Гап-гади, йоп-йомшак төлке бүрек. Көннәрнең берендә, түбәләрдән асылынып торган боз алкаларында беренче язгы тамчылар ялтырый башлаган март аенда, Әлфинур үзенә кибеттән төлке бүрек алып кайтты. Чираты артык зур булганлыктан, кибеттә аның таманлыгын, килеш-килбәтен чамалап торырга туры килмәде. Кайтып киеп карагач, бүрекнең Әлфинур башы өчен сай икәнлеге беленде. Тубал кадәр итеп түбәгә өелгән чәч өстендә бу бүрек чүмәлә башына куелган түбәтәй кебек кенә булды. Көзге каршында бүрекнең бер артын, бер алдын әйләндереп киеп торганда, Әлфинурның каенанасы Бибинур кайтып керде.

– Бүрек алдыңмыни? – диде ул килененә.

– Юк, бу үземә түгел, – диде Әлфинур, каушабрак. Шулвакыт аның башына бер фикер килеп, акылын яктыртып җибәргәндәй булды. – 8 Март бәйрәме якынлаша бит, – диде ул, – сиңа бер бүләк булыр дип, шуны алган идем. Ошатырсыңмы, белмим инде...

Бибинур әллә нишләп китте. Күңеленә рәхәтлек йөгерде. Әйтерсең аның суына башлаган йөрәген җылы, йомшак учка алып кайнар сулыш белән өрделәр дә иплэп кенә урынына куйдылар. «Мондый бүрекләр киеп йөрердәй заманым узган инде, сез яшьләр киегез» дияргә теләгән иде, анысын да әйтә алмады, килененең хәтерен калдырырга курыкты. Бары тик: «Рәхмәт, балам, бик нык куандырдың», – дип кенә әйтә алды. «Балам» дигән кадерле сүзне ишетү Әлфинурны да сөендерде.

Бибинур, килене чыгып киткәч, төлке бүрекне бит-ләренә тидереп, бик озак юанды, аннары үзенең сирәк ачыла торган тимерле сандыгына салып куйды. Хәзер инде аның бөтен уе килененә нәрсә бүләк итү турында иде. Акча дигәндә аптырамый ул, ай саен уч тутырып пенсиясен ала. Димәк, бүләкнең дә шәбе булырга тиеш.

Кибеттән кибеткә йөри торгач, бүләкнең менә дигәнен тапты каенана. Нәкъ килен эзли торган бәйләм кофта очратты.

– Менә, кызым, яратсаң, шушы нәмәрсәкәйне алган идем әле сиңа.

Әлфинур шатланып кычкырып җибәрде:

– И әнкәем, ошамыймы соң?! Каян таптың моны? Мин ел буе эзләп тә тапмаган идем бит. Бигрәк әйбәт йоннан бәйләнгән инде. Миңа бик таман да икән. Бәйрәмнәрдә генә киярмен үзен.

Анасы белән әбисенең шатлыктан чөкердәшеп сөйләшүләрен күргән Рашат та бүләк бирү турында хыяллана башлады. Ул нәрсә бирергә икән дип озак баш ватмады, үзенә чәйгә бирелгән конфетларын иплэп кенә кесәсенә чумдырды да табын янынннан торып китте. Аннары ул конфетларын әбисе ята торган караватның җәймәсе астына тыгып куйды. Инде кич җиткәнен көтәргә, әбисенең конфетларны табып алганын күрергә генә калды. Менә шулчак әбисе шатланыр инде. Каян килгән бу конфетлар дип шаккатар. Әмма Рашат теләгәндә аның киче дә җитми бит. Бүтән чакта «эһ» дигәнче кояш бата иде, бүген күккә кояшны кадаклап куйганнармыни?! Тора да тора бер җирдә. Рашат, түземсезләнеп, әбисенә барып ябышты:

– Әбекәй, син кайчан ятасың инде?

– Бик иртә бит әле, балам. Көпә-көндез ничек йоклап ятмак кирәк.

Болай да эш барып чыкмагач, Рашат конфетларны кире барып алды. Кайнар учында шактый гына әвәләгәннән соң, чалбар кесәсенә салып, тагын әбисе янына килде:

– Әбекәй, син бүген берәр җиргә чыкмыйсыңмы?

– Кибеткә барырга ниятләп торам, улым.

– Шулаймыни?! Ә нәрсә киеп чыгасың?

– И-и, нигә болай сагызландың әле? Нәрсә киеп чыгыйм инде. Пальтомны киярмен.

Рашат конфетларын пальто кесәсенә яшерде дә аның киенгәнен көтә башлады. Әби кеше ашыкмый гына киенде, әмма кесәсенә кулын тыгарга һич кенә дә исәбе юк. Ә Рашатның түземлелеге кимегәннән-кимеде:

– Әбекәй, синең кесәң кабарып тора түгелме соң?

– Нишләп кабарсын? Берни дә юк бит.

Әбисе кесәсенә тышкы яктан шапылдатып сугып куйган иде, кулының ниндидер каты әйбергә бәрелгәнен тойды. Аннары кабаланып кулын тыкты. Конфетларны күреп, ул бик нык аптыраган булды.

– И-и, әллә пальтомны фәрештәләр киеп йөргән инде, кесәсенә конфет салып киткәннәр, рәхмәт төшкереләре. Мин ярата торган конфетлар үзләре.

Әбисе кет-кет көлде. Аның куанганын күрү Рашатка бик тә күңелле иде.

– Бүген сезнең бәйрәм бит, әбекәй. Фәрештәләр сине бәйрәм белән котлаганнар, – диде Рашат, мут кына карап.

– Мә әле, улым, фәрештәләр конфетыннан син дә авыз ит, – диде әбисе.

Ләкин Рашат аның кулын читкә этәрде.

– Кирәкми, әбекәй, кирәкми. Мин ашадым инде.

– Әллә соң фәрештә дигәнебез Рашат микән? – диде әбисе һәм оныгының йомшак җиреннән сөеп куйды.

...Әйе, чынлап та хикмәтле булып чыкты ул төлке бүрек. Хәзер инде, берәр бәйрәм якынлашса, бүләкне ничек тә бер-берсеннән уздырырга тырышып алалар алар.

## НУРМИГӨЛ ТҮТИ ДОГАСЫ

Була бит шундый кешеләр, алар һич тә вакыт агышы белән исәпләшмиләр, кайчан карама бер килеш торалар. Ямьсезләнмиләр дә, картаймыйлар да. Ләкин бу дөньяга гамьсез караудан яки тормыш ыгы-зыгыларына битараф булудан түгел, киресенчә, кешеләргә карата күңелләрендә олы мәхәббәт саклаудан шулай. Кемгә дә булса изгелек эшләү, мәрхәмәт күрсәтү өчен дәртләндерүче эчке бер көч аларны вакыт дигән нәрсәнең рәхимсез бизәкләреннән саклап кала.

Нурмигөл түти дә – картаюны белми торган кешеләрнең берсе. Мәхмүт аны тирә-юньдәге кешеләрне бер-бер-ләреннән аера башлаганнан бирле һаман бертөсле итеп хәтерли. Ак йөздә сирәк кенә шадралар, авыз тирәли тирән булмаган җыерчыклар. Кычкырып көлгәндә яшьләнеп, үзенә бертөсле итеп ягымлыланып китә торган коңгырт күзләр. Бу күзләр ничәмә-ничә еллар инде дөньяга сокланып караудан туймыйлар. Кайвакыт аңардан Мәхмүт:

– Нурмигөл түти, сиңа ничә яшь инде? – дип сорый.

– Кем санаган аны, туганнан бирле бер көн дә калмый яшәп ятам, – ди Нурмигөл түти, шаярып.

– Мин киез итек буе чакта ук син шулай идең, гел үзгәрмисең.

– Әкияттәге шикелле, ел үсәсен ай үсәргә туры килде миңа, улым. Үстем-үстем, картайдым, картайдым да туктадым, – дип сөйләп китә Нурмигөл түти.

Мәхмүт аның үткән тормышы турында әз-мәз ишетеп белә. Мәктәптә укыганда, гражданнар сугышында һәлак булган батырлар альбомы төзегәннәр иде. Шул альбомның беренче битендә Нурмигөл түтинең ире Солтан рәсеме тора. Солтан атаклы Чапаев дивизиясендә сугыша. Үзле Яр дигән авылны аклардан азат иткәндә күрсәткән бер батырлыгы өчен Солтанга дивизия командиры үзенең биноклен бүләк итә. Күп тә үтми, Солтан һәлак була. Солтаннан кадерле истәлек булып шул бинокль һәм яшь ярымлык кыз кала.

Нурмигөл түтинең кызы Кадрияне Мәхмүт тә хәтерли әле. 40 нчы еллар башында авылда кызлар арасыннан бердәнбер шофёр булгангамы, Мәхмүтнең күңелендә Кадрия һаман да сакланып тора.

– Кадрия апа, машинаңа утырт әле, – дип килеп җитә иде Мәхмүт, ул кайтып туктау белән.

– Утыртыр идем дә, машинамның баллоны шартлар дип куркам. Бигрәк зур булып үскәнсең бит, прәме кочакка сыймый башлагансың.

Шулай ди дә Мәхмүтне күтәреп алып, йомшак җи-реннән сөеп куя Кадрия. Һәм, малайны кабинага утыртып, өйләренә кереп китә. Өйдән ашап-эчеп чыккач:

– Йә, машинага утырып туйдыңмы инде? – ди.

Мәхмүт, кызарып:

– Йөрмәгәч туялармыни? – ди.

– Ә син бит йөрт димәдең, утырт кына дидең, – ди Кадрия, шаярып. Аннан ул Мәхмүтне утыртып авыл башына кадәр алып бара. Кире юлны Мәхмүт җәяүләп кайтырга да риза инде.

Сугыш башлангач, көннәрнең берендә Кадрия дә военкоматтан фронтка китәргә повестка алып кайта. «Машина да, трактор да йөртә беләм, танкка да көчем җитәр, – дигән ул военкоматта. – Минем кебекләрнең урыны фронтта». Ә китәргә дип хәбәр алып кайткач, авылдагы бөтен бала-чаганы машинасына төяп, әллә ничә мәртәбә урам урата. Бу аның авыл белән соңгы тапкыр саубуллашуы була. Китә дә суга төшкән кебек югала. Еллар үтеп, дөньялар тынычлангач кына, тере вакытта иясен таба алмаган орден, бик күп җирләрне урап, Нурмигөл түтинең кулына килеп керә.

Соңгы терәге – Кадриясе дә китеп югалгач, Нурмигөл түти шашар дәрәҗәгә җитә.

Түшәкләргә ятсам – түшәк суык,
Өйләргә генә керсәм – яме юк;
Кем күзенә баксаң – ул күз яшьле,
Кем күңеленең генә гаме юк, –

дип, бәет тә чыгара ул. Аннан инде, ялан кадәр өйдә ялгыз башына урын таба алмагач, еш кына Мәхмүтләргә кереп утыра башлый. Мәхмүтләр йорты, таяк тыгып болгаткан кырмыска оясыдай, гел мыжлап тора. Алты бала. Алтысы да чәчрәп торган тереләр. Такта өстенә ташланган борчак кебек, сәке өстендә тәгәрәшәләр генә. Боларның әүмәкләшкәннәрен карап утыру Нурмигөл түтинең күңеленә ял бирә.

– И-һи, балалар, – ди ул, кинәт кабаланып, – мин сезгә бер нәрсә апкергән идем, онытып торам лабаса.

Җанлы борчаклар, мәтәлчек атуларыннан туктап, Нурмигөлгә якынлашалар.

– Нәрсә апкердең, күрсәт, Нурмигөлттәй...

Нурмигөл алъяпкычын чишеп җибәрә. Аннан әле рәтләп суынып та җитмәгән арыш шишарасы килеп чыга.

– Мәгез, балалар, бүлгәләп ашагыз. Карыннарыгыз да ачкандыр. Әнкәгез кайчан эштән кайта да кайчан әзерләп ашата әле.

Шишара, сихерче кулына эләккән әйбер кебек, күз ачып йомганчы юкка чыга. Алты авыз аны, бик тиз әйләндереп, тиешле урынга озата. Нурмигөлнең алъяпкычында башка нәрсә юклыгына ышангач, җанлы борчаклар тагын кайсы-кая тәгәриләр. Нурмигөл аларга сиздерми генә үз хәсрәтен кире үзе белән алып чыгып китә.

Бервакыт Мәхмүткә кышның гаҗәеп салкын бер көнендә сеңлесе белән икәүдән-икәү генә өйдә калырга туры килә. Зурраклар укуда. Өй тып-тын. Морҗада җил сызгыра да, идән астында ашарга таба алмаган тычканнар кыштырдаша. Мәхмүтнең сеңлесе:

– Абый, пес-песем килә, – дип шыңшый башлый.

– Пес-песең килсә, хәзер чыгарбыз, түлке җылама. Җыласаң, өй иясе килеп керер дә икебезне тиң капчыгына салып апкитәр.

Шулай сеңлесен үзенчә юатып, мич башындагы итекләрен идәнгә ыргыта Мәхмүт һәм алар артыннан үзе дә сикереп төшә. Сеңлесе әле бик кечкенә, шуңа күрә аның киез итеге дә, бишмәте дә юк. Мәхмүт итегенең сыңарын үзе кия, икенче сыңарын сеңлесенә кидерә.

– Менә минем шикелле титаклап чык. Егыла башласаң, күлмәгемә тотынырсың.

Ишекне каты итеп ябалар да, сыңар аякта сикерешеп, тышка чыгып китәләр. Тәпиләре суынганчы эшләрен бетереп кире керергә уйласалар, ишекне ача алмыйлар. Соңыннан беленә: эчтән келәсе төшеп бикләнеп калган икән.

Гыйнвар салкыны балаларның киндер күлмәкләре аркылы бик тиз үтеп керә. Сеңлесе инде елый ук башлый. Мәхмүт кенә һаман да нинди дер бер үҗәтлек белән ишек артына кадаклаган тирене (чөнки тоткага буе җитми) тарткалый. Тик аның да түземлеге озакка бармый, сеңлесенә кушылып еларга тотына. Салкынлыктан балаларның күз яшьләре дә җиргә төшеп җиткәнче туңа.

Шулай ишек төбендә күпме торганнардыр, анысын беркем дә белми. Шулвакыт балаларның елаган тавышларын ишетепме, әллә очраклы рәвештә генәме Нурмигөл түти килеп керә. Өйалдында яткан балта белән ишекне каерып, Мәхмүтләрне өйгә кертә. Каяндыр спирт табып, балаларның туңган тәннәрен уа. Мичкә ягып җибәрә. Икесен бер юрганга төреп, җылытып йоклаткач кына фельдшерга йөгерә. Ике атнадан артык больницада ятып чыккач, Мәхмүт тә, сеңлесе дә сәламәтләнәләр.

Бу вакыйгадан соң Нурмигөл түтигә Мәхмүтләр биг-рәк тә якынаялар. Беркөнне Мәхмүтләрнең әнисе Нурмигөлгә:

– Нурмигөл, синең бу яхшылыгыңны ничек кайтарырга да белмим инде, – ди.

– Куйсана, – ди Нурмигөл, – нинди кайтару ул. Яхшылыкны бурычка эшлиләрмени? Мин үлгәч, Мәхмүт кабер казышырга барса бәхил инде. Мин бит каккан казык кебек ялгыз.

Нурмигөлнең күзләре яшьләнә. Ул аларны читкә карап яулык почмагы белән сөртеп ала да тирән итеп көрсенеп куя. Аннан сүз сугыштагы ирләр, сугыштагы хәлләр турысына күчә. Илгә яман бәла китергән Гитлер каһәрләнә. Хәсрәтләрне уртаклашып, күңелләрне бушатып бераз җиңеләеп калгач, Нурмигөл түти Мәхмүткә борыла һәм, шаяртыбрак:

– Кабер казышырга барырсың бит?! – ди.

– Барам, барам, Нурмигөл түти.

– Үлүен генә үл, дисеңме?! Әҗәл алмый шул әле, улым. Дөньяның авырлыгы яшьрәкләр җилкәсенә төш-те.

– Бер дә үлмә, Нурмигөл түти, яшә дә яшә.

– Үләргә исәп юк югын, балам. Һаман куш куллап тормышка ябышып яту. Кайгы-хәсрәт килер дә китәр, гомер генә ике килмәс, дигәннәр бит. Дөньялар гел болай тормас, бер рәтләнер.

Әйе, ил өстенә килгән афәт үтте. Еллар, язгы елгадагы бозлар төсле, бер-берләрен куышып ага тордылар. Мәхмүт тә үсеп җитте. Колхоз аны монтёрлыкка укытып кайтарды. Авылга электр керү үзенә бер бәйрәм булды. Авыл башындагы фермага узган линиядән Мәхмүт иң беренче электрны Нурмигөл түтигә кертте.

– Нурмигөл түти, менә сиңа иптәшкә электр кертәм әле. Бервакытта да өеңдә ут сүнмәсен. Яктылык гел иптәш булсын сиңа.

– Рәхмәт, балам, яхшы сүзеңә. Инде, Аллага шөкер, дөньялар тынычланып, тормышлар түгәрәкләнеп бара. Яшәргә дә яшәргә генә. Тик картаебрак кителде шул. Исәпләсәң исең китәр дигәндәй, син дә буй җиткән егет булдың. Кадрия апаңның машинасына утырып йөргәндә, кабина тәрәзәсеннән башың да күренми иде.

– Унтугызга чыктым, Нурмигөл түти. Быел армиягә китәм инде. Берничә тапкыр комиссиядә дә булдым. Бар җирең дә таза, диделәр.

– Без картаймый кем картайсын. Орчык кебек балалар имән кебек үстеләр, – дип калды Нурмигөл Мәхмүт артыннан.

Ни өчендер Нурмигөл күрше-тирәдәге башка балалардан Мәхмүтне артыграк күрде. Аны үзләренә чакырып тәмле-тәмле ризыклар белән сыйлау дисеңме, кием-салым алып бирү дисеңме – берсен дә кызганмады ул. Мәхмүт үзе дә аңарга бурычлы булып калмады: Нурмигөлнең бар нәрсәдән дә бигрәк ялгызлыктан ныг-рак җәфаланганын белгәнгә күрә, йомышы булса булмаса да, аның тирәсендәрәк чуалды. Ә Нурмигөлгә шул гына кирәк тә. Ул бөтен дөньясын онытa, үз тирәсендә чуалып йөрүче ваемсыз сабыйга караса, йөзендәге җыерчыклары язылып киткәндәй була. Башта Солтаны, аннары Кадриясе китеп югалгач, аңа дөнья беткәндәй тоелган иде. Баксаң, ул менә шушы Мәхмүтләр булып, кар астыннан чыккан чирәмдәй яңадан калкалар икән.

Мәхмүтнең армиягә китү хәбәрен ишеткәч, Нурмигөл, бик якын кешесен озатырга җыенгандай, ашыгып, табасында карабодай коймаклары чыжлатырга тотынды. Ә бер сәгатьтән ул Мәхмүтләрдә иде инде.

– Менә, улым, бераз коймак керткән идем, кайнар көе капкалап ал әле.

Мәхмүт, тамагы тук булса да, карчыкның хәтерен калдырудан куркып, берничә коймак ашады.

– Рәхмәт, Нурмигөл түти, коймагың бик тәмле булды.

– Ә хәзер менә бу коймакны бер тешләп куй инде, – диде Нурмигөл, тәлинкәдән бер коймак алып.

– Анысы нәрсәгә тагын?

– Ашалып бетмәгән ризыгың калса, шул үзеңне тартып кайтарыр, дигәннәр картлар.

– Алайса, коймакның иң зурысын алып тешлим әле, ризыгым күбрәк калсын, – дип, Мәхмүт Нурмигөлнең теләген үтәде. – Өч ел хезмәт итеп кайткач ашармын, кешегә бирмә, Нурмигөл түти.

– Ярар, улым, исән күрешергә булсын.

– Күрешәбез әле, Нурмигөл түти. Мине ничек озатып калсаң, шулай каршы алырга да тиешсең.

– Алайса, миңа тагын өч ел яшәргә кушасың икән. Рәхмәт, балам. Дөньялар тыныч булса, өч елы да үтәр, дөньялар гына болганмасын. Илләр имин булсын!

Озатканда шулай дип озаткан иде Нурмигөл Мәх-мүтне. Каршы алганда: «Исән кешеләр бер кайта, менә сине күрергә дә насыйп булды. Үлгәннәр генә кире кайтмый», – дип көрсенде ул. Бу минутта аның хәтереннән Солтаны, Кадриясе чагылып үтте. Еллар йөрәктәге кабер туфрагына әкрен-әкрен үлән үстерсәләр дә, аны җир белән тигезли алмыйлар шул. Ул һаман да калкурак булып кала бирә. Шуңа күрә дә, үткән гомер юлына күз ташлаганда, иң беренче шушы калкулыклар күренә.

Нурмигөл түтигә әле Мәхмүтне тагын берничә кат озатып калырга туры килде. Бу юлы инде алай озакка түгел, Казан каласына – укырга. Казанда биш ел укып агроном булып кайткач, Мәхмүт, дипломын күтәреп, Нурмигөл түтигә керде.

– Менә, Нурмигөл түти, инде укуны да бетереп кайттым. Моннан соң беркая да китмим. Гомер буе авылыбызда эшләячәкмен.

– Бик хуп, улым. Синең зур кеше булып чыгуың миңа да шатлык. Исәпләсәң исең китәр, кайсы гына йортны алып карасаң да, берәр баласы Казанда укымаган гаилә юк. Заманалар үзгәрде.

– Әйе, үзгәрде, Нурмигөл түти. Заман белән син дә, синең тормышың да үзгәрде. Хәтереңдәме? Мин, армиягә киткәндә, сиңа электр гына кертеп киткән идем, ә кайтуга, өстәлеңдә бозау хәтле радиоалгыч каршылады. Кайчандыр менә бу почмакта йөзлекләре сап-сары итеп юылган сәке тора иде, хәзер аның урынында никельләнгән карават. Казанга укырга киткәндә генә телевизорың юк иде, ул да булган.

– Бер минем тормыш кына түгел, балам, бөтен авылныкы шулай.

– Бөтен авылныкы гына да түгел, бөтен илнең тормышы матурланды, Нурмигөл түти. Башларына кара шәл ябынган тол хатыннар төсле салам түбәле йортларны бер генә авылдан да таба алмассың хәзер. Авыллар яшәрә дигән сүзне китапларда гына язалар дип уйлый идем, чынлап та шулай икән. Таякка таянган бөкре карт кебек терәүле йортлар урынына алтыпочмаклы, сигезәр тәрәзәле биек йортлар ничек мәһабәт булып утыралар. Авыл белән бергә кешеләр дә яшәрә. Миңа калса, Нурмигөл түти, элеккегә караганда син дә яшәрдең бугай. Йөзеңдәге җыерчыклар язылгандай, аркаларың турайгандай тоела.

– Гел җилкәгә төшкән авырлык безне иртә бөккән иде, улым. Ил белән бергә без дә турайдык. Дөньялар тынычлыгы, ил иминлеге кирәк, балам. Шул булса, бар да булыр. Тик менә шушы тормышны Кадрияләр, Солтаннар гына күрә алмады. Бигрәк иртә гомерләре өзелде. Искә алып юаныргa Солтанымнан бер бинокль дә, Кадриямнән шушы орден гына калды.

– Юк, Нурмигөл түти, синең сүзең белән килешеп бетмим. Мин дә кечкенәрәк чакта әтидән бер кәҗә тун белән күн итек кенә калган дип йөри идем. Алай гына түгел икән, минем әтиләр, Солтан абыйлар, Кадрия апалар безгә бик-бик зур мирас калдырганнар. Ул – безнең җиребез, бәхетле тормышыбыз, Нурмигөл түти. Алар безнең уңдырышлы җирләребезне, кадерле туган туфрагыбызны саклау бәрабәренә гомерләрен бирмәгән булсалар, бүгенге көнебез болай матур булыр идемени?!

– Әйе, балам, син бик дөрес әйтәсең.

Шулай озак кына сөйләшеп утырганнан соң, Нурмигөл түти үзенең һәрвакыт кабатлый торган догасын әйтеп куйды: «Илебез имин булсын, дөньялар болганмасын!»

## АХЫРЗАМАН КАРТЫ

Шиһап карт, пенсиягә чыккач, радио тыңларга бик һәвәсләнеп китте. Кич булдымы, сандык хәтле радиоалгычы янына утыра да тегенең колакларын боргалый башлый. Радиоң гына чыдасын. Йә «Би-би-си»дән джаз тотып ала ул, йә «Америка тавышы»н тыңларга керешә. Гарәпләр үз телләрендә көйләп бирәр дога укып җибәрсәләр, карт тәмам оеп тыңлый. Мондый вакытларда дөнья белән алыш-биреше калмый аның.

Беркөн шулай гадәтенчә «Америка тавышы»н тыңлап утырганда, бер коточкыч хәбәр тетрәндереп җибәрде картны. Имеш, ниндидер бер планета җиргә якынлашып килә икән. Ике айдан соң шул планета, безнең Җиргә бәрелеп, көлебезне күккә очырачак. Шиһап картны бу хәбәр шулкадәр куркытты, хәтта ул бераз вакыт кырыенда утыручы карчыгына да сүз әйтә алмады. Картының төсе китүен күреп, ни булуын карчыгы үзе сорамаса, ул шулай тетрәнүдән айный алмыйча озак утырыр иде әле.

– Катын, дөнья бетә икән, – диде карт калтыравык, өметсез тавыш белән. – Менә Әмрикә шулай диде.

– Тилермә әле, атасы. Әмрикәнең кайчан рәтле сүз сөйләгәне бар.

– Бүтәнен дөрес сөйләмәсә дә, монысын ялганламый инде ул. Әкәдимик тикле әкәдимик үзе сөйләсен дә алдасын, имеш. Безнең гәзитләр дә Җиргә бер йолдызның якынлашып килүен язып чыктылар бит. Алар безне куркытмас өчен юри дөресен әйтмәгәннәрдер әле. Синең белән мин белмибез аны.

Сәхипҗамал карчык картының бу сүзләренә ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Ул йодрык хәтле бер йолдызның Җир тикле Җирне көл-күмер итә алуын берничек тә башына сыйдыра алмады. «Төшсә дә, безнең бакчага төшмәс әле», – дип юатты карчык үзен. Әмма Шиһап карт бу хәлне авыр кичерде, хәтта ашау-эчүдән язды. Бары тик бу кайгының бер иргә түгел, бөтен миргә килүе генә бераз тынычландырды аны.

– Катын, – диде ул беркөнне, – кассадагы теге мең тәңкә акчаны нишләтәбез? Ашарга-эчәргә безгә хәзергә берни дә кирәкми. Балда-майда йөзсәк тә, ике айга җитәрлек ризык бар.

– Нишләтәсең инде аны! – диде Сәхипҗамал, көрсенеп. – Өйне сипләтәбез, дип йөри идең бит үзең.

– И юләр, ике ай гомер өчен өй сипләтеп торалармыни?! Мин түбәгә дигән калайларны да берәрсенә биреп җибәрергә торам әле.

– Дөнья бетәсе булгач, синең калаең бүтәннәргә нигә кирәк?

– Бүтән кешеләр ахырзаман җитүен белмиләр бит. Әйдә тилеләр эшләп йөрсеннәр, җәфаланып өй салсыннар, бакча утыртсыннар. Ә безнең байлыгыбыз бу ике айны рәхәтләнеп торып калырга җитә. Мин, катын, теге акчага мотоцикл алырга торам әле. Яшьтән үк шул нәмәстәкәйгә бик кызыгып йөрдем, әмма дөньяны җиткереп булмады. Бер картлыкта, бер яшьлектә дигәндәй, дөньяның тәмен татып калыйк. Теге бишеклесен алсак, үзеңне дә утыртып йөрермен.

Шиһап карт, карчыгының үгет-нәсыйхәтләренә колак салмыйча, район кибетеннән бишекле мотоцикл алып кайтты. Һәм алып кайткан көнне үк ишегалдындагы бер койманы, бер читәнне калдырмыйча кырып бетерде. Бу әкәмәт нәрсәдән куркып, тавык-кош, каз-үрдәк абзарла-рын ташлап качтылар. Алар урынына, тавык чебеш-ләреннән дә күбрәк булып, бала-чага җыелды. Шуграк малайлар мотоциклга, ә анда сыймаганнары, картның җилкәсенә атланып, мотоцикл йөртергә өйрәнделәр. Йөри торгач, ишегалды гына тар булды, малайлар картны мотоциклы-ние белән этеп урамга алып чыктылар.

Бер атна буена балалар картны урамнан урамга тартып йөрделәр. Бала-чагалардан бик туйган чакта, Шиһап карт яшерен генә авыл артындагы Кәҗә аланы дип йөртелгән чирәмлеккә чыкты. Ләкин анда да картны ялгыз калдырмадылар. Ә бер атна дигәндә, ул мотоциклын әйбәт кенә йөртә башлады. Артыннан малайлар йөгергәнен күрсә, газга басып, бик тиз генә алардан кача башлады. Шушы атна эчендә ул сыңар колак яфрагын өздерде, маңгаена өченче каш ясатты, чалбар ертты, ике түбәтәй югалтты. Ләкин дөнья тикле дөнья беткәндә моның ише вак-төякләр генә җәлмени?

Картының бу кыланмышларына түземе калмаган Сәхипҗамал беркөнне:

– Атасы, бөтен кеше бәрәңге утыртып бетерде, безнең бакча да сөрелмәгән. Болай җил куып йөрү ярамас, – дип сүз башлады.

Шиһап карт бу сүзләрдән көлде генә:

– Ай ярымнан дөнья бетәргә торганда бәрәңге утыртып йөриләрмени? Безнең бит былтыргысы да бер баз, шунысын ничек ашап бетерергә диген син. Мин әле иртәгә бер сарыкны суймакчы булам, юкса алты сарыкны кайчан ашап бетерәсең.

– Шул гына җитмәгән иде.

– Алай димә, катын. Кичәгенәк шулай мотоциклым үгез кебек кәҗәләнде дә, Мастайларга кергән идем. Карасам, ишегалларында сыер суеп маташалар. Зыянлады, шуңа суйдык, дигән була миңа. Мин, мыек астыннан гына көлеп, Әмрикәне син дә тыңладыңмыни, дим. Белмәмешкә салышкан була.

Шиһап карт бакчасына бәрәңге утыртмады, атна саен бер сарыгын суеп ашый торды. Күрше-күлән, танышбелеш бу хәлгә бик аптырадылар. Күпләр очраганда үзенчә киңәш бирергә тырышты. Ләкин карт беркемне дә тыңламады, мотоциклына утырды да Кәҗә аланына китте. Тора-бара ул карчыгын да мотоциклда йөрергә күндерде.

– Әйдә типтереп калыйк, катын, – диде ул Сәхип-җамалга. – Көннәребез санаулы гына кала. Моңа утыргач, минем йөрәк яшәреп киткәндәй булды. Җилләнеп, картлыкны коеп кайтыйк. Болай да инде дөнья мәшәкатен күп татыдык. Яшь чакта йөри алмаганнарның үчен кайтарыйк.

Мондый сүзләргә Сәхипҗамал карчыкның да күңеле җилкенеп китте:

– Әйдә, булмаса, карт, бер җилләтеп апкайт, – дип, бишеккә менеп утырды.

Кырыена сөекле карчыгы да утыргач, Шиһап карт тагын да яшәреп киткәндәй булды.

Алар шулай парлашып мотоцикллары ватылганчы йөр-деләр. Әҗәлләре җитмәгәнгәме, ничектер үлми калдылар тагы. Әкрен-әкрен абзарда сарыклар да бетте.

Беркөнне Шиһап карт, шаккатып:

– Бу корсак дигән нәрсә, үзе бәләкәй генә булса да, нихәтле ризык йоткан, – дип зарланды карчыгына.

Карчыгы инде дөньядан кул селтәгән иде, малларын бер дә кызганмады.

– Бетсен, хәзер атна-ун көн генә гомер кала, – диде ул.

– Әле безнең сыерны да суясы бар, – диде Шиһап. – Бу арада ашаган итләргә эч кенә чыдасын. Ике-өч көннән, Алла боерса, сыерны суярмын. Ә хәзергә кичә биргән пенсия белән мотоциклны төзәттерергә кирәк булыр.

– Төзәттер, төзәттер, карт, бик рәхәт нәрсә бит. Калган гомерне йөреп калырга кирәк.

Карчыгы белән парлашып типтерә торгач, ике айга якын вакыт үтеп тә китте. «Ахырзаман алдыннан кырык ел кырык көн кебек кенә тоелыр, диләр иде, дөрес икән», – дип уйлады карт һәм сыерын суярга чыгып китте. Ул сыерын суеп керүгә, карчыгы радионы ачып куйган иде. Соңгы вакытларда, төрле эш белән мавыгып, радио тыңларга вакыты калмаган Шиһап карт йотылып тыңларга кереште. Анда Мәскәүдән соңгы хәбәрләр тапшыралар иде. Ахырдан Җиргә якынлашучы теге планета турында да әйттеләр: ул Җиргә җиде миллион чакрым ераклыкта үтеп киткән икән. Карт белән карчык, бу хәбәрдән һушлары китеп, каты идәнгә егылдылар.

## «КАРА КӨН»

Әхмәтсафа, айлык эш хакы салынган кесәсен капшый-капшый, өйләренә ашыкты. Менә ул ике юл чатына җитте һәм кая барырга белмичә икеләнеп туктап калды. Сул якка китсә – өйләре, ә уң якта – саклык кассасы. Әхмәтсафа беравык шулай уйланып торды да, сул якка сул кулын селтәп, уң юл чатына борылды. Саклык кассасында аны күптәнге танышыдай елмаеп каршы алдылар. Хәер, монда аны белмәгән кеше юк иде инде. Менә биш ел буе Әхмәтсафа барлык эш хакын түкми-чәчми шушында китерә. Ул озак кына саклык кенәгәсен кулына тотып уйлана, ашыкмый гына андагы һәр язуны укып чыга, әйләндереп-әйләндереп аның печатен тикшерә, аннан соң гына кесәсендәге акчасын чыгарып кассиршага бирә. Чибәр кассирша кызның балаларча пөхтә почеркы белән тагын бер айлык акча өстәлеп куйгач, кенәгә тагын да матураеп киткәндәй була. Әхмәтсафа аны бик якын кешесенең рәсемен карагандай яратып, сокланып карый. Йомшак кына итеп тышыннан сыйпап куя. Шулай сокланып туйгач кына, шытырдавык кәгазьгә төреп, күлмәк эченә тегелгән каптырмалы түш кесәсенә салып куя. Әхмәтсафа бу эшне бик ләззәтләнеп, үзенә генә бер канәгатьләнү белән башкара. Бу вакытта аны якасы кырылып тирегә калган пальтосы да, әллә кайчаннан бирле чаңгы сорап теңкәсен корытып бетергән улы да борчымый. Ул аларны тәмам оныта, бары тик кенәгәдәге шактый ук түгәрәкләнеп бара торган сумманы гына уйлап куана. Кенәгәдә һәр сан аның каршына тере кеше, изге нәрсә булып килеп баса. Аның бөтен эчке дөньясын тутыручы шатлыгы шул гына.

Менә бүген дә ул ниндидер бер бик зур яхшылык, кемгәдер әйтеп бетергесез куаныч китергәндәй эчке бер сөенү белән сөенеп өенә кайтып керде. Ул, ишекне ачып бусагадан атлау белән, өйдә ниндидер күңелсезлек булуын сизеп алды. Башка вакыттагы кебек, улы аның каршысына чыгып кочып алмады. Хатыны Зәйтүнә дә кухня ягында тәмле аш исләре чыгарып савыт-саба чылтыратмады. Өйдә ниндидер шомлы тынлык иде.

Әхмәтсафаның бу шомлы тынлыкка әллә ни исе китмәде. Ул һәр көндәгечә ашыкмый гына чишенде, кыршылып беткән пальтосын өйалды ягына түгел, ә өйдәге бердәнбер мебель булган имән шифоньерга кертеп элеп куйды. Бу шифоньерны аларга элекке фатир хуҗалары калдырып киткән иде. Үзләре яңа фатир алгач, иске, зур шифоньерны сөйрәп йөриселәре килмәде. Аннары, кырык ел өйдә торган нәрсәнең кандала ише бөҗәкләре дә булуы мөмкин, аларны да яңа фатирга күчереп йөртәселәре килмәгәндер.

Әхмәтсафа, чишенеп, шифоньер ишеген бикләп куйганнан соң, почмакта елап утырган улын күрде.

– Нәрсә булды? Нигә шыңшыйсың? – дип сорады ул кырыс кына.

– Кулымны кыстым, – диде улы Наил, елавыннан һаман да туктый алмыйча.

Бу вакыт кухня ягыннан чыгып килгән хатыны сүзгә кушылды:

– Шул балага бер чаңгы да алып бирә алмыйбыз инде икәүләп эшләп, – диде ул. – Менә, үзенә чаңгы ясыйм дип, өйгә такталар алып кайткан. Такталарын әле яңа гына чыгарып аттым. Шуны юнганда, кулына пычак кереп киткән. Ярый әле мин кайтып җиттем, югыйсә бичараның каны агып бетәсе булган. Нәрсә өчен генә ата булып эшләп йөрисеңдер инде син? Ичмасам, йортка бер генә тиенлек тә файдаң юк бит.

Әнисенең яклавын ишетеп, почмактагы Наил дә ныг-рак шыңшырга тотынды. Өйдәге Әхмәтсафа кайтып кергәндәге тын атмосфера әкрен-әкрен үзгәрә башлады. Өй барометры давыл буласын ап-ачык күрсәтеп тора иде.

Әхмәтсафа да үзенең нахакка рәнҗетелүенә түзеп тора алмады:

– Җитәр сезгә! – дип, такталары калҗаеп беткән өстәлгә китереп сукты. Әхмәтсафаның йодрыгын гына көткән иске өстәл такталары дөнья белән бәхилләшеп идәнгә таралып төштеләр. – Кем өчен эшлим соң мин? – дип кычкырды ул, кызганнан-кыза барып. – Сезнең өчен бит. Башкалар акчаларын алалар да рестораннарга кереп рәхәтләнеп бүртенгәнче ашыйлар, коньяк чөмерәләр. Ә минем шушы яшемә җитеп берәр рюмка авызыма алганым бармы? Юк! Кеше төсле кием кигәнем бармы? Юк! Барысын да сезнең өчен җыям бит, сез «кара көн»дә ач калмасын дип. Әллә мин башкалар кебек тәти кием киеп, тәмле ашыйсым килми дип беләсезме? Корсак киереп телевизор карап, диванда кыйммәтле папирос пыскытып ятарга мин дә бик риза булыр идем.

– Синнән Аллага да юк, муллага да юк! – диде Зәйтүнә. – Шул «кара көн» дип авызың ачылган инде синең. Башкалар көннең карасын, агын тикшереп тормыйлар. Рәхәтләнеп ашыйлар да, киенәләр дә. Безнең Наилне кеше янына чыгарырга да оят бит, балалар тау шуа башласалар, ул, ятим бала кебек, бер читтә басып тора. Туңдырма тирәсеннән балакаем хәзер читкә карап уза инде. Ул өстенә кигән пальтосын әйтәсе дә юк, патша солдатының чикмәненнән дә начаррак. Синең кай җиреңә кызыгып кияүгә чыктым икән, йөргән вакытта да бер мәртәбә киногa да алып бармадың.

– Җитәр сиңа, искеләрне казыма! Киноларга бик йөрисең килгәч, башка кешегә чыгарга идең. Әнә теге Хәмзәңә. Ул киноларга да һәр көнне билет алып килә иде, рестораннарга да чакыра иде. Икәүләшеп бүгенге көндә рәшәткә арасында утырган булыр идегез. Анда кием өчен дә кайгыртасы юк, киносына да бушлай алып баралар.

– Әллә син шунда булып кайттыңмы, бик белеп сөй-лисең?

– Белер өчен анда буласы юк. Бик билгеле ул болай да.

Әтисе белән әнисенең кычкырышкан тавышларын тыңлый-тыңлый, Наил елавыннан туктаганын да сизми калды. Аның хәзер кулы да нык сызламый, әз генә сулкылдый гына. Әнисенең аны яклап әйткән сүзләре күңелен күтәргәндәй булды. Ул шулай почмакта бөтен кеше тарафыннан онытылып, бөрешеп утыра торгач, йокымсырап китте. Күз алдыннан тиз-тиз чаңгылы малайлар узды. Менә ул малайлар зур тауга килеп җиттеләр дә кычкырышып-кычкырышып таудан шуарга тотындылар. Алар шундый кызу шуалар, күз дә иярми. Ә чаңгылары шундый матурлар, ялтырап торалар. Ә Наилнең аягында үзе ясаган авыр такта чаңгылар икән. Ул, башка малайлардан калышмаска теләп, олы-олы атлап тауга менә. Ләкин аның авыр чаңгылары тирән көрткә баталар да атларга комачаулыйлар. Наил, тешләрен кысып, югарыга үрмәли. Аяклары карга баткач, куллары белән таянып тартып чыгара, һаман өскә, тауның очынарак менә. Шулай тырыша торгач, ул тауның башына менеп җитә, ә тау шундый биек – аннан бөтен дөнья күренә. Бу кадәрле биеккә менгәч, тирә-якны рәхәтләнеп күзәтмичә төшеп китү дә кызганыч. Наил бөтен күкрәген тутырып, киерелеп бер сулап ала да түбәнгә, башка малайлар артыннан ташлана. Ләкин ни гаҗәп: аның чаңгылары түбәнгә таба да шумыйлар. Башка малайлар аннан көләргә тотыналар, әйдә буксирга алабыз, диләр. Тик Наилнең малайлар арасында хур булып, буксирга тагылып төшәсе килми. Ул кулындагы таяклары белән көчкә-көчкә гәүдәсен этә. Алай да чаңгылары урыныннан купмагач, этисен каһәрләргә тотына. Менә гаҗәп, шулвакыт тау башына аның әтисе килеп чыга. Аның кулларында өр-яңа ике пар чаңгы. Әтисенең өстендә дә өр-яңа спорт костюмы. Җитмәсә, Наилгә дә шундый ук, үзе белән пардан итеп костюм алган. Үзе гел көлә, шатлана. «Хәзер, улым, безнең бөтен нәрсәбез дә бар», – ди. Наил әтисеннән: «Әллә, эти, теге көткән «кара көн» җиттеме, әллә кассадан акчаларыңны алдыңмы?» – дип сорый. Налнең әтисе башын кага: «Әйе, улым, көтелгән «кара көн», ниһаять, килеп җитте», – ди. Үзе Наилнең аякларындагы иске чаңгыларны алып бер читкә ата да яңаларын кидерә. Аннары алар икесе дә, талпынып, түбәнгә таба очалар. Наил сөенеченнән ура кычкырып җибәрә. Һәм шулвакыт уянып та китә. Уянып китсә, бөтен нәрсә дә элеккечә. Әтисе бәреп ваткан өстәл такталары да идәндә аунап ята, үзе юнган йомычкалар да җыеп алынмаган. Әтисе белән әнисе генә кычкырышудан туктаган. Өй тып-тын калган.

Наил, күргән төшеннән аерыласы килмичә, күзен яңадан йомып карады. Ләкин инде күзенә кабат йокы кермәде. Ул көрсенде, киерелде һәм урыныннан торды. Аның бөтен уе, бөтен теләге шул «кара көн»не тизрәк җиткерү иде. «Кара көн» җитсә, барысы да булачак: чаңгы да, яңа костюм да, тәмле аш та, җылы пальто да. Ул үз теләген бөтен өйгә яңгыратып әйтте: «Әй, тизрәк җитче «кара көн»!

Әхмәтсафа улына сәерсенеп карап куйды да сандык төбенә салып куелган саклык кенәгәсен кулына алды, ләкин бер минутка йомшап китүе өчен үзен ачуланып, кенәгәне кире үз урынына салып куйды.

## СҮЗСЕЗ АҢЛАШУ

Йорт янына йөк машинасы килеп туктады, кабинаның ике як ишеге дә ачылып китте, һәм берьюлы ике кеше җиргә сикерде. Сул як ишектән чыгучысы – әзмәвердәй егет, ул сикереп төшкән урында, дымлы җирдә, бер илле тирәнлектә сытылып аяк эзләре төшеп калды. Уң ишектән чыгучысы – аркасы шактый ук бөкрәя башлаган бер карчык. Ул төшкәндә, аяк астында гына үсеп утыра торган әрем дә селкенмәде. Карчык, машинаның тәгәрмәченә басып, кузовка күтәрелде дә аннан зур гына көрәк алып төште, аннары бөкре аркасын язар өчен турайгалап алды да чүп савытларына якынрак килде. Савытларга сиксән фатирлы берничә йортның бәрәңге кабыклары һәм калдык-постык ашлары җыелган. Карчык, ах-вах килеп, бер савытны кымшатырга тырыша башлады. Шулвакыт якында гына туп тибеп йөрүче кечкенә малайлар йөгереп килделәр дә савытның астын өскә әйләндереп ташладылар. Савыт төпсез икән, күрәсең, шулай аударырга җайланып эшләнгән. Әби ашыкмый гына көрәге белән бәрәңге кабыкларын машинага ыргыта башлады. Ул көрәген чумырып-чумырып ала да бер тигез ритм белән генә кабыкларны машинага төйи. Ә шофёр егет, сул кулы белән бөеренә таянып, йотлыгып-йотлыгып тәмәке тарта. Ул җибәргән зәңгәр төтеннәр әбинең баш очында бөтерелгәләп очалар да юкка чыгалар. Менә егет тәмәкесен тартып бетерде һәм, хәзер ни эшләргә икән дигәндәй, як-ягына каранып куйды.

Шулвакыт аның аяк астына балаларның тубы килеп керде. Егет бар көченә ул тупны тибеп җибәрде. Балалар, чыр-чу килеп, туп артыннан чаптылар. Шофёр егет тә, үзенең алар белән уйнарга теләге барлыгын белдергәндәй, ашыкмый гына туп артыннан китте. Балалар моны бик хуплап каршы алдылар, чөнки зурлар белән уйнау алар өчен бер горурлык бит. Ләкин шофёрны бу уен да тиз туйдырды. Дөресрәге, тулы гәүдәсен сөйрәп туп артыннан чабып йөрисе килмәде аның. Ул яңадан машинасы янына килде, ә әби кабыкларның яртысын гына төягән иде әле. Шофёр

иснәнеп куйды һәм сәгатенә күз төшереп алды. Шулчак ишегалдына бер чибәр кыз келәм кагарга чыкты. Егет, бу кызны күргәч, ничектер җыйнакланып киткәндәй булды. Кулына буялган мазутларын чалбарына сөртеп куйды һәм кызга якынлашты.

– Нихәл, чибәркәй, берүзеңә генә авыр түгелме? – дип, кызга дәште. Ә үзе, кызның җавабын да көтмичә, келәмнең бер башыннан тотып кагыша башлады. Кинәт кызның кулыннан келәме төшеп китте, ләкин кыз җиргә иелмәде, ә бөтенләй башка якка – машина ягына карап тора башлады. Шофёр егет тә ялт итеп шул якка борылды һәм бөкрәя-бөкрәя бәрәңге кабыклары төяүче карчыкны күрде. Әйе, күрде, һәм аңа әйтеп бетергесез оят булып китте. Ул, кызга әйләнеп тә карамыйча, машинасы янына килеп, әбинең кулыннан көрәкне алды һәм көрәкне чумырып-чумырып төяргә тотынды. Кузгалып киткәндә, ул кыз ягына борылып карады һәм таныш түгел кызның җылылык бөркеп торучы күзләрен күрде.

## СИЗГЕРЛЕК

Саҗидә касса янына килеп акча түләде дә, сатучы күрсәткән чемоданны алып, магазиннан чыкты.

– Ярый, яхшы булды әле бу, авылга күчтәнәчләр салып кайтырга чемоданым бик кечкенә иде. Казан тикле җиргә килеп буш кул белен кайту ару түгел, монда бит һәрвакыт килеп йөреп булмый.

Саҗидә Казанның яңгырдан соң калыккан гөмбәдәй тиз үсүче йортларына кызыгып, яшеллеккә чумып утыручы урамнарына сокланып атлый бирде. Казанга килсә, ул җәяү йөрергә ярата, аның һәр төзелеп килүче яңа урамны үз күзе белән күрәсе, һәр яңалыкны үз тойгысы аша кичерәсе килә.

Саҗидә кулындагы чемоданын бер кулыннан икенчесенә күчерә, аңа чемодан торган саен авырая бара кебек. «Буш, яңа гына алган чемодан нишләп болай авыр соң, әллә югыйсә аруым шушымы?» – дип уйлап куйды Саҗидә. Ләкин арырга бит әле ул нибары берничә чакрым юл үтте. Саҗидә шулай чемодан авырлыгына гаҗәпләнеп бара торгач түзмәде, бер аулаграк почмакка барды да чемоданын ачып карады. Һәм аның бөтенләй исе китте: яңа гына сатып алган чемоданда күн бияләйләр иде. Бер-ике пар гына түгел, ә ярты чемоданнан артык. Саҗидә чемоданын ашыгычлык белән япты да җәяүләп магазинга чапты. Ашыкканда күп вакыт шулай була бит ул: акыл дигән нәрсә белән уйламыйчарак эш итәсең. Мондый вакытта кеше акылы, уйлары бары бер генә нәрсәгә төбәлгән була – ул үзенең максатына тизрәк ирешергә генә тырыша. Ә максат дигән нәрсә кешенең кабалануын белми ул. Ул аңсыз да, җансыз да. Саҗидә белән дә шулай булды: яныннан трамвайлар, троллейбуслар шаулап үтеп торуга карамастан, ул җәяү барды. Аның трамвай көтеп торган бер минуты да барасы юлны озайтыр, вакытны сузар кебек тоелды. Шуңа күрә ул тротуардан, халык агымын төрткәли-төрткәли, җәяүләп чаба бирде.

Ул чемоданын күтәреп янып-пешеп килеп җиткәндә, магазинны төшкелеккә ябып маташалар иде. Хәер, әле магазин үзе ябылып җитмәгән, бары тик эчтәге кешеләрне генә чыгаралар. Саҗидә, керергә ярамый, магазинны төшкелеккә ябабыз диюләренә карамастан, чыгып килүче халыкны ырып-ерып эчкә үтте. Һәм, сатучының борын төбенә үк китереп, чемодан эчендәге бияләйләрне бушатып ташлады. Сатучы, нәрсә бу дигәндәй, бер бияләйләргә, бер Саҗидәгә карап тора башлады. Ул, Са-җидәнең яңа гына чемодан алып чыгып киткән кыз икәнен таныса да, эшнең нәрсәдә икәнен төшенеп җитә алмый иде әле.

– Сездән алган чемодан эченнән бияләйләр чыкты, – диде Саҗидә һәм, яңадан карап сатыгыз дигәндәй, сатучыга җитди генә караш ташлады да ишеккә таба юнәлде. Тик ул ишек турысына килеп җитә алмады, сатучы кыз аның җиңеннән килеп тартты: «Зинһар, берничә минутка гына туктап торыгыз!» – диде ул Саҗидәгә ялварулы тавыш белән һәм үзе директор бүлмәсенә йөгерде. Күп тә үтмәде, бүлмәдән урта яшьләрдәге бер ир белән сатучы кыз йөгереп чыктылар. Бу ир кеше магазин директоры иде. Ул Саҗидәгә төссез күзләрен тутырып карап торды-торды да аннары, ниндидер бер карарга килеп, Саҗидә бушаткан бияләйләрне кире аның чемоданына тутыртты. Аннары Саҗидәнең чемоданын кулына тоттырып, аны үзенең кабинетына алып кереп китте. Кергәч, ул сүзне нәр-сәдән башларга белмәгәндәй бераз уйланып торды, ни өчендер кәгазь, каләм әзерләде, аннары гына сүз башлады:

– Исемегез, фамилиягез ничек сезнең, чибәр туташ?

Саҗидәнең болай мыскыллы тон белән «чибәр туташ» дип әйтүгә ачуы чыкса да, тыштан сиздермәде, биргән сорауга тулысынча җавап бирде:

– Исемем Саҗидә, фамилиям Хәерова.

– Кайда торасыз?

– Совхозда, «Бөртек» совхозында.

– Ачыклабрак сөйләгез, иптәш Хәерова, нинди республика, кайсы район?

Сәҗидәнең инде мондый сораулардан түземе бетә башлаган иде, тик шулай да ул үз-үзен тыйды, ярсый башлавын белдермәде, тышка чыгармады.

Магазин директоры Сәҗидәнең җавабын кәгазьгә язып куйды да, күтәрелеп карамыйча гына:

– Паспортыгызны күрсәтегез, – диде.

– Паспортым юк минем монда, мин бит Казанга авыл хуҗалыгы алдынгылары киңәшмәсенә килгән кеше генә, – диде Сәҗидә, өзгәләнеп.

Сәҗидәнең тынгысызлана башлавын күреп, директор җанлана төште.

– Димәк, паспортыгыз юк? – диде ул, бик кирәкле нәрсәгә төшенгәндәй, канәгатьләнеп.

«Газетага язарга төпченәдер инде, бездә бит чак кына бер яхшылык эшләр хәл юк, хәзер дилбегә буе итеп газетага язып чыгалар. Берәрсенең онытылып калган сәгатен табып хуҗасына тапшырсаң да, трамвайда картларга урын бирсәң дә, яки берәр авыру карчыкның идәнен юып бирсәң дә». Ләкин директорның уе башка иде. Ул, тиз генә икенче бүлмәгә кереп, Сәүдә министрлыгына шылтыратты. Дөрес, ул нәрсә өчен икәнен аңлатып тормады, бары тик кичекмәстән магазинга дүрт-биш кешелек ревизия комиссиясе китертүләрен генә үтенде. Аннары, министрның рөхсәтен алгач, иркенләп милиция идарәсенә шылтыратырга тотынды.

– Кара әле, Биктимер дус, син миңа тиз генә ике бөркетеңне җибәр әле. – Директор бүлмә ярыгыннан Сәҗидәгә күз төшереп алды һәм, анасын көтеп арыган сабый кебек басып торучы Сәҗидәне күргәч: – Хәер, берәү дә җитәр, – диде. – Карак дип... карак ук түгел, – диде ул, телефонда сөйләшүен дәвам итеп, – бары тик сизгерлек, саклану чарасы гына. Мин бит, үзең беләсең, кайчандыр чекист булган кеше.

Директор телефоннан сөйләшеп тагын кайларгадыр шылтыратканнан соң, бүлмәгә яшь кенә бер милиционер килеп керде. Ул карак тотарга дип бик эре кыяфәт белән килеп кереп тә, карак дигәне шундый чибәр, шундый ягымлы кыз икәнне күргәч каушап калды. Баскан урынында бераз таптанып торганнан соң, ул аптыраулы карашын директорга текәде. Директор, бер үк вакытта кызга да, милиционерга да мөрәҗәгать итеп, һәр сүзенә басым ясап сөйләп китте:

– Гражданка Сәҗидә Хәерова бүген безнең магазиннан чемодан сатып ала һәм аның чемоданында нишләптер безнең бияләйләр була. Ул китергән бияләйләр егерме пар, кем белә, бәлки, алар кырык пар булгандыр. Мин хәзер ревизия комиссиясе чакырттым, шулар килеп эшне ачыклаганчы, сезгә, иптәш Хәерова, милиция участогына барып торырга туры килер.

Башын түбән иеп, милиционерга ияреп, Сәҗидә магазиннан чыгып китте. Ул чык суыдай саф яшькә чыланган күзләрен сөртү өчен кесәсеннән кульяулыгын алды, ә кульяулыкка ияреп аның юлга, самолётка алган билеты килеп чыкты. Билетта «самолёт 11 сәгать 30 минутта китә» дип язылган иде. Сәҗидә соңга калып яраксызга чыккан билетын ачу белән кисәкләргә тураклап ташлады. Билет кына түгел, аның бу вакытта кешеләргә булган ышанычы да ерткаланган, кимсетелгән иде.

## ГЫЙШКЫЯ ХЫЯЛ КЫЗЫ ТҮГЕЛ

**1**

Фәннурны Вильдановларга телефон куярга җибәрде-ләр. Ишекне унике яшьләр тирәсендәге бик җитез хә-рәкәтле малай ачты. Ул, кулына телефон аппараты тоткан таныш түгел абзыйны күрү белән:

– Әһә, белдем, сез безгә телефон куярга килгәнсез, – дип, шатлыгыннан кулларын чәбәкләп алды.

– Әти-әниең өйдә юкмыни? – диде Фәннур, бүлмәдә малайдан башка кеше юклыгын абайлап. – Чит кешене өеңә кертергә курыкмыйсыңмы соң?

– Минем әни бер соравыңа җавап алмый торып, икенчесен бирергә ашыкма, ди. Ә сез миңа ике сорау бирдегез, кайсына алдан җавап бирим соң? – диде малай, Фәннурны шаккатырып.

– Кайсысы сиңа ныграк ошаса, шунысыннан башла инде алайса, – диде Фәннур.

– Әнием өйдә юк, эштә. Ул миңа, телефон куярга- килсәләр ачып кертерсең, дип китте. Әйтмәгән булса да, мин сезнең телефон куючы икәнегезне белгән булыр идем.

– Ничек? – дип сорады Фәннур, кызыксынып.

– Кулыгызда аппарат бар ич, – диде малай, – аннары, түшегездән шнурлар чыгып тора.

Фәннурга бу малай ошап китте. Бердән, шәһәр баласы булуына карамастан, татарча бик чиста һәм матур итеп сөйләвен, икенчедән, күзәтүчәнлеген яратты ул аның. Кызларныкыдай чибәр йөз, кәкрәеп килгән озын керфекләр Фәннурга кемнедер хәтерләткәндәй булдылар.

– Исемең ничек соң синең, чибәр малай?

– Фәннур Вильданов мин.

– Без синең белән адашлар икәнбез алайса. Бик шәп.

– Ә нигә адашлар булабыз? – диде малай.

– Ике кешенең исеме бертөсле булса, алар адаш булалар, – диде Фәннур. Ләкин малайны бу җавап кына канәгатьләндермәде. Ул һәрнәрсәне төпченергә, аңларга тырыша. Фәннурның телефон аппаратын ачканны күр-гәч, ул йөгереп килеп җитте һәм бусы нәрсә дә, бусы нәр-сә, дип җентекләргә кереште.

– Ни өчен адашлар булуыбызны әнием кайткач сорыйм әле, – диде малай, тагын шул сүзне исенә төшереп.

– Синең әниең шулай бөтен нәрсәне дә беләмени?

Малай, син минем әнине белмисеңмени әле дигәндәй, бераз гаҗәпләнеп адаш абыйсына карады. Аның йөзе шулкадәр тиз үзгәрә, әйтерсең бөтен кичерешләре, бөтен уйлары башта шушы йөздә туа да аннары гына миенә барып җитә.

– Минем әни бар нәрсәне дә белә. Белмәсә, университетта укытмас иде, – диде ул искиткеч бер горурлык һәм ярату белән. Бу минутта аның күзләре дымланып, керфекләре чылт-чылт йомыла башлады. Әнисенә булган мәхәббәте, аның эченә генә сыймыйча, күзләре аша ташып чыккан диярсең. Фәннур үзенең дә шундый малае булмауга үкенеп куйды. Яше утыз тулып үтүгә карамастан, өйләнмәгән буйдак иде ул. Дусларында, танышларында шундый акыллы матур балалар күргәндә «өйләнергә кирәк» дип уйлый да ялгызы калгач тагын оныта.

– Әтиең турында берни дә сөйләмисең, әтиең бармы синең, адаш энекәш? – диде Фәннур.

– Юк, – диде малай усал гына.

Фәннур телефонын урнаштырып, чыгып китәргә җыенып торганда, малайның әнисе дә кайтып керде.

– Кунак бар икән, исәнмесез! – диде ул, Фәннур ягына бик җәһәт кенә караш ташлап. Аннары салкыннан кызарган битләрен учлары белән каплап җылытып алды.

– Менә үзем барында сөйләшеп карагыз, бәлки, ишетелүе начардыр, рәтләрмен, – диде Фәннур.

– Рәхмәт, әйбәт ишетелә, – диде ханым, шылтыратып караганнан соң. – Ләкин звоногын әз генә баса төшкәндә зыян итмәс, юкса төнлә йокыдан куркытып уятуы бар. – Шулай диде дә кулындагы сәгатькә карап алды. Аның сул кул аркасындагы миңен күреп, Фәннур сискәнеп китте. Гаҗәеп бер җитезлек белән башында уйлар чагылып, акылын яктыртып җибәргәндәй булды. Ханымның йөзенә карады һәм:

– Гыйшкыя, синме бу, әллә саташаммы? – дип кычкырып җибәрде.

Ханым, башта бераз сәерсенеп, аптырабрак торса да, Фәннурны таныды. Икесе дә, дөньяда сүзләр барлыгын онытып, бик озак бер-берләренә карашып тордылар.

**2**

Алар бер авылда туып үстеләр. Бер үк мәктәптә укып, Фәннурча әйткәндә, китап кимереп, бер үк юлда чабата туздырдылар. Гыйшкыя авылда иң чибәр кызларның берсе иде. Адым саен үзенең матурлыгы турында ишетү аны бик яшьли көзгегә карарга өйрәтте. Ә көзгенең бер сихерле көче бар: аңа ешрак караган саен, кызлар тиз-рәк җитлегә. Кызлар үзләренең язларын башлап көзгедә күрәләр һәм шул мәхәббәтле, чәчкәле чорларын каршы-ларга әзерләнәләр. Әле нинди икәнен дә белмәгән мәхәббәт аларның түшләренә керә, акылларын исертә, йөрәкләрен икеләтә дәрт белән тибәргә мәҗбүр итә.

Кояш ктысы әйбәт төшкән урында гөлләр тизрәк чәчәк аткан күк, егетләр карашын тоеп кызлар тизрәк өлгерә. Унбиш яшендә инде Гыйшкыя беренче үбешү тәмен, ә унҗидедә хыянәт ачысын татыган иде. Фәннур аңа караганда ике яшькә кечерәк һәм, сихерле карашларның нәрсә икәнен белмәгәнлектән, соңлабрак егет булды. Егет булуны кызлар күзенә туры караудан курка башлаудан исәпләсәк, ул вакытта Фәннурга унҗиде, Гыйшкыяга унтугыз иде.

Гыйшкыя районда урта мәктәп бетереп кайтты да авылда хат ташучы булып эшли башлады. Ул чагында авылда акчалы эш бары шул гына, колхозчыларга хезмәт көне генә языла, икмәк уңган елны көзен икмәк бирәләр. Билгеле инде, Гыйшкыя, акча ала башлагач, өс-башын бөтәйтеп җибәрде. Өс-башы да рәтләнгәч, ул тагын да матурланып китте. Ул хат ташучы булып эшләгән чорда, егет-җиләне булган йортлар күпләп газета-журналларга язылырга кереште. Шундый чибәр кызның һәр көн саен өеңә кереп чыгуы үзе бер бәхет ич. Җае туры килгәндә, клубка

чакыра, яшерен сүзләрең булса, хатка язып турыдан-туры үзенә тоттыра аласың. Газетага язылу «чире» Фәннурга да кагылды.

– Әни, – диде ул беркөнне, – газетага язылырга акча кирәк. Район газетасы белән генә эш барып чыкмый, Мәскәү, Казан газеталарын алдырыйк.

– Ул хәтле каян акча җиткермәк кирәк, – диде әнисе. – Ипи төреп йөрергә бусы да җитә.

Фәннур, әнисенең бервакыт лотореялар тиражы эзләп йөргәнен искә төшереп:

– Ул газетада тираж булмый, әни. Мәскәүнекендә генә була, – дип, салпы якка салам кыстырып куйды.

– Алайса, язылсаң язылырсың, тик берүк тиражлысы булсын, – диде ана, килешеп.

Әнисен күндерә алуына куанып, Фәннур Гыйшкыяларга чапты. Ул килеп кергәндә, кыз өйдә ялгызы гына иде.

– Газетага язылырга кердем әле, – диде егет, акланган сыман. – Ләкин бер шарты бар: газетаны өйалдында гына калдырып китмәскә, һәр көнне өйгә кертергә.

– Һе, шартлар куя-куя язылмасаң, бик исем китми әле, – диде Гыйшкыя. – Синнән башка да подписчикларым күп. Планым үтәлде.

– Ну бит инде, ни... Артыграк яздырсаң, үзеңә дә шәбрәк.

– Нәрсәнең шәп, нәрсәнең начар икәнен мин үзем дә беләм, энекәш.

Кызның болай мыскыллаган кебек «энекәш» дип дәшүенә Фәннурның хәтере калды. Ул үзенең колакларының уттай кызышуын тойды. Каһәр суккан колаклар: нәрсә булса иң беренче шунда бәреп чыга, әйтерсең кызулыгы эчне генә көйдереп торса ярамый.

– Син теләмәсәң, мин районга да барып языла алам, – диде ул, үпкәләп.

– Кызлар кебек үпкәләп торма, егет кешегә килешми. Әйдә, теләсәң, өегезгә кертеп бирермен, өйалдында гына ташласам, тычканнар кимерер дип куркасыңдыр инде, – диде Гыйшкыя, хәйләкәр елмаеп.

Гаепле кешедәй читкәрәк карап сөйләшүче бу оялчан егетне сүзләр белән чеметкәләп алу кызга күңелле иде. Фәннурның үзенә гыйшык тотып йөрүен сизә иде ул. Гыйшкыя суга Фәннурлар тыкрыгы аша йөргәнлектән, «ауган тыкрык читәнен утыртучы» бу егет аңа еш очрый. Элегрәк, сабый чактарак, Фәннур, судан кайтучы Гыйшкыяны абындыртып егу өчен, тимерчыбыктан төрле тозаклар куя иде. Ә үзе, таллар арасына посып, кызны күзәтә.

Бервакыт кыш көне Фәннур сукмакның тапталган карын тирән генә итеп казыды да, өстенә нечкә генә чыбык-чабыклар ташлап, йомшак кар сибәләде. Шикле булып күренмәсен өчен, җиңел генә басып, олтанлы итегенең эзен төшерде. Көн шактый буранлап та торганлыктан, юл белән юлсыз җирнең аермасы калмады. Фәннур, үзе уйлап тапкан нәрсәнең кызыгыннан алдан ук көлә-көлә, шул тирәдә чаңгы шуып йөрде. Ниһаять, су юлында берәү күренде, шакмаклы шәленә караганда Гыйшкыя булырга кирәк. Атлап килүе генә салмаграк, хәер, мондый көрттә беркем дә кыр кәҗәседәй сикермәс. Менә инде ул мәкерле урынга якынлашып та килә. Җитте. Һоп!

Фәннур читән артынарак посты һәм, тавышын бераз- үзгәртә төшеп: «Гыйшкыя, Гыйшкыя, мәче булып кычкырсаң, баздан тартып чыгарам», – дип дәште. Ниндидер сукрануга охшаш аваз ишетелде. Фәннур тагын үз таләбен кабатлады. «Көянтә белән башыңны ярсам чыгарырсың әле». Бу юлы тавыш ап-ачык булып яңгырады. Шунда гына Фәннур моның Гыйшкыя түгел, ә кызның әнисе Фәрдия түти икәнен аңлады. Инде хәзер үзеңне танытмыйча гына качып китәргәме? Качып китсәң дә, барыбер кем шуклыгы икәнен белерләр. Нишләп соң бу Фәрдия түти һаман ухылдап ята, чокыр тирән түгел ич, бот төбеннән генә.

Фәннур курка-курка гына хатын янына килде:

– Фәрдия түти, мин ни... Теге... Шаярып кына иткән идем.

– Минем белән шаярганчы, кәҗәгезнең сакалы белән уйнарга иде. Менә аягымны имгәттем, басып та булмый. Кил, ярдәм ит, нәрсә карап торасың.

Фәннур чокыр читендә утыручы Фәрдия апаны күтәрешеп торгызды һәм өенә илтеште.

– Фәрдия түти, суны үзем күпме кирәк шулхәтле ташыйм, борчылма, – диде ул һәм, хатынның җавабын да көтмичә, чиләкләрен алып чыгып йөгерде. Ул көнне Гыйшкыяларның бөтен буш савытлары су белән тулды. Фәрдия түтинең аягы җиңелчә генә авырткан икән, Фәннур су китереп бетерүгә төзәлде.

Хәзер инде Фәннур Гыйшкыяга карата мондый шук-лыкларны ничек эшли алдым икән дип аптырый. Кире-сенчә, ул хәзер, кыш булса, һәр көн иртән торып бәке тишә, җәй җитсә, басма сала. Бары тик Гыйшкыя гына алар турысыннан су алсын. Бары тик тыкрыкта аның эз-ләре генә җуелмасын!

**3**

Җиде класс бетергәннән соң, Фәннурга укуын ташларга туры килде. Абыйсы, армиягә китәргә повестка алып кайткач: «Фәннур, минем урынга заправщик булып син кал, мин председатель белән сөйләштем, ул каршы түгел, өйгә ярдәмең тияр», – диде. Бу эш Фәннурга таныш, абыйсы урынында эшләп торгалаганы бар аның. Әнисе әйтмешли, «укып мулла булалмасын» ул белә. Машиналар тирәсендә чуалу утын-курмы әзерләгән вакытларда да бик ярап куя. Машинасы булмаса, мае аның кулында бит. Колхозның җиде машинасы, сигез тракторы бар. Аларның да берничәсе чиратлап ремонтта тора. Кул белән заправить итәсе булса да эш озакка бармый. Кыскасы, эшен ярата Фәннур. Шофёрлар белән дә боткасы пешә малайның. Бары Тәлгатьне генә өнәп бетерми. Тәлгать төскә матур, гәүдәгә таза егет, бу якларына Фәннур соклана. Үзенең гәүдәсе какча, ябык булганлыктан, таза beләкле, киң күкрәкле егетләргә кызыга ул. Ә менә Тәлгатьнең мактануы аның җенен кабарта. Бигрәк тә кызлар турында күпертә башласа, бик ачуы килә Фәннурның.

Менә бүген дә, машиналарына ягулык тутыргач, шофёрлар тел кайрашып алдылар. Араларында иң ялкынланып сөйләгәне Тәлгать булды.

– Асыл кош аягыннан капты, егетләр, – дип дәвам итте ул. – Кырыемда утырып бара-бара бу йокымсырый башлады, сикәлтәлерәк җиргә эләгеп селкенгән саен миңа табарак елыша. Сизеп торам: юри йокымсыраганга салыша. Тегенди-мондый хәл килеп чыкса, үзләрен гаепсез итәргә шулай кыланалар алар. Мин мондый хәйләләрне беләм инде. Аларга шулай ошый икән, пусть кылана бирсеннәр.

– Шуннан, шуннан? – дип, шофёрлар кызыксына башладылар.

– Шуннан соңмы? Билгеле инде, кызый йоклаганга сабышса да, мин йокламадым. Машинамны беренче тизлеккә генә куйдым да, тегенең ап-ак муеныннан кочаклап, иреннәренә үрелдем. Уянып киткән булды. «Нишләвең бу, Тәлгать?» – ди. «Йөрәк парәм, Гыйшкыям, синең өчен яшь коям. Берүк ачулана күрмә. Ачуланып бер генә сүз әйтсәң дә, тотам да машинамнан сикерәм», – дим. Башта береаз чәбәләнде. Ә мин машинамны нәкъ Дим күперенең уртасында туктаттым да: «Тагын бер сүз әйтсәң, башым белән суга чумам», – дим. Кабинаның ишеген киереп ачтым да пинжәгемне салып, тегеңә тоттырдым. Инде ташланып харап булам дигәндә, иңемнән тотты. «Тәлгать абый, ташланып үлә күрмә, бөтенесен гафу иттем», – диде дә, муеныма сарылып, үзе үбеп алды.

Фәннур баштарак сүзнең кем турында барганын абайламыйрак торган иде, Гыйшкыя хакында икәнен белгәч, әллә көнләшүдән, әллә Тәлгатькә ачуыннан аркасына тир бәреп чыкты.

– Ялганлыйсың, донжуан, – дип кычкырды. Аның күп кызлар белән йөрүче егетләрне шулай дип атаганнарын ишеткәне бар иде.

– Кара-кара, Мәҗнүн телгә килде, – диде Тәлгать, аны тагын да үртәп.

– Син үзең Мәҗнүн, – дип бүлдерде Фәннур Тәл-гатьне, чөнки ул Мәҗнүннең кем икәнен белми, ә аны мыскыллау дип кенә аңлый иде. Егетләр тагын әйткәләштеләр, һәрберсе дошманына карата сүзнең әч-келтемрәген сайлады. Инде эш сугышуга кадәр барып җитә язган иде, шулчак Гыйшкыя килеп чыкты.

– Кайсыгыз районга бара бүген, егетләр? – диде ул. – Мине дә утыртып барырсыз. Почтаны үзләре китерә алмыйлар, шылтыраттылар.

Тәлгать, алга чыгып:

– Синең өчен булганда, графикны бозып та районны ике урарга була.

– Графикны бозганга үзеңә эләгер шул.

– Эләкмәс, судан гел коры чыга ул, председатель малае ич, – диештеләр шофёрлар.

Тәлгать кызны, ай-ваена карамыйча, кыстый-кыстый машинасына утыртты да районга юнәлде. Егетләрдән бераз читтәрәк мәхәббәттән янган йөрәген учлап басып калган Фәннурны Гыйшкыя бөтенләй күрмәде.

**4**

Тәлгать Гыйшкыяга башта ошамый иде. Үзен башка-лардан өстенрәк тотуы, масаебрак йөрүе ничектер Гыйш-кыяның күңелен кайтара. Матурлыгы белән авылда йөзек кашы саналып йөргән кыз Тәлгатьтән үзен өстен сизә. Икесе дә шулай горур булгангамы, алар арасында шактый вакыт эчке тартыш барды. Әмма егет Гыйшкыяга караганда хәйләкәррәк, кызларның кайсы кылларын чиертсәң нинди тавыш чыкканын белә. Җае чыккан саен, Гыйшкыяга берәр комплимент әйтеп китә. Кыз өстендә яңарак күлмәк күрсә: «Күлмәгең бигрәк килешә, Мәскәүләрдән кайтарттыңмы әллә?» – дип, ярым уйнап, ярым чынлап дәшеп куя. Авыл егетләренең кайсысы кызларга шулай игътибарлы?!

Ә бервакыт клубта, кино барганда, кинәт кенә ут сүнә. Урыны ишек төбенәрәк туры килгән Тәлгать, караңгыда кешеләрне этә-төртә, Гыйшкыя янына ашыга. Кулына кемнеңдер кагылуын тоеп, кыз сискәнеп китә һәм, аның Тәлгать икәнен белгәч:

– Бу караңгыда мине ничек таптың? – ди.

– Энҗе бөртеген табу кыен түгел, ул әллә каян ялтырап тора, – ди Тәлгать.

Бу сүзләрнең шаярып әйтелүен белсә дә, кызның күңеле була. Димәк, Тәлгать матурлыкны күрә белә. Матурлыкны аңлый алган кеше аны кадерли дә алачак.

Кар өстенә кар төшеп йомшак агачны әкренләп еккан кебек, һәр очракта әйтелгән мактау сүзләре дә кызның горурлыгын сындырды. Ул Тәлгатьне якын итә башлады. Моңа кадәр дә берничә егетне яратып, берничәсен армиягә озатып, берничәсен каршылап өлгергән Гыйшкыя мәхәббәттә үзен шактый тәҗрибәле кеше итеп сизә иде. Шуңа күрә, егетләрне теләсә ничек үз кубызыма биетә алам, дип йөри иде. Ләкин, ни гаҗәптер, Тәлгать белән моның бөтенләй киресе килеп чыкты. Башка егетләрне үз капкаларына ике өй калгач кайтарып җибәрә торган Гыйшкыя Тәлгатькә ишегалларына кадәр керергә рөхсәт итте. Фәрдия түти төннәрен авыл Советына дежурга киткән чакта, алар өйгә дә кереп утыргаладылар. Бервакыт Тәлгать Гыйшкыяга:

– Теге мүчкә нигә гел сине сагалап йөри ул? – диде.

– Кем? – дип сорады кыз, аңламыйча.

– Кем булсын, Фәннур. Әле без монда кереп киткәндә дә майлы күзләрен ялтыратып карап калды.

– Ха-ха-ха, әллә көнләшә инде?! Бала гына бит әле ул. Әйдә, апасына гашыйк булып тик йөрсен, аннан сиңа ни зыян? – Гыйшкыя чын-чынлап көләргә тотынды. Егетнең көнләшүе аның өчен рәхәт кенә иде.

– Көчек кайчак өреп йөри-йөри дә үкчәңнән каптырып та ала ул, – диде егет. – Син боларны Фәннурдан шүрләгәнгә әйтә дип уйлама. Аның куркырлыгы юк, ул чыннан да бала гына әле. Шулай да сиңа миннән башка кешенең күзе төшүен теләмим мин.

– Алай ук эгоист булырга ярамый инде, Тәлгать. Ә беләсеңме, быел Фәннур миңа бик зур ярдәм итте бит. Һәр өй саен кереп, газета-журналга язып йөрде. Безнең авыл быел көндәлек матбугат таратуда районда беренчелекне алды. Апаңа шуның аркасында күлмәклек отрез да бирделәр. Миңа шундый күлмәк алып бирешкәне өчен, Фәннурны бер үбеп чыгам әле.

– Болай да тиле кебек йөри, юри генә булса да берәр үпсәң, бөтенләй акылыннан язар, – диде Тәлгать. – Бигрәк беркатлы нәрсә, һәрнәрсәгә балаларча ышана.

– Потому что кайбер егетләр кебек кызлар артыннан йөреп бозылмаган, – дип яклады Гыйшкыя Фәннурны. Дөресен генә әйткәндә, бу тыйнак егет кай ягы беләндер аңа ошый. Хәер, моны ошау дип тә әйтеп булмый. Кыз үзен яраткан кешеләрне әзме-күпме ихтирам итә. Аларны башкалардан өстенрәк куя. Фәннурга булган якынлык хисе дә бары тик шундый гына дип уйлый ул.

– Шул малайның исемен дә ишетәсем килми, – диде Тәлгать, ачуланып.

Икесе дә беразга сүзсез тордылар. Гыйшкыя, Тәл-гать белән бәхәсләшүнең ахыры үзе өчен җиңелү белән бетәчәген белгәнгә, Фәннурны яклап маташмады. Тәлгать-кә чишәргә теләп күңелен кытыклап тора торган зур сере бар иде аның.

– Тәлгать, – диде ул, – минем авылдан китәсем килә.

– Ә минем сине беркая да җибәрәсем килми, – диде егет, сүзне уенга борып.

– Юк, мин шаярмыйм, чынлап әйтәм, – диде кыз. – Ун класс белемем бар, гомерем буе хат ташучы булып эшләмәм. Берәр күңелгә ошардай профессия сайларга кирәк.

– Менә мин ун класс белемем белән колхозда шофёр булып йөрим бит әле, – диде Тәлгать, турсаеп. – Шәһәргә китеп, артистка булырмын дисеңмени? Хат ташучы эше ошамаса, фермага бар. Анда әйбәт.

– Аның белән якын итеп киңәшәләр, ә ул, кызыл күлмәк күргән күркәдәй, хәзер кабарырга тора. Минем, бәлки, укыйсым киләдер. Паспорт алып булса, Казанга китеп берәр эшкә урнашыр идем дә кичке университетка экзаменнар биреп карар идем.

– «Идем» дә «идем» синең. Барысы да бик җайлы гына килеп чыга. Минем теләкләр белән исәпләшергә дә теләмисең. Син укырга теләсәң, мин, бәлки, өйләнергә телимдер. Гомерем буе буйдак килеш яшәмәм. Армиядән кайтканыма да өч ел. Әни дә шул турыда һәр көн саен колак итемне ашый.

Гыйшкыяга өйләнергә кирәк дигән фикер Тәлгатьнең моңа кадәр башына килеп караганы юк иде әле. Авылда иң чибәр кызны үзенә каратып, теләгәнчә башын әйләндереп йөрү аның өчен рәхәт һәм мактаныч иде. Ә менә шул кызның кулдан ычкыну мөмкинлеге барын тойгач, йөргән кызы ташлап китте дигән сүз ишетеләчәген күз алдына китергәч, тәне эсселе-суыклы булып китте. Әгәр дә Гыйшкыя китеп барса, егетнең горурлыгына каты сугачак.

Нинди генә юллар белән булса да аны тотып калырга, үзеңә бәйләргә кирәк. Аның бит әтисе колхоз председателе, справка бирмәсә, кыз паспорт ала алмаячак. Бу хакта әтинең колагына киртләп куярга кирәк.

– Нәрсә уйга калдың? – диде Гыйшкыя.

– Син мине шаярып кына йөри дип уйлыйсың, ахры, – диде Тәлгать, үпкәләгән сыман. – Мин бер сүз сөйлим, ул икенчене.

– Миңа моңарчы өйләнергә уйлавың турында әйткәнең юк иде, өйләнсәң, миннән башка кызлар да бетмәгән сиңа. Теләсә кайсы барам дип тора.

– Ярый, Гыйшкыя, бу турыда сүзне туктатыйк, беркая да китмисең, вәссәлам. Өйләнешәбез дә куябыз. Синең дә, минем дә яшем кергән.

– Ай-яй син тиз хәл итәсең. Барысы да ул кушканча гына булсын. Әйтерсең бүтән кешенең үз юлын сайларга хакы юк.

Алар шактый озак бәхәсләштеләр, ләкин һәркем үз фикерендә калды. Берничә көн үткәч, Гыйшкыя председательгә справка сорарга кергән иде, тик тегесе аның турында ишетергә дә теләмәде. «Һәркем авылдан китә башласа, колхоз эшен кем эшләр?» – дип япты ул кызның авызын.

**5**

Шактый вакыт узды, Фәннур инде үзенең хәленә күнә башлады. Ләкин ул Гыйшкыяны яратудан, аңарга ниндидер югары зат итеп караудан туктамады. Кыз су ала торган басмаларны һаман да төзәтеп, ярлары киртләчләнеп китсә, баскычлар ясап торды. Бервакыт авылда Тәлгать Гыйшкыяга өйләнә икән диган хәбәр таралгач, балтасы суга төшкәндәй йөргән иде, вакытлар үтеп бу хәбәрнең һаман да тормышка ашмавын күргәч, тагын тынычланды. Ләкин язмыш аңарга бик каты сугарга әзерләнеп торган икән...

Көзге көннәрнең берендә колхоз яшьләре өмә белән урамга агачлар утыртырга чыктылар. Әллә очраклы рәвештә, әллә Фәннурның сайлавы буенча, Гыйшкыя белән Фәннур бергә туры килделәр. Егет аңа сөенеп бетә алмады. Тау-ташларны актарырлык көч сизде ул үзендә. Бервакытта да булмаганча кыюланып, Гыйшкыяга кызык-кызык сүзләр әйтте. Ә топольләр арасына адашып эләккән бер алмагач күргәч, бөтенләй шатланып:

– Гыйшкыя, әйдә менә бу алмагачны сезнең капка төбенә утыртабыз, – диде. – Җылы якларда урамнарга тәгәрәгән алмаларны иртән дворниклар себереп йөри икән. Бездә дә берәр вакыт шундый булса икән.

– Хыялый син, Фәннур, – диде Гыйшкыя, көлеп. – Ул якларда, күрәсең, кәҗә юктыр. Бездә бит утырткан берен кәҗә кимереп бара.

– Алайга калса, топольне дә кимерә инде ул, – диде Фәннур. – Шулай да утыртабыз бит. Шәһәрдәгечә һәрберсен рәшәткә белән әйләндереп куябыз аны. Кәҗә тимер теше булса гына кимерер.

Алар, шулай шаярып-көлеп, алмагачны Гыйшкыялар капка төбенә утырттылар. «Бу алмагач ялгызы гына моңаеп тормасын инде», – дип, Фәннур аның янына бер тополь дә утыртты.

Ә кич белән Фәннурны Тәлгать урамда очратты да:

– Син нәрсә һаман Гыйшкыя тирәсендә чуаласың? – дип бәйләнергә кереште.

– Гыйшкыя синең шәхси милкең түгел бит, – диде Фәннур.

– Шәхси милкемме, түгелме, анда синең эшең юк, ләкин аңардан ераграк йөр. Мыштым Мәҗнүнләнеп, астыртын гына миңа чокыр казып йөрмә.

– Мине өйрәткәнче, хатыныңны өйрәт дияр идем, хатының юк инде, – диде Фәннур.

– Ә булса нишләрсең?

– Ха-ха-ха.

– Авызыңны ерма. Әгәр бик беләсең килсә… – Тәлгать, кычкырып әйтә башлаган сүзен кинәт кенә пышылдауга күчереп, Фәннурның колагына әйтте:

– Кабахәт, – дип кычкырды Фәннур һәм бар көченә әле генә шундый әшәке сүзләр пышылдаган Тәлгатьнең авызына китереп сукты. Тегесе Фәннурдан моны көтмәгән иде булса кирәк, бер мәлгә аптырап калды. Ә исенә килеп, йодрыкларын йомарлап өлгергәнче, Фәннур китеп барган иде инде.

Күкрәп үсеп утыручы агачның үзәк тамырына балта чапсаң, ул кинәт шәлперәя, җирдән кирәкле соклар ала алмый башлый. Тәлгатьтән ишеткән бу хәбәр дә Фәннурга шулай тәэсир итте. Дөньяда иң изге дип исәпләп йөргән кешесенә карата шундый яла ягучы белән бугазга бугаз килергә әзер иде ул. Әйе, яла. Моның чын булуына әз генә дә ышана алмый Фәннур. Тормышта матур кешеләр бар яклап та матур булырга тиешләр аныңча. Аларга карап сокланасың. Матур чәчәкләр күңелгә ләззәт, хисләргә рәхәтлек биргән шикелле, алар да күңел боек чакларда

елмайталар, яктылык өстиләр. Кешеләр өчен иң изге нәрсә – мәхәббәт тә матурлыкка карап сокланудан башланды. Дөрес, матурлык – табигать биргән бүләк. Кешеләргә үзләре тапкан, гүзәлләүдә үз көчләре кергән нәрсәләр кадерлерәк. Ләкин табигать сине кай ягың беләндер булса да башкалардан өстен итеп яраткан икән, шул өстенлекнең кадерен бел, сакла.

Шуңа охшашлы уйлар Фәннурның күңелендә кайнады. Ул Тәлгать белән чуалганы өчен Гыйшкыяга үпкәләде, яласы өчен Тәлгатьне эт итеп сүкте. Тәлгатьнең бу сүзләренә тамчы да ышанмаса да, нииндидер авыр уй аны борчыды. Аның Гыйшкыя белән сөйләшәсе, кызның күзен ачасы килде.

Беркөнне, ялгызы гына капка төбендә утырганын күреп, Фәннур Гыйшкыя янына килде.

– Әйдә, утыр әле, Фәннур, – диде кыз, аны күрү белән. – Бу арада бер дә күренми башладың. Качып йөрисең, ахры. Беркөн минем кайтканны күргәч, тык-рыкка кереп киттең.

– Синең белән сөйләшкәнне күрсә, Тәлгать эт урынына ябыша, – диде Фәннур, кызның сүз башлавына куанып. – Беркөн дә чак сугышып китмәдек.

– Нәрсә өчен?

– Беләсеңме, Гыйшкыя, миңа калса, Тәлгать сине яратмыйдыр ул. Яратса, синең турыда тузга язмастай сүзләр сөйләп йөрмәс иде.

– Аңа шулай ошый икән, сөйли бирсен.

– Горурлыгың кая синең, Гыйшкыя?

– Син минем горурлыгыма кагылма, миндә кешенең эше юк, – диде Гыйшкыя Фәннурга, кырт кисеп.

Аның бүген никтер кәефе начар күренә. Күзләре дә бераз кызарган сыман. Елаганмы әллә?

– Мин синең хәтереңне калдырырга теләп әйтмәдем. Беләсең килсә, синең хакта начар сүз сөйләүче һәр кешенең авызын төярдәй булам, – диде Фәннур.

– Мине идеаллаштырма, Фәннур, мин дә башкалар шикелле үк кеше. Кешенең дә йомшак характерлысы. Матур кыз булу да җиңел түгел. Һәркем сиңа соклана, мактау сүзләре яудыра, ә син шул сүзләрнең кайсы чын, кайсы ялган икәнен аерырга тиешсең.

– Ялган белән чынны гына аерып була инде анысы, – диде Фәннур, ни әйтергә белмичә.

– Юк шул, – дип кызып китте Гыйшкыя. – Кайвакыт хаклык ялганга караганда тирәндәрәк ята, эзләп табуы- авыррак була. Безнең бит күзебез иң беренче кешенең күңеле-нә түгел, йөзенә төшә. Ә йөзгә бик аз нәрсә ягыла шул.

– Кемгә ничектер инде, миңа калса, йөз күңелнең көзгесе булырга тиеш.

– Көзгедә бар нәрсә дә чагылмый, Фәннур, – диде Гыйшкыя, һәм бөтенләй көтмәгәндә аның күзләреннән ике бөртек яшь тәгәрәде.

Әгәр кыюлыгы җитсә, Фәннур бу яшь бөртекләрен, җиргә төшермичә, иреннәре белән корытып алыр иде.

– Гыйшкыя, Гыйшкыя! Ни булды? Мин үпкәләткән булсам, гафу ит, – диде ул, чиктән тыш аптырап.

– Сорама, Фәннур. Бөтен серне дә кешегә сөйләп булмый. Кешеләр ярдәм итә алмый торган нәрсәләр дә бар дөньяда. Их, кулымда паспортым булса, бүген ук авылдан чыгып китәр идем. Туйдым инде хәерче сыман өйдән өйгә кереп йөрүләрдән.

– Паспортны аны алып буладыр, – диде Фәннур, кызны тынычландырырга теләп. – Председательдән справка ал да районга илтеп бир. Бер өч көннән әзер булыр.

– Справка бирмиләр шул. Шул хакта сүз кузгаттым исә, Сәгыйть абзый ачуланырга тотына. Әллә нигә миңа шулай каты тора. Башкаларга алай бәрелми ул. Әнә Әкълимә дә китеп барды. Казанга тегү фабрикасына эшкә кергән.

– Йә сине җибәрәсе килмидер, – диде Фәннур. Ул килене итәсе киләдер дип әйтергә уйлаган иде дә, кызны үпкәләтүдән куркып әйтми калды. Чынлап та, Тәлгать ул хакта этисенә әйтеп куярга мөмкин ич. Ата белән улның бер сүздә булуы бик мөмкин.

Фәннур Гыйшкыяның авылдан китәргә теләвен белгәч шатланып куйды. Димәк, ул Тәлгатьне яратмый. Яраткан кешене ташлап китмиләр. Әмма кызның ни өчендер үкенгән кебек сөйләнүе, тик торганда күзләре яшьләнеп китүе Фәннурны сагайтып җибәргәндәй булды. Әллә соң?.. Юк, юк, мондый хәлнең булуы мөмкин түгел. Кызларның күңеле юктан да тулар. Һәр елаган кешене күреп, әллә ниләр уйлый башласаң, бик тиз юләргә санарлар. Гыйшкыяга ничек ярдәм итәргә соң? Председатель белән Фәннур үзе сөйләшеп караса нишләр? Хәер, бер киреләнсә, Сәгыйть абзыйны җиңәрмен димә. Тукта әле, тукта...

Егет уйланган уен тормышка ашыру өчен җай чыгуын көтеп йөри башлады. Ә планы бик гади иде аның. Председатель күрмәгәндә берәр ак кәгазьгә пичәтен басып алырга да справкасын соңыннан үзең язарга. Паспорт өстәлендә Сәгыйть абзыйның имзасын кем таный. Элегрәк идарәдә Фәннурның әнисе җыештыручы булып эшли

иде, шул вакытта чамалап каласы икән дә, кем белгән бит болай буласын. Хәер, болай да җае чыгар: Фәннурның әллә ничә тапкыр өстәлдә ул түгәрәк пичәтнең ятканын күргәне бар.

Сагалап йөри торгач, чынлап та җае чыкты. Фәннур кесәсендә йөртеп инде шактый карала башлаган ак кәгазьгә, председатель каядыр чыгып киткән арада, пичәтен төшереп алды. Шул ук көнне ул өенә кайтты һәм справкасын язып, Сәгыйть абзыйныкына охшатып имзасын куйды. Имза кыен түгел, биш-алты гына класс укыган председательнең хәрефләре курка-курка язган Фәннур язуы төслерәк иде. Инде хәзер Гыйшкыяны шатландырырга була. Гыйшкыяга үзенең дә бер ярдәм итә алуына куанып тизрәк аларга чапты ул.

– Менә, Гыйшкыя, справка булды бит, – диде Фән-нур, кыз белән исәнләшергә дә онытып.

– Ничек бирде? – диде Гыйшкыя, гаҗәпләнеп.

– Бирде инде, – Фәннур кызарынды, тагын колаклары уттай янарга тотынды. – Районга икәү барабызмы? – диде ул, кыенсынуын яшерергә тырышып. – Паспорт та алырбыз, китәрең өчен билетлар да.

– Мине шулай бик тиз җибәрәсең киләмени?

– Мин сине бер дә җибәрмәс идем дә... Ләкин шулай да ашыгырга кирәк. Безнең председательнең акылына төшенеп булмый, биргән справкасын ала да башлар.

– Бер биргәч алмас. Бик зур рәхмәт инде, Фәннур, син алып бирмәгән булсаң, Сәгыйть абзый янына керергә дә курка башлаган идем.

Берничә атнадан соң Гыйшкыя каядыр китеп барды. Берәүләр, ул Красноярск ягына киткән икән, дип, икенчеләр, Казанда, имеш, дип сөйләделәр. Тик Фәннур кызның үзеннән хат алмагач, тәгаен генә аның кайдалыгын белә алмады...

Унөч ел күрешми торган авылдашлар арасында сүз күп булды. Берсен-берсе бүлеп сораштылар. Әйтерсең киноны ярты сеанстан ташлап чыгып киткәннәр дә ахыры нәрсә белән беткәнлеге турында кызыксыналар. Бигрәк тә Гыйшкыя күп төпченде. Аның кайчан, ничек дигән сорауларына Фәннур җавап биреп өлгермәде. Аптырагач, ул:

– Мин монда син югында улың белән сөйләшкән идем, үзенә берьюлы ике сорау биргәч, минем әни, бер соравыңа җавап алмыйча торып, икенчесен бирмә, дип әйтә, диде. Малаеңа алай дип өйрәтсәң дә, үзең шул кагыйдәне тотмыйсың икән, – диде, шаярып.

– Әйе, Фәннур бик акыллы булып үсә. Кая, үзе тыңлап тормасын тагын, югыйсә мактау кешене боза бит.

– Кара әле, Гыйшкыя, син авылдан китүгә үк тормышка чыккансың, ахры, үзең хәтле малаең булган, ничә яшь инде аңа?

– Унике тулып китте. – Гыйшкыя беразга тын торды. Ул салкыннан кайтып кергәндәге шикелле бераз алсуланып киткән битләрен учлары белән каплады.

Гыйшкыя элеккегә караганда шактый үзгәргән. Олырак кешенең карышына сыярлык биле ярыйсы гына юанайган, гәүдәсе тулыланган. Бары тик куллары гына нәфисләр, кечкенәләр. Күрәсең, физик эш эшләмәүнең нәтиҗәседер.

– Мин тормышка чыкмадым бит, – диде Гыйшкыя, авыр йөкне күтәргәндәй еш сулап. Аннары, Фәннур төрле сораулар биреп бүлдермәсен дигән шикелле, бераз ашыгыбрак сөйләп китте: – Тормышка чыгарга һич тә вакыт булмады. Килгәч тә балалар бакчасына няня булып эшкә урнаштым. Ел буе подготовительный курсларда йөрдем, икенче елны университетка кердем. Башта университет, аннан аспирантура бетсен ди торгач, гомер дә шактый үтеп киткән.

– Ә малай?.. – Фәннур, үзенең соравы урынсызрак икәнен белсә дә, сорамый булдыра алмады.

– Малай Тәлгатьтән, – диде Гыйшкыя, артык дулкынланмыйча, бу хакта Фәннурның сораячагын белә һәм шуңа әзерләнгән иде.

Фәннурга кинәт кенә эссе булып китте. Унөч ел аның күңелендә нindидер матур хыял томаннарына өртелгән кыз гәүдәсен әйтерсең кемдер күкрәгеннән каерып алды. Озак еллар үз хыялына үзе ышанып, инде чынбарлык булып миеңә сеңгән идеалыңны югалту нинди авыр. Очрашмаган булсалар соң! Гыйшкыя һаман да буй җитмәслек югарыдан ашкындырып, дәртләндереп торучы серле йолдыз шикелле балкыр иде. Монда Гыйшкыяны гаепләп тә булмый. Ул бит бервакытта да Фәннурны яратмады. Шулай булгач, ник соң әле Фәннурга кыен, нигә сулышы кысыла?! Ныклабрак уйлап карасаң, Гыйшкыя һаман да аңардан өстен түгелме соң? Ялгыз килеш бала тәрбияләү, укып зур кеше булу. Боларның берсе дә Фәннурда юк бит. Бервакыт Фәннур кыр казлары очып барган вакытта берсенең алдагы каз койрыгына тотынып баруын күрде. Аларның очуын күзәткән бер бабай, бу койрыктагы казның йә күзе сукыр, йә канаты имгәнгәндер, дигән иде. Сыңар канат белән очучы казны хәтерләтте аңа хәзерге

Гыйшкыя. Ул тормышка теше-тырнагы белән ябышкан да бернигә карамый алга бара. Ләкин хәзер ул элеккеге Гыйшкыя кебек хыял кызы түгел, ә гөнаһлары, йомшаклыклары булган җир кызына әйләнде.

– Бер дә үзең турында сөйләмисең, Фәннур, – диде Гыйшкыя. – Син үзгәрмәгәнсең. Җилкәләрең бераз калынайган да йөзеңә әзрәк ирләр төсе кергән.

– Минем сөйләрлек нәрсә дә юк. Университетта да укымадым. Син авылдан китеп баргач, озакламый миңа да китәргә туры килде.

– Кара әле, Фәннур, син миңа справканы ничек алган идең? Әнкәй миңа, аның өчен сине гаепләп йөрттеләр, дип язган иде.

– Әйе, ул справка өчен миңа комсомол билетын тапшырырга туры килде. Председательнең печәтен урлап, үзем язган идем мин аны. Син киткәч, Тәлгать, нигә колхоздан Гыйшкыяны җибәрдең, дип, әтисенә бәйләнә башлаган, дөрес булса, сугышканнар да бугай. Әтисе, мин бернинди справка бирмәдем, дип ант итеп кенә котылган. Үзең беләсең, мин Тәлгатьне бер дә яратмый идем. Моның тагын да җенен кабартыр өчен, справканы Гыйшкыяга мин бирдем, дидем. Башта кычкырып көлде, имеш, каян килгән председатель. Ә хәлнең асылын бел-гәч, эшне райкомга язып җибәрде. Судка бирәм, дип тә йөргән иде, яшьләр авызлыкладылар үзен. Аннан минем армиягә китәр вакытым җитте. Армиядә чакта әнкәй үлеп киткән, мин авылга кайтмадым. Хезмәтем беткәч, бер иптәшем белән чирәм җирләр күтәрешергә киткән идек. Миңа никтер Казахстан һавасы килешмәде, баргач та авырый башладым. Кайтарып җибәрергә мәҗбүр булдылар. Хәзер Казанда яшим.

– Минем аркада зур бәлаләргә тарыгансың икән. Ә соң комсомолга кабат алдылармы үзеңне?

– Үземне аклап, яңадан комсомолга кергәнче яшем чыкты.

Сөйләшә-сөйләшә, берничә чәйнек чәй эчелде.

Фәннур киткән вакытта Гыйшкыя:

– Хәзер кайда торганлыгыбызны беләсең инде, кил-гәләп йөр, Фәннур, – дип калды.

– Килермен, Гыйшкыя, хәзергә сау бул! Сау бул, адаш энекәш!

Фәннур кайтып китте. Аның башында каршылыклы уйлар өермәсе купты. Күңелендә элекке хыялдагы Гыйшкыя белән хәзерге чынбарлыктагы Гыйшкыя көрәште. Икесен бизмәннең ике ягына салып карасаң, тормышка аек караучы, эшен һәм кешеләрне яратучы хәзерге Гыйшкыяны баса төшәр иде.

## ТАРТЫШУ

Сезнең Сабан туйларында аркан тартышкан кешеләр-не күргәнегез бардыр. Бауның бер башыннан биш-алты ир, икенче башыннан биш-алты ир бөтен көчләре белән, муен тамырлары тәмам бүртенгәнче, уч төпләре суелганчы, көчәнеп-көчәнеп бер-берләрен тарталар, көчлерәк як әкрен-әкрен көчсезрәк якны үз ягына өстери. Җи-ңелүчеләр үкчәләре белән яшел чирәмне тырный-тырный бирешмәскә тырышалар, ә җиңүчеләр, аякларын терәп, җан-фәрман сөйри бирәләр.

Менә шушы Сабан туйларындагы тартыш кебегрәк нәрсә хатын белән минем арада да бара. Ул бер якка өстери, мин икенче якка тартам. Ул алдыра башласа, мин аякларым белән җир сөрдерә башлыйм, мин көчәеп китсәм, ул җирне тырный. Озак вакытлар инициатива хатын кулында булды. Хатынымны баһадир дип тә, эш эшләп чыныгып үскән кеше дип тә әйтмәс идем мин. Нәзек кенә билле, иркә генә хатын ул. Беләкләрендәге көч тә ярты чиләк су күтәрергә генә җитә. Үзе ул тормыштан артта калган кеше түгел, шактый гына укыган. Өстәвенә көндәлек матбугат белән дә кызыксынып бара. Барысын җыеп, аның үз сүзләре белән әйткәндә, кешедән артык та, ким дә түгел. Кеше арасында йөз кызармаслык белеме бар. Ләкин безнең тартышу аның белеме уртача булудан түгел, мин үзем дә вуз бетермәгән. Вузны башлап кына ташлаган кеше. Хатын укуны сөйми икән, монысы әллә ни куркыныч түгел. Укуны сөймәгән хатын белән торып була, ә менә үзеңне сөймәсәләр торып булмый инде. Монысы – тормыш тарафыннан күп тапкырлар исбатланган хакыйкать. Әмма мин бу яктан тыныч, аның җаны-тәне белән мине яратканына тырнак хәтле дә шигем юк. Менә шулай җаны-тәне белән яратканга күрә дә тартышам мин аның белән. Яратмаса, бауның икенче башын күптән ычкындырган булыр идем инде. Кеше, көчәнеп тартканда кисәктән генә бавы ычкынып китсә, бик каты егыла бит ул.

Безнең тартышуыбыз өйләнешкәннең беренче көннәреннән үк башланды дисәм, дөреслеккә туры килеп бетмәс. Беренче көннәрдә бауны ике кулына да урап тотып, бернинди каршылыксыз хатын мине үз ягына сөйрәде. Яратып алган кешем булгач, юл куйдым. Хәер, аның беренче таләпләре минем үз теләкләрем белән туры да киләләр иде. Ул да мине, мин дә аны кеше итмәкче булып тотындык. Кеше булуны һәрберебез төрлечә аңлаганлыктан килеп чыкты

безнең тартыш. Ул башка кешеләрчәрәк яшәүне ярата төшә. Һәрнәрсәне кешегә яраган безгә дә ярар дип карый. Өйләнешергә уйлап, туйга әзерләнә башлагач та, ул, булгач-булгач кешечә булсын дип, расход-фәләненнән курыкмыйча, мул итеп аш-су әзерләде. Мин дә каршы килмәдем, туйны ел да ясап тормыйлар дип, кесә мөмкинлеге сыйдыра алган кадәр бернәрсә дә кызганмадым. Аракының кызылын да, агын да, шампанскийны да күп алдым. Хәтсездән бирле кассага салып килә торган акчаларга да урын табылды. Сый-нигмәтләр ифрат та күп иде. Күп кенә ризыклар, кухня ягына гына сыймыйча, олы якка да вакытлыча прописка сорый башладылар. Кунаклар да күп килде. Туганнарны да, дусларны да калдырмаска тырыштык. Өйдә энә тыгар урын да калмады. Бушаган бер шешәне хатын белән икәү кәрзингә тутырып тышка чыгарабыз һәм өй буендагы карга күмә барабыз. Алай да аракыны һәм төрле ризыкны куеп бетерер урын юк. Аларны кая куярга белмичә аптырашып торганда, бер соңга калып килгән кунагыбыз туй бүләге итеп балалар юындыра торган ванна алып килде. Соңга калып килгәне өчен штрафной дип, зур сыра кружкасына бер яртыны бушатып бетердек. Башка стакан-мазар юк иде. Ул, ашамаган-эчмәгән килеш, карышып-нитеп тормыйча, теге салып биргән яртыны бушатып куйган иде, озак та тормый бөтенләй йомшап төште һәм кухня ягыннан да чыга алмас булды. Без аракылы шешәләрне тегенең ваннасына тутыра башладык. Кайбер бәлеш-пәрәмәч ише нәрсәләрне дә, бик шәплап кагазьгә төреп, шунда шешәләр өстенә куйдык. Кухнябыз бераз бушап китте. Ваннаның өстен ашъяулык белән каплап куйдык та икебез дә олы якка кунакларны сыйларга чыктык. Күп тә үтмәде, кухня ягында нидер шалтыр итеп коелып төште. Мин йөгереп шул якка чыктым. Чыксам, ни күзләрем белән күрим, теге йокымсырап яткан кунагыбыз уянган да су эчәргә чүмеч ише нәрсә эзли башлаган. Шкафтан нindидер савыт тартып чыгарганда, үтүкне теге аракы шешәләре өстенә тартып төшергән. Шешәләр, үзләре белән бу кадәр рәхимсез кыланганны яратмыйча, ватылганнар да беткәннәр. Бер кырыйгарак төреп куйган пәрәмәчләребез аракыда йөзеп йөриләр. Исерешә башлаган кунаклар, аракы сорап, бу якка да керә башладылар. Кибеткә чабарга кесәләрдә рәт беткән иде. Нишләргә белмичә, кунакларга хәлне аңлатып, гафу үтенергә туры килде. Бу хәлне ишетеп, кунакларыбызның кайберләре көләргә тотынды, ә кайберләре, давай-давай, ваннасы белән өстәлгә утыртабыз, дип шаулаша башлады. Баштарак болай дип әйтүчеләрнең сүзен уенга алган идек, тик бик нык таләп итә башлагач, ышанырга туры килде. Ваннасы белән үк өстәлгә китереп утыртмасак та, ваннадагы аракыны бик рәхәтләнеп эчтеләр. Болай төрле-төрле аракыны кушып ясаган эчемлек бигрәк тәмле була икән, дип мактый-мактый эчтеләр. Кайберләренә, бәлки, ошап та бетмәгәндер дә бит, башка чара калмагач нишлисең. Менә шулай итеп, кешечә булсын дигән туебыз кешенекеннән артык та булып китте.

Туй узды. Шау-шу басылды. Бөтен кытыршылыклары белән тормыш юлы башланды. Беренче көннәрдән үк бер-беребезне бәхетле итәргә тырыштык. Тормышның беренче көннәрен ничек башласаң, шулай дәвам итә дигән сүзләрне ишеткәләгән бар иде. Шуңа күрә, һәрвакыт яхшы, һәрвакыт бәхетле генә үтсен өчен, ничек тә бер-беребезгә ягымлырак булырга тырыштык. Хатыным беренче көннән үк бик ягымлы итеп әйтеп куйды: «Мин тәмле итеп аш-су әзерли белмим, сиңа, эш кешесенә, тәм-ле дә, калорияле дә азыклар кирәк, ашханәгә генә йөрербез». Бу кадәр үзең өчен тырышкан кешегә ничек каршы киләсең инде. Каршы килә алмадым шул. «Моңа кадәр ашханәдә туена идем бит әле, моннан соң да ярар», – дип риза булдым. Тагын шунысы да бар: мин кайтканны көтеп, хатыным ач утыра. Берүзем анда чыгып йөрисем килми, ди. Шулкадәр синең кайтканыңны көтеп, ашамыйча да утырган кешегә ничек инде авыз күтәреп сүз әйтергә кирәк. Икәү бергә җитәкләшеп кенә ашарга барып кайтабыз да юл уңаеннан киногa керәбез. Дөньяның оҗмахы өйләнгәч икән. Берни өчен дә кайгырасы юк. Киемнәрем дә чиста хәзер, чөнки хатыным пычрак һәм эленке-салынкы йөргәнне бер дә яратмый. Киемнең берәр җирендә кечкенә генә тап күрсә дә, химчисткага кертеп бир син моны бүген үк эшкә барышлый, дип, киемнәремне төреп тоттыра. Беррәттән прачкага да керерсең дип, үз киемнәрен дә биреп җибәрә. Эшкә барганда бөтенесе юл уңаенда гына бит. Киткәндә кертеп чыксаң, кайтканда кереп аласың. Берние дә юк икән аның, ә мин моңа кадәр шуны да белми йөргәнмен. Бервакыт хатыныма, әзрәк эшкә өйрәнмәсме дип, эшкә керергә кушкан идем, бик тиз авызымны йомды. «Ни сөйлисең син, күгәрченкәем, – диде ул. – Мин эшкә керсәм, мине үзең дә яратмый башларсың. Сине иркәләргә, хәзерге кебек сине генә карап торырга вакыт калмас. Син бит эш кешесе. Сиңа кадер-хөрмәт кирәк, наз кирәк. Мин бөтен тормышымны синең бәхетең өчен багышларга булдым. Болай да кешедән ким тормыйбыз, бар нәрсәбез дә бар. Булмаганы әкренләп булыр».

Бу кадәр дәлилләргә каршы килерлек сүз тапмадым. Кеше бөтен яшьлеген сиңа багышлап, тәмле телләре белән иркәләп торгач, берни дә эшләп булмый шул. Колак артыңны бер кашып куясың да күнәсең. Тормыш тагын элеккечә дәвам итә башлый. Җитәкләшеп ашарга барасың, сөенә-сөенә башкасын эшлисең.

Минем өчен бөтен кадерле вакытын корбан иткән сөекле хатыным өчен үземнең дә берәр яхшылык эшлисем килә башлады. Нәрсә генә эшләсәм дә аз булыр кебек. Шул уйлар белән көн-төн баш вата башладым. Уйлый

торгач, чарасы табыла икән, тәки бер шәп нәрсә уйлап таптым. Һәм тормышка ашыруны да озакка сузмадым. Ләкин көне җиткәнче әйтми тордым. Үземә күрә бер сюрприз ясарга уйладым.

Беркөнне эштән иртәрәк кайттым да болай дидем: «Гүзәлкәем, мин бүген эштән расчёт алып кайттым, бөтен ялкынымны сиңа гына бирәсем килә». Хатынымның болытсыз күк шикелле зәңгәр күзләре кинәт зурайдылар, аннары аларны томан каплый башлады. Ә үзе егылып китүдән чак калды. Мин бу сюрпризны болай ук тәэсир итәр дип уйламаган идем, көткәннән дә ныграк килеп чыкты. «Нишләдең син, – диде хатыным, – минем турында бер дә уйламадыңмыни?»

«Синең турында уйлаганга шулай эшләдем дә инде, – дидем мин. – Кылган яхшылыкларыңа минем дә җавапсыз каласым килмәде».

Шуннан соң нәрсә булганын барын да язып тормыйм. Яши-яши савыт-сабалар да чылтырап куйгалады. Әмма мәхәббәтебез барлык каршылыкларны да җиңде. Күп тә үтмәде, хатыным эшкә керү турында сөйләнә башлады. Мин сөенә-сөенә риза булдым. Аны үзем эшли торган төзелеш конторасына эшкә урнаштырдым. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: мин эшемнән чыкмаган идем, бары тик берничә көнгә отгул гына алган идем. Тартыша торгач, безнең көрәш тәмам булды. Тора-бара тормыш арбасын икебез дә бер якка гына сөйри башладык. Болай чынлап та шактый җиңел икән. Хәзер икебез дә төзелештә эшлибез. Ул да кранчы, мин дә. Бик зур завод корабыз. Салына торган йортның бер ягында аның краны, икенче ягында минем кран тора. Ялга туктаган чакларда, краннарыбызның укларын бер-беребезгә таба борабыз да икебез бер төенчектән хатын әзерләгән әбәдне ашыйбыз. Ә кайвакыт җитәкләшеп ашханәгә дә киткәлибез. Икәүләп эшләгәч, болай йөрү тагын да күңеллерәк.

Сер итеп кенә әйтим, кайвакыт шулай тартышу файдалы икән.

## КИЛЕН КАРШЫЛАУ

Көннәрдән бер көнне Рабига апаларга Казан каласында студент шулпасы чөмереп, китап кимереп ятучы уллары Зөфәрдән мондый хат килеп төште: «Кадерле әнкәй һәм әткәй! Инде менә белем дигән Каф тавының түбәсенә менеп җитәргә күп калмады. Түш кесәгә дипломны салып сезнең тарафларга кайтып кергәнче, әзрәк көч җыеп алырга дип уйлап торам. Сыйларыгызны әзерли башлагыз. Кайтканда, үзем белән бик симпатичный бер овчарка алып кайтам. Әкәмәт шәп нәрсә. Күрсәгез, сез аңа үзегез дә үлеп гашыйк булачаксыз. Ул күзләре, мин сезгә әйтим, безнең авылның иң чибәр кызларында да андый күзләр юктыр. Ул гәүдәсе, сөлекнең сөлеге. Кем әйтмешли, бер кашык су белән йотып җибәрерлек. Бүлмәмә кайтып керүем була, мине үбәргә тотынуы була. Мин үзем дә аны күрмичә бер көн дә тора алмыйм. Кайвакытларда лекция язасы җирдә аның рәсемен ясап утырам. Әле менә мин сезгә хат язам, ә ул иркәләнеп минем янда сырпалана. Исеме дә бик матур – Сильва. Итне бик ярата. Шоколад ише нәрсәләрдән дә баш тартмый. Кыскасы, сыйларыгыз сыек булмасын. Бер атнадан кайтып җитәрбез».

Бу хатны алгач, Рабига апа бик нык аптырашта калды.

– Нәрсәгә кирәк булды икән безнең малайга әбчәрке, ә? – Һәм, соравына җавап көтеп, ире Фатыйхка текәлде.

– Ызначит, кирәктер, – диде Фатыйх, исе китмәгән төстә. – Малай кеше ни белән мавыкмас?!

– Безнең Зөфәрнең эт белән уйнар чагымыни? Армиядән кайткан. Институтын бетереп, менә-менә инженер булырга тора. Ә син малай дисең...

– Малайны кыз димәм инде.

Ата белән ана әнә шулай әрепләшеп алдылар. Билгесезлек аларның эчләрен тырнап торды. Хатны кат-кат укыдылар. Укыган саен аңлашылмаулары артты, шикләре көчәйде. Җаннарын кимергән сорауга җавап таба алмый утырганда, күршеләре Гөлбәдәр карчык килеп керде.

– Әллә улыгыз Дөфәрдән хат бармы? – дип сорады ул, Рабиганың кулындагы зәңгәр конвертны күреп.

– Бар иде шул, – диде Рабига.

– Ниләр яза? Кайчан пырафисыр булып чыга инде?

– Озакламый диплом алабыз, дигән. Шушы көннәрдә кунакка кайтырга исәп бар, дигән. – Рабига хатны кулында әйләндергәләп торды һәм: – Тик менә, Гөлбәдәр түти, Зөфәрнең хатыннан бер нәрсәне аңлап җитмәдек әле: ул, үзем белән бер әбчәрке апкайтам, дигән. Нигә икән безнең малайга эт, әй?

– Кит аннан! «Әбчәрке апкайтам» дигәнме? – Гөлбәдәр түтинең күзләре сигез литрлы самавырның чәен ялгызы эчеп бетергән чактагы шикелле ялтырап киттеләр. – Каяле, кая? Хатын укып карыйк әле.

Рабига хатны кычкырып укый башлады. Гөлбәдәр түти, яхшырак ишетер өчен, яулыгын читкәрәк шудырып колакларын чыгарды һәм бик игътибарлап тыңлый башлады. Кайбер җөмләләрне кабат-кабат укытты, ә үзе

башкалар белмәгән серне төшенгән кыяфәт белән каш астыннан гына елмайгалап утырды. Хат укылып беткәч, ике куллап ботына чапты:

– Аңлашылды, Рабига килен, аңлашылды. Болай булгач, итәк-җиңнәрегезне җыйгалый башлагыз.

– Син нәрсә, Гөлбәдәр түти? Аңлатыбрак сөйлә әле.

– Хи-хи-хи! Үзең уйлап кара инде, Рабига килен. Әбчәрке нәрсә ул?

– Нәрсә дип... эт!

– Этен эт. Әмма ләкин прастуй эт түгел. – Рабиганың һаман төшенеп җитмәвен күреп, болай дип өстәде: – Син, Рабига килен, бигрәк беркатлы кеше икәнсең. Дөфәрегез өйләнеп кайта. Әбчәрке – килен инде ул. Әнә бит ничек тәфсилләп язган. Кем инде этнең күзенә карый. Ликсия вакытларында рәсемнәрен ясап утырырлык булгач, беткән малаегыз, кулдан ычкынган.

– Булмаганны. Киленне әбчәрке дип әйтмәс иде.

– Абразауный кешеләрдән чыга җыен шундый сүзләр. Моңа исең китмәсен, абразауный кешеләр синең белән мин түгел алар.

Яшермичә генә әйткәндә, Рабиганың үз күңелендә дә шундыйрак шик туган иде. Казан тикле Казаннан кем инде эт иялтеп йөрсен? Авылда беткәнмени алар. Әнә хатын ничек тәфсилләп язган. Эт турында андый мәхәббәтле хат язар идемени? Ярый әле Гөлбәдәр түти керде.

Ә Гөлбәдәр түти үз зирәклегеннән үзе сокланып сөй-ләнә бирде:

– Исеме Силбы, дигән. Безнең халык түгелдер. Абразауный кешеләр марҗага кызыгучан.

Гөлбәдәр түти Рабиганың йөрәгенә ут салып чыгып китте. Ә икенче көнне инде Зөфәрнең өйләнеп кайтуы турында бөтен авыл сөйли иде.

Рабигалар, пыр тузынып, туйга әзерләнә башладылар. Күрше-тирә хатыннар җыелып өй юдылар, мич агарттылар, Фатыйх кыш чыккан бозауны егып суйды. Килен ит ярата икән, рәхәтләнсен. Рабига, пешеренергә оста хатыннарны дәшеп, төш пешертте, чәкчәк катырды. Җай чыккан саен кибеткә сугылып, тегесен-монысын алдылар. Шәһәр кызы алдында оятка калырлык булмасын.

Зөфәрнең кайтыр көне җиткәндә, олы якка мул итеп табын әзерләнгән, өйгә тәмле ит исе таралган иде.

Менә бервакыт капка төбенә җыелган балалар: «Кайталар, кайталар», – дип кычкырып җибәрделәр. Рабига апа белән Фатыйх абый йөгереп ишегалдына чыктылар. Анда соры овчарка җитәкләгән Зөфәр басып тора иде.

## КЫЗЫЛ ТАПЛАР

Ире санаторийга китеп ике-өч көн тору белән, Халисә үзендә ниндидер үзгәреш сизә башлады. Эч пошумы бу, сагыну яки юксынумы? Алай дисәң, эч пошарга сәбәп күренми. Тормышы гадәтенчә ага бирә: вакытында эшенә барып кайта, өен җыештыра. Ә сагыну, ярату дигән төшенчәләргә Халисә көлеп кенә карый. Ире аның ике ятып бер төшенә дә керми. Бәлки, көнләшәдер? Бусы Халисә өчен бигрәк көлке нәрсә. Ул мәхлуктан ничек көнләшмәк кирәк?! Гомерендә чит-ят хатын-кызга күз сала торган гадәте юк. Бу ягын Халисә күп мәртәбәләр сынады инде. Тегенди-мондый мәҗлесләргә барырга туры килгәндә, ирен ул юри чибәррәк, чытлыграк хатын-кыз янына утыртырга тырыша. Үзе читтән генә, иренә сиздермичә, күзәтүләрен алып бара. Ә ире, ипи заты күрмәгән сарыкка телеме белән күмәч сузгандай, аптырап, гаҗәпләнеп чибәрләргә карап ала да башын читкә бора. Мондый чакларда ул бик көлке кыяфәткә керә. Йә кулыннан чәнечкесен төшереп җибәрә, йә алдына ни китерсәләр, шуның барысын сыпырып ашап бетереп бара. Халисәгә шул гына кирәк тә, ул иренең үз-үзен тотышыннан рәхәтләнеп көлә. Әйе, көнләшергә иренең һичнинди сәбәп биргәне юк. Алайса, нәрсә борчый, пошындыра Халисәне? Борча тешләгәндәй, төн урталарында сикертеп торгыза, кайвакыт кыздырырга куйган бәрәңгесен табасы-ние белән стенага сыларлык хәлгә җиткерә. Шулар өстәвенә тагын битенә кызыл таплар чыга башлады. Юк, ярамый болай, врачка күренергә кирәк. Ирең кайтканчы үлеп куйсаң, сагынудан үлгән дип шатланыр.

Әмма врач Халисәне юатырдай нәрсә әйтмәде. Күбрәк һавада йөр, физкультура белән шөгыльлән, тынычланырга тырыш, дип кенә җибәрде. Ичмасам, күңел өчен берәр таблетка язса иде.

Халисәнең моңарга җен ачулары чыкты. «Җыен әрәмтамак шушында җыелган, эшләмичә акча алып яталар. Бөтенесен утлы табага бастырасы бар», – дип сукрана-сукрана кайтты ул өенә. Икенче көнне, бушлай карый торган җирдә адәм рәтле кеше эшлимени дип, түләүле поликлиникага китте. Аның бәхетенә каршымы, бәхетсезлегенә каршымы, анда чират бик зур иде. Чиратсыз керергә тырышып, ике-өч кеше белән ут өереп талашканнан соң бераз тынычланып, арткы урындыкларның берсенә утырды. Чират көткәндә, һәркем үзенә якынрак утырган кешегә моң-зарларын түгәргә тырыша. Бер-берләренә киңәшләр бирешү, нинди чирне ничек дәвалау турында фикер алышулар

башлана. Бу юлы да шулай булды. Халисә урындыкка килеп утыру белән, урта яшьләрдәге бер хатын аның йөзендәге тапларга текәлде.

– Нәрсәгә бәбәгеңне акайттың? – диде Халисә. – Психлар йортыннан чыккан маймыл күрмәгәнсеңдер бит.

– И-и, иптәшкәем, – диде теге хатын, Халисәнең сүзләрен бөтенләй ишетмәгән төсле. – Сезнең чирегез миңа бик таныш.

– Шулаймы? – диде Халисә, басыла төшеп. – Әллә сез дә минем кебек авырдыгызмы?

– Нәкъ сезнең төсле. Менә бу биттәге тапларга кадәр бертуган. Муеныгызда да бармы?

– Бар, бар. Менә! – Халисә, изүен ачып, муенын күрсәтте.

Теге хатын, күктән эзләгәнне җирдән тапкан кеше кебек, сөенеп сөйләргә тотынды:

– Сезгә, дускаем (хәзер инде ул Халисәне «дускаем» дип атый иде), врачка күренеп торуның хаҗәте юк. Фән телендә сезнең чирегез «стресс» дип атала. Моны миңа бер таныш профессор әйтте.

– Анысы нәрсә тагын?

– Анысымы? Анысы менә шул: кеше дигән нәрсә машина аккумуляторы төслерәк икән ул. Зарядка алу чоры була, бушану чоры була. Аккумуляторга туктаусыз зарядка биреп торсаң, кислотасы кайный, пробкаларны бәреп чыгара, хәтта стенасын тишә. Андый чакта бушану кирәк.

– Таптыгыз шаярыр нәрсә! – диде Халисә, яңадан кыза башлап. – Мин сезне рәтле сүз сөйли дип торам. Сез әкият сатасыз икән.

Халисә бер кызса, туктату кыен иде, теге хатын да аның кызу учагына утын өстәп торды. Тел тегермәнен шактый әйләндергәннән соң, бермәлне икесе берьюлы туктап калдылар. Теге хатын, әле яңа гына талашканын онытып, кечкенә сумкасыннан саплы көзге чыгарып, Халисәгә сузды.

– Әйттем бит мин сезгә бушану кирәк дип. Менә йөзегезгә карагыз әле, борын очындагы җәенке табыгыз кечерәйде бит.

Халисә ышаныр-ышанмас көзгегә үрелде. Борын очындагы тап ярыйсы ук бәләкәйләнгән кебек тоелды аңа. Эшләр болайга киткәч, әңгәмәдәшенең авызына керергә җитешеп, йотылып тыңлады.

– Менә әйттем бит, – дип кабатлады теге хатын. – Мөгаен, сез өйдә ялгыз калгансыздыр. Эштән зарядка алып, кайнап кайтасыз, ә бушаныр кеше юк. Шулаймы?

– Әйе. Ирем курортка киткән иде.

– И җанкисәгем. Мин кешене бер күрүдә таныйм. Ирегез күптән киттеме?

– Атнадан артты инде.

– Ирегез кайтырга күп вакыт бар икән алайса. Аңынчы сез эштән чыгачаксыз. Болай ярамый, ярамый. Без, хатын-кызлар, үзебез турында кайгыртырга тиешбез.

– Нишләргә соң инде миңа?

– Мин үзем болай иттем. Өрми-тешләми торган бер эт баласы алып, шуңарга иремнең исемен куштым. Үземдә әз генә пошыну, тынычсызлану билгеләре сиз-сәм, шуңарга ябышам. Эттән алып эткә салам. Ишәк, димен, күсәк, димен. Кешеләрнең ирләре хатыннарына ярдәм итешә, син йокы симертәсең, димен. Билгеле, һәркемнең үз репертуары инде. Башкачарак әйтергә дә мөмкин. Анысын иреңнең характерыннан чыгып эш итәсең. Кыскасы, шул: иреңә әйтәсе сүзләрнең барысын көчеккә әйтә торасың. Шуннан бераз бушанып каласың. Бер атна дигәндә, тапларыңның эзе дә калмас. Төннәрен, ирең барындагы кебек, үлеп йоклый башларсың. Аппетитың ачылыр, кәефең күтәрелер. – Хатын киңәшләрен шулай тезде. Соңыннан ул: – Көчек никадәр юашрак булса, шуның кадәр яхшырак. Усал көчек, ачуланган чагында өреп, начар реакция тудыра. Теләсәң-теләмәсәң дә, табагачка барып ябышырга туры килә. Этне үзең беләсең, ул синә ирең түгел. Суксаң тешләве бар яки үлеп китүе.

Халисәнең врачка керергә чираты җиткән иде, ләкин ул, үз чиратын арттагы кешегә калдырып, базарга чапты. Анда арзан гына бәягә бер үләр-үлмәс көчек сатып алды һәм, өйгә кайтып җиткәнне дә көтмичә, юлда ук иренә әйтә торган сүзләр белән көчекне «сыйларга» тотынды. Мескен көчек, сумкадан башын чыгарып, нәкъ Халисәнең ире кебек, күзләрен мөлдерәтеп, тавышсыз гына ята бирде.

Ә өч көннән Халисәнең чире юып алган кебек юкка чыккан иде.

## ТӘРБИЯ ДӘРЕСЛӘРЕ

*(Юмореска)*

Җәмил абзый үзен авылның иң акыллы, иң белдекле кешеләреннән саный. Клуб тирәсендә яки кибет янында яшь егетләрнең җыелып торганын күрсә, ул тизрәк шунда ашыга. Әгәр инде авызына «шайтан төкереге» дә эләксә, яшьләрне «тәрбияләмичә» булдыра алмый.

– Җегетләр, – дип килеп җитә ул алар янына, – белеп торам: сез кызлар турында сүләшәсез. И һәм дөрес эшлисез, җегет чагында кызлар турында сүләшергә кирәк. Әмма ләкин Җәмил абзагызны да тыңлап карагыз әле. Үзегез беләсез, Җәмил абзагыз авылның прастуй кешесе генә түгел. Җиде катын аерып, сигезенчесенә өйләнгән Җәмил абзагыз бу! Йә әйтегез, бармы бүтән мондый кеше?!

Ул күкрәгенә сугып куя. Яшьләр аңа сиздерми генә елмаешып алалар.

– Тәрбия дәресләре бирергә килдеңме, Җәмил абзый? – дип, арадан берәрсе төрттереп куя.

– Ә нигә? – ди Җәмил абзый. – Сезнең ише кикриксез әтәчләргә үрәтерлек акыл бар бездә. Чүтеки җиде катын аерган кеше бит мин. Ә бер катын аеру иң кимендә бер пужарга тиң, ди, прафисырлар. Җиде тапкыр янып исән калып карагыз әле. Сез дә үрәтерсез акылны.

– Әйдә, башлап җибәр алайса, – диләр яшьләр.

– Ә нигә башламаска? Башлыйм. Менә, пример, сез, җегет аламалары, йөргән кызларыгыз белән нәрсә турында сүләшәсез?

– Төрлесен инде, – диләр яшьләр.

– Мин белеп торам, – дип дәвам итә Җәмил абзый, – йөргән кызларыгызга «гүзәлем», «фәрештәм» дигән булып башларын әйләндерәсез инде сез.

Яшьләр, аның ни әйтәчәген алдан белгәнлектән, Җәмил абзыйны кыздырып җибәрер өчен: «Әйе, әйе, «гүзәлем» дибез, «фәрештәм» дибез», – диләр.

– Стоп, җегетләр, – дип туктата аларны Җәмил абзый. – Кызларыгызга мондый сүзне ялгыш та әйтә күр-мәгез.

– Нигә? – дигән булалар егетләр.

– Потому что, – ди Җәмил абзый һәм, егетләрнең игътибарын үзенә юнәлтер өчен, озак кына пауза ясый, – потому что өйләнгәч, «убыр», «җен», «мунча пәрие» диячәксез.

– Ул мунча пәрие булмаса дамы?

– Өйләнгәч, мунча пәриенә әйләнмәгән хатын-кыз жук ул. Моны сезгә сигез хатынга өйләнгән Җәмил абзагыз әйтә.

– Йә, йә, – диләр егетләр, – кызларга тагын ни диергә ярамый?

– Тагынмы? Ялгышып та «акыллым» дия күрмәгез.

– Монысы нигә, Җәмил абзый?

– Потому что озакламый сез аңа «чүпрәкбаш», «тавык мие эчкән нәрсә», «аңгыра сарык» ди башлаячаксыз. И һәм сезгә «акыллым» дигән сүзләрегез өчен кызарырга туры киләчәк.

Егетләр, аңардан мондый «акыллы киңәшләр»не шактый еш ишеткән булсалар да, киңәшләрнең яңараклары чыкмасмы дип, кызыксынучанлык күрсәтәләр. Ә Җәмил абзыйның «акыллы киңәш»ләре гел артып тора. Ул, йөзенә серлелек чыгарып:

– Берүк кызларыгызга «уңганым» дия күрмәгез, – ди.

– Ә ул уңган булса?

– Пущай уңган булсын. Дөнья бит ул бүгенге көн белән генә бетми. Син менә шул уңган кызыңа өйләнеп җиффәрәсең. Күпмедер вакыт күгәрчендәй гөрләшеп яшисез, ди. Әмма дә ләкин дөньяда кәефсез чаклар да була. Йә сине нәчәлнигең сүгә, йә эшләгән эшең барып чыкмый. Тормышың җүнләп бармаса, ачу чыга. Ә ачуны кемнән аласың? Әлбиттә инде, катыннан. Мондый чакта, ап-ак итеп юып куйган керләрне типкәләп, «шапшак» дисең, тәмле пешкән ашны умыра-умыра, «өшегән бәрәңге, юньләп аш та пешерә белмисең» дип битәрлисең. Әгәр дә мәгәр син аңарга өйләнгәнче «уңганым» дип сайрасаң, катын дигән нәрсә йөзеңә шул сүзләрне чәпәячәк. Ир кеше һәрвакыт чигенергә юл калдырырга тиеш. Ягъни мәсәлән, керереңнән алда чыгарыңны уйла.

– Тагын, тагын? – диләр егетләр.

– Тагынмы? Соң, егетләр, яшь чакта без бит шыр дурак булабыз. Сөйгән кызларыбызның тавышы былбыл сайравыннан матуррак тоела. «Былбылым», «сандугачым» дигәнеңне сизми дә каласың. Әйткән сүз – аткан ук. Аны кире кайтарып алып булмый. Ә донҗа көтә башлагач, катының гел сандугач булып кына сайрамый. Карга булып та каркылдый. Менә шундый чакларда катыныңа авыз тутырып «сакау карга» дия алыр өчен, өйләнгәнче «былбылым» сүзен ычкындырудан сакланырга кирәк.

– Бу мәсьәләдә тәҗрибә зур инде синең, – дип куялар егетләр.

– Анысы җитәрлек, – ди Җәмил абзый, канәгать елмаеп. – Әле мин сезгә иң глауныйларын әйтмәдем.

– Ягъни мәсәлән? – диләр егетләр, аныңча итеп.

– Ягъни мәсәлән, мәгъшукаларыгызга «бердәнберем» диюдән асубый сакланыгыз. Юкса: «Синең кебекләрне мин йөзне табам», – дигәндә, катыныгыз, элекке сүзләрегезне әйтеп, үзегезне оялтып куяр.

– Тагын да глауныйрагы калмадымы, Җәмил абзый? – диләр егетләр.

– Ник калмасын? Бар ул бездә. Глауныйның да глауные «яратам» сүзен теш арасыннан чыгара күрмәгез.

– Нигә, Җәмил абзый?

– И аңгыра башлар. Нигә дип сорап торасыз тагын. «Яратам» дип әйттеңме, беттең инде, катын-кыз синнән аркан ишә, сине колы итә. Яраткач, фәлән нәрсә эшлә, төгән нәрсәне ал, ди. Әгәр яратам димәсәң, ул баш вата, интегә, уйлана, йокысы кача. Бу мине яратсын әле дип, кылны кырыкка яра. Сиңа сырпалана, песи кебек аякка урала. Син мине яратасыңмы, мин сине яратам, ди, ә сиңа шул гына кирәк. Бер ачуың чыкканда, «яратам» дип башымны әйләндерден дип китереп чәписең үзенә. Катының өнсез кала. Менә шулай, җегетләр, сүзне чамалап әйтергә кирәк. Ә иң глауные...

Җәмил абзый иң глауныен әйтергә өлгерми кала. Аның сигезенче хатыны Җәмиләнең каяндыр тавышы ишетелә:

– Җәмил, Җәмил, дим, карт тәре, кая югалдың инде, кайт тизрәк?! Аш пеште.

Җәмил абзый, әйбер урлаганда тотылган баладай каушап:

– Хәзер, карчыгым, кайтам, сандугачым, – дип, ашыгып китеп бара.

## ЭЧТӘЛЕК


Төзүчедән. *С. Хәкимова* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

**Повестьлар**

Тамырлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Фаҗига . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

**Хикәяләр**

Әйтелми калган сүз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Борчылмагыз, балалар, мин тиз генә китмим әле . . . . . . . .
Сара түти шәһәргә бара . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Колхоз умарталыгында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Әйтмичә ярамый, кызым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Иң кадерле байлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Бәрәңге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кнопка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Аерылышканда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Менә шулай, кодагый! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Күршеләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Күңелле ял . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Рәхмәт яусын! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Май төне . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Шөпшә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
«Сандугач» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Сабан туенда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Гыйльминур карчык курортта . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Посылка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кузгалак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Соңгы балкыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Авылга театр килгәч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Ышансагыз ышаныгыз... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Хәйлә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Зәлифә ире . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Әйбәт кеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Сәер кунак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Итекчене читекче . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Каршылау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кайгырту . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кешегә дип . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Качу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Күңелле сәяхәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Сагыну . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Туй алдыннан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Ике күрше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Соңгы хәбәрләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Шикләнүчән Тимербулат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Яралы күңел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Ана һәм бала . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Урманчы кызы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Авыл Апушы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Чигүле күлмәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кырыс медсестра . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Шикләнү бәласе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Игелекле бәндәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Дөньясы – эт оясы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Дуслык шуннан башланды . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Нурмигөл түти догасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Ахырзаман карты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
«Кара көн» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Сүзсез аңлашу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Сизгерлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Гыйшкыя хыял кызы түгел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Тартышу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Килен каршылау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кызыл таплар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Тәрбия дәресләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Литературно-художественное издание

**Яруллин** Фанис Гатауллович

**НЕВЫСКАЗАННОЕ СЛОВО**

Составитель **Хакимова** Савия
(**Мингазова** Савия Галимзянова)
Казань. Татарское книжное издательство. 2013
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Яруллин** Фәнис Гатаулла улы

**ӘЙТЕЛМИ КАЛГАН СҮЗ**

Төзүчесе **Хәкимова** Сәүия
(**Минһаҗева** Сәүия Галимҗан кызы)

Мөхәррире *Л. Ә. Гыйззәтуллина*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р. Х. Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Ф. Р. Гыйсмәтуллина*
Корректорлары *Г. Г. Габдуллазянова, Л. Р. Галимова, Р. Н. Нуриева*

Оригинал-макет-тан басар-га кул куелды 11.02.2013. Форматы 84х108$^{1}/_{32}$.
Шартлы бас-ма табагы 23,52. Ти-ражы 3000 д. За-каз

«Та-тарстан китап нәш-рияты» ДУП. 420111. Ка-зан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: info@tatkniga.ru**

**Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча сатып алырга мөмкин:**

Ка-зан, Де-каб-ристлар урамы, 2.
Та-тарстан китап нәш-риятының маркетинг бүлеге. Тел.: (843) 519-45-35.
Ка-зан, Бауман урамы, 29/11.
Та-тарстан китап нәш-риятының фирма кибете. Тел.: (843) 292-03-18.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиг-рафия-нәш-рият комплек-сы.
420066. Ка-зан, Де-каб-ристлар урамы, 2.